
# Казан утлары

8.2000



# 30 АВГУСТ — РЕСПУБЛИКА КӨНЕ











# Казан утлары
# Qazan utları

*2000*

**8**

**(934)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Гәрәй Рәхим**
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ. Хәтер иляләре. *Шигырьләр.* ... 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Иртәләгән сагыш. *Роман. (Р. Фәйзуллин кереш сүзе белән)* ... 12
Рифкать ЗАКИРОВ. Мөлдер-мөлдер аһән-моңнар бар. *Шигырьләр* ... 93
Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА. Дөнья буйлап үтеп барышлый. *Шигырьләр* ... 99
Вазыйх ФАТЫЙХОВ. Сиртмәле кое чиләге. *Шигырьләр* ... 126

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Факил САФИН. Җаек буе — яу җире ... 103

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Эзләнүләр бәрәкәтлеме? ... 131
Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Онытырга хакыбыз юк. *(Рецензияләр конкурсына)* ... 137

**ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ**

КОРЪӘН татар телендә ... 142

**ФӘН**

Рәшит ГАЛЛӘМОВ. Татар халкы оешуга яңа караш ... 165

**ХӘТЕР**

Марсель ЗАРИПОВ. Хакыйкатькә юл озын ... 175

**САФА САБИРОВКА 85 ЯШЬ**

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ. Үз заманы баласы ... 183

**SALİX BATTALNIŊ TUUINA 95 YIL**

Salix BATTAL. Tuğan yağıma. *Şigerlər* ... 186

Укучы сүзе ... 185
Безнен календарь ... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 190
Тышлыктагы сурәтләр ... 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: начало романа Р. МИРХАЙДАРОВА «Ранняя печаль» *(с предисловием Р. ФАЙЗУЛЛИНА)*; стихи М. АГЛЯМА, Р. ЗАКИРОВА, Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ, В. ФАТЫХОВА.
«Публицистика»: историко-публицистическая статья Ф. САФИНА «Край Яицкий - поле брани» *(окончание)*.
«Литературная критика»: статья А. АХМАДУЛЛИНА «Результативны ли поиски?».
«На конкурс рецензий» А. ЗАКИРЗЯНОВ рецензирует книгу Ф. Байрамовой.
«Жизнь и религия»: Коран на татарском языке.
«Наука»: статья Р. ГАЛЛЯМОВА. «Новый взгляд на происхождение татарского народа».
«Память»: М. ЗАРИПОВ. «Длинный путь к истине».
В номере отмечаются 95 - летие С. Баттала и 85 - летие С. Сабирова.
Слово читателя.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Сююмбике - последняя царица Казанского ханства» - работа художника Ш. Шайдуллина; писатель Данил Салихов.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": the begining of R.MIRHAIDAROV'S novel «The early sadness» (with R.FAIZULLIN'S preface); the verses of M.AGLAM, R.ZAKIROV, SH.ZIHANGIROVA, V.FATIHOV.
«Publicism»: F.SAPHIN"S article «Yaisk region - field of battle» (ending).
«Literary criticism»: A.AKHMADULLIN'S article «Have quest result?»
«Review competition»: A.ZAKIRZANOV'S review of F.Bairamova's book.
«Life and religion»: Koran in Tartar.
«Science»: R.Gallamov"s article «The new view of Tartar"s origin».
«Memory»: M.ZARIPOV «The long way to truth».
«Commemorating the 95th anniversary ofs. Battal and 85th anniversary ofs. Sabirov».
«Reader"s word».
Our calendar.
The diary of social and cultural life. On our covers: «Suumbika - the last queen of Kazan boorishness» - Sh.Shaidullin"s work; writer Danil Salihov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 15.03.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7542 Заказ Э-301
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел—Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.

## ШИГЪРИЯТ



# Мөдәррис Әгъләм

### ХӘТЕР ИЯЛӘРЕ

## Утызынчы август

*Йөрәк кайный, тулып диңгез*
*кадәр көчле теләкләрдән...*
Нәкый Исәнбәт 1916 ел.

**Килде бер тетрәнү—**
**Мәйданнар күкрәде,**
**Шомланып,**
**Сискәнеп тураеп куйдык...**
**Бер төнлек бар иде кап-караңгы якка,**
**Уянып, кояшка тәрәзә уйдык.**

**Ә аста...**
**бер таштан бер ташка**
**Сикерә-сикерә йөгерә инеш...**
**Шулкадәр ихласи яшәеш барында**
**Инешкә күңелсез булмаска тиеш...**

**Тәрәзә уясы... булган бит.**
**Кояшы җан бирде бу өйгә...**
**... Күк-түбә биек...**
**Кемнәрдер һаман да бу өйгә сыймады,**
**Яшәмәк булалар дөньяны киеп.**

**Ә аста...**
**бер таштан бер ташка**
**Сикерә-сикерә йөгерә инеш...**
**Шулкадәр нарасый хәрәкәт барында**
**Кешеләр яманлык кылмаска тиеш.**

**Үзенчә әләме,**
**Үз телдә сәламе—**
**Бер колак салыгыз,**
**Калыгыз танып!**

Утларга да керде, бирәсен дә бирде,
Яшәсен, ниһаять, аласын алып.

Ә аста...
бер таштан бер ташка
Сикерә-сикерә йөгерә инеш.
Мәңгелек агымнар тынмаган мәлдә
Адымнар тукталып тормаска тиеш.

Гасырлар төбеннән
Сакланып киленгән
Гыйбрәтләр алырлык дәүләти калып...
Үзенчә сөенсен,
Үзенчә киенсен
Дөньяга колагын үзенчә салып...

Ә аста...
бер таштан бер ташка
Сикерә-сикерә йөгерә инеш...
Агымы үзенең иркендә булганда
Чит-ятлар бәхетен ормаска тиеш.

*1998*

## Бытбылдык

Тирә-якта юк бит болын да,
Аваз бирдең кинәт юлымда,
Шаккатырып мине, бытбылдык,
Син генәме... без дә юк булдык.

Болыннарны сөрдек, таптадык,
Биләмәңне аттык актарып—
Син кайткансың янә, бытбылдык,
Колак салып торам таң калып.

Үтмәсләнде зиһен кайчыбыз,
Туган җирен белми кайсыбыз—
Себер якларында, бытбылдык,
Нәсел-нәсел булып юк булдык.

Халыкларны туган ягында,
Үз аңында түгел чагында
Афәт, афәт, афәт, бытбылдык,
Сагалады һәрбер адымда...

Сиптеләр шул безне, чәчелдек...
Булдык язгы, көзге чәчүлек...
Койрыкларны кыстык, бытбылдык,
Шулай өрми торган эт булдык.

Син бәхетле, син бит канатлы.
Без дә атлы идек, пар атлы.
«Держиморда»лары, бытбылдык,
Авыз-борыннарны канатты.

Туган җиргә күңел суынды,
Шатлыгыннан Иблис уынды—
Белә-белә бөлдек, бытбылдык,
Белә-белә яман эш кылдык.

Үзебезне салып таптадык,
Хаҗәт түгел тору акланып.
Син кайткансың әнә, бытбылдык,
Өмет белән карыйм...
Таң калып...

## Бәлки...

Илем, бәлки, Оренбурдыр,
Өст тархандыр, Аст тархандыр.
Кирәксә, кирәкмәсә дә
Сукнандыр дөнья, каккандыр—
Кемдер илкәен югалтып,
Кемдер үз илен тапкандыр.

Илем, бәлки, Сембердәдер,
Ә кем белә—Чиләбедер...
Бүген ил эзләп ятулар
Чын-чынлыклап чиләнүдер,
Һәм тишексез иләк аша
Әкияти иләнүдер.

Бәлки, Татар Бугазыдыр?
Ә кем белә—Өркеттәдер—
Әнә шулай уйлый алу
Бәлки безне ир итәдер!
Ә чынлыкта безне әле
Дәүләтсезлек өркетәдер.

Илем, бәлки, Самарадыр,
Инде килеп Сары Таудыр—
Яулар арты яулар килгән,
Тел бетмәгән—күпме яудыр!
Бу чынлыкта тәңребездән
Хаклык өчен ярлыкаудыр.

Илем, бәлки, Тубылдадыр,
Кем белә бит, Төмәндәдер—
Эчтә калсын—серләреңне
Сөйләмәче кемнәргәдер.
... Ил турында әле, бәлки,
Өметләрең көмәндәдер.

Бәлки, төп халкың яшәгән
Күршедәге Өфедәдер?
Тик саташма, азау ярган
Иблис белән син бергә-бер.
Мең биш йөздә илле икедә
Кара көздә килгән әмер:
Җирең инде урыс, дигән
Чукынырга тырыш, дигән...

Татарстан дигән бер зат
Канат җәйде бу арада...
Ә татармы?
Бетмәс, бетмәс...—
Иблиснең дә көче җитмәс—
Орлыгы да, аңа киткәч,
Түгел аның Бохарада...

## Хәтер көне

Йомыркадан чыккан чебеш кебек
Таш капчыктан чыгып килә бәндә...
Айкалган да халык,
Чайкалган да,
Чайкалган да халык, түгелгән дә...
Дүрт йөз елдан артык яшәсәң дә
Бабаларың, даны исәбенә,
Хәтерсезлек хәтәр!
Яшәп булмый
Хәтерләмичә генә, хәтерләмичә генә.

Күпереп торган илне изү, басу,
Камыр азык ясау дәвам итте...

... Һәм, ниһаять
Өркетелгән милләт,
Кимсетелгән милләт... тәпи китте—
Айны тәре белән алмаштырып
Җигелсәң дә Мәскәү мичәвенә,
Хәтерсезлек хәтәр!
Яшәп булмый
Хәтерләмичә генә, хәтерләмичә генә.

Инде шөкер, ата-бабаларның
Рухын искә алыр мөмкинлек бар,
Иман эстәү
Эзсез калмас, дигән,
Болай бармас, дигән бер өмет бар,
Казан урамнары чүплек базын
Хәтерләтә иде кичә генә...
Хәтерсезлек хәтәр!
Яшәп булмый
Хәтерләмичә генә, хәтерләмичә генә.

Күмелмәгәне һәм күмелгәне,
Күз яшьләре булып түгелгәне—
Нәүмиз булып күзгә карап тора
Бер гөнаһсыз кеше гомерләре,
Кисә генә Иблис, кисә генә
Безнең балаларның исәбенә...
Хәтерсезлек хәтәр!
Яшәмәгез
Хәтерләмичә генә, хәтерләмичә генә...

## Рәхмәт сиңа

Галиҗәнаб көзләр исеменнән
ачык калган балкон ишегеннән
үрмәләде суык:
колак яфраклары куйды зеңләп,
яңа иртә киңлекләрне иңләп
килә иде туып...

Рәхмәт сиңа!
Ул уятты безне,
ул уятты безнең күңелебезне—
миләш кебек әче...
Фәрештәләр безгә кулын сузды,
сизгер суык безнең җылыбызны
алып өлгергәнче.

... Һәм капланды ир өстенә дулкын,
ике тән бер булып торды бер тын,
бүтән дулкын какты!

Галиҗәнаб Вакыт исеменнән
көз көнләшеп балкон ишегеннән
сузылып эчкә бакты;
еламсырап койды яфракларын...

Бик тә таныш хәлләр—шулай ярым
сагышланган чакны...

Җилли-җилли балкон ишеген япты,
әллә каян гына болыт тапты,
яңгыр тәрәз чиртә...
Ничек инде Көзгә үпкәлисең?
Рәхмәт, Суык, уятканың өчен,
рәхмәт сиңа, иртә!

... Күкрәгемә башын салып
йоклап китте иркә—
яңгыр тәрәз чиртә...

## Саулыгың кыйбат

*Рафаэль Сибатка*

Түбән Шөн түгелдер, бәлки,
Түбән Сөндер ул—
Бөтен табигате беләң,
Бәлки, синдер ул?

Халкы изелгән, сытылган
Нократ яклары...
Табигатьнең ташып чыккан
Олпат яклары.

... Синдә кунак булдык,
Рәхмәт,
Рафаэль Сибат—
Булуың дөнья бәһасе,
Булуың кыйбат.

Заман—яман! Безнең өскә
Сикерә генә...
Әмма ир-егетләр аңа
Төкерә генә.

«Ил төкерсә, күл була» ди,
Күлмени—Елга!
Боз астыннан агып керик
Киләчәк елга.

... Бу авыл Түбән Шөн түгел,
Түбән Сөндер ул?
Бәлки һуннар заманыннан
Килгән синдер ул?

Синдә кунак булдык,
Тыйнак
Булдыкмы, Сибат?
Алда гасыр—яңа гасыр...
Саулыгың кыйбат.

## Хәтер иябләре

**Мин бит монда күпме урман кискән,
Күпме көтү көткән.
«Әткәң-әнкәң монда ята»,—дисең,
Алар гына микән?...**

**—Илле тула инде,—димә әле,
Җаным—бала-чага...
... Ә шөпшәләр—Хәтер иябләре
Элеккечә чага!**

## Кыйбла дүрт якта...

*Алга, көн чыгышыннан,
уңга, көн уртасыннан,
артка, көн батышыннан,
сулга, төн уртасынача...*

Орхон-Енисей язмаларыннан, VI-VII гасыр

**Мин киткәч тә әллә ни үзгәрмәс,
Мин киткәч тә сезгә калачак...
Актарылып-актарылып болыт
Киләчәк тә...
оеп явачак.**

**Мин киткәч тә әллә ни үзгәрмәс,
Татар халкы сыер савачак...
Һәм вакытлы түрәләре аның
Иман шартын тартып алачак.**

**Мин тәгәрәп үскән үзәннәрнең
Уртасыннан инеш агачак.
Шул инешне бетерергә үчегеп,
Мәскәү тагын канун табачак.**

**Бушлат кигән татар балалары
Шуны үтәп хәлдән таячак.
Уйламагыз, мондагылар безне
Аяр, диеп,
Аямаячак!**

**Үз телләрен белмәс малайлары
Калдырачак безне таякка—
Шундый хәлдә милләт ничек инде
Тәпи китсен,
Бассын аякка.**

**Бавырларга, бөерләргә сауды,
Баш миенә каннар савачак—
Орхон-Енисейдан калган язма
Күрсәткәнчә—дүрт як калачак.**

**Шундый чагы бүген яшәешнең,
Шундый чагы бүген дөньяның
Күпме телләр,
Күпме илләр әнә
Кыйбла итеп яши дүрт ягын.**

Заман кырыс,
Заман үз дигәнчә...
Бер кавемне аямаячак.
Бу түрәләр корсак мәнфәгатен
Үтәячәкләр дә...
Таячак.
... Үпкәләдем, диеп,
Үпкә сонып,
Авыз ачып татар калачак.

... Һәм дүрт ягы кыйбла булганнарны
Бер заман да аямаячак.

## Сөю булып җиргә алма ява...

Без гөнаһлы иске Җир шарының
затлы бөртеге лә...
Беләсезме, безгә кадәр аның
әле бер кеме дә
бу кадәрле изгелекләр теләп
бакмагандыр аңа—
безнең хәтта кадим өмет, теләк
яңа булып яна.

Рәнҗүләргә, әрнү, үпкәләргә,
кимсенүгә хәтле
тел тидереп сүз әйтүме әллә?
Сүз дә мәрхәмәтле.

Тояк белән тик җылысын аның
тоячак атыбыз—
бу гөнаһлы иске Җир Шарының
гөнаһлы заты без.

Оят онытып бары азга гына
Ычкынды бу сәдәп,
югыйсә бит безнең назлануга
җирнең көзе сәбәп...

Киңлекләргә тулып таралган да
көз килә әвәрә,
сөю булып җиргә ява алма,
ничек түзсен бәндә—
Ул да шаша, тула, пешә
коела
бутап көнен-төнен.
Тартынудан гына шулай тоела,
сизә өлгерүен.

Һәм алырга безгә язылганын
бардыр бит хакыбыз?
... Бу гөнаһлы иске Җир Шарының
гөнаһсыз заты без.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

# ЗАМАНА ЯЗУЧЫСЫ

Рауль Мирхәйдәров... Кем ул? Татар укучысы беләме, таныймы аны? Сорауга җавап шул: аз белә. Хәтта, язучыларыбызның да шактые әсәрләрен укып түгел, ишетсә ишетеп кенә беләдер. Хәбәрдарларның берәүләренә ул—мавыктыргыч сюжетка корылган детектив романнар авторы, берәүләренә—хакимиятнең теләсә нинди югары даирәләрендә үз була алган супершома замана егете, берәүләренә—дөньяны чолгап алган җинаятьчел коррупция кармавычларын аяусыз кисеп торучы куркусыз шәхес. Ни генә димәсеннәр, ул—иң әүвәл, безнең халык баласы, рус телендә иҗат итүче татар язучысы. Тормыш кредосы, иҗат принциплары, эстетик карашлары турында фикер йөртер өчен әдипнең тормыш юлын бераз гына булса да шәрехләү кирәк.

Рауль Мирсәет улы Мирхәйдәров 1941 елда Казакъстанның Актүбә өлкәсендәге Мартук поселогында туа. Үзе әйтүе буенча, аның әти-әнисе чыгышлары белән Оренбург ягыннан.

Раульнең үсмер-яшьлек еллары Актүбә шәһәрендә үтә. Ул биредә 1960 елны тимер юл техникумын тәмамлый. Соңрак төзүче-инженер була. Егерме еллап төзүче булып (прораб, участок начальнигы һ. б.) эшләү дәверендә аңа Советлар Союзының бик күп республикаларын, йөзләгән шәһәрләрен гизәргә туры килә. Ике дистәдән артык ел Ташкентта яши. 30 яшендә «Полустанок Самсона» дигән беренче хикәясен яза һәм ул Мәскәүдәге «Родники» дигән альманахта басылып чыга. 1975 елда Р. Мирхәйдәров яшь язучыларның Бөтенсоюз киңәшмәсенә чакырыла һәм тиздән, «Молодая гвардия» нәшриятында «Оренбургский платок» исемле китабы дөнья күргәч, ул СССР Язучылар союзына кабул ителә. Кырык яшеннән Рауль Мирхәйдәров төзелеш эшеннән китә һәм гомерен тулысынча әдәби иҗатка багышлый. Ул—бүгенге көндә дистәләгән китаплар авторы. Әсәрләре чит ил телләрендә һәм СССР халыклары (казакъ, үзбәк, грузин, татар, каракалпак, һ. б.) телләрендә күп тапкырлар тәрҗемә ителеп басыла. Хәзерге вакытта Мәскәүдә яши.

«Мәскәүдә яши», дидек. Ни өчен соң әле үзе бик тә якын иткән, яраткан, яшьлеге үткән шәһәрне—Ташкентны ташлап китәргә мәҗбүр булган Рауль Мирхәйдәров? Әйе, нәкъ менә мәҗбүр булган, мәҗбүр иткәннәр. Аның беренче сәяси детектив романы «Пешие прогулки» (1988) басылып чыккач, Үзбәкстан мафиясе Р. Мирхәйдәровка һөҗүм оештыра. Ул могҗиза белән генә исән кала. Бу могҗиза—аның яшьтән таза-сәламәт булуында, спортның төрле төрләре белән шөгыльләнүендә. Ул боксчы—заманында Актүбә шәһәренең чемпионы, футболчы—»Локомотив» спорт клубының җирле командасында уйнаган. Әнә шул чыныгулардан килгән ныклык коткарып кала да аны. Шулай да язучы егерме сигез көн яшәү белән үлем арасында була, аннары да озак айлар буе хастаханәләрдә ята.

Әмма табигате белән куркусыз-тәвәккәл бу кеше хастаханәдә ятканда да, күкрәгенә такта куеп, карандаш белән яңа романын яза. Аннары икенчесен, өченчесен... Бер-бер артлы язылып һәм басылып торган романнары хакимияткә үрләгән мафиоз түрәләрне тәмам чыгырдан чыгара: Р. Мирхәйдәровка һөҗүм оештыручылар боерыгы белән аның машинасын куып алып китәләр,

китапларын сатуны тыялар, «Масть пиковая» романының наборын чәчәләр... Менә шушы этлек-әшәкелекләрдән соң, Р. Мирхәйдәров язучылык эшен тынычлап дәвам иттерү өчен Мәскәүгә күчә дә инде. Куркып түгел, һич юк! Эшен дәвам иттерү—иң югары түрәләрнең җинаятьчел дөньясын фаш итү өчен.

Болар—Р. Мирхәйдәров биографиясенең кайбер штрихлары. Укучылар беркадәр мәгълүмат алсын дип язуым. Гадәти биография, Раульнекенә караганда да әллә нинди катлаулы, әллә нинди мажаралы язмышлар бихисап бу дөньяда... Әмма, ни гаҗәп—тормышта, әдәбиятта Рауль Мирхәйдәров феномены бар! Болай әйтерлек нигез бар. Беренчедән, ул—гаҗәп күп һәм нәтиҗәле эшли торган язучы. Һәр ел саен диярлек аның берәр калын романы басылып чыга тора! (Язылып кына түгел, басылып!). «Пешие прогулки» (1988), «Двойник китайского императора» (1989), «Судить буду я» (1990) һ. б. Кемнәрдер бер-ике табаклык китабын дистә еллар чыгара алмый изаланган заманда бит бу! Икенчедән, аның романнары миллионлаган (!) данәләр белән нәшер ителә (танылган прозаикларыбызның әсәрләре 3-5 мең тираж белән чыга хәзер). Өченчедән, махсус филологик һәм әдәби белеме булмаган төзүче-инженер яза бу китапларны. Язу эше белән дә шактый соң — яше утыздан ашкач башлаган.

Әйе, аның романнары кабат-кабат—кайсысы унар, кайсысы алты-тугызар мәртәбә дөнья күрә. Хәзер Р. Мирхәйдәров—бертомлык, өчтомлык, дүрттомлык сайланма әсәрләр авторы.

Уйланырлык. Бу арада Р. Мирхәйдәровнең романнарын җентекләп укып чыктым. Төрле уйлар килде башка. Кая бара дөнья? Киләчәктә әдәбият нишләр? Татар язучысының хәле ничек булыр? Тукай-Дәрдмәндләрне, Такташ-Җәлилләрне, Туфан-Хәкимнәрне, Юзәй-Шәүкәтләрне, Мөдәррис-Харисларны кемнәр укыр? Китапларыбызның тиражлары аз, укучылары сирәк... Ә менә Мирхәйдәров китапларын укыйлар. Димәк, ихтыяҗ бар. Хикмәт фәлән телдә язуда гына түгел. Әнә рус классикларының китапларына да бик ябышып ятмыйлар хәзер...

Сер нәрсәдә соң? Моңа төгәл җавабым юк. Фаразлый гына алам. Миңа калса, Р. Мирхәйдәров без шаһитлары булган бүгенге җәмгыятьнең, системаның, идарәчеләрнең яшәү рәвешен, кылган һәм кылырга теләгән гамәлләрен ниндидер бер эчке сиземләү белән, рентген нуры аша карагандай, ачык күрә, үлчи, бәяли. Ә җәмгыять, беләсез, бөтен организмы белән диярлек җинаятьчел вируслар белән агулы. Замана каһарманнары (әллә имгәкләре?) без күрергә теләгән идеалларның капма-каршылары булып чыкты. Оешкан җинаятьчелекнең хакимияттәге югары түрәләр белән үрелеп берегүе, бик күпләр өчен акчаның иманга әйләнүе, рухи кыйммәтләрнең очсызланып-кадерсезләнеп бетүе, бөтен нәрсә диярлек сатыла-сатылына алынуы—һәммәбез күз алдында. Р. Мирхәйдәров романнарындагы персонажлар менә шушы вәзгыятьнең авансценасында —алгы сәхнәсендә төп рольләрне уйнаучы геройлар. Тәрбиябез буенча без күрергә теләгән хәләл хезмәт геройлары түгел, ә акыл-хәйлә, янау-үтерү белән дөнья көндегән тотучы яңа «геройлар»—Артур Шубариннар һәм башкалар...

Р. Мирхәйдәров үз әсәрләрендә, теләсә—«законлы бур», теләсә—генпрокорур, теләсә «төнге күбәләк» булып табигый сөйләшә ала! Бу—профессиональ осталык. Ул моңа ничек ирешкән?—монсы минем өчен чыннан да сер.

Дөресен әйтим: Р. Мирхәйдәров әсәрләрен укыганда гел ләззәтле генә хисләр кичермәдем мин. Ят дөнья. Ят гамәл-кыланмышлар. Без кинода гына күргән зур акчалар дөньясы. Психологик яктан аңлап бетермәгән, йә аңларга теләмәгән нәрсәләр күп. Күрәсең, заманына күрә алынган тәрбия, һәм дә өстәп, үткән гомер консерватизмы үз хасиятен башкара булса кирәк. Әмма нишлик?—күңелең белән кабул итмисең, акылың белән килешергә мәҗбүрсең. Йә без артык артта калган, йә тегеләр бик «алга» киткән. Язучы «чырайсызлар» заманының чыраен дөрес күрсәтә. Каләм сукасы эчке буразна эченә тирән төшеп, шәп ерып бара... Гыйбрәт алу, нәтиҗәләр ясау—укучылар эше... Шунсы да бар: Р. Мирхәйдәров—бу җинаятьчел дөньяның елъязмачысыннан бигрәк, аның тикшерү-өйрәнүчесе... Бу бик мөһим момент: язучының социаль аналитик булуы зур нәрсә. Тормыш, дөньябыз ничек?—аның чагылышы безнең күзләрдә, идеалларда, җырларда, әсәрләрдә. Р. Мирхәйдәровтән, бәлки, Бунин яки Еники чалымнарын эзләү кирәкмидер, бәлки, Ж. Сименон ягалгысы анда көчлерәктер...

Янә уйга калдым. Ялгышмыйммы икән? Детектив романнар язучы әдипләрнең шәхесен, гадәттә, ике төп стереотип—киң таралган тасвирлау белән чикләнәләр. Беренчесе—Шерлок Холмс тибы. Ул кайчандыр үзе утлар-сулар кичкән тикшеренүче-эзләнүче «сыщик» һәм буш вакытларында үзе күргән-кичергәннәрне кәгазьгә төшерә. Икенчесе—үз бүлмәсендә генә утырып, сюжет-фәләннәрне бармактан суырып яки каләмдәшләре язганнардан аз-маз чәлдергәләп, кәгазь буяучы бертөрле Манилов тибы. Мондый язучы кисәкләренең хәзерге заманда чуты-чамасы юк. Монысы да сер түгел. Урамнарда чат саен шуларның «детектив әсәрләре» күзенә чекерәеп кереп тора.

Рауль Мирхәйдәров исә бу ике стереотипның берсенә дә охшамаган, минемчә. Аның романнары гаять күп фактик материалга нигезләнеп язылган. Шәхси күзәтү-фикерләүләре дә, рәсми чыганаклар да—һәммәсе бер синтетик чагылыш таба алганнар. Шунысын да әйтергә кирәк, Р. Мирхәйдәров романнары турында юридик басмаларда дөнья күргән рецензияләрдә дә авторның җинаятьчел даирәләрне һәм хокук саклау оешмаларындагы мохитне искиткеч яхшы белүен искәртеп узалар. Монысы да детектив әсәрләр язучылар өчен сирәк күренеш.

Рауль Мирхәйдәров, әйткәнемчә, гадәти булмаган кабатланмас шәхес. Эш аты, әйткән сүзен үтәүче ир-егет, көяз-франт (М. Мәһдиев: «Рауль иҗат йортларына берничә чемодан белән 15 тән дә ким энә-җептән төшкән костюмсыз килми ул»,-дия торган иде), сәнгатькяр. Сүз уңаеннан шунсын да әйтеп узыйк—Р. Мирхәйдәров бик зур кыйммәткә ия нәкыш әсәрләре коллекциясе иясе. Сәнгатьне тирән тоючы белгеч буларак, ул җыйган картиналар әледән-әле төрле күргәзмәләрдә күрсәтеп торыла. Язучы кеше өчен бу да ят шөгыль түгел, һәрхәлдә, тарлык түгел—киңлек.

Әсәрләрне укыганда авторның профессиональ осталыгы да уйландыра. Бүгенге укучы күңеленә эленке-салынкы җөмләләр, беркатлы наив фикерләр белән юл салып булмый хәзер. Стиль—Кешенең нәкъ үзе инде ул, дигән гыйбарә бар. Дөрес сүзләр. Язучы кемнәр яки нинди вакыйгалар турында язмасын, барыбер, күпмедер дәрәҗәдә әсәрдә автор язмышы чагылмый калмый. Раульнең стиле—логик төзек, динамик стиль. Сүзләрнең җегәре зур. Шул җегәрле сүзләр мавыктыргыч сюжет чылбырында гаять тәэсирле көчкә әверелә. Укучыларны «тота» алуның бер сере шунда, минемчә. Тагын бер мөһим нәрсә, ул—төгәл сурәтләү. Язучы кайдадыр кайчандыр үзе күргән кирәк детальләрне фотографик төгәллек белән кабатлап күз алдына китереп бастыра ала. Мәсәлән, «Пешие прогулки» романында Кырымдагы Күктүбә тирәсен тасвирлаган урыннар бар. Заманында мин үзем дә шул җирләрне күп таптадым. Хәзер дә әзме-күпме хәтердә. Ә менә Раульнең әсәрен укыгач, мин анда әле кичә генә барып, күреп кайткандай хис иттем. Кирәк һәм иң характерлы деталь-штрихлар шул кадәр осталык белән тотып алынган. Афәрин, молодец!- дияргә генә кала. Тарлык-киңлек сүзе чыккач, күңел түрендәге әчке уйлар да баш калкыта: Кемнәребез бар да, кемнәр юк! Кан яратылышы буларак, кемнәрең кайда туып, нинди сыйфатта, кем булып кайларга таралмаган! Үзем күреп белгәннәрне генә искә төшерсәң дә—байтакка җыйнала. Магаданда—Бөгелмә ягы егете Альберт Мифтахетдинов, Красноярскида—Минзәлә егете Ринат Суфеев (Роман Солнцев), Чиләбедә—Рөстәм Вәлиев, Ташкентта—Әсгать Мохтар, шунда ук Җәүдәт Ильясов... Кайберләре дөньяның фаныеннан бакыена күчтеләр инде... Кемдер әйтер—татарга нинди кагылышлы язучылар инде болар? Килешәм дә кебек. Исем-фамилияләре безненчә булса да, сүз дә юк, рухи тамырдан ерак киткәннәр. Явыз Иван Казанны алганнан соң исән калган асыл ирләр еракларга сирпелгән кебек... Әмма нишләргә соң? Сыркыдыдан янә Һади Такташ, Пенза ягындагы Пешләдән Шәриф Камал, Нижгардан Кави Нәҗми, Оренбурдагы Мостафадан янә Муса Җәлилләр килерме? Килмәсләр кебек... Шулай булгач, каннарында төрле катнашмалар булса да, төбендә татарлыгы яткан, бүген бүтән телләрдә иҗат итүче егетләребезне нигә онытырга? Булган дәрт-рухларының, иҗат мөмкинлекләренең берәзын гына булса да уртак генофондыбыз тамырына нигә тоташтырырга тырышмаска?

Рауль Мирхәйдәровне укучыларыбыз белми әле, дип башта әйтсәм дә, хәл бөтенләй алай ук түгел. Моннан ике ел элек безнең журналда аның «Игълан буенча танышу» исемле повесте басылып чыккан иде. Россиядәге зур афералар-алдашуларны тасвирлаган «За все—наличными» дигән янә романының өзекләре «Республика Татарстан» газетасының биш-алты санында дөнья күрде. Һәм, ниһаять, «Казан

утлары» Марс Шабаев тәржемәсендә аның «Иртәләгән сагыш» исемле романын тәкъдим итә.

Бу романның язылу тарихы болайрак. Үлем сулышын тойганда кешенең хәтереннән яшен тизлегендә бөтен үткән гомере уза, диләр. Мөгаен, бу дөрестер. Р. Мирхәйдәров та, үлем белән көрәшеп ятканда, үз тормышына йомгак ясагандай, сагышлы хатирәләргә бирелә, аңа әле нибары кырык җиде генә яшь була. Менә шуннан «Ранняя печаль» («Иртәләгән сагыш») романы языла.

Роман, нигездә, биографик әсәр, анда ерак Казакъстанда туып үскән татар егете Рушан Дасаевның катлаулы тормыш юлы туксанынчы еллар башындагы вәзгыять белән чагыштырылып тасвирлана. Бәлки бу роман язучы иҗатының иң характерлы әсәре түгелдер. Әмма анда безнең язмышлар, безнең уртак сагышлар...

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН.**
*Май, 2000*



# Рауль Мирхәйдәров

## ИРТӘЛӘГӘН САГЫШ

РОМАН

*Улым Ренарга багышлыйм бу әсәремне.*
*Автор.*

*Без, агым белән көрәшеп, һаман алга йөзәргә тырышабыз, агым исә безнең көймә-каекларыбызны һаман кирегә, үткәннәребезгә кайтара тора...*

*Ф. С. Фицджеральд.*

### I

Ни өчен шундый купшы чәчәк исеме белән атаганнардыр, шәһәрдә яманаты чыккан «Лотос» кафесының бер дә алай ис китәрлек җире юк иде. Зур һәм юан төпле тәбәнәк кенә пыяла гөмбәне хәтерләтә ул. Ни эчендә, ни тышында дигәндәй, өстәл-урындыклары, хәтта гап-гади таяныр урыны да юк ичмасам. Хәер, килгән-киткән кеше эчкә үтәргә ашкынып та тормый. Анда гөмбәнең хуҗасы—ясалма паригы бер якка кыйшаеп төшкән тузган чәчле юан хатын үзе дә көчкә борылып йөри ала. Тирә-ягы әрҗә, тартма, боз кисәкләре салынган шыксыз алюмин

савытлар белән шыплап тутырылган. Тар гына тәрәзәгә исә буфетчының башы да көчкә-көчкә генә сыядыр сыман тоела башлый. Әйе, «Лотос» унайлылыгы яисә эчке бизәлеше белән үзенә тарта, дип һич әйтеп булмый. Әмма ни гаҗәп, кеше шактый күп йөри монда.

Рушан Дасаев монда, гадәттә, эштән соң сугыла һәм үзе дә тышкы кыяфәте белән башкалардан әллә ни аерылып тормый диярлек. Юл унаеннан, ягъни эштән кайтышлый кереп чыгарга ниятләгән башка бик күпләрнең кулында портфель, «дипломат» булган кебек, Рушан кулында да затлы гына «кейс» булыр.

Кафеда сораганынны бик тиз үтиләр: Рушан, бер тәнкәсен сузып, «Шифалы су бирегез» дияргә дә өлгермәде, паригы астыннан тузган чәчләре бүлтәеп күренеп торган хатын үтә дә житез-төгәл хәрәкәтләр белән каршысындагы стаканны, башланган шәраб шешәсеннән, тамчысын да түкмичә, мөлдерәмә тутырып та куйды. Цирк артистына хас осталык белән башкарылган бу эш-гамәл Рушанны сокландырды хәтта. Ул минераль су сорарга ниятләгәнен бөтенләй онытып, стаканны кулына алганын сизми дә калды. Кулында башкаларныкы шикелле үк гадәти стакан булгангамы, аңа беркем дә игътибар итмәде.

Кафенын ниндирәк урын икәнен яхшы белсә дә, Рушанның кызыксынуы кимемәде, ул иркенләп тирә-ягын күзәтә башлады.

«Лотос» тирәсендә ана бөтенләй таныш булмаган тормыш хөкем сөрә. Монда барысы да эчкечеләр һәм махмырдан интегүчеләр генә, дисән,—ашыгыч нәтиҗә ясау булыр иде. Гәрчә араларында андыйлары да, мондыйлары да житәрлек иде бугай.

Бик кызыклы халык жыела икән монда. Әнә, нефтедоллар, «Уотергейт» һәм еврокоммунизм, экстрасенслар һәм тамил хирургиясе, агропромкомплекслар һәм компьютерлар турында нинди генә бәхәс куертмыйлар! Дасаев хәтта кемнендер Морис Бежар балеты турында фәлсәфә коруын да ишетеп алды, икенчесе ана Джон Кранконың Штутгарт балетын мисалга китереп маташа иде. Әмма бераздан икесе дә уртак бер фикергә килеп, сүз жебен Герберт фон Кароян оркестрына күчерделәр, аннары Карояннан Эдинбургтагы хәзерге заман сәнгате фестивалена сикерделәр, сүз арасында гына композитор Бенджамин Бриттен белән дирижер Зубен Меттаны да телгә алдылар, аннары фестивальдән—Америкадагы Гугенхайм фондына һәм Рокфеллар үзгәнә...

Ниндидер бер джентельменнар клубы диярсең, билләһи. Сүз сөрешләре дә Рушан эшли торган прораб бүлмәсендәгедән яки тресттагыдан күпкә кызыклырак, мәгънәлерәк бугай әле. Аларда исә көндәлек тормыш, базар хәлләре, бала-чага, йорт-җир турында күбрәк сөйләшәләр.

Дасаев көне буе шушында тел чарлап гомер уздырган агай-энене ашыкмый гына күзәтергә кереште. Кызык, аларның барысына да хас уртак чалымнар да бар икән ләбаса. Берсенең-бер өстендә яна кием юк, анын ише вак-төяккә сукыр тиен дә тотмаска сүз берләшкәннәр диярсең. Кием-салымнарына игътибар беләнрәк караган саен, андый «сүз бирү»нең кайчанрак булганын да чамаларга мөмкин иде.

Мәсәлән, дүрт төймәле, бер капламлы пиджак кигән һәм балаларныкына охшаш кыска галстук таккан кеше андый сүзне, мөгаен, Дасаев институтта укыган елларда ук биргән булгандыр. Анын янындагы икенче берсе галәмәт кин якалы пинжәктән, аска таба киңәеп киткән «клеш» балаклы чалбардан. Көяз, шома егетләр моннан ун-унике еллар элек шулай киенәләр иде. Арада алтмышынчы елларда бик модалы саналган, әмма хәзер инде күптән төсен җуеп, кыршылып беткән дакрон костюмлылар да бар.

Нейлон күлмәкләр, твид тройка костюмнар, вельвет пинжәкләр, мамык кытай пуловерлары, очлы башлы мокасиннар, калын платформа табанлы туфлиләр, төрле фасондагы эшләпәләр, туза белмәс габардин һәм бостон костюмнар, кин каптыргычлар һәм галстук булавкалары...

Болар игътибарлы кешегә кием хуҗаларының язмышы турында бик күп нәрсәләр сөйли иде. Тузып-таушалып, кыршылып-шомарып өлгергән кием-салым, кайчандыр, гади кием генә булмыйча, заманы өчен купшы-нәфис, үтә модалы саналган бит. Алар үз хуҗаларының модадан калышмыйча матур яшәгән, җегәрле-көчле вакытларының телсез шаһитлары да иде.

Үткәннәр турында шулай уйлана-уйлана Дасаев төрле стильдә, төрле чуар төсләрдә киенгән бу кешеләрнең барысына да хас икенче бер үзенчәлекне дә абайлап алды. Һәркайсының киеме чиста һәм пөхтә иде. Хәтта инде күптән искереп беткән әйберләргә ул кадәр җентекле пөхтәлек кирәкмәстер кебек тоела башлый иде. Тагын шунысы кызык, болар галстуксыз яши алмый икән. Ул хуҗасының дәрәҗәсен билгели, аны бөтенләй упкынга тәгәрәүдән саклый шикелле. Аның нинди булуы мөһим түгел: таушалып беткәнме, кыршылып шомарганмы, капронмы-йонмы, атласмы-ефәкме, күнме-башкамы, бәйләп куелганмы-резин шнурлымы, тармы-киңме, озынмы-кыскамы—анысы барыбер, бары тик галстук кына булсын.

Әле тагын күпләрнең күкрәк кесәсеннән пөхтә итеп бөкләнгән кульяулык та күренеп тора, байтагының аяк киемнәре ялтыратып-шомартып куелган. Әмма иң гаҗәбе шул: монысын игътибарсыз кеше дә күрми калмас иде: болар арасында бер генә кырынмаган кеше дә юк, барысының да чәчләре, бөртеге-бөртеккә яткырып дигәндәй, матурлап таралган булыр. Күрәсең, бу мохитнең үзенең язылмаган кануны, эталоны яки бер билгеле баскычы—дәрәҗәсе бар, шуннан түбән тәгәрәү әдәпсезлек санала булса кирәк.

Дасаевны «Лотос»ка мәгънәсез-буш кызыксынудан зуррак-мөһимрәк нәрсәләр тарта һәм ул, алдан әзерләп куелган бер тәнкәсен учына йомарлап, соңгы вакытта монда шактый еш керә башлаган иде. Бер сумнан зуррак акча сузсаң, мондагыларның үзенә ышанмый башлаячакларын да сиземли иде ул.

Ул килгән саен аның белән сүзсез генә, әмма әдәп саклап исәнләшәләр, кайберләре хәтта пеләшләнгән башларындагы эшләпәләрен джентельменча бер инсафлык белән күтәреп куя. Төс-кыяфәтен җуйган ул баш киемнәре мондый тәкәллефлеккә һич ятышмый, Рушан ирен читләренә куна башлаган елмаюны көчкә-көчкә генә тыеп кала иде.

Әмма ана күрсәтелә торган иң зур хөрмәт,—ә ул, бәлки, һәр яңа кешегә булган гадәти игътибарлылык кынадыр,—анысын Рушан аңлап та бетерә алмады—башка нәрсә иде. Рушан тиз һәм оста итеп шәраб салына торган тәрәзә янында ыгы-зыгы, тәртипсезлек юклыгын, берәүнең дә чиратсыз керергә маташмавын абайлаган иде инде. Гәрчә чиратның бетеп торганы булмаса да, чиратсыз керергә маташу зур әдәпсезлек санала иде күрәсең. Шунысы сәер: Дасаевны ни өчендер башкалардан аерыбрак куйдылар, аның тавыш-тынсыз гына чират койрыгына килеп басуы була, алдындагы кеше борылып үз алдына басарга ымлый, икенчесе дә, өченчесе дә шулай эшли. Кыскасы, Дасаев, рәхмәтләр әйтә-әйтә, күпләрнең тәкатен корыткан әлеге тәрәзә янына барып җиткәнче шулай итәләр иде.

Ни гаҗәп, аралашу-гәпләшү өчен шәһәрнең төрле почмакларыннан җыела торган бу халык арасында ябышкак-бәйләнчек гамәлләр дә, тәкәллефсез дорфа тупаслыклар да юк иде. Ир-ат күбесенчә кечкенәрәк төркемнәр булып оеша, әмма ул төркемнәр ярты сәгать саен диярлек яңарып тора: берәүләр китә, икенчеләре килә. Аларны нинди мәнфәгатьләр берләштергәне Дасаевка аңлашылып бетми иде. Рушан шикелле үк, стакандагы шәрабен йоткалап вакыт үткәрүче ялгызлар да аз түгел иде биредә, андыйларның ялгызлык иркенә кагылмыйлар, җаны теләгән—елан ите ашаган, дигәндәй,—рәхим ит, агай-эне!—синең янына берәү дә килеп сырышмас. Шулай да Рушан сизеп тора: теләк белдереп, бер ым гына как—әңгәмәдәш-остәлдәшләр хәзер табылачак. Биредә беркем дә

бирәүне дә ашыктырмый, шулай ук беркемне дә ирексезләп тотмый, һәркем үз вакыты белән «өлгереп житә», бер бөтеннең аерылгысыз кисәге булырлык дәрәжәгә ялгызы ирешә һәм, «Лотос»ка тәүге тапкыр нинди кием-кыяфәттә килеп кергән булса, балавыз сыннар музеендагы шикелле, нәкъ шул кыяфәттә ахыргача катып кала.

Бу «пыяла гөмбә» тирәсендәге хәлләр, андагы вәзгыять Дасаевка берьюлы гына ачылып-аңлашылып бетмәде әле. Әмма ясаган ачышы аны таң калдырды. Монда ачыктан-ачык, башкаларга сиздереп, берәү дә беркемнән дә әҗәткә акча сорамый һәм алмый иде.

Башка сыраханә-фәлән тирәсендәге кебек, кемнендер тиеннәр җыеп торганын күрүне күз алдына да китереп булмый. Бер стакан портвейнга дип сузылган бер тәнкәдән ун тиен кайтарылырга тиешлеген һәркем белә, әмма аны беркем дә сорап вакланмый. Күпләргә ул, күрәсең, әле теге, мул-иркен яшәгән элекке тормышында рестораннарда «чәйлек» калдырган шикелле юмарт бер гамәл булып тоеладыр. Бервакыт Рушан агачлар арасындагы күрше юл-сукмактан бөтенләй төс-кыяфәте калмаган бер исерекбашның «Лотос» ягына монсу караш ташлап үтеп киткәнен күреп калды. Әмма ул исерекбаш бирегә якын килергә базмады—ниндидер «ярамый», табу-тыю кебек нәрсә дә бар, ахрысы, бирегә. Дасаевка монысы да аңлашылып бетми иде.

«Пыяла гөмбә» әһле турында уйланып йөри торгач, аның зиһене ачылып киткәндәй булды: «Лотос»—тормыш төбенә тәгәри баручылар өчен бер чик, соңгы бастион лабаса! Үзләре өчен билгеләгән бер дәрәҗәне, билгеле бер статусны саклап, әле һаман да бирегә килеп йөри алганда, болар әле үзләрен хөрмәткә лаек кешеләр дип саный иделәр булса кирәк. Ә бәлки, тагын да гадирәктер—алар үзләрен эчкечеләр арасында өстен катлам—элита итеп сизәләрдер? Әлбәттә, шулай: никадәр көлке һәм монсу тоелмасын—элита! Шуның өчен—галстуклар, илтифатлы-әдәпле сөйләшүләр, башка кешеләр арасында күптән онытылган, табигый булмаган нәзакатлелек, күптән юылмаган, коелып-сирәкләнеп беткән чәчләрне тырышып тарап куюлар, кыршылып-каешланып каткан пинжәкнең күкрәк кесәсендәге кыланчык кульяулык... һәм аларның югалган абруйларының шәүләсен булса да саклап тотарлык дөньядагы бердәнбер урын—шушы «Лотос», ул, батып баручы өчен салам шикелле, үзенә тартып тора. Үзенең бөгәрләнеп беткән, бәлки әле кимсетелүләр белән эшләп тапкан бер сумына бер стакан шәраб алып эчкәндә, эчүче үзенең күпсанлы дошманнарына: «Күрегез, шул берлекне тотып, шешәгә дип, кибеткә йөгермим, капка төбендә өч борынга да чамалап тормыйм. Минем өчен эчү мөһим түгел, мин кафега кызыклы кешеләр белән аралашырга килдем—карагыз, кемнәр генә юк биредә!»—дип әйтәдер шикелле.

Сөйләп торасы да юк, «Лотос»ка кемнәр генә килми дә, нинди генә чуар халык җыелмый! Күпләр бирегә казна хезмәтеннән соң сугылып чыга, хуҗалары кебек үк таушалып беткән портфельләре шул хакта сөйли, шулай да ешрак күптән модасы чыккан, кулланылыштан төшеп калган күн папкалар худта. Ул портфель-папкаларның хуҗалары хезмәт баскычларыннан көннән-көн түбәнрәк тәгәри төшүче, төрле дәрәҗә-вазифа үтәүче белгечләр иде. Алар соңгы елларда бик үрчеп киткән ниндидер контор-ларда, ширкәтләрдә, җәмгыятьләрдә һәм тагын шундый әллә нинди урыннарда эшлиләр иде булса кирәк, чөнки аларны нинди булса да житди, абруйлы хезмәткәрләр итеп күзаллау кыен иде.

Дасаевның «Лотос» тирәсендәге әңгәмәләрнең бик күп төрле һәм зыялы булуы турындагы беренче тәэсирләре тиздән эреп таралды, юк, бирегә йөрүчеләр кинәттән генә еврокоммунизм яки Тибет медицинасы турында сөйләшүләрдән туктаган өчен түгел иде бу. Бу әңгәмә-сөйләшүләрнең төрлелеге аны һаман да гаҗәпләндерә, әмма ул икенче бер нәрсәне дә аңлап алды: сөйләшүләр очраклы гына, өстән-өстән, әпен-төпен генә була, алар, шул ук портфель яки галстуклар шикелле, бу кешеләргә үзләрен әле һаман да башка тормышка, рухи тормышка

катнашлары бар кешеләр итеп тояrга ярдәм итә иде.

Кешеләргә хас яhаны белергә тырышу, нәрсә өчендер кайгыру-борчылу, кемнендер кайгы-шатлыгын уртаклашу кебек гап-гади хисләр болар өчен тормыш ихтыяжы булудан туктаган инде. Аннары эштә дә,—әгәр чынлап та эш-хезмәт урыннары булса, әле портфельләр генә моңа мәҗбүри ышандыра алмый бит,—боларны кемнәрдер житди кабул итәме икән, өйләрендә, гаиләдә дә, мөгаен, шулайдыр. Ә аларның һәркайсына да игътибар кирәк, ничек кенә кирәк әле! Бездә бит Америкадагы кебек Гайд-парклар юк, булыры да күренми, ә «Лотос»—менә ул, янәшәндә генә, монда сине игътибар белән тыңларлар, сүзләреңне хуплап каршы алырлар йә кире кагарлар, биредә син ялгыз түгел, син үз кеше. Менә шуңа күрә дә алар, газет-журналлардан алынган яки радио-телевидение аша ишетелгән тәэсирле өзек-төтек хәбәрләрне башларына дыңгычлап тутырып, үзләренең шушы «Гайд-паркларына» киләләр—хәзерге заманда хәбәрдарлек артыгы белән алып ашкан, ә боларның буш вакытлары күптин күп тә чуктин чук.

«Лотос»ка йөрүче бу бәндәләрнең күпчелеге үзен тыныч-ипле тота, ашыкмый-кабаланмый. Кайберләре хәтта куркып-өркебрәк, сак кылана—андыйларын тормыш бабай шактый тукмаган бугай, алар инде бер генә янмагандыр. Боларның күзендә өмет уты сүнгән, күренеп тора: нинәрсә өчендер көрәшү түгел, үзләре өчен дә көрәшерлек көч-җегәр калмаган аларда.

Үзләрен иркенрәк тотучылар иҗат кешесе булып күренергә теләүчеләр иде. Яланаякка сандали кигән, кайбер җирләре тәмәке уты төшеп янган-тишкәләнгән җинел синтетик курткалы берсе шактый шаушулы иде. Таушалган кыяфәтле, сары чәчле бу кеше үзен һәркемгә журналист дип атый. Ул унга да, сулга да атаклы журналистларның исемнәрен сибеп кенә тора, бик белдекле кыяфәт белән, сер итеп кенә, тиздән булачак нindидер мөhим үзгәрешләр турында, кемнәрне кайдан «төгәрәтәчәкләре», кемнәрне кайда күтәрәчәкләре турында сөйли. Имештер, бу хакта әле бик ышанычлы, тар даирәләргә генә билгеле. Аның үзен, имеш, әле бер, әле икенче абруйлы газетка эшкә чакырып кына торалар, әмма ул үзенең алтын каләмен коллыкка сатарга теләми, чөнки әлеге редакцияләрдә җыен ялагай, җыен сәләтсезләр утыра, ә ул исә үз таланты белән аларга уңыш китерергә теләми. Әле артык картаерга өлгермәгән бу адәмгә газет редакцияләренә түгел, рәтле-юньле башка берәр җиргә дә инде юллар ябык икәнлеген аңлау өчен аңа аек күз белән бер карау да житә иде. Моңа нинди дә булса эшне ышанып тапшырганчы шактый озак баш ватарга туры килер иде.

Кафега йөрүчеләр нindидер бер шагыйрьнең пәйда булуын аерым бер җанлылык белән каршы алалар, аны яратканнары сизелеп тора. Ул үзенең шагыйрь икәнлегенә, башкаларны ышандырырга теләүдән битәр, бигрәк тә үзе ышанырга теләгәндәй, буаз күседәй бүлтәеп торган иске портфеленнән әледән-әле таушалып беткән газетлар һәм тышлыгы төшкән бер журнал тартып чыгара. Күләме һәм форматына караганда, журнал һич тә әдәби түгел. Менә шуның бер битендә шагыйрьнең бер бәйләм шигырьләре басылган икән. Шигырьләре янында авторның фоторәсеме дә тасраеп торган бу журнал шагыйрь өчен иң кадерле әйбер иде. Айныткычларга эләгеп, анда иҗат кешесе буларак аерым мөнәсәбәт таләп иткән очракларда бу журнал шагыйрьгә байтак игелекләр күрсәткән, дигән имеш-мимешләр дә йөри иде.

Болай карап торуга шагыйрь «Лотос»ка йөрүче башкалардан тышкы кыяфәте белән берничек тә аерылып тормый: шул ук ике якка ачып куеп, шомартып таралган классик прическа, каешланып-ялтырап торган костюм, елның теләсә кайсы фасылында аягында—туза белмәс каучук табанлы кышкы ботинкалар һәм биредәге чуар халыктан аерып торучы иң абруйлы атрибуты—җыерчыклы нечкә муенындагы җете кызыл ялык. Шагыйрь дә беркайчан да портвейнга чират тормый—халык аны хөрмәт

белән чиратсыз үткәрә. Әчеп алгач, ул бик тиз усаллана башлый, шуның белән башка ипле-тыныч кешеләрдән ямьсез якка аерылып тора, кычкырып-кычкырып шигырьләрен укырга тотына, аларны әшәке сүзләр әйтә-әйтә шәрехли—мондый йөгәнсезлек бер аңа гына рөхсәт ителә. Мөгаен, кайчандыр аның ходай биргән сәләте дә булгандыр, әмма эчтән буып алган усаллыгы-явызлыгы аңа чын шагыйрь булырга мөмкинлек бирмәгән. Һәрхәлдә Дасаевка шулай тоела иде. Шагыйрьнең шигырьләре дә рәхимсез һәм күңелсез-хәерсез иделәр. Еш кына Серж,—аның исеме шулай иде,—портфелен онытып чыгып китә, портфельне кадерләп кенә «пыяла гөмбә» хуҗасына тапшыралар һәм ул шунда, иясен көтеп, берничә көн, ә кайчакта берәр атна да ята, бу вакытта шагыйрь, күрәсең, газет-журнал редакцияләрендәге мөхәррир түрәләр белән сугышып-талашып йөри.

Бирегә Серждан башка да берничә шагыйрь кисәге килгәли. Әмма аларның берсе дә эффектлы кызыл муен яулыклы, мэтр кебек данлыклы түгел һәм портвейнга чиратта да гомуми нигездә басып торалар иде. Мөгаен, шуңа күрәдер, алар «елгыр каләмдәшләренең» «Лотос»тагы популярлыгына ачыктан-ачык көнләшеп карыйлар, аны демонстратив төстә инкарь итәләр, аның белән сөйләшмиләр, үзара бик дус булып кыланалар һәм бик белдекле кыяфәт белән зыялы әңгәмәләр коралар—Морис Бежар балеты турындагы фикерләрне Рушан нәкъ менә шулардан ишеткән иде. Алар Серж өметсез искергән шагыйрь, аның рифмалары белән ерак китеп булмый, дигән гайбәтләр таратсалар да, «Лотос»ның беренче шагыйренең данына зыян китерә алмыйлар, әле киресенчә, данын гына арттыралар. Ни генә димә, аларның берсенең дә шигырьләр бәйләме белән рәсеме басылган журнал юк. Кыюлыклары да шул чаклы гына шикелле—берсе-бер, тәвәккәлләп, кычкырып үз шигырен укымас, юкса, Серж булмаганда, җәмәгатьчелек, эстетик ачлык тоеп булса кирәк, «укыгыз әле» дип сорый да торган иде. Ләкин бер-берсенең шигырьләрен алар үзара укыштыралар иде—Рушан анысын берничә мәртәбә ишетте. Алар кайвакытларда үз араларына берничә музыкантны да алалар, гаҗәбе шул ки, музыкантлар бирегә иң ишле халык иде.

Алар арасында үзләренең танылмаган композиторлары да бар, дирижерлары гына юк иде бугай, хәер, монысын Рушан тәгаен генә әйтә алмый. «Пыяла гөмбә»гә корсак үстергән бер юан гына адәм кергәләп йөри бит, аңа: «Иптәш прокурор...» дип мөрәҗәгать итәләр.

Үзе «Лотос»ка сугылгалап йөргән арада Рушан бу сәер упкынга килүчеләрнең төрлесен күрде. Инде күз ияләшеп беткән кайберәүләр яки хәтта тулы төркемнәр кинәт кенә юкка чыгалар да, аларның урынын үзенә таныш булмаган, әмма «пыяла гөмбә»дә үз кеше саналган башка кемсәләр ала иде. Дасаев «Лотос»тан шулай әледән-әле юкка чыгып югалып торганнарның кайларга барып эләгүләрен, кайларда вакыт үткәрүләрен күңеленнән генә исәпләп чыгарырга тырыша. Ул аларның язмышына һич тә битараф түгел, ул аларны ихластан кызгана, бигрәк тә әле кешелекләрен бөтенләй югалтып бетермәгән, соңгы көчләрен җыеп, көндәлек гадәти тормышка теше-тырнагы белән ябышып калырга тырышкан, ничек кенә көлке янгырамасын, үзләрен әле кеше дип исәпләргә мөмкин булган, шушы «Лотос»ны котылып калырлык бер утрау итеп күргән, әмма ихтыярлары инде бөтенләй дә сынган бәндәләрне кызгана иде ул. Мондый фикер дә очраклы гына тумаган иде.

Рушан тагын ничектер Инженер кушаматлы урта яшьләрдәге бер кешегә игътибар итте. Аның турында «башлы мужик», кайчандыр зур начальник та булган бугай, дип сөйлиләр иде. Вакыты-вакыты белән нинди булса да хезмәттәдер, берәр шөгыле бардыр кебек тоелса да, хәзер Инженерга карап, аның даими хезмәт урыны булуы турында фараз кылырга мөмкин түгел иде шикелле. Кайдадыр нәрсә беләндер шөгыльләнгән чагы булса, бу кеше гаҗәп үзгәреп китә иде—моны бер Дасаев кына сизми, «Лотос»ка йөрүче башкаларның да байтагы сиземли. Андый көннәрдә Инженер янында халык мыжлап тора, кызып-кызып сөйләшүләр

башлана. Юк, Инженерның акчалы чагы булганга түгел, барыннан да бигрәк аның бик мавыгып үзенең хезмәте, планнары турында сөйләве, үзе эшли торган урында хуҗалык бик таркалган икән дә, шунда ул әллә нинди реформалар үткәрәчәк икән—менә шул хакта кычкырып-кычкырып аңлатулары кызык иде аның. Дасаев бу кешенең «дөрес юлга басуы» өчен дә, күзләрен очкынландырып, Инженерның сөйләгәннәрен ихлас күңелләшү белән тыңлап торучы башкалар өчен дә сөенеп куйган иде.

Аннары Инженер кинәт юкка чыкты. Рушан үзе монда йөргән вакыт эчендә берәүнең булса да шәраб сөременнән котылганын күргән шикелле булган иде. Әмма күп тә үтмәде, Инженер, үзенең дә, башкаларның да өметләрен аклый алмаганлыктан, ничектер үзен гаепле сизеп, кыенсынып, тып-тын гына, кырын-кырын гына, бик күзгә чалынмаска тырышып, янадан «Лотос»ка килеп керде. Аның таушалып беткән төс-кыяфәте күптән инде хезмәт планнарын оныткандыгын, кайда туры килсә, шунда куныр йөргәнлеген, ә соңгы көннәрдә вакытын, мөгаен, базар һәм вокзалларда үткәргәнлеген бик ачык әйтеп тора иде.

Инженерның «пыяла гөмбә»гә әйләнеп кайтуында башкалар аның гына түгел, үзләренең дә өмет-хыяллары җимерелгәнлеген күрделәр. Әмма шул ук вакытта аның бу юлы да үзендә упкынга бөтенләй үк тәгәрәмәслек көч тапканын, үзен азмы-күпме тәртипкә китереп, янадан «Лотос»ка әйләнеп кайта алуын мөһим бер гамәл итеп бәяләделәр. Кафега йөрүчеләрнең һәммәсенең дә диярлек вакыт-вакыт шушы каһәр суккан юлны үткәнлекләренә Дасаев шикләнми иде инде.

Кайчандыр зур өметләр баглаган сәләтле-талантлы байтак кына кешеләр бирегә килеп сөртенә шул. Дасаев еш кына бер кызганыч бәндәне күрә, ул—элекке музыкант, пианист, инде унсигез яшендә үк симфоник оркестр белән концертлар куеп йөргән. Ана гаҗәп матур киләчәк юраганнар. Ә хәзер, эчеп юкка чыккан бу маэстрога карап, Дасаев, бик теләсә дә, аның шундый данлыклы үткәнен күзалдына китерә алмый иде.

Бервакыт Дасаев биредәге еш алышынып торган төркемнәр арасында үз вакытында бик атаклы булган футболчыны күреп алды, ул йөз меңләгән футбол сөючеләрнең алласы, ана гашыйк-мөкиббән китүчеләрнең исәбе-хисабы юк, матбугат аны кайвакыт Пеле һәм Беккенбауэрларга тиңли иде.

Сәләтле һәм гаҗәеп оста уены белән бихисап кешеләрнең күңелен яулап алган, кайчандыр көч-җегәре ташып торган бу чибәр, яшь егетне күрү Дасаевны көтелмәгән бер фикергә китерде. Табиблар, им-томчылар гомер бакый кешенең гомерен озайту, аны яшәртү чараларын эзләгәннәр. Бу авыр, четерекле юлда кешелек дөньясы ниндидер уңышларга ирешсә дә, аның нәтиҗәләре бик кечкенә, шулай да ниндидер мөмкинлекләр барлыгы бераз өмет тә калдыра шикелле. Аның каравы, кеше фән ярдәменнән башка да үз-үзен бетерү юлында гаять зур уңышларга ирешкән! Рушан әкренләп шәраб диңгезенә батып баручы әлеге футболчының хәрәкәтчән-житез, сыгылмалы-көчле, искиткеч акыл-зиһенле, яшь-чибәр чакларын яхшы хәтерли әле. Ә хәзер...

## II

Рушанга инде илле тулып килә. Аз түгел... Хәтерли, Фадеевның «Тар-мар» романыннан ул шундый бер җөмлә укыган иде: «Мунчада кырык яшьләрдән узган карт юынып утыра...» Әгәр дә инде кырык яшьтә үк карт икән—димәк...

Менә ана да гомер йомгагын төеннәргә иртәрәк әле. Әмма еш кына күңелен сагыш-моң баса һәм ул Ташкенттагы фатирында, күптән юылмаган тәрәзә каршында, озын кичләрдә отыры озаккарак калып басып тора, пычрак ишегалдында аңа әллә нинди сәер күренешләр

кузаллана. Кайвакыт аңа бер үк китапны, башы-азагы булмаган, бик күп геройлары чалынып-чалынып кына киткән бер романны үзе берьюлы яза да, укый да, экранлаштыра да шикелле тоела. Әмма ни өчендер ешрак полуторка машина әрҗәсендәге малай хәтеренә төшә...

1949 ел. Рушанга сигез яшь.

Бәйрәмчә кызылга төренгән, һәр җирдә транспарантлар балкып торган көнне ул яхшы хәтерли, фронтовик үги әтисе эшли торган җирле артельнең полуторкасын күрә. Менә машина аулак райүзәкнең күрше урамына парадка кузгалып китәргә җыена, әмма байраклар тоткан кешеләр белән дыңгычлап тутырылган машина әрҗәсенә иң соңгы мизгелдә теге малайны да күтәреп алалар. Әкәмәт малай ул—өстендә бугазына кадәр төймәләнгән яшькелт хаки төсендәге китель, пөхтә чалбар, тик лампаслары гына юк.

Лампаслар турындагы уй шунда ук күңелгә килә, чөнки кая карама, тирә-юньдә Юлбашчының төсле портретлары—алар менә дигән яхшы кәгазьгә басылганнар, фанер такталарга пөхтәләп ябыштырылганнар, кайберләре пыялалы рам эчендә, аларны һәр колоннаның башында күтәреп баралар. Малайның да бәйрәм костюмы Юлбашчыныкы төсле үк, ә сул як күкрәк кесәсе өстендә чит ил ордены балкый, күрәсең, әтисенекедер. Аксыл житен чәчле малайны машинага күтәреп биргән ир кешенең күкрәге дә орден-медальләр белән тулган, алар атлап йөргәндә, алтын-көмешләрен, бакырларын балкытып, искиткеч матур чыңлыйлар.

Бәйрәм көнне бүләк алырга артель янына җыелган малай-шалай машина ягына көнләшеп карап-карап куя. Аларга бит «Кызыл мәйданга»—партия райкомы янындагы мәйданчыкка җәяү тәпиләргә туры киләчәк. Андагы тузанлы кечкенә бакча эчендә бер-берсенә кара-каршы баскан кыска аяклы ике гипс юлбашчы һәйкәле тора, аларны бәйрәмгә алтынсу төскә буяп, янартып куйганнар.

Генералиссимус кебек итеп киендерелгән малай Рушанга таныш түгел, артельдәге утренникта да юк иде ул. Рушан янында торган иптәшеннән ул бәхетле малайның кем икәнлеген сорый. Арттан кемдер: «Женя Дудченко» дип пышылдый, ләкин бу исем-фамилия Рушанга бер нәрсә дә сөйләми, аларның мәктәбендә андый малай юк.

Европа белән Азия чигенә терәлеп үк диярлек утырган дала поселогы Мартук зур түгел, шулай да бик кечкенә дә түгел, аның төп дәрәҗәсе-абруе шунда—ул тимер юл буенда. Еракгагы экияти шәһәрләргә: Ташкент, Алма-Ата, Сталинабад, хәтта ниндидер Курган-Түбә яки Җәләлабадка ашыгучы поездларның һәрберсе биредә туктап ала.

Сугыштан соң поселок дәррәү үсә-төзелә башлады, райүзәккә даладагы караңгы авыллардан һәм Урал арьягындагы ерак казак станицаларыннан кешеләр агылды, әмма күбрәге Көнбатыштан килгән качаклар иде.

Рушан Мартукның иске өлешендә яши. Ул Татар бистәсе дип атала, анда мөселманнар—күпчелеге татарлар, казакълар, башкортлар. Соңгы елларда чеченнәр дә килеп төпләнгән иде.

Күрәсең, житен чәчле малай яна күченеп килүчеләрдән һәм поселокның икенче башында яшидер, әмма ни өчендер хәтергә уелып калган—«Женя Дудченко». Шулай килеп чыкты, Рушан аның белән үз тормышында тагын бер кат очрашты әле. Ташкентка китәр алдыннан поселоктагы элеватор төзелешендә бераз прораб булып эшләп алганда булды бу хәл. Женя ул вакытта армиядән яңа гына кайтып төшкән һәм эш эзли иде, ә райүзәктә эш табу, ай-һай, җиңел түгел. Билгеле инде, Рушан аңа эшкә урнашырга булышты. Ул вакытта Женя төз-озын гәүдәле, гаять ягымлы егет иде, шулай булып истә калган да.

Озакламый Рушан туган якларыннан китеп барды, әти-әниләре янына кунакка сирәк-мирәк кенә кайткалап йөри башлады. Шундый кайтуларының берсендә җыелышып Илек суы буена бардылар. Ул вакытта елга әле заводтан аккан пычракка батмаган, мул сулы иде. Бик ерακта калган яшьлек елларын искә төшереп утырганда, кинәт кенә теге малайның

фамилиясе калкып чыкты—ул хәзер шәһәр ГАИсында эшли икән.

Алар беркайчан да дус та, дошман да булмадылар. Тормыш юллары, мәнфәгатьләре бервакытта да кисешмәде. Икесе дә тимер юл буендагы ярлы поселоктан чыккан якташлар алар—бары шул гына. Бу поселок Рушан өчен дә, Женя өчен дә—кечкенә ватан.

Бәлки ул да вакыт-вакыт йокылы поселокның җәйге төннәрен исенә төшерәдер. Нинди сихри, тылсымга төренгән күренешләр алар. Күк йөзен тутырып балкыган ай яктысында ташландыкка әйләнгән, пычрак урамнарның ярлылыгын сизмисең, шәрекъ эсселегеннән әлсерәгән бакчалардагы сирень һәм сәрби куаклары башка бер гүзәл һәм матур бер тормышның сихри күренешләре булып тоела башлый. Ә бәлки, бурап яуган карбураннар, көрткә баткан урамнар, салкыннан боз-бизәккә төренгән тәрәзәләр артындагы җылы утлар, салкын күккә сызылып-сызылып күтәрелгән төтеннәр белән кыш күз алдына киләдер. Һәм, мөгаен, тормышында бер мәртәбә булса да, ул да Пушкинның «ватан төтене» дигән гыйбарәсе нәкъ менә шушы—туган йортның җимерек морҗасыннан саркып кына чыккан көчсез төтендер ул, дип уйлап куйгандыр.

Кем белә, бәлки, бөтенләй алай түгелдер, әнә бер нәрсә дә күзалланмый да, ишетелми дә, тимер юл буендагы поселокка да кайтасы килмидер, үткән еллар эчендә анда ни-нәрсә генә үзгәргәндер, һәркайдагы шикелле, анда да барысы да җимерелеп-таркалып барадыр...

Рушан бит ул егетне бөтенләй дә белми, аның белән күңелен ачып беркайчан да сөйләшкәне, акыллы мәҗлесләрдә янәшә утырганы булмады, аның хатыны кем, балалары бармы-юкмы икәнен дә белми. Ә бәлки, Дудченконың хатыны Рушанның элекке сыйныфташыдыр яки Украина урамында яшәүче, кайчандыр үзе танцыдан озата кайтып, аны-моны уйламыйча, караңгы төндә үбешкән берәр гүзәл чыркылдык кыздыр. Аңа да, кызга да бернинди җаваплылык йөкләми торган яшьләрчә беркатлы-самими үбешү... Вакытлар чылбыры өзелгән, туган йорт белән бәйләп торган җепләр черегән...

Яшьләр, туган ояларын ташлап, ни өчен икәнен дә төшенеп җитмичә, каядыр ерак якларга китеп барырга ашкыналар. Аңлашылмаган ерак җирдәге кызларга, гыйшык-мәхәббәт тотып та тормастан, ашыкпошык өйләнәләр, кызлар исә шул килмешәк «принцларга» кияүгә чыгалар. Аннары кияүнең йә киленнең туганнарына кайту бер як өчен тәмам газапка әйләнә, чөнки һәркайсысы үз йортын сагына, үз инеше, үз урамы, үз дуслары төшләренә керә. Еллар үтә тора, бер-берсен үпкәләтмәс, хәтер калдырмас өчен алар ике якның да әти-әниләре, тугантумачалары янына кайтмас була, мыжгып торган тәмугка—Сочига яки Ялтага йөри башлыйлар, шулай итеп тамырлар бөтенләй өзелә. Бары тик сиздермичә, әкрен генә гомер кояшы баеп барганда, тормыш куакуа үзен абайламый да калган җете ачык көннәр эреп бетеп килгәндә генә, кинәт бугазына төер килеп утыра, полуторка машинадагы малайны исенә төшерәсең, кайчандыр урам аша гына чыгып, күршеңнең янкапкасын киереп ачып:

—Исәнме, Женя! Хәтерлисеңме?..—дип сөйләшеп торыр чакларның узып киткәнлеген белеп, эчеңнән сызланасың.

Бәлки, шунадыр да дүртенче каттагы фатирның күптән юылмаган тәрәзәсе яныннан сәгатьләр буена китеп булмый, тәрәзәдән күңелсезбоек ишегалды гына күренсә дә, бөтенләй башка нәрсәләр күзаллана һәм, соңлап булса да, күңел күзе ачылып китә...

Һәм үлеп беләсе килә: үзең белән бергә тәүге адымнарың ясаган, бер мәктәптә укыган, бер партада утырган, бер урамда, бер кварталда яшәгән, бергә октябрят булган, аннары соңрак дулкынланып-шатланып пионерга кергән, сугыштан соңгы бишьеллыклар чорындагы ярлы гына җәйге лагерьларда учак якканда бергә җылынып утырган кемнәр кайларда да, кайсысы кем булган, аларның язмышлары нинди икән?

Бергә бары тик ике генә кыш укып калган, җирән тиенгә охшаш

Валечка Велигдановаың сукмак-эзләре кай якларга китеп югалды икән—аның әтисе станциядә милиционер иде. Райком секретаре кызы Диночка Могилева кайда хәзер? Сугыш азагында гына поселокка килеп чыккан һәм әтисе белән күрше урамдагы землянкада яшәгән Вилли исемле немец малае кай тарафларда тапты икән язмышын? Аларның ул землянкасын йорт йә алачык дип әйтергә тел дә әйләнми иде бит.

Ул Вилли белән нәрсәләр булып бетте икән? Үзенең тук-мул Гамбургында даладагы поселокны, үзенең футбол капкасын бар көчен куеп саклаган чакларын, шактый шома гына татарча да, казакъча да сөйләшергә өйрәнеп йөргән чакларын хәтерлиме икән? Вилли белән аның әтисе турында поселокта шактый озак сөйләнделәр, чөнки алар Көнбатыш Германиягә илленче еллар башында ук китеп барган иделәр. Имеш, аларның бик тә югары дәрәҗәле туганы табылган, әллә генерал, әллә банкирмы шунда, дигән хәбәрләр дә йөрде. Үзенең балачагы узган поселокка күңеле белән генә булса да тартыламы икән бай Германиядә яшәп ятучы ул кеше? Әллә инде ачлык-ялангачлыкны, салкын землянкада бетләп бетеп, кимсетелеп-рәнҗетелеп яшәгәнен тизрәк онытырга тырыштымы икән?

Бу сорауларга гомергә дә җавап табасың юк—Виллиның эзләре мәңгелеккә югалган... Шуңадырмы, сирәк кенә булса да, йөрәкне сагыш-моң кысып куя...

Аннары тагын ни өчендер сыйныфында икенче елга утырып калган Коля Верноквас искә төшә. Егерме еллар элек Верноквасны хөкемгә тартып, атып үтергәннәр—мәктәпнең биш сыйныфын да ерып чыга алмаган, гомеренә «икеле»ләрдән башы чыкмаган ул кемсә Ростовта бер банданың атаманы булган, кешеләрне кычкыртып талап йөргән һәм күпләрнең җанын кыйган булган икән...

Дасаев әле бишенче дистәне дә тутырмаган кеше, әмма инде аңа пенсиягә дә күп калмаган. Прораб эше бик авыр хезмәт бит. Ә ул төзелешкә утыз ел гомерен бирде диярлек. Менә шушылай уйланып утырырга хирыслыгын ул шактый соңрак аңлады, тик үзенең тормышка булган карашларын беркем белән дә уртаклашмады. Ул үзе өчен яңадан ачкан хакыйкать ачы иде, әмма алар барыннан да элек аның үзенә кагыла торган хакыйкатьләр иде...

Үзе ачышка тиң дип тапкан бу нәрсәләр күптәннән инде акыллы трактатларда чагылдырылган, ул хакта әдипләр вә фәйләсуфлар тау-тау китап язып калдырган, әмма алар бит чит-ятларның тормыш тәҗрибәсе, ә монда Рушан һәрберсенә үз акылы-зиһене белән, эчке сизенүе белән барып житә. Әнә шул тәрәзә аша дөньяга багып торган хәлендә, ясый ул үз ачышларын.

Әгәр дә башында кайнаган уй-фикерләрен кәгазьгә төшерергә тырышып караса, бик мөмкин—алар үтә беркатлы һәм игътибарга лаек та булмас иде. Әмма бөтен хикмәт тә шунда шул, ул ниндидер гомуми фәлсәфәләргә бирелә белми һәм аны теләми дә, ә һәр нәрсәне йә үз тормышына, йә үзе белгән, үзе яраткан, үзе аралашканнар мисалына күчерә. Шуның өчен дә хәтерендә Вилли дигән малай яки күрше сыйныфта укыган чибәр кызый Роза Хәмидуллина калкып чыга. Ул кыз Яңа ел бәйрәмендә «Төн» булып киенгән иде. Кара тәскә манылган гап-гади марляга такта чәй төрә торган көмешсу фольгадан кисеп йолдызчыклар тегеп куйган иде ул. Ярлылык-хәерчелек һәрвакыт шундый хыялларга, нәрсә дә булса уйлап табарга һәвәс була шул. Кызның башында шул ук фольгадан ясалган көмеш таҗ балкый, әйтерсең лә, ул чын патшабикә иде! Таҗына шоколад конфетлардан калган алтынсу төстәге икенче фольга белән «1951 ел» дигән сүзләр беркетелгән.

Рушанның соңгы вакытларда шулай еш кына үткәннәргә әйләнеп кайтуының сәбәпләрен, аның һәркөнне диярлек балачагына, яшьлек елларына сәяхәтләрен ничек дип атарга да белмәвен хәзер инде аңлатуы да авырдыр. Нәрсә иде соң бу? Истәлек-хатирәләрме? Алай дисән,

истәлекләр үзеннән-үзе, синең ихтыярың-акылыңнан башка, күңел төпкеленнән һич көтмәгәндә калкып чыгалар иде. Юк, «истәлекләр» дигән бу кыска төшенчә аның күңел халәтен чагылдырмый. Әйтерсең ул дуслары-сөйгәннәре, бик тиз шаулап узган яшьлек еллары турында мавыктыргыч китап укый кебек иде.

Йончыткыч, хәлдән тайдыргыч көндәлек авыр хезмәттә озак еллар әвәрә килеп, ул аларны үз вакытында юньләп аңламаган да, тоемламаган-сизмәгән дә, ә менә хәзер соңлап, бик соңлап күптән онытылган кешеләрнең төс-кыяфәтләренә күңеленнән генә булса да бага, бүгенге тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, шул чордагы вакыйгаларны яңадан аңларга, кичерергә тырыша. Ул башы да, азагы да булмаган мәңгелек бер китапны укый шикелле, шул китапка даими рәвештә яңадан-яңа сәхифәләр өстәлә тора: кайбер вакыйгалар вакыт-вакыт яңа төсмерләр ала, шунлыктан булып үткән хәлләрнең баштагы мәгънәсе кискен үзгәрә, күңелдә урнашкан образлар буталып бетә.

Аның, әлбәттә, ишеткәне бар: хәзер авторлары тарафыннан бик тә хәйләкәр уйланылган, еш кына башы да, ахыры да юк кына түгел, хәтта сюжеты һәм геройлары да булмаган китаплар аз басылмый—ничек теләсән, шулай аңла син аларны. Андый китаплар елгыр тәнкыйтьчеләр өчен шатлык инде—тетмәсен тетеп кенә ташла! Әдип язганнардан да буталчыграк итеп теләсә нәрсә язарга була, бик горур кыяфәт, зур дәгъвалар белән мондый алымны «үземчә укуым» дип атарга була, теге яки бу әдәби агымнарга ачы-үткен, әмма үле туган төшенчә-билгеләмәләр: «параболик, интеллектуаль, спираль, синусоид проза, акыл агышы, дөньяны танып белү рәвеше» кебек сүзләр тезәргә була.

Ләкин болар барысы да шайтан коткысыннан, чит уй-фикерләрне чарпалаштыру-бәрелештерүдән, башкаларның тормыш тәҗрибәсен ботарлаудан килеп чыккан нәрсәләр—шулай булган һәм бар булганы да шул. Ә Рушан исә үз язмышына юньле-башлы үзе хуҗа да түгел, кая инде ул башкалар турында сөйләнеп торырга—ни Аллаһы Тәгалә, ни хөкемдар түгел бит ул... Кайвакыт ана әлеге «мәңгелек китапны» үзе укый гына түгел, үзе үк яза да шикелле тоела. Юкса, үз гомерендә хезмәте буенча галәмәт озын, күңелсез исәп-хисап кәгазьләреннән тыш бернәрсә дә язганы булмады, ул «өлешенә чыккан көмешен» белә һәм хыялларында алай бер дә күкләргә ашмый, ул, гомумән, үз урынын, үз эшен белгән кешеләрне хөрмәт итә иде.

Гомер юлының күп өлеше үтелгәнлеген аңлагач, дусларын һәм якыннарын югалтып бетергәч, ул, ниһаять, вакытның гына түгел, үз буынының, җанга якын кешеләрнең китә баруын тойды—алар белән бергә шул чордагы гореф-гадәтләр, йолалар, үз-үзеңне тоту рәвешләре, традицияләр, тел үзенчәлекләре, уен-көлкеләр, җырлар, хәтта табигать күренешләре, һава үзе һәм тормыш-көнкүреш—барысы да юкка чыгып бара иде. Бу күңелсез санап-барлап чыгуларны прораб чиксез дәвам итә алыр иде, бик күп нәрсәләр уйлап-нитеп тормастан һәм ашыгычлык белән тормыштан сызып ташлана, кысып чыгарыла шул. Шулай моңсу сагышка бирелгән мизгелләрендә аңа инде алардан соң килүче буыннар аларның ничек яшәгәнлекләрен, нәрсәләр турында хыялланганлыкларын—ә алар бит меңнәр вә меңнәр!—яңадан һичкайчан белмәс-аңламас кебек тоела иде.

Язмыш бер дә иркәләмәгән, инде китеп баручы үз буыны кешеләре кызганыч иде аңа, әмма тагын да авыррагы илнең рухи тормышында яки тарихта үзләренең сизелерлек бер эз дә калдырмыйча китеп баруларын аңлау иде. Зыялылар, хәтта аларның иң юньсез, юлдан язган вәкилләре турында күпме китаплар язылган—алар шулай сөйгәннәр, янган-көйгәннәр, шулай газапланганнар, алар шундый бәхетсез булганнар, тормыш акыллы вә талантлыларга һәрчак шундый гаделсез булган...

Шундый чакларда Рушанның шәрран ярып кычкырасы, сорыйсы килә иде: «Ә без бәхетлеме? Безгә тормыш-язмыш рәхим-шәфкатьлеме?

Безме яратмаган-сөймәгән? Безме хыялланмаган?»

Менә шулай күңеле тулышкан минутларында аның утырып бик зур китап язасы килә башлый иде. Ул китапта мәктәптән соң бер дә очрашмаган сыйныфташы Верочка Пейзюкның тормыш юлы да, шул Верочканы яратып йөргән Толик Чипигин турында да язылган булыр иде. Хәер, Чипигин күптән юк инде—ул гап-гади ангинадан вафат булган. Аннары, мөгаен, яшел күзле Томочка Солохо турында (аның абыйсы Толик үзенә таныш булмаган бер кызны коткарам, дип, күлгә батып үлде), күрше кызы чибәр Валя Панченко турында да язар иде ул. Станциягә практикага килгән һөнәр училищесы укучылары белән Алик Штайгер җитәкчелегендәге поселок егетләре шул кыз өчен чын-чынлап сугышкан иделәр.

Хәтерли әле, икенче көнне иртән алар мәктәптән хастаханәгә йөгерделәр, анда безнең егетләрнең яраларын бәйләгәннәр, ә башы марляга чорналган һәм күз төбе зур булып кара янып чыккан Толик Крицкий, ачуы килеп, әсәренеп кемгәдер сөйләнә иде: «Ни пычагыма кирәк булды инде ул Панчуха миңа?!» Шунда ук, авыруларны кабул итү бүлмәсендә шәһәрдән килгән ике тикшерүче шәйләнә һәм бу вакыйга күпләр өчен шактый күңелсез тәмамланган иде. Әллә кем дә булса болар турында китап язар, ул китапта сөйкемле-гүзәл Панчуха һәм маңгай чәчләре күзенә үк төшеп торган, хәтта судта да Мартук кызларына елмаеп карап утырган гайяр егет, үзен герой итеп тойган һөнәр училищесы укучысы булыр иде дип уйлыйсызмы? Рушан моның буласына бер дә ышанмый иде.

Бәлки, шунадыр да, хәтерендә кемне булса да яңартса, ул аның язмышын ачыкларга тели һәм, һичшиксез, аны үзе язарга теләгән әлеге «мәңгелек китабы»на теркәп калдырырга тырыша иде.

Шулай бервакыт очраклы гына ул үзен «Мәскәү-Ташкент» поездының вагон түбәсендә баручы ундүрт яшьлек малай итеп хәтеренә төшерде. Кулында кечкенә генә төенчек, шәһәргә ул техникумга керер өчен документлар илтә иде. Матур җәйге көн. Каратугай күперен узуга,—күптән түгел генә шушы күпердә сыйныфташы Алешка Верещакның абыйсының башы өзелгән иде,—Рушан, түбәдән-түбәгә сикерә-сикерә, поездның койрыгына таба йөгерде.

Шул чагында ул үзен хәтәр оста-житез, көчле һәм бәхетле итеп тойган иде—моны сүз белән генә әйтеп бетерешләме соң?! Аңа тулы дүрт ел буе шәһәрдә яшәргә туры киләчәк, әле үзе бер дә булып карамаган шәһәр исә әкәмәт ымсындырып, бик теләгәндә барлык уй-хыялларын тормышка ашарлык бер әкияти җир булып тоела иде.

Менә шушы шатлыклы тойгы, якындагы бәхет малайның күкрәк читлегенә генә сыеп бетмәде, ул кинәт кенә түбә уртасына басып туктап калды, төенчеген төтен торбасы янында калдырып, кулларын төшлеккә житеп килгән кояшка таба күтәрде, ташыган хисләреннән әсәрләнеп кычкырып җибәрде: «Мин шәһәргә барам!..» Каршы искән җил аның кайнар иреннәреннән ургылып чыккан авазны йолкып алып китте, ә поезд исә инде өлгереп килүче алтын башаклы иген кырлары буйлап иксез-чиксез казакъ далаларыннан алга таба да чаба иде, бодай басулары өстендә җинелчә дулкыннар гына йөгерешә.

Бәхете ташудан һәм әсәрләнүдән дөп-дөп типкән йөрәге сикереп чыгар төсле тоелган иде. Кинәт аны бер көтелмәгән уй көйдереп алды: «Бу тормышта мин кем булырмын, минем йортым-җирем кайда булыр? Хатыным нинди булыр—чибәр, ягымлы, акыллымы, әллә хәйләкәр, усалмы? Зифа буйлы сылумы, әллә нәзберек кенәме, зәңгәр күзлеме, әллә соры күзлеме? Улым булырмы икән? Ул кем булып үсеп житәр?»

Башына кинәттән генә әллә кайдан килеп кергән бу сораулардан аптыраштa калыпмы, ул кояштан кайнарланган вагон түбәсенә лып итеп утырды да, алга таба үзенең киләчәге турында уйланып бара башлады. Ана ул киләчәк бик ерак һәм томанлы булып, ә тормыш үзе «Мәскәү-Ташкент» поезды текелдәп барган күз күреме житмәс казакъ далаларыдай иксез-чиксез булып күренде. Ә яшь акыл колачлап ала алмаслык, ярлары

күренмәс тормыш дингезе еш кына күз алдавыч мираж гына була икән—ул бер кечкенә дача-бакча кишәрлегенә дә сыеп бетә ала һәм карашың күрше коймасына килеп төртелергә дә бик мөмкин. Рушанның байтак чордашларының тормышы—моның ачык мисалы. Поезд вагоны түбәсендә башында кайнаган төп сорауларына җаваплар Рушанга хәзер инде билгеле булса да, тормыш бер дә күнеллерәк, рәхәтрәк түгел иде.

Еллар үтә тора, ә сораулар һич кимеми, киресенчә, ишәя генә бара. Теге чакта, менә ул—аннын-зиһеннән ачылып, киләчәкне алдан күреп барган мөһим сәгате—1956 елның бәхетле җәе. Үсмер малайның әле татып карамаган яңа тормышка, шәһәргә китеп барган чагы. Ә туган якта яраткан кешеләр, алар белән бәйле якты балачак, беренче шатлыклар һәм күңелсезлекләр, мәхәббәткә охшаш тәүге хисләр калды...

## III

Ана җидеме-сигезме яшьләр иде. Аларның ерак туганы тиешле Сафия апа кияүгә чыга. Аны әнисе белән сукыр әбисе тәрбияләп үстергән—алар исә Рушанның Мәскәү янындагы сугышларда ятып калган әтисе ягыннан туганнар.

Ярлы поселокта бу гаилә шактый аерылып тора иде: калай түбәле зур гына йорт, бу якларда һич күрелмәгән, патша заманындагы Кузнецов заводларында эшләнгән тау-тау фарфор савыт-саба, Венеция пыяласыннан әкәмәт вазалар, көмеш чәнечке-кашыклар, залның биек түшәменә эленгән алтынсу кысалы бәллүр люстра... Гомумән, бу гаилә күпләргә билгеле иде. Сукыр әби чыгышы белән бик борынгы һәм бай татар ыруы Мәмлиләр нәселеннән булып, алар бу ерак, аулак якларга революциядән соң, Оренбургтагы табышлы йортларын һәм кибетләрен югалтып килеп төпләнгәннәр иде.

Кияү кәләшен алырга килгәндә, аны өйгә кертмиләр, хак таләп итәләр—мондый йола барлык халыкларда да бар диярлек. Татарларда исә ул «ишек бавы» дип атала, аның хәтта шундый такмагы да истә әле:

> Ишек бавы—бер алтын,
> Безнең апай—мең алтын...

Кияү алдында әнә шул «ишек бавын» тотуны, иң якын туганнары, дип, Рушан белән анардан бераз өлкәнрәк Мелис дигән малайга тапшырдылар. Кияү таза, базык гәүдәле Гали исемле егет иде. Кәләше янына керер алдыннан ул малайларның һәркайсына искиткеч матур сөяк саплы пәке бүләк итте, пәкеләрнең берсе кызыл, икенчесе яшел төсле иде.

Бу туй Рушанның үз гомерендә күргән иң беренче туй иде, шунлыктан булса кирәк, ул һәр мизгеле белән аның күңелендә гомерлеккә уелып калды: җыр-биюләре дә, сый-нигъмәтләре дә, кунаклары да... Өстәл янында яшьләргә әйтелгән теләкләрне дә һаман хәтерли әле ул. Андый теләкләрне бигрәк тә бүләкләр биргәндә мулдан яудыралар, матурдан-матур сүзләрне тезеп кенә торалар икән. Туйның әнә шундый мизгеле житте: залга зур поднос күтәргән бер кеше килеп керде, аның янәшәсендә кечкенәрәк подноска бер шешә шәраб белән матур итеп кисхәләгән, балда катырылган чәк-чәк куйган бер апа да бар иде. Кунаклар, көмеш подноска бүләкләрен салалар да, яңа өйләнешүчеләргә үзләренең матур теләкләрен әйтәләр, җавапка «рәхмәт» сүзе белән бергә бер рюмка махсус әзерләнгән шәраб һәм баллы чәк-чәк алалар.

Кияү белән кәләш артында басып торган Рушан, авызын ачып, бераз исерешә башлаган кунакларның теләк-тостларын тыңлый һәм Сафия апасы белән Гали җизнәсенең, гомер буе бер-берсен яратышып-килешеп, картайганчы тигез яшәячәкләренә, аларның берсеннән-берсе матур, сәләтле балалары булачагына, үзләренә әле менә бу туй бара торган

йорттан да мәһабәтрәк-гүзәлрәк йорт житкерәчәкләренә ихлас ышана иде. Ул яшьләрнең киләчәк бәхетләре өчен шулкадәр нык шатланды, хәтта кайсыдыр бер мизгелдә күнеле кыбырсып, көнләшеп тә куйды: аның үзенең туена чаклы бик ерак шул әле, аннары кәләшлеккә Сафия апасы кебек чибәр, шундый да унган, шундый да булган кыз, ай-һай, табылырмы икән әле? Ул хәтта Сафия апасын кияү жизнидән дә бераз көнләде бугай әле... Менә шулай...

Туган йортыннан читкә бик иртә чыгып киткән һәм Мартукка сирәк-мирәк кенә кайтып йөргәләгән Рушан, әгәр дә тагын кемнендер туенда яшь кияү белән киленгә әйтелгән шундый ук теләкләрнең сүзгә-сүз кабатлануын ишетмәгән булса, мөгаен, бу гаиләне бервакытта да хәтеренә төшермәс иде. Аның, билгеле, соңыннан да төрле туйларда булганы булды, ләкин һичкайчан күңелендә алдануга охшаш мондый ямьсез тойгы уянганы булмады. Бу вакытта ул инде ялгыз кичләрен әнә шулай тәрәзә буенда басып торырга күнегеп киткән һәм бер үк шәйдә үзе яза да, үзе укый да торган «мәңгелек китабы»ның беренче битләрен актара башлаган иде. Менә шул чагында көчле ихтыярлы сукыр әбисенең бердәнбер оныгын кияүгә биргәне, күптән булып үткән туй кылт итеп хәтеренә килде, Сафия апасы белән Гали жизнәсенең бөтен тормышлары күз алдыннан үтеп киткәндәй булды.

Аларның алдагы тормышында алтын-көмеш туйлар да булмады, үлгәнче яратышып-сөешеп яшәүләре дә барып чыкмады, имән кебек төптән юан, таза кияү жизни дә күптән вафат инде, армиягә киткәнче үзенең котырынкы холкы белән бөтен Мартукны дер селкетеп йөргән беренче уллары Хәлил дә бу дөньядан иртә китеп барды, кайчандыр бай булган йорт таркалып-бөлеп бетте. Исерек ызгыш-талаш, сугыш-тарткалашлар вакытында йорттагы Венеция пыялалары да, Кузнецов фарфоры да жил себереп алгандай юкка чыга торды, Мәмлиевләр монограммасы төшерелгән көмеш кашык-чәнечке, пычак-фәлән дә югалып, урланып бетте. Бары тик чебен пычратып бетергән бәллүр люстра гына түшәмдә ятимсенеп эленеп калды. Ә бит кайчандыр Рушанга үз күз алдында оешып килгән бу гаиләнең тормышы колачлап бетереп булмаслык шикелле тоелган иде, кояшлы көннәрдә үзенең ялтыр калай түбәсе белән үткән-сүткәннәрнең күзләрен сукырайтып торган, таза кызыл кирпечтән салынган бу сәүдәгәр йортының калын диварлары артында яшәүче һәркемнең язмышы әйтеп-сөйләп бетергесез серләргә бай булыр шикелле иде. Һәм ул серләр күз алдында диярлек шулай тиз, бик тиз ачылдылар да беттеләр, язмышлар языллы-укылды, тормыш китабының һәр бите актарылды. Чүп үләне басып киткән ташландык бакчага кыйшайган тәрәзәләрен чекерәйткән, яртылаш жиргә иңгән бу йортта хәзер Сафия исемле чал чәчле шапшак карчык ялгызы гына көн күрә. Кыршылып беткән паркет идәнле, күптән жыештырылмаган-каралмаган бүлмәләрдә элекке тәртип, чисталык-пөхтәлекнең эзе дә юк, ә карчыкны яшь, чибәр итеп, көнләшерлек бай бирнәле кәләш итеп күз алдына китерүе дә кыен. Ә бит Рушан бу йортның зиннәтле күркәм, бай чакларын белә, Сафияны кар кебек ап-ак туй күлмәге кигән килеш күргән кеше!

Барысы да кырылды да бетте... Бу гаиләнең фажигале язмышы үзе бер роман түгелмени? Кем язар аны? Мескен Мартук үзенең елъязмачысын кайчан көтеп ала алыр?

Әлбәттә, Мәмлиевләр ыруыннан булган туганнарның ачы язмышын Рушан үзенең «мәңгелек тормыш китабы»нда чагылдырып узмый калмады. Кешеләр хәтерендә нәрсә булса да сакланып кала барсын, күрсеннәр, гажәпләнсеннәр: Татар бистәсенең нәкъ үзәгендәге Украина урамында кислоталы яңгырлардан калай түбәсе череп төшкән ярым жимерек кызыл кирпеч зур йорт бармы? Бар. Ә бит ул йортның шаулап-гөрләп торган бәхетле көннәре дә бар иде, анда яшәүче сукыр әби исә дин кардәш мөселманнарның әхлаклы-иманлы булуларына күз-колак иде.

Бер иртә таңда бу йортның кыйшая төшкән янкапкасыннан әле

хәрби киемнәрен дә салып өлгермәгән кыю десантчы Хәлил йөгереп чыга да туп-туры станциягә юл тота. Аның ярты сәгать буена диярлек буш перронда тыныч кына арлы-бирле йөренгәнен күргәннәр, берәү дә егетнең коточкыч хәвефле уйларын сизенмәгән. Алма-Ата экспрессы «Казакъстан», йөрешен әкренәйтмичә, Мартукта туктамый-нитми үтеп барган чакта Хәлил кинәт кенә перроннан сикереп төшә дә хәтәр локомотивның алдына ташлана. Аның яшендәгеләр, ихтимал, сугыш вакытында дошман дзотының амбразурасына нәкъ менә шулай бер ыргылыш белән ташлана торган булганнардыр.

Перронда ярты сәгать буена арлы-бирле йөренгән соңгы минутларында ни-нәрсәләр уйлады икән Хәлил? Күнеленнән генә кем белән хушлашты икән? Ни өчен карап торуга бер сәбәпсез-нисез шулай җиңел генә, җан өшеткеч рәвештә тормышын корбан итте икән? Ә бит ул көчле ихтыярлы, тормышта үзенә тиешлене ычкындырмый торган сау-таза егет иде.

Күрәсең, аның турында белгән-ишеткәннәр булмаган, бу дөньяның ялганнарын, шәфкатьсезлеген кабул итә алмастай, җиңел яраланучан, самими-садә күңелле зат булгандыр. Бу хакта хәзер бары фараз кылырга гына кала, барлык серләрен Хәлил үзе белән алып китте, аны инде кайгы-хәсрәттән кибеп корышкан Сафия карчыктан башка беркем дә хәтерләмидер дә.

## IV

...Рушанга унике яшь, ул инде күптән пионер, отличник. Әле Иосиф Виссарионович Сталин да исән. Шул язда бугай, аның шәһәр-авылларны яшелләндерү һәм урман полосалары утырту буенча галәмәт зур программасы тормышка ашырыла башлады—бөек һәм изге эш-гамәл иде ул, хәзер ни генә сөйләмәсеннәр—бөек эш-гамәл иде, бүген инде шундый адымны кабатлау кирәклеге турында уйлап та бирмәстән, юлбашчының үзен дә бик сирәк телгә алалар. Шул язда Рушан утырткан зәгыйфь үсентеләр хәзер Мартукның Татар бистәсендә, туган йорты каршысында көчле карагачлар, колач җитмәс тирәк һәм өрәнгеләр булып шаулап утыралар—үсентеләрне мәктәп бушлай тараткан иде. Инде дала уртасындагы Мартук тирәсендә мәһабәт урман күтәрелде, хәтта кош-кортлары, киек җәнлекләре бар, гөмбә үсә, каралып карлыган пешә... Ул урманны юлбашчы боерыгы белән кешеләр үстергәнне хәзер инде бик азлар гына белсә-беләдер.

Әмма ул язын Рушан бер дә урман полосалары яки юлбашчы исеме белән генә бәйләп искә алмый. Әлбәттә, юлбашчы аның бөтен тормышы аша үтте, аның белән, теләсә-теләмәсә дә, беркем дә «очрашмый» кала алмады, әгәр дә хәзер инде кемнәрдер кимсетеп, аны бары тик Сосо дип кенә йөртсә дә, истәлек-хатирәләрдә Сталин исеме ары табан да калкып-калкып килеп чыга икән—бу бер дә модага ияру генә түгел, генералиссимусның күләгәсе ул елларда Мәскәүдән бик ерак булган Мартукка да төшә иде. Ул язда аларга әнисенең кайдадыр Ужгородта хезмәт итүче энесе Рәшит ялга кайткан иде. Менә шуның белән дә истә калган әле ул яз.

Рәшитне солдатка соңлап алганнар: ул тимер юлда башта кочегар, аннары, курсларда укып кайткач, паровоз машинисты булып эшли һәм ана нииндидер бронь тиешле иде. Армиягә киткәнче дә бу абый Рушан өчен күпне күргән, дәрәҗәле кеше булып тоела, бигрәк тә яка һәм җиң очларына көмешсу билгеләре тегелгән ярым хәрби кителен һәм укалап чигелгән чалбарын да киеп җибәрсә—беттең инде! Ялга ул өлкән сержант дәрәҗәсендә кайтып төште. Аякларында Мартукның иң оста итекчесе Петерс тегеп биргән шыгырдавыклы фырт күнитек. Хәрби устав кагыйдәләренә сыеп бетмәгән кием-салымнан тагын шәп шарф һәм кәҗә

мамыгыннан бәйләнгән ак перчаткалар. Мартукка ул март урталарында, әле кыш үз вәкаләтләрен язга тапшырыргамы-юкмы дип, йокымсырабрак яткан чакта кайтып төште. Әмма һавада инде яз исе аңкый, урамтыкрык чатларында беренче су тибеп чыга, кар көртләре күз алдында чүгеп-кечерәеп баралар, көндезләрен тәбәнәк түбәләрдән тамчылар тама иде... Әйе, яз—борын төбендә генә!

Март ае ул елларда аерым бер дәрәҗәле ай санала иде: ни өчендер мартта һәрвакыт сайлаулар була. Ул елны да сайлаулар булып, ул мартның соңгы якшәмбесенә билгеләнгән иде. Ә бу инде, поселокта сайлауларга кадәр бер ай кала, агитпунктлар эшли башлый дигән сүз.

Ах, ул сугыштан соңгы елларда Мартук кебек җирләрдәге агитпунктлар! Алар, ихтимал, бик күп сайлаучыларның хәтерләренә сенеп калганнардыр. Агитпунктта көн саен ярты төнгә кадәр ут яна, буфеты гөрләп эшләп тора, ә залда—аккордеон уйнавына кушылып, бию-танцылар, танцылар... Шулай итеп, уңган-булган өлкән сержантыбыз ялы белән нәкъ менә шул көннәрнең үзәгенә үк туры китереп баскан иде, ә бәлки әле махсус шуңа туры китереп кайткан булгандыр, сайлаулар турында алдан ук билгеле була иде бит.

Һәр кичне «Шипр» одеколоны сибенеп, шыгырдавыклы күнитекләрен көзгедәй ялтыратып алганнан соң, Рәшит, туганнарын күңелсезләндереп, өйдән чыгып югала һәм ярты төн үткәч кенә, тирә-юньдәге бөтен этләрне уятып кайтып керә иде. Ир-атларын сугыш шактый кырып салган поселокта солдат егетнең ялга кайтып төшүе эзсез калмады, әлбәттә. Мартук чибәрләре дә йоклап ята торганнардан түгел иде шул!

Рәшитнең ял алып кайтуы әлеге дә баягы сайлаулар белән генә бәйләнмәгән, нәкъ менә март аенда аның туган көне дә иде. Ул аны апасының өендә үткәрмәде, шуның өчен өйдә бераз үпкәләшүләр дә булып алды, ә станциядәге бер яшь кенә тол хатында үзенең яшьтәшләрен җыйды.

Рушанның әнисе белән Рәшит абый арасында бу туган көнне кайда үткәрү мәсьәләсендә каршылыклар чыкса да, әнисе пешерендетөшеренде—бөккән-фәләннәре дә, зур кәстрүл белән винегреты да, шактый кыенлык белән каяндыр юнәткән галәмәт бер үгез башыннан ясалган дердерие дә әзер булды. Рушанга исә йөгертеп кенә кибеттән шәраб һәм консервылар алу эше ышанып тапшырылды. «Сельмаг» кибетендә консервылардан диңгез кысласы—краб кына бар иде, сатучы хатын алмаска кинәш итте—күрәсең, малайны консервылары-ниләре белән кире борып җибәрүләреннән курыкты. Туган көн итеп мул гына сый-нигъмәтле өстәл әзерләнсә дә, Рәшит абыйсы туганнары янында озак юанмады—Рушанның үги әтисе белән чәкәшеп бер-ике рюмка шәраб эчеп куйды да станциягә китәргә ашыкты, мәҗлесне аннан башка гына дәвам итәргә калды.

Мөгаен, бу ялы, бу Туган көне Рәшит өчен ни-нәрсәседер белән бик мөһим булгандыр, Рушанның әнисе аның армиягә киткәнче тимер юлда эшләп җыйган-туплаган акчаларын уйлап-нитеп тормастан туздырып бетерә баруына борчыла иде. Ул заманнарда тимер юлда эшләү абруйлы санала, яхшы түләнә, әллә нинди льгота-өстенлекләре турында әйткән дә юк—илнең теләсә кайсы почмагына бушлай барып кайтудан алып бушлай күмер бирүләргә кадәр бар иде.

Гомумән, Рәшит абыйсы Рушанга бик юмарт, шат-көләч, ягымлы күренә һәм ул үзе дә аңа охшарга тырыша иде, ихтимал, апасының улына тормышта үз сукмагын табуда өлкән сержантның да йогынтысы аз булмагандыр.

Ә армиядән нинди бүләк-күчтәнәчләр алып кайткан иде ул! Рушанның әнисенә—соңрак авылларда гына түгел, шәһәр гүзәлләре арасында да бик модалы булган чәчәкле-чуклы искиткеч чегән шәле, үги әтисенә—Львов базарында сатып алынган чып-чын «Золинген» бритвасы, ә Рушанга—әкәмәт тә матур электр фонаре! Ул бүләккә балалар гына түгел, өлкәннәр дә исләре китеп көнләшеп карадылар, иллә дә

шатланган, илләә дә горурланган иде Рушан ул чакта! Соныннан армия хезмәтен тутырып кайткач, Рәшит абыйсы аңа Горький заводында эшләнгән зурлар велосипеды да бүләк итте әле. Велосипедның көпчәк өстендәге кысалары хромланган, кул тормозы да, матур фарасы да бар, утыргычы күннән, звоногы, багажнигы, арткы көпчәге канатында кып-кызыл булып стоп-сигналы янып тора, хәтта чылбыры өстендә чалбар балагы уралмасын өчен куела торган тимер капкачына хәтле бар иде. Бигрәк тә рамы алдына беркетелгән завод эмблемасы—горур боланның матур башы әллә кайлардан күренеп тора, ул, күрәсең, көязлеккә һәм тизлеккә ишарә булгандыр инде...

Рушан ул заманнардагы әйберләрне, тормыш-көнкүрешнең вак-төякләрен юкка гына шулай тәфсилләп хәтеренә төшереп утырмый, чөнки алар да үз хуҗалары белән бергә кире кайтмаслык булып юкка чыга баралар. Һаман да бер урында таптанып, яңадан велосипед уйлап чыгарып тормас өчен булса да, бик күп нәрсәләр турында сөйләп калдырасы килә. Әгәр дә бүген Халык хуҗалыгы казанышларының бөтенсоюз күргәзмәсе—ВДНХ дигән ялган-ясалма күргәзмәгә Рушанның кырык ел элек булган велосипедын, әлеге кесә фонарен, шуларга өстәп бөтен Европага атаклы заводның перламутр саплы пәкесен дә китереп куйсаң, валлаһи, эталон-үрнәк, хәзергечә әйтсәк, дизайн могҗизасы булырлар иде, ә инде сыйфаты һәм бәясе турында сөйләп тә торасы юк.

Кайсыдыр бер карт әйтмешли, кабахәт начар заман иде, әмма Иделдә балык бар иде. Ә бит ялга кайткан Рәшит абыйсы әле тагын бер банка хәлвә, шикәргә катырылган берничә кап мүк җиләге белән мармеладлы лимон кисәкләре һәм Һинд чәе дә алып кайткан—болар солдат акчасы да җитәрлек арзан товарлар иде. Хәзер менә күңеле төшенкелеккә бирелгән минутларда Рушан бездә бөтен нәрсәнең җимерелә-кырыла баруы, юкка чыгуы, кыргыйлануы турында әрнеп уйланып утыра...

Мондый уй беренче тапкыр моннан ун еллар элек, төрек шәһәре Эфеста дөньядагы җиде могҗизаның берсе дип йөртелгән борынгы Артемида гыйбадәтханәсе харәбәләрен карап йөргәндә башына килгән иде.

Хәтта ярым җимерелеп беткән булса да, ул гыйбадәтханә үзенең нәфислеге-гүзәллеге белән, очып китәрдәй җиңел корылмалары белән таң калдыра иде. Алгы ягы белән диңгезгә караган да, ул гүя дулкыннар өстеннән очып бара яки һавада тирбәлә төсле, борынгы төзүче осталар тарафыннан һәр миллиметрына кадәр уйланылган пропорцияләренең сере-тылсымы да әнә шунда аның.

Якыннан караганда гыйбадәтханә үзенең галәмәт зурлыгы белән һушыңны китәрерлек булса да, эченә кергәч, Рушанны ниндидер җиңеллек һәм нәфислек хисе чолгап алды. Чынлап та, дөнья могҗизасы! Рушан моны үзе төзүче буларак та, «Архитектура СССР» журналының егерме еллык нәзберек укучысы буларак та раслар иде. Союзда илле ел эчендә төзелгән иң әйбәт саналган биналарның барысын бергә алганда да, алар Эфес шәһәрендәге фәхешханә җимерекләренә дә тормыйлар, дип әйтергә була. Ул фәхешханәнең күрсәткеч тактасы бик яхшы сакланып калган: мәрмәргә уеп искиткеч гүзәл, гаҗәеп сылу ялангач хатын-кыз сыны ясалган, ә астарак—зур гына ир-ат аяк табаны һәм юнәлешне күрсәтә торган ук, мондый язуы да бар: «Әгәр дә сез почмактан борылып керсәгез, сезне ягымлы-назлы вә дәртле-дәрманлы хатын-кызлар каршы алыр». Төрек гидлары шаяртканча, ихтимал, бу язу дөньядагы беренче реклама-белдерү язуы булгандыр.

Шәһәрдән Артемида гыйбадәтханәсенә бик яхшы сакланып калган юл илтә, аңа безнең эрага кадәр яшәгән дипломсыз-нисез, без хәзер шапырына торган белемнәрсез архитекторлар тарафыннан проектлаштырылган эре ак мәрмәр плиталар түшәлгән. Бу юл совет туристларын үтерде дә салды, чөнки аларның һәркайсысы белә: бездә берәр магистраль юл салып өлгермиләр, бер елдан анда инде машиналар «бөкесе» килеп

тыгыла, файдалана башлап бер ай да үтмәстән, капиталь ремонт кирәклеген сөйләп тә торасы юк. Менә шул чагында Рушан үзебезнең цивилизация турында төшенке уйларга бирелгән иде, юкса хәзерге дөнья цивилизациясендә Советлар иленең үзенә аерым бер урыны бар-барын...

Берничек тә тыеп, идарә итеп булмастай хәтере кинәт кенә үзен илтеп ташлаган борынгы Эфес шәһәреннән, гүзәл Артемида гыйбадәтханәсеннән, бөтен ихтыярын җигеп дигәндәй, Рушан янә дә ялга кайткан сержант абыйсының Туган көненә әйләнеп килде.

Дөресен әйткәндә, Туган көннең үзе турында Рушан бер нәрсә дә әйтә алмый—станциядәге тол хатын өендә үткән мәҗлес аның өчен сер булып калды. Әмма иртә белән уянгач, ул өстәл өстендә Рәшиткә бирелгән гади генә бүләкләрне күрде: портсигар, гәрәбә мөштек, тар гына ак атлас шарф, мамык перчаткалар, әмма алар элекке кочегар фарсит итәргә ярата торган ак төстәге түгел, ә көрән иделәр, мөгаен, дөя мамыгыннан булганнардыр. Шунда ук куе зәңгәр тышлы калын гына китап ята.

Малайның карашы иң элек шул китапка төште. «Л. Н. Толстой. «Воскресенье»,—дип укыды ул китап тышындагы язуны. «Воскресенье...—бу нинди якшәмбе инде тагын?»—дип уйланды ул. «Воскресенье» сүзенең асыл мәгънәсе «яңадан туу» икәнен аңларлык малай түгел иде шул әле ул. Анысы соңлап, шактый соңлап килде... Аннары сәерсенеп кенә китапның эчен ачты. Титул битенә матур хатын-кыз кулы белән: «Кадерле Рәшиткә егерме биш яше тулган көнендә. Бәхетле бул! Раилә.»—дип язылган иде.

Баксаң, аның Рәшит абыйсына егерме биш яшь тулган икән, Рушанга ул әллә кайда, хыял ирешмәслек ерактагы еллар булып тоелды һәм әле бик озак шул «егерме биш яшь» сүзләре үз язмышын исәпләүнең баш саны булып торды. Абыйсы китеп барганнан соң укып чыккан әлеге зәңгәр тышлы китап та аның хыялларын кузгатты, чөнки райпотребсоюзда эшләүче чибәр бухгалтерша язган сүзләрдә ниндидер тирән яшерен сер ята, дип уйлый иде ул.

Китап кибетләренең киштәләре китаплардан сыгылып торса да, ни өчендер егерме биш яшьлек ир-егеткә нәкъ менә «Воскресенье» романын бүләк иттеләр икән? Малай шул турыда баш вата иде. Ә бәлки, «Воскресенье» бүләк алучының түгел, бүләк бирүченең берәр серен яшереп саклыйдыр? Кыскасы, малай үз хыял-фаразларында тәмам буталып бетте, Раилә апаны урамда очратканда аның чибәр йөзенә текәлеп караштыргаласа да, бу табышмакны чишәрлек нәрсә күрә алмады. Шул малайлык чорында ул үзенә дә егерме биш яшь тулган көнендә нәкъ шул романны бүләк итүләрен тели, бәлки, шул чагында Мартук бухгалтершасының серен ачар кебек тоела иде. Әмма бу балачак хыялы да тормышка ашмады—аңа Толстойны бала чагында да, соңрак та бүләк итүче булмады.

Ул вакытта, мәктәптән кайтканда да, аяк астындагы суларга да, язгы тамчыларга да, авыл советы янындагы карт өрәңгеләрне сырып алган шау-шулы кара каргаларга да игътибар итми Рушан, тик бер генә уй башын бораулый: абыйсы райпотребсоюз бухгалтершасына өйләнермеюкмы икән? Ул, Толстой томы атлас шарф кына түгел, Рәшит абыйсын җитди адым ясарга этәрә торган бүләк, дип ихластан ышана иде.

Аларның өйләнешәчәкләренә иманы камил булган минутларда Рушан әлеге бухгалтершаның нәселе булган Сиражетдиновларның малайларыннан кемнәр аның машинист абыйсы алдында «ишек бавы» тотып торачагы турында уйлана иде. Ә менә хәзер, инде күп еллар узгач, ул абыйсы турында бөтенесен дә белә, хәтта чибәр шәфталу йөзле, миндаль күзле бухгалтершаның да язмышы билгеле, ул аны бервакыт «мадам Баттерфляй» дип тә атаган иде әле. Әлбәттә, ул аларның тормышязмышларын махсус күзәтеп бармады, башкаларныкын да күзәткәнеөйрәнгәне булмады, әмма шулай да кирәкле хәбәрләр аңа ирешә торды, әйтерсең, ниндидер югары илаһи бер зат аның кайчандыр үзе яраткан һәм белгән кешеләре турында «мәңгелек китабы»н язарга уйлаганлыгын күреп торган.

## V

Рәшит абыйсы Роза Гомәровага өйләнде. Монын бер дә гажәпләнерлек нәрсәсе юк—аларнын әниләре бик әйбәт ахирәт дуслар иде.

Гомәровлар гаиләсе Мартукта бераз гына яшәп алды да, аннары көтмәгәндә генә шәһәргә күченеп китте. Рушан аларнын йортында булгаласа да, бу гаилә турында әлләни күп нәрсә белми—аларнын ниндидер серләре бар шикелле, төгәлрәк әйткәндә, алар башкалар аңламый торган ниндидер яшерен тормыш белән яшиләр иде.

Рушан хәтерли әле: Рәшит абыйсы өйләнгәнчегә кадәр, хәтта ул ялга кайтып, станциядәге тол хатында Туган көнен үткәреп киткәнче үк, Рушаннарнын өендә Розаның энесе Исмәгыйль ике атналап качып ятты. Ул гитарада яхшы уйный, тыпырдатып чечетка бии, әнисе Рушанны шул унай белән: «Уйнарга өйрән, биергә дә өйрән, шундый сәләтләрен булмаса, бәхетле дә була алмассын, кирәге чыгар»,—дип, ярты айлап игәүләде. Әмма, күрәсен, Ходай Рушанга бию сәләтен дә, гитара чиртеп, үзәк өзгеч төрмә жырлары жырлау һәвәслеген дә бирмәгәндер—ул тәки берсенә дә өйрәнә алмады. Сонрак, Рушан күрше шәһәрдә техникумда укый башлагач, ана Гомәровлар гаиләсенен кайбер серләре бераз ачыла башлады.

Розанын ир туганнары—Шамил белән Исмәгыйль жинаятьчел дөньяда зур абруй казанган—«авторитет» егетләр булып чыкты. Рушан йә тимерюлчылар сараена—«Тимерлеккә», йә Пушкин паркындагы жәйге бию мәйданчыгына, кышларын исә бик тә модада булган өлкә мәдәният йортына бию-танцыларга йөри башлагач, күпмедер вакыт бу «даннары чыккан» туганнары белән горурланып та караган иде әле. Өлкә мәдәният йортында саксофончы Эдди Костакинын атаклы джаз оркестры уйный, купшы-фырт Исмәгыйльне шәһәрдә Исмәгыйль бәк дип кенә йөртәләр, үзе кайчандыр качып яткан йортта тыпырдатып биергә һәм гитарада уйнарга өйрәтеп азапланган егетне күргәндә, ул һәрвакыт: «Бу студент—минем туганым»,—дип кенә жибәрә иде. Рушан өчен бу сүзләр ышанычлы сак кына булып калмады, үзен дә ничектер таныттырды, аны кем белән булса да таныштырганда: «Исмәгыйль бәкнен туганы»,—дип таныштыра башладылар.

Әмма Шамилгә дә, Исмәгыйльгә дә бию мәйданчыкларында еш биергә туры килми, әйтерсен, магниты бардыр—аларны төрмә дигәнен әледән-әле тартып ала тора иде. Иректә яшәү алар өчен авыр бер мәшәкать кебек иде бугай.

Рушаннын яраткан абыйсы әнә шул гаиләгә барып капты. Инде өлкәнәйгәч, Рушан Рәшитнен Гомәровлар гаиләсе белән үрелгән тормышы-язмышы турында еш уйлана, жинаятьче бертуганнарга да шаккатмый—аларнын әниләре Минсылу апага тан кала иде.

Табигать менә кемгә ныклык, елгыр зирәклек һәм булдыклылыкны өеп биргән! Шул шыксыз-ямьсез генә, эре шадра йөзле, ябык кына надан хатын әлеге усал-дәһшәтле гаиләне үз кулында биетеп тота иде. Республикада ул белмәгән судьялар, прокурорлар, адвокатлар, нотариуслар, суд башкаручылары, төрмә һәм тикшерү изоляторлары башлыклары, угрозыск башлыклары, гади тикшерүчеләр юк шикелле иде. Участок милиционерлары турында сөйләп тә торасы юк, ул хәтта лазаретлар һәм психушкалардагы табибларга хәтле барысын да белә. Ул бөтен этапларны, күчерү-озату лагерьларын, Караганда, Акмулла, Чимкент төрмәләрен күргән, хезмәт белән төзәтү учреждениелары өстеннән күзәтү-надзор алып баручы прокурорлар белән дә таныш. Ул теләсә нинди жинаять эшләре буенча адвокат контораларыннан да шәбрәк итеп кинәш-табыш итә ала, чөнки законнарнын да камил түгеллеген белә иде. Әгәр дә бер улы инде төрмәдә утырып, икенчесенен эше судта булса, ул Себердә урман кисүче яки Күмертау рудникларында интегүче токтыннар янында

яки нindидер район йә үз шәһәренең берәр суды арасында бәргәләнеп чабып йөрер иде.

Улларының берәрсе үз чиратында төрмәдән котылып кайтып керсә, ул гөрләтеп мәҗлес үткәрә. Шамилеме, Исмәгыйль бәгеме шунда ук паркта яки бию залларында пәйда була, өсләрендә—коверкот костюм, кунычына еш кына финка хәнҗәр кыстырылган шыгырдавык күнитек, хәзер инде күпләрнең төшләренә дә керми торган шыштыр-шыштыр салкынча ефәк күлмәк булыр иде. Шул заманнарда ук һәркайда Кытай товарлары сатыла башлаган иде, бертуган егетләр аксыл-сары габардин чалбарлар, «Дружба» тамгасы сугылган күн табанлы, чия төсендәге очлы башлы туфлиләрдән генә, бик көязләнеп, артык талымчан булмаган кызыкайларның күзләрен кыздырып йөрерләр иде. Әле берсе, әле икенчесе беренче-икенче мәртәбә генә түгел, чираттагы әйлә ничәнче туен шаулатып үткәрер, туганнары буларак, ул туйларда Рушан да катнашыр иде. Әмма, егетләрнең ирекләге тормышлары бик кыска булган шикелле, ул никахлар да озын гомерле булмаслар иде.

Костакинның джаз оркестры дангыр-донгыр уйнап торган җәйге парк ресторанында көн саен кәеф-сафа коручы бу елгыр бертуганнарның берәр көн генә кайда булса да эшләгәнлекләрен Рушан хәтерләми. Хет үтер менә! Ул шулай ук бу йортта бердәнбер мал табучы Миңсылу апайның нәрсә белән шөгыльләнгәнен дә әйтә алмас иде. Хәзерге тел белән әйткәндә, ихтимал, «Бөтерелгәндер, тапкандыр, алгандыр, саткандыр»... Ә бәлки, хокук саклау органнарындагы үзенең күпсанлы дуслары-танышлары вә әшнәләре белән законнарга бик үк буйсынмый яшәүчеләр арасында арадашчылык иткәндер. Кем белә?..

Хәзер инде һәркемгә мәгълүм: ул «гадел хөкем сарайларында», олысы-кечесе дигәндәй, һәркайсысы ришвәт алып утыра һәм елгыр-житез арадашчыларсыз андый гамәлләрне эшли дә алмый. Монысы—Рушанның фаразлары гына, соңлап күзе ачылуы. Чынлап та, бертуган Гомәровлар төрмәгә бик тиз барып та керә, бик тиз ирекка дә чыга иде. Хикмәте нәрсәдә булды икән шуның?

Роза әнә шул «даны чыккан» абыйлары белән кайнашып үсте. менә ул инде гитара да чиртә, тыпырдатып чечеткасын да бии, хисчән тынлаучыларны елата-елата кызганыч-моңлы итеп блатной җырларны да җырлый иде. Булдыра иде кызый!

Бертуган егетләр аның сайлаган киявен өнәмәделәр—алар сүзе белән әйткәндә, сеңелләре нindидер бер «пошига», «кочегарга» кияүгә чыккан, әмма шул ук вакытта бу никахка комачаулый да алмадылар, чөнки икесе дә чираттагы мәртәбә төрмәдә утыра иделәр. Җинаятьчел дөнья үзара меңнәрчә җепләр белән, шул исәптән, туганлык җепләре белән дә бәйләнгән, Ихтимал, бертуган Гомәровлар Роза аша үз душ-ишләренең берәрсе белән туганлашырга да теләгән булганнардыр. Роза чибәр генә түгел, ул җинаятьчел тормыш кануннарын да яхшы белә, шуның романтикасын тоеп-күреп үскән—кыскасы, бу эшләрдә хатын-кызларның катнашуы сирәк булса да, читтән килеп кысылган кеше булмас иде.

Бертуган егетләр ирекка чыккан чакларда аларда күчмә коштай кунаклар еш була—кем утырып чыккан, кем утырырга җыена, ә кемдер, чираттагы «уңышлы эшен» майтарган да, бер типтереп алырга дип, махсус килеп чыккан. Бу гаиләдә аларны сатмаячакларын, бәладә калдырмаячакларын белеп, озаклап качып ятучылары да булгалый, ул егетләр арасыннан да кемнәрдер Кармен кушаматлы бу кызга шук-наян күз аткалагандыр—аны «кулына гитара тотып тугандыр бу» дип сөйлиләр иде. Әмма ни хәл итәсең, Карменның йөрәген элекке кочегар егет яулап алды шул... Соңыннан, гаилә ызгыш-талашлары чыкканда, Роза да Рәшитне, абыйлары шикелле кимсетеп, «поши» йә «алаша» дип кенә йөртә башлады...

Бу гайре табигый гаиләгә килеп капкан Рәшитнең дә язмышы бик четерекле булып чыкты.

Чирек гасырлап вакыт сиздермичә үтеп тә китте—Рушанның күз

алдында бу кешеләрнең бөтен тормышы пыран-заран килеп бетте. Гаиләнең байтак кешеләре вакытсыз җир куенына керде.

Төрмәдән качкан чагында Исмәгыйль бәк һәлак булды. Анын ул әвәрәгә ничек катнашып китүен һич анлап та булмый, юкса ирекка чыгарына да нибары өч ай гына калган булган. Кайвакытларда Рушаннын күз алдына ниндидер Себер елгасынын камышлы уйсу яры килеп баса, шул камышлар арасында күзе яраланган Исмәгыйль бәк качып яткан бит. Анын үле гәүдәсен шул тирәдә яшәүчеләр сүнгән учак яныннан табып алганнар, дип сөйләделәр.

Кайдадыр себер тайгалары уртасындагы бер авылнын ярлы гына зиратында мәһабәт гранит һәйкәл—кабер ташы бар. Ватылмый торган пыяла астына бронза рамга беркетеп куелган фоторәсемнән чибәр генә яшь егет карап тора, ул бостон костюмнан, якалары пинжәк өстенә чыгарып куелган ак күлмәктән.

Әмма, үлгәннән соң да улын кешеләр алдына әйбәт итеп күрсәтергә тырышмаса, Минсылу апа Минсылу апа буламы сон? Кабер ташындагы туган-үлгән елларын күрсәткән кайгылы язудан аскарак сәрхуш скульптор эре хәрефләр белән «инженер» дигән сүзне дә уеп куйган. Кабер ташын куярга килгәч, әнисе шул тирәдә яшәүчеләргә улынын инженер булганлыгы, искиткеч бер проектны эшләгәндә җибәргән хаталары өчен хөкем ителгәнлеге, төрмәдән качуы да, аны көтеп ала алмыйча, кияүгә чыгып куйган сөйгән кызынын туена кайтып керү ниятеннән генә булганлыгы турында сөйләгән, имеш. Сөйгән кызынын туена кинәт кенә кайтып төшеп бу «инженер»нын нәрсә әйтергә теләгәне һич анлашылмый—күрәсең, Минсылу апанын шуннан артыгын уйлап чыгарырга башы җитмәгәндер. Әмма күз яшьләре белән сөйләнгән бу хикәят авыл халкы күңеленә сеңеп калган һәм хәзер өйләнешүче яшьләр ЗАГСтан чыгуга шушы кабергә килеп чәчәк салалар, ул каберне тугрылыклы тирән мәхәббәтнең символы итеп санын̆лар икән.

Әйе, Исмәгыйльнең үлеменнән соң килгән бу данына күп кенә чыгып ашкан җинаятьчеләр көнләшеп карар, кызыгыр әле. Аны искә алганда шундыйларның кайсыдыр берсе бик матур иттереп: «Ул бу тормышта җыр кебек янгырап үтте, безнен хәтеребездә дә шулай җыр булып калыр әле...»—дигән, имеш. Ә бу кавем арасында андый «чәчәклечуклы» сүзләр бик кыйммәт бәһаләнә. Сон, һәркайда ялганга төренеп яшәгән заманда бандитларнын кабер ташлары өстенә гади халык чәчәк сала икән, бу бер дә гаҗәп түгел. Картаеп барган Минсылу апа моны яхшы белә һәм тоя, шуна күрә дә үз вакытында кайсы якка борылырга кирәклеген дә яхшы чамалый иде.

Бер елдан сон, чираттагы туе вакытында колакка катырак Шамилне дә үтереп ташладылар. Бу юлы инде кабер ташы тирәсендә әкиятләр сөйләп торырга кирәк булмады, чөнки шәһәр халкы «инженер» Гомәровларнын кем икәнлекләрен бик әйбәт белә иде.

Улларынын бер-бер артлы үлеп китүе Минсылу апанын көченҗегәрен шактый суырды, яше дә үзенекен итте һәм ул калган бөтен бар булганын кызы белән киявенә күчерде, Рәшитне дә ул биләүдә чагыннан ук диярлек белә иде.

Рәшит тимер юл эшенә әйләнеп кайтмады—армиядә өч ел хезмәт иткән арада паровозлар электровозларга алышынган иде инде, ә яңадан укып өйрәнү өчен урта белемен булу һәм тагын күпме еллар сарыф итү кирәк булыр иде. Аннары шунысы да бар: тимер юлда эшләү күз алдында үзенең абруен җуя бара иде. Кайнанасы аны ит комбинатына урнаштырды, ниндидер бик авыр һәм пычрак цехка. Анда ул һәрвакыт ит түшкәләреннән үз кулы белән ин шәп кисәкне чабып ала һәм курыкмыйча алып кайтып китә—чөнки проходнойдагы вахтерлар Шамилнең вә Исмәгыйльнең элекке дуслары яки Минсылу апа үзенең органнардагы танышлыгы белән берәр бәладән коткарган кешеләр була иде. Озакламый Рәшит сугым цехыннан казылык цехына мастер булып күчте.

Ул вакытта инде Роза-Кармен тупылдап торган ике малай үстерә иде. Әмма бу балалар да гаиләгә иминлек-тынычлык китермәделәр. Һаман ызгыш-талаш, гауга-сугыш белән, савыт-саба һәм гитаралар ватып яши бирделәр алар. Чакырып торсалар да, Рушан аларга барырга яратмый иде.

Рәшит тә еш кына өеннән чыгып югала. Хәтта бервакыт Мартукка кайтып, ярты ел чамасы Рушаннарда да яшәп алды. Бу ярты ел, мөгаен, Рушан күңеленә генә уелып калмагандыр. Хикмәт шунда: Рәшит поселок ресторанында казылык цехы ачып җибәргән иде. Ул җитештерә-пешерә торган искиткеч тәмле казылыклар, сосиска-сарделькалар һәркемгә дә җитә иде.

Әмма Мартук халкы ул казылыкларны ашап озак юана алмады—Кармен ирен янадан үз йортына кайтарып утыртты һәм ысланган казылык исләре поселоктан гомерлеккә юкка чыкты.

Рәшит аннан соң да әле гаиләсен ташлап китеп йөргәләде, ераккарак, хәтта Ташкентка кадәр үк кыяклады—анда ул зур апасында бер елдан артык торды. Зиһенле, башлы һәм оста куллы ир шунда ук аякка басты, бик һәйбәтләп киенеп җибәрде, алтын тешләр куйдырды, ул вакытта бик модада булган юка гына «Полет» сәгате алып такты, анысы да алтыннан, хәтта браслеты-беләзегенә кадәр алтын иде. Ташкентның күптәннән, гомер бакый яшәп килгән «хезмәт биржасында» аны бик тиз шәйләп алдылар: ул газга көйләнгән тимер тартмалы түгәрәк мичләр ясый башлаган иде. Әлеге «биржага» ул беренче атнасында гына йөрде, аннары аны өенә килеп машина белән алып китәләр, ә кичләрен тамагы тук кызмача останы шул ук машиналар китереп тә куя иделәр. Ташкент бервакытта да төзелүдән туктамады, шуңа күрә анда оста кулларны хәзер дә бик хөрмәт итәләр, югары бәһалиләр.

Рушан үзенең беренче хезмәт ялын Рәшит абыйсы әнә шулай «акча суккан» елны Ташкентта үткәрде. Якшәмбе көннәрендә алар икәүләп Комсомол күлендәге җәйге ресторанга йөриләр иде. Рәшит абыйсы әле яшь, чибәр, әйбәт киенә, шуңа күрә хатын-кыз халкы аңа сокланып карый иде. Ләкин Роза-Кармен аны Ташкенттан да йолкып ала алды—абыйсы һаман саен шуның янына әйләнеп кайтырлык булгач, күрәсең, ул хатынның да нindидер хикмәти серләре-сихерләре булгандыр инде.

Шул җәйдә, кайчандыр атаклы булган «Регина» ресторанының куе йөзем куаклары һәм үрмә гөлләр белән уратып алынган верандасында кәефләнеп утырганда, Рушан берничә мәртәбә абыйсыннан ни өчен «мадам Баттерфляй»га өйләнмәгәнлеген сорарга талпынып карады, әмма кыюлыгы җитмәде. Бәлки, менә шул чагында ул аның егерме биш яшенә бирелгән бүләкнең серен, ни өчен Толстой, ни өчен «Воскресенье» романы икәнлеген белгән булыр иде... Ләкин ул сер бүгенгә кадәр ачылмаган сер булып калды.

Рәшит абыйсын ул янадан, бик күп еллар үткәч, үзенең үги әтисен җирләгәндә күрде, анда да күз кырые белән генә. Абыйсы нык картайган, авызындагы тешләре коелып беткәнлектән, яңаклары эчкә батып, йөзе ямьсезләнгән, элекке сөйкемлелегенең эзе дә калмаган иде. Кием-салымы да хәрт кенә, рәтләп кырынмаган да, ә бит яшьлегендә нинди көяз иде, әле соңрак, ресторанның казылык цехында мөдир булып эшләгәндә дә, тегенди-мондый гына егетләргә биргесез иде ул. Тавышы да, елмаюы да, нурсызланып калган күзләре дә—берсе дә элекке Рәшитне хәтерләтми, еллар аны бик нык талкыган икән...

Ташкенттан әйләнеп кайткач, Рәшит химзаводның иң зарарлы цехына эшкә урнашкан. Ул цехка зур хезмәт хакына кызыгып та беркем дә бармый, шуна күрә, кешеләрне ымсындырыр өчен, анда эшләүчеләргә күпмедер кишәрлек җир һәм йорт салыр өчен зур гына кредит бирә торган булганнар, Рәшит менә шуңа «чирткән» дә инде. Ул вакытта үзенә буйсындырып яшәтүче кайнанасы үлгән, Карменның юлдан язган абый-энесе дә бу дөньяда юк, юкса язмыш кешечә яши башларга мөмкинлек биргән булырга тиеш иде шикелле. Әмма бәхетле гаилә

тормышы тәки барып чыкмады аларның.

Рәшит шәһәр читендәге химиклар поселогында әкәмәт бизәкләр төшереп, иң зур йортларның берсен житкереп керде, аны кыйммәтле импорт гарнитурлар белән тутырды, хәтта Мәмлиевләрнең сукыр карчыгыныкы шикелле бәллүр люстра да элеп куйды, әмма йортка барыбер бәхет инмәде. Дөрес, элекке еллардагы кебек дүрт кулдан бәллүр һәм фарфор савыт-сабаларны кырып салмыйлар иде инде, әмма шулай да... Рәшитнең уллары үсеп житеп, тиз аякка бастылар һәм туган йорттан бер-бер артлы чыгып та очтылар. Берсе кайдадыр Камчаткада балык тота, икенчесе Чуйский тракты буйлап еракларга машина куа, Монголиянең иң караңгы аймакларыннан йөк ташый, хәзер инде чәчләре чаларган Роза-Кармен Себер белән Камчатка арасында чәбәләнеп йөри иде. Шундый йөрүләренең берсендә ул, бик каты салкын тигезеп, Петропавел шәһәрендә үлеп кала, аны чит-ят кешеләр шундагы хастаханә зиратына җирлиләр. Дингездәге улы әнисе үлеп утыз алты көн үткәч кенә кайтып төшә, Рәшит исә, хатынының үле хәбәрен алуга ук юлга чыкса да, һавалар начар тору сәбәпле, анда өч атнадан соң гына барып житә. Шулай итеп, язмыш дигәнең бу гаиләне дә дөньяның төрле почмакларына таратып ташлады...

Кайчандыр сокланып, «мадам Баттерфляй» дип йөрткән Раилә апаның язмышын Рәшит абыйсы язмышыннан аерып карыйсы килми иде Рушанның, ул бит Рәшит абыйсының райпотребсоюздагы шул чибәр бухгалтер кызга өйләнәчәгенә ихлас ышана иде. Раилә апаның да тормыш серләре ачылып бетте диярлек, аның да язмыш китабы укылды, аның тормышы шулай да тынычрак һәм иминрәк булды шикелле.

Раилә апа армиядән соң Караганда шахталарында «шактый күмер ашаган» башсыз-тәвәккәлрәк, шат күңелле бер егеткә—автолавка шоферына кияүгә чыкты. Шофер әле бик озак, кырык яшьләренә хәтле «Кооператор» командасында футбол да уйнап йөрде. Ихтимал, «мадам Баттерфляй» ире белән матур гына яшәгәндер дә—Милижан эшчән, хәйләсез, әйбәт холыклы кеше иде. Әмма чибәр ханымнарга кайда бәхет елмаюын, аларның кем белән бәхетлерәк булганын кем белә бит әле? Шунысы кызганыч, бу шофер бик иртә үлеп китте, сәгате-минуты эчендә инфарктан дөнья куйды. Рушан аларның кызлары барын, ул кызның хәзер Ташкентта табибә булып эшләгәнен дә белә.

«Рәшиткә егерме биш яше тулган көнне...» дигән күнел дулкынландыргыч язулы, куе зәңгәр тышлы Толстой томыннан әнә шундый истәлекләр калган иде...

## VI

Алтмышынчы еллардагы Ташкент Рушанның күңеленә хуш килде һәм ул андагы тормышка бик тиз ияләшеп тә китте.

Сентябрьдә театр сезоны ачыла иде һәм Рушан еш кына концерт залларына китеп югала башлады. Гастрольгә килүче артистлар Ташкентны йомшак, жылы көзе, мул жиләк-жимеше, халкының ачык йөзле, кунакчыллыгы, шәрекъчә ягымлылыгы һәм шәрекъчә хәйләкәрлеге, ашыкмый гына үз көенә яши белүе өчен яраталар иде. Шунлыктан Рушан моңа кадәр газетлардан укып яки радиодан ишетеп кенә белгән кемсәләрне һәр атнада диярлек күрә торган булып китте. Ул еллардагы чиктән тыш арзанчылык аңа дуслары белән рестораннарга йөрергә дә мөмкинлек бирә һәм ул үзе өчен исемнәре серле булган «Бахор», «Шәрекъ» кебек кызыклы урыннарны яратып та өлгергән, бигрәк тә әле революциягә кадәр үк булган күркәмлеген һич югалтмаган «Зеравшан» ресторанына йөрергә һәвәс иде. Күп еллар буена гел шунда кәеф-сафа коручылар аны искечә исеме белән «Регина» дип атыйлар, ә кинорежиссерлар, «иске тормыш кыйпылчыкларының» ничек итеп

типтереп яшәгәнлекләрен күрсәтергә мөмкин булганга күрә, ярата иделәр.

Ул ерак калган еллар джаз музыкасының гөрләп чәчәк аткан чоры булып, Рушан «Регина»ның купшы-бай көзгеле иркен заллары, зур-зур кисмәкләрдәге яшел пальма гөлләре, өстәлләргә матурлап тезелгән зәңгәр бәллүрләре һәм авыр көмеш кашык-чәнечкеләре өчен генә йөрми иде. Анда Ташкентның иң әйбәт джаз секстеты уйный, тагын да төгәлрәге,— негр шикелле кара-кучкыл йөзле, озын гәүдәле үзбәк егете, саксофончы Хәлил сихерли иде аның күңелен.

Хәлилнең бөтен залны яулап, әсир итеп уйнавында ниндидер дәһшәтле хәвефлелек тә, шул ук вакытта искиткеч гүзәллек тә, күңелләрне айкап-айкап ала торган сихер дә бар иде. Ялгыз соло—импровизация башкарырга аның чираты житкәндә, бөтен зал тынып кала. Егет торып баса да, күзләрен йомып, акыл томаланырлык транска бирелеп, чайкала-чайкала, тәмам хәлдән тайганчы уйный. Аның аскет дәрвишләрнекедәй бронза йөзе бөтенләй үзгәреп китә, изүләре ачык кызыл күлмәгеннән муенындагы кан тамырлары бүртенеп чыкканы күренә. Ул һәр уйнавын монысы соңгы мәртәбә дигән кебегрәк онытылып уйный. Күрәсең, үзенең гомере кыска буласын сизенгәндер, бахыр. Бер елдан соң, ресторандагы даны иң югары биеклекләргә менеп житкәч кенә, шау-шулы бер мәжлестә ярты төнгә кадәр уйный да, челпәрәмә китереп ваткан саксофонын һәм «Китәм, берәүгә дә начарлык теләмим» дигән язуын калдырып, агуланып үлә Хәлил.

Яшьлектә кешеләр белән жиңел танышып китәсең, жиңел аралашасың, бер-береңә тегенди-мондый юк-барларны гына сөйләмисең, ә бөтен йөрәк серләреңне ачып саласың. Рушан, әнә шул джаз ярату аркасында, «Регина»да Камил исемле бер егет белән танышты. Камил да төзүче иде. Күркәм генә, үз-үзенә нык ышанган, матур яши белүче бу егет Рушаннан бер дүрт яшькә өлкәнрәк иде. Алар әле якташлар булып та чыктылар: Камилнең туган жире Ак-булакта да, ул укыган Оренбургта да Рушанның булгалаганы бар иде.

Хәер, аларның биографияләре дә, тормышка карашлары да, мавыгу-һәвәслекләре дә бер-берсенә тәңгәл килеп тора. Бервакыт төнлә бик соңлап алар Лабзактан кемнендер туеннан Анхор суы буендагы Урдага жәяү кайтканнар иде. Камил шунда бер бүлмә алып тора икән (хәзер ул су буенда бер нәрсә дә юк инде, жир тетрәүдән соң андагы йортларны бетерделәр).

Кайткан чагында Рушан ул кич өчен бик табигый булган сорау бирде Камилгә:

—Синең туеңда кайчан биибез инде, Камил?—диде.

Камилнең жавабы кайсы ягы беләндер үзенекенә охшаш тарих булып чыкты. Мәхәббәт турындагы хикәятләр чама белән шулай барысы да бер төслерәк буладыр инде. Ләкин Камилнең соңгы сүзләре исне китәрде: «Зур мәхәббәт—бәхет кенә түгел, ул зур газаплар да...»—дигән иде ул.

Камилнең сөйләгәне тәүге мәхәббәт турындагы һәр хикәят шикелле диярлек сагышлы-моңсу иде.

Ул туып үскән Ак-булак поселогы да, тимер юл станциясе булганга күрә генә, поселок дип аталып йөртелә икән, тимер юл белән барганда—иң якын шәһәр Оренбург. Менә шул Оренбургта студентлык елларында Камил беренче курста укыганда ук бер шәһәр кызына гашыйк була. «Беләсеңме, ике бабасы да, ике әбисе дә исән иде. Мондый хәл тормышта сирәк очрый...»—дип сөйләгән иде Камил. Бу сүзләре белән ул мәгъшукасының никадәр иркә, өф-төф итеп кенә үстерелгәнлеген әйтергә теләде булса кирәк. Биш ел артыннан йөреп тә ул кызыйны тәки үзенә карата алмаган Камил, юкса кызый белеп-күреп тора: егет бар, егет аңа үлеп гашыйк.

Институтны тәмамлаганнан соң, Камил Ташкентка эшкә жибәрелә һәм көтелмәгәнчә яхшы урнаша. Бер ел дигәндә, ул гади мастердан

прораблыкка, аннары төзелеш идарәсе бүлекчәсе башлыгына кадәр күтәрелә, бер-ике елдан хәтта баш инженер булырлык сәләте барлыгын да тоеп яши башлый. Ташкентта ул елларда йортлар да күп салына, промышленность биналары да күп төзелә һәм югары квалификацияле белгеч кадрлар житешми иде. Бу вакытта Камил әнә шул Урдада яши, фатиры да, фатир хужалары да начар түгел, ә инде хезмәт хакы кичәге студент өчен галәмәт шәп, үзенең киләчәге—матур! Унышларыннан канатланып, ул кинәт кенә Оренбургта калган мәгъшукасына кияүгә чыгарга ризалыгын сорап хат белән тәкъдим ясарга карар кыла. Чамалый егет: кызның артыннан йөрү—бер нәрсә, ә инде тәкъдим ясау—бөтенләй башка.

Җавап хаты гажәп тиз килеп житә. Дөресен әйткәндә, хат салып жибәргәч, Камил шактый куркып, шөбһәләнеп тә калган була. Юк, кызны яратуы кинәт сүрелгәндер дип тә, гаилә тормышының авырлыкларыннан өркеп тә түгел, моның сәбәпләре башкада икән.

Ул, мәсәлән, сөйгәнен Ак-булакка, үзенең күпсанлы туган-тумачалары янына ничек алып кайтып керәсен күз алдына да китерә алмый. Аның туганнары надан, тәрбиясез, гаугалы, телләре тик тормас кешеләр бит... Ә дуслары?! Берәр төрле ахмак-ямьсез сүз яки сүгенү ычкындырмаслар, дип ышанып, кызны алар янына бер генә минутка булса да калдыра алырмы соң ул? Юк, андый ышанычы юк иде аның.

Туганнары-дуслары бер хәл әле, Ак-булакка кайту үзе, ә кайтмый калып булмас иде, әнә шул кайту үзе сөйгәне өчен бер кимсетелү, мыскыл шикелле булыр иде: пычрак вокзал, озын кышлар буе тонналаган көл түгелгән, чокыр-чакырлы, тузанлы урамнар, егетнең үзе туып үскән кечкенә генә, тәбәнәк кенә, бернинди уңайлыклары булмаган туган йорты, баксаң, кыз күзләре белән караганда анда әле чисталык та бик үк житеп бетми торгандыр. Менә шушылар барысы да егетне өметсез төшенкелеккә сала. Соң, ул кыз бала аның туганнары һәм якыннары белән ни-нәрсә турында гына сөйләшә алыр иде икән?

Камил инде алдан ук туган-тумачаларының, хихылдап көлә-көлә, кәләшнең бик юка-нәзберек икәнлеге, куллары хужалык итәр өчен яратылмаган, артык нәфис булуы турында гайбәт сатканнарын ишетеп тора шикелле. Ә бер тутасы, һичшиксез, «мондый гәүдә белән бала табуга бик өметләнеп торасы юк», дип тәрттереп тә куяр әле, ә бәлки, бөтен кварталга ишетелерлек итеп пышылдап кына тагын да әшәкерәк сүз әйтми калмас иде.

Ә туй? Туй турындагы уйлар Камилне бөтенләй бетереп ташлый. Ул сөйгәненең искечә зыялы, һавалы-тәкәллефле әти-әниләрен күз алдына китерә. Ә Камилнең әтисенең юньле-рәтле костюм-чалбары да юк шикелле, эш аңа гына калса, ул ягын Камил рәтләр дә иде әле, әтисенең күп эчүдән шешенгән йөзе, беренче рюмканы кәгеп куйганнан соң ук бар йортка ишетелерлек итеп сүгенеп жибәрүе, туй уртасында кем белән булса да эләгешеп-бәйләнешеп китүе... Ул катнашкан мәжлесләр һәрвакыт сугыш белән, савыт-саба кыру белән тәмамлана, шуна күрә дә бер ун ел инде аны беркем дә кунакка чакырмый иде.

Менә боларның барысы да Камилне ояләта, аның жан тынычлыгын ала.

Хатны салып жибәргән көннәрнең берсендә ул төшендә үзенең туен күрә. Бу вакытта ул, саксофончы Хәлилнең уенын тыңларга дип, «Регина» ресторанына ияләшеп киткән һәм шунда бик күп туй мәжлесләрен күргән иде инде.

Төшендәге туйда кунаклар, ни өчендер, «Регина»ның даими клиентлары булып чыккан—төрле кешеләр, әмма һәммәсе дә абруйлы-дәрәжәлеләр, затлы киенгәннәр, үзләрен бик горур һәм тәкәллефле тоталар һәм бу Камилнең күңеленә бигрәк тә хуш килә, имеш. Иң гажәбе шул: үзенең әти-әниләре утырасы урында аксыл-коңгырт озын чәчләрен иңнәренә таратып салган калку-нәфис гәүдәле Софи туташ—оркестр жырчысы белән аның һәр кичне оркестрга якын гына килеп

кунаклаучы сөяркәсе, мәһабәт кыяфәтле Марик Моленберг утыра, имеш. Туйга аеруча матур-көяз киенеп килгән һәм Голливуд фильмнарындагы ата-аналарны хәтерләткән Софи белән Марик бик матур тостлар әйтәләр, кияү белән киленне шундый ягымлы-назлы итеп кайгырталар икән дә, бу гүзәл яшь парның бәхетле булачакларына берәү дә шикләнми, имеш.

Камил бу төшеннән оялмаслык дәрәҗәдә үк юләр һәм миһербансыз түгел, хәтта таныш булмаган берәр атаклы кешене «туй генералы» итеп чакыруның да әхлаксызлык-оятсызлык икәнлеген аңлый, ә биредә—үз әти-әниләренне мәһабәт күркәм кыяфәтле купшы-көяз кешеләр белән алыштыр әле! Аның кайдандыр укыганы бар: үз якыннары өчен оялган кеше бозык, бәгырьсез кеше була икән. Ләкин, моның шулай икәнен аңлау ничек кенә газаплы булмасын, кунакларның исерек әтисенә карап, нәселдәнлек турында чыштын сөйләшүләрен ишетеп утырганчы, шулар Марикның ялган әти ролендә булуы яхшырактыр, дип уйлый ул. Эченнән генә шулай алыштырып кую белән килешеп, төгәлрәк әйткәндә—ялганга барып, ул үзенең бозыклыгын, күңеленең икегә аерылуын да таный...

Ул бит ничәмә-ничә еллар буе үзенең Аңа булган мәхәббәтен кадерләп саклаган, Аның образын иркә-назлы, нәзакәтле итеп сурәтләгән. Хәзер инде ул Аның, үзенең сөеклесенең иренең пычрак күлмәкләрен юганын, күршеләре шикелле, иртән колонкага барып юынганын яки хуҗалардан калган шыгырдавык иске диванга үз янына килеп ятканын күз алдына да китерә алмый. Аның сөеклесе, әлбәттә, әйтеп тә, сөйләп тә бетермәслек гүзәл. Ул бары тик әкияти дөньяда гына яшәргә тиешле кебек. Камил Ул гүзәл затка шундый шартлар тудыра алмаганына үкенеп, гомере буе үзен гаепле сизеп яшәр идеме? Менә шунда аның тәҗрибәсез акылы бик акыллы нәтиҗәгә килә: зур мәхәббәт—зур бәхет кенә түгел, ул зур газаплар да икән...

Шуңа күрә дә ул, кыздан кире җавап алгач, җиңел сулап куя, гүя күңелен басып торган авыр ташны алып ташлаган шикелле була. Шул көннән башлап Ул кыз, егетнең күңелендә бер дә сүрелми-тоныкланмыйча, ничектер аерым бер якын кеше булып кала, аңа яшәргә комачауламый...

Аннары ике дусның юллары аерылды—Камилне көтмәгәндә генә Наманганга яңа төзелеш идарәсенә баш инженер итеп күчерделәр. Киткәндә ул Дасаевны да үзенә эшкә чакырган иде, ләкин Рушанның Ташкенттан китәсе килмәде—бу шәһәрне яратып өлгергән иде инде ул.

Намаганда Камил өйләнеп җибәрде, Рушан аның туенда кияү егете булып утырды. Камилнең хатыны Замирә Кырым татарлары кызы, чибәр генә табибә иде, Рушан аны ошатып калды. Дусты кияү булып барып кергән гаиләдә дә аның күңеленә хуш килде. Ташкентка берәр эш-йомыш белән килеп чыкса яки кая да булса ялга китеп барышлый, Камил һәрвакыт Рушанны эзләп таба торган иде. Шулай итеп, алар һаман да очрашып тордылар, аннары ничектер әкренләп аралары өзелде—тормыш шундый кырыс бит ул. Дасаев танышлары аша Камилнең малае белән кызы барлыгын да ишетеп белә, тормышын шулай көйләп җибәргән дусты өчен шатланып бетә алмый иде.

Җир тетрәгәнчегә кадәр яшьлегендә «Регина» ресторанында еш очрашып йөргән танышларыннан берсе моннан бер еллар элек аңа Камилне берничә мәртәбә Ташкентта, теге «Лотос» кафесы тирәсендә күргәнлеген әйтте. Бу хәбәр яшьлек хатирәләрен актарып ташлады, Лабзактагы күптәнге туй, шул туйдан кайтышлый, Камилнең җавапсыз калган мәхәббәте турында сөйләгәннәре искә төште. Моның бер күңелсез ягы да бар—»Лотос»ның шәһәрдә начар даны таралган иде.

«Лотос» янында «Пахтакор» командасының атаклы һөҗүмчесен күргән көнне Рушан, ниһаять, Камилне дә очратты. Камил Рушан китәргә җыенганда гына, кафе ябылыр алдыннан гына килеп керде.

Әгәр дә Рушан аны, бу «пыяла гөмбә» янында ничә көннәр сагалап тормыйча, урамда гына очратса, бәлки, танымыйча узып та китәр, алар аймылыш булырлар иде. Элекке үз-үзенә ышанычлы матур-көяз Камилне

тануы да кыен иде. Иң элек аның өстендәге костюмы күзгә ташланды, ул туйга алынган һәм аны алар икәүләп бик авырлык белән генә юнәткәннәр иде. Ике капламлы инглиз тройкасы иде ул, соры төскә кара-корым буй-буй сызыклар төшерелеп, бил тирәсен тарайткан пинжәк гомер тузмас шикелле иде.

Рушан үзенең элекке дустын бер ярты сәгать булса да читтәнрәк күзәтеп тормакчы булган иде, барып чыкмады: Камил аны шунда ук күреп алдымы, әллә күз карашын тойдымы шунда—баш какты. Көтмәгәндә шулай «пыяла гөмбә»дә очрашып, шактый вакытлар үткәч, Рушан күңелсез бер нәтиҗәгә килде: соныннан килеп чыккан фаҗиганың сәбәбе, бәлки, шул көннән башлангандыр? Сәрхушлектән психикасы какшаган кешедән моны көтәргә бик мөмкин иде.

Күрәсең, Камил «Лотос» тирәсендә аны яшь, уңган-булган заманнарында белгән кешеләрне очратмасына ышанган, ике миллион халыклы Ташкентта эреп юкка чыгарга уйлаган булгандыр, мөгаен, шуңлыктан да Рушанны ул бик тиз күреп алгандыр, аның үзен эзләп килгәнлеген аңлагандыр. Юк, ул үзенең иске дустын танымамышка салынып, сиздермичә тиз генә чыгып китәргә тырышмады. Андый чакларда, гадәттә, башка исерекләр кыланган кебек, тупас-әшәке сүзләр дә әйтеп тормады, гаепле елмаеп килде дә калтыранган кулларын як-якка җәеп: «Менә шулай килеп чыкты, туган, син гафу ит инде...»—дип мыгырданып кына куйды.

Рушан аны шул кичтә үк үзе белән алып китәргә теләгән иде, әмма Камил киреләнде: «Теләсә кайсы башка көндә, ләкин бүген түгел...»—диде.

Аерылышыр алдыннан Камил кинәт кенә әйтеп куйды:

—Хәтерлисеңме, кайчандыр яшьлектә без синең белән Лабзактагы туйдан тәрәзәләре Анхор суына карап торган минем бүлмәгә кайтып бара идек. Мин сиңа шунда яшьлегемдә өзелеп сөйгән Оренбург кызы турында сөйләгән идем, аның миңа кияүгә чыгарга теләмәгәнен белгәч, шатланганымны да әйткән идем. Хәтерлисеңме?

—Хәтерлим,—дип җавап бирде Рушан.—Синең ул кыйссаң ни өчендер минем күңелемә кереп калган, мин еш кына синең сүзләреңне кабатлый идем: зур мәхәббәт—зур бәхет кенә түгел, ул зур газап та...

Камил, керләнеп каткан җиңе белән кинәт кенә яшьләнгән күзләрен сөртеп алды да, күп газаплар аша үзе инанган сүзләрен әйтте:

—Аның миңа кияүгә чыкмавы зур бәхет! Мин моңа һаман саен шатланам... Аңлыйсыңмы, шатланам...

—Ни өчен?—дип аптырады Рушан.—Бәлки, син аның белән бәхетле булган булыр идең, тормышың да башкачарак көйләнер иде...

—Юк!—диде гаҗәп ышанычлы итеп Камил.—Минем белән булырга тиеш нәрсәләр барыбер булыр иде. Язмыш... Энкечедән энкече генә туа, күпләргә бу фикер ошамаса да, фән бу хакта үзенең ныклы сүзен әйтеп чаң кагарга тиеш...

Дустының үз сүзеннән кире чигенүенә ышанмаса да, Рушан:

—Бу әле бәхәсле мәсьәлә,—дигән булды.

Алар, шушы кечкенә бакчада бер көннән соң янадан очрашырга сүз куешып, караңгы төшкәч кенә метро ишеге төбендә аерылыштылар. Кайтып барышлый Рушан һаман да Камил турында, Ак-булактан килгән ярлы студент егетне, ихтимал, инде күптән оныткан Оренбург кызы турында уйланып кайтты. Үзенең гүзәл һәм гел уңышлардан гына торган яшьлегендә шулай бәхетсез мәхәббәткә тарган Камил, ничектер инстинктив рәвештә, үзе дә сизмәстән, ул кызга бәлаләр генә китерәчәген аңлаган, күрәсең—чынлап та, зур мәхәббәтнең серләре сөйләп бетергесез буладыр...

Билгеләнгән көндә Камил бакчага килмәде, күңелендә ниндидер борчылу сизенеп, Рушан аны эзләп Куйлук дигән җиргә китте. Камил анда элекке бер буфетчы хатынга барып сыенган булган икән. Биредә Рушанны коточкыч күренеш көтеп тора: кайчандыр чибәр-көяз, ә хәзер эчеп кешелектән чыккан Камил ул килергә ике сәгатьләр генә кала асылынып үлгән иде.

Рушан үзен бу ят һәм шапшак йортка ниндидер бер илаһи көч тартып китергәнен, дустын кешеләрчә җирләргә кирәклеген аңлады. Камилнең үлемендә үзенең дә күпмедер гаебе бардыр кебек тоелды аңа: теге көнне «Лотос»ка барып, аны сагалап торып очрашмаган, үткән тормышларын искә төшереп утырмаган булсалар, кем белә, бәлки, Камил әле һаман яшәр иде... Әлбәттә, аның бу тормышын яшәү дип атап булса...

Камилнең үлеме Рушанның хәтереннән бик озак китмәде. Ул аның Намангандагы тормышы турында тәфсилләбрәк белешергә теләде: бәлки, егетебез хатыныннан уңмагандыр? Бәлки, бу фаҗиганың төп сәбәбе гаиләдәдер? Әмма Камилне яхшы белүчеләр сәбәп бөтенләй Замирәдә дә, гаиләдә дә түгеллеген сөйләделәр. Элекке прораб алай кинәт кенә эчә башламаган, төзелештәге бик күпләр шикелле, эчүгә әкренләп эшендә тартылган булган икән...

Язмыш дигәнең үзенең шәфкате белән Оренбург кызын бәладән коткарып калса, икенче канаты белән бер гаепсез Замирәгә кайгы-хәсрәт салып киткән. Рушанның күз алдында шундый матур башланган тарихның шундый моңсу азагы... Дасаев өчен тагын шунысы да сер булып калды: ни өчен Камил тормышына чик куяр алдыннан да үзенен мәхәббәтен кире каккан кыз турында уйланды икән? Ни өчен үз балаларының әнкәсе булган бәхетсез Замирә турында бер сүз дә сөйләмәде икән?

## VII

Үткән гомереннән кем яки нәрсә Рушанны әлеге «мәңгелек китап» турындагы уйларга этәргәндер, кичләрен сәгатьләр буена тәрәзә янында басып торырга дучар иткәндер, хәзер инде тәгаен генә әйтүе дә кыен. Шунысы бәхәссез: якыннарының-дусларының үз язмышы белән тыгыз бәйләнгән язмышлары көн саен үткәннәргә шулай әйләнеп кайтырга сәбәпче булды.

Рушан Дасаев үз хәтеренең мөмкинлекләренә таң кала, аның турыдан-туры үзенә кагылышлы булмаган, бары тик ишетеп кенә белгән, инде менә ничәмә-ничә еллар үткәч, күңелендә кинәт кенә яшен ташыдай чатнап-яктырып киткән әллә кайчангы вакыйгаларны саклый алу сәләтенә исе китә.

Менә әле дә бала чагында һәм яшьлегендә тормыш юлында очраган бик күп кешеләр арасыннан хәтере, ни өчендер, кинәт кенә чеченнәр белән немецларны аерып алды, аларның фаҗигале ачы язмышлары гыйбрәтле дә, кызганыч та иде шул...

Һай бу дөнья!..

Инде бишенче дистәсен ваклагач кына Рушан даһи юлбашчы Иосиф Виссарионович Сталинның урман полосалары гына утырттырмаганын, ә бөтен бер халыкларны, туган җирләреннән тамырлары белән каерып алып, күчереп утырттырганын, генералиссимусның бу явыз эш-гамәлләре хәтта ерак даладагы Мартук шикелле тын почмакларга да килеп бәрелгәнен бар тирәнлеге белән аңлады.

Чеченнәрне туган җирләреннән кырык дүртенче елда сөргәннәр, алар Мартукка, далалы кыргый бу якларга инде кыш ингәч килеп чыкканнар. Бу вакытта Рушанга нибары өч кенә яшь булган әле.

Аның хәтерендә, тоныкланган-төссезләнгән кинокадрлар яки фоторәсемнәр шикелле генә булып, озын муенлы кызыл бакыр кувшинчүлмәкләр күтәргән кара яулыклы хатын-кызлар, бу яклар өчен гайре табигый йонлач папаха бүрек кигән картлар гәүдәләнә, алар «Казбек» папиросы тышындагы җайдакны бик тә хәтерләтәләр иде. Рушанның әбисе, әгәр дә даладагы бу поселокта чеченнәр белән бер үк диндә—мөселман динендәге казакълар белән татарлар булмаса, ул бахырлар зәмһәрир салкын кышта шул елда ук үлеп беткән булырлар иде, дип сөйли иде. Үзләре дә ач-ялангач, күшегеп-тунып яшәүче халык, сукыр

Мәмлиева карчыкнын—Рушанның әбисенең ихтыярына буйсынып, хәлсез-зәгыйфь чеченнәрне өй буенча таратып алып бетергән, ул беренче авыр кышны исән-имин чыгарга ярдәм иткән. Ә язын инде чеченнәр үз тормышларын җайга салырга тотынганнар, Мартукның тирә-юнендәге дала басуларына монарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән кукуруз чәчкәннәр, дәррәү җыелышып, өмә ясап йортлар күтәргәннәр—гаҗәп эшчән һәм нык-таза булып чыккан бу тау халыклары!

Җылы якларда яшәргә күнеккән, әмма Кавказда һәрвакыт иң биек папаха бүрек киеп йөрергә өйрәнгән чеченнәрне ач-ялангач килеш далада кыш кышларга сөргән Юлбашчы, күрәсең, аларның исән калырларына исәп тотмаган булгандыр. Кешеләрнең күңелләрендә әле кызгану хисе һәм шәфкатьлелек сакланып калганлыгын, әле ни тырышып та, маузерлар һәм төрмәләр белән генә кырып-себерелеп бетерелмәгән дин-иман исән икәнлеген дә күзаллый алмагандыр...

Чеченнәрне кайвакыт «чехлар» дип атап йөртәләр иде. Рушаннар сыйныфында баштан ук берничә чечен малае укыды, шуларның берсе Гани Цупаев белән Рушан бер партада утырдылар. Ничектер бервакыт Рушан, ял көне балыкка барырга сөйләшеп куярга дип, аларның өенә барып керде. Ишек шар ачык булганлыктан, ул шакып-нитеп тормаган иде. Кухня да, өйалды да хезмәтен үтәгән алгы бүлмәдә Ганинең әтисе, фронтовик-пулеметчы Мәхмүт ага утыра, ул үзенең гаиләсен сугыштан соң шушы Мартукка килеп эзләп тапкан иде.

Эчкә батып кергән ябык күкрәкле һәм кайгылы карашлы бу кеше тупас кына каккалап-суккалап ясалган өстәл янында утыра, алдында өстәл өстендә исә тау-тау акча өеме—шулкадәр акчаның булырын Рушан күз алдына да китерә алмый иде. Ул чор балалары хәзергеләр шикелле мәми авыз түгелләр һәм ике йөз илле-өч йөз илле сум хезмәт хакы өчен әти-әниләренең таңнан төнгәчә бил бөккәннәрен күреп үсәләр, ә инде биш көнлек эш атнасы турында ул заманнарда берәү дә уйлап карамый иде. Бер мизгелгә күз карашын акчалардан Рушанга күчергән йорт хуҗасы күрше бүлмәгә таба кычкырып улын дәште. Өсләренә кайнар су сиптеләрме, малайлар икәүләп урамга атылдылар.

Ишегалдына чыккач, һаман да әле дулкынлануын баса алмаган Рушан сорап куйды:

—Кайдан сездә шулкадәр күп акча?..

Гани аңа ничектер зурларча карап алды да кистереп әйтте:

—Безнең акчалар түгел ул. Яхшысы, син ул хакта оныт, яме! Юкса безгә бик зур күңелсезлекләр булырга мөмкин,—диде.

Рушан үзенең ниндидер бер серләр шаһиты булганлыгын аңлады һәм бу хакта беркайчан да, беркемгә дә сөйләнеп йөрмәде. Юкса алар мәктәптә Гани белән бергәләп Павлик Морозов турында укыганнар иде...

Ярлы чеченнәр өендә күргән ул тау-тау акча өеме бервакыт хәтеренә килеп төште дә, Рушан, соңлап булса да, аларның серен аңлаган-ачкан кебек булды. Әмма ул вакытта ул кем белән булса да үзенең бу ачышын, мөгаен, уртаклаша алмас иде, аннары кем дә булса аны аңлармы, ул вакыйга Рушан салган тирән мәгънәне ачып биргән булыр идеме икән? Бүген, андый гына түгел, әллә нинди серләр ачылган заманда, аның хакында да сөйләргә ярар иде. Бигрәк тә яшь чечен егетләренең шул акчалар өчен нинди михнәтләр күргәннәрен белгәч... Хәзер инде кемнән исәп-хисап сорыйсың? Иптәш Сталиннан сорасаң гына инде... Ә табышмакка җавап гел очраклы гына табылды...

Җитмешенче елларда совет матбугаты һәм телевидениесе һәртөрле милли-азатлык хәрәкәтләренә һәм сул партияләргә зур игътибар бирә, тегеләр яки бу партия өчен акча вә алтын-көмештер кебек кыйммәтле әйберләрне талап йә урлап алуны экспроприация дип атап, аны милли көрәшләрнең батырлык сәхифәләре итеп күрә килде. Гомумән алганда, бу тактика яңа түгел, аны анархистлар да, большевиклар да кулланган, бу эш-гамәлнең тарихка кереп калган үз каһарманнары да булган:

Кропоткин, Камо, Савинков...

Телевидение Латин Америкасындагы милли-азатлык көрәше өчен акча юнәткәндә гомерләрен дә кызганмаган яшь егетләр турында чираттагы тапшыруын күрсәткән чагында, Рушан Мартукта һәм бөтен өлкәдә бик еш булып торган судларны исенә төшерә иде—әле банк яки саклык кассасын басалар, әле берәр алтын-көмеш кибетен, соңгы кашыгын да калдырмыйча, талап чыгалар. Талаучыларны һәрвакыт диярлек тоталар, алар чечен егетләре булып чыга иде. Шунысы гаҗәп: акчалар да, алтын-көмешләр дә һичкайчан да табылмый, егетләр озак елларга төрмәгә утыра—балигъ булмаганнарына да ун елдан кимне чәпәмиләр иде. Ул малайларның күбесен Рушан яхшы белә, бергә уйнап үскән малайлар иде бит...

Телевидение тапшыруларын карый торгач, ул Цупаевлар өендә үзе кайчандыр күргән тау-тау акчаларның кайдан килгәнлеген аңлап алды. Ул инде сөрелгән чеченнәрнең, үзләрен туган ватаннарына кайтаруны таләп итеп, Мәскәүгә даими рәвештә йөргәнлекләрен, вәкилләр җибәреп торганлыкларын белә иде, теләсә нинди сәяси көрәш зур чыгымнар сорый. Ул акчаны чечен егетләре иректән мәхрүм булу бәрабәренә табалар. Себер төрмәләренә әле мыек та чыкмаган яшүсмерләр булып китеп, аннан чаларган ир-атлар булып исән-сау кайта алганнары ничек яшәп яталар икән хәзер?

Техникумда укыганда Рушаннар группасында Алга якларыннан килгән чечен егете Лом-Али Хәкимов укыды—бик акыллы, сәләтле, сәясәт белән кызыксына, һәр нәрсәне төбенә төшеп аңларга тырышучан иде ул. Аның кулында һәрвакыт төргәк-төргәк газет була, аңа төрле политинформацияләр ясауны тапшыралар. Хәкимовны белгән кешеләрнең берсе дә аның кайчан да булса дипломат яки берәр зур сәяси эшлекле булырына шикләнми иде. Лом-Али тулай торакка еш кына килеп йөрүче бер абзасы тәрбиясендә булды—күрәсең, бу егеткә туганнары да зур өметләр баглаган булганнардыр.

Газеталар актарып утырганда, бу талантлы егетнең фамилиясен очратырмын, дип уйланган чаклары да булды Рушанның. Ул да Хәкимовның йә дипломатик, йә партия баскычларыннан югары үрләячәгенә ышана—егеттә тегесенә дә, монысына да җитәрлек һәвәслек бар иде. Әмма егет, өметле бик күп яшьләр шикелле үк, кинәт кенә юкка чыкты, күзгә чалынмый башлады.

Бервакыт шулай тулай торак ишегалдында йөргәндә, Хәкимов Рушанга болай дигән иде:

—Ә беләсеңме, чечен телендә «әфәнде» дигән сүз юк. Димәк, «кол» дигән төшенчә дә юк. Менә шулай, дустым...

Мөгаен, дөрестән дә, шулайдыр—чеченнәр арасында Рушанның куркакларны, кыюсыз-йөрәксезләрне очратканы булмады. Соңгы мәртәбә перронда басып торганда, Хәкимовны Грозныйга алып китәргә тиешле тиз йөрешле поезд кузгалыр алдыннан биш минут кала станция чаңын суккач, егет хушлашып әйтеп куйды:

—Мин синең дусларың арасында берәр чечен егете булуын телим. Син беләсең бит, без чеченнәргә ышанырга була...

Гомер үтеп бара, әмма чеченнәрдән Рушанның Лом-Алидан башка дуслары тәки булмады, кайчандыр тиз йөрешле «Москва-Ташкент» поезды түбәсендә дәртләнеп хыялланган үзенең матур дүрт елын ул Лом-Али белән бер бүлмәдә яшәп уздырды. Шуның белән шул... Аннары, Рушан «кукуруз» сүзен ишетсә, Никита Сергеевич Хрущевны түгел, ә чеченнәрне исенә төшерә, чөнки далалы якларга ул гаҗәеп үсемлекне шулар алып килде, Казакъстан җирләренә шулар тернәкләндереп җибәрде бит. Чеченнәрнең кукурузлары икешәр метрлы булып үсә, һәр нәрсәсе файдага китә: чәкәне—орлыкка, сабагы—малларга, аларны ягып өй җылыталар һәм хәтта йорт түбәләрен дә шуның белән ябалар иде.

Мартукта Вавилондагы телләр буталышын белмәсәләр дә, анда ул

елларда калмыгы да, нугае да, ингушы да, алманы-немецы да, яһүде дә үз телендә сөйләшә белә иде... Һәм боларның күбесе иленнән, туган якларыннан сөрелгән халык иде...

Немецлар поселокка барысыннан да алдарак килеп төштеләр, аларны төрле жирләрдән—кайчандыр әле Ленин мактап телгә алган үз республикалары булган Идел буеннан, Кубаньнан, Краснодардан, Ставропольдән сөргәннәр иде. Немецларны күп китерделәр, чеченнәрдән нык күп, шуңамы, алар бик тиз тернәкләнеп киттеләр—ул заманнарда эмиграция турында, тарихи ватаннары булган Германиягә китү турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Алар бик ныклап, озакка исәпләп төпләнделәр. Аларны, мөгаен, туган-торган жирләреннән егерме дүрт сәгать эчендә жыеп алганнар да, яна урында бөтенесен дә янабаштан булдырырга кирәк иде.

Рәсәй немецларының гаиләләре күп балалы. Югары уку йортларына, фән тирәсенә керү юлларына хакимият әллә нинди киртәләр корса да, ул балалар комсызланып белемгә омтыла иде. Бүген, совет немецларының Германиягә күпләп киткән бер чорында, кызганыч ки, кайчандыр аларның бабаларын чакырып китергән Россия ике йөз ел эчендә дә немецлар өчен чын ватан була алмаганын танырга гына кала. Ә бит немецларның бу ил алдындагы хезмәтләре гаять зур булды. Алар Рушан яшәгән ерак дала поселогында да үзләренең игелекле эзләрен калдырып киттеләр.

Хәзерге бишьеллыклар гына ул берсеннән-берсе куанычсыз, бигрәк тә соңгы өч бишьеллыкта көнкүреш өчен иң кирәкле товарлар юкка чыкты, азык-төлеккә хәерчеләнгән-ярлыланганны сөйләп тә торасы килми, ә бит сугыштан соңгы заманнарда һәр бишьеллык илне яңа бер баскычка күтәрә иде әле.

Инде илленче еллар башыннан ук Мартук кинәеп-жәелеп үсә башлады. Ә немецлар әллә нинди әкәмәт йортлар төзиләр иде. Пыялаланган иркен верандалар, зур-зур тәрәзәләр белән, менә дигән сарайлар-мунчалар белән һәм бер йорт икенчесен һич тә кабатламый, һәр хужа үз йорты өчен нинди дә булса бер хикмәтле үзенчәлек эзләп табар иде. Ул йортларны шунда ук «немец йортлары» дип кенә йөртә башладылар. Шуларга карап, жирле халык та бу архитектура яңалыкларын кулланырга тотынды—без кемнән ким, янәсе!

Немецлар килгәнче, бу тирәләрдә ни агач, ни чәчәкләр юньләп үсә алмый, дигән катгый фикер бар иде, ә алар килеп, тормышларын көйләп жибәргәч, һәр ишегалдында чәчәкләр-гөлләр дә пәйда булды, хәтта шау чәчәкле алмагачлар гөрләп үсеп китте, соңрак йөзем куаклары да күренде. Ә инде помидоры-кыяры, болгар борычы, иртә өлгерә торган кәбестәсе, башлы суганы-кыяклысы—һәммәсе хужалы һәр йортта үсә иде.

Күрексез-шыксыз дала Мартугын немецларның шулай гөрләтеп үзгәртеп жибәрүен беркем дә инкарь итә алмастыр. Алар килгәч, тирә-якта чиләк-чиләк сөт бирә торган голланд токымлы сыерлар һәм бекон дуңгызлары бихисап үрчеп китте. Дөрес, аларга кадәр дә һәр урыс ишегалдында чучка мыркылдый иде, әмма дуңгыз ыслау жайланмаларын немецлар гына булдырды, кешеләр ысланган казылыкның исен-тәмен татыдылар. Поселокның иң зур предприятиесе—бөтен районның авыл хужалыгы техникасына ремонт ясала торган РТС озак еллар буена республикада алдынгы хужалыкларның берсе булып килде. Анда нигездә немецлар—техникага хирыс халык эшли, алар инде аннан-моннан гына эшләргә һич күнекмәгән иде.

Чираттагы төзелеш ыгы-зыгысы Мартукта яңадан алтмышынчы еллар башында купты, анда өлкәдә иң зурлардан булган элеватор сала башладылар. Халык төзелешкә дәррәү кузгалды—әйбәт түлиләр иде, иң мөһиме—төзелеш материаллары юнәтү жае чыкты. Жирле халык арасыннан Рушан бередә бердәнбер прораб иде, аның участогында немецларның комплекслы ике бригадасы эшләде, алар мәктәптә бергә укыган малайларның әтиләре һәм абыйлары иде. Шулай итеп, бөтен дөнья таныган «немец хезмәте»нен ни-

нәрсә икәнлеген Рушан ишетеп кенә белми, ә күреп тә белә, алай гына да түгел, үзе дә бик яхшы үзләштергән иде.

Ул заманнарда тактадан кормаштырган әрҗәләргә коела торган монолит бетон бик худта булды. Техник шартлар буенча, инде бер файдаланылган опалубка такталары исәптән сызылып, яндырылырга тиеш, ә хуҗаларча карасаң, аларны әле теләсә кайда кулланырга була, кулың гына житсен! Халык рәхәткә тиенде—сыпырталар гына шул такталарны! Такталарны йорт-кура төзелешенә алырга, тәвәккәлләп, Рушан рөхсәт бирде. Хәтерендә, ул үзенә дә шундый бер машина такта кайтарткан—сарай түбәсен ябарга, күптән череп беткән койманы алыштырырга кирәк иде. Далалы Мартукта агач алтын бәясе иде бит. Әмма инде исәптән сызылган шул такталар гомере буена Рушанның күңелендә уелып калды.

Такта бушаткан трехтонка машина чыгып китәргә дә өлгермәде, гадәттә тын гына йөргән әнисе көтмәгәндә тавыш кубарды—бу такталарны хәзер үк яңадан төзелешкә илт булгач, илт, янәмәсе! Башта әнисенең шулкадәр хафага төшүен аңламады, әнисе күрше урамда яшәүче немец Тилковскиларны мисалга китергәч кенә, күңелендә борчылу хисе кузгалды һәм янадан төзелештән бер нәрсә дә алып кайтмаска вәгъдә бирде. Ул әнисенең йөрәгендә гомерлеккә уелып калган курку хисенең ни-нәрсә икәнлеген сизенде, ул хисне һич ничек тә юып ташлап булмасын да белә, хәтта вакыт та бу очракта көчсез иде.

Ә эш менә нәрсәдә иде.

Рушан Дасаев белән бер сыйныфта бик тыныч, тырыш немец малае Коля Тилковски укыды. Аның соңрак сәер генә рәвештә күлгә батып үлгән Юра исемле абыйсы һәм Ольга исемле сеңлесе дә бар иде. Хәзер Рушан белә инде: меңләгән совет немецлары бомбежкалар вакытында һәлак булган яки хезмәт лагерьларында үлеп калган, әтисезлек гадәти күренеш иде һәм ул беркайчан да Колянын әтисе кайда икән, дип кызыксынмады. Инде менә хәзер, соңлап булса да, сыйныфташының әтисе язмышын белде.

Сугыш елларында, немецларны Мартукка сөреп китергәч, Тилковскиның әтисе элеваторда грузчик булып эшләде—ач-ялангач еллар, өйләрендә өч бала, аларны ашатып-эчертеп тотарга тыныч заманнарда да җинел булмас иде һәм менә көннәрдән бер көнне Рушанның әнисе белән күрше хатынын Тилковскилар яшәгән землянкага «пүнәтәй» итеп чакыралар—такы-токы гына белемле әнисе бу сүзне гомеренә оныта алмады. Өлкән Тилковски эштән кайтып керүгә үк аның артында НКВДдан килгән ике кеше дә пәйда була, «пүнәтәйләр» дә шунда, хуҗаның кесәләрен туп-туры шул «пүнәтәйләр» кулына бушаттыралар...

Әнисе, күз яшьләренә тыгыла-тыгыла, ул бичараның сырган фуфайка кесәләренең икесеннән чыккан бодайның бер кушучка да җыелмаганын әрнеп сөйләгән иде. Әнисенең кулына бушаттырылган әнә шул бер кушуч булыр-булмас бодай өчен немецка унбиш елны чәпәп тә куйганнар, ул аны, көнен-көнгә, минутын-минутка дигәндәй, тутырып утырып чыккан.

Бер кушуч бодай өчен—унбиш ел! Бу вакыйга Рушанны тетрәндергән иде һәм ул шуңа күрә дә әнисенең курку-өркүенең ни дәрәҗәдә булганлыгын төшенде.

Ярар, сугыш еллары, законнар кырыс-каты заман, шулай унбиш елны чәпәсеннәр дә, ди, ә ни өчен соң сугыштан соң, һич югы бөек Җиңү көне уңае белән, шулай хөкем ителгәннәрнең эшләрен яңадан карамаганнар? Өйләрендә, елашып, өч бала утырып калган бит! Чын-чынлап кешеләрне кол дәрәҗәсенә төшергәннәр, алардан бары бер генә нәрсә—бушка эшләү генә таләп ителә. Тилковскины, мөгаен, төрмәдән дә чыгарырга теләмәгәннәрдер әле, немецлар бик намуслы һәм эштә ару-талуны белмәс халык бит...

Өлкән Тилковски Себердән 1959 елның ноябрендә генә кайтып төшеп, Рушан бригадаларының берсендә балта остасы булып эшли башлаган иде. Прораб бу сүз тыңлаучан эшчән немец алдында миһербансыз

дәүләте өчен үзен ничектер гаепле итеп тоя һәм аны бер вакытта да төнге сменага яки вагоннардан цементтыр-агачтыр бушатырга, авыр эшләргә куймый, немецның эшлисесен тулысынча «тегендә» эшләп бетереп кайтканлыгын аңлый иде...

Тилковскилар гаиләсенең, картайган әтиләрен алып, Федератив Германиягә яшәргә китеп барганнарын Рушан туганнарыннан ишетеп белә, еш кына болай уйлый: «Шундый авырлыклар белән аларны сөнлап булса да үзенә сыендырган тарихи Ватаннары үзләренә ягымлы-шәфкатьле булсын, бу якларда алар бер игелек тә күрмәделәр бит. Инде беркем дә, беркайда да бер кушуч чүпле бодай өчен немец Гюнтер Тилковски түләгән хакны түләмәсен иде...»

Чеченнәр белән еш кына шау-шулы, гаугалы хәлләр булып тора— аларны спецкомендатура кешеләре дә, НКВД вәкилләре дә куркыта алмый иде. Алар үз абруй-дәрәҗәләрен кимсетергә берәүгә дә юл куймыйлар, кергәндә бик җентекләп тентеп кертсәләр дә, чечен кешесе белән наганлы бер генә түрә дә кабинетында япа-ялгыз, күзгә-күз калырга тәвәкәлләмәс иде. Ул заманнарда түрә-башлыкларның өстәл өсләрендәге барлык авыр әйберләр: генералиссимус Сталинның бронза яки мәрмәр сыны да, шулай ук тимер Феликс сыны да, ул елларда бик модалы булган, чуеннан коелган авыр язу әсбаплары да, хәтта сулы графиннар да алып бетерелгән булган, дип сөйлиләр иде.

Ә немецлар бөтенләй башка кавем—тып-тыныч, законнарга буйсынучан халык, спецкомендатурага да артык мәшәкать тудырмыйлар.

Ләкин бервакыт гайре гадәти хәл—ЧП килеп чыга, бу вакыйга алдында тау халыкларының барлык кыю гамәлләре дә тоныкланып кала. Немец егете Рубинның эше белән НКВДның Мәскәүдәге зур түрәләре һәм хәрби разведка үзе шөгыльләнгән, имеш, дип сөйләделәр. Рубин ул чагында әллә сигезенче, әллә тугызынчы сыйныфта укый һәм поселокның аргы башында яши иде, шуңа күрә Рушанның аның белән очрашканы юк, бары тик әнисе белән ялгыз яшәгәнен генә белә, әнисе исә мәктәптә мич ягучы һәм җыештыручы булып эшли иде...

Ерак калган балалык елларын хәтереннән үткәргәндә, Рушан Дасаев үз мәктәпләрендә җыештыручы булып эшләгән немец хатын-кызларын да берничә сүз белән генә булса да яхшы яктан искә алып китәргә кирәк тапты.

Аларның иркен һәм тәзек мәктәпләрендәге һәр сыйныф бүлмәсе ул заманнарда күмер ягып җылытыла—ә балалар ике сменада укый, өлкәннәр өчен әле кичке өченче смена да бар—димәк, иртә таңнан караңгы төнгә кадәр егермедән артык мичкә ягыла, дигән сүз. Житезэшчән җыештыручылар ул күмер теткәзеп булмаслык комсыз мичләргә ягып кына калмыйлар, дәресләр барган араларда һәр тәнәфестә мәктәпнең озын коридорларын да ялт иттереп юып чыгаралар иде. Хәзер, инде үзе өлкәнәйгәч, Рушан ул хатын-кызларның хезмәт сөючән тырышлыгы йөзләрчә балаларны туберкулездан саклап калганын яхшы аңлый.

Мәктәпләрендәге ул җыештыручыларны Рушан Рубинга бәйләп кенә искә алмый. Бервакыт ул төзелеш эшләре белән Нукуска баргач, очраклы гына бер мәктәпкә барып кергән иде. Үзәктән ягып җылытышлы, заманча салынган мәктәптә аның тыны кысыла башлады һәм бу мәктәп бүлмәләренең-залларының, коридорлары-баскычларының айга бер мәртәбә дә юылмаганын-җыештырылмаганын күрде—өч сменага йөреп укучы балалар көн саен меңнәрчә аяклардан күтәрелгән тузанны сулыйлар икән. Бәлки, шуңадыр да Каракалпакстанда сәламәт кешеләр юк диярлек, алар бит мәктәптән үк зәгыйфь-көчсез үпкә белән чыгалар. Түбән белемле немец хатын-кызлары белгәнне мондагы җирле түрәләрнең һәм табибларның белмәве-аңламавы кызганыч, әлбәттә...

Нинди дә булса романда алар турында, ай-һай, берәр мәгълүмат табарсыңмы икән, дип, мәктәп җыештыручыларына күңеленнән генә булса да «өлешчә тигән көмешен» биргәч, Рушан яңадан хәтере белән Рубинга әйләнеп кайтты.

Немецлар ул елларда, башка бирегә сөрелгән халыклар: калмыклар, ингушлар, чеченнәр шикелле үк, торган җирләреннән комендатура рөхсәтеннән башка бер кая да чыгып китә алмыйлар, кулларында бернинди документ-фәләннәре дә булмаганлыктан, тегендә-монда барып йөрү өчен мөмкинлекләре дә бик чикләнгән иде. шуңа күрәдер дә, ике ай элек югалган немец малае Рубин исемле укучының, Көнбатыш чиген бозып, аргы якка чыгып китәргә маташканда тотып алынуы турындагы хәбәр гаҗәпләнерлек булды. малайны өенә, әнисе янына кайтардылар—балигъ булмаган баланы нишләтмәк кирәк? Педсоветта укытучылар биргән сорауларның барысына да аның җавабы бер була: ул үзенең тарихи Ватанына кайтырга теләгән. Аны бертавыштан «синең Ватаның—Советлар Союзы: син шушында тугансың, шушында әти-әниләрең һәм хәтта бабаларының бабалары туып үскән, шушында гына сиңа бөек Сталин конституциясе тарафыннан хезмәткә, түләүсез белем алырга һәм дәваланырга, йорт-җирле булырга, ниһаять, ирекле совет гражданы булырга һәм тагын әллә нинди рәхәтлекләргә тулы хокук бирелгән» дип ышандырырга тырышалар. Әмма шул чакта ук Рубин инде, күрәсең, үзенең чын тарихи Ватанында нинди ирекләр көткәнен аңлаган булгандыр.

Башка малайлар шикелле, Рушан да, документсыз-нисез, бер тиен акчасыз килеш бөтен ил аша уза алган һәм бары тик чик сакчылары гына тотып калган егетне күрергә дип, өлкән сыйныф укучылары укый торган катка йөгереп менгән иде. Баксаң—моң-сагыш тулы карашлы, ябык кына гап-гади үсмер малай икән Рубин, отличник, контроль эшләрдә мәсьәләләрнең һәр дүрт вариантын да шартлатып чишә, математиканы бик шәп белә икән. Аның дус-ишләренең берсе дә Рубинның шундый адым ясарын—франкфурт-Майннан берме-икеме мәртәбә хатлары һәм тентеп актарылган бер посылкалары килгән нindидер абзасы һәм туганнары янына барырга җыенганын күз алларына да китерә алмаганнар икән.

Мәктәпне тәмамлагач, Рубин яңадан качкан, әмма бу юлы аны чикне бозып чыгып барган чагында атып үтергәннәр, әнисе аны җирләргә барган, ә соңрак, бердәнбер улының каберен карап-рәтләп торыр өчен, бөтенләй шул якларга күчеп киткән, аның башка беркеме дә калмаган—ире Чиләбедәге хезмәт лагеренда һәлак булган.

Рубинны бик каты гаепләп, мәктәптә җыелыш үткәрделәр—ихтимал, кайдандыр югарыдан шундый күрсәтмә килгән булгандыр. Әмма укучылар үзара бөтенләй башкача сөйләнеп йөрделәр: Рудин кызганыч, ул бит шпион түгел, укучы гына, Мартуктан нинди серләр-фәләннәр алып чыгып китә алсын инде ул—бетәшкән «Өченче интернационал» колхозы серләренме? Яшәсен иде үзе теләгән җирдә, без бит иң ирекле илнең—Советлар союзының гражданнары...

Хельсинки киңәшмәсенә әле күп еллар кала кеше хокуклары турындагы декларациянең барлыгын да белмәгән Мартук малайлары кырык ел элек үк әнә шулай гади һәм ачык кына итеп уйлыйлар иде.

Хәзер инде Рубинның ашыга төшкәне билгеле. Ул бик яшь булган шул, заманны тоемлый алмаган, сөйләшер-киңәшер кешесе дә булмагандыр—хәтта әнисе дә, мөгаен, аның уй-хыялларын белмәгәндер. Ә заманалар үзгәрә, хәтта иң авыр дигәннәре дә үтә тора, әмма беркем дә кайчан җиңеллек киләчәген, күпме көтәргә туры киләсен белми, шуңа күрә дә ашыгалар, ялгышалар һәм һәлак булалар...

Мартук парикмахерскоенда чибәр генә ике бертуган кыз—Марта белән Магда эшли иде. Рушан алардан чәчен бөтенләй кырдырып алдыра—ул елларда түбән сыйныф укучыларына чәч йөртергә ярамый да иде. менә шул Тиссеннар гаиләсен Көнбатыш Германиядәге нindидер туганнары эзләп тапкан да, янә имеш-мимешләр куерып киткән: имеш, туган тиешле кеше әллә банкир, әллә генерал, диме шунда. Тиссеннар юлга җыена башладылар...

Мартаның ул вакытта инде ярәшелгән егете Вольдемар бар иде, Рушанның иптәше Сегизмунд Вуккертның абыйсы (энесен дус ишләре

урысчалатып Саня дип кенә йөртә иделәр). Немецлар тиз кулдан гына туй үткәрделәр, юкса Вольдемар-Володяның кәләшсез калуы бар иде, ә инде тегендә, ГФРда андый чибәр кызны, мөгаен, берәр бюргер шунда ук сугып алган булыр иде—Рушан белән Сегизмунд шулай фикер йөртteләр.

Дөресен әйткәндә, Володя Көнбатышка китәргә бик ашкынып тормый, сөеклесен югалту куркынычы гына аны бу адымга этәргән иде. Мартуктан ул елап китеп барды, монысын Рушан да раслый ала, теге яктан килгән беренче хатлары да Россияне сагынып моңлану белән тулы булды—Рушан аларны үзе укыды. Ул заманнарда кешеләрнең бер-берләреннән яшерерлек әлләни серләре юк, абыйсының ГФРдан язган хатларын Саня һәрвакыт мәктәпкә дә алып килә иде.

Малайларны якташларының эшкә урнашканнан соң язган бер хаты шаккатырды. Володяның анык кына бер һөнәре дә юк, кайда нинди эш туры килсә, шуны башкарып йөри, ә поселокта эш мәсьәләсе һәрвакыт кыен иде.

Ул тегендә үзенә җайлы гына урын тапкан: кухнялар, сыраханәләр, арзанлы ашханәләр өчен кирәкле гади генә табуреткалар ясый торган бер кечкенә остаханәгә эшкә урнашкан икән. Ничек, ни-нәрсә эшләргә кирәклеген күрсәткәннәр дә, кулына эш кораллары тоттырганнар моның, әйдә, эшлә, янәсе—хуҗаның күп сөйләшеп торырга вакыты юк. Володяны көнлек норма гаҗәпләндергән—көнгә нибары ике урындык ясарга кирәк икән. Һәм ул хуҗасына Рәсәй немецларының да төшеп калганнардан түгел икәнлеген күрсәтергә теләгән. Кыскасы, кичкә шалт итеп сигез урындыкны ясап та куйган, хәтта төшке ашка да барып тормаган.

Мактау көтеп торганда, хуҗасының аптырап калган йөзен күргәч, үзе дә пошаманга төшкән бу. Хуҗа, әлбәттә, бик абруйлы бер танышының тәкъдиме белән генә эшкә алынган яңа эшчесенең «тырышлыгына» тиешле бәяне биргән, әмма алга таба, артык та түгел, ким дә түгел, бары тик ике генә табуретка, ләкин аларны бер ел, ике ел, ун елдан соң да кибеп какшамаслык, шыгырдап тормаслык итеп ясарга кирәклеген аңлаткан. Бәлки, менә шунадыр да, житмеш елдан артык совет чорында яшәгәннән соң да, кайбер йортларда гап-гади генә итеп бөгеп эшләнгән, патша заманыннан калган венский урындыклар очрый әле—аларны Россиядәге Көнбатыш илләре белән уртак предприятиеләр эшләп чыгара торган булган. Чынлап та, алар шыгырдамыйлар да, кибеп какшап та бетмиләр, һаман да исән-саулар.

Яңа хуҗалары алдында үзләрен күрсәтергә теләп, артык «тырышып» җибәргән безнең элекке гражданнарыбыз турында бик күп әкәмәт хәбәрләр сөйлиләр. Шундый хәбәрләрнең берсе Рушанның да исен китәргән иде, күптән түгел Израильдә «кыяклаган» Бохара яһүде белән булган бу хәл.

Ташкенттан китеп Тель-Авивка барып урнашкан яһүд үз һөнәре буенча бер ит кибетенә эшкә кергән икән. Әлеге Володя-Вольдемар шикелле, бу да бик тырышып эшли, көн саен кибет хуҗасына әйбәт кенә керем илтеп бирә. Күпмедер вакыттан соң, хуҗа үзе кибеткә килеп чыккач, бу яһүд, уңайлырак мизгелне көтеп алган да, хуҗасын арттагы бүлмәгә чакырган һәм шунда, як-ягына карангалап, бер төргәк акча чыгарып биргән.

Кибет хуҗасы аптырап калган: «Кайдан бу?»—дип сорый икән. Сатучы яһүд мактаныбрак кына кемгәдер үлчәп житкермәгәнен, кемгәдер сдача биреп бетермәгәнен, кемгәдер итнең сортларын буташтырып сатып җибәргәнен сөйләп биргән. Бер сүз белән әйткәндә, бездә хуҗалары ничек таләп итсә һәм үзе ничек эшләргә күнеккән булса, шулай «мәтәштергән» икән. Һәм менә бер айга шушы кадәр акча җыелган, имеш. Аның «кадерен белмәгән» хуҗа үзен шунда ук эштән куган. Бу гаҗәпкә калып, бик озак аңлый алмаган: ни өчен? Ул бит «суллан» кергән акчаларның бер тиенен дә үзенә алмаган, хуҗасына ярарга тырышкан. Анда исә ярарга тырышырга кирәкми—намуслы һәм сыйфатлы итеп эшләргә генә кирәк икән.

Ай-һай, безгә әле әнә шул гап-гади хакыйкатьләрне—«үтермә, урлашма» дигән дини кануннарны аңыбызга сеңдерергә дә озын-озак еллар кирәк...

Кызганыч, чит илләргә ышанычлы, эшчән, әйбәт кешеләр чыгып китә тора. Шунысы юаныч инде, ичмаса житмеш елдан артык чор эчендә алардан «яңа совет кешесе» ясый алмаганнар. Дөнья халыклары гаиләсенә кушыла торсыннар соң әйдә! Аларның юлына аркылы төшәргә дә, аларга буш-ялган вәгъдәләр бирергә дә кирәкми. Алар бит җәмгыятьтә үзләренең хезмәтләре, тырышлыклары, сәләтләренә тәңгәл килердәй урыннарны озак эзләгәннәр, озак көткәннәр, озак өметләнгәннәр, әмма тапмаганнар. Турысын гына әйткәндә, алар «совет кешеләре» булмаганнар, булырга да теләмәгәннәр. Ичмасам, хәзер үз тарихи ватаннары аларның түземлелегенә һәм хезмәтенә тиешле бәяне бирсен, бәхетле булсыннар алар...

Рушан Дасаевларның борын-борыннан мөселманнар яши торган кварталында бер генә урыс гаиләсе—Козловлар гына бар иде, төгәлрәге, Козлов бабай белән Августина әбкәй. Украин урамы чатындагы таба-таба көнбагышлар үсә торган, читәненә балчык чүлмәкләр эленгән йорт-кура хуҗасының ни атлы икәнен Рушан белми дә иде, чөнки олысы-кечесе аны бик гади генә итеп, Козлов бабай дип йөри иде. Козлов бабай Мартукка Рушанның әбисе—сукыр Мәмлиева карчык белән бер үк елда килеп төпләнгән һәм алар гомерләре буена дус булганнар. Сугыш елларында Татар бистәсендә бердәнбер ир заты булып шул Козлов бабай гына калган, барлык ир-атларны фронтка озатып бетергәннәр.

Козлов бабай инде күптән, беренче бөтендөнья сугышында ук сугышасын сугышкан—«ярманнарга» әсир төшкән, өч мәртәбә качып караган, соңгысында тотып алгач, яңадан качып йөрмәсен дип, аягын сугып сындырганнар, шунлыктан ул аксак калган иде.

Үз гомерендә күпне күргән, күпне эшли белгән ул, әсирлектә немец телен дә өйрәнгән һәм Идел буйларыннан сөрелгән, инде телләрен оныткан немецларга да үз телләрен, үз йолаларын бик теләп өйрәтә, шуңа күрә аны ихтирам итәләр һәм күпләр балаларына исем кушарга да аны дәшәләр иде.

Татар бистәсендә ни-нәрсә генә килеп чыкмасын, Козлов бабайга чабалар: ярдәм ит, киңәш бир, нишләргә, кая барырга? Һәркем өчен аның ягымлы сүзе булыр, оста кулы булышыр, кирәк икән—соңгы сыныгын да бүлеп бирер иде ул. Фронттан килгән һәрбер өчпочмаклы хатны тотып хатын-кызлар аңа баралар: ул бит фронтовик, немецлар белән беренче сугышта ике Георгий тәресе алган, әсирлектә ниндидер бер бюргерда батраклык иткән—ул инде сугышның ни-нәрсә икәнен белә дә белә, киңәшен дә бирер, каһәр төшкән сугышның кайчанрак бетәрен дә әйтер. Ләкин фронттан хатлар килү беренче кышта ук шактый кимеде: Төркестан дивизиясендә булган күп кенә мартуклылар—шул исәптән, Рушанның әтисе Мирсәет тә,—кырык беренче елның кышында Мәскәү тирәләрендә ятып калды. Атаклы панфиловчылар арасында да мартуклыларның ике якташы бар, хәзер аларның исемнәрен базар артындагы тузанлы, чокыр-чакырлы ике урам йөртә.

Сугыш елларында далалы бу якларда буеннан-буена зәмһәрир салкын кышлар торды, бөтен Татар бистәсе халкының итекләренә бушлай олтан салып утыручы Козлов бабай сукрана иде: эх, урынын да билгеләгән иделәр юкса, ирләр белән җыелышып, кварталда сугышка кадәр бер кое казып калдырып булмады. Суга станциягә хәтле үк йөриләр, якын ара түгел, анда да әле ачулары чыккан станция хатын-кызлары арасында үзләрен унайсыз сизәләр, әллә ничек кешенекенә кызыгып килгән шикелле була иде... Татар бистәсенә килгән чираттагы һәр үлем хәбәре кое казыр ирләр калмаячагына ишарә—читтән кешеләр ялларга туры киләчәк иде.

Фронттан иң озак килеп торган хатлар күрше казакъ Сөләйман хатлары булды. Ул да кырык бернен җәендә казып өлгермәгән коены исеннән чыгармый, мескен хатын-кызларның салкыннарда-пычракларда

интегеп су ташулары өчен уфтанып яза икән. Германиягә барып житкәч, кое өчен, һичшиксез, бер егерме метрлап шәп чылбыр алып кайтырга вәгъдә итә—ул заманнарда үзебездә тутыккан кадак та табып булмасын шәйләгән, күрәсең, бахыр. Әмма кырык дүртенче елда Будапешт тирәләрендә Сөләйман да һәлак булды, «шәп чылбыр» алып кайта алмый калды...

Козлов бабай аңлады: мескен хатын-кызларның анардан башка ышаныр кешеләре юк—госпитальләрдән дәваланып кайтырга тиешле ир-атлар исәпкә керми, кайсы кулсыз, кайсы аяксыз, дигәндәй, ә кайберләре бөтенләй сукыр. Һәм менә, Жиңү елының жәендә Козлов бабай, үзенең голланд токымлы бердәнбер сыерын сатып, шуның акчасына кое казытты.

Кое халыкка бик озак хезмәт итте, суы да эчеп туймаслык тәмле иде, Рушан аның суын күп эчте. Инде унбиш еллап булыр, кое юк хәзер—аны күмдерделәр, хажәте бетте аның, һәр ишек алдында электр белән эшли торган колонка бар. Ә кое кызганыч...

Татар бистәсендә бүген яшәүчеләр ул коены, аның нинди бәягә төшереп казылганын хәтерләмиләрдер дә. Козлов бабайның үзен дә онытканнардыр. Казакъ Сөләйманның берәр оныгы, кызып китеп, урыс Козлов бабайның оныгының оныгына: «Сыптыр үзеннең Рәсәеңә!»—дип тә кычкырса...

Боларны уйлаганда, тәннәр чымырдап китә. Бер юаныч кала: ни Сөләйман, ни Козлов бабай бу сүзләрне ишетми инде...

## VIII

Хәтереннән үткәннәргә сәяхәт ясап, Рушан хәзерге заман кешесенең иң юк дигәненең дә тормышы әллә нинди вакыйгаларга бай икәнлегенә төшенде. Ә кайларга гына, нинди ерак араларга барып чыкмый хәзер кеше! Әле кайчан гына ил буйлап болай тиз йөрүне берәр кечкенә авылмы-поселокмы кешесе күз алдына да китерә алмый иде. Чын мәгънәсендә—космик гасыр, космик ераклыклар, космик тизлек...

Кәефе килгәндә Рушан еш кына кемнәрдәндер алынган иске хатларны яңадан укып утыра, үз гомерендә шактый күп жыелган, саргаеп беткән фоторәсемнәрне озаклап, гажәпләнеп карый. Алар яшәлгән елларның шаһитлары, бер бизәлеше кебек, әмма күбрәк бу рәсемнәр яна хәтерләүләргә этәргеч була, күңел төпкеленнән әллә кайчан онытылып беткән хәлләр-вакыйгалар калкып чыга.

Хәзер, егерменче йөз тәмамланып килгәндә, һәртөрле гайре табигый, аңлатып булмый торган серле «фәннәр» белән моңа кадәр күрелмәгәнчә кызыксыну барлыкка килде—һәртөрле күрәзәчеләр, экстрасенслар, шаманнар, шарлатаннар, гороскоплар белән мавыга башлады халык. Берәрсенең кулына кәрт килеп эләксә—шунда ук сезнең үткәнегезне һәм киләчәгегезне әйтеп бирергә тотыначаклар. Ничектер, шулай фоторәсемнәр карап утырганда, Рушан янәшә яткан ике рәсемгә тап булды, менә шулар аны ерак аралар һәм язмышлар турындагы уйларга этәрде дә инде. Ул күңеленнән шул ике рәсем арасына сызык сызды—бер кыйтгадан икенче кыйтгага хәтле булды ул сызык.

Бер фотосурәт Рушан Находка портында командировкада булып, кызыл агачтан эшләнгән Вьетнам паркеты кабул иткәндә, Азиянең иң көнчыгыш ноктасында төшерелгән. Ә икенчесе—Португалиянең Язмыш борыны дигән жирендә, Европаның иң көнбатыш ноктасында. Бу билгеле географик төбәкләрнең һәр икесе дә биек текә яр өстенә урнашкан, ә аста ике бөек океан шаулый.

Рушан, жәмгыятьнең иң яхшы, сайланган катламына—хәзергечә әйтсәк, элитасына кермәсә дә, байтак кына жирләрдә булырга өлгерде. Прораб хезмәте авыр, жаваплы хезмәт, төзүчеләрнең тормышын матурлый-жиңеләйтә төшү максатыннан чыгып, югарыдагы түрәләр, бигрәк тә

аларның тапшырыласы төзелешләргә күзәтчелек итеп торганнары, ике сезон арасында үз эшчеләренә төрле юлламалар бүлеп бирәләр иде. Рушан да шундый юллама белән баруларының берсендә әлеге Язмыш борыны дигән җирдә фоторәсемгә төшкән иде. Ләкин ул чагында, жилле апрель көнендә, кайчандыр планетаның икенче бер иң читтәге ноктасында да фоторәсемгә төшкәнен хәтерләп тә карамаган иде. Менә хәзер, еллар үткәч кенә, бу ике фоторәсем, очраклы рәвештә мач яткан кәртләр кебек, рәттән яткач кына, үзенә нинди ерак җир читләренә барып чыгарга туры килгәнлеген төшенде. Ул эш бүлмәсендә эленеп торган картадан шул ике ноктаны эзләп тапты да аларның бер-берсеннән никадәр ерак булганлыкларына таң калды. Алар арасында кыйтгалар, дистәләрчә илләр, әллә ничә гасырлык тарихлары булган йөзләрчә шәһәрләр, меңнәрчә поселоклар һәм авыллар ята, хыял белән дә колачлап алып булмаслык ул киңлекләрдә төрле расадагы һәм төрле диндәге миллионлаган кешеләр яши—һәркайсының үз тормышы, үз язмышы...

Бәлки, шуңадыр да, үзен тәүге мәртәбә чүлдәге ком бөртегедәй, океан суындагы бер тамчыдай итеп тойганнардыр, Рушан үз-үзенә, үзенең тормышына, үзенең үткәненә текәлебрәк карый башлады.

Гаҗәп: бу хәтер дигәнең сине кайчандыр син булган атаклы-данлыклы җирләргә, әйтик, Парижларга алып китми, һаман да гомереңнең чишмә башы булган елларына, мәктәпкә алып кайта.

Ә бит күпме җилләр искән, күпме сулар аккан! Әле ул чакларда сәер генә Фасоль фамилияле мәктәп директоры да буйдак бер егет иде. Һәм менә, бер кышта сыйныфлар өстеннән чыштын-пыштын гына бер хәбәр йөгертеп узды: Фасоль өйләнгән икән, хатын алып кайткан. Ул заманда директор мәктәп йортында тора иде, Рушан бер тәнәфестә өстенә матур тиен тун, аягына ни өчендер «венгерка» дип йөртелә торган, биек үкчәле, кыска кунычлы күнитек кигән зифа буйлы, тәбәнәк кенә кызны күреп алды. Салкыннан бит очлары алсуланып янып чыккан, кайсы төше беләндер шәһәрнең өлкән сыйныфта укучы кызларына охшаш бик сөйкемле һәм чибәр генә бер туташ иде ул. Рушан аның балалар табибәсе икәнен ишеткән иде инде. Ул әле аларның озакламый кызлары туганын да хәтерли, ул баланы көн саен мәктәп тирәсенә һава суларга алып чыгалар иде. Өлкән сыйныфта укучы кызлар тәнәфестә аның сиртмәле арбасы янына җыелалар, чиратлашып аны чәчәк атып утырган сәрби куаклары арасындагы мәктәп аллеялары буйлап этеп-тартып йөриләр—болары да хәтердә уелып калган. Сәрби куаклары, кызгылт ком сибелгән юл-сукмаклар, күбәләкләрдәй ак алъяпкычлы укучы кызлар, биләүгә биләнгән нәни кызчык...

Инде шактый еллар үтеп, үзенең чираттагы бер ялына кайткач, Рушан җәйге бакчада шул кайчандыр бәби булган, инде буй җиткергән сөйкемле кыз белән биегән һәм күптәнге истәлекләрен сөйләп көлдергән дә иде әле... Кыз ул вакытта Ленинградтагы югары уку йортларының берсендә укучы студент иде инде. Үтә гомер... Рушан китеп барган шул ерак августта ул кыз өчен ниндидер бер егет, сыйныфташы бугай, атылып та үлгән. Әйе, тормышта һәр нәрсә дә шулай тыгыз үрелгән—мәхәббәт тә, үлем дә...

Хәзер инде шахмат уйнарга үлеп ярата торган Фасоль фамилияле мәктәп директоры да исән түгел, перчаткалы туңган кулларын күкрәк турысындагы муфтасына яшергән, тиен тунлы булганлыктан, Рушанга кайчандыр өлкән сыйныф укучысы гына булып күренгән хатыны да күптән пенсиядә, ә кайчандыр мәктәп ишегалдында кечкенә арбада тартып йөргән сабыйдан сылу кыз булып үсеп җиткән гүзәл теге каһәрле төндә ау мылтыгының тәтесенә баскан малайны алай еш хәтеренә дә алмыйлардыр әле. Вакыт дигәнең шул чаклы тиз үтә, яшьли үлгәннәрнең каберләре өстендәге фәкыйрь генә такталарга кагылган язулы калайлар шундый тиз тутыга, иң күнелсез-моңсу вакыйгалар да шундый тиз онытыла...

Соңгы вакытларда Рушан мәктәпне бик еш искә ала, ә дөресрәге,

үз гомерендәге ике мәктәпне. Кайчакларда мәктәп елларын артык идеаллаштырып, гел матур, күтәренке, романтик еллар итеп карый шикелле дә тоела. Чын хакыйкать сүзләре дөньяга чыга башлагач, илленче-алтмышынчы елларда совет мәктәпләрен тәмамлаучыларның хәзерге сиксәненче еллар азагы—туксанынчы еллар башындагы егет-кызларга караганда күпкә белемлерәк, өлгергәнрәк булганнарын күреп, Рушан горурланып та куйган иде. Әмма ул бу горурлану хисеннән оялды да бугай әле, соң, бер дә табигый хәл түгел ич: утыз ел эчендә безнең балаларыбыз гәүдәгә сузылып та, надан калгач, моның нинди яхшы ягы бар инде—шул рәтле-юньле белеме булмаган, начар тәрбиядә үскән буын җилкәсенә синең картлыгың да төшәчәк бит әле.

Ләкин инде бөтенләй килеп терәлгән картлык турында ни өчендер бик уйлыйсы килми, шуңа күрәдер дә, бәлки, һаман да яшь төшләр, төгәлрәге, яшьлек турындагы төшләр күрелә. Шунысы сәер: ул төшләрдә син яратып-сөеп йөргән затлар, гомереңә исеңдә калдырганча, һаман да шулай яшь булып, чибәр булып сурәтләнәләр. Син үзең дә үтеп киткән еллар авырлыгын җилкәңдә тоймыйсың, ул төшләреңдә, еш кына шулай ук яшь буласың, әмма, зирәк ташбака Тортилла шикелле, үткән гомереңнән зарури ачы тәҗрибәсен туплагансың—сиңа хәзер һәммәсе дә ачык һәм аңлаешлы! Нинди искитмәле матур төшләр! Һәм ул төшләрдән соң уянып, чынбарлыкка кайтулар нинди газаплы, нинди әче хәсрәтле була... Бөтен гомерең буе күңелеңдә йөрткән, әле яңа гына төшеңдә күреп, яңадан очрашырга сүз куешкан яки башка бер вакытта да үпкәләшмәскә сүз биргән ул сөйкемле-гүзәл кызлар күптән юк бит инде. Язмыш аяусыз кыйнаган, авыр тормыштан арган-талчыккан, картаеп килүче хатын-кызлар гына бар. Берәүләре инде пенсиядә, икенчеләре шуның бусагасында, ул ханымнарның элекке матурлыгыннан, нәзакәтле җиңел атлап йөрешләреннән җилләр искән. Яшьлекләреңдә аларны белмәгән-күрмәгән берәр кешегә бу ханымнарның кыз чагында нинди чибәр, нинди гүзәл булулары турында сөйләп кара әле—кычкырып көләчәкләр генә! Миһербансыз-шәфкатьсез еллар барысын да талап ала: күзләрендәге яшьлек очкыннарын да, күпереп-тузгып торган чәчләренне дә, сихерле-серле елмаюларынны да...

Мөгаен, кыз-кыркынның, кияүгә чыккач, кыз чактагы фамилияләрен югалтуында ниндидер хаклык та бардыр, шуның белән хакыйкать раслана дыр: инде ни Гәлләмова, ни Давыдычева, ни Беккерт юк, бары тик Насретдинова, Астафьева, Зотовалар гына бар. Син кайчандыр күз атып, яратып-сөеп йөргән ул затларның яңа фамилияләре сиңа бер нәрсә дә сөйләми, алар үзләре дә таныш түгел, чит-ят ханымнар гына—кемнәрнендер хатыннары, кемнәрнеңдер әниләре, ә кемнәрнеңдер әбиләредер дә инде, бәлки...

Ихтимал, еллар салган чал чәчләрнең һәм йөздәге җыерчыкларның да үз өстенлеге бардыр—аларга ия булгач, һич югында җиде кат күкләрдә гизмисең, үткәнеңә дә, бүгенгеңә дә, киләчәгеңә дә аек күз белән карый башлыйсың, алсу күзлекләрең бу вакытка инде йә ватылган, йә бөтенләй югалган була. Хикмәт, соңлап булса да, кайсы ишектән керергә кирәклеген аңлауда түгел, ә ни өчен икенче ишектән кереп киткәнеңне белүдә. Шулай да әле һаман да күп нәрсәләр аңлашылып бетми, бигрәк тә эш йөрәк мәсьәләсенә, гыйшык-мәхәббәткә барып терәлгәндә шулай була. Кызлар йөрәгенең бернинди мантыйкка, акылга сыймаслык гамәлләре турында тау-тау китаплар язылган, асылда бөтен әдәбият кына түгел, бар тормыш шуннан тора—менә монысы Рушан өчен гомерлек сер булып калды, алга таба да шулай булыр, мөгаен. Хәтта дистә еллардан соң да хәтереңдә кинәт кенә сөеклеңнең әйткән берәр сүзе, берәр хәрәкәте калкып чыга, син аны теге чакта аңламагансың һәм хәзер дә аңлый алмыйсың, баксаң—ул шумер чөй язуларыннан да катлаулырак икән. Менә шуны тою бик газаплый да...

Чит кешегә, ул бигрәк тә яшь кеше дә булса, кемнеңдер кайчандыр берәр унынчы сыйныфта укучы яки берәр студент кызның үзенә нәрсәдер

әйткәнен яки ничек итеп караганын исенә төшереп, уйланып утыруы гайре табигый бер юләрлек булып тоеладыр. Әмма, ничек кенә гаҗәп булмасын, инде шактый гомер кичергән кайберәүләр өчен бу бик мөһим була. Шулай килеп чыккан ки, кешене мөстәкыйльлектән мәхрум итеп, аның өчен һәр нәрсәне хәл итәргә омтылып, аның шәхси йөзен бөтенләй җуеп, һәр эштә бергәлек булсын дип тырыша торгач, җәмгыять бары тик йөрәк хисләренә генә үтеп керә алмый калган, шуңа күрә дә шәхси тормышыбызда шулай тиз вә җиңел яраланучан безнең күңелләребез. Бер генә юаныч кала: мәхәббәттә, хәзергечә әйткәндә, инициатива һәм альтернатива рөхсәт ителә әле. Безгә башка өлкәләрдә үзебезне күрсәтергә мөмкинлек бирмәделәр, шунлыктан да без мәхәббәттә уңышсызлыкны, гаилә җимерелүне хезмәт юлындагы уңышсызлыкларга, үрләр яулап ала алмавыбызга караганда тирәнрәк, авыррак кичерәбез.

Рушан бала чагыннан ук бик тиз гашыйк булучан иде, бәлки, шунлыктандыр да аның хатирәләре романтик пәрдә белән өретелгән, һәр нәрсә артык хисчән тойгыларны уята иде. Ул бит, чынлап та, туйда чакта Сафия апасына да гашыйк булды, шәраб парлары башларына киткән кунакларның аны мактауларын ишетеп, үсеп җиткәч үзенә андый кыз тәтемәс шул инде, дип кайгырды. Соңрак ул нәфис шәфтәлу йөзле «мадам Баттерфляй»га гашыйк булды, Рәшит абыйсы юләр, тәки шуңа өйләнмәде бит. Хәтта мәктәп директорының хатыны табибә Юлияне дә яратып йөрде, аннары, бик озакка булмаса да, йөрәген пионервожатый кыз Наденька Кривцанова яулап алды.

Хыялларга чумып яшәү, дөньяга алсу күзлек аша романтик караш, чамадан тыш әсәрләнүчәнлек-хисчәнлек аның тормыштагы төп хезмәте—төзелеш белән һич бәйле түгел, һич ятышмый, андый сыйфатлар күбрәк иҗади һөнәр ияләренә, зыялы мохитта үскән кешеләргә хас булырга тиеш, ә Рушан берничек тә алар исәбенә керә алмый иде. Югыйсә төзүчегә хас булмаган андый сыйфатларга ия кеше начар прораб булырга тиештер кебек, әмма бөтен хикмәт тә шунда шул—Дасаев үз эшенең остасы иде, әгәр дә бераз елгыррак та булса, ул инде күптән чит илләрдәге берәр зур төзелешне җитәкләр иде, тәкъдим ителгән илләре дә кызыгырлык иде бит: Куба, Марокко, Алжир, Һиндстан.

Бетәшкән Мартукта нинди дә булса гайре табигый сирәк һөнәрләр турында сөйләшүләр кешеләрдә аңлашылмас ачу кузгата, үртәлү тудыра иде. Рушан хәтерли әле: башка сыйныфтан бер кыз белән үзе арасында гыйшык-мыйшыкка охшаш хисләр туып кына килә иде, менә шул Валя Домарова ирекле темага язган иншасында үзенең балерина булырга теләвен ачып салган да, бу яңалык бөтен Мартукка таралып, бик тискәре янгыраш тапкан иде. Хәтта Татар бистәсендәге кое янында да карчыклар, урысчасын-татарчасын бергә бутап, көлешә-көлешә бер-берсеннән сорашалар:

—Ишеттеңме әле, шуфир Вәскә Домаровның дучкасы бәлирунә булмакчы, ди?

—Ул, теге, нижнее бельедан гына—эчке күлмәктән генә кешеләр алдына чыгып, бот-чатларын күтәреп биюче буламы соң? Ха-ха-ха!

—Хи-хи-хи! Шул инде, шул...

Аннары инде бөтенләй кәгазьгә төшерергә ярамаган оятсыз сүзләр китә. Балерина булырга хыялланган кызны озак еллар эзәрлекләп килгән бу әшәкелек әдәбият укытучысы аркасында килеп чыккан иде. Әгәр ул кызның бу самими серен «тишмәгән» булсачы соң?..

Бу вакыйга ун-егерме елдан соң да онытылмады, Валяның әнисе күптән вафат инде, балерина булырга хыялланган кыз, мөгаен, үзе дә пенсия яшенә житеп барадыр, ә менә аның эти-әниләре турында сүз кузгалса:

—Ә-ә-ә, теге, кызлары балерина булып сикергәләп йөрергә җыенган Домаровлармы?—диярләр иде...

Ул вакытларда мартуклылардан кемнең дә булса дипломат яки

журналист, композитор яки язучы, режиссер яки артист булу мөмкинлеге хакында берәүнең дә башына килеп карамагандыр. Имеш-мимеш гайбәт сүзләрдән куркудан түгел, мартуклылар андый һөнәр ияләренең кайдадыр башка җирләрдә генә туа алуларына ихлас ышанудан да иде бу галәмәт.

Шуңа күрә дә бирeдән дәррәү булып, тау эшләре техникумнарына һәм институтларына китәләр, чөнки ул елларда шул уку йортларында гына иң зур стипендия түләнә, бушлай кием-салым бирелә иде. Шундый ук сәбәп белән бик теләп хәрби һәм диңгез училищеларына агылалар, хәтта һәртөрле һөнәр училищеларын да чит итмиләр: һәркайсында бушлай ашаталар, бушлай киендерәләр иде бит. Болар инде күпләр өчен сәләтомтылышлардан көчлерәк дәлил булып чыга иде. Рушан үзе тимер юл техникумының төзелеш бүлегенә китеп барды: анда да шул ук өстенлекләр, күп нәрсә түләүсез, ә иң мөһиме—илне күреп-йөреп чыгу мөмкинлеге ачыла. Кайсы малай сәяхәтләр белән хыялланмый?! Кабул итү игъланында ачык итеп акка кара белән язылган: һәр елны Советлар Союзының теләсә кайсы почмагына бушлай барып кайту хокукы бирелә, диелгән иде. Тормыш юлын, һөнәр сайлауны менә шул хәл итте дә куйды инде.

Бала чагыннан ук Рушанның табигатенә артистлык хас һәм ул, ихтимал, нинди дә булса иҗат өлкәсендә дә үзен тапкан булыр иде. Әмма булмаган булмаган инде. Бәлки, менә хәзер, соңлап булса да, үзенең «тормыш турындагы мәңгелек романын» күңеленнән генә иҗат итеп, үзендәге әнә шул иҗади башлангычны тормышка ашырырга телидер ул.

Ана һәм аның яшьтәшләренә фарт килде: сугыштан соң ук алар бик күп трофей фильмнар карап үстеләр. Ул заманда актер осталыгы, режиссера кебек нечкәлекләр турында сөйләнеп тормыйлар, әмма фильмнарның берсен дә калдырмыйлар иде. Хәзер менә, Голливудның чәчәк аткан чоры сугыш алды һәм сугыш еллары, дип саныйлар икән, ул фильмнарның күпчелеген Рушаннар күргән иде инде. Үзләре бөтенләй башка шартларда яшәп, совет фильмнарында тәрбияләнгән буын башка дөньяларны, кешеләр арасындагы башка мөнәсәбәтләрне йотылып карый иде. Ул чит ил фильмнарында барысы да бүтәнчә, Рушаннар карашынча, һич тә чын түгел иде.

Фильмнарны «Өченче интернационал» колхозының иске атлар сараеннан ашык-пошык кына «киношка» итеп әтмәлләгән залда күрсәтәләр. Зал шыгырым тулган була, малай-шалай юл өстенә, идәнгә чүмәшергә генә кала иде. Зал ягылмый, халык никадәр күп тулса, шулкадәр җылырак була.

Рушан үзенең экран астында ук идәндә, маен сыгып алган көнбагыш түп-түберен күшәп утырган чакларын исенә төшерә. Ә экранда—үтә зиннәтле-купшы курорт. Әкәмәт пальмалар һәм чәчәк атып утыручы кактуслар утыртылган зур-зур кисмәкләр тезелгән кардай ак кунакханәнең иркен фойесында, кан-кызыл келәм җәелгән киң мәрмәр баскыч ягына карангалап, күз явын алырдай бер гүзәл кыз йөренә. Баскычтан пөхтәләпмайлап таралган кара-кучкыл чәчле яшь егет төшеп килә, өстендә—атлас якалы зиннәтле костюм, костюм эченнән ак пике жилет, муенына да ак күбәләк элгән.

Матур киенгән бу әкияти геройга карап дөньясын оныткан Рушан кулындагы түп-түбер кисәген ирексездән төшереп җибәрә, караңгыда аны эзләп тә тормый. Ул комсызланып әлеге бәхетле егетне күзәтә, әнә бит, аны нинди гүзәл кыз көтеп тора! Һәм кинәт, көтмәгәндә генә малайның башына бер уй килә: үсеп, акча эшли башлагач, үземә дә шундый костюм тектерермен әле, ди ул.

Бер ун еллар үткәч, техникум тәмамлап, Кызыл-Орда тирәсендә тимер юл биналарын һәм корылмаларын карап-күзәтеп торучы булып эшләгәндә, бер получкасын алгач, ул шәһәргә барып, үзенә гомерендә беренче мәртәбә костюм тектерергә булды. Ательенең заказлар кабул итүче кызы, аның теләген белгәч, кулына бер төргәк мода журналлары тоттырды да, үзе каядыр озакка китеп югалды.

Менә шул журналларның берсендә Рушан кинәт кенә теге фильмда күреп хәйран калган костюм төсле костюм үрнәгенә килеп төртелде, ул могжизаи кием смокинг дип атала икән. Рушан аңардан күзен ала алмый карап утырганда, аның янына тегүче яһүд килеп баскан иде инде. Яһүд мыскыллы көлемсерәп:

—Әллә смокингка үрелмәкче булдыгызмы, егет?—дип сорады.

Нindидер ярамаган эш белән тотылган кеше шикелле кызарынган булса да, Рушан үҗәтләнеп җавап бирде:

—Әйе, мин менә нәкъ шушындый смокинг тектерергә телим!—диде.

Хәзер инде тегүчегә гаҗәпләнергә чират житкән иде, ул хәтта Рушан янына утырып, гафу үтенгәндәй, әйтеп куйды:

—Минем смокинг текмәгәнемә бер утыз еллар бардыр инде, шулай да тырышып карармын, элек әйбәт кенә килеп чыга иде,—диде.

Рушан тыны бетүдән сизелерлек җәфаланучы бу кешенең кайчандыр Ленинградның атаклы театрында костюмер булып эшләгәнлеген һәм теге каһәр суккан елларда Кызыл-Ордага сөрелгәнлеген белде. Аларның кайсысы—әллә тегүче, әллә смокинг тектерүчесе күбрәк шатлангандыр, кистереп әйтүе кыен. Ленинградлы карт Рушанга смокинг астыннан кияргә ак пике жилет та тектерергә киңәш итте, ә тегәселәрен тегеп бетереп тапшырганда, дулкынлана-дулкынлана, аңа бүләк—муенга тагыла торган ак күбәләк тә сузды:

—Монысы шәхсән үземнән, картлык көнемдә мавыктыргыч эш белән шатландырганың өчен,—диде.

Рушан Кара-Үзәктәге бер кешеләрдә бүлмә алып яши иде, бүлмәсенә кайтып, яңа киемнәрен киеп карагач, шатлыгын хуҗалар белән дә уртаклашырга булды. Әби карчык аны башыннан аяк карап чыкты да өнәмичә әйтте:

—Күнитекләреңнең рәте юк, ә син театрга җыенган кебек киенгәнсең...—диде.

Балачак хыялы шулай көтмәгәндә генә тормышка ашкан иде. Хәзер аны искә төшерү дә көлке, ә теге чакта... Теге чакта Рушанга пальмалы кисмәкләр куелган ап-ак кунакханәгә дә, данлыклы әкияти курортка да ерак калмаган төсле тоелган иде.

## IX

Рушан Дасаев техникумда укыган шәһәр, тимерьюлчылар термины белән әйткәндә, «узел станциясе» дип йөртелә иде. Бу—биредә поезд бригадалары алышына, вагоннар һәм локомотивлар депосы да, вагоннарны сортларга аеру өчен таучык та бар—кыскасы, иске һәм яңа локоматившлар өчен үзенә күрә бер порт яки гавань дигән сүз. Техникумда кыган чагында, Шәһрезадә әкиятләреннән калкып чыккандай матур вокзал бинасы Рушанны сокландыра, зур кызыксыну тудыра иде. Гасыр башында, Мәскәү-Ташкент тимер юлы белән бер үк вакытта төзелгән станция биналары, әгәр дә хәзер сакланып калган булсалар, архитектура истәлекләре итеп бәяләнерлек иде. Әкәмәт бизәкле биек түбәләре, шәрекъ стилендәге манаралары һәм гөмбәзләре, уксыман очлатып уелган тәрәзәләре һәм төсле витражлары булган, һәйбәт сары таштан салынган бу биналар озын юлның буеннан-буена шәһәр-авылларны бизәп торыр иделәр. Һәр станциянең, әлбәттә инде, су җыю каланчасы булыр, чөнки бу заманнарда бары тик паровозлар гына йөри иде әле. Янәшәтирәдә йөк кабул итә торган урыннар, пакгаузлар тезелеп киткән... Болар барысы бер бөтен, матур бер архитектур чишелеш тапкан, шуның белән хәйран калдыра да иде...

Шактый вакытлар үткәч, үзе инженер булып нindидер проект эшләгән чорында, Рушан архивларда бу тимер юл төзелеше турындагы

документларга юлыкты, ә тимер юлны ул биш бармагы кебек белә— Мәскәүдән Ташкентка кадәр булган һәр чакрымын хәтереннән үткәрә алыр иде. Урта Азия белән Үзәкне тоташтыручы, әле һаман да икенче юлы булмаган бу төп тимер юлны, артык шаулап тормыйча гына, бик кыска вакыт эчендә нибары ике төзелеш батальоны салган икән. Ә барлык станция биналарын гади архитекторлар проектлаштырып эшләгәннәр. Ул биналар шушы гомергә тиклем,—ә бит аларга, баксаң, бер гасыр гына түгел инде,—ремонтсыз-нисез сакланганнар, кайбер станцияләрдә исемсез төзүче-солдатлар сузган суүткәргеч торбаларга хәтле бар.

Рушан төзелеш эшләрендә шактый тәҗрибә туплаган кеше, әйтик, атаклы БАМ—Байкал—Амур магистраленең нинди бәяләргә төшереп салынганын да белә, шуңа күрә дә, очраклы рәвештә генә табып алган архив материаллары белән танышкач, аның исләре киткән иде. Соңрак, борынгы Артемида гыйбадәтханәсе хәрабәләрен карап йөргәндә дә, аны шундыйрак тойгы биләп алган иде. Әмма бу тимер юл, аның төзелү тарихы күбрәк хәйран калдырды, ни әйтсәң дә гаҗәп түгел, бу бит һәрберебезгә кагыла: тимер юллар зур дөнья белән тоташтыра... Нәрсәләрне онытып, кайларга килеп төртелгәнебезне яхшырак аңлар-белер өчен, сирәк кенә булса да, архивларда казыну кирәк икән...

Үзе дүрт ел буена көн саен яныннан үтеп, шуннан дистәләрчә мәртәбә кайтып-китеп йөрелгән, һәр ышерен почмакларына кадәр таныш станцияне хәтеренә төшерүе очраклы түгел иде: үзенең тормыш юлында очраган күп кешеләр кебек үк, ул станция дә гомерлеккә юкка чыккан, әйтергә мөмкин—һәлак булган иде.

Онытканда бер туган якларына кайтуының берсендә, инде житмешенче еллар башында, Рушанның Актүбәгә поезд белән барырга җыенуын белгәч, якын танышларыннан кемдер гади генә әйтеп куйды:

—Андагы гаҗәеп матур борынгы вокзал юк инде, аны җимереп ташладылар,—диде.

Тиздән Рушан моны үз күзләре белән күрде. Ерактан караганда гыйбадәтханәгә охшаш элеккеге мәһабәт бина урынында сәер генә бетон тартма кукраеп тора—ул галәмәт зур, уңайсыз-шыксыз, күрексез бер сарайны хәтерләтә иде. Шул да булдымы архитектура һәйкәле?! Хәзерге заман язучыларыннан кайсыныңдыр шундый юллары искә төште: «Яңаны шундый итеп төзергә кирәк ки, ул үткәннәрне сагынып-кызганып искә алырлык булмасын».

Соңыннан иске вокзалны ничек «кыйратканнары» турында сөйләделәр. Борынгы бинаны шартлатканнар да, танклар, авыр тракторлар белән кырып-җимереп тә бетергәннәр. Шәһәрнең бердәнбер күрке булган шул бинаны реставрацияләп, элекке хәленә кайтарасы урынга, җимереп ташлаганнарына Рушан бик үртәлгән, хәзерге заман Герострватларыннан кайсысының хәерсез эше икәнлеген бик беләсе дә килгән иде, булмады...

Гаҗәеп дөньяда яшибез без: моннан берничә мең еллар элек Эфестагы Артемида гыйбадәтханәсен яндырган Геростратны беләбез, ә ун еллар элек Мәскәүдәге Коткаручы Гайса пәйгамбәр чиркәвен (Храм Христа-спасителя) яки әле күптән түгел генә Актүбәдәге шушы вокзалны шартлатырга боерык биргән түрә кисәгенең кем икәнлеген белмибез. Хәер, еллар үтү белән күп нәрсәләрне аңларга була. Менә хәзер, туксанынчы еллар башында, төрекләр, финнар, немецлар, шведларның Мәскәүдә Россия өчен изге, истәлекле саналган биналарны яңартуын күргәч, Рушан үзенең никадәр самими-беркатлы булганлыгын аңлады— гап-гади станция вокзалы ише биналарның һәммәсен дә төзекләндерергә шул чаклы чит ил төзүчеләрен кайдан җыеп бетермәк кирәк? Аңа нинди акчалар җиткермәк кирәк?

Үзенең яшьлеге билгесе,—ә бит яшьлек тә гомерлек булыр шикелле иде!—әнә шул вокзал бинасы иде. Аны югалту кайгысыннан каңгырап, ул көнне Рушан Дасаев ирексездән тимер юллар буйлап станция биналары ягына китеп барган иде. Төн уртасында өеннән шәһәргә «Оренбург—

Гурьев» почта поездына утырып кайткан чакларында ул шулай итә иде. Аның бу юлы да үзе утыз еллар элек яшәгән тулай торагын күреп китәсе бик килгән иде, әмма барып чыкмады.

Еллар буе чистартылмаган, мазутка буялып беткән рельслар аша атлый-атлый, Рушан, үзе дә сизмәстән, инде тузып-күгәреп беткән паровозлар саклана торган иске депога барып чыкты. Тимер юл эшеннән күптән киткән булса да, ул күнеленнән генә кайчандыр шул МПС (Министерство путей сообщения) кешесе булганы белән горурлана иде. Яшьлегендә хәтта «Локомотив» футбол командасында уйнап та йөрде бит әле. Кайчандыр паровоз машинисты, аннан соң казылык ясау остасы булган Рәшит абыйсы, ничектер бервакыт моңаеп: «Тимер юл ул—беренче мәхәббәт шикелле, гомерең буена онытылмый»,—дигән иде.

Тәрәзәләре ватылып, тимер капкалары каерылып бетерелгән иске депо бинасы эчендә җил генә йөри, тишелеп беткән түбәдән тамчылар тамып тора. Матур гына җиңел пассажир паровозлары, салкыннан һәм утәли искән җилдән бөрешеп, киң күкрәкле көчле йөк паровозлары «С. О»—«Серго Орджоникидзе»га елышканнар шикелле, ә житезлеге өчен «чуртан» кушаматы алган, уенчыктай матур маневр паровозы ишек янында ук беренче булып тора, ул гүя бу каберлектән чыгып ычкынырга җыена төсле иде. «Мөгаен, бу паровозлар иске вокзалны хәтерлиләрдер, аны һичкайчан да онытмаслардыр»,—дип, моңаеп уйлап алды Рушан.

Төрлесе төрле дәрәҗәдә сакланган иске локомотивлар шактый күп иде биредә. Әмма барысыннан да бигрәк каралып беткән бакыр бандажлы, кызыл көпчәкле, ап-ак торбалы, ерткычларча елгыр «И. С»—«Иосиф Сталин» күзгә нык ташланып тора иде. Аны малайлар «бурзай» дип йөртә иделәр, чынлап та, ерактан караганда ул матур бурзай этен хәтерләтә иде. Әле менә монысының да күкрәгенә Юлбашчының кызыл бакырдан эшләнгән профиле чекрәеп карап тора, нинди могҗиза белән сакланып калгандыр ул?

Рушан бу паровозга шундый бирелеп карап торды, ирексездән үзе тирәсендә кайнар шлак төшеп көйдерелгән креозотлы шпаллар исен, йөгерек «бурзай»дан бөркелеп торган кайнар пар һәм машина мае исен тойгандай булды. Бу ис һәрвакыт күмере янып, суы кайнап утыручы, тукталышларда кочегар чистартып тора торган мич авызыннан да, өйдәге күнегелгән зур самовардан да килгән шикелле, һаман да килә иде кебек.

Рушанны станциядә үсте дип әйтергә дә була, шуңа күрә ул бу күркәм паровозны бик җиңел генә Мартукта итеп тә күз алдына китерә ала, паровоз тирәсендә өч ир-ат та булырга тиеш әле. Аларның берсенең кулында—озын саплы кечкенә җиңел чүкеч, икенчесендә—биш литр сыешлы шактый зур май савыты—масленка, ә өченчесендә—тукталышларда тендар белән мич арасында йөгергәләп йөрүче кочегар кулында көрәк белән кувалда булыр. Кечкенә чүкечлесе—машинист, әгәр дә паровозның түшендә Юлбашчы профиле булса,—ә ул бик күп йөк паровозларында бар,—машинист, чүкече белән суккалап, көпчәкләрне-фәләннәрне тикшергәнчегә хәтле, беренче эше итеп мыеклы генералиссимусның йөзен көзгедәй ялтыратып-чистартып куя, моны бик каты таләп иткәннәрен белә ул. Чибәр туташларның да һәрберсе бизәнергә-төзәтенергә ул кадәр үк вакыт сарыф итмидер, ә менә Юлбашчыны һәр тукталышта карап-кадерләп торырга кирәк.

Сагышлы-моңсу уйларга чумган Рушан юлын тулай торак ягына таба бормакчы булган иде, әмма аның игътибары күрше юлда торган паровозга юнәлде. Паровоз зур, көчле, әле хәзер үк йөгертеп кузгалып китәрлек жегәре бар шикелле иде. Аның күкрәгендәге Юлбашчы профилен ямьсез генә итеп тимер кискеч зубилалар белән умырып-кисеп алганнар. Шулай булса да, ул әле, парларын бөркеп, менә хәзер кузгалыр кебек. Рушан аның сулыш алганын, вакыт-вакыт пар чыгарып, станция дежурные-ның соңгы командасын көтеп торганын ишеткәндәй булды.

Шул вакытта Рушанның күңелендә әле беркайчан да, беркемгә дә

сөйләмәгән хәтәр бер вакыйга калкып чыкты. Хәтерләсәләр, аны бары тик Мартукның күптәнге кешеләре генә хәтерли торгандыр...

Аллага шөкер, даладагы Мартукның мәңгелек юлдашлары булган «ачлык» һәм «салкын» дигән сүзләр халык теленнән кире кайтмаслык булып төшеп калды шикелле инде. Ни урманы, ни әрәмәсе, ни куакфәләне юк, өстәл өсте шикелле тип-тигез, такыр далада яшә дә, йортыңны нәрсә булса да ягып, жылытып кара! Сыерың булса, шул гына коткара— шуның салам катыш тизәге кушып сугылган тирес кирпечен ягарга була иде. Ләкин кыш бик иртә килә, соң китә, читәне дә, коймасы да калмый—һәммәсен комсыз мичләр ялмап кына ала тора. Соңгы чиктә станциягә йөгерәсең, анда ичмасам, үтеп-сүтеп йөрүче поездлардан бушатып калдырылган, яндырылган ташкүмер шлагы Монблан, Эверест таулары хәтле булып өелеп ята. Хәлсез хатын-кызлар, әби-чәбиләр иртә таңнан барып шул тауларда казыналар, үтеп китәргә тиешле чираттагы паровоздан яңа шлак бушатканнарын түземсезлек белән көтеп торалар: андый чакта юлың уңарга бик мөмкин—янып бетмәгән зур-зур ташкүмер кисәкләрен дә табарга була.

Егетләрне әйткән дә юк инде, үсә төшкәнрәк, елгыррак малайлар да паровозлар тирәсендә кайнашалар, кочегарга су тутырырга булышкан булып, берничә кисәк ташкүмер сорап яки урлап алырга өметләнәләр. паровозлар белән бергә үлгән бу эш-гамәлнең үз исеме дә бар иде— ташкүмер сыптыру! Эшли-эшли арып хәлдән тайган кочегар һәрвакыт килешә, чөнки, паровоз миче белән тендер арасында чабып йөреп, икегә ярыла алмый, ә кыш көннәрендә су тутырганда, әз генә авыз ачып торсаң да, суың ташып чыга да, паровозның койрыгы бозланып ката. Әле аннан да хәтәре—ташкүмер бункерына су тулырга мөмкин, янә кочегарга бәла: жилдә-буранда юл буена кувалда белән шул бозланып каткан күмерне ват! Ул заманнарда бит хәзерге кебек автоматика юк иде.

Тимер юл рельслары арасында фил хортумы шикелле брезент торбалы галәмәт зур колонка—каланча булыр иде, менә шуны башта тендер авызына турылап куярга, аннары, төшеп, шулай ук бик зур тәгәрмәч-капкасын ачарга һәм, су тулуга, ябып та өлгерергә, брезент торбаны урынына этеп куярга кирәк—мескен кочегарга маймыл урынына әле өскә, әле аска чабып йөрергә генә кала. Ә паровоз мичен чистартырга күпме көч кирәк? Болар һәммәсе дә барган уңайга кулдан эшләнә бит, шунда ук мичкә ташкүмереңне дә ташлап өлгер! Менә шуңа күрә дә, малайларның көнетөне станциядә кызык өчен генә кайнашмаганын белсәләр дә, кочегарлар аларның паровоз янына жыелуларына каршы килмиләр, ни генә әйтмә, булышчылар бит. Моны станция башлыклары да, машинистлар да күрмәмешкә салына.

Өйдә бер тиен акча юк, казакъ авылларыннан бер арба тирес кирпеч сатып ала алмыйсың, нишләмәк кирәк—шундый зәмһәрир салкын кышларда ун яшьләреннән Рушан да станциягә «ташкүмер сыптырырга» йөри башлады.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: станция янындагы кәжүннәй йортларда тимерьюлчылар яши, аларның малайлары вокзал тирәләрен үз биләмәләре итеп саный, читтән килеп, паровозлар тирәсендә кайнашкан башка малайларны бер дә яратмыйлар иде. Әлбәттә, аларның, Рушаннар шикелле, күмер өчен кайгырасы юк—тимерьюлчыларга ташкүмер бушлай бирелә, аларга әле иске шпаллар да эләгә, ташкүмер мәктәпкә, хастаханәгә, райкомга, милициягә дә бар... Шулай булгач, яшәргә була. Әмма станция малайлары да барыбер «күмер сыптырырга» йөри һәм бу шөгыльнең осталары саналалар иде. Дөрес, алар ташкүмернең «михайловский» дигән сорты белән генә кызыксыналар, чөнки шундый күмер генә самовар куярга ярый. Ул заманнарда исә һәр мөселман йортында иртәдән кичкә кадәр самовар кайнап утыра, менә шулар өчен паровозлардан «ташкүмер сыптыралар» да инде. Күмернең үз хакы да бар: чиләге ике сум тора, ә чиләк зур—егермешәр литрлылар, күмерне чүмәкәйләп өеп бирәләр.

Шулай эшләп тапкан акчаларына станция малайлары кинога йөриләр, көнбагыш чиртәләр, хәтта бер малай шулай итеп җәй буена үзенә велосипед алырлык акча да җыйган, дип сөйлиләр иде. Ә ул заманда велосипед—зур байлык инде ул.

Бик уңышлы башланып, бик зур фаҗига белән тәмамланган ул көнне Рушанның гомергә дә онытасы юк. Кышкы каникул көннәренең берсе иде. Ул үзенең дусты Диас Искәндәров белән иртән иртүк станциягә барырга сөйләшеп куйган иде: барып чыкса—«ташкүмер сыптырырга», юк икән—үтеп киткән паровозлардан ташлап калдырылган шлакны булса да җыеп кайтырга.

Чанасына чегәннәрдән калган, ямалып-яньчелеп беткән иске чиләк, зур гына капчык һәм җәй көне колхоз алачыгында ясатып алган тимер кисәү агачы салып Рушан Диасны ияртеп бергә вокзалга төшеп китте. Диас үзе генә һич тә бармас иде, чөнки, бер мәктәптә укысалар да, станция малайлары соңгы вакытларда бик тә бәйләнә башлаганнар иде. Рушан күпне күргән, кыю малай санала, шуңа күрә Диас ана ияргән дә иде инде.

Төн буена ябалактай мамык кар яуган, көн җылы, җилсез—каникул өчен менә дигән инде: шатлан гына!

Озакламый беренче юлга йөк поезды килеп туктады. Кочегары да әйбәт кеше булып чыкты, тендерга су тутырырга рөхсәт итте. Әле Рушанны аннан да зуррак шатлык көтеп торган икән: паровоз өстенә үрмәләп менсә, ни күрсен—бункеры кисәкле-кичәкле күмер белән шыплап тутырылган, иң өстә галәмәт зур кисәге ята, ватсаң, бер ун чиләкләп булыр һәм бөтенесе дә «михайловский» ташкүмере!

Су тутырып азапланган арада, машинист үзенең ярдәмчесе белән станция буфетына китеп барды, күрәсең, радио аша аларга озак торасыларын әйткән булганнардыр. Рушан, кочегарның паровоз мичен чистартып бетергәнен күреп, Диаска кул изәде, бу—паровозның теге ягына чык, дигән сүз иде. Авыр сөякле Диас мышный-мышный вагон астыннан килеп чыкканны да көтмичә, үзе кар өстенә бер-бер артлы күмер ыргыта башлады—мондый бәхетнең тәтегәне юк иде әле. Диас башта күмер кисәкләрен ераккарак илтеп өя башлаган иде, Рушан аңа, вакыт әрәм итеп тормаска, шушында—паровоз янына өяргә кушты. Кочегар паровозның икенче ягында мич белән әвәрә килеп азаплана иде, Рушан байтак кына күмер ыргытып өлгерде, ә Диас аларга оста гына итеп кар сибә бара иде—бик күренеп ятмасыннар.

Рушан өстән кочегарга су тулып беткәнен әйтүгә, тегесе әлеге зур кисәк күмерне тәгәрәтеп төшерергә рөхсәт итте—юлда аның белән чиләнәсе килмәгәндер инде. Әмма Рушан, ничек кенә көчәнмәсен, зур күмерне урыныннан кузгата алмады, ә Диас паровозга үрмәләп менәргә курыкты, юкса бергәләп ничек тә төртеп төшергән булырлар иде әле. Кочегар бункерга үзе күтәрелде дә, әлеге күмерне юлның поселок ягына тәгәрәтеп төшерде. Шул арада машинист белән аның ярдәмчесе дә күренде, чөнки станциянең аргы башында, поездга юл ачылганын белдереп, семафорның яшел уты кабынган иде инде.

Рушан да тиз-тиз генә аска төште, Диаска күмер кисәген кар белән күмәргә булышты: машинист ярдәмчесе паровоз тәрәзәсеннән күреп алмагае дип курыкты, кочегарга да әләгергә мөмкин иде. Шул кадәр күп ташкүмергә хуҗа булган Рушан шатлыгыннан җырларга-биергә дә әзер иде. Диас белән икесе дә авызларын җыя алмыйлар: менә өйдәгеләр шатланыр инде, дип куаналар, әле күмернең бер-ике чиләген кибетче Кожемякина түтәйгә сатып та җибәрсәләр, әниләрдән акча теләнмичә генә, ике атналап кинога йөрергә дә буласы иде.

Кирәк бит нәкъ шул вакытта, РТС ягыннан бер төркем станция малайлары күренде. Төрле яшьтәге сигез-тугыз малай. Рушан белән Диас әз-мәз кар сибелгән ташкүмер өеме янында кукраеп басып тормаса, бәлки, ул малайлар аларны күрмичә үтеп тә киткән булырлар иде. Гөнаһ

шомлыгына каршы, күрделәр шул, күмер өемен дә күреп алдылар. Бу кадәр күмерне станциянең иң елгыр малайлары—бертуган Чурсиннар да «сыптыра» алганнары юк иде әле. Гади күмер генә дә түгел бит, самовар күмере—«михайловский»! Малайларның атаманы Фаддей инде үзеннән өлкәнрәк егетләр арасында да кайнашкан, шуңа күрә күмер өеме янындагы бу ике өтек аның өчен чүп тә түгел иде. Ул күмерне тартып алырга уйлады—элек тә еш кына шулай итәләр иде. Бу кадәр шәп күмерне Татар бистәсенә илтеп сатсаң, кесәгә күпме акча керәсен дә чамалап алган иде бугай ул.

Станция малайларының өерелеп үзләренә таба килгәннәрен күргәч, Рушан белән Диасның котлары очты, аларның күңеле ниндидер бәла булачагын сизенә иде. Бу очрашудан яхшылык көтеп тә торасы юк—күпкатлы кызыл кирпеч йорт малайларының холыклары билгеле. Әгәр дә табыш бер-ике чиләк күмер генә булса, кызганып та тормас иден, әмма гомергә бер килгән мондый табыштан үз иркең белән баш тартырга—юк, һичкайчан була торган эш түгел бу, талаш-сугышсыз гына бирәүнең дә үзенекен бирәсе килми.

Кыюлык өчен кычкырып сүгенә-сүгенә якынлашкан Фаддей, паровозлардан калган ташкүмер бары тик аларга—станция малайларына гына булырга тиеш, дип игълан иткәч, Рушан үзе дә көтмәгәндә тыныч кына аны күмер өеме яныннан авыр кисәү агачы белән этеп җибәрде. Фаддейны өркетү өчен: «Хәзер Хәмит белән чечен Солтан чана тартып килеп җитәчәк. Күмернең кемнеке икәнлеген менә шуларга аңлатырсың, яме!»—дип тә өстәп куйды.

Ул заманнарда Фаддей кебек ыбыр-чыбыр гына түгел, Солтаннан станциянең өлкәнрәк хулиганнары да курка, гомумән, поселокта чеченнәр белән бәйләнешергә берәү дә атлыгып тормый иде. Солтан Татар бистәсендә яши, ә Фаддей Рушанның әбисе сукыр Мәмлиева карчыкның мөселманнар арасында абруйлы булганын да белә, Рушанны да чеченнәр белән бергә еш күрә иде. Шуңамы, ул беразга шүрләбрәк калды шикелле.

Әмма беразга гына... Мәктәптәге укуына караганда, Фаддей зирәкләрдән түгел, авыр уйлый торган малай иде. Инде кулга кергән табыш шуып бара түгелме соң? Аннары, малай-шалайлар алдында сынатасы да килми иде аның: шундый бай табышны маңка ике татар малаеннан тартып та ала алмады, дип көлеп йөрерләр иде бугай.

Шулчак Диас белән бер сыйныфта укучы кәтәнә генә бер малай, кыюланып китеп, бер күмер кисәгенә үрелде. Мондый оятсызлыкка хәтта Диас та түзеп тора алмады. Ул сыйныфташына киез итеге белән шундый итеп китереп типте—тегесенең бүреге нәкъ Фаддей аяк астына атылып барып төште. Бу хәл станция малайларын тагын да аптырашта калдырды—ә бәлки, «татарчоноклар» чынлап та чеченнәр ярдәмен көтәләрдер.

Күмер өеме китәргә торган поездның беренче вагоны янәшәсендә үк, ике юл арасында ята иде. Рушан белән Диас күмер янында тораташ катканнар, ә станция малайлары төп тимер юл өстендә—ике рельс арасында таптаналар. Арырак станция башында тизрәк кузгаласы килгән паровоз әледән-әле куе пар бөрки, шунлыктан малайлар томан эчендә калган кебек була. Ә каршыга ниндидер состав ажгырып килә—беренче юлдан китәргә җыенган поездны тыеп, тегесенә «яшел урам» ачканнар иде.

Ажгырып килгән состав бертуктаусыз гудогын кычкырта, кисәтә иде. Машинист юл өстендәге малайларны соңлабрак күреп алды, әмма тизлеген киметергә уйламады да, чөнки ул малайларның кайсысы булса да ажгырып-дөбердәп килгән составы ишетер-күрер дип ышана иде. Әмма бөтен бәла дә шунда: малайларның иң кечкенәсе дә бәрхеттәй җемелдәп яткан «михайловский» ташкүмере өеменнән күзен ала алмый, барысы да «сукыр-саңгырау» иде бу мизгелләрдә. Киеренке халәттә, бар көчләренә кычкырыша, акыра-бакыра—һәр ике як үзенекен даулый иде. Шунлыктан, алар инде өсләренә менеп килгән составны абайламый да

калдылар, юкса, юлдан читкә ыргылып өлгергән булыр иделәр...

Паровоз малайларның өчесен шунда ук бәреп үтерде, Фаддейның ике аягы да киселгән иде, тагын ике бәләкәч юлдан читкә атып бәрелделәр—алары ниндидер могҗиза белән, бәрелеп-сугылып кына котылып калды. Ә Касперов фамилияле бер малай исә ничек исән калгандыр: паровоз аны өскә чөеп ыргыткан һәм ул, бампер рәшәткәсенә барып төшеп, нәрсәгәдер тотынып калырга өлгергән иде.

Паровозның ниндидер чыгып торган бер тимере Рушанга да тиеп узган иде, әле хәзер дә башында уң чигәсеннән өстәрәк биш тиен акча кадәрле түгәрәк пеләше—тамгасы бар, чәче-ние белән бер кисәк тиресе умырып алынган булган, юкса ул бүректән дә иде бит әле. Аннары, шул тимер кисәге тиеп киткәч, Рушан, күрәсең, егылгандыр, ниндидер катыга—мөгаен, күмер өеменәдер бәрелеп, сул аягын нык кына авырттырган иде. Ул бик озак—ике айлап аксап йөрде.

Аңына килгәч, ул шунда ук нинди фаҗига булганын төшенеп алды: күпкатлы кызыл кирпеч йорттан болайга таба кешеләр йөгерешә иде. Рушан, беренче юлда яңадан тоткарланган составның вагоннары астыннан үрмәләп-мүкәләп чыкты да, авырттырган аягын сөйрәп, әкрен генә елый-елый, чанасыз-нисез килеш өенә таба титаклады. Җинелчә курку белән генә котылып калган Диастан җилләр искән иде инде.

Өйгә кайткач, Рушанның курку-коты алынулары тышка бәреп чыкты, ул косып җибәрде, температурасы күтәрелде.

Бер өч сәгатьләрдән соң аларга НКВДның шәһәрдәге тикшерүчесе килеп керде, аңа поселок милиционеры Велигданов та ияргән. Рушан аның кызы Валюшка белән бер сыйныфта укый иде. Болар килеп кергәндә, малай тәки күмер көтеп ала алмаган салкын мич янындагы урын өстендә җансың бүрәнә шикелле ята иде.

Өйдәге салкынлыкны тоеп, сыкылап-елап утырган юеш стеналарны күргәч, тикшерүче, мөгаен, малайның ни өчен станциягә барып чыкканын шунда ук аңлап алгандыр. Шулай да ул, ниндидер кәгазьләр сырлап тутырды да, Рушанның әнисенә кырыс кына итеп әйтеп куйды: менә, янәсе, улыгыз өйдә китап укып кына утырса йә мондый матур көндә, каникулына шатланып, уйнап кына йөрсә—бу бәла дә булмас иде.

Урысчаны ипи-тозлык кына белгән, тормыш изгән, тын-юаш әнисе елап җибәрде. Ләкин станциядә булган хәлләрне ишетеп килеп җиткән Мәмлиева карчык ярдәмгә килде. Үзенә каршы сүз әйтмәслек катгый тавыш белән:

—Сез хаклы түгел, егетем!—диде.—Бәла минем оныгым станциягә барганнан килеп чыкмаган, ә ул анда барырга мәҗбүр булганга килеп чыккан. Әлбәттә, ул менә шушы салкын өендә катып үлсә, сезгә борчылырга урын калмас иде. Мәшәкатьләгәнебез өчен гафу итәсез...

Шәһәр түрәсе алдында каушабрак калса да, сүзгә Велигданов та катнашасы итте, ни дисәң дә, аның шушында яшисе бар, ә ул сукыр карчыкның Мартукта күпчелек булган мөселманнар арасындагы абруй-дәрәҗәсен яхшы белә иде:

—Иптәш капитан, сез юкка гына... китаплар турында... Әйбәт малай ул, отличник, минем кызым белән бер сыйныфта укый...—диде.

Капитан, монда килеп чыккан фаҗига-бәладән үзенә әлләни-нәрсә таммасын аңлап, урыныннан кузгалды да, саубуллашмый-нитми генә, иске одеал элеп куелган тәбәнәк ишеккә таба атлады.

Шуннан соң Рушанны бимазалаучы булмады, хәер, югары сыйныфтагыларны укытучы бер апа «социалистик милекне урлаучы» малайны пионердан чыгарып ташлатырга тырышып шактый озак йөрде. Әмма педсоветта бу чарага бармадылар—бөтен авыл диярлек закон бозып яшәгән бер вакытта, андый шәфкатьсез әхлак була алмый иде...

Әле менә, иске ташландык депода басып торганда Рушанның исенә шул куркыныч вакыйга килеп төште дә, кәефе кырылды, кайчандыр үзе бәхетле елларын үткәргән тулай торакка кайтасы килү юылды да бетте.

Шәһәргә ул бик күптәннән «Мәскәү» дип йөртелә торган тимерьюлчылар бистәсе аша кайтты. Шундагы Депо урамында аның беренче студентлар тулай торагы иде. Автобус тукталышына килеп чыккач, Рушан еракган тимерьюлчыларның ашханәсен күреп алды, техникумнарында үз ашханәләре булса да, Рушан монысына да еш кына кергәләп йөри иде. Бу ашханә һәрвакыт пөхтәләп саргылт-алсу төскә буялган, текә түбәсе ачык яшелдән булыр иде. Ә хәзер... ишекләренә аркылы-торкылы такта сугылган, тәрәзә пыялаларын ватып-кырып бетергәннәр, урыны-урыны белән череп беткән түбә астыннан янтайган-кыйгайган моржалары тырпаеп тора... Нинди кызганыч, монсу күренеш...

Кинәт кенә Рушанның йөзе яктырып киткәндәй булды, ул, вакытлыча булса да, авыр уйларыннан арынды шикелле...

## X

Узәк станциядә поезд бригадалары алышына—рейстан кайтканнары да, рейска китәселәре дә шул депо ашханәсенә сугылмый калмый, анда аларны чиратсыз ашата-эчертә иделәр. Рейстан кайтканнары аш-су янына, әлбәттә инде, берәр кружка сыра да ала. Рушан яхшы хәтерли: тыны беткән кеше шикелле, авыр сулыш ала торган насослы капкорсак мичкә янында һәрвакыт башына челтәрле ак калфак кигән юан гәүдәле буфетчы хатын басып торыр иде. Паровозчылар һәртөрле салаттыр-каймактыр алалар, әле, житмәсә, алар сузган биш сумлыктан күпмедер вак акча да кайтарып бирелә.

Күпмедер вагы белән бер сумлыгын учына кысып тоткан Рушан, шулай булырга тиешлеген белеп, көнләшми-нитми генә эченнән уйлый иде: «Менә, эшли генә башлыйм әле, мин дә биш сумга ашап йөрермен». Ул заманнарда һәркем үзенә бәхет килеренә ышана, өмет белән яши һәм көтә дә белә иде. Ул хәзер күптәннән биш сумлык ашый, ә кооператив забегаловкаларда кайвакытта унлыгын да кызганып тормый. Күптән түгел генә Мәскәүдә шундый бер ашханәгә кергән иде: анда токмачлы аш үзе генә дә биш сум тора, дөрес, инде бүгенге яңа акча белән, димәк, сонлап булса да, бу тормышта нәрсәләрдер чынга аша. Биш сумга тулы әбәт ашап чыгу—ул хәзер хыялый әкият, төштә булган кебек кенә, кызганыч ки, мәңгегә шулай булып калыр да шикелле.

Ниндидер билгеле бер яшькә житкәч,—ә ул һәркем өчен үзенчә була,—кеше ирексездән (урынлымы-түгелме—анысы башка мәсьәлә) үткән тормышына йомгак ясый, югалтулары белән килешә, зур өметләренең жимерелгәнен таный һәм хәзер инде үзенең фаразларын-күзаллауларын елмаеп кына искә ала, ә бит ул аларны озын-озак кайнар бәхәсләрдә яклый иде. Яңа буыннар аларның самими-беркатлылыкларына көлебрәк карасалар да, ә бәлки, кайбер вакытларда аларның зирәклекләренә гажәпләнерләр дә әле...

Бервакыт Тимерьюлчылар сараена—«Тимерлек»кә биюләргә баргач, ә Рушан анда, үзен Исмәгыйль-бәк яклаганга гына түгел, Казакъстан тимер юлының бокс буенча жыелма командасына бик иртә кереп, хәтта бер тапкыр «Локомотив» составында Бөтенсоюз ярышларында да катнашканлыктан, үз яшьтәш-кордашлары арасында шактый билгеле егет санала иде,—менә шунда биюләргә баргач, гомергә истә калырлык тагын бер кызык кына вакыйга булган иде.

Ул заманнарда жирле патриотизм бик көчле, үз төбәкләрендә үсеп чыккан жырчыларны, музыкантларны, шагыйрьләрне, рәссамнарны, спортчыларны, хезмәт батырларын бик яраталар, хөрмәтлиләр иде. Сәләтле-талантлы кешеләр өчен игелекле, искиткеч ихлас-эчкерсез заман иде ул. Шуңа күрә аларның җәһәннәм артындагы тын шәһәрчекләрендә дә илленче еллар азагында джаз оркестрлары, үз эстрада жырчылары пәйда булды, концертларда заллар шыгырым тулы, рәссамнарның

күргәзмәләре үткәрелә, ә инде шигърият кичәләре турында әйткән дә юк иде.

Ул көнне алар Лом-Али Хәкимов белән бергә иделәр. Җитди чечен егете иптәшенең джаз белән мавыгуын бик үк өнәп бетермәсә дә, йөрәк хисләре аны Рушанга иярергә буйсындырган—күрше факультетта укучы аның күзе төшеп йөргән кыз башка җиргә бармаса бармас, әмма Тимерьюлчылар сараендагы шимбә биюләреннән калмас иде.

Чытлык-кыланчык Эллочка Изместьеваны ул көнне биергә еш кына ниндидер таныш түгел бер егет чакыра, шунлыктан горур чеченебезнең борыны төшкән иде. Теге ят егетне кыздан аеру өчен Рушан Эллочканың дус кызына игътибар күрсәтә башлады. Рушан, биеп туктагач, шул кызны Эллочка янына китереп куйды да, Эллочкадан:

- Кем ул, синең белән биюче егет?—дип сорады.

Кыз горур гына җавап бирде:

- Ул булачак юрист, Алма-Атадан, университет тәмамлап килә. Хәзер безнең прокуратурада практика үтә,—диде.

Рушан белән Лом-Али рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр һәм бер тавыштан диярлек:

- Юрист? Үлеп-бетеп баручы һөнәр! Ике-өч бишьеллыктан соң эшсез калачак әле ул,—диделәр.

Бу сүзләр ихластан, нык ышанып әйтелде. Кыз Хәкимовның техникумда укымышлы, җитди егет саналганын, аның ил эчендәге һәм чит илләрдәге хәлләрдән хәбәрдар икәнлеген дә белә иде. Димәк, егетләр шаяртып сөйләмиләр.

Беркатлы Эллочка булачак прокурорны шунда ук «онытты», ни әйтсән дә, тимерьюлчы—гомерлек һөнәр ул!

Менә шулай, ул заманнарда алар, бер дә икеләнмичә, тиздән юристларның кирәге калмаячагына ышаналар, җинаятьчелек бетәчәк дип уйлыйлар иде. Бу самими ялгышу хәзер бигрәк еш искә төшә: җинел генә кергән зур акчалардан һәм җәзага тартылмауларыннан башлары әйләнгән җинаятьчеләрнең бәхет сәгате сукты, аларны ишетеп кенә түгел, күреп тә белгән бик күпләргә хәзерге хәл коточкыч куркыныч, төзәтеп булмаслык өметсез булып тоела...

Тормышыңа йомгак ясаганда, артык һаваланып, борын күтәрмисең, тәкәбберләнеп, эреләнә алмыйсың, элекке шикелле юк-бар өчен дә бәхәсләргә кермисең, бик күп кенә күптәнге хыялларыңның җимерелеп төшкәнен таныргә туры килә. Бер генә юаныч кала—киләчәккә нинди ышаныч-иман, нинди өметләр белән яшәлгән бит! Аларны хәзер ин матур, иң татлы төшләреңдә дә күрә алмыйсың...

Әмма Рушанның өмете өзелеп, бик нык күңеле кайтуының сәбәбе—бүгенге болгавыр тормыш түгел, ә үз буыны иде. Теге, булачак юрист егет турында ихластан әйткән шикелле, яшьлегендә ул шулай ук чын күңеленнән бу әшәкелекләрнең бетәренә ышана иде: гаделсезлек, кабахәтлек, оятсызлык, наданлык, компетентсызлык, эчкечелек, ярлылык-хәерчелек, мәгънәсез-ятышсыз тормыш-көнкүреш—болар һәммәсе дә, Рушаннар буыны җитлегеп, җәмгыятьтә үз урыннарын алуга юкка чыгарга, бетәргә тиеш кебек иде. Рушан өлкәннәргә белем, зыялылык җитми, аларны каһәр суккан «карангы иске тормыш калдыклары» изә, аларның эчке ирекләре юк, алар богауланган шикелле, дип уйлый иде. Ә менә яңа буын, Егерменче съезд материалларын яттан үзләштергән яшьләр—алар бөтенләй башка: җәмгыятьнең бөтен хаталары-ялгышлары алар өчен уч төбендәгедәй ачык, алар башкача яшәячәкләр—чистарак, әйбәтрәк, гаделлек, алар белән бергә бөтен дөнья үзгәрәчәк...

Яшьлегендә Рушан эчкечеләрне, ялкауларны, балаларын-гаиләсен ташлап китүчеләрне күңеле белән аңлый, гафу итә—шулай булырга тиеш, чөнки аларның тормышын тоталитар җәмгыять гарипләндергән бит, дип уйлый иде.

Алар буыны, нигездә, әтисез үсте, сәбәбе бер иде—сугыш. Үзе

әтисез үскән егет бервакытта да сабыен ятим калдырмас шикелле иде... Кая ул! Тыныч тормыш, әти-әниләре исән, ә балалар йортларының саны сугыштан соңгы елларга караганда йөзләрчә мәртәбә артты.

Менә шушы тормыштан күңел кайту—иң авыры, иң кыены—ул йөрәкне гел әчеттереп, гомер бетмәстәй сызлатып, авырттырып тора. Кемнәрдер, бәлки, бу хисләрне шиккә дә алырлар: нинди беркатлынаив булгансыз, заманны, аның киләчәген тоймагансыз, диярләр... Ничек карыйсың бит әле! Алар буынында һәммәсе дә бергә буталган—беркатлылык та, ышаныч-иман да, тормышка аек караш та. Рушан үз чорын бик яхшы хәтерли... Алтмышынчы еллар уртасы, ил башында—Брежнев, азмаз гына төрлечә фикер йөртүләргә дә ирек куела.

Рушан бер ял көнен бик ачык итеп исенә төшерде: ул көнне алар «Пахтакор»ның футбол уенын карап утырган иделәр. Командада—атаклы бомбардир Красницкий (илле яшен дә тутыра алмады), аксыл-сары чәчле житез Беляков (утыз яшен дә билгеләп үтә алмый калды), Пеле кушаматлы Хәмит Рәхмәтуллаев (кырык яшендә автокатострофада һәлак булды). Их, заманнар...

Дуслар «Ташкент» ресторанының җәйге кафесы террасасында башланган әңгәмәләрен дәвам итәләр.

Рушан кайнарланып сөйли:

—Иманым камил, минем гомеремдә үк ике герман дәүләте кушылачак, Корея дә берләшәчәк... Вьетнам турында әйтеп торасы да юк...

Җавапка дуслары шаркылдап көлә генә—берәү дә аның сүзләрен чынга алмый, барысы да социалистик дөньяның берлегенә-бердәмлегенә һәм аның мәңгегә шулай буласына ышана. Ләкин Рушан инде шул чагында ук бу хәлнең табигый булмавын аңлый иде—ничек инде бер халык, бер милләт ике төрле дәүләттә яшәргә тиеш? Ниндидер бер система, бер идеология хакына милләтләрне аерып буламы соң?

Бүген халык, күпьеллык йокысыннан кинәт уянып киткән шикелле, теленә ни килсә, шуны сөйләү мөмкинлегеннән тәмам исергән-шашкан, кычкыра да акыра. Бигрәк тә яшьләр картларның тетмәсен тетә. Янәсе, сез ул үзегезнең теләсә нәрсәне дәшми-тынмый гына хуплап торуыгыз белән илне шушы хәлгә китереп житкергәнсез!

Бәлки, шулайдыр да. Әмма миллионлаган шахтерлар торгынлык елларында да көн саен күмерне Сталин заманнарындагыдан ким чыгармый иде, ә хәзерге хәбәрдарлык чорындагыдан күпкә артык та иде әле. Нефтьчеләр житмешенче елларда илгә ике йөз житмеш миллиард долларлык «жир мае» суыртып бирделәр. Ходай кушып, хәзерге яшь буын, алтынын-күмерен—бар булганын бергә исәпләп, хет алдагы гасыр башына шул кадәр сумманы эшләп бирсен иде әле! Торгынлыкмыфәләнме, демократияме-фәсхетме, илдәге миллионлаган таксистлар машиналарына утыра һәм, нинди көн булуга карамастан, сменага үзенең 350-400 километрын әйләндерә иде. Чөнки халык акчалы иде!

Ә төзүчеләр? Рушан үзен белә-белгәннән бирле, аларның эшсез утырганнары булмас һәм кичке сигезсез өйгә кайтмас, ә иртән еш кына караңгыдан ук чыгып китәр иделәр. Бәлки, илнең таркалуына җаваплылыкны һәркемгә үзенә тиешлесен бүлеп бирергәдер? Илгә генә түгел, барлык социалистик дәүләтләргә мамык бәйсезлеге китергән үзбәк дехканының ни гаебе бар? Ул ни-нәрсә өчен кызарырга тиеш әле? Үзенең хәерче тормышы, ярлылыгы өчен кызарса гына инде...

Үз эшләрен намус белән башкарган, әле бу үзгәртеп кору чорына кадәр үк күзләре ачылган, тормышның кабәхәтлекләрен алданрак күргән һәм аңлаган, үзләренең үткәне өчен йөзләре кызармастай кешеләр күпләр алар.

Моннан ун еллар элек, әле Брежнев заманында, ил «җиде чакрымлы адымнар белән коммунизмга якынлашып килгәндә», дәрәҗәсе буенча илдә икенче кеше, СССР Министрлар Советы Рәисе Алексей Николаевич Косыгин

вафат булды. Иң түрдә-югарыда утырган карт түрәләрнең үлемен халык фаҗига итеп кабул итми башлаган иде инде. Әмма Косыгин вакытсызрак вафат булган икән шул: аның үлеме кадерле Леонид Ильичның Туган көненә туры килгән икән! Дөрес, үләр көнен иң зур түрәләр дә сайлап ала алмый анысы, әмма бәйрәмнәрнең, бигрәк тә үз бәйрәменең ямен җибәрергә яратмаган Брежнев партия һәм Политбю-родагы иң якын көрәштәше-иптәше хакына да сүзен бирми. Шуңа күрә Косыгинның вафатын илхалыктан өч көнгә яшереп торалар. Бу вакыйга күп нәрсә турында сөйли булса кирәк—иң әүвәл исәннәргә дә, үлгәннәргә дә кадер-хөрмәт булмаган заман һәм шул замандагы начар гадәтләр турындадыр. Ә без: «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел!»—дигән булабыз.

Ничек кенә булмасын, әлеге кайгылы хәбәр кичкә таба Рушаннарның прораб бүлмәсенә дә килеп ирешә. Инде кыш алды салкыннары тора, кибеп-корып баручы Арал диңгезе ягыннан котырынып тоз тәме катнаш әче җил исә. Инде күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Планерка азагында кемдер ике шешә аракы белән әллә ни бай булмаган кабымлыклар күтәреп керде. Стаканнарга салып чыккач, дәртләндерергә теләпме, кемдер:

—Нәрсә өчен эчәбез?—дигән булды.

Шунда кайсысыдыр:

—Иптәш Косыгинның рухы өчен,—диде.

Җитди һәм урынлы әйтелде шикелле бу сүзләр, эчәр өчен берәр сәбәп кирәк бит.

Барысы да стаканнарына үрелделәр, ул көнне бик арыган һәм тизрәк кайтып урынга авасы килсә дә, Рушан тыштан караганда кирелеккә охшаш, әмма ниндидер эчке бер каршылык-протест белән, хезмәттәшләрен аптырашта калдырып, кинәт кенә кистереп әйтеп салды:

—Мин аның өчен эчмим!—диде.

Аракыны инде авызларына китергән халык өчен бу сүзләр шундый кинәт булды ки, хәтта берсе чак кына стаканын кулыннан төшереп җибәрмәде. Ул заманнарда әле сәяси бәхәсләр кухнялардан урамнарга бәреп чыкмаган һәм ил башлыклары өчен эчеп куюдан болай ачыктан-ачык баш тарту гадәте дә юк иде. Һәммәсе дә гаҗәпләнеп, җанланып китеп, төпченә башладылар: ни өчен дә нишләп?

—Ә ни өчен әле мин аның өчен, Алексей Николаевичның рухы өчен, эчәргә тиеш?—дип, тавышын күтәребрәк әйтте Рушан.—Ул хакимияттә кырык еллап утырды һәм кырык еллап җиңел промышленностька җаваплы кеше булды, дистә еллар министр иде. Ә шул вакыт эчендә халык өчен нәрсә эшләде соң ул? Нәрсә сатып алабыз, нәрсә киябез, ни белән мактаныйк? Франциядән китерелгән урыс кайры туннары, урыс күнитекләре беләнме?..

Хәзер шул күптәнге вакыйганы хәтерләп, Рушан көлемсерәп куйды. Моннан ун ел элек, ул заманны бит хәзергесе белән чагыштырып та булмый, кибет киштәләре товарлардан сыгылып торган заман иде әле ул...

Талчыккан прорабларның барысының да эчендәгесе тышка бәреп чыкты! Һәркем үзенекен әйтеп калырга ашыга, хөкүмәт башлыгы рухына эчәргә теләгән бер кеше дә калмады. Ә бит, дөресен әйткәндә, Алексей Николаевич Косыгин хөкүмәттә дә, Политбюрода да иң начар кешеләрдән түгел иде һәм моны, башкалар шикелле үк, Рушан да яхшы белә иде. Бөек илне бөлгенлеккә төшергәннәре өчен бөтен халык каһәр укыган элгәрләре урынына килгән бүгенге идарәче даирәләр аңлыйлармы икән шуны?..

Актүбәдәге борынгы вокзал җимереп ташланганнан соң, үзенең Мартукка кайткан шул ерак көннәрен искә төшереп, Рушан Дасаев бер фикергә килде, анысы да шул каһәр суккыры «михайловский» ташкүмеренә бәйле иде: кешенең табигате бик сәер, дистә еллардан соң да аны әллә кайчан булып үткән хәлләр, шулар белән бәйле нәрсәләр дулкынландыра, дөньяда бөтен нәрсә дә үзара үрелеп берләшкән, дигән фикер кабаттан раслана. Бер шагыйрь дә бит: җирнең бер читендә кемдер суга таш ыргытса, икенче читендә ул туфан суы булып күтәрелер, дигән.

Теге вакытта, күмерсез-чанасыз килеш, авырттырган аягын көчкә сөйрәп, елый-елый өенә кайтып барган унбер яшьлек малай әле үзе дүрт елдан соң гына барып чыгасы бер шәһәрнең бер йортында «күбәләк» бантиклар яратучы кыз үсеп килгәнен, соныннан бер күрүдә үк шул кызга гашыйк булачагын, ә ул көнне әлеге йортта, аның исемен аерып телгә алмасалар да, Мартук станциясендә булган үзенә кагылышлы фаҗига турында сөйләшәчәкләрен фараз да итә алмый иде. Әмма ул вакытта ни Тамара исемле кыз бала, ни аның әти-әниләре бу фаҗиганы аның исеме белән берничек тә бәйли алмаганнардыр. Ә менә дүрт елдан соң, ниндидер күренмәс җепләр Рушанның алдагы бөтен тормышын шул гаиләгә бәйләп тотачак иде.

Моның нәкъ шулай булганлыгына хәзер шикләнми инде ул. Чөнки кызның әтисе Василий Петрович—машинист һәм аның теге каһәрле көндә ике паровозның берсендә булуы бик ихтимал, әгәр дә юк икән, ул барыбер бу вакыйга турында кайтып сөйләгәндер: андый фаҗигалар көн дә булып тормый бит. Һәм, мөгаен, сонрак почта тартмасыннан кызына адресланган хатларны алганда яки телефоннан сөйләшкәндә, ул беркайчан да Рушанның кайчандыр үзе кайтып сөйләгән Мартук малае икәнлеге турында уйлап карамагандыр.

Тормышта бөтенесе дә әнә шулай тыгыз үрелеп беткән, бу фикер дә аның башына әле генә килде. Хәзер инде Василий Петрович та вафат, «Тимерлек» янында үзе очраткан, кулына озын ефәк баулы ноталар папкасы тоткан купшы бантиклы кызчык та картаеп баручы хатындыр, ул да үзен гомере буе яратып йөрүче кеше турында әле очрашканчыга кадәр күп еллар элек ишеткәнлеген сизенмәгәндер. Югыйсә алар бәхетле яшьтә танышкан иделәр: кызга—ундүрт, малайга унбиш яшь кенә иде әле. Кайтарып ала алмаслык, ерак калган заман...

Поезд бригадалары биш сумга ашап чыга торган тимерьюлчылар ашханәсен исенә төшергәч, Рушан тагын бер вакыйганы хәтерендә яңартты—анысына да ирексездән катнашы бар иде аның.

...Сафия апаның туенда кайчандыр икәүләп «ишек бавы» тотып торган, соныннан эзе Ленинградка китеп югалган ерак туганы Мелис, егет булып җиткәч, кыска цигейка тун, хәзергечә әйтсәк, чын сарык мехлы пальто киеп йөрде. Бәхәскә ике бармагы белән бакыр биш тиенлекне бөгә ала торган Мелис төз-озын буйлы булып, тун аңа иллә дә килешеп тора иде. Ул вакытта инде сырган фуфайкаларны унайлы мех якалы кыска бобрик пальтолар алыштырып бетергән, аларның күкрәк югарылы-гында кыекча кесәләре дә бар, шунысы яшүсмерләргә тагын да ошый иде. Шул үсмерләр арасында көяз егет Мелис Вәлиевнең бердәнбер мех пальтосы, әлбәттә, күзгә нык ташлана, аның хакында авыз чайкамаган кеше дә калмаган булгандыр. Рушан хәтта бервакыт ул пальтоның бәясен дә ишетеп белде: 450 сум икән! Ул акчага ике бобрик пальто алып була иде.

Шулай килеп чыкты, инженер булып алгач, Рушанга камволь-постау комбинатын «химиягә» үзгәртеп коруда катнашырга туры килде. Комбинат синтетик тукымалар, кыскартып әйткәндә, лавсан эшләп чыгаруга көйләнде. Ул алтмышынчы еллар Зур Химия билгесе белән үтте: тормышыбызга могҗизаи химия үтеп кергәч, нинди рәхәтлекләр булачак, дип, халыкка вәгъдәләрне юмарт өләштеләр. Иң мөһиме—барысы да бушлай диярлек, бик арзан булачак, йөге—бер сум, дигәндәй генә, ни әйтмә, химия бит, димәк, һавадан, төтеннән, газдан ясала.

Матбугатта габардин, коверкот, бостон, диагональ, шевиот, драп, бәрхет ише чын табигый тукымаларны китте яманлау, китте яманлау! Баксаң, алар кыйммәт тә, чыдамсыз да, тузанны да күп җыя, югач утыра, модалы да түгел икән—дөньяда иң алдынгы, иң прогрессив совет кешесенең хәзерге образына һәм бүгенге заманга, табигый ки, болар һич кенә дә җавап бирми. Кыскасы, аларның тамырын корытырга кирәк һәм эшне никадәр тизрәк тотсак, шул кадәр яхшырак булачак, имеш.

Кыргызстанның элекке Пешпек, хәзерге Бишкек, ә ул чагындагы

Фрунзе шәһәрендә әнә шундый комбинатны кырып салды Рушан һәм аның хезмәттәшләре. Ә бит ул заманнарда Кыргызстанда йонның исәбе-чуты юк иде, чынлап та, йөге—бер сум, таулардагы көтүлекләрдә миллионлаган сарык утлап йөри иде бит.

Хәтерендә, әбәткә туктагач, нindидер бер тукучы карт, үпкәсен белдереп, Рушанга әйткән иде: «Акылыгызга килегез, нишлисез сез?! Табигать үзе бар иткән тукымадан да яхшырагы беркайчан булмаган, булмаячак та. Әгәр дә инде дәүләтебез акчасын кая куярга белми икән, табигать могҗизасы—сарык үрчетүгә сарыф итсен». Менә шулай дигән иде ул карт. Ә Рушаннар, газеталардан кисеп җыелган мәгълүматларны укып күрсәтеп, синтетик тукымаларның нинди искиткеч сыйфатларга ия икәнлеген исбат итеп маташтылар.

Беренче совет лавсаны йон габардиннан ун сумга арзанрак тора иде, ләкин ике елдан аларның бәяләре тигезләнде, ә хәзер асылда үзебезнең йон тукымалар да юк, лавсан да каядыр югалды, ә бит шалкан бәясенә генә һәм күпме теләсәң, шул кадәр булыр, дип өметләндергәннәр иде.

Әле менә бу соңгы кышта Рушан, ничектер бер кибеткә кергәч, анда су буе чират күргән иде. Халык, сугыша-талаша дигәндәй, ясалма мех пальтолар ала икән. Ул моннан утыз еллар элегрәк Мелиснең шундыйрак мех пальто киеп йөргәнен исенә төшерде, әмма ул чын мех пальто иде, ә болардан бер чакырымнан химия исе аңкып тора. Рушан арыш капчыгыдай саргылт шул нәрсәне кибеттә үк өстенә киеп куйган бер бәхетлесеннән бәясе ни хак икәнен сорады. Теге адәм, киң күнеллелек күрсәтеп, бәясе язылган ярлык кәгазен йолкып алып бирде. Йа, Хода! Булса булыр икән—нәкъ утыз ел элек ишеткән сан—450 сум! Әмма яңа акча белән. Менә сиңа йөге—бер сум!

Габардинсыз-бостонсыз, йонсыз-тиресез, итсез-сөяксез утырып калдык түгелме соң? Миллиард сумнарны җилгә очырдык, табигатьне химия белән пычратып бетердек... Әйе, Фрунзедагы тукучы карт хаклы булган—акчаны сарык үрчетүгә тотасы калган, сарыкка, ә химиягә түгел.

Әгәр дә бүген кем дә булса илнең җитмеш ел эчендә мәтәштергән эре план-проектларын—авылларны колхозлаштырудан алып хәзерге азык-төлек программасына кадәр булганнарын—тикшерә калса, без үзебезнең аңгыралыгыбызга һәм наданлыгыбызга шаклар катар идек, дөньяның һәм үзебезнең хәзерге тәҗрибәбез биеклегеннән карасак, ул проектларның күбесенең корткычлыкка, диверсиягә тиң икәнлеген күрер идек.

Соңгы вакытларга кадәр хөкүмәтнең халык тарафыннан һәрчак җитди кабул ителә торган төрле карарлары арасында вакытлыча дигәннәре дә була иде. Алар шулай башланып та китә: «Шундый-шундый хәлләр аркасында вакытлыча бәяләр күтәрелә...» һәм башкалар. Әмма вакытлычадан да озаграк яшәгән бер нәрсә дә әлегә юк. Хөкүмәтнең шундый бер указы Рушанның хәтерендә гомерлеккә сакланып калды, ул аны һаман да оялып искә ала әле.

1961 елның иртә язы иде. Рушан Экибастуздан китеп барырга җыенып, вокзал перронында басып тора. Шушындагы төрмәдә әле күптән түгел генә Александр Исаевич Солженицын утырган, ә җирле ТЭЦның директоры Георгий Маленков үзе булган заман. Соңыннан Рушан аны Беренче Май бәйрәмнәрендә энергетиклар колоннасы башында демонстрацияләрдә дә күргәләде.

Рушан Павлодардан киләсе поездны көтеп тора иде. Менә шул вакытта вокзал репродукторы телгә килде, хөкүмәт указын тапшыра башладылар: «Шундый-шундый тискәре хәлләр аркасында» беренче апрельдән атланмайга бәяләр арта, вакытлыча, килограммы өч сум илле тиенгә кадәр булачак икән.

Рушанның янәшәсендә шулай ук соңарган поездны көтеп торучы бер төркем халык бар иде. Алар хөкүмәт белдерүен ачу белән, бер дә хупламыйча тыңладылар. Бигрәк тә җылы мамык шәл уранган юан бер хатын тузынды: «Аларның «вакытлыча» дигәне гомерлек була инде ул!»—дип чәпчеде.

Яшьлегендә Рушан, күпчелек халык кебек үк, рәсми пропагандага һәм ташка басылган һәр сүзгә ышана иде. Шуна күрә ул, әлеге усал төркемгә үз фикерен житкерүне, комсомол буларак, хөкүмәт карарын аңлатып бирүне үзенең гражданлык бурычы итеп санады. Ул алар янына тәкәллефсез генә якынайды да, мәсхәрәле елмаеп, катгый гына аңлата башлады:

- Сез, иптәшләр,—диде ул,—бер бик мөһим сүзне ишетми калдыгыз бугай. «Вакытлыча»! Аңлыйсызмы—ва-кыт-лы-ча... Вакытлы авырлыклар үтәр, май да элеккедән арзанрак булыр. Мин үзем шулай булырына һич шикләнмим.—Үзенең шушы гамәленнән бик тә канәгать калып, ул алар яныннан читкәрәк китеп барды.

Бу вакыйганы аның һич онытасы юк—соңгы елларда май белән даими өзеклекләр чыгып тора, май житми интектерә. Рушан кайчандыр үзе майларына чыдаша алмаган обывательләр дип санаган теге кешеләрдән, күнеленнән булса да, гафу үтенә. Нинди яшь һәм беркатлы булган ул!

Экибастуз, Солженицын, Маленков... Жәберләнгән юлбашчы белән жәберләнгән әдип... Безнең бу гөнаһлы жир йөзендә һәммәсе дә буталып беткән инде. Әмма, ни генә әйтмә—аларның һәркайсы, шул жөмләдән, билгеле, Рушан үзе дә бу шәһәрдән әлеге кечкенә перрон аша атлап китеп барган. Ә шәһәр ул заманнарда үзенең кырыс-усал төрмәләре һәм илдә беренче булып ачык ысул белән эшләүче руднигы белән танылган иде. Хәзер, Солженицын китаплары үз ватанында күпләп басыла башлагач, Рушан Дасаев аларның һәркайсысын аерым бер дулкынлану белән кулына ала: сон, шулай булмыйни—кайчандыр бер перроннан киткән кешеләр бит...

Рушан үзенең Солженицынга якынлыгын тагын шуннан да тоя, «Рак корпусы» романын әдип Ташкент хастаханәсендә язган, дип сөйлиләр яки, ана шул куркыныч авыру диагнозын куйгач, роман язу нияте Ташкентта туган, диләр...

## XI

Кеше язмышы югалтулар һәм табышлардан тора. Кайчакларда тегесе яки монысы йә күбрәк, йә азрак була, шуларның бер-берсенә нисбәтенә карап, мөгаен, тормышыңны бәхетле яки бәхетсез, уңышлы яки уңышсыз дип хисапларга мөмкиндер. Асылында язмыш—төпсез кое. Ахыр килеп, анда барысы да житәрлек, теләгең булса, картлык көнендә үткәненне тыныч һәм гадел генә актарып баксан,—чөнки ул инде синеке дә кебек, түгел дә кебек,—моны үзеннән башка беркем дә әйбәт итеп башкарып чыга алмас иде. Хәтта иң күренекле берәр әдип тә.

Ихтимал, шунадыр, Рушанның үзе турында да язып калдырасы килә, шунсыз ул заманны, безнең һәркайсыбыздан башка күрсәтеп булмаган шикелле, тулысынча күрсәтеп тә булмас иде бит. Бәлки, тормыш юлындагы ниндидер маяклар, синең яратуларың һәм мавыгуларың ни өчен теге яки бу вакыйгаларны, язмышларны, югалту-табышларны шулай кабул иткәнлегенне аңларга булышырлар. Атлантиканың биек текә яр буендагы Язмыш борыны дигән жиреннән алып Тын океан буендагы Находка портына кадәр сузылган галәмәт чиксез киңлекләрдә Рушанга бик күп нәрсәләр белән очрашырга туры килде бит.

Ә нәрсә соң әле ул югалтулар? «Югалту» дип без еш кына берәр жисми әйбер турында сөйлибез: акча югалту, мәсәлән. Ә бит югалтулар күп төрле була, бөтенләй көтелмәгәннәре, ышанып булмастайлары, кайбер югалтуларны без, вакыты житмичә, тоймыйбыз да.

Шундый югалтуларның берсе Рушанның тормышында шактый иртә, әле югалтуларга кеше күнекмәгән һәм аңа бик игътибар да итеп тормаган яшендә килде. Үз вакытында әһәмият бирмәгәнгә һәм хәзер генә ул югалтуның никадәр тирән мәгънәле булуын аңлагангамы, Рушан шул заманнарга әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта. Аңысы да ярый: сонлап

булса да, аңлавын яхшы, дип юкка гына әйтмиләрдер ич...

Ул, дүрт бишьеллыкка арткарак чигенеп, Мартугын исенә төшерә. Үткән тормышны шулай бишьеллыклап исәпләү безнең илгә генә хас, ул комга сеңгән су кебек аккан вакытны кискенрәк тоярга ярдәм итә. Рушан янә мәктәптә «Кем булырга телисең?» дигән иректә темага язылган иншасында үзенең балерина булырга хыяллануын яшермәгән кызны исенә төшерә.

Бүген, әрсез кызлар иншаларында валютага эшләүче фахишә булырга теләүләрен оялмыйча язган заманда, ул кызыйның хыялы бераүгә дә сәер тоелмас иде. Ә теге чакта... И-и-и, теге чакта Мартук гайбәтчеләре беркатлы үсмернең бәллүр хыялын челпәрәмә китерделәр шул, гомер буена аңардан көлеп, уңышсызлыкларын күргәндә, «балерина» дип мәсхәрәләп кенә тордылар. Ә кемнең тормышы гел уңышлы гына була? Юктыр андыйлар, булса да, бик сирәктер.

Бәлки, балерина булырга бөтенләй өмете юклыгын Валя үзе дә белгәндер. Ул һөнәргә бит бик кечкенәдән, махсус мәктәпләрдә һәм студияләрдә аерым укытучылардан өйрәнәләр. Билгеле инде, тузанга баткан Мартукта боларның берсе дә юк һәм, мөгаен, якын киләчәктә генә булмас та. Әлбәттә, ул хәтта өмет тә түгел, ә болай гына, иркә кыз баланың бер мизгеллек җинел һәм тиз уалучан матур хыялы гына булгандыр. Өлкәннәр шул ин изге теләкнең ни-нәрсә икәнен белергә теләгәннәр. Белделәр. Һәм, кызны адәм көлкесенә калдырып, поселокка тараттылар...

Бервакыт Валя әрнеп әйтеп куйган иде: «Йа, Хода! Безгә инде егерме сигез яшь!» Үзенең ничәнче яшеннән этәрелеп китеп әйткәне билгесез— әмма бу сан аның авызыннан бик кайгылы булып ишетелде. Рушан да үсеп җитүенең, җитлегүенең исәбен-вакытын күптән белә—дөрес, аныкы яшьрәк, егерме биш яшендә булды. Әмма алар икесе дә үз яшьләрен дөрес аңлап кабул итәләр иде инде.

Әгәр дә Рушанның сыйныфташларыннан үзе турында сораштырырга тотынсалар,—хәер, нинди уңай белән сораштырсыннар, ди?—кино йолдызы да, генерал да түгел, ә гап-гади прораб кына ич,—алар аның исеме белән янәшә Валя Домарованы, «балерина»ны да телгә алырлар иде, үз вакытында ул бит аңарга күз дә атып йөргән иде.

Әмма беренче мәхәббәт хисе турында үзеннән сорасалар, Рушан, уйлап та тормыйча, башка берәүнең—«1905 ел» урамында яшәүче, кулына ноталар салынган папка тотып йөрүче кызның исемен атар иде: Тамара.

Алар бәхетле үсмерлек елларында таныштылар—кызга—уналты, ә Рушанга унбиш яшь иде. Кайтарып алып булмас ерак заманнар. Ул чагында Рушан аны—чәченә купшы зәңгәр «күбәләк» кундырган, кулына озын ефәк баулы нота папкасы тоткан кызны Тимерьюлчылар сарае янында очраткан иде. Очратты да, артыннан ияреп тә китте. Тимерьюл-чылар көне унае белән яңа акшарланган-буялган диварлары, ялт итеп юылган тәрәзәләре белән балкып торган әкияти вокзал бинасы яныннан да үттеләр алар. Баксаң, кыз да Мәскәү бистәсендә, «1905 ел» урамындагы 28 нче йортта яши икән—кара син аны, хәтер шунысына кадәр саклап калган бит...

Хәер, Рушан белән Валяны да бер сүз белән генә аңлатып булмастай ниндидер хисләр бәйләгән иде—әле үзара сөйләшеп йөри башлаганчы ук, кыз, әлбәттә, Татар бистәсенең кара күзле бу малаена үзенең ошаганлыгын күнеле белән тоя, сизенә иде. Ә малай исә җәйге кинотеатрда ял көннәрендә була торган көндезге сеансларда күзләре белән гел аны эзли, күзләре очрашканда, кыз елмаеп та куйса, шатлыгы җиде кат күкләргә аша иде. Инде янәшә туры килсәләр, йә очраклы гына аның күлмәгенә-мазарына, кулларына да кагылып китсә, малайның дулкынла-нуының чиге булмый. Рушан аны берничә мәртәбә велосипедта да йөртте бит әле! Хәзер аларның ул гөнаһсыз мөнәсәбәтләрен моңлы-сагышлы елмаеп кына искә алырга калды.

Йә, велосипедта йөртте, ди. Моның ис китәрлек нәрсәсе бар соң? Хикмәт тә шунда шул, кызлар ул заманнарда теләсә кайсы малайның велосипедына утырмыйлар да иде. Кызлар альбомнарындагы: «Үлсән—үл,

әмма яратусыз үптермә!» дигән язулар да, башка гөнаһсыз мөнәсәбәтләр дә хәзерге яшүсмерләр өчен тузанлы тарих булып кына тоеладыр, бәлки. Хәер, ул яшьтә әле Рушаннар буыны үбешүләр турында уйлап та карамый иде. Иң кызыгы, иң дулкынландырганы китапханәдәнме, кибеттәнме кайтышлый яки шунда ук «очраклы гына» очрашу яисә кызның каршысына берәр чаттан велосипедта атылып килеп чыгу, аңа коедан сулы чиләген күтәрешеп кайту яки ул мәктәпкә барганда, янә дә «очраклы гына» очрашу булыр иде...

Ул Валя белән җәй көне, пионер лагеренда ял итеп кайтканнан соң, кинотеатр янында танышкан иде. Легендар Джон Вейсмюллер уйнаган «Тарзан» фильмының чираттагы сериясен күрсәтәләр, билет кассалары янында—мәхшәр, ә Рушаннар Татар бистәсеннән бер компания булып җыелып килгәннәр, араларында теге башкисәр чечен Солтан да бар иде. Рушан кассадан ерак та түгел җирдә тыгыз итеп, ак тасма-күбәләк куеп үрелгән толымлы кызны шунда ук күреп алды. Кызның бу сеанска эләгергә өметен өзгәне күз карашыннан ук сизелә иде. Шунда Рушан үзе дә аңышмастан кыз янына килде дә, бераз каушый төшеп сорады:

—Сиңа ничә билет кирәк?

Кыз шатлыгыннан балкып китеп:

—Бер, теләсә кайсы рәткә,—диде һәм учындагы тирләп беткән көмеш акчасын сузды.

Рушанның күңеленә ул гомерлеккә шулай учындагы егерме тиен акчасын сузган килеш кереп тә калды.

Бәлки, алга таба Валя белән аралары бөтенләй якынаеп та киткән булыр иде, әмма техникумда укый башлавының беренче көзендә үк ул алсу «күбәләк» бантиклы кызны очратты. Әгәр дә җәясендәге укны тартып торучы түгәрәк битле Амур дигән фәрештә бар икән, ул бер атуда ук Рушанның нәкъ йөрәгенә тигезде.

Валя белән дә, бер-берсенең күз алдында үскәнгәме, җәйге кинотеатр янында башланып киткән бер-берсенә тартылу хисе һаман да сакланып килә иде. Хәер, Валя—чибәр, үзсүзле, үзенең үзгә йолдызы барлыгына инанган кыз—биредәге малайлар арасыннан кемне булса да үзенә тиң санадымы икән? Ул, һичшиксез, Мартуктан кайдадыр еракта үзен Искиткеч Принц көтеп торадыр дип ихлас ышана иде.

Ә бит туган ояларыннан тизрәк очып чыгып китәргә ашкынган Мартук гүзәлләренең һәммәсе дә диярлек шундый хыял белән яшәгәндер. Шактый вакытлар үткәч, бер очрашканда Валя үзе шулай сөйләгән иде. Ул арада Валя инде Куйбышев шәһәрендә институт тәмамлаган, кияүдә булган, хәтта әле ике тапкыр бугай! Һәм, бераз тын алырга дип, әти-әниләре канаты астына кайтып сыенган чагы иде.

Рушан бу вакытта үзе дә институт дипломы алган, хәтта чак кына өйләнми дә калган иде, әмма туй дигәне һич тә аның гаебе белән сүтелмәде. Аның өстендә ниндидер кара язмыш бар иде шикелле—кайсы кызга гына гашыйк булмасын, алар һәммәсе дә шашкын-дәртле мәхәббәткә сусаган, хыялларында җиде кат күкләрдә йөзәләр, Искиткеч Принцка өмет итәләр, бер мәшәкатьсез, кайгы-хәсрәтсез романтик тормышта яшәргә телиләр иде. Билгеле инде, Рушан әкияти принц була алмый, кызлар теләгән «бер мәшәкатьсез романтик тормыш»ны тәэмин итәргә дә кулыннан килми. Ул хәтта андый тормышны күз алдына да китерә алмый иде. Ләкин шунысы сәер, ничәнче кат авызы пешсә дә, ул янә шундый ук берәр кызга гашыйк була, кызлары да, күрәсең, бу егеттәге ниндидер сыйфатларны ошаталар, аңа кияүгә чыгарга бик ашкынып тормасалар да, бөтенләй үк читкә дә тибәреп бетермиләр иде.

Инде хәзер, картаеп барганда, бер ялгызы калгач, кемнәрнеңдер күз алдында ул, бәлки, уңмаган бер бәхетсез адәм булып күренәдер. Әмма Рушан үзе һич алай санамый һәм үзенең үткән-кичергән тормышын һичкайчан да әйбәт хуҗабикәле тыныч рәхәт тормышка алыштырмас иде шикелле.

Бервакыт ул, үзенең төзелеш эшләренә кагылышлы командировкадан кайтышлый, юл уңаеннан берничә көнгә генә Мартукка сугылды. Исәнләшеп-сөйләшеп туйгач, тегесен-монысын караштырып бетергәч, ул, бөек Сталинның яшелләндерү планын тормышка ашыру максатыннан, кайчандыр үзе утырткан һәм хәзер инде куәтле-зур булып үсеп киткән карагачларның, тирәкләрнең корыган ботакларын кисәргә булды. Шул эш белән шөгыльләнгәндә, аның янына велосипедка атланган кыю гына бер кыз бала килеп исәнләште дә бер язу сузды.

Рушан шакмаклы дәфтәр битен аптырабрак кына кулына алды, язучының кулын танып, ашыгып укый башлады:

«Рушан, сөеклем! Кичә синең үзебезнең якларга кайтканыңны ишетеп бик сөендем. Очрашып сөйләшсәк, уртак дусларыбызны искә төшереп утырсак, ә Володя Колосов белән Толик Чипигин кебек иртә вафат булганнар рухы өчен берәрне тотып та куйсак, әйбәт булыр иде. Нинди яшь, беркатлы-самими һәм бәхетле булганбыз, шуны аңламаганбыз, әйеме? Мәктәпкә берәр кичәгә яки, әти-әниләрдән курка-курка, кача-поса гына паркка биюләргә йөрү, борылып карагач, синең ягымлы, ярату тулы карашыңны тою—нинди рәхәт, нинди матур чаклар булган ул!

«Минем турылыклы Рушаным»—синең исемеңне мин бик еш кына әнә шулай һәркем ишетерлек итеп, дус кызларны көнләштереп, кычкырып кабатлый идем. Сәер бит, безнең арада берни булганы юк, хәтта бер үбешмәдек тә, ә барыбер, ни өчендер, мин сине һәрвакыт үземнеке санап йөрдем, сина хакым бардыр кебек тоела һәм минем өчен утка-суга керергә ышана идем. Ялгышканмын. Гомумән, тормышымда күп ялгыштым һәм күп мәртәбәләр авызым пеште.

Әмма, бигрәк тә шуңа күрәдер, бәлки, сине тормышым-язмышымнан сызып ташлап булмый... Бихисап татар туганнарың үзенә карап, сокланып туйгач, бүген кич соңлабрак, сәгать унберләргә килеп чык әле. Валя.»

Рушан укып бетергәнче, велосипедлы кыз китми торды—мөгаен, язуга борының төрткән булгандыр әле, хәзер, әнә, кызыксынуын яшермичә, кайчандыр Валя апасы ошатып йөргән бу абыйны күзәтә.

Рушанның уйларга бирелеп, үзен онытканын күргәч, кыз үҗәтләнеп сорады:

—Килерсезме?

Рушан, сискәнеп, уйларыннан айнып китте, таркау гына:

—Килермен...—дип җавап бирде, хәтере янә үткәннәргә кереп уралды.

Мартукның кичләре искиткеч була: җәен көндезләрен кырык градуслардан ашкан эсселек, вакыт-вакыт кайлардандыр көйдергеч-кайнар җилләр исә, ә кояш баюга бер могҗиза була—көтмәгәндә салкын төшә, һава сафлана, ә соңрак биектә, зәңгәрсу-кара төнге күктә бихисап якты йолдызлар кабына. Табигатьтәге бу сихри үзгәрешне хәтта күңеле катып беткән, бар нәрсәгә битараф кешеләр дә тоялар, юк-юкта, берәрсе сокланып әйтеп куя: һай, кичләре дә кичләре, карап-сулап туйгысыз!

Ул көнне дә дала ягыннан түзеп булмаслык коры-кайнар җил исте, кешеләрне әлсерәтеп, кояш рәхимсез кыздырды, ә зур утлы-кызыл шар бакчалар артына, офыкка кереп югалуга, нindидер тылсымчының кулы беләнме, бөтенесе дә үзгәрде дә куйды, хәтта, бакча хуҗаларын кич су сибү мәшәкатеннән коткарып, бер ярты сәгать чамасы җылы яңгыр да явып алды.

Валяны Рушан соңгы тапкыр бик күптән, моннан җиде-сигез еллар элек күргән иде. Кыз әле—студентка, җәйге каникулга кайткан, ә Рушанның исә чираттагы ялы иде. Бию мәйданчыгында очраштылар, әмма юньләп сөйләшә дә алмадылар—кызны гел генә биергә чакырып торалар. Шәһәр Валяга үз йогынтысын ясап өлгергән: кыркылган-кистерелгән чәч, буялган тырнаклар, соңгы модалы купшы-көяз кием, үзен тотышында да нindидер яңалык бар—дорфарак кыланчыклыкмы шунда. Егетләр белән үзен бик ирекле-иркен тотуын, биюләрдән туктап торган арада шулар белән бергә ачыктан-ачык тәмәке тартуын Рушан килештереп бетермәде шикелле. Ә

менә күпләргә кызның шул кыланышлары ошый, хуплап: «Күрсәтә бу!»— диләр. Вакыт-вакыт Валя артык күп һәм артык каты кычкырып көлә, шуның белән башкаларның игътибарын тагын да ныграк җәлеп итә иде. Ләкин Рушан, авыз ачып, ана: «Син үзенне артык әдәпсез, артык вульгар тотасың»,—дип әйтә алмады. Кич буена шул сүзләр тел очында торса да, кыюлыгы җитмәде. Дуслары аңламас: «Балеринасын кулыннан ычкындырган ачудан сөйләнә»,—дип әйтүләреннән курыкты. Үз-үзенне табигый иркен тоту белән тупас әдәпсезлеккә якын вульгарлык арасын кем сизә, кем сизми дигәндәй, шул чикне Рушан сизә-тоя, ә Валентина үзе чамалап бетерми иде, ахрысы. Ана мөкиббән киткән поселок егетләре һәм кызлары турында инде әйтеп торасы да юк: алар Валяның үз-үзен тотышын заманга ятышлы иң яхшы үрнәк итеп кабул иткәннәр иде.

«Нindirәк икән ул хәзер? Тормыш нәрсәгә өйрәтте икән үзен?»— Шундыйрак сораулар Рушанны көне буе бимазалап торды. Купшы капрон «күбәләкле», тыгыз үрелгән толымлы кызның дымлы көмеш егерме тиенне үзенә сузып торган сурәтен соңгы мәртәбә күргән кыз—кистерелгән-буялган сары чәчле, әйтергә дә оят кыска мини итәкле, бармак араларына сигарет кыстырган кыз сурәте каплый да китә, каплый да китә иде.

Дөресен генә әйткәндә, командировкадан калган берничә көнен өйдә үткәрергә дип кайтканда, Рушан Валя турында уйлап та карамаган иде. Әле хәзер, чакыру алгач та, әллә нинди планнар корып тормады. Асылда, аның очрашуга баруы яшьлегендә үзенең шул кыз өчен кем булуын һәм ни өчен алар арасында бер нәрсә дә барып чыкмавын ачыклау өчен кирәк иде. Велосипедлы кыз артыннан биреп җибәргән язуында Валя матур сүзләр тезүен тезгән дә бит... Әйтерсең, алар, Сиам игезәкләре кебек, гел бергә булганнар!

Әлбәттә, Рушан үзе дә нык үзгәрде. Ул бик яшьли, бөтен яңалыкны комсызланып йотардай вакытыннан ук шәһәр кешесе булып китте. Үзенең «авыл бәрәңгесе» икәнлеген аңлагач, ул үзенә чит күз белән карарга өйрәнде, шул ана бик күп ярамаган гадәтләреннән арынырга ярдәм итте. Әмма барыннан да бигрәк, үзендә булган яхшылыклар өчен ул гыйшык тотып йөргән кызларына бурычлы—алардан саф яктылык бөркелә иде сыман. Ул кызлар Рушан ахырынача аңлап бетерә алмаган нindiдер әкияти-хыялый дөньяларда, җиде кат күкләргә ашарга теләп яшәсәләр дә, аларның берсен дә кулларында сигарет белән, урынлы-урынсыз кычкырып-кычкырып көлүләре, буялган тырнак, каралткан-зәңгәрләндергән каш-күз, бөтенләй итәксез диярлек мини-юбкалар белән күз алдына да китереп булмый иде.

Ул кечтә элеватор янындагы тын урамда, кайчандыр утыртылган нечкә-зәгыйфь көмешсыман тупылларның мәһабәт ябалдашлары арасына кереп сыенган өйдә алар икәүдән-икәү генә очраштылар...

Чынлыкта, бер-берсе турында бик аз белгән ике зат...

Әлбәттә, бу очрашу үзләренә бөтенләй башкача тоела иде...

## XII

Совет урамына Рушан билгеләнгән вакыттан алданрак килде: аның бу урамны азагына, кирпеч заводына кадәр карап узасы килә иде. Ин соңгы йортта Эмма Бобликова тора, бервакыт анда октябрь бәйрәме кичәсенә җыелышып, Рушан белән аның дусларын кертмәгәннәр иде. Биек койма артында кәеф-сафа корып утыручы бәхетлеләргә нинди дә булса этлек эшлиселәре килеп, шул йорт тирәсендә бик озак бөтерелгәннәр иде. Ярый әле, ул хурлыклы адымнан кемдер тыеп калды. Урам беткәч, аерым утарда Генка Лымарь яши, теге ноябрь кичennән соң ике атна үткәч, шунда Яңа елны каршыладылар. Эммадан башка кызларның һәммәсе дә килгән иде, ә Эмманы, «хыянәтче» дип, чакырмадылар да, Рушанның ул тирәләрне дә күрәсе килә иде.

И, ул яңа ел бик кызык булган иде! Валентина ул елны унны бетерә,

Рушан исә Мартукка шәһәрдәге дуслары Роберт белән Рафаилны ияртеп кайткан иде. Алар, поезддан төшүгә үк, туп-туры мәктәпкә—яна ел кичәсенә киттеләр, ә шуннан соң инде, шау-гөр килеп, бирегә—Мартук читендәге утарга килделәр.

Ике шәһәр егете дә булу кичәгә аерым бер ямь өстәгәндәй булды, аларның килерен алдан ишетеп белгән кызлар танымаслык гүзәлләр иде. Шунлыктандыр, мөгаен, «бал-кичәнен хуҗасы» Саня Вуккерт бер өстәл тирәсенә үзара көндәш булган бик күп кызларны рәттән тезеп утырта алды. Ә иртәнге якта Роберт яшькелт күзле Томочка Солохоны озата китте дә... үзен милиционер китерде. Егет адашкан икән дә, бик ышанып һәм гадәтләнгәненчә, милиция бүлегенә барып кергән—анын әтисе ул заманда өлкә прокуроры булып эшли иде.

Шунда Рушан гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр кызыл «Цимлянское» дигән шампан шәрабе эчте. Биек бокал эчендә, ут яктысында ул искиткеч матур уйнап-балкып тора иде. Бары тик шул кызыл шампан шәрабе өчен генә дә ул ерак калган яңа елны искә алырлык иде. Әмма ул кичәдән тагын бер нәрсә күңелдә уелып калган әле: «Цимлянское»дан тыш анда гади шампан да булып, анысы... гади ярты литрлы шешәләрдә иде. Үткен телле Вуккерт аңа шунда ук «Ике кешелек шампан» дигән исем дә биреп өлгерде, чөнки кайберәүләр, берәр шешә эләктереп, күзе төшкән кызы белән күрше бүлмәгә кереп шылырга ашыктылар...

Сүрән яктыртылган Совет урамына килеп чыккач, Рушан бераз югалып калды. Бакчалардагы куе-биек сирень куаклары карангыга чумган йортларны каплап торганлыктан, ул каршыдагы өч йортның тәгаен генә кайсысы Валентиналарныкы икәнен абайлап бетерә алмый иде. Элекке билге—Домаровлар янкапкасы каршысындагы кое да күптән юкка чыккан икән. Ул, алдан ниятләгәнчә, урам буйлап китеп барырга булды, сәгать унберләргә борылып килгәч, кайсы капканы шакырга икәнен, мөгаен, чамалар әле. Әмма кинәт кенә бер бакча артыннан матур гына итеп гитара чирткән тавыш ишетелде, аннары—ниндидер тын, шатлыклы аваз, күптән кыркылмаган сирень куаклары кыштырдавы—янкапкадан ак күлмәкле, зифа буйлы кыз күренде, ул ерактан ук ясалмарак пышылдап:

—Рушан, минем кайда торганымны әллә оныткансың да инде?—дип сорады.

Рушан тиз генә юлны аркылы кисеп чыкты да, яңгырдан соң җыелган күлләвек аша сикереп, кыз янына килеп басты, үзенә сузылган салкынча һәм искиткеч ягымлы-нәфис кулны кысып алды.

—Исәнме, Валя. Бер дә онытмадым,—дигән булды ул, бераз каушый төшеп.—Алданрак килеп, Эмма Бобликовалар йортына кадәр барып килергә теләгән идем, сез анда, безне—Татар бистәсе малайларын кертмичә генә, Октябрь бәйрәме кичәсе үткәргән идегез.

—Ә син эчкерле икәнсең,—дип көлемсерәде Валя.—Ичмасам, бергә үткәргән яңа ел кичәсен исеңә төшерер идең! Теге, синең дустыңны, Роберт иде бугай, иртәнге якта милиционер китергән кичәне, дим... Ә нинди шампан эчкән идек ул чакта, ә! Кызыл «Цимлянское»! Беләсеңме, шуларны сөйләсәм, мина беркем дә ышанмый...—Кыз кинәт кенә күңелсезләнеп калды.

Менә шулай, капка төбендә үк, истәлекләр киче, «Ә хәтерлисеңме?..» сорауларына җаваплар уены башланып китте.

—Сезнең бакчада нинди гитарачы яшеренгән?—дип сорады Рушан.

—Мин байтактан гитара чиртәм бит, студентлык елларымнан бирле,—диде Валя.—Начар уйнамыйм, диләр.—Бераз тынып торгач, кинәт өстәп куйды:—Син бит минем хакта бернәрсә дә белмисең. Безнең бит хан заманнарыннан бирле күрешкән юк инде. Әйдә, рәтләбрәк күрим әле үзеңне,—дип шаяртып, биек багана башындагы фонарьдан төшкән сүрән яктылыкка табан—күрше йорткарак өстерәде.

Күршеләрнең кыйшайган коймасы буенда Рушанны әле тегеләй, әле болай әйләндергәләп караштырганда, Рушан үзе дә олыгаеп киткән Валяны

күзәтү форсатын ычкындырмады.

Аллага шөкер, теге бию мәйданчыгындагы акшарлы сары чәчле кызыйдан берни дә калмаган икән. Хәзер Валя, гадәттәгечә, табигый: бернинди химиясез-бөдрәләрсез чәче шома гына итеп артка таба жыеп куелган, киң-биек маңгае да ачылып киткән, күз тирәләренә сизелер-сизелмәс кенә төс индергән, шунлыктан карашы да серлерәк, матуррак тоела. Бу серлелекне ул әле тагын үсмерлек елларында күргән Голливуд фильмнарындагы Грета Гарбо, Мерилин Монро, Элизабет Тейлорлар кылана торган алым белән дә көчәйтеп жибәрә: Валентина кинәт кенә, гел көтмәгәндә керфекләрен түбән төшереп, күз карашын читкә ала, аннары үзенең матур башын оста гына итеп бора да керфекләре янадан күтәрелә һәм күзләре йолдызлар шикелле жемелди башлый.

Бу «жемелдәшкән йолдызлар» дигән мактау сүзен кызга биюләр вакытында ниндидер бер практикант егет әйткән иде. Ә Мартукта ул практикантлар жәйләрен житәрлек була: инженерымы, табибымы, ветиринары-фәләне, дисеңме—буа буарлык! Ә Валя теге чакта шунда ук, түзмичә, Рушанга мактанасы итте: «Минем күзләрем, чынлап та, жемелдәшкән йолдызлар төслеме?»

Хәзер сокландыра белүнең бу ысул-алымын ул шулкадәр оста һәм житез итеп, сәнгатьчә башкара иде, ул хәтта аның гадәтенә әйләнгән иде инде. Әле дә менә Рушанга әнә шул «жемелдәшкән йолдыз»лы карашын берничә мәртәбә бүләк итеп өлгерде.

Артка жыеп куйган чәче өстендә ялтыравык муар бант, ул ачык бизәкле эре тропик күбәләккә охшап тора. Менә шул «күбәләк» аны аеруча матурайтып-яшәртеп күрсәтә—зифа буйлы бу гүзәл инде ике мәртәбә кияүдә булып кайткандыр, дип берәү дә әйтә алмас иде шикелле.

—Кызганыч, яшьлегемдә сине бәяләп бетермәгәнмен,—дип көрсенеп куйды Валя.—Бик чибәр күренәсең: менә дигән ир-егет, тазарып-ныгып та киткәнсең. Ә мин сине еш кына иске велосипедка атланган йолкыш бер малай итеп искә төшерәм. Син һәрвакыт көтмәгәндә һәм бик еш килеп чыга идең... Ә соңыннан бөтенләй югалдың...—Аның холык-табигатендә әнә шундый шартлаучан кискенлек бар иде.—Өстенә элгәнең дә ярыйсы, башкалача...

Бу «элгәнең» сүзе Рушанның күңеленә тиеп узды—«1905 ел» урамында яшәүче кыз бер генә дә алай әйтмәс иде.

—Поселокныкылардан бик азлар гына чын шәһәр кешесе булып китә. Рухы, асылы белән, дим,—әле һаман да Рушанны тартынусыз-нисез әйләндергәләп, күңеленә үтеп керердәй карашлары белән бораулый-бораулый, ул сүзен дәвам итте.—Син моны булдыргансың бугай. Славка Афанасьевны хәтерлисеңме? Ну, теге, биегәндә уйнаткычтагы пластинка-ларны алыштырып торыр өчен сез яңа ел кичәнә чакырган егетне әйтәм. Ул, баксаң, «Караван» көен ярата икән, гел дә шул Эллингтонны әйләндереп торган иде...

—Әйе, хәтерлим,—дип елмайды Рушан, ул кичтә, чынлап та, шундый мәзәгрәк хәл булган иде шул.

—Менә шул Славик, мәсәлән, шәһәр кешесе була алмаган һәм була да алмас, мөгаен. Юкса, синең шикелле үк, башкалада—Алма-Атада яши. Мин аны узган айда күрдем, әти-әниләре янына кайткан иде. Корсак үстергән, юньләп кырынмаган да, бик каты эчә бугай. Өстендә ниндидер «Мосшвейпром» костюмы капчыктай эленеп тора... Ә син импорт кигәнсең, француз парфюмериясе исләре дә бар үзеңдә, бер сүз белән—джентльмен...

Карап-өйрәнеп бетергәч, ул Рушанны култыклап алды һәм кинәт, янә көтелмәстән әйтеп ташлады:

—Ярар, синеңчә булсын, Бобличихалар йорты яныннан әйләндереп алып киләм үзеңне. Бәлки әле хужабикә дә килеп чыкмасмы шунда—алар соң ята. Мине синең белән күреп, көнләшсен әле.

—Ә нигә көнләшсен?—дип аптырап сорады Рушан.

—Ә шуңа, без синең белән шундый яшь, төз-зифа буйлылар, көязләр, ә Эммочка, беләсең килсә, кадерлем, инде илле сигезенче размерга сикерде,

эчке күлмәкләрен дә ательеда тектерә. Билгеле, Парижда түгел инде...—алар икәүләп ихластан көлеп җибәрделәр.

Әйе, Валя әле дәртен-ялкынын сүндермәгән, һаман да—ут...

Алар кирпеч заводы янына кадәр бардылар, Эмманың йорты яныннан да үттеләр: ишегаллары дөм караңгы, йомшак җил генә баудагы кипшенгән керләрне шыштырдата иде бугай. Ерак булмаган тимер юлдан дөбердәп состав үтеп бара иде, якындагы йортларның тәрәзә пыялалары зеңли башлады. Валя анда да үзенең элекке дустын мыскыллап алырга онытмады:

—Бу безнең кадерле Эммочкабыз йокысында күрсенеп, икенче ягына әйләнеп ятты...—диде.

Лымарьлар йорты янына да барып җиттеләр, анда хәзер башка кешеләр тора икән, ә Гена әти-әниләре белән Актүбәгә күченеп киткән, ниндидер автохуҗалыкта эшли икән. Янә дә теге, шәмнәр яндырып, Дюк Эллингтон, Элвис Пресли һәм хәзер инде бөтенләй онытылып беткән Джонни Холлидейларны җырлатып-уйнатып, төн уртасында фал ачып, күрәзәлек итеп үткәргән яңа ел кичен исләренә төшерделәр. Яшькелт күзле Томочка Солохо бик оста күрәзәче икән, һәркемгә ерак юллар, буш мәшәкатьләр һәм иртәләгән сагыш юрады ул... Юраганы юш килә бугай шул...

Алар шулай култыклашып йокылы поселок урамыннан атладылар да атладылар, тынып калган төнге Мартук өстенә йолдызлы биек күктән үтә күренмәле нур-балкыш коела, хәтта этләр дә өрми—ни хуҗасызлары, ни һәр биек коймa артында чылбырда булганнары, дигәндәй—тирә-юньдә тынлык хөкем сөрә иде. Бәлки, табигатьнең шул төнге тынлыгыннан сихерләнепме, Валя, ни өчендер пышылдап, әмма тавышындагы гадәти шаянлык белән кинәт әйтеп куйды:

—Безнең очрашуны билгеләп үтәргә вакыт җитте дип уйлыйм...—ул Рушанны кысыбрак култыклап, адымнарын тизләтергә мәҗбүр итте.

Капкалары янына кайтып җиткәч, Валя аны бераз артистларча кыланып ачып җибәрде дә, үзе янбакчага кереп югалды һәм аннан сабына кызыл бантик бәйләнгән гитара күтәреп килеп чыкты.

Шулай туры килгәнме, Совет урамында таза-нык хуҗалыклы халык яши, йортларны да «немец манерында»—төрле архитектура бизәкләр белән житкезәләр иде. Валяның әтисе исә көчле-чыдам кеше—юл төзү идарәсендә шофер булып эшли, кирпечтер-цементтыр ишеләрне җиңел таба, шунлыктан йорт-җире, каралты-курасы гөлт итеп тора. Калай түбәле, биек болдырлы төп йорттан тыш, иркен ишегалдында җәйге кухнялары да бар—анысының чирәп түбәсе сыек яшелгә буялган, тәрәзәсез, киң-иркен верандасы ачык, ул җилләр иркендә.

Валя Рушанны шул җәйге йортка алып керде. Төрле җирләре зәңгәр төсләрнең әле куерагына, әле сыеграгына буялган ачык веранда һәр хуҗалыкта була торган яшелчә бакчасы ягына карап тора иде. Ләкин Совет урамындагы яшелчә бакчалары шуның белән аерыла, алар биек ярлы, тирән чокырерымга барып терәлә, ул ерым, агач-куаклар үсеп, күптән инде кыргый бер бакчага әверелгән, кайберәүләр яр буйларына җимеш агачлары да утыртканнар. Домаровларның да шундый бакчасы бар иде...

Веранда дивары буенда тәбәнәк журнал өстәле, аның як-ягына тирән генә ике кәнәфи куелган, аларны, күрәсең, төп йорттан алып чыкканнардыр. Өстәл өстенә, аш өстәле рәвешен китереп, шикәрдәй ак ашъяулык җәелгән, шуңа күрәме, уртага куелган бәллүр вазадагы вак роза чәчәкләре аеруча җете күренәләр. Матур, зәвыклы итеп табын корылган, минераль судан тыш яхшы коньяк шешәсе дә кукраеп утыра.

Кунакны утырткач, Валя гитарасын бер читкә куеп, өстәлгә кабымлыклар, җиләк-җимеш, үлән-сәлән тезә башлады. Бу эшне ул ничектер бик җиңел, килешле-матур башкара, Рушан әле: «Мөгаен, уңган хуҗабикә булыр бу»,—дип уйлап та алды. Ә безнең заманда андый хатын-кызлар шактый сирәк очрый хәзер. Өстәлгә куясыларын куеп бетергәч, алда торган сугыш кырын караган генералдай, Валя аны янә бер тапкыр күздән кичерде һәм... утны сүндерде. Аннан соң, веранданың ишеге тирәсендәге суыткыч

янында шырпы сызылды, хуҗабикә, өч жепле шәм-дәлнең шәмнәренә ут элеп, өстәлгә китереп утыртты. Кунагы янына килеп, һаман да шулай артистларча каты пышылдап:

—Курыктынмы?—дип сорады, аннары иелеп, тирә-якка таныш түгел хушбуй исе бөркеп, Рушанны үбеп алды.

Шуннан шома гына юлдан истәлекләр кичәсе башланып китте. «Ә исендәме?» сүзе, пинг-понг шары кебек, бер кәнәфидән икенчесенә очып кына торды. Кайбер мизгелләрдә Рушан элекке Валяны—сокланучан, тиз ышанучан, Балерина кушаматы алган самими кыз баланы таныган да кебек булды. Әмма төтәсләп, эри-эри янган шәмнәрнең карангылы-яктылы күләгәсендә нәфис ак күлмәкле, кырыс холыклы, таныш түгел ханым утыра һәм ул бик оста гына итеп Рушан турында һаман да күбрәкне белмәкче була: үткән тормышы нинди, алдагы планнары?.. Ләкин Рушан да төшеп калганнардан түгел, маңгайга бәреп бирелгән сораулардан матур гына тайчанып, шәрекъчә сырлап-сырлап, озын-озаклап җавап бирә, нәтиҗәдә үзе турында сөйли дә кебек, сөйләми дә кебек килеп чыга. Ә ханымның нәкъ менә аның турында беләсе килә...

Андый озын-озак сүз боткасы куертырга күнекмәгән, күрәсең, ниһаять, ханым түзмәде, рюмкаларга коньяк койды да, шаярткандай итеп һәм бер үк вакытта үпкәләгәндәй дә кыланып:

—Мин аңа бар булганымны ачып салам, стриптиз биегәннән дә артык чишендерәм үземне, ә ул боргаланып утыра!—диде. Аннары тезә башлады:—Синең ихласлыгыңны Шәрекъ шулай кырып-көйдереп бетердеме? Ә мин бит синең хакта кайбер нәрсәләрне беләм... Күз алдына китер әле, мин хәтта син фәрештә күреп йөргән кызның өендә дә булдым. Минем хатын-кызларча аңлыйсым килә, ни өчен синең Томочка Давыдычева белән мөнәсәбәтләрең барып чыкмады? Син бит аны өзелеп сөйгән идең шикелле. Ну, минем белән булганы аңлашыла, мин үзем дә нәрсә теләгәнемне, кемне теләгәнемне белми идем, әгәр дә дөресен әйтсәк, мин сезне—мартуклыларны бер тиенгә дә санамый идем, минем арттан бер син генә чапмадың бит. Үз-үземә артык ышанганмын, тәкәббер һәм юләр булганмын, сездән мән чыккан, кайсыгызны алып карасаң да, үз юлыгызны тапкансыз, кеше булгансың.

—Син Тамараны кайдан беләсең? Ничек син аның өенә барып керә алдың?—Рушан бу сорауларны тонык тавыш белән, дулкынлануын яшерә алмыйча бирде.

—Ниһаять, жан керде үзенә, кызыксына!—дип кычкырып җибәрде Валя һәм аңа таба рюмканы этте.

Эчеп куйгач, сорады:

—Дөресен генә әйт әле, мине алдаша дип уйладыңмы? Юкка, синең пассияннең—сөйгәненнең, дим,—исеме беркемгә дә сер түгел иде бит. Синең белән бер үк вакытта шәһәрдә Мартук кызлары байтак укый иде—кооператив техникумында, культура-агарту училищесында, медучили-щеда һәм мединститутта. Сонлап булса да, үзенә комплимент әйтим әле: ул кызлар синең белән горурлана, син анда шактый танылган, бокс буенча чемпион, шәһәрнең күзгә күренердәй егетләре белән генә аралаша-сың, дип сөйлиләр иде. Бервакыт Валя Белозерова белән Тома Ярошенко паркта хәтта син булып кыланып та күрсәттеләр. Дүртенче курста укыган чагында кичләрен Бродвейга чыкканыңны. Пөхтә үтүкләнгән киемнәрдән, көзгедәй ялтыратылган туфлиләрдән, кыл уртадан ачып, майлап-шомартып таралган чәчле син, имеш, үзең еш кына була торган кырык бишенче мәктәп яныннан башлап дөмбер-дөмбер джаз уйнаган паркка кадәр гел унга-сулга баш иеп, сәлам биреп кенә киләсең икән—Бродвейда үз кеше булгансың инде. «Ә без,—дип сөйли иде Белозериха,—Карл Либкнехт урамындагы берәр тын почмактан карап-күзәтеп торабыз, дус кызлары-бызга, горурланып: «Күз камаштырырлык елмаеп килүче ул чибәр егет безнең Мартукныкы, якташыбыз!»—дибез. Әмма безгә бик ышанып бетмиләр иде...» Менә шулай дип сөйли иде ул.

—Әйе, мин сине бераз шыттырасың, арттырып җибәрәсен, дип уйлаган идем. Анысы хатын-кызга хас нәрсә. Безнең Шәрекътә: «Матурлык белән мәкер янәшә йөри»,—диләр.—Рушан аны үпкәләтмәскә тырышып, шаяртыбрак шулай җавап бирде. Аның холыксызлыгын белә, шуңа күрә бу кичнең ямен җибәрәсе килми иде.

—Ну, бу юлы синең ирләрчә күзәтүчәнлегең сынатты. Ярар, шулай булсын, Томочканның өенә ничек барып эләккәнемне сөйләп бирим. Күзләреннән күреп торам, юкса син гомерен буе шул серне уйлап газапланачаксың...

Валя, капылт кына кузгалып, чәчәкле ваза артыннан сигарет пачкасы алды һәм, гаепләмә инде, дигәндәй, кулларын як-якка җәеп, авызына сигарет алды һәм тартып җибәрде.

—Беренче ике курсында син һәр шимбә саен диярлек кайтып йөрдең, мәктәпкә кичәләргә яки клубка биюләргә килә идең һәм без еш очраша идек. Ул чакларда мин сиңа ошый идем, дип уйлыйм, әгәр дә синең хисләреңә җавап биргән булсам, син ул тимерьюлчы кызын онытыр да идең. Ләкин мин теләсә кем белән теләсә ничек чытлыкланып йөрдем, нәрсә теләгәнемне үзем дә белмәдем. Ә тегәлрәге, мин көттем. Аны күреп, һәркем акылдан шашарлык булыр, ә ул бары тик мине генә сөяр, дип өмет иттем.

Әмма өченче курста сине инде поездда бушлай йөрү дә кызыктырмый, кайтуларың сирәкләнгәннән-сирәкләнә бара иде. Дусларың сине йә ярышларда, йә команда җыенында, йә бик күп сызым эшле проект белән утыра, дип сөйлиләр иде. Ләкин мин инде сине шәһәрдә нәрсәдер башка нәрсә тоткарлап торганын сизенә килдем. Һәм тиздән, бөтенләй очраклы рәвештә, синең ни өчен кайтмый башлавынның сәбәбен белдем. Тормышта нәрсәләр генә булмый...

Күп кенә мартуклыларныкы шикелле, Актүбәдә безнең дә ерак туганнарыбыз бар. Шулай бервакыт әтинең туган көненә һәм яңа йортның салынып бетүе хөрмәтенә кунаклар җыйдык. Һәм, күз алдына китер әле, шәһәрдән әти-әниләре белән ерак кыз туганым Светлана Костылева да килде. Без яшьтәшләр, билгеле инде, тегесен-монысын сөйләшергә тотындык, малайларны да онытмадык. Менә ул әйтә: «Беләсеңме, безнең мәктәп кичәләренә бер егет килеп йөри башлады,—ди.—Ул үзе студент, сезнең Мартукныкы икән. Шундый сөйкемле, кара күзле, Рушан исемле. Ул инде танылган кеше икән, бокс буенча чемпион, хәтта ярышларга Мәскәүгә дә барып кайткан... Син аны белмисеңме?»—ди.

Һушсыз-тынсыз калдым, әмма сиздермәскә тырыштым, җилкәлә-ремне сикерткән булдым да: «Мартукта татар егетләре ярты поселок, барысы да сугыш чукмары—чемпионлыкка әзер кандидатлар... Бик кирәк булса, белешә алам...»—дидем. Ә Светлана тагын сөйли: шул Рушан аның сыйныфташы Томочка Давыдычевага үлеп гашыйк икән, шуны күрер өчен мәктәптәге бер кичәне калдырмый йөри икән. «Болай да ул аны көн саен күреп тора, чөнки мәктәп белән техникум янәшә—койма аша гына. Без физкультурага аларның спортзалына йөрибез»,—ди. Менә шунда мин синең нинди ярышларың, нинди проектларың булганлыгын аңладым...

Бәлки, шул мәхәббәтең сине бер зур бәладән коткарып калгандыр да әле. Син үзең аны белмисеңдер дә. Язын, мин тугызынчы сыйныфны түгәрәкләгәндә, Мартукка бер дингезче офицер кайтып төште. Шул клубка туган-тумачалары белән бераз кызмача килгән бит. Шунда болар Татар бистәсеннән кем беләндер бәйләнешеп китәләр, Шурик Сәйфуллин белән бугай... Сүз уңаеннан, төрмәдә утырып чыккач, армиядә хезмәт иткәндә бик серле рәвештә үлеп калды ул.

—Шурик Сәйфуллин үлгәнме?—дип әсәрләнеп сорады Рушан. Ул бу хакта ишетмәгән иде әле.

—Әйе, ул юк инде, поминкасында үзем булдым. Бик кыю, тәвәккәл егет иде... Менә шул, сугышып китәләр болар. Офицер үзенең матур кортигын суырып чыгара, шуның белән яңа да. Бу вакыйга эзсез калмый, синең

дусларын үзләренең беренче срокларын алалар, дөрес, күп түгел—кемгә бер ел, кемгә ике елны чәпиләр. Ләкин ярты елдан, ниндидер амнистиягә эләгеп, бөтенесе дә әйләнеп кайттылар—Толик Чипигин да, Витя Будко да... Әгәр дә ул кичне өйдә булган булсаң, син дә дусларың белән бергә китеп барыр идең. Мавыгып, читкәрәк кереп киттем шикелле, әмма сиңа моны белеп тору комачауламас...

Рушан ансыздан кулындагы буш рюмканы әйләндергәләп утыра, рюмкада шәм яктысының нечкә нурлары чагыла иде.

—Үзеңең туган көнең үтеп, бер айданмы, әти шәһәргә машина белән мебель алып кайтырга җыенды, билгеле инде, мин дә барырга теләдем. Башымда күптән бер уй өлгереп җиткән иде: син гашыйк булган ул таныш түгел кызны күрергә тиешмен! Светка Костылева килеп сөйләп киткәннән бирле, ай буена үземә урын таба алмый йөрдем, хәтта ачуымнан бер тапкыр елап та алдым: синең йөрәгеңне яуларга ничек батырчылык иткән ул?! Мин инде шул чакта ук сине үземнеке генә дип хисаплыйм һәм сине ничек теләсәм, шулай боргалап йөртә алам, бер бармак ишарәмнән дә син минем өчен утка-суга керергә әзер, дип ышана идем... Гаҗәпләнмә, бу—һәр хатын-кызга хас һәм киң таралган хаталану. Мөгаен, синең Тамараң да шулай булгандыр...

Бакыр шәмдәлнең уртадагы шәме кинәт кенә төтенли башлады һәм Валентина аны сүндереп куярга мәҗбүр булды. Аның коньяктан һәм истәлекләрдән кайнарланган битен Рушан хәзер күрә алмый иде.

...—Мин үземнең бөтен зирәклегемне эшкә җиктем,—дип сүзен дәвам итте Валя.—Син гашыйк булган ул кыз янына икәү барырга Светканы тәки күндердем. Алар, ни әйтсәң дә, сыйныфташлар бит. Билгеле инде, үземнең синең белән кызыксынганымны әйтмәдем, сине белгәнемне генә әйтергә туры килде, югса Светка ышанмас иде.

Ул Мәскәү бистәсенә борынгы матур вокзал аша барганымны хәтерлим. Юллар аркылы салынган, тирбәлеп, дангыр-доңгыр килеп торган асылмалы күпердән чыктык, аста тиз йөрешле Алма-Ата поезды тора һәм тирә-якка шул кадәр тәмле алма—апорт алмасы исе таралган иде. Минем бу шәһәргә беренче килүем, шунадырмы, аның ул вакытларда Мартуктан бик аз аерылып торганын абайлап, гаҗәпләнгән идем. Хәтта ул кызларның йорты да—«1905 ел» урамында бугай—нәрсәсе беләндер безнең йортка охшаш иде шикелле. Шул ук ян бакча, сиреньнәр, яшелчә бакчасы, шыгырдап торган дүрт басмалы биек болдыр, пыяла тәрәзәле веранда... Бәхеткә, кыз өйдә булып чыкты, әмма безне бик якты йөз белән каршыламады. Бигрәк тә, минем Мартуктан икәнемне белгәч... Ләкин аны-моны сиздермәде, сине дә искә алмады. Хатын-кыз сизгерлеге белән, интуитив рәвештә, минем үзенә көндәш икәнлегемне чамалагандыр, дип уйлыйм.

Миңа ул бер карауда ук ошады, бәрхеттәй коңгырт-кара зур күзләр, искиткеч матур керфекләр, ул аларны шундый сокланырлык итеп, әкрен генә әле түбән төшерә, әле күтәрә, күрәсең, егетләрне һуштан яздырырлык карашының көчен сизенә иде инде. Мин тагын шунысын да аңлап алдым—ул синнән күпкә өлкәнрәк егетләрнең дә күзен кыздырырга тиеш иде. Аңарда яшүсмерләргә хас килешсез-килбәтсез хәрәкәтләр юк, битендә күп кызлар газапланып кичерә торган бетчәләре дә күренми, үзен ышанычлы тота.—Валя көрсенеп куйды.—... Әйе, шома нәфис бит алмалары, матур сызылып киткән кара кашлары, өске иреннән бераз югарырак, сул якта сөйкемле миңе... Бу аңа сокланырлык аерым бер мөлаемлык бирә иде. Мин шунда ук ачуымнан ул миннән зур сөял булып үсүен теләп куйдым. Бик матур уелган авыз, дәртле-сизгер иреннәр, Мерилин Монроныкы шикелле, һәркемне көнләштерерлек тигез ак тешләре... Дөрес, алгы тешләренең берсе әз генә аерылыбрак тора иде шикелле. Аңысы инде мин бик тырышып берәр кимчелеген эзләгәнгә күрә генә күренгәндер. Мин синең аңа бер карауда ук татарларга хас кайнар дәрт белән гашыйк булганлыгыңны аңладым, күргә ук артыннан ияреп киткәнсеңдер...

Аннары мин шунысын да аңладым: тышкы чибәрлек кенә җитми,

анарда күп кенә хатын-кызларда булмаган сыйфатлар бар, ул да булса—үзенә генә хас үзенчәлекле, бердәнберлеген тою хисе. Анарда Актүбә кебек кечкенә шәһәрләрдә үскән башка кызларга хас авылча провинциальлекнең исе дә юк. Ул үзенең ирләрне исертерлек соклангыч гүзәллеген тоя, аның тавышы да һәркемне дулкынландырырлык ягымлы иде. Ул әле мәктәп укучысы гына булса да, тормышка үз карашлары булган хатын-кыз булып өлгереп җиткән, ул, Светлана белән миңа яшьтәш кыз, акылы белән бездән күп өлкәнрәк, сыйныфташларын гына түгел, вакытны да узып, алга китебрәк яши шикелле... Менә ул рояль янына барып утырды, инде бер минуттан безнең барлыгыбызны да онытып, үзе өчен генә уйный башлады.

Әгәр дә башыма көтелмәгән бер уй килеп, җиңеллек китермәгән булса, мин бөтенләй күңелсезләнер идем. Кинәт шуны аңлап алдым: син бу гүзәл һәм тәкәббер кызның йөрәген һичкайчан да яулап ала алмаячаксың, чөнки ул да табигате белән миңа тартым, кан кардәшләрдәй, без бер үк токымнан, ул да үзенең Искиткеч Принцын эзли, шуны көтә. Ул бары тик мине генә сөяр, дип өмет итә.

Без дуслашып диярлек аерылыштык...

Дөнья тар, кайвакытларда Куйбышевтан кайтканда мин аны поездда очрата идем—ул Оренбургта укыган чагында. Иске танышлардай, озаклап сөйләшәбез, ләчтит сатабыз. Шунысы сәер, ни ул, ни мин бер мәртәбә дә синең хакта сүз кузгатып карарга тырышмадык. Юкса, өчебезне ниндидер уртак бер язмыш бәйләп торганын ул да сизенә иде, дип уйлыйм. Беренче курсларда укыганда, мин аны бер-ике тапкыр чибәр генә, озын-төз буйлы, алтынсу-салам төсендәге сирәк очрый торган чәчле бер егетнең озатканын да күргәләдем. Зәңгәр күзле, кызларныкыдай озын, куе керфекле ул егеткә кысан вагон эчендә дә кызлар ирексездән борылып карыйлар иде. Мөгаен, күпләр әнә шундый Принц турында хыялланганнардыр... Мин алар арасында роман булганлыгын аңладым, әмма үлеп гашыйк булган бу чибәр егетнең дә аның йөрәген яулап ала алмаячагын күңелем белән тойдым. Аннары мин Тамараны бер-ике елга күздән югалтып тордым, шуннан соң гына поездда янадан очраттым. «Теге, зәңгәр күзле чибәр егетең кайда?»—дип сорагач, ул: «Аны армиягә алдылар, Черновцы шәһәре тирәсендә хезмәт итә»,—дип җавап бирде. Бу сүзләрнең ничек әйтелешеннән мин аның тагын бер егетнең тормышын ватканын аңладым...

—Ул егет Ленечка иде, минем танышым. Чынлап та, чибәр егет... Син дөрес әйтәсең, ул аның тормышын бозды,—дип тоныкк кына әйтеп куйды Рушан һәм кинәт:—Әйдә, мәхәббәттән уңмаган барлык бәхетсезләр өчен дә эчик әле!—дигән тәкъдим ясады.

Валя риза иде, ләкин кистереп өстәде:

—Димәк, синең белән минем өчен дә...

Алар сүзсез генә эчеп куйдылар.

Утырулары җеназаны хәтерләтә башлады, чөнки алар үлгән, һәлак булган дуслары—Шурик Сәйфуллин, Володя Колосов, Толик Чипигин рухына да коньяк уртладылар.

Валентина шуны сизенде. Кулына гитарасын алып:

—Ә хәзер мин синең өчен генә уйнап-җырлап бирим әле,—диде.—Мөгаен, Тамара кайчакларда рояльдә этюдлар уйнап та иркәләгәндер әле сине.—Аннары сискәндерерлек итеп, кинәт кенә җырлап җибәрде, әйтерсең, фонограмма уйната башлады. Җыры ниндидер бик җилле, кабак җыры шикелле тупас иде. Гитара сабындагы кызыл бант, җилдә җилфердәгәндәй, бер өскә-бер аска сикергәли башлады.

Рушанның әллә кәефе шундый булды, әллә Валентина әйбәт уйнап, матур җырлый идеме, әмма аңа ошады шикелле, шуны сизенгәндәй, ханым кызганнан-кыза барды.

Менә ул көтелмәгән рәвештә, башта гитарада озак кына кереш көй уйнап, романслар җырларга тотынды. Гитарада яхшы уйный белүе күренеп тора иде. Бераздан ул, җырлый торган романсын ярты сүздә өзеп:

—Әйдә, бакчага төшик, җырга иркенлек кирәк,—диде.

Яндырылган кызыл кирпеч тезеп ясалган, яшелчә бакчасы аша бормалана-бормалана ерымга таба сузылган тар сукмактан төштеләр. Төнге бакча аларны сизелерлек салкынча һава белән каршы алды. Ул шактый зур икән, хәтта ай яктысында да яхшы уйланылган, тәрбияле бакча икәне күренә иде. Бакчаны күрсәтеп бетергәч, Валя Рушанны, кулыннан житәкләп, караңгы аллея буйлап беседкага таба алып китте. Анда да романсларын дәвам итмәкче иде дә, нишләптер, бер сәбәпсез тавышы бозылды һәм ул гитарасын бер читкә куйды. Рушан янына якынрак елышып, гадәтенчә, кинәт кенә дулкынланган тавыш белән:

—Кич буе аңлый алмыйм, синдә нинди үзгәрешләр бар соң? Шул миңа тынгы бирми...—диде.

Рушан шаяртып котылырга тырышты. «Акыллыландым, өлкәнәйдем»,—кебегрәк сүзләр тезде. Әмма Валя һаман да тынмады, нәрсәнедер үҗәтләнеп аңларга, нининдер үзе өчен бик мөһим бер әйберне аңлатырга тырышты. Һәм, капылт кына Рушанның кулыннан тотып, йөзен ана якын ук китерде:

—Исемә төшердем... таптым...—Аның тавышы калтырый иде.—Син элек бик матур итеп көлә идең, ихластан, чын күңелдән... Мин синең ул көлүеңне бик ярата идем. Аны хәтта Татар бистәсеннән, станциядән, Вуккертлар ишегалдыннан да ишетеп ала идем... Син шундый итеп мавыктыргыч көлә идең... Мин сине шул көлүеңнән теләсә кайдан эзләп таба идем, син миннән беркайда да качып котыла алмый идең... Котыла алмавың да көләргә яратуыңнан иде... Ә хәзер, Рушан сөеклем, син ул көлүеңне югалткансың һәм мин сине эзләп таба алмыйм. Нинди коточкыч хәл...—ул, башын Рушанның күкрәгенә салып, үкси-үкси, кычкырып елый башлады.

Бөтен тәнен калтыраткан үксүләре аша: «Син көлүеңне югалткансың... Ничек яшәрсең көлүсез?.. Коточкыч... коточкыч...»—дигән сүзләре генә ишетелеп тора иде. Рушан башта югалыбрак калды, аннары үзен кулга алып, Валяны бик озак тынычландырырга тырышты, әмма ханым сулкылдавыннан тыела алмый, елап шешенгән, яклаучысыз сабый балаларча күңелне йомшатырлык йөзен күтәреп карый да, янә сулкылдарга керешә иде. Рушан аерым бер наз белән аның күзләрен, муенын, чәчләрен үбә, әмма ул һаман тынычлана алмый иде. Көтмәгәндә ул бөтен тәне белән тыелгысыз калтырана-дерелди башлады, ерымда шактый салкынча һәм дымлы иде—бәлки, туңгандыр дип, күп уйлап тормастан, Рушан аны күтәреп алды да, өскә—җәйге йортка алып менеп китте. Анда, караңгы верандада эреп аккан шәмнәрнең төпчекләре дә янып бетеп килә иде.

Валя өстәл әзерләп йөргәндә ярым ачык калган ишектән бер бүлмәгә кереп, кәгазь салфеткалар алып чыккан иде һәм: «Җәйләрен мин шунда яшим»,—дип әйтеп куйган иде. Рушан аны шул бүлмәгә күтәреп керде. Керә-керешкә ут яндырырга теләгән иде, Валя, көйсезләнеп: «Кирәкми... Елап шешенгән йөземне күрүеңне теләмим...»—диде.

Егетнең күзләре караңгыга тиз ияләште һәм ул дивар буендагы җәеп куелган урын-җирне абайлап алды—Валяны шунда илтеп салды. Туфлиләрен дә салдырып алгач, крахмалланган салкынча чиста җәймәле җылы одеалны өстенә ябып, янына утырды. Һаман саен тропик күбәләккә охшаш муар бантка тәртелә-тәртелә, Валяның чәчләреннән сыйпый-иркәли башлады.

Валя аны кинәт кенә үзенә тартып, кайнар пышылдады:

—Рушан, бәгырем, мин сине бүген беркая да җибәрмим! Син минеке булырсың...—ул, урыныннан күтәрелә төшеп, егетнең иреннәреннән суырып үбеп алды.

Рушан анарда янә үзе аңлап бетерә алмаган нинидер истерика башланадыр, ахрысы, дип уйлады. Чөнки Валя ана шундый көтелмәгән женси дәрт-теләк, тыелгысыз наз белән бирелде ки, әйтерсең лә, үткән тормышындагы бөтен уңышсызлыклары, күңеле кайтулары өчен барысын берьюлы алып калырга тели һәм иркәләү-назлауларны алдагы кара көннәренә дә җыеп калырга тырыша кебек иде...

Рушанның моңа кадәр тойган-кичергәннәре, татыганнарының берсе дә бу төндә Валя бүләк иткән рәхәтлек белән тиңләшә алмый иде. Валя, саташкандай итеп, бертуктаусыз пышылдый: «Рушан, бәгырем, мин шундый бәхетле... Мин сине таптым... Син минеке... Без бергә... бергә... бергә...» Аннары сүзләрнең күпчелеге сизелмичә йотыла һәм ул, Рушанны үбә-үбә, бер генә сүзне кабатлый: «Минеке... минеке... минеке...» Рушан да аңа шундый ук иркәләү-назлау белән җавап бирә, аның дәртен сүндерүдән куркып, кысып кочаклый иде. Әмма кинәт кенә ул Валяның гүя ниндидер акыл томаланырлык дәрәҗәдәге трансга булуын шәйләде, ханым янә үз уй-хисләренә бирелгән, аның үзен дә, теләкләрен дә тоймый шикелле иде...

Йа Хода, тормыш нинди мәрхәмәтсез! Әгәр дә элегрәк, яшьлегендә Валентина аңа шушы татлы сүзләренең, кайнар куеннарының, сөйкемле карашларының бер мыскылын гына бирсә дә—Рушан нинди бәхетле булыр иде, ул аны фәрештәсе-алиһәсе итеп, кулларында гына йөртер иде бит! Шул рәнҗештән, шул бәхетнең үзен читләп үтүен тоюдан, инде бернәрсәне дә кайтарып алып булмаслыгын аңлаудан күңеле тулып, күз яшьләрен яшереп тә тормыйча, Рушан елап җибәрде. Әмма үз теләге-дәрте белән мавыккан Валя аның елаганын сизмәде дә...

Рушан китеп барганда, Валентина абайламый калган, әмма Рушан күңеленә озакка уелып калган тагын тагын бер нәни генә хәл булып алды.

Җәйге кухня белән төп йорт арасында, калиткага бара торган сукмак өстендә кечкенә янгырдан калган кечкенә күлләвек җыелган, кергәндә алар аны әйләнеп үткәннәр иде, ә хәзер, саубуллашканда, ирексездән шуның янында тукталдылар. Валяның Рушанны иртәнгә кадәр җибәрәсе килми иде һәм ул, адым саен кочаклап, ниндидер дулкынландыргыч сүзләр бытылдый иде. Биектән тулы ай яктырта, бер-берсенә иркәләнеп-назланып сыланган икәү әлеге күлләвектә көзгедәгей чагылып күренә. Рушан шуны күрсәтмәкче генә булган иде, Валя кинәт кенә шул суга китереп басты да, су-көзге чәлпәрәмә килеп ватылды, сурәт юкка чыкты. Рушан моны начарга юрады...

Капка төбендә соңгы кат үбешкәч, Валя ничектер ятимсенеп, кызгандырып сорады:

—Бүген кич килерсеңме?—элек Рушан, очрашу сорап, аңа шулай ялвара иде.

Рушан аның үбешү-кочышу араларында бер якка кыйшайган муар бантын төзәтеп куйды, иркәләүчән шат тавыш белән:

—Әлбәттә,—диде.—Мин бу очрашуыбыздан бик бәхетле.

Бу минутта ул хәйлә-мәкерсез иде, бу таныш та, таныш та түгел ак күлмәкле ханымга карата күңелендә, мәктәп елларындагы ягымлы хис барын тойды ул...

## XIII

Валя белән булган кичәге төн һәм бүген буласы очрашу турындагы уйлар иртәдән кичкә кадәр Рушанның башыннан чыкмады. Җәйге озын көн дәвамында ниләр генә уйлап бетермәде ул. Үзенең бөтен үткән тормышын төбенә хәтле актарып чыкты. Кайсыдыр мизгелләрдә ул вакытны ашыктыра, тизрәк кич житсен иде, дип тели, Валяның кайнар сүзләрен яңадан ишетергә алгысый, аның иркә кулларының үз тәненә кагылганын тоя, дәртле пышылдавын ишетә: «Минеке... минеке... минеке...»

Әле балалар гына килеш бер-берсенә тартылган бу ике җанны, бәлки, язмыш шулай яңадан бергә кушкандыр, өмет өзелү, югалтуларның ачысын төбенә кадәр эчеп, хәзер икесе дә бәхет һәм рәхәтлек тапсын, дигәндер.

Күңеле йомшарып тәэсирләнгән Рушанның Валяга берәр куаныч ясыйсы килде, поселок универмагына барып, бер флакон француз хушбуе сатып алды. Алганда «Клима», «Фиджи» һәм «Кара магия» дигән

хушбуйларның кайсысын алырга белмичә, озак сайланды, сатучы кыз аңа «Шанель № 5»не тәкъдим итте.

Фантастика! Зур шәһәрдә аны көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың, ә биредә—кемгә кирәк ул? Әле хәзер дә, бүләкләр турында уйлый башласа, кулында беренче һәм соңгы мәртәбә тоткан шул «Шанель № 5»нең тыйнак кына ак тартмасы күз алдына килә.

Гастроном кибетенә дә сугылды ул, «Ахтамар» дигән затлы әрмән коньягы сорагач, аны күреп белмәгән яшь кенә сатучы кыз, елмаеп, Мартукта мондый кыйммәтле коньякны бик сирәкләр генә алганын, алай да бүген Рушаннан алда гына инглиз теле укытучысының нәкъ шундыйны алып киткәнен әйтеп куйды. Моны Рушан яхшыга юрады һәм кичәге яңгырдан калган күлләвек көзгесендә ватылган сурәт турында онытты.

Билгеләнгән сәгатьтә, бүләкләрен күтәреп, ул Совет урамына ашыкты. Валя аны янә янбакчаларында гитара чиртеп көтеп утыра иде. Ләкин бүген ул җете кызыл күлмәк кигән, башындагы кичәге ялтыравык кара муар бантын да кызылга алыштырган.

Рушан бүләкләрен биргәч, ул бик куанды, аның муенына ташланып, туктаусыз үбәргә тотынды. Ул бүген ничектер сәер әсәрләнгән иде. Рушан, ике арадагы мөнәсәбәтләрдә, бәлки, ниндидер үзгәреш буласын сизенеп, шул дулкынланудан Валя ул килгәнче эчеп куйган, ахры, дип тә уйлады. Ә нигә? Әгәр дә аңа—ир кешегә шундый бәхетле үзгәреш турындагы уй башына килә икән, хатын-кызга, мөгаен, киләдер дә киләдер, Рушанның үзеннән нинди канатланып-очынып кайтып киткәнен күреп калды бит ул.

Аның алдан эчеп куюы турында шаяртмакчы булып, Рушан үзе аңа иелде дә иреннәреннән үпте, әмма шәраб-фәлән исе сизмәде, гаҗәпләнә калды. Ләкин соңыннан ул аның артык әсәрләнүен, күзләренең сәер елтыравын дулкынланудандыр, дип уйлады.

Алар шулай кочышкан килеш, инде кибеп өлгергән күлләвек янынннан узып, җәйге йортка барып керделәр. Анда инде өстәл әзерләнгән иде, алар кара-каршы кәнәфигә утыруга, өч яна шәм дә шунда ук кабынды.

Кичәге сөешү-яратышудан соң алар бер кавым үзләрен уңайсызрак тойдылар, Валя ничектер борчулы күренә—ни өчен икәнен аңлата алмаса да, Рушан моны сизенә иде. Ханым кичәге кебек үк ягымлы да, шундый ук рәхәт дулкынландыргыч сүзләр дә сөйли, әмма Рушанда ниндидер сәер тойгы—алар икәүләп һаман да каядыр упкынга очалар, ычкыналар шикелле. Бу авыр уй-хисләрдән үзен дә, аны да арындырырга теләп, Рушан Валяның җырлавын үтенде.

Валя, аның «җыр тынычландырыр» дигән уен белгән шикелле, гитарасын теләп кулына алды, ләкин аның борчылулы киеренке халәте җырларында да чагылды—ул, ни өчендер, тоткыннарның төрмәдә генә җырлый торган җырларыннан башлады.

Рушан шунда ук Рәшит абыйсының Актүбәдәге йортын исенә төшерде, ул анда берәр бәйрәмдә яисә Исмәгыйль бәк белән Шамилнең Туган көннәрендә барып чыккалый иде. Аларның Туган көннәре, бернәрсәгә дә карамастан, хәтта Туган көне булган кеше үзе төрмәдә утырса да, изге бер көн итеп билгеләп үтелә—йорттагы бу йоланы Минсылу апа бик нык саклый иде...

Верандада үтәли җил йөри, шәмдәлдәге эреп агып утырган өч шәмнең дә зәгыйфь ялкыннары Валя ягына авыша, шунлыктан Рушан аның гитара өстенә иелгән йөзен яхшы күрә иде. Кайбер мизгелләрдә Рушан аны Карменга охшата, юк, Мериме иҗат иткән гүзәл, ут борчасыдай испан кызына түгел, ә Рәшит абыйсының хатынына, аңа да бертуган егетләрнең дуслары шундый кушамат такканнар иде бит. Ул Карменның да шундыйрак кызыл күлмәге бар, яраткан гитарасының сабын шушындый ук зәвыксыз бант бизи, уйнау рәвеше дә шушындыйрак була иде. Кармен бары тик башында мондый «күбәләк» кенә йөртми, Рушан аңысын яхшы хәтерли, ә җырлары исә нәкъ шушы җырлар иде—әйтерсең лә, Валя Гомәровлар өенә барып өйрәнеп йөргән, диярсең!

Мондый юньсез җырларны Рушан бервакытта да яратмады—яшьлегендә дә, хәзер инде бигрәк тә—шуна күрә, Валя, туктап, кылларын тарттырып маташкан арада, гитараны аның кулыннан алды да:

—Әйдә әле, эчик, кичәгедәй сөйләшеп утырыйк...—диде.

Ләкин ханым аның эчке кичерешләрен сизенеп алды һәм каһкаһә белән җавап бирде:

—Син, Дасаев, сноб икәнсең. Борыңның бик югары икән...—диде.—Мин менә шундый инде—төрмә җырларын яратам, алар хәзер бик тә популяр. Мартукта инде минем җырлавымнан үлеп китәләр...—Аннары кинәт кенә мыскыллап әйтеп куйды:—Ах, онытып җибәргәнмен, синең бит утырып чыкканың юк, тормышны да юньләп белмисеңдер...

Рушан бу сүзләргә артык игътибар итмәде—Валяның холкын белгәнгә күрә: «Үз сүзен сүз итәргә уйлый»,—дип кенә фараз кылды.

Гитарасын ишек янындагы кадакка элеп куеп, Валя өстәл янына борылып килде һәм Рушан каршысында күтелмәгән нәзакәтле пируэт ясап, шукланып аның чәчләрен чуалтып ташлады:

—Типтер, Рушан сөеклем! Ярат, рәхәтлән, әлегә мин синеке...

Рушан, ул янадан аңлаешсыз кыланчыклана башлады, дип уйлап, аңа эчемлекне гадәттәгедән азрак салды. Әмма ялгышты: Валяның борчылуы эреп юкка чыкты, ул кичәге шикелле үк ягымлы, назлы-сөйкемле булып калды. Рушан да тынычланды.

Алар янә кара-каршы утырдылар, төтенләп янган шәм ялкыннары аларның өстәл аша бер-берсенә ташланган яратулы карашларын тагын да кайнарландыра кебек—алар үзләрен кайчандыр нык бәйләп торган, әмма күптән онытылган нәрсәнедер исләренә төшерәләр иде бугай. Ханым бүген дә тарта—яшел каплы «Салем» сигареты белән зажигалкасы каршысында ята—әмма сирәгрәк тарта иде.

Бу кичтә Валя Рушанны тагын гаҗәпкә калдырды. Бөтенләй тынычланып беткәч, ул салкын су алып килергә сорады, Рушан ишегалдындагы колонкадан кувшин тутырып су алып кергәндә, ул янадан тартып утыра, әмма авызында ментоллы «Салем» түгел иде. Анысының исенә Рушан күнеккән иде инде, үзе тартмый торган кеше буларак, ул бу яңа исне дә бик тиз сизеп алды. Валяның кулында хәзер сирәк очрый торган папирос күреп, исе китте: «Нишләп әле тупас «Беломор»га күчтең?»—дип сорамакчы булды, әмма тыелып калды: Валяның сәер кәйсезләнүләрен белгәнлектән, янадан кәефен җибәрүдән курыкты.

Валя ничектер күнегелмәгәнчә тарта, матур башын артка ташлап, кәнәфинең биек аркасына терәгән, ниндидер эчке бер ләззәтләнүдән күзләрен йомган, ә Рушан исә, кичәге шикелле, янә аның өч рәт итеп тезелгән ясалма энҗе муенсалы нәфис муенын, хатын-кызларга гына хас ымсындыргыч түгәрәк ачык иннәрен сокланып күзәтә. Валяның күлмәк корсеты белән кысып, күтәртеп куелган ярым ачык калку күкрәге папиросын суырган саен күнелне дулкынландырып күтәрелә, Рушанга аның шулай тартып утыруына карау да рәхәтлек бирә иде. Ханым озын, матур бармаклары белән папирос көлен көллеккә, карап-нитеп тормыйча, илтифатсыз гына кагып төшереп, бик килешле итеп тарта иде...

Тартып бетергәч, Валентина күзләрен, гадәтенчә, ялкау гына ачып җибәрде, егетнең үзен сокланып күзәткәнен сизенгән шикелле, күкрәктән чыккан дулкындандыргыч тавыш белән пышылдап кына үтенде:

—Рушан бәгырем, син мине кичә шундый күнелләрне эретерлек итеп күтәреп йөргән идең, бәлки, бүген дә шул рәхәтлекне кабатларсың, ә?

Ул, әйтерсең, егетнең уйларын укыды—Рушан нәкъ менә Валяның папиросны ташлавын гына көтеп тора иде. Ул аны күтәреп алды да веранда түрендәге бүлмә ишегенә таба атлады, ләкин ханым, аның муеныннан каты итеп кочаклап алган килеш, колагына пышылдады:

—Йә инде, ишегалдыннан бер генә булса да әйлән, миңа шул кадәр рәхәт, ышанычлы...

Ишегалдында аны күтәреп йөргән бәхетле мизгелләрнең бер мәлендә берме-икеме тапкыр Рушан ана үзенең гашыйк икәнлеген һәм мәңге тугрылыклы булачагын чүт кенә әйтми калды, ләкин һәрчак ханымның берәр шуклыгы яки үбеп алуы бу уйларын читкә тибәрә торды. Мона аның һич тә кәефе китмәде—алда татлы төн көтә иде.

Аннары алар җәйге йорттагы бүлмәгә кайтып кerdeләр. Бүген анда бер почмакта тонык кына сүрән утлы торшер янып утыра иде, Рушан шул яктыда хатын-кызларча пөхтә-унайлы бүлмәне күздән кичерергә өлгерде, алсу обойлар бүлмәгә аерым бер күркәмлек бирeп тора иде. Егетнең почмактагы торшерга аптырабрак карап торганын күргәч, Валя, аның йөзенә ягымлы карап:

—Минем синең белән рәхәтләнеп ләззәтләнәсем генә килми, сине күрәсем дә килә,—диде. Аннары иркәләнеп өстәп тә куйды:—Каршы түгелсеңдер бит?

Ул, билгеле, каршы түгел, аның да Валяның гүзәл йөзен күреп торасы килә иде.

Әмма бүген, Валентина аңа кичәге кебек үк дәрт-теләк белән бирелсә дә, нәрсәдер шулай да, шулай түгел дә төсле иде. Баштарак Рушан, ут яктысы комачаулыйдыр, дип уйлады, әмма, аны-моны әйтеп тормастан, Валя утны үзе сүндерде.

Ханым үз дәртендә ничек кенә ашкынып кабаланмасын, ничек кенә ярсынып-комсызланып назламасын-иркәләмәсен, Рушан шул ук вакытта аның бик тиз хәлсезләнә баруын, битараф төшенкелеген тоеп алды—гашыйк кешедән үз халәтенне яшерү мөмкин түгел, ә бу очрашуга Рушан гашыйк булarak килгән иде бит. Бүлмәдә ут янып торганда, ул берничә мәртәбә аның үз өстенә бик якын иелгән күзләрен күрде—ул күзләр бүген бөтенләй башка, алар каядыр читкә карыйлар кебек, үзләрендә куркытырлык бушлык чагыла иде. Инде үз-якын, ягымлы-сөйкемле ханым кинәт кенә аңа ниндидер аңлашылмас ягы белән ачыла бара иде. Һәм Рушан яңадан, инде урын өстендә яткан көйгә, аның очрашкач та башланган борчылу-тынычсызлануын, нәрсәгәдер хафалануын сизде.

Валя кинәт кенә изрәп-мәлҗерәп төште, егетне үзеннән тибәреп, көйсезләнеп боерды:

—Рушан, өстәлне бире керт тә икенче шешә «Ахтамар»ны ач әле!—диде.—Сине шат күңелле итеп күрәсем килә, житди кыяфәтең унайсызлый мине...

Егет каршы килмәкче булды, ләкин Валяның күз карашына төртелгәч, уң кулын шәрекъчә итеп күкрәге өстенә куйды һәм, башын буйсынучан иеп, шаяртып җавап бирде:

—Баш өсте, сез боерганча булыр, мин сезнең колыгыз...—диде.

Үзе бу гамәлләрнең ниндидер чишелешкә тәгәрәгәнен, әмма, үзенә кагылышлы булса да, мона берничек тә тәэсир итә алмаячагын аңлады, ул янә үз язмышына үзе хуҗа түгел иде инде.

Валя көтмәгәндә аның белән брудершафтка эчәсе итте һәм коньякны су сала торган зур бокалларга койды—мөлдерәмә тутырмаса да, ярты шешәне бушаткан иде. Рушан, монысын эчкәч вакыйга ниндидер гаугалы-җәнҗаллы төс алыр инде, дип уйлаган иде, әмма тагын акылга сыймас хәл килеп чыкты—буш бокалларны читкә этәреп куйгач, Валентина, комсызланып, аның иреннәренә сөлектәй ябышты, Рушан янә аның кичәге кебек дәртле-ялкынлы сүзләрен ишетте: «Минеке... минеке... минеке...»

Аның кайнар кочагында тыннары кысылган Рушан, елмаеп, үзенең хатын-кызларны, мөгаен, беркайчан да аңлый алмаячагын уйлап куйды. Валяның нәфис тәнен үбә-үбә, иркәли-назлый, ул янә күкнең җиденче катында иде.

Ниһаять, ул, бәхете һәм куанычы тулышып, тынып калды, күңелендә көтмәгәндә яңадан кузгалган мәхәббәт хисләрен инде әйтергә дип кенә җыенганда, Валя кинәт аның өстенә иелде, әллә шаяртып, әллә чынлап сорады:

—Дасаев, синең кайчан да булса хатын-кызларны шампан шәрабендә коендырганың бармы, аларга миллионлаган алсу розалар яки саф энҗе һәм бриллиантлар бүләк иткәнең булдымы?

Егет җавап бирүдән шаяртып котылмакчы иде, ләкин ханым үпкәләп, үҗәтләнеп кабатлады:

—Мин бит синнән чынлап сорыйм,—диде.

Вакыйганың мондый юнәлеш алуыннан айнып китеп, Рушан:

—Бу бит блатнойлар иҗаты...—диде.—Хатын-кызга нигә шампанда коену кирәк? Мин аны хәтта зарарлы дип уйлыйм, иң яхшысы—сабын...

Валентина шартлап китте, дары мичкәсе, диярсең:

—Их син, сабын... Зарарлы түгел. Мин коендым, бер генә дә түгел әле...

Рушан, аның кычкырып җибәрүен ахырынача аңлап бетермичә, һәм, билгеле инде, сүзләрен җитдигә алмыйча:

—Ә юынгач-коенгач, ул шампан шәрабен нишләтәләр инде?—дип ычкындырып ташлады.

Валентинаның шуннан соңгы җавабы бу ярым тиле сөйләшүнең җитдилегенә ышанырга мәҗбүр итте:

—Әйе, мин шампанда коендым, ә дусларым һәм мина шул күңел ачуны оештырган кешем шәрабне ваннадан бокаллары белән чумырып алып эчтеләр һәм мина саулык-сәламәтлек теләделәр—шундый йола, матурлыкка һәм гүзәллеккә, хатын-кыз тәненә шулай соклана беләләр алар. Ул искиткеч! Ләкин, күреп торам, син моны гомер аңлый алмаячаксың, сиңа бирелмәгән ул! Гомерең буе получкадан получкага яшәгәнсең инде... Шулай яшәрсең дә...

—Син чынлап сөйлисеңме? Кем була инде ул хатын-кыз матурлыгын шулай нечкә бәяләүче һәм ваннадан шампан чөмерүче кеше?—дип сорады Рушан, җавап алырга өметләнмичә генә. Чөнки һаман да әле монысы да Валяның чираттагы шаяртуы-уены гынадыр дип уйлый, егетләрдән аның соңгы еллардагы әкәмәт сәер кыланмышлары турында ишеткәне бар иде.

Ләкин Валентина ачу китерерлек горурлык белән җавап бирде:

—Дато Гвасалия. Мине чын-чынлап яраткан-иркәләгән кешем. Аның кушаматы юкка гына Лорд түгел иде: чәчәкләрне ул кәрзине-кәрзине белән, хушбуйларны дюжиналап бүләк итә иде, менә бу саф энҗе муенса да аның бүләге...

Ә Рушан аның муенындагы ул энҗе муенсаны ясалмадыр яки әле чех пыяласыдыр дип кенә уйлаган иде... Ләкин боларның берсенең дә әһәмияте юк иде инде. Рушан бөтенләй айныды. Үзенә чит һәм җирәнгеч бу ханымны җиңелчә генә читкәрәк тибәрде, аның сыгылмалы, ымсындыргыч тәненә карата бернинди кызыксыну хисе калмады, ул урындык аркасына эленгән күлмәгенә үрелде.

—Син кая?—дип гаҗәпләнеп сорады Валя.

Рушан җавап биреп тормады. Киенә-киенә уйлады—әйтергәме, әйтмәскәме?—әмма соңгы мизгелдә әйтергә булды:

—Беләсеңме, Валя, мин бүген сиңа тәкъдим ясамакчы идем...

Төнге салкынча һава аны суындырды, барыбер йоклап булмасын чамалап, ул өенә кайтырга ашыкмады, төнге Мартук урамнарын гизеп, уй-хисләрен тәртипкә китереп йөрергә булды—тагын бер көннән ул китеп барырга тиеш иде. Паркка барып житкәч, моннан сигез ел элек Валяны шушында сап-сары буялган чәчле итеп күргәнен хәтерләде һәм капылт көлеп җибәрде, бу көтелмәгән көлү аның кәефен җиңеләйтте. Ул кинәт кенә кысан ванна бүлмәсен, төссез-ямьсез сантехниканы, заводтан ук шадраланып чыккан кафель плиткаларны, ванна тирәсендә бокал тоткан карактыр-фәләндер әтрәк-әләмнәрне һәм шәраб эчендә, мәгънәсез көлеп, чупырдап яткан Валентинаны күз алдына китерде... Тамаша, чынлап та, көлке һәм хәтта кызганыч күренеш булгандыр, әгәр дә санузел дигәне ванна бүлмәсендә булса, бигрәк тә... Йа Ходаl..

Һәм бөтенесе дә анык-ачык булып үз урыннарына утырды: Валяның

өф-төф итеп тәрбияләп тоткан бармак араларына кыстырылган тупас папирос та, әллә кая читкә карап, пыялаланып калган күзләре дә, шунда ук битараф ваемсызлыкка әверелүчән дәрт-теләге дә, сәер төрмә җырлары да, энже муенсасы да һәм хәтта шампан шәрабле ваннасы да...

Сигез ел элек үк, ул әле «1905 ел» урамында яшәүче кыз белән мавыгып йөргән заманнарда ук, Куйбышев шәһәрендә очучылар училищесында укучы кайсыдыр бер егетнең сүз аралаш кына әйткән сүзләрен Рушан колагына да элмәгән иде. Ул егет Валяның мыштым гына наркотиклар тартуын, энә кадаулардан да тайчанмавын, шәһәрдәге юньсез егетләр белән чуалуын һәм хәтта ниндидер бер җинаять эше буенча шаһитлык кылып йөрүен дә сөйләгән иде. Ул чагында башында башка уй-исәбе булган Рушан ул имеш-мимешләргә игътибар итеп тормаган иде, ә менә хәзер һәммәсе дә бер логик чылбырга тезелде...

Инде бүген, егерме еллап вакыт үтеп киткәч, Мартукта Валя Домаровага өйләнергә аздан гына тәкъдим ясамый калган ул гаҗәеп кичне хәтереннән үткәреп утырганда, Рушан аңлый: ул заманнарда, башка бик күп нәрсәләр турында кычкырып сөйләнмәгән төсле, наркомания турында да ачыктан-ачык сөйләү юк иде, әйтерсең, ул безгә кагылмый. Әмма аны теге чакта да, хәзер дә таң калдырганы—юк, наркомания үзе түгел, ул ямьсез күренеш белән мавыккан, авыруга сабышкан егетләрне Рушан күп очратты,—ә шул кармакка капкан, үзе күргән бердәнбер ханымның кайчандыр үзе яратып йөргән, кайчандыр мәктәп иншасында балерина булырга хыяллануын язган кыз булуы таң калдырды...

Бүген ул белә инде, үзе аңа «Шанель» бүләк иткән теге җәйге төннән соң, ике ел үткәч, Валя янадан Мартукка өйләнеп кайткан. Кайдадыр механик булып эшләүче, әмма күбрәк хастаханәләрдә һәм даруханәләрдә наркотиклар даулап гауга чыгаручы наркоман ире белән кайткан. Мәгәр аның үзенең дә ул вакытта инде «энәдә утырганын» күпләр белеп торгандыр. Андый начар гадәтләр белән, өстәвенә, җәмгыятьтә үзенә ниндидер аерым өстен урын дәгъвалап, кечкенә поселокта яшәве кыен шул. Озакламый алар бер җәйге төндә Рушан чын-чынлап бәхетле булган Совет урамындагы йорттан китеп барганнар һәм шуннан соң Валентина турында Рушан бүтән беркайчан да ишетмәде. Язмышы ничек булып беткәндер ул бәхетсез ханымның?..

Хәер, бервакыт, берничә ел үткәч, Мартуктан меңнәрчә чакрым җирдә Рушанга энҗе муенсаны да, шампан шәрабле ваннаны да исенә төшерергә туры килгән иде.

## XIV

Валя белән очрашу шәхсән Рушанның үзенә түгел, ә Рәшит абыйсына бәйле, әмма барыбер аның да тормышына кагылышлы тагын бер ачыш ясарга ярдәм иткән иде. Һәрхәлдә йөз кырык ике килограмм ук түгел, ә нибары йөз егерме алты килограмм гына булган Эмма Бобликовадан ишетеп белде: Рәшит абыйсының кайчандыр егерме биш яшен билгеләп үткәргән атаклы Туган көне Эмманың әнисе йортында булган икән—шулай итеп, балачактагы тагын бер сер ачылды.

Ә ул кичтә Валя әле аңа, ачусыз-нисез генә, Славик Афанасьевның һичкайчан да шәһәр кешесе булып китә алмаячагын сөйләгән иде, көзгегә баккан, диярсең—хак әйткән икән. Бер-ике елдан Славик Алма-Atадан өйләнеп кайткан, баеп киткән якташларына алтын тешләр куеп, зур акчалар суга башлаган. Безнең Рәсәй халкы шешә биреп рәхмәт әйтүдән башканы белми бит, шулай туктаусыз эчә торгач, тәки айный алмыйча, үлеп киткән Славик. Очрашканда кайгырып искә алынучыларның исемлеге шактый зурайды, аларны хәзер, сайлаулардагы кебек, гомуми бер исемлек белән генә искә алып куя башладылар.

Бүген Рушан үз югалтуларының барысын да диярлек белә инде, әмма

элек бервакытта да егерме сигез яшьләренә, ә бәлки, аннан да иртәрәктер әле, үзенең ихлас көлә белүен югалтуы турында сизми дә, уйламый да иде. Хәзер ул Валяның теге кичтә ни өчен елаганын анлый инде: Валя аның һәм үзенең әле ахырына барып җителмәгән тормышын алдан ук кызганып елаган. И бу хатын-кыз сизгерлеге...

Күптән түгел генә Рушан, газетлардан укып, шаккатыргыч саннар белде. Ә бит аның танышларыннан берсе дә—ни эштә, ни өйдә булсын—моңа игътибар да итмәгән, ул хәтта бер-ике көн автобус-троллейбусларда да колак салып, тынланып йөрде, бәлки, кемдер: «Нинди коточкыч!» дип әйтер төсле иде. Ләм-мим, ник берсе-бер бу хакта үз фикерен әйтсен, әсәрләнеп сөйләнсен—күрәсең, битарафлыкка күнеккәннәр инде. Бәлки, газет-фәлән дә укымыйлардыр? Ә газеттан Рушан менә нәрсәләр укыды: илдәге җинаятьләрнең алтыдан берсен хатын-кызлар ясый икән, бер ел эчендә ике мең биш йөз хатын-кыз яңа туган баласын үтергән өчен суд җаваплылыгына тартылган. Бу санны әле, милиция күзенә чалынмый калганнарын да кертеп исәпләсәң, мөгаен, тагын унга тапкырларга кирәктер, бары тик шунда гына чын дөресе килеп чыгар. Димәк, җәмгыятьнең күпмиллионлы җинаятьчел катламыннан үз тормышында бары берсенә—Валяга гына тап булып, Рушан җиңел котылган.

Юк, Валя Домарованы, аңа чак кына өйләнешергә тәкъдим ясамый калса да, Рушан һич кенә дә үзенең беренче мәхәббәте дип атый алмый, әмма ике арада булган мөнәсәбәтләрне, теге җәйге ике бәхетле кичне дә тормышыннан сызып ташлый алмый: булганы булган инде.

Күрәсең, ул хәлләрне мәхәббәткә кереш—прелюдия дип санарга гына каладыр...

Үткәннәрен барлаганда, Рушан үзенең ихлас көлүен югалтуы, туганнары-дуслары үлеме, Актүбәнең борынгы вокзалы һәлакәте һәм Ташкентта бер-бер артлы юкка чыга баручы чәйханәләрне генә түгел, тагын байтак нәрсәләрне искә төшерде әле. Үткән гомердә бик күп җисми серләр дә ятып калган икән. Ул, мәсәлән, язгы төн уртасында соңлап кына Орджоникидзе урамыннан кайтып барган чагында, бер мизгелдә күзләрен сукырайтып, каршысына килеп чыккан машинадан бер кыз кул изәп—Светланка Резникова иде ул кыз,—шул кул изәүнең ни-нәрсәгә ишарә икәнен еллар үткәч тә һаман да анларга тырыша әле. Резниковлар «Волга»сы тимерьюлчылар сарае чатыннан борылып, каршыдагы тыкрыкка кереп югалганчы, үзенә генә изәп барган шул кулны күреп торган иде ул. Нәрсә анлата иде икән ул кул изәү? Яңа ел кичәсендә дәррәү кабынып киткән хисләре мартта ук өзелгән иде бит юкса...

Яки ни өчен Ниночка Новова аңа бик үтенеп, «Рапсодия» дигән Америка фильмын каравын сорады икән һәм ни өчен ул, аңа әйтми-нитми генә, чыгарылыш кичәсеннән соң ук Ленинградка китеп барды икән? Юкса, ул китәр алдыннан алар икәүләп Ниночкаларның Кызыл урамындагы алма бакчаларында таңга чаклы йөргәннәр һәм таң аттырганнар иде бит... Сәер, нишләп хәтер шундый вак-төякләрне дә саклый икән?

Әмма хәтердә әле үз вакытында җавап таба алмаган, һаман да күнелне бимазалап торучы сораулар тулы нindidер анык вакыйгалар гына сөзелеп калмаган, бөтенләй анлатып булмаслык нәрсәләр дә гомер буе табышмак булып ияреп килә...

Бервакыт Рушан үзләре Бродвей дип йөрткән урамда Жорик Стаин белән бергә,—Жорик турында аерым сүз булыр әле,—искиткеч гүзәл бер кызны күргән иде, әмма хәтергә уелып калганы шул Сашенька Садчикова үзе түгел, ә аның тегелеше белән дә, төсе белән дә гадәти булмаган күлмәге булды. Сөйкемле Садчикованың шул күлмәге төсе Рушанны ни өчендер гомере буе эзәрлекләп килде, ул аның нинди төс икәнлеген ачык кына әйтеп бирергә аптырый иде. Һәм менә хәзер, утыз еллап вакыт үткәч, көтмәгәндә генә, үз иленнән сөрелгән Тибет далай-ламасын әле кайчан гына үзе дә диссидент булган, ә хәзер шул илнең президенты Вацлав Гавел кабул иткәнне телевизордан күрде дә исе китте. Теге табышмакка җавап

табылды бит: аксыл-сары чәчле Сашеньканың күлмәге төсе бер дә әфлисун төсе түгел, ә будда далай-ламасының кызгылт-сары хитоны төсендә булган икән.

Яки, бер карасаң, Рушанны атаклы Ницца белән нәрсә бәйләп торырга мөмкин? Әйе-әйе, зәңгәр диңгез буендагы гүзәл шәһәрчек белән. Хәер, бу диңгез буендагы курортның үзе белән дә түгел әле, ә бары тик колакларны иркәләп торучы исеме белән.

Ницца...

Ул да, Рушанны еш кына бер сәбәпсез сагышка салып, бик озак аның хыялында йөрде. Мөгаен, Ницца аның хәтеренә теге, май ахырындагы бөтенләй дә язга охшамаган төксе бер көндә уелып калгандыр, алар ул көнне Ниночка Новова белән Тимерьюлчылар сараендагы ниндидер бер концертка очраклы гына барып эләккәннәр иде: концерт программасы әллә ни ис китәрлек түгел, артистлары да вак-төяк шәһәр-авылларда гастрольләр өчен генә җыелган, кайчандыр өметле генә булып, соңыннан эчкечелеккә бирелгән, тормыштан күңелләре кайткан, бар яшәү чыганагы шул үзләре сөймәгән авыл сәхнәләре булган әтрәк-әләмнәр иде.

Еракта калган ул май аенда Ниночка мәктәп, ә Рушан техникум тәмамлап киләләр һәм, тиздән аерыласыларын сизенеп, көн дә очрашалар иде. Киләчәктә тормыш юллары гомерлеккә аерылачагын тойгангамы, ул очрашулар ничектер комсыз, шашкын, ярсулы булды, юкса, телдән, әлбәттә, галәмәт зур планнар коралар, күз алларына китергән хыяллары өсте-өстенә өелә тора иде...

Концертка алар соңладылар, борынгы сарайның яңгырап торган ярым буш залына килеп кергәндә, сүрән генә барган концерт бераз җанлана төшкән һәм кайсыдыр бер җырчы сыек кына кул чабулар ишетү бәхетенә дә ирешкән иде. Алар кереп урыннарына утыруга, сәхнәдә бер хатын-кыз күренде, аның җыры Рушанның күңелендә бик озакка, дистә елларга сакланып, һәрвакыт шул ерактагы Ницца турындагы тормышка ашмас хыялларын кузгата торган булып калды.

Юаная башлаган, озын гына буйлы җырчы хатын үкчәләренә үк төшеп торган чия төсендәге озын бәрхет күлмәктән, авыл җирләре өчен артык кыю ачып куелган декольтесе зифа муенын, хатын-кызларга хас мәрмәр ак җилкәләрен, каты корсет белән күтәреп куелган тулы күкрәкләрен күзгә бәрелерлек матур итеп күрсәтә. Ул кулына шушы дала якларында үсә торган фарсы сирененең коела башлаган чәчәген тоткан иде, үзе үк җырның исемен әйтте: «Ниццадан килгән чәчәк».

Бу җырчы Рушанга шактый карт, талчыккан йөзле булып күренде, бәлки, әле кырыкны да тутырмаган булгандыр, әмма үзенең унҗиде яшьлек каланчасыннан Рушан шулай күрде, ирексездән аның эченә җыелган сагышын тойды, ни өчен шушы шәһәрчекнең ярым буш залына килеп чыкканын аңлады. Җыр, күрәсең, җырчының күңеленә якын, ул үзе дә, мөгаен, Ниццаның буй җитмәс, тормышка ашмас хыял икәнен күптән аңлаган иде. Җырдан да, җырчыдан да бөтен дөньяларны биләп алырлык тирән сагыш саркый, бәлки, бу бинаның диварларына әллә кайчан эленеп калган сагыштыр ул, инде менә шул сагыш Рушанның да күңеленә инеп калды. Бәлки, башкалар аны бераз гына сагышлы гади җыр итеп тыңлаганнардыр, әмма егет өчен ул бүтәнчәрәк яңгырап ишетелгән иде. Әйтерсең, Рушан ерактагы алгы көннәргә, үзенең әле яшәлмәгән тормышына йөгерде дә, тормышка ашмас өметләре һәм бәхетсез мәхәббәте өчен алдан ук хәстәрләнеп, тирән сагышка батты. Мөстәкыйль тормыш бусагасына аяк басарга җыенган, җитмәсә әле янында чибәр чытлык Ниночка Новова булган унҗиде яшьлек егет өчен бик сәер тойгы иде бу.

Күрәсең, җыр икесендә дә бер төслерәк хисләр кузгаткан иде, чөнки Ниночка Рушанга ничектер моңсу гына карап алды да, ана сыена төшеп, караңгыда кулын капшап тапты һәм аны сыйпый-иркәли башлады, ниндидер көтелмәгән хәвеф-борчылу сизде бугай.

Әле яшәлмәгән тормышы өчен шундый ук кайгыру-борчылу хисен

ул тагын ун ел үткәч, балерина булырга хыялланган Валентинаның, аңлап та җитмәстән, үзләренең уңмаган, барып чыкмаган язмышларын елап искә алганда кичерде...

Концерттан кайтып барганда Рушан ирексездән офтанып куйды: «Ниццадан килгән чәчәкләр...» Зәңгәр диңгез яры буендагы сагышлы мәхәббәт турында сөйләшергә әзер булган Нина: «Кирәкми, Ницца чәчәкләре безнең өчен түгел...»—дип җавап кайтарды.

Ул чагында Рушан аның сүзләренә әһәмият биреп, бәхәсләшеп тормаган иде. Ләкин бүген ачынып икърар итәргә туры килә: хәтта уйсыз-башсыз яшьлек елларында, мөстәкыйль тормышка аяк басар алдыннан да алар ни Ницца, ни Венеция, ни Монте-Карло, ни Фиджи яки Мальорка утраулары турында хыяллана да алмыйлар иде—алар баштан ук бөтән тормыш өчен, күз камаштыргыч коммунизм үрләренә бару юлындагы мәңгелек киртәләрне җимерер өчен әзерләнгәннәр иде. Бүген Рушан, соңлап булса да, моңаеп уйлана: аның туган иле халкы Егерменче гасыр цивилизациясеннән—мәдәният казанышларыннан гына аерылмаган, ул, гомумән, табигый кешеләр тормыш-көнкүрешеннән дә мәхрүм, кая инде монда Ниццалар...

Әмма Тимерьюлчылар сараеның ярым буш залында күңеленә кереп калган Ницца аның хыялларын озак ымсындырып торды әле. Бервакыт Ялтада, шаулап-гөрләп торган субтропик яшеллек арасында ул тулай кызыл тактадан әллә кайларга кычкырып торган реклама күргән иде: «Ниццага барыгыз!» Троллейбус бик тиз чапканлыктан, ул астарак тагын бер сүзне абайламый калган, анда исә «ресторан» дип язылган иде, шундый реклама белдерүенә башка бер урында яңадан килеп төртелгәнче, өч көн рәттән башыннан шул Ницца чыкмады. «Ницца» дигәннәре гап-гади бетон идәнле «пыяла тартма» икән, башка шундый урыннардан варьете биюле кечке ресторан хисапланып йөртелүе белән генә аерылып тора иде. Залының мескен фәкыйрьлеген яшереп, пыялаларын чия төсендәге ковралон белән каплаганнар—мөгаен, «Ницца» яныннан үтеп йөрүчеләр аның эчендә гаять бай, күңелле кәеф-сафалы тормыш бардыр, дип уйласыннар өчен дә шулай эшләгәннәрдер. Кыршылып беткән өстәлләре, өстәл өстендәге пластик савытлары һәм чатан тимер урындыклары белән күзгә бәрелеп торган бу фәкыйрьлекне залның ярым караңгы булуы һәм сәхнәнең оста гына итеп яктыртылуы яшереп тора, сәхнәдә исә ашык-пошык кына аннан-моннан җыелган кызлар варьете бии, кечкенә бер оркестр уйный иде. Нәрсә генә маташтырмаганнар: чыршы бизи торган ялтыравык укалар, зәвыксыз гына ясалган рәсемле, еш алышынып торучы сәхнә, дисеңме, сәхнәдә дә, залда түшәмнән дә асылынып төшкән, ялык-йолык килеп әйләнүче көзгеле шарлар, дисеңме—берсе дә калмаган. Алар, күрәсең, атаклы диңгез курортларында сезон вакытында була торган нинди дер үтә зиннәтле, бай һәм күңелле тормышка кагылышлары барлыкны аңлатырга тиештер инде.

Рушан залның фәкыйрьлеген дә, варьетенең мескенлеген дә күрде. Әлбәттә, «Ницца» дигән купшы исемле бу «пыяла тартма»ның ул озак еллар хыялланып йөргән гүзәл Ницца белән бернинди уртаклыгы да юк иде, тонык яктыртылган Ялта урамнары буйлап төн уртасында күңелсез генә кайтып барганда, ул үзен янә бер кат алдадылар шикелле хисләр кичерде.

«Ни өчен бездә һәркайда әшәкелек, зәвыксызлык, фәкыйрьлек, аларны караңгыга төреп тә, оста яктылык белән дә яшереп булмый бит...»—дип, моңаеп уйланды ул. Яктыртып куелган реклама тактасындагы «Ялта—дөнья курортларының энҗесе»,—дигән язу мәсхәрәләп көлү кебек тоела иде.

Шаулап үткән елларын, китап битләрен актарган кебек актарып, дусларын хәтеренә төшереп утырган мизгелләрдә ул үз шәхесенә бик якын килергә базмый иде шикелле, юкса, үз-үзен тулысынча ачып бетермичә, заман җирлегендә үз фотосурәтен булдырмыйча, бу истәлекләрнең кыйммәте бик аз булуын да тоя иде. Мөгаен, аның үз тормышы ул сөйлисе килгән вакыйгаларга яңа төсмер бирер, димәк, яңадан артка, илленче елларның

икенче яртысына, бөек казакъ далаларыннан жил китергән ком баскан шәһәрчеге Актүбәгә кайтырга, «1905 ел» урамындагы йорт яныннан берничә мәртәбә үтеп китәргә яки тәрәзәсе каршысында басып торырга кирәктер. Кулына нота папкасы тоткан зәңгәр бантиклы гүзәл кыз шунда яши иде бит. Рушан аны Тимерьюлчылар сарае янында очратып, сокланып-хәйран калып, артыннан ияреп киткән иде. Кайчакларда ана әле хәзер дә һаман аның артыннан атлый төсле тоела...

Ул кызны искә төшерүе рәхәт, кызый аның төшләренә дә бик еш керә. Төшләрендә ул күптән үткән елларының исен-төсен тоя, авазларын ишетә, аны шул замандагы тормыш-көнкүреш шау-шулары, шул чаклардагы музыка чолгап ала, ул янадан яшьлегендәге парк-бакчаларда йөри, кинотеатрларга керә. Иң кызып, яшьләр белән тулышып торган Бродвейны, мәктәп кичәләрен һәм Тимерьюлчылар сараендагы дәртле биюләрен күрә... Аның төшләре үзе катнашындагы ретрофильмнар алар. Бик кыен, түзә алмаслык мизгелләрдә, бер сәбәпсез-нисез күнелен сагыш-моң басканда, ул кешеләрнең язмышлары белән идарә итүче югарыдагы ниндидер илаһи заттан ялварып сорый: «Төшләремә яшьлегем керсен!»—ди. Ә яшьлек—мәхәббәт ул.

Үз вакытында абайламый, аңламый калган күп нәрсәләрне утыз елдан соң күрергә, аңларга мөмкин булган гүзәл төш-фильмнар... Дөрес, аларның берсен дә ахырына кадәр күреп бетереп булмый, алар, детектив сериаллар шикелле, иң кызыклы җирендә өзеләләр дә, ничек кенә ырымласаң да, дәвамын күрә алмыйсың. Ул төш-фильмнар бер тамашачы өчен генә, бер тапкыр гына күрсәтелә, алардан соң көндәлек тормышка янадан кайту бик кыен була. Ләкин Рушан алардан һич кенә дә баш тарта алмас иде.

Аның техникум күршесендәге мәктәптә укучы кызга булган җавапсыз мәхәббәтеннән йомшак кына көлеп, дуслары кайчандыр: «Моңайма, тәүге мәхәббәт—кызамык кебек ул, авырырсың да терелерсең, икенче берәүне очратырсың, үзеннән тәкәббер музыкантшаңны онытырсың»,—диган иделәр. Бүген инде яшисе яшәлгән дип исәпләнә шикелле, ә ул аны барыбер онытмады, хәер, теге чакта ук ул бу ярату хисенең житди һәм озакка булырын тоемлаган иде инде.

Прораб бүлмәсендә хезмәттәшләре арасында үз балаларының беренче мавыгулары, тәүге ярату хисләре турында сүз чыгып, аларны житдигә алмауларын ишеткәндә, Рушанның йөзеннән моңсу елмаю йөгереп уза. Ул үзе андый бәхәсләргә катнашмый—аның яралы күңеленең ачы сабаклары кемгә кирәк? Аның үзенә—тормыш йөген туйганчы тарткан ялгыз прорабка карап, аны да кайчандыр дәрт-теләкләр газаплагандыр, ул да кайчандыр көйдергеч мәхәббәтнең тылсымлы ялкынын татыган-тойгандыр, шул турыдагы истәлекләре үзе өчен сакланып калган иң кадерле әйберсеәер, ул шулар белән генә яшидер, дип уйларга мөмкинме соң?

«Истәлекләр—безне куып чыгарып булмый торган бердәнбер оҗмах ул»—бу тирән мәгънәле сүзләрне ул кайчандыр кайдандыр укыган һәм гомере буена хәтерендә калдырган иде.

Күңеле белән кулына нота папкасы тоткан кызга әйләнеп кайтканда, соңгы көннәргә кадәр аны бер нәрсә газаплый, аның язылмаган әлеге «гомер китабына» кемдер күз төшерер дә сорап куяр шикелле: «Әллә син Глорияне яратмадың? Ә Светланка Резникованы? Ниночка Новованы? Ниһаять, Валя Домарованы?.. Аның белән үткәргән ләззәтле төннәрең?...» Үз эш-гамәлләре өчен үзе җавап бирергә күнеккән, беркайчан да башка кешеләр артына кача белмәгән Рушан менә шушы, әле беркем дә бирмәгән сораулардан куырылып кала. Бәлки, үзен кеше алдында тулысынча ачып бетерү мизгелен дә шуна күрә кичектереп киләдер әле...

Мөгаен, гади прораб кына булмыйча, сизгеррәк күңелле бер кеше—әйтик, рәссам, язучы яки артист-фәлән булса, хәзер инде анык кына бер нәрсә дә дәгъва итми торган, күптән булып узган мөнәсәбәтләрен җинел генә шәрехләп, аңлатып бирер дә иде, ләкин Рушан өчен бу—мөмкин булмаслык эш: ул үзенең истәлекләрендә үзен дә, сөйгәннәрен дә, үзенә

кадерле булган башка кешеләрне дә түбәнсетергә теләми иде. Шуна күрә дә ул «күңел китабы»ның сәхифәләрен шәхси тормышындагы һәр мәгъшукасына лаеклы урын табылган вакыйгалар белән тутырырга ымсына иде. Һәм ул әнә шул күптәнге үзен һәм үзенә кадерле башка нәрсәләрнең асылын танып белү юлын тапты шикелле...

Бервакыт, бөтенләй очраклы гына, бер китапта аның күзенә Жан Кокто турындагы истәлекләр чагылды. Күптән булып үткән вакыйгаларны анларга менә шул ачкыч булды да инде. Язучының вафатыннан соң, биографлары аның фронтка китәр алдыннан язган мәхәббәт һәм иркәләү сүзләре тулы дүрт хатын табып алганнар—ул хатларны мәхәббәт лирикасының иң югары үрнәкләренә тиңлиләр икән. Ләкин... иң кызыгы шунда: ул хатларның барысы да, копирка аша язылган кебек, бер төсле, үзләре исә дүрт хатын-кызга адресланган икән. Һәм тагын да сәеррәге шул, озын һәм бәхетле гомер кичергән ул гүзәл ханымнар, соңрак хакыйкатьне белгәч тә, берсе дә «үзенә генә» язылган хаттан баш тартмый, киресенчә, хатта белдерелгән мәхәббәт хисләре бары тик үзенең Кокто белән булган мөнәсәбәтләренең чын асылын ачып сала дип бара икән...

Дасаев, әлбәттә, француз Кокто түгел, биредә турыдан-туры охшашлык була да алмый, әмма танылган драматургны һәм аның мәхәббәт хатларына ихластан дәгъва кылучы мәгъшукаларын аңларга тырыша торгач, ул үзенең ерак үткәнендәге кайбер вакыйгаларның чишелешен тапты шикелле.

Рушанның шәһәрдә яхшы билгеле бер «буй җитмәс» төркемдә йөргән сыйныфташ кызлары—Светлана Резникова һәм Ниночка Новова белән булган кыска, әмма бик шашкын «мәхәббәт уены» үзе техникумның дүртенче курсында укыган чагында, инде диплом проектына тотынгач, соңгы ярты ел эчендә булып алган иде. Хәзер Рушан ул чагында үзенең кызларның ниндидер мәкерле-хәйләле гамәлләрен башкару өчен генә «бик вакытлы» туры килүен аңлый инде, һәм, ни хикмәт, ике мәртәбә шулар кармагына капкан иде бит, ә барыбер ул хәйлә-мәкерләрен ахырына кадәр һаман да әле ачып бетерә алганы юк. Бары тик шуны гына белә: кызлар аңа махсус тозак кормаганнар, ул алар кул астына очраклы гына килеп кергән һәм, үзе дә аңламастан, алар уйлаган рольне башкарырга бик кулай булган. Һай, бу кызлар!.. Әмма хикмәт тә шунда шул: җинел генә уйланылган хәйлә-мәкерләре үз йөрәкләренә дә кагылып узар һәм, соныннан ачыкланганча, озакка яндырып торыр, дип кызларның берсе дә көтмәгән—монысын да Рушан хәзер яхшы белә.

Әлбәттә, бу «мәхәббәт уеннары» турында искә төшермәскә дә, аларны яшьлектәге юләрлекләр дип кенә үтеп китәргә дә булыр иде. Бигрәк тә ярты ел эчендә ике мәртәбә гашыйк булу—җитди эш түгел, мәхәббәт турында сөйләгәндә аларны искә алып торырга да кирәкмәс иде. Әмма вакыт дигәненнән бу очракта бер әһәмияте дә юк, Рушан, китаплардан укып, кешеләр өчен кайчагында көннәр һәм хәтта сәгатьләрнең дә бик мөһим булган мисалларын белә, ул көн вә сәгатьләр кешеләрнең язмышларын хәл иткән яки гомерләре буена рухи таяныч булган. Тагын да ныклы дәлил бар—һәркайсында тамга тора: «Вакыт тарафыннан сыналган».

*Дәвамы киләсе санда*



## Рифкать Закиров

### МӨЛДЕР-МӨЛДЕР АҺӘҢ-МОҢНАР БАР

**Җир сискәнер кебек...**

**Илдә—кытлык... Өйдә кот юк...**
**Минем куңелем китек:**
**Җирне сискәндерер кебек**
**Моңым түгелеп китеп...**

**Тик мин йөрмим чырай сытып,**
**Ялтырыйм—елмаямын;**
**Аптырыйм: ничекләр итеп**
**Арттырыйм дөнья ямен?!**

**Якты йөздә күз яшенең**
**Балкуын истә тотам:**
**Татлысы тамса яшермим,**
**Ачысын эчкә йотам...**

**Мәңге мөлдерәмә тулы**
**Күңелем... китек минем.**
**... Бара инде җырлы-моңлы**
**Гомерем үтеп минем...**

**Галиҗәнап Вакыт**

**Вакыт узып бара,**
**Эзе, төсе кала:**
**Йә кан булып ага,**
**Йә яшь булып тама.**

**Вакыт мәңге ага**
**Бары артка таба...**

Еллар гына алга
Елгыр аттай чаба!

Берәү—юл башында,
Берәү—юл чатында;
Кемдер—уртасында,
Кемдер—җир астында.

Үлемсез, дип, Җирдә
Бары Үлем генә,
Күпләр ята гүрдә
Сабыр—түзем генә.

Ә вакытка чик юк:
Бакый агып тора...
Куя сәгать сугып,—
Вакыт ашыктыра!

Тора безне көтеп
Серле билгесезлек:
Кемне—күңелсезлек...
Кемне—үлемсезлек!

## Сабыр канатлары

Сабыр канатлары—авыр канат,
Тоела иңгә алар таш кебек;
Ташлар идем йолкып-аергалап,
Тыгыла күзгә кайнар яшь килеп...

Хәл үзгәрмәс чөнки аңа карап,—
Ни буласын беләм аннан соң:
Элеккедән ныграк әрнеп-канап,
Җанда күбрәк яра каласын.

Җитми торып үзе шундый чиккә
Минем хәлне кеше аңлармы?..
Күтәрмиләр һич тә алар күккә,
Мин күтәреп йөрим аларны!

Киң иңсәмдә гел авырлык тоеп,
Килгәндә дә кайчак еласым,
Йөрим түзеп, үз-үземне тыеп:
«Күпкә түздең, азга чыдарсың!..»

Сабыр канатлары—авыр канат,
Авырлыгы аның—бәхәссез;
Әмма авырдан да авыр газап:
Яшәү җирдә өмет-канатсыз.

Сабыр канатлары—авыр канат,—
Сыный икән, әйдә, сынасын...
Каерылса да алар кабат-кабат
Һәм торса да канап... сынмасын!

## Синсез гомер—утсыз күмер

Тирән күлгә төнлә ай төшә лә,
Вак балыклар уйный сай төштә;
Син балык та түгел, ай да түгел,
Син кайда соң, җаный, кай төштә?

Айда дисәм, булмас иде ул гел
Сагышлы да болай, моңсу да.
Суда йөзсәң, вак балыклар түгел,
Уйнар иде нурлар тын суда.

Синсез инде... менеп айны китеп
Төшерерлек мәлгә җиттем мин!
Диңгез-күлне, биек күккә элеп,
Киптерерлек хәлгә төштем мин!

Йә син үзең кайтып күрешкәнче,
Йә мин үзем табып күргәнче,
Мин эзләрмен сине йә үлгәнче,
Йә тереләй утка кергәнче!..

Тирән күлгә төнлә ай төшә лә,
Вак балыклар йөзә сай төштә.
Әллә җирдә яшим, әллә күктә,—
Ялгыз башым, белмим, кай төштә?!..

## Таш калыпта, тимер кысада...

Шәһәргә хас: «йортлар-әрҗәләр»,
Буш кәрәздәй нурсыз тәрзәләр,
Пәрәнҗәдәй котсыз пәрдәләр...

Тимер ишек, тимер челтәрләр
Ышыгында төрле кемсәләр
Тилмерешеп гомер кичәләр.

Күршеләрен күрми күршеләр,
Кеше хәлен белми кешеләр,—
Кемдә имеш, кемнең эше бар?

Өшеп җаным, дер-дер калтырыйм:
Күршеләрем миннән ачтыр, дим,
Ишекләрен ничек ачтырыйм?!

Кемнәр алар: баймы, ярлымы?
Күңелләре моңлы-зарлымы?
Керемнәре юклы-барлымы?

Яталармы хәмер-сыра эчеп...
Саталармы әйбер, урлашып...
Кайталармы хаер сорашып...

Бу шәһәрдәниләр генә юк!
Бу мәхшәрдә кемнәр генә юк?!
...Коерыклы җеннәр генә юк!..

Ирештек, дип, хөрлек, ирекка,
«Тавык күзе» куеп ишекка,
Бикләнгәннәр кереп «читлекка».

Кемгә хаҗәт мондый татарлык,
Тәкәбберлек, милли таркаулык
Һәм куркаклык,—шаклар катарлык!

Әле һаман «ала каргадан»
Алачагын ала алмаган
Татар халкын... Алла каргаган.

Фаш булудан очып котлары:
«Без,—дип,—бары Алла коллары»,—
Яшн посып акча кортлары!

Һәм мин килдем катгый карарга:
Ымсынсам да балга-майларга,
Ярлыларга... хәтта байларга

Бирер идем соңгы тиенемне,
Сакласалар Туган телемне,
Сатмасалар туган Илемне...

## Хат

*Рафаил Газизовка*

**Рухи җәүһәрләрне табып ал да,
Ап-ак кәгазьләргә җәеп сал;
Ап-ак кәгазьләргә җәеп сал да,
Караларын сайлап җыеп ал.**

**Ал да тагын чүпләп сарыларын,
Тирәнгәрәк яшер, төпкәрәк—
Кара кайгы, сары сагыш барын—
Халкың күрми торган төшкәрәк.**

**Артык вагын, китек-ватыкларын
Ераккарак куй син, эчкәрәк:
Илнең киләчәге—сабыйларның
Кулы җитми торган төшкәрәк.**

**Ә сафларын—манып күз нурыңа,
Керсез хисләреңә төреп син,
Өләш үз халкыңның үз кулына,
Энҗе-сәйлән итеп тезеп син!**

**Шунда гына тынычланган кебек
Булыр җаның, менә күрерсең!
Чынлап та син энҗе тапкан кебек
Елмаеп һәм балкып йөрерсең.**

**Ихлас Хозыр Ильяс шикелле син,—
Кемлегеңне беләм төгәл мин;
Бик тә кешелекле Кеше бит син:
Үзең—шагыйрь, үзең—мөгаллим!..**

## Калган эшкә кар ява

*Ялган оптимистларга*

**«Бүгенге хәлләр ал да гөл,
Артта—чәчәк, алда—гөл...»
Юк, алай түгел, болай ул:
Әллә күмер, әллә көл...**

**Керәндәй ачы әремне
Төргәндәй күк чәчәккә:
Сылтап барсын күрәчәккә,
Калдырмыйк киләчәккә!**

**Элек: «бәхет—алда!»—диеп,
Түрәләр күп чакырды;
Ә ул көлеп, һаман биек
Үрләргә күчә торды.**

**Без әле дә юанабыз:
Күрер, дибез, алда күз...
Дивана без... булалмабыз
Күпләребез анда без!**

Әнә шундый хәлләрдә без,
Менә шундый хәлдә без;
Бүген безне алдамагыз,
Үзегезне алдагыз!..

## Йорт казы

Ак каурый сыман кар яугач,
Йөрәгенә кара кан саугач,

Ут капкандай йөри ана каз:
Күпме кар йотса да аңа аз...

Бәбкәләрен аның кем алды?—
Бер иртәдә барысы югалды!

Ишек алды бушап тын калды,
Дөнья тулып сагыш-моң калды...

Сөйләр иде барсын—теле юк,
Яшьсез еламаган көне юк.

Кыйгак-кыйгак, диеп, какъ-какъ, дип,
Ул үзенчә гүя: «кайт-кайт!»—дип,

Чакырса да күпме өзелеп,
Кайтмас инде алар тезелеп.

Әле кайчан гына: «пип-пип»—дип,
Туган йорттан ерак китмик, дип,

Читкә таралышып бетмик, дип,
Әнкәйләрне ятим итмик, дип,

Җәй үткәнче башта үстеләр,
Кыш җиткәнче ашта пештеләр...

Якты көннәр казга—кара төн,
Канатканчы чукый канатын:

Канат нигә—күктә очмагач,
Бәбкәләрен көн дә кочмагач?!

Карый күккә үксеп йорт казы:
Ник булмадым мин, дип, кыр казы?!

... Әле кайчан җитә яңа яз?..
Тәгәрәпләр китә ана каз.

## Дәрвиш

Дәрвиш булып, йөри җил куып дип,
Тик юләрләр генә уйларлар...
Йөрмәс идем: башны идерерлек,
Яшьне койдырырлык уйлар бар!..

Табигатьтә күк-гарештән иңгән
Сихри нурлар, серле ымнар бар;
Бик тирәннән, бик ерактан килгән
Ыңгырашкан аваз-өннәр бар.

Очраса да якын танышларым:
Кара каен, кара аккошлар,
Тыңласам да кәккүк тавышларын,
Арта гына бара сагышлар.

Сәхраләрдә гизәм, әрәмәдә...
Мәҗнүн микән, мәхлук микән мин:
Аңлаталмыйм һаман адәмнәргә
Сак-Сокларның... кәккүк икәнен!

Тибрәнәдер дисәм талда былбыл,
Шырык-шырык көлә саескан;
Юкка чыккан былтыр үскән бер гөл,—
Шул сагыштан чишмә саеккан.

Аңсыз инсан кылган кансызлыктан
Шомланалар сыман аланнар:
Кемдер соңгы тамчы канын сыккан,—
Сызланалар сынган баланнар.

Язлар саен яшәрсә дә хәят,
Картайталар аны хаиннар:
Йә бер яра, йә бер җөй-җәрәхәт
Җирдә һәрбер адым саен бар!

Лаф орса да кеше: «Мин—Кеше!»—дип,
Табигатьнең теле-теше юк.
Ә көче күп!.. Тик ул тора түзеп:
Чыкмасын дип юкка кешелек...

Кырылмасын, диеп, киек-кошлар,
Корымасын, диеп, яшь каен,—
Сез аңларсыз микән мине, дуслар,—
Сәрхүш булды газиз башкаем!

Кайда йөрсәм, шунда мин чит илдә
Йөрим гүя—упкын читендә;
Сөйләнәбез әле дә без чит телдә,
Чиләнәбез тормыш төбендә...

Ниләр күрдем дә мин, ни күрәмен:
Бөтен ямен җуйган тирә-юнь.
Тоеп Җир-әнкәнең үксегәнен,
Сулык-сулык елый йөрәгем!

Көтеп ярдәм, багам мин күкләргә,
Күтәреләм үрдән—үрләргә;
Күтәрелгән саен мин үрләргә,
Төшәм сыман гүрдән—гүрләргә.

Кайда да шул: телләр, сүзләр белән
Әйтеп булмый торган ымнар бар;
Тетрәндергән, үзәкләрне өзгән,
Мөлдер-мөлдер аһәң-моңнар бар.

... Күпләр, карап Әҗәл күзләренә,
Килә торыр, китә торырлар...
Җирсеп йөргән җылы эзләремә
Сандугачлар оя корырлар!..



# Шәмсия Җиһангирова

## ДӨНЬЯ БУЙЛАП ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

### Ходайга ялварам иң элек

Яралы җанымны бәйләп куйган
Төеннәрем китсә өзелеп,—
«Рәхмәтеңнән мине ташлама...»—дип,
Ходайга ялварам иң элек.

Дөнья тулы кеше арасында
Ялгыз башым йөрсәм тилмереп,—
«Җәзалама ялгызлык белән...»—дип,
Ходайга ялварам иң элек.

Башкаема урын табалмыйча,
Ят иңнәргә куйсам иелеп,—
«Гөнаһларым ярлыкагыл...»—диеп,
Ходайга ялварам иң элек.

Чарасызлыкларга түзалмыйча,
Күз яшьләрем койсам илереп,—
«Сабыр арты сабырлыклар бир...»—дип,
Ходайга ялварам иң элек.

Күз яшьләрем кибә, җан төзәлә,
Йөрәгемә килә җиңеллек,—
Бар икәнен, бер икәнен белеп,
Ходайга ялварсам иң элек.

Әгәр мине Ходай ташламаса,
Беләм авыр чаклар үтәсен.
Чарасызлыклардан чара табып,
Морадыма бер чак җитәсем.

Кич саен юатам үземне:
«Иртәгә башкача көн туар!»
Барысы да булыр, дим, башкача,—
Торса да каршымда таш дивар.

**Баш төнлә шәп эшли! Шаккаткыч!**
**Бернинди киртә дә юк миңа!**
**Иртәсен, күземне ачуга,**
**Каршымда—кичәге таш дивар!**

❧

**Чыгыйк та без япан кырларга,**
**Тергезик икәүләп бер учак.**
**Кайгырма, ягарбыз кайгыны—**
**Миндә бит Шатлыклар бер бөртек,**
**Кайгылар бер кочак... мең кочак...**

**Китик тә исемсез илләргә,**
**Тергезик икәүләп бер шәһәр.—**
**Миндә бит бер бөртек Шатлык бар—**
**Нигезгә салырга шул җитәр...**

**Меник тә иң биек тауларга,**
**—Кил!—диеп дәшик без Бәхеткә...**
**Тормышта аерым булсак та,**
**Салырбыз башны бер ләхеткә...**

**Аһ!**
**Ник икән адәми затларга**
**Акыллар керә би-и-и-ик соңарып?!—**
**Юк шул ул безгә тиң юлдашлар,**
**Исемсез юлларга чыгарлык!..**

❧

**Син упкынның кырыенда инде.—**
**Ярты адым калган очарыңа.**
**Тик шулай да сыенасың килми**
**Минем сөю тулы кочагыма.**
**«Сабыр итче,—дисең,—сабыр итче.**
**Әйдә, тагын бераз гына көтик...»**
**Без болай да инде, көтә-көтә,**
**Көтүче хәленә калып беттек.**
**Нәрсә әйтим?! Рәхмәт инде сиңа—**
**Сөю кадерен белмәгәнең өчен.**
**Чакырылмаган кунак булып килдем,**
**Шул ук тамга белән кире китим.**
**Ишлисең бит, ышанасың килми**
**Язмыш үзе биргән бу шатлыкка.**
**...Сау бул инде. Соңгы сүзем сиңа:**
**«Ялгызлык иленә—мең фатиха!»**

❧

**Рәнҗемә миңа, инәкәем,**
**Хат язмыйча тилмерткәнем өчен,**
**Җәяү барып җитмәс җирдә яшәп,**
**Сагындырткан, көйдерткәнем өчен.**

Рәнҗемә, денсез булмасам да,
Уразалар тотмаганым өчен,
Бала чакта башка сабак укып,
Намазларың отмаганым өчен.

Рәнҗемә ак чәчләрең өчен,
Йокысыз үткәргән төннәр өчен...
Рәнҗемә, күз нурымны түгеп,
Үстергәнмен, диеп,ниләр өчен.

Рәнҗемә: «Әнисе янына,—дип,—
Онытты бу—елга бер кайтасын...»
Онытмадым!!! Һәр көн куркып яшим...
Белеп яшим... Кемне югалтасым!..

Гомер буе тар сукмактан
Йөреп арылган иде.
Олы юлга чыгармын, дип,
Һаман барылган иде,
Тәмам арылган иде.

Кая барып бәрелим, дип,
Карап торылган иде.
Башым белән таш диварга
Барып орылган иде,
Еглап торылган иде.

Олы юлга килеп чыккач,
Сукмакларым тарайды.
Дошман түгел, дусларның да
Күңелләре тарайды,—
Шуны белү ярады.

Син инде «үлгән» идең...
Мин сине «күмгән» идем...
Онытырмын. Кабат искә
Төшермәм, дигән идем.

Аклы күлмәгемне салып,
Караны теккән идем...
Исемеңнең һәр хәрефен
Җилләргә сипкән идем...

Исемеңнән, җисемеңнән
Тәмам бизенгән идем...—
Юньлелеккә түгелдер бу
Диеп, сизенгән идем.

...Хәрефләп җыеп, исемең
Җилләр кире китерде,—
Сине өзелеп яратуым
Кабат искә төшерде.

Дөрли-дөрли дөрлимен дә
«Гөлт»ләп кинәт кабынам...
Яратам сине! Яратам!
Сагынам! Үлеп сагынам!

Казып алам җисемеңне
Күңелем зиратыннан...—
Сөеп була, үлеп булмый
Икән—«үлгән» артыннан...

Күз күрә. Колак ишетә.
Тел бар исемең дәшәргә.
Шулай булгач, үлмик әле!
Әйдә! Кабат яшәргә!

Кемнәр белә: бәлкем, минем гомер
Сезгә озак кебек тоелыр...
Тупаслыкка бәрелеп,
Әрле-бирле сугылып йөрер дә ул,
Булмаган да кебек җуелыр.

Сизмәсләр дә минем юк икәнне,—
Барлыгымны белмәгән кебек...
Кемдер юксынганда,
Икенчеләр, азмы андыйлар, дип,
Авыз ерып, торырлар көлеп.

Кемдер сорар: «Кем иде ул?»—диеп,
«Ят кешеме, бер-бер танышмы?»
Мин әйтермен:
—Мин идем ул...—диеп,—
Сугылып чыккан идем сезнең янга,
Дөнья буйлап үтеп барышлый...

Факил Сафин

# ҖАЕК БУЕ—ЯУ ҖИРЕ*

**Тарихта җуелмас эзләр бар...**

ОРЕНБУРГА КИЛЕП тө, кайчандыр мәшһүр "Хөсәения" мәдрәсәсе урнашкан бинаны күрми китү гөнаһ булыр иде. Беренче мәртәбә бу якларга аяк баскан кеше буларак, өлкәнрәк кешеләрдән мәдрәсә хакында сораша, юл белешә башладык. Төгәл әйтүче юк. Урыслар җилкәләрен генә сикертәләр, татар чалымнары булган кешеләр, озаклап безнең гозерне тыңлап торалар, тик алар арасында да мәгълүматлы кешеләр очрамады. Йөри торгач өлкә дәүләт архивы урнашкан йорт янына килеп чыктык. Борынгы бинага урнашкан архив хезмәткәрләре безгә теләп ярдәм итәргә булдылар. Алгы бүлмәдә бераз көтеп торырга кушкан яшь кенә ханым, ун минутлап кайдандыр ниндидер белешмәләр алгач, тәфсилләп, мәдрәсәнең кайдалыгын аңлатып бирде.

"Хөсәения" мәдрәсәсе Киров урамының Фучик бакчасына барып төртелгән почмагында, сулга борылып керүгә беренче бина. Тау ташыннан җеген-җеккә китереп, гаять осталык белән эшләнгән өч катлы бина. Әйткәнемчә, бина почмагында зур булмаган тактада әлеге йортта 1918-1919 елларда Муса Җәлилнең белем алуы бәян ителә. Кайчандыр бу бинаның татар халкына чын мәгънәсендә хезмәт иткән, йөзләгән алдынгы карашлы мәгърифәтчеләр, милли кадрлар әзерләп чыгарган "Хөсәения" мәдрәсәсе булуы хакында бернинди истәлек тактасы юк. Бүген анда Оренбур Агроуниверситетының агрономия факультеты урнашкан.

Ишек төбендә "даһи дарвинист" А.К.Тимирязов (1843-1920) бюсты тора. Гомумән, татар яшәгән төбәкләрдә бу галимнең исемен "яраталар". Уфа педагогия институты да әлеге галим исемен йөртә иде. Хәзер ничектер.

Бинаның эченә үтәбез. Коридорлар киң, түшәмнәр биек. Иркен баскычлар буйлап укытучылар, яшь егетләр, кызлар —ниндидер йомыш белән килеп чыккан (август башы бит) студентлардыр инде, ашыкмый гына гапләшә-гапләшә өскә менеп баралар. Аларның бездә бер гамьнәре дә юк шул. Кайчандыр мәдрәсә утарын төзүдә катнашкан Шарлык районы Мостафа авылы кешеләре даһи артистыбыз Хәлил Әбҗәлиловның әтисе Галиулла оста, Муса Җәлилнең әнисе ягыннан якын кешеләрдән саналган Хаммат Сәйфетдинов, тагын дистәләгән миллəттәшләребез —таш, агач осталары һәм, билгеле, бинаны салдырган атаклы Хөсәеновлар әлеге хәлгә битараф кала алмаслар иде. Җаннары әрни, рухлары рәнҗидер аларның.

---

* Ахыры. Башы 7 нче санда.

Каршыбызга каравылчы—урта яшьләрдәге тәбәнәк буйлы бер урыс адәме килеп басты. Урысларга хас булганча, бераз гына кызмача. Кем керер дә, кем белән тел чарлап алырмын, дип, зар-интизар булып торган чагына туры килдек. Сораша, җавап та көтми, сөйли; безнен ни нәрсә кызыксындыруын чамалап алуына сөенә инде үзенчә:

—Әйе, әйе, бу бай Хөсәеновлар йорты. Монда элек татарлар укыган, муллалар укыткан,—ди ул белдекле кыяфәт белән.—Көн саен диярлек килеп, карап йөриләр сезнең братва. Менә шулай басып торалар да китәләр.

Бергәләп ишек алдына үтәбез. Марат аганың әтисе Әхмәтсафа Дәүләтьяров шушында укыган. Мәдрәсә утарындагы тулай торакта яшәгән, ашханәсендә тукланган. Хәзер ишек алды ташландык хәлдә. Кайчандыр төзек ансамбль тәшкил иткән: өч катлы төп уку корпусы (ел саен анда биш йөздән артык кеше белем алган), таш мәчете (ул мәчет хәзер яхшылап реставрацияләнә), имам өе һәм мәдрәсәнең хезмәткәрләренә исәпләнгән ике катлы торак биналардан тора. Хәер, кайбер биналарның стеналары ишек алды ягына бүселеп чыккан, җимерелеп бара. Каравылчы, томанлы карашы белән шул җимерекләргә сәер вәкарьлек белән карап торды да, тавышын басып сөйли башлады:

—Беләсезме, бу бинага юкка килеп йөрмиләр татарлар. Миңа узган ел кемдер әйтте, мәдрәсә астыннан дүрт якка җир асты юллары үтә икән. Менә шушы подвалдан төшеп китәсең дә, Урал елгасы буена, күрше ишек алдына барып чыгарга була икән. Калган икесе кайсы якка китәдер, белгән юк. Хәзинә яшергән дип сөйлиләр Хөсәеновлар монда, кызыксынучылар бар...

—Дөрес,—дидем мин аның үз хәбәреннән тыны кысылып калуын күрмәмешкә салынып,—без гаять кыйммәтле хәзинә чыгарылган урында торабыз. Кызганычка каршы, ул хәзинәне инде эзләп табып та, кире кайтарып алып та булмас кебек...

—Табарлар, әллә кемнәр бар бит дөньяда.

—Бирсен Ходай, иншалла, шулай була калса бик яхшы булыр иде дә...,—дип, без чыгу ягына борылдык.

Татар балаларына белем бирү Оренбур шәһәре төзелгәннән соң ук башлана. 1744 елда шәһәрдә татар балалары беренче мәчет каршындагы мәдрәсәдә белем ала башлыйлар. Анда солдатка алынган татарларның балалары укый. Беренче мәчет князь Волховский чорында төзелә. Шиһабетдин Мәрҗани күрсәткәнчә, мәчетне Бохараның кәрванбашы Иш исемле кеше төзеткән, аңа казна да күпмедер ярдәм иткән. Иш тархан дәрәҗәсе ала. Бохарадан Оренбурга беренче тапкыр кәрванбашы булып килүче (ягъни Рәсәй белән сәүдә мөнәсәбәтләрен тергезергә теләк белдерүче беренче сәүдәгәр дип уйларга кирәк)—шушы кеше була. Аның улы Хаҗи Назарбай Оренбурда Габдессәләм мөфтинең кызына өйләнә. Безгә мәгълүм булган Оренбур имамнарының иң элеккесе—мелла Ибраһим бине Түләк исемле зат... Мелла Ибраһим югарыда телгә алынган Котлымөхәммәд мирзаның имамы иде. (Котлымөхәммәт Тәфкилев), —дип яза Мәрҗани хәзрәтләре.

Тарихчылар К.Тәфкилевне (1675-1766) чукынган татар—Александр Иванович Тәфкилев дип йөртәләр, 1763 елда, Казакъ ханы Нургали патша Екатерина II дән, Тәфкилевне Оренбурга кайтарып, казакъ-кыргыз мәсьәләләре белән шөгыльләнүен сорый. Күрәсең, татар-башкортларга рәхимсез булган Тәфкилев казакъларга йомшарак кылангандыр. Э.Нигъмәтуллин әйтеп киткәнчә, аны Оренбурга кайтармыйлар. Коллегиянең Тәфкилев турындагы белешмәсендә болай язылган: "Оренбургка кайтырга, анда идарә итәргә ул бәлки бик теләп кайтыр иде, әмма аның ислам динендә булуын күрә торып моңа юл куярга ярамас". Күренгәнчә, чукынсаң да, патша хадимнәренә ярап булмый икән...

Халыкның исә Тәфкилевкә нәфрәте чиктән ашкан. "Тәфтиләү бәете" моңа ачык мисал:

...Әхмәт мирза амбарындин алты чучка таптылар,
Әхмәт мирзаның муенына тугыз крест тактылар.
Тәфтиләүнең җирләре барысы да өчпочмак,
Әхмәт мирза почмагында алтыны бар бер кочак.
Әхмәт мирза атлары барысы да кан җирән,
Туймас булып йөргән идең, туйдыңмы инде, карт бирән.

Тәфкилев татар генералларыннан ялгыз булмый. Оренбур төзелгәч, Неплюевның хәрби мәктәбе төзелә. Анда татар-башкорт балалары да белем ала. Мәсәлән, татар-башкорт мәгърифәтчесе Мөхәммәтгалим Өметбаевның шушы Кадетский корпус дип аталган уку йортында белем алган чорында анда полковник Салихҗан Кукляшев белән берлектә, генераллар Мирсалих Бикчурин, Баймөхәммәт Айчуваков та укыта. Вакыфлар комиссиясендә генерал-майор Гобәйдулла Чыңгызов исеме билгеле.

"Хөсәения" мәдрәсәсенә нигез салучы бертуган Хөсәеновлар Әхмәт (1837-1906), Мөхмүт (1839-1910), Гани (1839-1902) Гали Хөсәеновның уллары. Гали Хөсәенов урта куллы сәүдәгәр, сәүдә эшләре белән йөргәндә читтә үлеп кала. Уллары авырлык белән, хәерчелектә үсәләр. Иң өлкән малай Әхмәт иң элек авыр эшләрдә эшләп тиенен тиенгә җыеп, сәүдә эшен башлап җибәрә. Аңа энеләре кушыла. Хөсәеновлар фамилиясе, сәүдәгә нисбәтле рәвештә, беренче мәртәбә 1886 елда документларда күренә башлый. Шушы елда, Сеет бистәсе мещаннары Әхмәт Гали улы Хөсәенов, кырык җиде яшьтәге һәм үзенең хатыны, туганнары Габделгани (кырык алты яшь), Мөхмүт (кырык яшь)шулай ук хатыннары, балалары белән Оренбур казна палатасы тарафыннан ике гильдияле купецлар сословиесенә күчерелә. Беренче гильдиягә күчкәч Хөсәеновлар 1889 елда мәдрәсә ачып җибәрәләр. Чорына күрә иң белемле, алдынгы карашлы мөгаллимнәрне эшкә тарталар. Шуңа күрә мәдрәсә тиз арада җәдитчелек үзәкләренең берсенә әверелә. 1905 елда мәдрәсә телгә алынган яңа бинага күчә. Мәдрәсәдә белем алган тарихчы Зәки Вәлиди, Сәгыйть Рәмиев, Ильяс Кудашев-Ашказарский, Мирхәйдәр Фәйзи, Афзал Таһиров, Шамил Усманов, Шәехзадә Бабич, Кәрим Хәкимов, Муса Җәлил, Әхмәтсафа Дәүләтьяров, Шамун Фидаи, Тәхфәт Ченәкәй, Мөхәммәт Гали, Ярлы Кәрим, Сәгыйть Агиш, Гариф Гомәр, Сәлах Атнагулов, Гыйбад Алпаров һ.б. бик күпләрнең исемен атарга мөмкин булыр иде. Һади Такташ та мәдрәсәгә килеп йөри. Мәдрәсәне барлыгы ике мең илле шәкерт тәмамлый. Укытучылар арасында Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинов, Шәриф Камал, Харис Фәйзуллин, Муса Бигиев, Зәки Вәлиди, Сәгыйть Сүнчәләй, Сәгыйть Рәмиев, Габдрахман Сәгъди, Җамал Вәлиди, Борһан Шәрәф һәм башкаларны атый алабыз. Гаяз Исхакый да 1902-1903 елда шушы мәдрәсәдә укыта башлый. "Сәгыйть Рәмиев белән Гаяз Исхакый шушы мәдрәсәдә 1902 елнын көзендә очрашалар,—дип яза Ч.Зарипова. Әмма заманына күрә шушы алдынгы мәдрәсә дә Гаяз Исхакыйны канәгатьләндерми. Ул дусты С.Рәмиевны гаҗәпләндереп, икенче елга бу мәдрәсәгә эшкә килми. Әмма 1905 елда С.Рәмиев тә бер төркем шәкертләр белән мәдрәсәне ташлап чыга." Үзе дә Оренбурның "Вәли хәзрәт мәдрәсәсе" шәкерте булган, паспортында күрсәтелгәнчә "башкорт мишәре" Галимҗан Ибраһимов исеме Оренбур белән тыгыз бәйләнгән.

"Иң нык болганыш Оренбургның "Хөсәения" шәкертләре белән була"—дип яза Г.Ибраһимов.—Бөтен 1906 ел буенча бу хәрәкәт киңәйде. Шуннан бераз вакыт үтүгә, иң алдынгы саналган "Хөсәения" мәдрәсәсеннән кырыклап шәкерт мәдрәсәне ташлап чыктылар." Чынлык та, бу шәкертләрнең гомум шаукымга кушылулары гына дип карарга кирәк. Мәдрәсәдә белем бирү, тәрбия эшләре шактый югары дәрәҗәдә оештырыла. Моны үз чорының танылган мәгърифәтче-язучылары да таный. "Ялгыз Оренбургта Хөсәеновлар һиммәте илә ислах ителеш бер мәдрәсәдән азчак мәгариф кукысы килмәктәдер,"—дип, яза Фатих Кәрими. Совет чорында да, алтмышынчы еллар уртасына кадәр,

мәдрәсә дипломы педагогия техникумы белемен раслау документы буларак рәсми гамәлдә йөри.

1918-1919 уку елы тәмамлангач, ул "Хөсәеновлар укытучылар институты" итеп үзгәртелә. Ә 1921 елдан ул дүрт уку йортына (бер бинада) бүлгәләнеп—татар, башкорт, казах, шәрыкъ халыклары мәгариф институтлары рәвешендә яши башлый.

Бу тарихи бина янынннан киткәндә, күңелдә әрнүле хисләр уянды. Бүген күп уку йортлары дәүләт ярдәме белән дә яши алмый. Үз чорында шундый зур һәм мәртәбәле эшне татар авылы Каргалыда туып-үскән Хөсәеновлар никадәр белекле, алга карап эш йөртеп, башкарып чыкканнар бит. Югыйсә, Әхмәт бай яза да белмәгән диләр...

## "Чикылдап торган татар" "Каруанһарайда"


БАШКОРТ ХАЛКЫНЫҢ "Көрван-Сарай" дигән борынгы җырында мондый юллар бар.

> Айкай да гына чайкай, ташлар вата,
> һай кем, ташлар вата,
> Көрван да гына сарай, ай, салырга,
> һай кем, ай далада...

Даны еракларга таралган күп бәхәсләр, җәдәлләр чыганагына әйләнгән Көрван-сарай турында бу җыр.

"Йөз мәртәбә ишеткәнче—бер мәртәбә күргең яхшы" диләр. Шушы сүзне истә тотып, "Көрван-сарай"ны да күреп китәргә булдык.

Әлеге тарихи бинаны шәһәрнең Бакча (Парковая) урамыннан эзләп таптык. Без бина янына килеп җиткәндә ике кеше Көрван-сарай мәчете маңгаена язылган "Караван-һарай" дигән сүзләргә карап нидер сөйләшәләр, фикерләшәләр иде. Астарак әлеге бинаның башкорт халкының тарихи архитектура истәлеге икәнлеген искәрткән сүзләр дә язылган иде. Мәчеткә үтәргә ниятләп торганны күреп алгач, көләпүшле кеше үзе үк безне мәчеткә чакырды:



*Көрван-сарайның бер өлеше*

—Хуш киләсез, кардәшләр, өйдә үтегез, үт,—диде ул, башкортча. Ул мәчетнең имамы икән.

Кайсы яклардан килүебезне сораштырганнан соң, Татарстаннан икәнне белгәч, имам янындагы икенчесе, мәчетнең яңарту, безгә өчен җаваплы хадимнәрдән иде булса кирәк, безне мәчетнең төп бинасына алып керде.

Сөйләве башкортча булганлыктан, аның сүзләрен татарчага әйләндереп бирәм инде.

—Мәчет башкорт тирмәсенә охшатып эшләнгән. Гөмбәзле стеналарда Коръән сүрәләре,—диде ул.—Башкорт халкының гыйбадәт йорты. Элек ул ташландык хәлгә җитеп килә иде. Хәзер менә төзәттек, яңарттык. Витражлар эшләдек. Бина борынгы башкорт җирендә урнашкан,—дип тә өстәде.

Минем сөерсенүле карашымны тотып алгач, ашыгып өстәп тә куйды:

—Әйе, әйе, бу борынгы башкорт җире. Башкорт дәүләтчелегенең үзәге. Оренбург өлкәсе тулысы белән башкортныкы!—дип кистереп үк куйды.—Кәрван-сарайны да башкортлар үз акчаларына төзеткәннәр. Бөтен Башкортостаннан акча җыйганнар. Иң беренче төзелгән башкорт хөкүмәте дә шушы бинада урнашкан. Монда элекеге башкорт хансәрләренең-кантоннарның Баш идарәсе булган. Яндагы корылмалар да башкорт хөкүмәте бинал
ары. Аларын әле кайтарып аласы бар, безнең кулда түгел. Кәрван-сарайга килгәндә бакча күрдегезме? Элек утыз алты гектар булган ул. Агачларын махсус рәвештә Стәрлетамактан алып килеп утырткannar. Башкорт агачлары!—Сөйләүче бу мизгелләрдә тарихи горурлык хисләре кичерә иде йөзе алсуланып китте.

Хәерле булсын, без тыңлап тордык та, сәфәр намазлары укыганнан соң, ишек катындагы бүлмәгә чыктык. Ишек төбендә үк аркылы өстәл артында имам утыра. Аның каршысында ике яшь кеше—ир белән хатын мәчеткә хәер китерә килгәннәр. Имам сорашып, Аллаһ бәндәләренең өлкәнең бер районыннан килгәннәрен белеп алгач:

—Әһә!—диде, тавышына серле төсмерләр чыгарып.—Сез башкортлар. Ата-бабаларыгыз да, үзегез дә, туганнарыгыз да башкортлар. Башкорт йортына килеп, мәчеткә садака бирүегезгә бик тә рәхмәт,—дип догалар укып, хәернең бирелү суммасын бер биткә теркәп куйды. Аннан, аларны стена буендагы, дини китаплар, догалыклар, күз тиюдән саклый торган (хәзрәт әйтте) төрле вак-төяк таратып салынган икенче өстәл янына әйдәкләде.

Баш имамлыкны да, мәчет садакасын җыюны да, сәүдә эшләрен дә берьюлы алып бара хәзрәт.

Чират безгә җитте. Мондагы хадимнәр һәр ике сүз саен мәчетнең башкорт йорты булуын төкрарлап торсалар да, җир шарының кайсы төбәгендә төзелүенә карамастан мәчет—Аллаһ йорты булуын истә тотып, без дә мәчеткә сәдака бирдек. Имам безне өстәл янына чакырып, фамилия, исемнәрне сораша башлады. Иң беренче нәүбәт минеке иде. Исем, фамилиямне ишеткәч, хәзрәт күзен чепиләндереп өч кенә сүз әйтте:

—Чикылдап торган татар!

Марат аганы исә, һич икеләнүсез башкорт милләтенә "кушып" куйды:

—Сез—башкорт, үзебезнеке! Дәүләтьяров—башкорт!

Чаллыдагы милли хәрәкәттә актив катнашучы Марат ага, бу кадәр тәвәккәл раслаудан аптырап, кулларын бутап алды:

—Юк, мин татар! Каргалыдан безнең нәсел, татар авылыннан...

Аның сүзләрен хәзрәт артык тыңлап тормады, үзенә кирәген генә эләктерде:

—Әйе, әйе, Каргалы да безнеке, үзебезнең кешеләр. Дәүләтьяровлар күп анда. Бар алар!

Шулай итеп Кәрван-сарай мәчетеннән Марат ага белән "икебез ике милләт кешесе булып" чыгып киттек. "Каргалы башкорт"лары турында сүз чыккач , бер тарихи мәгълүмат: 1814 елда Сәет бистәсе сәүдәгәрләренең балаларын башкорт исеменә язалар.

Тарихи дөреслек өчен әйтеп китик: Кәрван-сарайны "Казан утлары" журналының 1999 ел алтынчы санында филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов "Фатих Кәрими мирасында яңа сәхифәләр" дигән мәкаләсенең, искәрмә өлешендә: "Кәрван-сарай—Оренбур шәһәрендәге атаклы татар мәчете бинасының исеме" дип күрсәтә.

"Кәрван-сарайлар—XIV йөзләрдән алып, Урта Азиягә баручы сәүдә юлларында төзелә башлаган җәмгать биналары",—диелә кайбер белешмәләрдә. Кәрван-сарай Казанда да, башка шәһәрләрдә дә, төбәкләрдә дә булган. Равил Әмирхан Кәрван-сарай хакында белешмәдә болай яза: "Мәгълүм булганча, Кәрван-сарай беренче чиратта, Шәрекъ мәдәниятенә хас төшенчә. Ул кәрван йөртеп сәүдә кылган малчылар

өчен истирахәт кылу (ял итү), рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү урыны да булган. Бу җәһәттән Кәрван-сарайны кардәш төрки кавемнәрнең— татар, башкорт, кыргыз, казакъ һәм башка халыкларның аралашу, сөхбәтләшү (әңгәмә кору), алыш-биреш итү, мал алмашу, икътисади хаҗәтләрен үтәү өчен уртак сарай булган дисәк, шаять хаталанмабыз."

Оренбур зур сәүдә юлына урнашканлыктан, монда төрле төбәкләрдән килүче-китүче малчы-сәүдәгәрләр күп булган, аларның бөтен шәһәр буйлап таралып урнашулары шәһәр идарәсе эшләренә шактый мәшәкать тудыра. 1836 елда Оренбур генерал-губернаторы В.А.Перовский башкорт һәм татар кантоннары башлыкларына мөрәҗәгать итеп: "Оренбургка үз йомышлары һәм хөкүмәт эше белән килүче башкорт һәм татарларның шәһәрдә тукталу өчен бернинди дә урыны юк. Шушы кыенлыкны бетерү өчен, мин җәмәгать йорты, ягъни Кәрван-сарай төзи башларга җыенам. Анда барлык татар һәм башкортлар бернинди түләүсез торып китә алыр иде,"—ди. 1836 елның 21 апрелендә В.А.Перовский Түбән Чебенле авылы мулласы татар кешесе(!) Габдулла Дәүләтшинга барлык кантоннарны йөреп чыгып, Кәрван-сарайны төзү өчен хәйрия ярдәме оештыруны йөкләү турында фәрман җиткерә. Перовский кантон түрәләренә җиткергән мөрәҗәгатендә шундый кисәтүне дә кирәк дип таба: "Мулла Абдулла Давлетшин, снабженный от меня особыми видами и сборной шнуровой книгой, имеет поручение объехать все башкирские, мещерякские кантоны и собирать взносы единоверов своих, записывая каждое приношение в книгу за подоятеля.

Во избежание всяких неуместных толков, нелишним считаю еще присовокупить, что приношения эти совершенно зависят от воли каждого мусульманина и что никаких принуждений в этом отношении со стороны старших и начальников делать не следует".

Габдулла Дәүләтшин иганә җыюга ике елдан артык вакыт сарыф итә, ягъни кантоннарны йөреп чыгу 1838 елның көзенә кадәр сузыла. Фәкать унберенче кантонның өч авылына гына барып җитә алмый Габдулла мулла, чөнки бу авыллар олы юллардан читтә һәм анда барып та өлле-ни майтарып булырлык түгел—авыллар кечкенә була. Габдулла Дәүләтшин барлыгы 15895 сум 95 тиен иганә җыя.

Ш.Мәрҗани Кәрван-сарай мәчетенең Оренбурдагы өченче мәчет булуын, 1843 елда башкортлардан акча җыеп төзелеп, 1845 елда ачылуын әйтә. Равил Әмирхан: "Корылма, татар-мишәр һәм башкорт халыклары хәерҗәте һәм көче белән салынып, нигездә шул милләт кешеләренә хезмәт итәргә тиеш була,—дип яза...—Ул мәчет, зур бакча (әлеге дә баягы "башкорт агачларыннан" тергезелгән бакча турында сүз бара), күп санлы ярдәмче каралты-бүлмәләрдән гыйбарәт бинаны тәшкил итә".

1841—1842 елларда Кәрван-сарай төзелешенең төп эшләре тәмамлангач, анда башкорт-мишәр гаскәре командующиеның канцеляриясе урнаша. Патша хөкүмәте 1798 елның апреле карары белән Уфа губернасында идарәнең кантон системасын гамәлгә ашыра. Халыклар (нигездә башкортлар һәм мишәрләр) хәрби-казаклар сословиесенә күчерелә. Башкорт-мишәр гаскәрләре төзелә. Мондый идарә 1865 елларга кадәр, ягъни Уфа губернасыннан Оренбург губернасы аерылып чыкканчы дәвам итә.).

Кантоннар башта уникe була, ә мишәрләр аерылып гаскәр буларак теркәләләр. 1812 елдан соң мишәр кантоннары белән башкорт кантоннары берләшеп, унҗиде кантон барлыкка килә. Тарихи дөреслек өчен искәртеп китик, мишәрләр катламына ясаклы татарларны да, башка милләт кешеләрен дә язып куюлары билгеле... Башкортлардагы мишәрләр үзләрен татар дип, урта диалектта сөйләшүчене типтәр дип, хәтта Казан ягы авылларындагы татарларны да Казан типтәрләре дип атыйлар." (Д.Рамазанова). Ревизия вакытларында халыкны милләте буенча түгел, социаль катлам буенча исәпкә алу киң тарала. Ә инде югарыда телгә алынган мишәр-башкорт янәшәлеге турында бераз тукталу кирәк булыр.

Башкорт галимнәре үзләренчә үтә "нечкәлек" белән бик тә четерекле эшкә алынмакчы булып азапланалар. Алар, гөнаһ-язык турында уйлап тормыйча, татар халкын эчтән таркату нияте белән зур "ачыш"лар ясау юлына бастылар. Мондый имансызлыкның бер мисалы итеп Рим Янгузинның кайбер "гыйльми фикерләрен" укучыларга җиткерәсе килә:

"Возникает вопрос: почему именно наряду с башкирами вначале только мишари были переведены в военное сословие, хотя они составляли по численности незначительный процент населения Башкирии? Чтобы ответить на этот вопрос, вкратце надо напомнить историю мишарей. В 1794 г. мишарский депутат Уложенной Комиссии Абдулкадыр Абдулкаримов "с товарищами" обратился к генерал-прокурору с прошением. В нем говорилось: "Мещерятский наш народ прежде других иноверцев по собственному своему желанию, переселевшись из Золотой Орды в Росссию еще в 1493 г., за верныя и беспрочныя предков наших российскому скипетру службы как при взятье Казани (1552 г.—Р.Я.), так и при других многих тогдашнего времени случаях, жалованы были в разных местах на нагорной стороне Волги полисадными дачами и для населения их выгодными землями и угодьи". (Ә.З.Әсфәндияров, "Башкортостандагы мишәрләр кемнәр? // Башкортостан, 1999. 22-29 октябрь). Итак, по мнению депутатов, мишари являются самостоятельным народом и активно участвовали на стороне Ивана Грозного во взятии Казани.

Распространенное мнение, будто бы мишары являются татарами, не соответствует исторической действительности. Мишари по языку, быту и культуре отличаются от татар, хотя и близки к ним. Недаром среди современных мишарей замечается преобладание, в отличие от казанских татар, понтийского антропологического типа. Почти все крупные этнографы России связывает мишарей с древним финноугорским именем "мещера", жившим в бассейне Средней Оки и впоследствии тюркизированным. Мишари это особая тюркская народность. Неслучайно, как в дореволюционных переписях, различных статистических учетах, так и в переписи 1926 г. мишари фиксировались, и совершенно справедливо, своим этнонимом, т.е. как мишари. Процесс окончательного формирования мишарского народа был приостановлен политикой советского государства. В переписи населения 1939 г. и последующих переписях мишарей начали причислять к татарам. Следует, однако, подчеркнуть, что сегодня не только в мишарских деревнях, но даже и у городских мишарей , живущих изолированно от основной мишарской массы, сильно развито национальное самосознание. Они называют себя мишарами, а не татарами, подчеркивая этим свое иноплеменное происхождение."

Менә шулай. Этнография өлкәсендә янә бер "мичуринчы"—Рим Янгузин пәйда булды.

Нинди нәтиҗә килеп чыга соң? Элекке Уфа губернасында (хәзерге Минзәлә, Актаныш, Мөслим, Әгерҗе якларын да кертеп) башкортлар гына яшәгән, анда татар дип аталучы кавем—асылда—башкортлар, мишәрләр—исә—башкортларның рухи туганы. Башкортларның барлык кайгы-хәсрәте, күргәннәре өчен Казан тирәсендәге өч-дүрт район җирендә яшәүче Казан татарлары гаепле. Бөтен явызлыкның башы шуларда. Алар эксплуататорлар, төрки милләтләрне изеп торучы баскынчылар. Р.Янгузинча уйласак, бүгенге татарның ягъни Казан тирәсендә яшәүче кавемнең хәле мөшкел, бик мөшкел була түгелме соң әле?

Бөтен гаепне татардан күреп, саташучыларга Ш.Бабич болай дип җавап бирә:

Әй мирза, керфек астың калынайган,
Синең күздә күренәдер: "Татар хайван!"
Әйтимме? Бу кайдан килә? Ачуланма!
Күкрәгеңдә кяфер рухы тамыр җәйгән!..

Бу сүзләр башкорт милләтчеләренә дә кагыла.

Бу төбәктәге күп җирләрнең XV гасыр ахырында XVI гасыр башында ук Казан ханнары биргән ярлыклар нигезендә татарлар тарафыннан үзләштерелүе мәгълүм.

1847 елда Оренбур аша Орск шәһәренә солдат хезмәтенә—сөргенгә җибәрелгән Т.Г.Шевченко: "Мин Сакмар елгасы аша чыккан вакытта кояш яңа гына баткан иде әле. Еракта иң элек күземә мәчетле һәм бик матур манаралы зур алсу төстәге бина күренде."—дип яза. Бу—Кәрван-сарай мәчете булган.

Сарай төзелеп беткән көннәрдә Оренбурга яңа губернатор В.Обручев дигән кешене билгелиләр. Әлеге бәндә—татар-башкорт кавемен сөймәс кеше булып, Кәрван-сарай төзелеп бетүгә, аны төп хуҗаларыннан—татар, башкортлардан тартып алып, яртысын үз квартиры итә, яртысына губерна канцеляриясен урнаштыра. 1865 еллардан башлап сарайның тартып алынуы халык арасында ризасызлык тудыра, һәрдаим бинаны кайтарып бирү мәсьәләсен кузгатып торуга, ызгышларга сәбәп була.

Октябрь түнтәрелеше чорында, Оренбурда барган күп вакыйгаларның үзәге Кәрван-сарайда була.

Фатих Кәрими турындагы истәлекләрдә шундый хәл тасвирлана: "Февраль революциясе булгач, Кәрван-сарайда булган зур бер митингта карагруһлар Фатих абзыйга һөҗүм итеп "үтерергә кирәк, бөтен дөньяны айкатучы шул Фатих", дип кычкыргач, Фатих абзый трибунага чыгып, башындагы эшләпәсен салып: "җәмәгать! Минем бу чәчләр нигә агарган?"—дип батыр нотык сөйләгән иде."

Бу чорда башкорт халкының дәүләтчелеге өчен көрәш лидерларының берсе Әхмәтзәки Вәлидинең (1890-1970) гамәли сәяси эшчәнлеге Оренбур белән тыгыз бәйләнгән. 1917 елның беренче октябрендә Оренбур казаклары гаскәре (ОКВ) атаманы булып А.И.Дутов сайланган гадәттән тыш хәрби җыенга егерме бишенче сентябрьдә үк Зәки Вәлиди котлау телеграммасы җибәрә. Башта Вәлиди һәм аның тарафдарлары бер якка да кушылмау сәясәтен алып баралар. "мы не большевики и не меньшевики, мы лишь башкиры. На какой же стороне мы должны быть? Ни на какой. Мы на своей собственной стороне... Двухмиллионный башкирский народ не может быть игрушкой в таких ничтожных политических забавах. У него должны быть свои нужды, свои потребности, своя политика, своя точка зрения". Бу сүзләр язылган беренче санлы Указга 1917 елның унберенче ноябрендә кул куелган. Ноябрь башында З.Вәлиди өч карта-схема төзи. Аларның берсе—"Кече Башкортостан", икенчесе—"Олы Башкортостан" һәм өченчесе—"Көнчыгыш Россиянең мөселман өлкәләре автономияләре Союзы" карталары. Башкортостан өлкә шурасының 1917 елның унбишенче ноябрендәге икенче санлы фәрманы белән "Кече Башкортостан" чикләрендә Башкортостан автономиясе игълан ителә. Әлеге автономиягә Оренбур, Пермь, Самара губерналарында яшәүче башкорт төбәкләре һәм Уфа губернасының бер өлеше керә.

Шушы ук көннәрдә, 1917 елның егерме икенче ноябрендә Уфада Милләт Мәҗлесе эшли башлый. Мәҗлес озак бәхәсләрдән соң төрки-татарларның Идел-Урал штаты рәвешендә территорияле (җирле, тупраклы) мохтариятен игълан итә, ягъни милли дәүләтчелекнең нигез ташын сала. Милләт Мәҗлесе кабул иткән резолюциядә (1917 ел, 29 ноябрь) шундый пунктлар да бар:

1. Русия идарәсе кушма җөмһүрият булырга тиеш.
2. Русия штатлары эчендә Уфа, Казан, Оренбур губерналары вә боларга чиктәш башка губерналарның төрек-татарлар торган кыйсемнәренә кергән бер штат (җөнүби Урал вә Идел буе штаты булырга тиеш).
3. Бу даирә эчендә аерым кечкенә штатлар булмаска тиеш.

Башкортлар белән сөйләшүләр алып бару өчен "тупраклы мохтарият комиссиясе" тарафыннан Оренбурга Г.Ибраһимов җибәрелә.

Милләт Мәҗлесенең депутатларының кайберләрен искә төшерик:

Шәриф Манатов, Фатыйх Мөхәммәдьяров, Шәһит Әхмәдиев, Сәлах Атнагулов, Сәет Вахитов, Шәйхулла Алкин, Галимҗан Шәрәф, Абруй Сәйфи, Зыя Камали, Хәсәнгата Габәши, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Шонаси, Гаяз Исхакый, Фатих Кәрими, Закир Кадыйри, Галимҗан Баруди, Риза Фәхретдин, Мөхлисә Буби һ.б., һ.б.

Милләт Мәҗлесе сайлаган милли идарә 1918 елның 21 апрелендә Совет хакимияте тарафыннан бетерелә, шул сәбәпле Милләт Мәҗлесенең икенче съезды үткәрелми, ул яшәүдән туктый. (Д.Госманова "Милләт мәҗлесе тарихы"). Хәзерге чордагы милли мәҗлес дип аталган оешма Милләт Мәҗлесенең дәвамчысы түгел.

"Бер якка да кушылмаган" Вәлидичеләр дүртенче февраль төнендә (1918 ел) кызыллар тарафыннан кулга алыналар һәм бәхетенә каршы З.Вәлидине дүртенче апрельдә казаклар кинәт һөҗүм ясап, төрмәдән коткаралар, ә июль аенда Оренбур янәдән дутовчылар кулына күчә. Дутовка Чиләбедән шундый эчтәлектәге телеграмма килә: "Оренбурны золымчылар хакимиятеннән азат итүегез белән котлыйм. Штабыбыз һәм бер яки ике полк белән Оренбурга кузгалабыз. Полклар өчен ике казарма өзерләвегезне сорыйм. Шулай ук Кәраван-сарайны Башкорт шурасы һәм хөкүмәте өчен тулысынча саклап торуыгызны үтенәм... Валидов" өченче октябрьдә З.Вәлидов ОКВ ның III съездында чыгыш ясап, Кәрван-сарайның сулъяк өлешен Башкортостан хөкүмәте өчен бирүләрен сорый. Шунысы кызык, генерал-лейтенант А.И.Дутов З.Вәлидовның үтенечен канәгатьләндерсә дә "Кәрван-сарайның һәм аның тирәсендәге биналарның башкортларга тиешлеген раслаучы рәсми документларның булмавын" күрсәтә.

Амбицияле З.Вәлидов "Олы Башкортостан" төзү идеясеннән кайтмаган һәм Оренбурны башкортларның пайтәхетенә әверелдерергә теләгән. 1918 елның икенче декабрьгә каршы төндә Кәрван-сарайда киңәшмә җыеп, дүрт башкорт полкын күтәреп, атаман Дутовны кулга алып, гаскәрләрне Учредитель Собраниясенә кушу хакында план кора. Әмма уртак фикергә килә алмыйлар, 1919 елның февралендә Вәлиди башкорт гаскәрләренең бер өлешен алып, кызыллар ягына чыга.

"Идел-Урал штаты" идеясе сүнми, "Үзәк мөселман" эшләре буенча комиссариат Мулланур Вахитов соңрак С.Сәидгалиев Ленинны "татарлар белән башкортлар бер үк халык",—дип ышандыралар һәм 1918 елда Татар-башкорт республикасы төзү күздә тотыла башлый. Моңа башкорт милләтчеләре каты каршылык күрсәтәләр, башкорт авылларына җибәрелгән татар мөгаллимнәре һәм мөгаллимәләре, табиблар, башка зыялылар ерткычларча үтерелә. Шушы хәлләрне истә тотып, Рәсәй хөкүмәте 1919 елның егерменче мартында "Кече Башкортостан" чикләрендә Башкорт Совет Республикасын игълан итә. Баш шәһәре итеп Стәрлетамак билгеләнә. Башкала Стәрлетамактан фәкать 1922 елда гына Уфага күчерелә.

Уфа губернасын Башкортостанга кушуның үтә четерекле нәрсә икәнен башкорт милләтчеләре үзләре дә аңлыйлар. Бу җирләрдә татарлар яши, анда кайчан да булса башкортлар гомер кичергәннәрме, юкмы, әйтүе кыен. Башкорт шагыйре Давыт Юлтый Совет хөкүмәтенең киң күңеллеләнеп Кече Башкортостанга тулы бер татар губернасын "бүләк" итеп бирүенә сөенеп: "Олы Башкортостан" шигырендә болай дип яза:

Ач көннәрдә, безне үгисетми,
Ярдәм итте кулдан килгәнчә;
Инде Өфене дә безгә бирде,
Барысы да булды безнең дигәнчә...—

Шагыйрь "кайчандыр кулдан киткән" җирләрнең кире кайтуын үтә дә хуплап язса да, мондый тарихи "гаделлек"нең бик шикле булуын чамалый булса кирәк, чөнки сөенечкә төп сәбәпче: совет хөкүмәтенең губернаны нәфселәре уйнаклаган башкорт дуслар кулына бирүе. Тарих, хакыйкать, гаделлек турында сүз алып барылмый. Кемендер башкорт

Республикасының зур территорияне билəп торуын күрəсе килгəн, совет хөкүмəте аны канəгатьлəндергəн һəм шуның белəн вəссəлам, "хəзер ярлы йорт иркенəйде", яшə генə.

Ə менə Зəки Вəлиди бу хəлгə бик тə пошына —1922 елның егерменче февралендə Ленинга язган хатында З.Вəлиди болай яза: "по... Соглашению (от 20 марта 1919 года) у Башкортостана должна была быть собственная армия, подчиненная непосредственно центральному Советскому командованию. Ныне по Постановлению от 19 мая 1920 года, наши войска лишены этого статуса, переподчинены Заволжскому военному округу, командованию которого представлено такие права по своему усмотрению дробить и переформировывать башкирские военные части. Фактически эти войска перестали существовать. На основании подобного же Постановления вы "Уфимскую губернию присоединили к Башкортостану", на деле эта лукавая мера означает не что иное, как присоединение Башкортостана к Уфимской губернии." Хаттан күренгəнчə, башы-аягы белəн "Идел-Урал" штаты төзүгə каршы булган, чыгышы белəн үзе язганча "Əстерхан нугае булып, Юрматы башкортларына (Д.Рамазанова билгелəп үткəнчə Юрматы кабилəсе—саф татар телендə сөйлəшүче болгар кабилəсе) кушылган" З.Вəлиди Уфа губернасының, анда яшəүчелəрнең күпчелеге татарлардан торган гавамның Башкортостан өчен нинди проблемага əйлəнүен яхшы аңлаган. Эмиграциягə киткəч тə "Идел-Урал штаты" идеясен яклаган Гаяз Исхакый, Фуат Туктаровлар белəн Зəки Вəлиди, истəлеклəреннəн күренгəнчə, дошманлык дəрəҗəсенə җиткəн бəхəстə була, "татар интеллегентларын" күрə алмавын ачык сиздерə.

Уфа губернасын Башкортостанга кушып, Совет хөкүмəте, (хəзер Рəсəй империясе дə) нəкъ менə З.Вəлиди сызган юлдан баралар. З.Вəлидине куркыткан "бергəлек" идеясен, ясалма башкортлаштыру идеясенə алыштырып, империячел көчлəр ике тугандаш халык арасына əле җəрəхəте озак гасырлар буена сызлап торачак зур чөй кактылар. Башкорт миллəтчелəре, һəм ике якта буталып йөрүче татар провакаторлары бу җəрəхəтне тагын да тирəнəйтəлəр, алар аңлы рəвештə империягə хезмəт итəлəр.

Мулланур Вахитов белəн Шəриф Манатов (Наркомнац. əгъзасы) Ленинннан изге Госман Корьəнен, Казандагы Сөембикə манарасын һəм Оренбурдагы Кəрван-сарайны мөселманнарга, хезмəт халкына кайтарып бирүне сорыйлар. Совет хөкүмəте 1917 елның тугызынчы декабрендə изге Госман Корьəнен (ул 1869 елда Сəмəркандагы Хуҗа Əхрар мəсҗиденнəн аз акчага сатып алына һəм, Петербургта саклана) Уфа диния нəзарəтенə кайтара. (1923 елның август аенда Риза Фəхретдин җитəкчелегендəге өч кешелек махсус вəкалəт Корьəнне Төркестан хөкүмəтенə—Ташкентка китереп тапшыра.) Ə 1918 елның егерме җиденче гыйнварында Сөембикə манарасын һəм Кəрван-сарайны мөселманнарга кайтару хакында карар кабул ителə.

Бу вакыйга уңаеннан Ш.Бабич та үзенең сөенечен белдерə:

Азат булды Кəрван-Сарай,
Азат булды барлык җирлəрең...
Җырлап җибəр сөенеп, уйнап курай,
Чыксын тизрəк шатлык җырларың.

Кəрван-сарай башкаласы Оренбур булган Кыргыз республикасы карамагында да була, анда соңрак педтехникум урнаша. 1953 елдан соң мəчет бинасында планетарий оеша. Фəкать соңгы елларда гына мəчет мөселманнарга кайтарып бирелеп, ул тəмам "башкортлаштырыла". Ə башка биналарга Оренбур өлкəсенең табигатьне саклау идарəсе, геология идарəсе урнашкан. Алар аннан чыгып китəргə җыенмыйлар да.

Ə инде тарихи гаделлекне эзлəүчелəр табыла калса, Кəрван-сарай "башкортлар акчасына төзелгəн" дигəнгə, "башкорт кавеме кем соң ул?" дип сорау куеп, аларның, иренмичə, "Казан утлары" журналының 1993 елгы 3 санын табып алуларын һəм Дəррия Рамазанованың "Урал буе татарлары: тарихы һəм теле" дигəн гаҗəп дəлилле мəкалəсен җентеклəп укып чыгуларын телəр идем.

Шөехзада Бабич ялган юл белән баруны болай суретли:

Алма ат, "алдакчы" дип, көкрене турыла, алдама!
Тиз таярсың, алдасаң, алдау юлы бик бозлы юл.

Кәрван-сарайдан чыккач, үземнең "чикылдап торган татар" булуыма сөенеп (чөнки башкорт галимнәре мин туган элекке Минзәлә өязендә "татарлар юк, гел башкортлар гына яши" дип баралар бит), ә Марат ага кинәт кенә "башкортлашып" китүенә гаҗәпсенеп-аптырап, дәшмитынмый гына алга атладык.

Моннан 1250 еллар элек үк Аристотель: "Вакыйгалар буталчык һәм көтелмәгәнчә үсештә булган саен трагедия тамашачыларны ныграк җәлеп итә" дигән фикер әйткән. Без сөйләгән хәлләрне гадиләштерү дә, белә торып бозып, буташтырып күрсәтү дә шулай ук трагедия—фаҗига ул. Рухи фаҗигабез. Кәрван-Сарайны да, тулаем Оренбур төбәген дә аерым бер халыкныкы гына дип күрсәтергә тырышу ни башкортларга, ни татарлар өчен файдага түгел. Чөнки тарих конкрет фактлар белән генә эш итә, хисләр кайчан да булса сүреләчәк, ул чагында бүгенге ясканулар көлке генә булып калачак. Җаек буйлары—уртак җирләр, уртак рухи байлыклар, уртак тарихыбыз. Юрганны тарткалый торгач, бөтенләй юргансыз калу ихтималы юк түгел.

## Каргалыда бер кыз үскән...

БИБИҖАМАЛ ӘБИНЕҢ өстәлендә "Яңа вакыт" гәзите, күзлек һәм ни сәбәптер һаман йөрүеннән туктамаган "хан заманындагы" будильниксәгать. Күп йортларда күргәнем бар —бу сәгать фәкать йөзе белән өстәлгә капланып ятса гына текелди. Әбинең сәгатендә шундый ук чир. Капланып яткан да саный вакытын әбинең. Аңа 86 яшьне бирмәссең. Хәтере әйбәт, хәрәкәтчән, күзе күрә. Шуңа күрә дә аңа "Биба апай" дип дәшәләр туганнары. Хәер, әби дигәнне ул үзе бик үк өнәп бетерми бугай. "Күзе күрә" диюем дә Биби апайның маңгай күзләре хакында гына әйтүем түгел. Минем әңкәй китап укый, яза белүчене, дини йолаларны белеп үтәүчеләрне, "күзе күрә" дип сөйли. Ягъни андый кешенең маңгай күзе генә түгел, күңел күзе дә күрә. Шундый кешенең генә "күзе күрә", укый-яза белмәсә, дини мәсьәләләрдә надан булса андый кеше инде "тома сукыр".

Биби апайның Оренбур уртасындагы бер бүлмәле фатирында утырабыз. Апай күптән күрешмәгән туганнары белән очрашуына сөенеп бетә алмый, озаклап дога кылды, изге теләкләр яудырды. Теләк теләүдә апай шундый остарган ки, җаваплы, саваплы һәм җитдилекне таләп итә торган әлеге шөгыль вакытында күңелгә "келт" итеп Камал театры сәхнәсендә "Чикерткә Гыйльмениса"сын уйнаган Вера Минкина килеп төште дә, елмаю хисе кузгалды да куйды бит әй! Биби апайның тавышы да, сөйләшү рәвеше дә, төс-кыяфәте дә мәшһүр артистканы хәтерләтә. Бу тышкы охшашлык кына әлбәттә. Ә инде Биби апайның башыннан кичкәннәр—үзе бер кыйсса.

Биби апай җәһәт кенә урыныннан кузгалып, кухняга чыгып йөгерде, ду китереп кунакларга—Марат ага, Әхмәт һәм Мохтар аңа туган балалары тиешле кешеләр инде, чәй әзерләргә кереште.Без дөнья хәлләре турында сөйләшүгә күчтек. Әңгәмәнең җебен тотып торучы кеше—Биби апайның игелекле улы Равил Галиев иде. Равил абый, әле алтмышны үтеп кенә барса да, пенсиягә чыгуына байтак икән инде, озак еллар Себердә, Красноярск краенда эшләгән. Югары белемле инженер бүген дә заводта эшләвен дәвам итә, үзе әйткәнчә, акчасын бирмичә тоткарласалар да, азмы-күпме ашамлык, башка кирәкярагын биреп куйгалыйлар икән.

—Пенсиягә генә яшәрсең,—ди ул ачынып.

Равил ага Галиев Енисей елгасы буендагы ябык шәһәрдә, зур төзелештә эшләгән.

—Шәһәр дигәнең—җир астында иде,—дип искә ала ул.—Тауны тишеп ясалган. Иртән, кичен халык эшкә агыла, Оренбур, Казан каласы сыман гөж килеп тора. Электричкалар чаба "шәһәр" буйлап. Ә мин төзелештә "верхолаз"—минем гаҗәпләнеп карап торуымны күреп, ачыклый төште,—әйе, биеклектә эшләүче монтажник идем. Җир астындагы "верхолаз" ягъни. Йөзәр метр биеклектә эшләдек. Менә шуннан чамала инде, энекәш, ул җир астындагы шәһәрнең ни хикмәт зурлыгын. Андагы күргәннәр... Казахстаннан уран рудасын китерәләр, аны тиешенчә баетып, хәрби эш өчен куллануга яраклы рәвешкә китерәләр иде безнең шәһәрдә. Заводны төзегәндә производство калдыкларын утильләштерергә, яки ныклап яшерү өчен корылмалар эшләнмәгән булып чыкты. Радиацияле суны, башка зарарлы чүп-чарны кеше күзеннән читтә торган тау куышларына тутыра башладылар. Алар тулгач, зарарлы матдә Енисей елгасына агып чыга башлады. Балык кырыла, якын тирәдә яшәүче халык нишләгәндер, безгә караңгы... Ул тирәдә иленнән кубарып, куып җибәрелгән халык яши иде авыллар төзеп. Татар авыллары да бар иде. Менә шушы кешеләр өстендә сынадылар инде ул радиация дигән нәмәрсәнең тәэсирен. Аннары тау араларында галәмәт чокырлар казып, кургаш белән катлап, калдык суны шунда агыза башладылар. Күрәсең, табигатькә зыян "галим"нәр уйлаганга караганда күпкә куркынычрак булгандыр, югыйсә, чыгымнар тотып азапланмас иделәр. Дөресен әйтәм, ул "кургаш тартмалар" да мәңгелек түгел, берзаман "җен" барыбер дөньяга чыгачак...

Чәйләр эчеп алгач, инде Биби апайның башыннан үткәннәрне ишетү насыйп булды.

—Мин Каргалыда туып-үскән кыз идем,—дип сөйли башлады Биби апай, күзләрен тәрәз аша күренгән ак болытларга төбәп.—Һай Каргалы-ы... Гөрләп торган авыл иде бит ул. Урам буйлап сәүдә йортлары тезелеп киткән. Алар белән янәшә таштан эшләнгән складлар. Көн саен өллә кайлардан олаулар мал-товар алып кайталар. Бушаталар, төйиләр—мәш киләләр инде. Урам тулы бала-чага. Сакмар хәзер саекты ул. Элек тирән иде, бөтерелеп-бөтерелеп ага. Көннәр буе сал агызганнарын карап, хәйраннар калып утыра идем. Әхмәтсафа абыем да берара сал агызучы булып эшләде. Яшүсмер генә иде әле ул чакта.

Әтием—Мостафа сәүдәдә йөрде. Ул мал белән сәүдә итте. Тирә-йон җыйды. Безнең нәселнең борынгыдан килгән эше. Кушаматыбыз да "каеш" бит. Гражданнар сугышы башланганда миңа биш-алты яшьләр тирәсе булгандыр инде. Яхшы гына барган тормышның асты-өскә килде. Миңа өч яшьләр тирәсендә әнием үлде. Әткәй үги әни алып кайтты. Бик миһербанлы булды әңкәебез безгә. Әле дөньялар тыныч чакта, әткәй өйдә бик тормый. Өйдә дүрт малай, бишенчегә—иң кечесе—берләнбер кыз мин идем. Малайлар бик шаяннар, сүз көрәштерәләр, сугышып та китәләр—бусы да Каргалының бер холкы булгандыр. Авылда гомер-гомергә мәдрәсәләр эшләп торды бит. Кайдан гына килми иде шәкерт. Уннан артык мәчет, һәр мәчеттә ике имам. Ул мәдрәсәләрдәге хәлфә, мөдәррисләр арасында кемнәр генә булмагандыр. Күренекле ишаннар Каргалыда да булган, якын-тирә шәһәрләрдә дә ишаннар, мөритләр күп иде. Әнә Зәйнулла ишан Рәсүли Троицкида гына иде.

Һәр ишанның үз юлы, ант иткән мәзһәбе, мөритләре бар. Мәдрәсәләрдә еш кына бәхәсләр, җәдәлләр чыгып тора. Ызгышлар да чыккалаган. Шуңа күрә Каргалы халкы холкына кечкенәдән дә шушы гыйбрәтләр сеңеп баргандыр сыман тоела. Аннан гражданнар сугышы башланды. Дутовчылар кайнаша, кызыллар килеп чыга. Тегеләре дә, болары да татарча сөйләшәләр. Һәркайсы, әткәйдән мал-байлык таптыра. Тиз арада тормышның рәте китте. Өлкән абыем Госман унтугыз яшьләрдә иде. Һәр ике як яшьләрне җыеп, үзләре ягында сугышырга куша. Качсалар, әгәр дә тотыла калсалар, Сакмар буена чыгаралар да

аталар "дезертир" дип. Госман абый өй төбсендә—чормада качып ята. Мин моны кайдан белеп алганмындыр инде, гел Госман абый янына түбәгә менә башладым. Менәм дә такылдыйм инде, сөйләшәсе килә абыем белән. Урамда мылтык күтәреп солдатлар йөри. Абый нишләргә белми, иплән кенә аңлата, чормага менәргә ярамаганлыкны. Кая ул, мин көйсезләнә башлыйм, абыйны ирештерәм—"Менә хәзер төшәм дә, солдатларга әйтәм",—дим. Абыйның күзләреннән яшь килә, җаныкаемның, мин һаман аны ирештерәм. Шуннан соң абый бер көн юкка чыкты, Украинага китәргә тиеш булган дип сөйләделәр, миңа аң кергәч. Белмим, кайсы якларда, ничекләр юкка чыккандыр, ул башка авылга кайта алмады. Үземне шушы бала шуклыклары өчен әле дә гафу итә алмыйм.

1919 елларда абыйлар авылда комсомол оештырып йөри башладылар. Әткәйне авыл муллалары, картлар бик тә ачуландылар, "динсезләр" дип сүгә башладылар. Әткәй ни эшләргә дә белми, гарьләнә иде. Җитмәсә, шушы ук елны Каргалыда зур янгын чыгып, ике өебез дә янып бетте. (Шуны да өстәп китәргә кирәк, Каргалыда элек тә янгыннар булгалаган. Аеруча 1912 елдагы янгын хакында еш сөйлиләр. Ул елны янгыннан кешеләр елгага төшеп кенә котылып калганнар. Авылны ялмап кына үткән ут давылы. Шушы ук елны Сәгыйть Хәялинның—Каргалыга нигез салган бабаның да өч катлы йорты зур зыян күргән.) Каккан казык та калмады, атларны аклар, кызыллар талап алып бетерделәр. Әткәй безне арбага утыртып, Дунай очына, бәләкәй генә йортка күчереп куйды. Шушы кайгы-хәсрәтләр, авыл кешеләренең кырын каравына түзә алмыйча үзенә кул салды әткәй... Бөтенләй ятим калдык.

Үги әңкәйгә рәхмәт, без исәйгәнче кияүгә чыкмый торды. Югыйсә яп-яшь иде ул. Үндүрт яшь тулгач, мине Хива ягында яшәүче туган тиешле кешеләр алып китеп, бер казакъка кияүгә бирмәкче булдылар. Озын буйлы, чибәр генә егет. "Нугай кызын" бик күзләп йөри, инде ярәшкәч бигрәк көефе күтәрелде моның, теле-телгә йокмый, үз якларына, далага алып китмәкче булды бу. Тимер юл станцасына төштек. Бер дә казакъ даласына китеп эзсез югаласы килми. Инде югалуның ни-нәрсә икәнен беләм. Каргалыны, анда калган абыйларым Гомәр, Әхмәтсафа, Әхмәтханны сагынам. Егете ничава, ну мин әйтәм, казакъ арасына китсәм, миңа кайту юк...

Каян килгәндер тәвәккәллек, поездга утырып киткәч, кияү егете, бер хәбәрсез, кәләшле булдым дип, куанып йөргән җирдән, бер станцада качтым мин. Калдым ялгызым. Ходай ничекләр көч, зиһен биргәндер, тәки кайтып егылдым Каргалыга.

Абыйлар инде үсеп җиткәннәр. Әхмәтсафа абый укып зур кеше булган, ул Казанда. Әхмәтсафа абый мине Казанга укырга дип алып китте. Хатыны Рәбига апа Арча районы Күпербаш авылында укыта, мин дә шундагы рабфак дип аталган җирдә бер ел укыдым. Шулкадәр җайланды тормыш, юк кына бит, Каргалы сагындыра, Гомәр абыйның кызы Фәүзияне үзем карап үстердем—шул баланы сагынуга чыдар әмәл юк—кайтам дип елыйм. Бу инде утызынчы елларның башы.

Адәм баласы рәхәткә түзми, михнәткә түзә, диләр, дөрес икән. Михнәтләрем шуннан соң башланды инде. Каргалыга кайтып төштем, инде шактый дөнья күргән, җиткән кыз мин. Аз-маз белем дә бар. Без, яшьләр кичке уеннар оештырабыз, малайлар арасында үскән кыз буларак бик чая идем. Электән мине белгән яшьтәшләр, "мут идең" дип тә җибәрәләр. Булгандыр инде. Шушы уеннар вакытында бер егеткә күзем төште. Гүәрдиндәй гәүдәле, бөркет карашлы, гайрәтле егет. Уенга ул килсә, барсы да аның авызына гына карап тора. Җитмәсә гармунчы да әле. Төшмәс җирдән төшәр күзең. Ул да миңа битараф түгел. Гел янымда бөтерелә. Киемнәрем дә шәп иде, шәһәр кызы сыман. Яшерен-батырын түгел, егетнең кем икәнен әйбәт беләм. Каргалыдан, Фәтхулла исемле иде ул. Инде өйләнеп, хатын аерган. Әти-әнисе Оренбурга күчеп, шунда яшиләр. Ә Фәтхулла үзе... данлыклы угры, ат карагы. Шөкүр карак шикелле, тирә-якта аны белмәгән кеше булмагандыр.

Каргалыда угрылар күп булган диләр. Белмим, әмма авылның шундый даны чыккан иде. Бөтен тирә-яктан сәүдәгәрләр җыела монда, мал-туар китереп тутыралар. Авыл тирәсендә төн үткәреп, икенче көнне Сакмар күпере аша чыгарып, терлекләрне ары алып китәләр. Ә Сакмар күперен үтү куркыныч иде. Төнен түгел, көндез үтү дә куркыныч инде. Яр буйлары куе әрәмә. Күпергә биек ярдан төшәсе, озын тау сыртына күтәреләсе. Күтәрелгәндә юл буйлап ике якта да куе урман. Угрылар шунда качып яталар да, кешеләргә һөҗүм итәләр. Күп җаннар кыелган җир ул. Шундый җыр бар иде:

Авыллары—Каргалы,
Бар да тимер арбалы.
Каргалыны үткән чакта
Күлмәк-ыштан калмады.

Угрылардан каза күргән кешеләр чыгарган җыр инде ул.

Фәтхулланың да кәсебе шушы. Ат урлап, Җаек аръягына, казакъларга саталар, аларның малларын урлап суялар. Иптәшләре дә үзе кебек гайрәтле. Карап торсаң юаш кына, акыллы гына егет инде менә.

Абыйлар ризалыгы белән Фәтхуллага кияүгә чыгу турында да уйлыйсы юк. Әхмәтсафа абый Казанда зур кеше, Гомәр абый белән Әхмәтхан абый да бик тәртипле кешеләр. Ә мин Совет хакимиятен җен урынына күргән, җитмәсә хатын аерган бер адәмгә кияүгә чыгарга йөрим. Юк, ризалык булмаячак. Сөйләштек тә качып чыгарга булдым Фәтхуллага. Кыш көне, таң атканда качтым мин Гомәр абыем йортыннан. Фәтхуллам шәп атта, толыпка төреп кенә алып кайтты. Өйләнде, әмма кәсебен ташламый гына бит ир дигәнем. Төннәрен чыга да югала. Өчәр көн кайтмый.

Шулай бер кич, тагын иптәшләре килеп керде. Нәрсә булса да була дидем, Фәтхулланың муенына сарылдым: "Бармыйсың, җибәрмим",— дип елыйм, аякларын кочаклыйм. Үзем авырлы да бит әле. Фәтхулла, нинди куркынычлар кичеп тә мондый хәлне күрмәгән кеше, аптырады да куйды. Мин моны сизеп алгач, һаман көчлерәк дулыйм. Фәтхулла мине күтәреп алды да, иптәшләренә, гаепле кыяфәттә: "Бүген үзегез генә барыгыз, күрәсез бит..."—дип кенә әйтә алды.

Ходай белдергәндер, шул төнне Фәтхулланың иптәшләрен тоткан милиция. Шартлатып төрмәгә ябып та куйганнар. Иртүк бу хакта Фәтхуллага хәбәр җиткерделәр. Милиция аны да эзли башлаган.

Фәтхулла шул ук көнне юкка чыкты. Озак вакытлар үткәч кенә Ташкенттан хәбәре килде, мине үз янына чакыра бу. Инде минем кызым—Рауза туган иде. Киттем чыгып юлга. Эш эзләп Бохара ягына чыгып киттек янә. Каракүл районы Җагачи кышлагында урнаштык. Мин алты ай курсларда укып, мөгаллимә булып эшли башладым. Фәтхулла геологлар отрядында, алтын эзлиләр. Шунда янә бәхетсезлеккә юлыктым—тире авыруы башланды. Кышлакта табиб-мазар юк. Инде йөри алмый башладым, аяклар шеш кенә. Ишеттем, Каракүлдә бер мулла бар, ул дәвалый икән. Мулла дип үзбәкләр укымышлы кешегә әйтәләр. Мине ишәккә атландырып, егерме чакрымдагы район үзәгенә алып киттеләр. Барып җиттек, эзләп таптык багучыны. Килешле генә сакаллы, өлкән яшьтәге абзый икән. Кайдан килүемне, кем булып эшләвемне сораша. Мөгаллимә икәнлегемне белгәч, пыр тузып, мине куа башлады: "Йөрмә монда, мин советка хезмәт итүчеләрне дәваламыйм",—ди. Елап та карыйм, файдасы тимәде—куып чыгарды.

Инде нишләргә? Капка төпләренә чыгып утырдым да елый башладым. Чыннан да хәлләр шәптән түгел, авыруым көннән-көн аза. Бик озак елаганнан соң, үзбәккә миһербанлык килде бугай, өендәге бер хатынны чыгарып җибәргән. Хатынның кулында кечкенә савытта кара төстәге мазь-май. Хатын әйтә: "Өйгә кайткач, кызыл сыерның җылы тизәген алып аякларыңа сыла, бәйлә, аннан соң тәзелми калган

төшләренә менә шушы майны сөрт,"—ди. Хикмәти Хода, берни эшләр юк, алар кушканны кыландым. Бер атна дигәндә аякка бастым. Тимрәү юкка чыкты. Ышансагыз ышаныгыз, юк икән юк инде.

Эшләр көйләнеп барганда, Фәтхулланы төрмәгә яптылар. Холыксыз, дуамал кешегә өйләнде ул, мине дә җәберли башлады.

Ике бала белән тагын Каргалыга кайтып киттем. Аннан инде Оренбурга күчеп, озак еллар мәктәптә җыештыручы булып эшләдем. Фәтхулла сугыштан соң, күкрәгенә орден-медальләр тагып кайтты. Килде миңа, тик күңел бер суынса, суына икән ул. Кертмәдем аны йортыма, Каргалыда өйләнеп яшәде, сиксәнгә җитеп вафат булды.

Биби апай хәзер мәҗлесләрдә коръән укып, яшенә-картына дин тәрбиясе, үгет-нәсихәт биреп, вәгазьләр сөйләп, башкаларны туры юлга күндерү нияте белән яши. Үткәннәре гыйбрәтле булса да, хәтирәләрдән җанына юаныч таба, авыр чакларны түгел, гомеренең гүзәл мизгелләрен барлап, яшьлеген сагынып яши. Иң сөенгәне шул, кызы Рауза, улы Равил игелекле булдылар, оныклары үсә. "Фәтхулла дуамал булса да, җанында, канында бер дә начарлык булмагандыр инде, югыйсә балаларым бу кадәр йомшак күңелле, ярдәмчел булмаслар иде,"—ди Бибиҗамал апай.

Хушлашканда яуган теләкләр арасында мондые бар иде:

- Казандагы Шәймиевны бик мактыйлар безнең Оренбурда. Итагатьле, акыллы илбашы. Мәскәү дә аның авызына гына карап тора. Бәхетегез, балакайлар, шундый достуйный кеше кул астында яшисез. Ходаем аңа да исәнлек-саулык бирсен, зиһененнән аермасын. Күрсәгез, Биби апайдан сәлам әйтегез.

Яхшы теләкләргә ни әйтик?! М.Мәһдиев әйтмешли, "едва ли" безгә президент белән күрешүләр. Шулай да, язмам дөнья күрсә, иншалла, Биби апайның сәламе, бәлки, иясенә барып ирешер дигән өметтә калам. Әманәт бит ул.

Каргалыда, Оренбурда да кем белән генә сөйләшмик, сүз Татарстан хәлләренә күчә һәм, әңгәмәдәшләребезнең һәркайсы Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев хакында ихлас җылы хисләрен белдерәләр, Рәсәй сәясәтчеләре арасында иң ышанычлысы итеп аның исемен атыйлар иде. Без аларны горурланып тыңладык, барлык татарларны берләштереп торырлык шундый илбашы булуына чиксез сөендек тә.

## Бикколда бер көн

ОРЕНБУРДАН ЧЫГЫП 70 чакрымлап юл үткәч, уң якта кечкенә бер авыл кала. Бикколь авылы булыр ул. Авылны нигезләгән Биккол баба бу җирләрне ничек эзләп тапкан да, ни рәвешле әлеге җирләргә хуҗа булып алгандыр, миңа караңгы, әмма үтә дә шәп, матур урында Биккол авылы. Буйга сузылган авыл урамы Саелмыш (күп чыганакларда Саилмыш (башкортча һайылмыш) дип языла, Биккол халкы мин язганча әйтә) елгасы ярына кадәр төшкән. Каршыда—биек тау. Тау бите ерактан караганда сипкелләнеп торган сыман, әйтерсең, кемдер бала бияләе кадәр ак ташларны бөтен тауга чәчеп чыккан. Монда да кылганнар, кылганнар. Тауга күтәрелеп, тирә-якка карап, шактый хозурланып та тордык әле. Авылга карап басканда, уң кулда Чаллы ягына илтүче Оренбур трассасы буйлап туктаусыз машиналар чаба.

Юл турында сүз кузгаткач шунсын да әйтим инде, күпме йөреп, кирәксә дә, эче пошканга да машина туктатып шоферга бәйләнеп, машина эчендә актарынып сәфәр кешесен азаплаган милицияне күрмәдек без Оренбур ягында.

Бикколга килгәндә генә, Октябрь районы үзегенә борылып киткән юл өстендә хәрәкәт иминлеген саклаучы милиция хезмәткәре—яшь кенә сержант туктатып, шоферыбыз Рәиснең документларын карап, аның белән күңелле генә әңгәмә корып алды. Сержантның, бигрәк тә,

Татарстан номерын күреп, бераз җанында кузгалган хатирәләре белән уртаклашып аласы килде бугай. Рәистән Татарстан хәлләрен сораштырды, үзенең дә моннан өч-дүрт ел Казанда булуын, башкалабызның аңа ошавын сөйләп, хөерле юл теләп озатып калды. Шоферларның әйтүе буенча, юл йөрү өчен иң хәтәре—Казакъстан чикләрен үткәч башлана икән. Иминлек сагында торучылар Рәсәй ягыннан килгән һәр машина хуҗасыннан күпме булдыра ала, ничек булдыра ала—акча "саварга" тырыша. "Закон да юк, чурт та юк инде",—дип җибәрәләр шоферлар, кайсы катлы-катлы сүгенеп тә куя Җаек артындагы хәлләрне исенә төшерсә. "Казакълар үзбәкләрне дә уздырып җибәрделәр",—диючеләре дә бар. Ярый, Бикколга әйләнеп кайтыйк.

Тау өстендә кайчандыр таш чыгарганнар. Авылда, урманнар булмау сәбәпле, бакча коймалары шушы тау ташыннан өелгән. Кайбер өйләр, келәт-сарайлар да таштан өеп эшләнгән. Мине иң хәйранга калдырганы авыл ягыннан агып ятучы Саелмыш елгасы булгандыр мөгаен. Сай гына, киңлеге—Сакмардан ким түгел. Киң, шактый чиста сулы, тик сай сулы елга ул. Елга яры һәр ике яктан вак таллыклар белән капланган, аръякта яр өстеннән үк матур гына урман башлана. Урман артында авыл халкының бәрәңге җирләре. Монда халык бәрәңгене өй янындагы бакчага утыртуны, нигәдер хуп күрми. Күрәсең, авылны нигезләгәндә оя коручылар җир азлыктан иза чиккәннәрдер. Саелмыш елгасының исемен "сай елга" дип таркатырга булыр иде дә, тик Г.Саттаров "сай" сүзенең "сайлау, сайлап алу"ягъни "яхшысын аерып алу" мәгънәсендә кулланoccurrences хакында әйтә һәм "сай" сүзе төрки телдә "яхшы" мәгънәсен белдерә, ди. Ә инде "илмыш—илмеш—илеш" сүзләре—яши торган җир дигәнне аңлата, бу сүзнең дә борынгы татар телендә булуында шик юк. Шулардан чыгып Саелмыш атамасының—яшәү өчен яхшы булган, сайлап алынган җир дигәнне аңлатуы бер дә гаҗәп түгел. Һәрхәлдә елга атамасына шушы мәгънә кучкән диясе килә.Авылның урнашкан урыны чыннан да бик матур.

Сакмарның Саелмыш елгасы койган уң як төше текә, биек яр. Бу тирәдә ике калкулык. Аларның исемнәре үк күңелгә шом сала—берсе Аскантау (Виселечная гора), икенчесе—Кискәнтау (Рублевая гора), ягъни кайчандыр кемнәрнедер, ни өчендер аскан-кискән җирләр икәнен искәртеп торалар. "Бу каһәрле атамалар,—дип яза Равил Бикбаев,—1740 елның сентябрендә шушында җәзаланган башкортларның истәлеге булып калган. Әлеге вакыйгаларның шаһиты П.И.Рычков үзенең "Ырымбур тарихы"нда болай дип язып калдырган: "Сакмар янындагы бер тауда гына илле кеше асылган, йөз егерме кешенең башы киселгән, аларның хатыннары һәм балалары хезмәттәге кешеләргә таратып бирелгән, болардан тыш өч йөз бер кешене чыбыркы белән ярып, борыннарын кисеп һәм колакларын кыркып (Пушкин сурәтләгән башкорт картын искә төшерик) алганнар..."

Авыл үзе артык зур булмаса да (йөздән артык кына хуҗалык бардыр) ике өлештән тора. Авылга керә торган уң як өлешен "хутор" дип атап йөриләр. Әле биш чакрымлап җирдә тагын Яңа Биккол авылы да бар. Шушы авылдан күчеп, "башка чыгучылар" яши торган бу кече авыл белән иске Бикколлылар уралышып-аралашып яшиләр, мәҗлесләргә йөрешәләр.

Биккол зираты нәкъ Каргалы авылы зиратын хәтерләтә. Кылганлы яссы тау бите, агач-мазар үсми. Фәкать "серле балбаллар"ны хәтерләткән кабер ташлар "урманы" гына монда яшәгән мөселман кавеменең олы тарихын үзендә яшереп саклый сыман. Зиратларның икәү булуы да авылның шактый борынгы булуына ишарә.

Оренбур тирәсендәге авыллар бер-берсеннән егерме-егерме биш чакрымда урнашкан һәм алар патша хөкүмәте тарафыннан ямчы авыллары буларак, махсус фәрман нигезендә бүлеп бирелгән җирләрдә нигезләнгәннәр. Ямчы авылларында нигездә хат-хәбәрләр йөртүче чапкынчылар яшәгән. Чапкынчы атамасы XVIII йөз ахырында телдән

төшә бара һәм аның урынына пушты сүзе кулланыла башлый. 1785 елда С.Хәлфин төзегән сүзлектә пушты—чапкынчы, чапкын—почтарь, гонец дип бирелгәнлеген күрсәтә М.Ногман. Ям авыллары чапкын атларын алмаштыручы почта станциясе хезмәтен дә үти. Жам аты—почта аты буларак борынгы төрки сүздә дә бар. Рус телендәге ямщик сүзе шуннан ясалган. Биккол авылы —борынгы ямчылар авылы.

Авыл Пугачев кузгалышына бәйле рәвештә тарихи чыганакларда телгә алынып китә. Бигрәк тә Салават Юлаев тормышын өйрәнүчеләр тарафыннан искә алына ул. Салават Юлаевның Каргалы мәдрәсәсендә укуын искә алсак бу яклар аның өчен шактый таныш булгандыр.

1773 елның 17 сентябрендә башланып киткән Е.И.Пугачев житәкчелегендәге крестьяннар кузгалышы Бикколга да кагылып үтте. Екатерина II фетнәчеләрне тар-мар итү өчен генерал Кар житәкчелегендә хөкүмәт гаскәрләрен жибәрә. Нигездә казак, татар, калмыклардан торган Пугачев гаскәрләренә каршы патшабикә башкорт старшиналары житәкчелегендә атлыларны жибәрмәкче булып, Уфа провинциясе канцеляриясеннән башкорт яугирлары жыйнап, Пугачевка каршы баручы хөкүмәт гаскәрләренә ярдәмгә, Оренбурга кузгалырга фәрманнар таратыла.

1773 елның октябрендә губернатор Рейнсдорпның шундый әмерен Шайтан-Кадәй волостеның 1768 елда бертавыштан сайлап куелган старшинасы Юлай Аднамин ала һәм, боерыкка буйсынып, отряд жыя. Юлай отрядның башлыгы итеп Салаватны билгели. "Яшь, кызу булса да, атта шәп чаба, корал белән оста эш итә, белемле"дә, ди, Салаватның тормыш юлын өйрәнеп китап язган тарих фәннәре кандидаты В.Сидоров. Белемле димәктән, Салаватның Каргалыда укуын башкорт авторы телгә дә алмый, ә аны авылына килеп укыткан Нәби Кәрими, имеш Салаватка татарча түгел, ә "иске төркичә" белем биргән икән. Нинди тел булды икән ул "иске төрки теле"? житмәсә, "яшьтән үк үтә "башкорт милләтчесе" булган Салават Нәби Кәримине өеннән куып та жибәрә икән әле. Татар булганлыгы өчендер инде.

1772 елда Юлай Аднамин Польша походында катнаша, старшиналык вазифасын Салават башкарып тора. Яуга озатканда Юлай улына шул походта алган медален бирә. Салават сиксән кешелек отряды белән, Пугачевка каршы яуга чыгу өчен башкортлар туплана торган урын—Эстәрлетамак пристанена юнәлә. Анда алар унбиш көн баралар. Губернатор биш мең кешелек гаскәр тупларга боерык бирсә дә, 2355 кеше генә жыела. Жыелма татар, мишәр, башкорт отрядына князь Ураков белән Нугай иле Кыркүл-Меңле волосте старшинасы Әлибай Морзаголов житәкчелек итәләр. Салават үз кешеләре белән Әлибай житәкчелек иткән төркемдә була һәм генерал Карның карательләр отряды белән нәкъ менә Биккол авылында очрашырга тиеш була.

Капитан Ураков һәм Әлибай Морзаголов житәкчелегендә мең ике йөз кешелек отряд, Кар гаскәрләренең башта Мостафага аннан Сарманай тирәләренә чигенүен ишеткәч, унынчы ноябрь көнне Биккол авылы янында Пугачев гаскәрләренә кушыла. Әле Салават Юлаев үзе исән чагында ук, Каргалы авылында ижат ителү ихтимальі зур булган бәеттә бу хакта болайрак аңлатма бирелә:

Жәя тарттым, ук аттым,
Беләккәемә ' ышандым;
Яшь башларымдин яу яуладым—
Пугачау картка ышанып.

Хөкем ителгәндә Салават болай ди: "Бикколга житәргә бер чакрым чамасы калганда, пушкалары булган ике меңнән дә күбрәк Пугачев атаманы Овчинников гаскәре безне камап алып, атакалады һәм кечкә кадәр жибәрми торды. Шунлыктан Әлибай, үзенең пушкалары да булмагач, пугачевчылар аның командасына караганда ике тапкырга күбрәк тә булганга тегеләр ягына ауды, барлык команда да фетнәчеләргә кушылды."

Кар отряды карательләре килә башлагач, башка авыллардагы кебек үк, Биккол авылындагы татарлар да Пугачев ягына качалар. 1874 елның яз һәм җәй авылларында да бу якларгы ирләр баш күтәрәләр. Менә шундый тынгысыз чорларны кичерә, баш бирмәс ирләре, яугирлары булган татар авылы Биккол.

Бикколдагы тугызъеллык мәктәптә 70 укучы белем ала. Мин мәктәпләренә дә кереп чыктым. Анда ремонт эшләре бара иде. Башлангычта татарча гына укыйлар, бишенче-тугызынчы сыйныфларда татар теле предмет буларак керә. Аннары укуны Марьевкадагы урыс мәктәбендә дәвам итәләр, монда, билгеле инде, татарча укыту бөтенләй юк.

Биккол авылы үзәге Марьевкада булган акционерлык җәмгыятенә керә. Күптән түгел идарә рәисе итеп яңа кешене, шул якта туган урыс кешесен куйганнар. "Яңа себерке" нигәдер эшне яхшылап оештырасы урынга, татарларга ябырылган. "Биккол татарларын туздырып бетерәм!",—дип яный икән. Татарстаннан бернинди ярдәм күрми, тау ышыгына сыенып, моңаеп утырган Биккол авылының бүгенге хәле шундый.

Без тукталган фатир хуҗасы Төхвәтуллин Сафа Насыйп улына сиксән яшь. Шулай булуга карамастан, агай әле нык, сынлы, сау-сәламәт. "Нива" машинасына утырып кирәк-яракка якын-тирә авыл-шәһәрләргә дә чаба. Әле без килгәч тә, кызы Тәнзиләне, Биккол мәктәбенең немец теле укытучысы, егерме яшьлек чая кызны район үзәгенә илтеп кайтты. Сафа абзый дөньяның ачысын-төчесен күп күргән кеше. 1941 елда, немецлар сугыш башлагач, иң беренчеләрдән булып сугышка алына. Гомель өлкәсе, Бобруйск каласы янындагы урманнарда август аенда камалышка эләгеп, немецларга әсир төшә. Колонна белән Германиягә куганда, җай чыгып, кукуруз басуы арасына кереп качкан һәм, шундагы бер авылда, украин крестьянкасы йортында ике еллап качып яшәгән. Гел-гел качып ятып булмый, авылдагы итек тегү остасына ярдәмче булып урнашып, бу эшнең шактый остасына әверелгән. Аннан тагын немецлар кулына эләгеп, Германиядә, немец хатыны йортында хезмәтче булып гомер кичергән Сафа агай. "Совет гаскәрләре килә башлагач, немец марҗасы кат-кат әйтте,—дип искә ала ул,—Сафа, кайтма Рәсәйгә. Сезне Сталин исән калдырмый. Әсирләрне анда лагерь көтә. Кал монда, без бит Англия кул астында. Көчләп сине Рәсәйгә бирәү дә кумаячак, ди. Кая ул! Илгә кайтасы килә. Минем үз сүземнән кире кайтмавымны күреп, немец хатыны әй уфтанды да инде. Ире сугышта үлеп калган иде, шуннан калган әйбәт киемнәрне киендереп, үзебезнекеләр ягына озатты."

Сафа агайларны Германиядән ике ай чамасы җәяү кайтаралар совет гаскәрләре сагында. "Этләр белән саклап, Дунай буйлап Одессага кадәр җәяү кудылар,—ди агай, ул "сәяхәтен" искә алып.—Одессага кырык чакрым калгач, вагоннарга төяп, шәһәргә поезд белән килеп кердек. Минем яңа ботинкам тузып, ялан аяк кайтып кердем Совет иленә. Одессада лагерьга озаттылар, фильтрация дип атала иде. Һәр кешедән җентекләп сорашалар, аннан өйгә түгел, Себергә озаталар халыкны. Төп гаеп—әсирлеккә төшү. Мине итекче һөнәрем саклап калды. Бер көнне офицер килеп сорый:

—Арагызда итекчеләр, тегүчеләр бармы?

—Бар,—мин әйтәм,—итекче булам.

Шуннан 1947 елга кадәр баш күтәрми мастерскойда эшләдем. Офицерлар үзләренә итек, хатыннарына яхшы күннән аяк киеме тектерәләр. Мине Себергә озатасы урынга, шушында әйбәт кенә эшләп, яшәп яттым. Аннан өйгә озаттылар.

Авылга кайткач, укытуга кергән идем—хезмәт дәресләре алып бардым—әсирлектә булган дип, куып чыгардылар. Колхозда бухгалтер булып эшли башладым. Уфадан агач кайтарып, өй салган идем, авылның көнчел кешеләре бәйләнә башлагач, мин инде әсирлекнең ни-

нәрсә икәнен беләм, эшне ташладым да, умарталыкка киттем. Пенсиягә чыкканчы шунда яттым. Башым тыныч булды."

Сафа агайга кайгы-хәсрәтләр килеп кенә тора. Алтмышынчы еллар азагында Казан медицина институтында укыган малаен, лекциядән кайтып барганда, хулиганнар пычак белән кадап үтерәләр. Шул кайгыдан укытучы булып эшләгән хатыны да вафат була.

—Олыгаеп килгәндә ишелде кайгы өстемә,—ди ул көрсенеп.—Тормышның яме, яшәүнең тәме китте.Хатынымның ахирәте кәләш димли башлады бер көнне. "Каргалыда Гадилә исемле бик акыллы, уңган ялгыз хатын бар, алып кайт үзеңә Сафа абый",—ди бу. Миңа нинди хатын килсен инде, илле биш яшьлек картка, дип карыштым башта. Димләгән хатын миңа караганда уналты яшькә кечерәк бит. Әйтмәс җиреңнән әйтерсең. "Килер, Сафа абый, ул инде ике тапкыр иргә барып кайтты. Баласы булмый дип, икесендә дә аерып җибәрделәр, дия-дия, теге хатын һаман үзенекен тукый. Ни булса булыр, ялгыз яшәве дә авыр дип, риза булдым. Булачак хатыным, Гадиләне дә ризалыштырган яучыбыз, Алланың рәхмәте яугыры.

Менә шулай, өйләнешеп яши башладык. Ике иргә барып та, бала табу бәхетенә ирешмәгән Гадиләм, миңа бер-бер артлы ике кыз алып кайтып бирмәсенме! Башта Айсылу кызым туды, аннан кечесе—Тәнзиләм дөньяга аваз салды. Тәнзилә туганда Сафа картка илле сигез яшь иде,—дип көлә агай. Айсылу хәзер Оренбурда медицина институтын тәмамлап килә икән, Тәнзилә педагогия училищесын тәмамлап, читтән торып педагогия институтына укырга кергән. Әйткәнемчә, Биккол мәктәбендә укыта, бик өлгер һәм уңган. Әтисенең "Нива" машинасына утырып, минут эчендә авылны әйләнеп килә, әти-әнисенә дөнья күтәргә булыша.

Сафа абзый безгә киңәш биреп тә куя:

—Тәмәке тартмагыз, оланнар, тәмәке бетерә кешене. Эчә белмисез икән, аракы белән дә маташмагыз. Үзем умарталыкта эшләгәч, өче бал ясый идем, бик тә файдалы нәмәрсә икән. Тик артыгын кулланмадым. Исерткеч, ни генә булса да, артыкка китсә, зыяннан башка файдасы юк. Хәрәкәт кирәк кешегә. Шуңа, Аллага шөкер, һич тә үземне сиксән яшьтә дип хис итмим. Гадилә апагыз да зарланмый,—кеткелдәп көлә абзый.

Моңарчы Сафа агайны тыныч кына тыңлап торган Гадилә апабыз, иренең шуклыгын ишетмәгәнгә сабышып, сүзне икенчегә бора:

—Авыл бик матур иде, гөрләп тора иде дә, менә хәзер яшьләр калмый. Күрәсезме, күпме өйнең тәрәзәсе капкач белән ябылган. Халык кими, балалар кими. Болай булса, мәктәпне дә ябарга күп сорамаслар. Инде укытучылар арасында шундый сүз йөри. Мәктәп беткәч, авыл бетә тек бетә инде ул. Яшьләрдә әдәп бетә, әхлак юкка чыга,—дип борчыла Гадилә апа.—Күр инде, шушы авылда туып үскән кешеләрнең балалары татарча белмиләр. Кайда гына яшәсә дә, балага туган теленә өйрәтү—ата-ананың төп бурычы. Әле Сафа абыегызның оныгы кунакка кайтты Светлана исемле. Троицкида, беренче гимназиядә укый. Алтынчы сыйныфта укучы шушы кыз "әбика, бабайка"дан башка бер авыз татарча белми. Җәй буе аптырап беттем. Инде бераз төшенә башлаган иде, тагын шәһәргә китә. Янә урыс баласы булып кайта инде икенче елга.

Клубта яшьләр татар җырын ишетмиләр. Элек Казаннан да, үзебезнең Оренбурдан да концертлар килеп куялар иде. Хәзер алар да килми. Авылны читләтеп үтәләр. Эчүчелек авылда, яше-карты эчә. Милләт дибез дә, менә шулай югала бара шул авыл. Шәһәрдә урыс тәрбиясе, авыл бетә. Кемгә кирәк соң без?—дип тилмереп сорый ул.

Ни дип җавап бирәсең инде Гадилә апага? Әгәр дә һәркайсыбыз, чит өлкәләргә чыгып, монда да татарлар яши әле, дип, сөенеп йөрүдән артык китә алмасак, инкыйраз көннәре озак көттермәс шул. Татарстанның чын хәле нинди икәнен искәртеп киткән идем инде. Әгәр чит төбәкләрдә татар дөньясы сакланып калмаса, ул чагында Татарстанның татар иле булып яшәве дә шик астында. Чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез зур елганы туендырып торучы саф чишмәләр

сыман,татарның татарлыгын үстереп, аңа яңа талантлар, акыл иялере, яңа кан, сулыш биреп торучылар. Алар язмышына битарафлык бүгенге рәсми җитәкчеләребез өчен дә, бихисап җәмәгать оешмалары өчен дә(аларның кайберләре рәсми хөкүмәттән акча алып та гомер кичерә бит), барлык зыялыларыбыз, укымышлыларыбыз өчен дә гафу ителмәслек хәл. Чит өлкәләрдәге миллəттәшләребез әле бетмәгән, алар бар, алар әле хәрәкәттә, алар сакланып калу өчен фидакарьләрчә эш алып баралар, аларның күзе—Татарстанда, димәк безнең һәркайсыбызда.

## "Заман кемнең заманы?" яки *"Ил берекми торганда"...*

СОҢГЫ БҮЛЕККӘ "Идегәй" дастаныннан алынган өлеге юллар туры киләдер кебек.

Дүрткөнлек сәфәр тәмам. Уттай кызган асфальт юл безне Чаллыга алып кайта.

Күңел урыныннан купкан: очрашу мизгелләре, яңа танышларымның йөз чалымнары, эш-гамәлләре, холык-фигыльләре кабат-кабат искә төшә. Бу дөньяда бернәрсәгә дә исе китмәгән кыяфәт белән сөйләшеп "җиффәрүче" Садыйк турында иркенләп язарга булыр иде. Җитмәсә, ул армиядә нәкъ мин хезмәт иткән якларда булган. Сөйләшкәндә Ерак Көнчыгышның Бикин, Уссурийск, башка калалар, бер-берсенә игезәк балалар сыман охшаган елгачыклар агып яткан җиде елга Үзәненә кадәр хәтердә яңарды.

Садыйкның тормышы һәръяктан җитеш, мул. Эшнең рәтен, җаен белә. Беренче күрүгә, бераз мактанчык, ахры, бу кеше дигән уй да килгән иде башка. Әмма, аның тормыш иткән дөньясын күргәч аңлыйсың, ул көн-төн эштә, булмаганны булдырырга сәләтле гаярь ир-егет. Кулы эшкә ята, яшәүдән тәм таба, кемдер китереп бирер дип өмет итеп ятучылардан түгел. Минем шулай өч-дүрт көн эчендә Каргалы, Оренбур яклары белән таныша алырыма, ни-нәрсәдер яза алуыма шикләнеп, ярып салган сүзләре колактан китми:

—Энекәш, син монда бер айга кил! Әллә кемнәр белән таныштырам. Һи-и, түрә кеше (Мохтар әфәндегә ымлый) синең башыңны гына әйләндерә ул, без простой халык шикелле мәңге җанын ачып салмаячак. Әйтәм ич, кил иркенләп, кач шул түрәләрдән. Бер китаплык мәзәк җыеп алып китәрсең Каргалыдан. Оренбурны әйтмим дә инде аны...

Садыйкның "текә" сөйләшүен яхшы белгән Мохтар әфәнде үз итеп елмаеп җибәрә. Мәршидә апайның да йөзеннән тыйнак елмаю китми. Ул —Садыйкның хәләл җефете. Озак еллар Оренбур шәл фабрикасының Каргалыдагы филиалы белән җитәкчелек иткән. Мондый филиаллар өлкә буйлап сибелгән булган. Хәзер барысы да ябылып беткән. Атаклы Оренбур шәлләрен чыгаручы төп фабрика үзе дә көч-хәл белән җан асрый. Шулай итеп бер Каргалыда гына дистә-дистә хатын-кыз эшсез калган.

—Шәлләребез бик матур, нәфис була иде, —дип искә ала Мәршидә апай. —Техник контроль дигәннәрне шул —без бәйләгән мамык шәлләрне йөзектән үткәреп карыйлар. Ул чакларны сагынып кына сөйләргә калды, — ди Мәршидә апай уфтанып. Матур якты йөзе буйлап сагыш дулкыны йөгергәнен күреп калам...

Тагын бер танышым —ачык йөзле, туры сүзле Ягъфәр. Минем чордашым. Бу чын татар егете инде. Ул беркемгә дә ышанмый. Рәсәй сәясәтчеләрен сүккән шикелле үк, өлкә, район, авыл түрәләре дә өлешсез калмый.

—Шәһәрдә ни хикмәт кылана яшьләр, авылда да шул ук, —дип кыза ул. —Авылга чор тудырган барлык әшәкелек тә үтеп керә. Беркемгә берни кирәкми. Һәркем үзен генә уйлый. Яше-карты эчә,

наркомания, угрылык, фахишәләр. Һи-и, болганды дөнья. Белмим бу батчаклыктан чыга алырбызмы, юкмы...—Аның ачынулы сүзләре йөрәккә ук үтеп керә. —Шунысы гаҗәп, —ди Ягъфәр, —чаң сугасы урынга, әлеге хәлләрне яшерергә тырышалар өстәгеләр. Күз йомгач—күрмисең, кычкырып сөйләмәсәң—ишетмисең, җаның тыныч, янәсе. Халык бит барсын да белеп тора. Кемнән яшерәләр, ни өчен, аптыраш, —дип, кулын селти ул кай тарафкадыр.

...Сулар ага тора... Көн артыннан көн үтә, эш-мәшәкатьләр белән әвәрә килеп, язмамны төгәлләү шактый озакка сузылды, ахрысы. Көннәрне кайтарып булмаган кебек, очрашу мизгелләрен дә кире кайтару мөмкин түгел. Ул гынамы, шушы арада язмада телгә алынган Ширияздан ага Сарымсаков, Бату ага Мөлековлар фанилыкны калдырып бакый дөньяга күчтеләр. Язылачак әсәр уңаеннан алар белән бик тә очрашасы килә иде, хәтта тиеш идем. Насыйп булмады. Соңардым шул, соңардым... Үкенечләр белән тулы дөньяга үкенечләр өстәлеп кенә тора.

Әле август башында Рәсәй хөкүмәтен С.Степашин җитәкли иде. Ул тынычлык, иминлек дип сөйләп,халыкны ышандырып та бетерә язган иде. Без Оренбурда чакта Казанга да килеп чыкты, хәтта. Кайтып ике-өч көн үтмәде, аның урынына"преемник" килеп утырды. Төньяк Кавказда яңадан сугыш учагын кабызып җибәрделәр. Шул рәвешле "преемник" җиң сызганып сайлауларга хәзерләнә башлады. Ниндидер бандитлар Мәскәүдә, тагын берничә җирдә йортлар шартлатып, сайлауларга старт бирелгәч, өрәк рәвешен алып бетергән Рәсәй президентына да "җан керде". Җиң сызганып әле Кремльдәге кабинетында, әле ял итә торган "Русь" кунак йортында бармагын селки-селки терроризм белән "көрәш"кә ташланды. Ул әйтсә әйтә инде. Элекке Чечен сугышы (1994-96 еллар) өчен генә дә рәшәткә артында "ял" итәргә тиешле Рәсәй түрәләре күңелендә әр-яңадан империячел дәгъвалар уянды. "Без империячеләр түгел, без федераллар" дия-дия Чечен җирләрен утка тоталар, халкын кыралар. Кем гаепле? Кем бер ил булып яшәгән бер халыкны ике территориягә таркатты? Бу ике төбәккә ике генерал утыртып куйгач, чеченнәр белән ингушлар бугазга бугаз килер, дип уйлаганнар иде Рәсәй козгыннары. Аларга кан түгелү шуны сылтау итеп череп барган империяне яңадан торгызу эшенә керешә башлау кирәк иде, дә. Юк, чечен белән ингуш сугышу түгел, күршеләрчә матур гына яши башладылар. Сугыштан башканы белмәгән ике генерал да (аларның өйрәнгән бөтен гыйлеме сугыш бит инде) бик тиз уртак тел таптылар. Шуннан соң Рәсәй үз кулы белән кан коешны оештырды Чечендә. Корал белән шыплап тулган армия складларын саклаусыз-нисез ташлап китеп барган булды Рәсәй армиясе Чечен иленнән. Меңләгән кеше кулына эләккән корал үз эшен шәп башкарды —кан коелды, киң масштаблы сугыш башларга сәбәп табылды. Уйлап куям, әгәр Татарстанга президент итеп бер генерал утыртып куйсалар (ул чагында моны эшләү әллә ни кыен түгел иде, хәзер ничектер), халыкка корал таратсалар —Татарстанда (Рәсәй төзегән федератив килешүгә Чеченстан белән Татарстан гына кул куймады) хәлләр ничек булыр икән? Без дә тоташ "бандит"ларга әйләнеп, авылларыбыз, шәһәрләребез бомба-ракеталар яңгыры астында калмас идеме? Татарстанда этник төркемнәр азмы, дөресен әйтик, аларны бер-берсенә каршы кыздырып йөрергә теләүчеләр әле хәзер дә юк түгел...

Империя халыкның бөгырен талый. Ислам диненә каршы нинди көрәш башланды бит, ә?! Үтә "нечкә" булырга азапланган Путин ишеләрнең ислам диненә карата тупас алымнар кулланып башлаган яңа сугышын күреп җаннар тетрәнә. Волгоградта, татар халкы мең еллар дөнья көткән изге җирдә —Сарсын каласында, мәчет төзергә теләгән миллəттәшләрне урыслар куып тараттылар. Мөфти Равил Гайнетдин дә, Бөтентатар конгрессы вәкилләре дә бу вәхшилекне

туктата алмадылар һәм туктата алмаячаклар да, чөнки империя тернәкләнә башлады, баштагы исәңгерәүле-миңгерәүле торышыннан актив хәрәкәткә килде. Өр-яңадан явыз миссионерлык хәрәкәте башланды Рәсәйдә. 1552 елдан соң, "Мәһдиш Иван Казанны алганганнан соң, — дип яза галим Равил Әмирхан, —мөселман мәчетләре урынында кирпеч өемнәре генә кала, күбесе исә махсус рәвештә җир белән тигезләнә. Коточкыч дәһшәттән аз гына ис-аңга килә башлаган, Яңа Бистә татарлары XVI йөз азагында мәчет төзергә омтылыш ясап карыйлар. Ләкин митрополит Гермоген татарларның "урыс шәһәреннән" "ук атымы" җирдә генә мөселман гыйбадәтханәсе төзелүгә бик нык ачулана һәм Иван IV нең улы Федор патшага шикаять кыла. Тегесе 1593 елның унсигезенче июнендә мондый фәрман бирә: "И вы б мечети татарские все велели посметати и вперед татарам мечети однолично ставити не велели, конечно б есте мечети татарские извели." Аннан соң да урыс патшалары мөселманнарны тынычта калдырмыйлар. Р.Әмирхан болай дип дәвам итә: "Петр патшаның христианлаштыру сәясәтендә аппетитлары шулкадәр зур була ки, хәтта үзенең "яшерен васыятьнамә"сендә ул бөтен җиһанны басып алуны, традицион ислам мәмләкәтләрен үзара сугыштыруны, аларны яулауны дәгъва итә, христианлыкны ислам динен кысырыклау хисабына дөньякүләм өстенлеккә ирештерү "зарурлыгын" васыять итеп калдыра. Хыял мондый: "Русия дәүләтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерер өчен, аның башкаласын Азия һәм Европа хәзинәләренең ачкычы булган Истанбулга күчерү шарт. Кичекми һәм ялгышмый эш итеп, Истанбулның Көнбатыш җирләренә ия булу кирәк. Шөбһәсез ки, Истанбулга ия булган патша дөньяда илаһи патша булачак... һәм Төркиянең, һәм дә Иранның дин әшлеклеләрен кулда тоту, алар аша сөнни-шигый каршылыкларны көчәйтү кирәк. Ислам динен Азиядән ераклаштыру, христиан һәм мәдәниятен анда җисми бер рәвештә тарату һәм җыю зарурдыр."

Икеләнмичә әйтергә була, бүген Рәсәй Петр патша васыятен тормышка ашырырга азапланып, тәүге һәм, үзләре уйлаганча, хәлиткеч талпынуларын ясап калырга ашыга.

Идел-Җаек буйларында яу бара. Әлегә күзгә күренми торган, кеше рухын яулап алу өчен гаять катлаулы, дәһшәтле яу бара безнең көннәрдә бу төбәктә. Оренбур өлкәсе губернаторы Владимир Елагин үзе хакимлек иткән өлкәне "Кече Рәсәй моделе" дип игълан иткән иде. Рәсәйдә барган һәрнәрсә монда чагылыш таба. "Южный Урал" газетасының кулга эләккән кайбер саннарына гына күз төшерсәң дә, моны ачык аңларга була. Газета, Троицк шәһәрендә мөселман мөгаллимәләренең мәҗлес уздыруларын хәбәр итә дә, башкаларның күңеленә шом салып куя, "ул ханымнарның җыйнаулашып серләшүләре ни хакта булды микән? Фаразларга гына кала..." Шулай булмый соң! Яки Богырысланда кинәт пәйда булган "баһавистлар" хакында күпме шауладылар өлкәдә. Әллә тагын бөтен Кавказ Богырысланга күчкән. Тынгысызлана Оренбур, тынгысызлана. Ләкин бу тынгысызлыкның сәбәпчеләре һич тә татар халкы да, ислам динен тотучы мөселманнар да түгел, шовинистик рухлы бәндәләр тудырган ыгы-зыгы ул. 1870 елда Русия мәгариф министры граф Д.А.Толстой болай дип белдерә: "Конечною целию образования всех инородцев, живущих в пределах нашего отечества, бесспорно, должно быть обрусение и их слияние с русским народом."

Бу хыял-теләкне тормышка ашыруны да Рәсәй хакимияте икенче планга калдырасы килми. Телдән һәм диннән яздыру —халыкны бетерүнең бердәнбер, ышанычлы юлы икәнлеген алар яхшы беләләр.

Яу бара... Кеше дигән зат җир йөзендә яшәгәндә яу, кәрәш сүзләре телдән төшмәс кебек. Рәсәйнең кайсы гына почмагында гаскәри мылтыгы шартласа да, татар бәгырен кыеп үтә. Чечняга сугышка "озын берлек" эзләп китүчеләрне Оренбур өлкәсендәге атаклы Тоцкидагы хәрби берләшмәдә туплыйлар. Чаллыдан сигезенче октябрьдә контракт төзеп, Тоцкига җибәрелгән татар егете бер ай дигәндә Чечняда һәлак булды.

Тоцки полигоны Оренбурдан ерак түгел, борынгы татар җирләрендә урнашкан. Бу полигонның исеме Чиләбе өлкәсендәге татарлар яшәгән Мөслим, Кыштым, Чибәркүл төбәкләре белән янәшә атала. Совет хәрбиләре кеше өчен үтә дә зыянлы булган химик корылмаларны төзүне, атом сынауларын үткәрүне нәкъ менә татарлар яшәгән җирләрдә башкарырга ни өчен "тәвәккәлләгәннәрдер", фаразларга гына кала.

1954 елның ундүртенче сентябрендә, Оренбур өлкәсендә Тоцки полигонында маршал Г.К.Жуков җитәкчелегендә атом-төш коралын кулланып хәрби өйрәнүләр үткәрәләр. "Өйрәнүләрдә" кырык мең кеше катнаша. Саклану чарасы итеп солдатларга противогаздан башка берни дә бирелми. Өйрәнүдә катнашучылар, өлеге хәл турында егерме биш ел буе дәшмәскә сүз биреп, кул куялар, хәрби сер янәсе.

Чөнки эпицентрдан унҗиде-унсигез чакрымдагы бер генә татар авылы да атом бомбасы шартлату алдыннан да, аннан соң да эвакуацияләнми. Анда яшәүчеләрнең сәламәтлеге, хәле белән элек тә, хәзер дә беркем дә кызыксынмый. Ә өйрәнүдә катнашкан солдатлар "шул көндә исән калсалар да, ("никаких массовых потерь не было" (!) яңадан күпләп вафат булалар, исән калганнары гомерлек интегүләргә дучар булып яшиләр, гарипләнәләр. Оборона министры Н.Булганин өйрәнү чорында аеруча өлгерлек күрсәткән хәрбиләргә бүләк—"Победа" сәгате тапшыра...

Әле Бикколда чакта, Сафа агайның оныгы Светлананы, Троицк шәһәрендә гимназиядә укучы кызчыкны күреп, имәнеп киткән идем. Кызның өстендә бәйләм кофта. Сүз дә юк, бик матур. "Яшен" дип аталган каптыргычының шудырмасына зур итеп тәре асылган. Алып атмалы түгел, шудырма нәкъ кызның күкрәк турысына җитеп, туктап кала, димәк, тәре дә һәрчак күкрәк тирәсендә диген сүз инде. Кызны оялтырга тырышам.

—Үскәнем, син бит татар кызы. Ни өчен күкрәгеңә тәре тагып йөрисең? Урыслар эшләп чыгарган һәрнәрсәне алып өскә киярга димәгән бит...

Кыз, аптырап әнисенә карады. Җүнләп татарча белмәсә дә, сүзнең "архиважный" нәрсә хакында барганын чамалап алды ул. Тик әнисенең генә керфеге дә селкенмәде.

—Базардан алган кием, —диде ул исә китмәгән кыяфәт белән. —Тәре дип... без ясап таккан нәрсә түгел, аны нишләтәсең инде. Кофтасы матур булгач...

Идел, Җаек буйларында мең еллар гомер кичергән татар халкына күсәк күтәрелде. Рәсәйдә сан буенча икенче урында торган халкым бу сынауларны үтеп чыга алырмы? Шушы сорау күп милләттәшләремне борчыган шикелле, минем дә җанымны телгәли...

Ә сәяхәткә килгәндә, фарыз эш инде ул юл йөрү. Фатих Кәрими әйтмешли: "Даимән бер җирдә утырмак вә нәкъ бер эш белән илә мәшгуль булмак инсанны бераз ялыктырадыр." Ул чагында, шундыйрак уйлар белән, Чаллыга куе эңгер төшкәндә исән-имин кайтып кердек без...

Ә күңелдә ниндидер кузгалыш: әйтеп бетергесез тынгысызлык хисе уянды. Бу хисне Дәрдмәнднең онытылмас сүзләре тагын да көчәйтә генә:

Мосафир, кем, җиһанга басты ботны,
Биетте ажгырып аны замана...
Өеп чергән өмидне... тәртте утны —
Йотып утларны китте... яна-яна...

*1999 ел,*
*Чаллы.*

## ШИГЪРИЯТ



# Вазыйх Фатыйхов

## СИРТМӘЛЕ КОЕ ЧИЛӘГЕ

Төнге учак, төнге ай
Бер-берсенә тартыла:
Араларда серле көчләр
Йолдыз булып атыла.

Киселеп кала ялкыннар
Ике ут арасында.
Сынган ялкыннар кадала
Йөрәгем ярасына.

Төнге учак, төнге ай
Бер-берсеннән читләшсә?
...Алсу пәрдәсен күтәреп
Кемгә кемнәр эндәшә?!

## Бушанулар кирәк

Әлсерәгән, ялын куккә чөеп,
Ак күбектә чаба Чулманым.
...Ялкынсынган чагың күп күрсәм дә,
Юктыр мондый ярсу булганың?!

Ярларыңа типтең кешни-кешни,
Аңлаганга сине, тыймадым.
Бушанулар кирәк шул сиңа да,—
Һәрбер җанга кирәк, Чулманым!

---

Вазыйх ФАТЫЙХОВ (1958) — *шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Тормыш арбасы» исемле китап авторы. Балык Бистәсендә яши. «Авыл офыклары» газетасы мөхәррире.*

## Ау сезоны ачылганда

Кыр казлары елап кузгалдылар,
Мылтык шартлаганга таң белән.
Ау сезоны—сагыш кемнәргәдер,
Кемнәргәдер татлы ял, беләм...

Кыр казлары елап кузгалдылар,
Аралардан... бушлык коелды.
Каз йолкыйлар кызыл күзләр җирдә,
Җан йолкыйлар кебек тоелды.

Кыр казлары елап кузгалдылар,
Югалтулар шактый булгандыр...
Табигатьне күпме талкып була,
Тагын кемнәр ничек юаныр?

Кыр казлары елап кузгалдылар,
Төтенләде мылтык көпшәсе.
Өзек чылбыр, каңгылдашты казлар,
Тулып акты кабат күз яше...

Кыр казлары елап кузгалдылар,
Иртә кузгалдылар төбәктән.
...Шаркылдаган көлү тавышлары
Нидер тартып алды йөрәктән...

## Сукыр җыры

Минем дә бар иде—карашымда
Матурлыкны кочып-сөеп елмайганым.
Сандугачның канатына кунып, очып,
Дәртлелекнең үлчәвендә сыналганым.

Минем дә бар иде—карашымда,
Дулкыннарны җилкән итеп йөзгән чагым.
Мәхәббәтнең йөрәгенә кулым куеп,
Сөелгәнем һәм сөйгәнем тагын-тагын.

Минем дә бар иде—карашымда
Төнге кичтә йолдыз белән шаярганым.
Икәү яккан учакларның ялкынында
Дөрли-дөрли, очкынланып, яналганым.

Минем дә бар иде—карашымда
Төнге кичнең караңгысын үз иткәнем.
...Көтмәгәндә мәңгелек төн. Тоймый калдым
Яктылыкның хыянәтен, чит иткәнен.

Карашымда—әле дә булса, элеккечә,
Матурлыкка чын йөрәктән талпынамын.
Җылыларын тоеп яшим кояшымның,
Имтиханым— «Мәңгелек төн». Уйланамын.

Минем өчен күңел күзе иң яктысы!
Җитмәгәне—кайбер караш, кайбер йөзгә.
Икесе дә булсын иде һәрбер җанда:
Кулым сузып кояшыма—телим сезгә!

## Җыр

Сиртмәле коеның чиләген тотырып,
Йолдызлар җыярга уйладым.
Күктә дә, суда да йолдызлар буталды,
Буталды самими уйларым.

Йолдызым кайларда, кайда син—
Күз кыскан шикелле һәммәсе.
Серлелек чолгады күңелне,
Кем чишәр йолдызлар хәйләсен.

Чиләгем тотырып йолдызлы су алдым,
Чайпалып йолдызлар коелды.
Тоттырмас йолдызлар йөрәккә атылды,
Бутады самими уемны.

Йолдызым кайларда, кайда син—
Күз кыскан шикелле һәммәсе.
Серлелек чолгады күңелне,
Кем чишәр йолдызлар хәйләсен.

Сиртмәле коеның сиртмәсен кочтым да,
Күкләрне кочарга уйладым.
Йомшак кул күземне томалап уйнады—
Таралды самими уйларым.

Йолдызым биредә, янымда,
Кул сузып йөрәккә тартыла.
Йолдызлар биешә, сибелә,
Табылган мәхәббәт хакына.

Син бар бит ул. Мәңгегә бар!
Шулай язган сине Ходай.
Яннарымда булмасаң да,
Син минеке генә бугай,
Син минеке генә бугай.

Сизәсеңме, аңлыйсыңмы:
Күзләр-күзгә күптән дәшә.
Яннарымда булмасаң да
Тоям сине гел янәшә.
Тоям сине гел янәшә.

Синең тавыш ишетелсә,
Дәва алам яраларга.
Яннарымда булмасаң да
Җылылык бар араларда:
Мәхәббәт бар араларда!

*Утыз яшькә җиткән ир-атларның*
*Икенче кат чәче агара.*

К. Сибгатуллин.

**Ирлек буламыни—ир еласа,**
**Еламый ул ирләр беркайчан.**
**Җырлый алар елар сәгатьләрдә,**
**Тыңлый белеп әгәр тыңласаң...**

**Ирлек буламыни ир егылса,**
**Егылмый ул ирләр, үлмичә.**
**Баскан килеш янса-яна белә,**
**Һәм егылмый—тәмам сүнмичә.**

**Ирлек буламыни ир сөймәсә,**
**Сөя белмим дисә, ышанма.**
**Ирләр сөйсә шундый итеп сөя**
**(Түземлегең җитәр, иншалла!)...**

**Ирлек буламыни ир картайса,**
**Ул картайса дөнья ни әйтер?**
**Еламый да, картаймый да ирләр...**
**(Дөнья өчен шулай әйбәттер!)**

## Син булмасаң әгәр

**«Син булмасаң әгәр», дип әйтәсе килә...**
**Тик әйтмимен, Ходай сакласын.**
**Сине, әйе, синең шикеллене**
**Ходай үзе, бәлки, тапмас ул?!**

**«Син булмасаң әгәр», дип әйтәсем килә,**
**Әйтмәм аны, әйтмәм беркайчан.**
**Сөясе дә килә башкаларны,**
**Йөрәк бар бит, ул бит тыңлаучан.**

**Син булмасаң әгәр, дип әйтәсе килә**
**Белмәс идем сөю барлыгын.**
**Янсам да мин серле учакларда,**
**Тоймыйм бүген дөнья тарлыгын.**

**Син булмасаң әгәр, дип әйтәсе килә,**
**Әйтәм әле: ярый син булган!**
**Синең өчен, белмим, тудым микән,**
**Бары минем өчен син туган!**
**Ялкынланам сөю утыннан...**

## Халәтем

**Йөрәгем тибеше—хыялым җилкәне,**
**Диңгезем—күңелем чишмәсе.**
**Ярсулы ташкыннар—кодрәтем,**

Кодрәтең булмаса нишләрсең?!
Хыялым җилкәне—ул минем киләчәк,
Кыйбламда—гомерлек оҗмахым.
Күзләрем төсендә—зәңгәр күк яктысы,
Туасы көннәрем—җырланыр җырларым.

Гомерлек оҗмахым—әхвәлем, тормышым,
Дусларым—ышаныч канатым.
Барысы янымда, шөкер, дим, Ходаем,
Өметле өметем—тезгенсез ак атым.

## Кирәгеннән артык

Кирәгеннән артык түземле мин,
Боза алмыйм йөрәк әмерен.
Көләм генә елар сәгатьләрдә,
Тик чыдасын гына бәгырең.

Кирәгеннән артык кешелекле—
Туганда ук шулай туганга.
«Көчле»ләрне күбрәк җәллим бүген,—
Көне-төне шомлы булганга.

Кирәгеннән артык гашыйк булам,
Ялгыш кына күргән кызга да.
Үкенмим һич сөя белгәнемә,
Мәхәббәттә гомер узганга.

Кирәгеннән артык гади шул мин,
Эчемдәге һәрчак тышымда.
Үткәннәрем—пакьлек тәлгәшләре,
Ак күңелем әнә учымда.

## Начарлык теләмә кешегә

Миңа да килмәс дип һичкайчан син әйтмә,
Бар җаннар—бер адәм баласы.
Яманлык, яхшылык меңнәрдән калган ул,
Кайсыдыр бездән дә каласы.

Бары тик яхшылык телә син,
Читләргә, туганга, күршегә.
Үз хәлең бик начар булса да,
Начарлык теләмә кешегә.

Кирәкмәс бу дип тә һичкайчан син әйтмә,
Кемнәрдер кадерле кемгәдер.
Яхшылык кылсаң да, яманлык салсаң да,
Гомерләр тукталмый үтәдер.

Ник тудым, китәм дип һичкайчан әйтмә син,
Гомер-юл сызылган алдан ук.
Никадәр байлыгың булмасын бу йортта...—
Синнән дә, миннән дә кала ул!

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Азат
Әхмәдуллин

## ЭЗЛӘНҮЛӘР БӘРӘКӘТЛЕМЕ?

Драматургия буенча билгеле бер чорга нәтиҗәләр ясаган, үсеш тенденцияләрен ачыклаган мәкалә язу шактый авыр эш. Хикмәт бу әдәбият төренә икенче сортлы нәрсә итеп карауда гына да түгел. Гәрчә бусы да эшне авырлаштыра. Карагыз: бездә драматургия өлкәсендә фикер-тәнкыйть әйтүчеләрне әдәби тәнкыйтьче итеп тану юк. Проза яисә шигърият өлкәсендәге тәнкыйтьчеләрне таныйлар, исемнәрен булса да атыйлар, хәтта «фәлән тәнкыйтьче генә миңа үсәргә булышты» дип тә җибәргәлиләр. Ә драматургия тәнкыйтьчесе турында—ләм-мим! Әнә, Язучылар берлегендә проза, шигърият, балалар әдәбияты остаханәләре бар, әйбәт кенә эшләп тә киләләр. Ә драматургияне каядыр проза арбасына тагып куйганнар да, шалтыраган тавышы да ишетелми... Яисә, ел саен иң укыла торган әдәби әсәрне билгелиләр. Проза бар, поэзия бар, балалар әдәбияты да истә. Драматургия әсәрләре турында исә бер сүз юк! Әйтерсең, аларны укымыйлар. Клублар, мәктәп сәхнәләрендә уйнау өчен генә дә китапханәләрдән күпме әсәр алалар бит инде, димәк укыйлар, өйрәнәләр. Татар пьесаны шигырьгә караганда да яратыбрак укый, югыйсә...

Кыскасы, «ул бит театрда гына тулы яңгырый торган әдәби төр»дип, кайчандыр, кемдер әйткән фикерне чынга алып, драматургияне тәмам театр белгечләренә, сәхнә хезмәткәрләренә генә тапшыру дәвам итә. Ә бит сер түгел, театр белгечләренең күбесе драматургиябез тарихын белеп бетерми, кайсыларыдыр аңар карата театр кануннарын кулланырга омтылып ялгыша.

Болары шулай. Тик алай да төп хикмәт—драманың әдәбиятта иң үзенчәлекле өлкә булуында. Юкка гына драма матур әдәбиятның «иң югары биеклеге», «таҗы» дип аталмаган, күрәсең. Ә бит болай дип аны әле XIX йөздә, кинодраматургия дә, телевидение драматургиясе дә булмаганда, мәйдан тамашалары да күренмәгәндә атаганнар.

Язучыларның соңгы корылтаеннан соң узган елларда бездә йөзләрчә пьесалар сәхнә күрде, басылып чыкты. Сан ягыннан караганда, ике съезд арасында бу юлы әсәрләр әүвәлгегә караганда шактый күп иҗат ителгән. Ягъни драматургларыбызның иҗат активлыгы үсте. Бу үзе үк күңелле фал. Сәбәпләрдән берсе—профессиональ театрларыбыз артты. Ихтыяҗ булгач, тәкъдим итү арта. Эш, билгеле, анда гына да түгел. Замана үзе шуңар этәрә. Катлаулы, борчулы, авыр, гади кешегә мәрхәмәтсез замана, гаделсезлек, кыерсыту, җәберләү, алдашу, җан кыю өчен уңай замана. Болар иҗат кешеләрен борчый, уйландыра, нәфрәтләндерә, үз кичереш-фикерләрен әсәрләргә күчерергә этәрә.

Ә менә ул уй-кичерешләрне сәнгатьчә гәүдәләндерү мәсьәләсенә килсәк,биредә эш алай ук күкрәк кагарлык түгел. Драматургиябезнең бүгенгесенә бу җәһәттән күп кенә таләпләр куярга, ризасызлык белдерергә мөмкин. «Пьеса» термины киртәләренә кергән күпчелек әсәрләр турында руслар уйлап тапкан исем белән «клип драматургиясе» дияргә була. Театр белгече Дания Гыймранова аны бер мәкаләсендә «ширпотреб» дип атады. Ә Зәки Зәйнуллин аларны тегермәнне файдасызга әйләндерүче буш орлыклар дип карый. Әнә, Мәдәният министрлыгы оештырган конкурска 66 пьеса килгән, ә беренче урынга лаеклы бер генә әсәр дә юк. Бу факт үзе генә дә бүгенге драматургиябезнең хәле мактанырлык булмау турында сөйли.

Әйе, житди проблемалы драмалар сирәк туа. Соңгы 5 елда да шулай булды. Ләкин бүгенге сәхнә әдәбиятыбызда уңайны күрмәү, эзләнүләрнең тукталмавын санга сукмау, казанышларны аңларга тырышмау, аларны уртага салып карамау дөрес булмас иде.

Ике корылтай арасында иҗат ителгән пьесалар белән танышкач, иң беренче, андагы тематика-мәүзуг төрләнә бару күзгә ташлана. Проза һәм шигърияттәге кебек, милләт язмышы проблемаларына игътибар көчәйде. Алар төрле яклап яктыртыла. Т. Миңнуллинның берничә әсәре нәкъ менә шул мәсьәләләрне күтәрә. «Илгизәр плюс Вера» драмасында ул милләтебезгә зыян салучы катнаш гаиләләр яссылыгында хәл ителә. Мәхәббәт дигән гүзәл хис бар. Моңа өстәп тагын русның да, татарның да үз гореф-гадәтләре бар, аларның һәрберсе үзе өчен изге һәм кадерле. Дуслык дигән изге төшенчә дә бар, һәр халык аңар табына. Ләкин катнаш гаилә икән—ул инде бер милләт кими, ә «олы туган» саны арта дигән сүз. Күп очракта олы туган ягына халыкның интеллектуаль хәзинәсен тәшкил иткән шәхесләр күчә. Жанр сәнгате ягыннан матур эшләнгән драмада шул фикерләр үзәктә тора.

Авторның «Шәҗәрә» драмасына карата да шуны ук әйтеп була. Милләт язмышы монда гасырлар дәвамында формалашкан, асылда татарның зыялы катламын тәшкил иткән морзалар токымы тарихын яктырту ярдәмендә чагылдырыла. Пьесага беркадәр фрагментарлык хас, әмма ул автор тарафыннан махсус шулай эшләнгән булса кирәк. Г. Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясендәге кебек. Анда читтән килгән Себер бае аерым-аерым күренешләр тәшкил иткән шәһәр тормышын күзәтә. «Шәҗәрә»дә авыл егете белән шәһәр кызы төрле язмышлы морзалар тормышы белән танышалар. Бер караганда, кабатлау бар кебек. Әмма мәгънә ягыннан бу—инде бер табылган драматургик формадан файдалануның матур бер үрнәге.

Ризван Хәмид соңгы елларда да актив иҗат итте. Ул—драматургия төренең үзенчәлекләрен тирән үзләштергән авторлардан берсе. Безгә бер генә персонажлы монодрама («Олы юлның тузаны»), ике генә геройлы драма («Ике сәгать—бер гомер») бүләк итте. Монограмма, гомумән, авыр форма, русларда да ул бармак белән генә санарлык. (Әхсән Баян узган елны тагын бер монограмма—французчадан файдаланып «Кеше тавышы» исемле әсәр язды.) Р. Хәмиднең драма вә трагедияләре дә гаять үзенчәлекле; аның кырыс, ләкин тормышчан геройларга, символикага, метафорикага ия пьесалары сәхнәләштерү өчен шактый ук авыр. Автор гади-гадәти чынбарлыктан тетрәндергеч ситуацияләр таба белә. Аның «Актамырлар иле» трагедиясе—шундый иде. Инде менә драматург «Җанкай улы Җанкыяр» исемле трагифарс, исеме буенча ук бик мәгънәле әсәр иҗат итте. Бу оригиналь әсәр драматургия буенча республика ябык конкурсында бүләкле урыннарның берсен алды. Трагифарс—татар милләтенә башка милләт вәкилләре белән, бигрәк тә урыслар белән катнаш гаилә коруның никадәрле хәвефле икәнен масштаблы итеп, сәнгатьчә көчле итеп сурәтләүнең иң уңышлы мисалларыннан берсе.

Драматургиябездә совет тәртипләрен фаш итү җанланды, шактый ук тирәнәйде. Иң беренчедән, 70 ел хакимлек иткән идеологиянең кешене шәхес буларак таркатуда уйнаган роленә игътибар ителә. Шулай ук басып алу сугышлары алып баруны яклау, милләтләрне кимсетүгә һәм юкка чыгаруга йөз тоту, халыкларның гасырлар дәвамында сыналган милли гореф-гадәтләренең санга сугылмавы, туган телнең милли тормышта үз урынын

саклый алмавы, эшләмәскә өйрәнү, халыкның иң күркәм сыйфатларыннан берсе булган хезмәт сөюне югалту, аерым кешеләргә генә түгел, ә тулаем халыкларның киләчәгенә яный торган аракы фаҗигаләре һ. б. тәнкыйтьләнә. Боларга бүген көннән-көн көчәя барган—үз баласыннан баш тарту, хәрам байлык артыннан куу, кеше гомерен өзүне чүпкә дә санамау, миһербансызлык, кансызлык, гаиләгә игътибар кимү һ. б. кебек «авырулар» өстәлде. Драма һәм трагедия жанрлары өчен кулай темалар, әлбәттә. Һәм андый әсәрләр алай ук күп булмасалар да, язылды. Моңа Т. Миңнуллин, И. Юзеев, Ә. Баян кебек өлкән буын иҗатчылар да, Р. Хәмид, Р. Батулла, Ф. Садриев, Р. Мингалим, Ю. Сафиуллин, Ф. Яруллин кебек урта буын һәм З. Хәким, Д. Салихов, Аманулла, М. Гыйлаҗев, Г. Каюмов кебек яшьрәк буын драматурглар да өлеш кертте.

Әйе, заманыбыз—коточкыч замана. Ул әле кичә генә «тигезлек җәмгыяте төзибез» дип ышанган кешеләр өчен бигрәк тә авыр: матди җитешсезлекләр өстенә, тагын идеалсыз калу... Бүгенге җәмгыять тәртипләрен «кыргыйлык» дип атарга мөмкин. Аның рәхимсез картиналарының кайберләрен драматургиябез сурәтләп бирә алды. Мисал өчен Зөлфәт Хәкимнең «Җүләрләр йорты» исемле мелодрамасын һәм Д. Салиховның «Алла каргаган йорт» драмасын күрсәтергә була. Материалны, әйтерсең лә, һәр ике автор үзара сөйләшеп сайлаган да, килешенеп эшкәрткән. Ситуация шулкадәр охшаш. Ләкин чишелеш бу ситуациянең барлыкка килүендә җәмгыятьне гаепләү ягыннан бик үк охшаш та түгел. Һәр ике әсәрне психологик кичерешләр сурәтләүдә төгәллек, вакыйгалар агышында логик бөтенлек характерлый. З. Хәким кешене рухи үтерүдә, шәхесне җимерүдә Брежнев чорларын ныграк гаепләсә, Д. Салихов бүгенге заманны, мафиозниклар һәм чиновниклар патшалыгын көчлерәк фаш итә.

Б. Ельцин «демократиясе» Россия империясенең ныклыгын ирек сөюче батыр чечен халкына каршы сугыш ачып расламакчы булды. Ләкин хурлык кына яулады. Сугыш чеченнарга гына түгел, урысның үзенә дә, Русиянең башка халыкларына да бәла-казадан, фаҗигадән бүтән нәрсә китермәде. Сугышның газаплары әле озакка барыр, күңелләрдәге яралар—бигрәк тә. Моны драматургларыбыз прозаикларга вә шагыйрьләргә караганда да үтемлерәк итеп һәм алданрак чагылдырдылар. Ю. Сафиуллин җыйнак эшләнгән, жанр таләпләренә тулы җавап бирә торган «Йөзек һәм хәнҗәр» исемле трагедиясендә аның шулай икәнен раслады, чечен трагедиясенең төп гаеплеләрен дә, ярдәмче чаралар вә геройларын да тәэсирле итеп сурәтләде. Иң мөһиме, мондый гаделсез сугышның халыкларга газап-кайгы гына алып килүен сәнгатьчә итеп күрсәтте.

Халкыбызның изге гадәт-йолаларны югалта баруы драматургларны гаять борчый. Бу темага шактый ук әсәрләр язылды. Һәрбер пьесада дип әйтерлек, вакыйгалар нинди җирлектә генә бармасын, бу тема-мотив калкып чыга. Совет чорларында башланган, шактый ук нәтиҗәләре дә күренгән бу чир бүгенге кыргый заманда бер дә кимеми, киресенчә, тагын да көчәя генә төште. Халыкның аракыга хирыслана баруына авторларның җаны җылый. Болар бигрәк тә комедия өчен характерлы.

Татар драматургиясендә комедия жанры гомер-гомергә актив, хәтта иң активы булды. Шул яктан үзенең позицияләрен бүген дә нык саклый. Жанр эчендәге төсмерләргә байлыгы белән дә ул беренче урында. Аның ярдәмендә иң җитди мәсьәләләрне дә күтәреп була. Шул ук вакытта ул иң буш, пүчтәк көлүдән гыйбарәт эчтәлеккә ия булырга да мөмкин. Шуңа да бу жанр тәнкыйтьтә еш кына бәхәсләр китереп чыгара, кискен кире кагулар тудыра. Мәсәлән, һәр күзәнәге татар дип сулкылдаган гаярь милләтпәрвәр вә язучы Зәки Зәйнуллин узган елны бүгенге драматургиябезнең атасы Т. Миңнуллинны соңгы комедияләре өчен пыр туздырып атты, аларны бушка чыгарды. Ләкин һәр очрактагы кебек, монда да мәсьәләне төрле яклап карарга вә бәяләргә кирәк.

Әйе, комедия—драматургиянең иң универсаль жанры, реалистик драматургиянең жанр доминантасы. Нәкъ менә ул сәхнә сәнгатенең үсешендә хәлиткеч рольне уйнады вә уйный. Антик сәнгатьтән үк шулай, татарда да.

һәм бу аңлашыла. Чөнки театр сәнгатенең нигезен, асылын уен тәшкил итә. Ә уен, иң әүвәл, комедиядә иң ачык гәүдәләнешен таба. Шуңа күрә дә «драматургиянең таҗы булып трагедия тора» дигән, Белинскийдан килә торган фикергә бүген ябышып ятып булмас. Кешене (тамашачыны) тетрәндерү ягыннан, әлбәттә, трагедия алда. Әмма кешене (тамашачыны) рухи хөрлеккә чыгару, туарып җибәрү, күңелен күтәрү ягыннан комедия белән бер жанр да ярыша алмый. Иҗтимагый тәртипләрне тәнкыйть итү ягыннан комедия хәтта драма жанры вазифаларын да үти ала. Рөстәм Мингалим үзенең Эсфир Яһудин белән бергә язган бер комедиясе уңаеннан бик дөрес әйтә: «Комедия асылында буш тамаша, очсызлы уен-көлеш, сикереш-тибеш түгел. Әсәрдә—ике меңенче елга кереп барган татарның эчке дөньясы, аның көлке дә һәм кызганыч та күренгән рәвеше» («Шәһри Казан», 1999, 15 гыйнвар).

Бүгенге шашкын заманыбыз да югарыда әйтелгәннәрне раслый. Г. Камал театрында да, К. Тинчурин театрында да, ягъни әйдәүче сәхнәләрдә, комедия өстенлек итә. Алар арасында, әлбәттә, бушлары да юк түгел. Мәсәлән, Казан телевидениесеннән «Мәхәббәт карагы» (Ф. Бүләков) исемле мәгънәсез көлүгә корылган комедия күрсәттеләр. Буш та буш, бу да—буш. К. Тинчурин исемендәге театрда да табып була андый спектакльләрне. Әмма хәлнең торышын мондыйлар билгеләми.

Бүгенге комедияләрнең иң уңышлылары—иҗтимагый эчтәлекле. Монда алга яшьрәк буын авторлар чыкты. Зөлфәт Хәким, мәсәлән, бу яктан «Кишер басуы» комедиясе белән башланган табышларын «Карак», «Күрәзәче» әсәрләрендә ишәйтте.

Аманулла «Кылый Кирам балдагы» комедиясе белән уңышлы чыгыш ясаганнан соң «Әле кичә генә яз иде» исемле оригиналь әсәр язды. Боларда бүгенге тормышыбызда сирәк очрый торган, әмма җәмгыять үсеше кануннарын үзенчәлекле чагылдырган яклар гәүдәләндерелә. Беренче әсәрдә төп игътибар тормышта урын дәгъвалаучы сатирик типларга бирелсә, икенче әсәрдә исә бүгенге яшьләр вә өлкәннәр мөнәсәбәте, яшь буынның яшәешендәге, тормышындагы үзенчәлекләр, борчу-эзләнүләр сурәтләнә. Тулаем алганда оптимистик рухлы әсәр туган, киләчәк буынга карата хәерһаклык белән сугарылган, бүгенге авырлыклар алдында рухи сынау үтә торган яшьләрне белеп тасвирлаган якты пьеса барлыкка килгән.

Алдагы сүзебезгә әйләнеп кайтыйк. Театрларда өстенлек алган комедия жанрында яшәешебезнең төрледән-төрле яклары чагыла. Алар шуның белән, көлүнең төрле төсмерләреннән файдалanuлары белән кыйммәтле; халкыбызның бүгенге эчпошыргыч, идеалсыз, соры, ач тормышын күпмедер бизиләр. Т. Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре» һәм «Йөрәк маем» комедияләре җиңел рухта, әмма аларга һич кенә дә файдасыз, буш дигән сүзләр кулланып булмый. Татарны төрлечә таркатырга, керәшеннәргә, мишәрләргә, нугайларга, Себер татарларына бүлгәләргә чакырып сөрән салган вакытта бу комедияләр шул кавемнәрне бер халыкның аерылмас өлеше итеп раслый вә күрсәтә, аларның татарлык рухына, матур гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияли. Ахыр чиктә татарның бердәмлеген ныгыту юнәлешендә эшли.

Җиңел рухлы, әмма эчтәлеге мәгънәле комедияләр барлык театрларның да репертуарын бизи. Алда әйтеп үткәннәрдән тыш Ф. Яруллин («Кызларның кызганнары»), Р. Вәлиев («Әй машина, машина...»), М. Гыйләҗев («Казан егетләре»), Г. Зәйнашева («Гайфи бабай, өйлән давай!»), Г. Каюмов («Һинд кызы»), Э. Яһудин («Мәхәббәткә мәдхия») һ. б. авторларның шундый комедия әсәрләре бүгенге көн үзенчәлекләрен чагылдырып кына чикләнмиләр, тамашачыны да театрларда тотып торалар.

Бүгенге драматургиябездә тагын да ике жанр активлашты. Берсе—трагедия. Бу жанр моңарчы сәхнә әдәбияты тарихында иң артта калганнардан иде. Совет чорында аның үсешенә мөмкинлек бирелмәде. Соңгы елларда «буа ерылды». Татар драматургиясенең бөтен тарихына караганда да күбрәк язылып, дистәгә якын әйбәт трагедия иҗат ителде, кайберләре сәхнәгә куелды. Юныс Сафиуллин алда исеме аталган әсәре өстенә «Идегәй» трагедиясенең яңа версиясен тәкъдим итеп, уңыш казанды. Ризван Хәмид белән Рөстәм Мингалим

шул ук исемдә кызыклы киносценарий яздылар. Р. Хәмиднең «Хан кызы Хансөяр» фаҗигасе исә бу жанрда ирешкән уңышлардан берсе саналырга хаклы. Батулланың чечен вакыйгаларына багышланган «Кояш баеганда» исемле трагедиясе классицизм иҗат методы рухында (вакыйгалар бер генә урында, 24 сәгать эчендә бара) язылуы белән кызыклы. Болар янына Әхсән Баянның элегрәк иҗат ителгән шигъри трагедияләрен («Алтын кашбау» һ. б.), Мансур Гыйләҗевның «Бичура» әсәрен, Данил Салиховның «Чукрак» исемле трагик драмасын куярга мөмкин. Ирешелгән уңышларны барлаганнан соң бер теләк тә әйтәсе килә. Әсәрне трагедия итеп фаҗигале чишелгән конфликт кына түгел, ә югары пафос та билгеләшә. Ә соңгысына драматургларыбыз сирәк ирешәләр.

Ике корылтай арасында мелодрама җанланды. Гомумән, Шәрык халыкларына хас булганча, татар тамашачысы да мондый әсәрләрне бик ярата. Мелодрамаларны бигрәк тә К. Тинчурин исемендәге театр белеп куя. Монда Рәдиф Сәгъдинең «Сынган беләзек», Ренат Суфиевның «Сакаллы сабыйлар», Исламия Мәхмүтованың «Син бит минем бергенәм», Харис Төхфәтнең «Сакла сөюне, таплама берүк» кебек мелодрамалары уңыш белән бара. Х. Вахит әсәрләре белән бергә бу жанр төренең тулы бер юнәлешен барлыкка китерәләр. Психологик кичерешләрнең өстә генә ятуы, бәхетле, һич югында хәерле финалга ия булуы белән, гадәттә гаилә мәшәкатьләре, картлар язмышы, ата-ана вә балалар мөнәсәбәтләре, мәхәббәт газаплары сурәтләнүе белән мондый әсәрләр тамашачыда теләктәшлек таба, тәэсир итә.

Соңгы елларда әдәбиятка артистлар шактый килде. Драматургияга уенчылар килү тарихта күптәннән бар. Бөек Г. Кариев та пьеса язган. К. Тинчурин, Т. Гыйззәт, Р. Ишморат, Ә. Камал... Бүгенге әйдәп баручылардан Т. Миңнуллин, Р. Батулла, Ю. Сафиуллиннар... Д. Салихов, Аманулла, Г. Каюмовлар... Инде Рәдиф Сәгъди, Харис Төхфәт, Фәнәвил Галиев, Шамил Фәрхетдиннәр уңышлы гына чыгыш ясыйлар. Өлкән буын артистларның драматургиягә килүе дә бәрәкәтле булды. К. Тинчурин театрының әйдәүче актрисаларыннан берсе И. Мәхмүтованың алда әйтелгән мелодрамасы репертуарга файда китерде, бүген дә уйнала. Танылган артистка Рәшидә Җиһаншина бер-бер артлы дүрт-биш пьеса язды. Аларның иҗат ителүен «Инсаният» исемле өлкән буын артистлар театры ихтыяҗы тудырды. Асылда мелодрама рухындагы «Улларым», «Ир баш—хатын муен», «Сөйдергеч бөтие», «Көтелмәгән кунак» кебек әсәрләр югары сәнгать таләпләренә тулысынча җавап бирә дисәң, дөреслеккә хилафлык булыр иде, алар урта кул әсәрләр. Әмма бигрәк тә картлар-карчыкларны борчый торган күпсанлы тормышчан проблемаларны күтәреп чыгулары белән файдалы эш эшлиләр, аларның үз тамашачысы бар.

Бүгенге драматургия процессының аерым билгеләрен ачыклауда соңгы елларда басылып чыккан пьеса җыентыклары да ярдәм итә. Мәсәлән, Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» (1996) җыентыгы, Зөлфәт Хәкимнең 3 томлыгының өченче томы (1997), Ф. Яруллинның «Пьесалар» (1998) һәм Д. Салиховның «Яшьлек хатам—йөрәк ярам» (1998) исемле җыентыклары. Болар—авторларның соңгы елларда ирешкән үз казанышларын да, драматургик процессның аерым уңай якларын һәм кимчелекләрен дә чагылдыручы тупланмалар.

Соңгы елларда ирешелгән сәнгатьчә уңышлар итеп, иң беренчедән, пьесаларның уку вә карау өчен кызыклана баруын күрсәтергә кирәк. Моңа төрле юллар белән ирешелә. Кабатланмаган конфликтны табу, әдәбиятта очрамаган ситуация-вакыйгаларны билгеләү, үзенчәлекле характерларны ачыклау аларны көтелмәгән кискенлек белән бергәндә генә үз максатына ирешә. Моңарчы, бигрәк тә гасырыбызның 30-60 елларында, әсәрнең башында ук вакыйга ни белән тәмамлануы билгеле, геройларның язмышы алдан ук «кычкырып» торган сәхнә әсәрләре мул язылды. Инде хәзер драматурглар шактый остардылар. «Сөяркә», «Хушыгыз», «Җанкай улы Җанкыяр», «Яшьләй сөйгән ярлар», «Карак», «Әле кичә генә яз иде», «Алла каргаган йорт» кебек драмаларда көтелмәгән ситуацияләр, фабуланың кызыклы төзелеше

күзәтелә. Әлбәттә инде, соңгы елларда язылган барлык әсәрләргә дә хас түгел бу. Конфликтның җиңеллеге, сюжетта «үтә күренмәлелек», алдан ук барысы да билгеле булу күпчелек пьесаларга, бигрәк тә комедияләргә хас.

Совет чорында еш кына драматургиядә бер таләп исәпкә алынып бетми иде. Бу—Аристотельдән үк килгән таләп. Драма әсәрендә персонажлар никадәр якын кардәшлек мөнәсәбәтендә торсалар, алар арасындагы каршылык һәм көрәштән алынган тәэсир дә шулкадәр көчле була. Моның төп сәбәпләреннән берсен мин түбәндәгедән күрәм. Хосусый милекчелеккә каршы көрәш хезмәткә дә мөнәсәбәтне үзгәртте. Кызыксыну кимеде. Моны күреп, совет идеологиясе күмәк хезмәтнең өстенлеген раслауга вә мактауга зур игътибар бирә башлады. Бу әдәбиятка да күчте. (Хезмәт проблемасын чагылдырган әсәрләр бер генә илдә дә бу кадәр күп язылмады. Чөнки капиталистик мөнәсәбәтләр хөкем сөргән җирдә хезмәт пропагандалауга мохтаҗ түгел.) Шуңа да совет драматургиясендә дә конфликт үзгәреш кичерде. Заводта, фабрикада, колхозда хезмәткә мөнәсәбәт тудырган каршылыклар үзәк урынны алды. Бөтенләй чит-ят кешеләр производствоны алга җибәрү өчен үзара тартышалар, көрәшәләр. Бик сирәк кенә бу көрәшкә кардәшләр, туганнар килеп кушыла. Карагыз Т. Гыйззәтнең «Мактаулы заман» пьесасын, М. Әмирнең совет классикасы саналган «Миңлекамал» драмасын алыгыз. К. Тинчуринның «Кандыр буе» әсәре дә шул рухта. Бөтенләй дип әйтерлек чит-ятлар үзара каршылыкка керә. Нәтиҗәдә конфликтның тәэсир көче кими.

Соңгы еллар драматургиясе моннан котыла бара. Хәзер инде якын кешеләр, ир-хатын, мәхәббәт җепләре белән үзара бәйләнгән кешеләр каршылыкка керә.

Бүгенге драматургиядә тематик төрлелеккә, конфликт кискенлегенә, вакыйга-ситуацияләр оригинальлегенә, эре типлар табуга омтылыш юлында авторларны һаман да бертөрле кимчелекләр сагалап тора. Хәер, андый кимчелекләр, авырлыклар элек тә хас булган. Артык киңәеп тормыйча, атаклы драматург Кәрим Тинчурин әйткәннәрне генә искә төшерик:

«Һәрбер каһарманның үткәндәге, бу көнге, иртәгәге характеры күренеп торырга тиеш. Шулай булганда гына каһарман чын кеше, әсәр өчен кирәкле кеше, тамашачыга тирән тәэсир калдыра ала торган кеше булып чыгачак. Бездәге драма әсәрләрендәге каһарманнарның унысыннан бер кеше ясап булмый.

Шуңа күрә берсенең сүзен икенчесенә күчерүдән, яисә берьюлы биш-алты кешене, каһарманны төшереп калудан «әсәргә» бер зыян да килми. Сүзләр дә каһарманнарның характерына каратылып сөйләтелми, теләсә кайсысының сүзен теләсә кайсысына биреп була. Шуның белән бергә сүздә мәгънә ягы да бик сай булып чыга». («Совет әдәбияты», 1933, 2-3 саннар).

70 ел әүвәл әйтелгән сүзләр. Ә нәкъ бүгенгечә, бүгенге күпчелек әсәрләргә каратып әйтелгәндәй яңгырыйлар. Иҗатчы кеше сәнгать камиллегенә ирешү юлында һәрчак истә тотарга тиешле таләпләр болар...

Кыскасы, соңгы елларда драматурглар ирешкән уңышларны һич тә кире какмаган хәлдә, драматургиябезнең үсеш дәрәҗәсе бүгенге укучыны вә тамашачыны канәгатьләндереп бетерә алмавын да таныргa тиешбез.

*Рецензияләр конкурсына*

# ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК

Фәүзия Бәйрәмова... Бу исем әдәбият-сәнгать сөючеләргә генә түгел, киң җәмәгатьчелеккә дә яхшы таныш. Берәүләр, ул исемне зурлап, хөрмәт һәм соклану белән телгә алса, икенчеләр исә, киресенчә, ачуларын яшерергә дә теләми. Моның сәбәбе барыбызга да яхшы билгеле, чөнки Ф. Бәйрәмова—озак еллар дәвамында Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәшкән, халкыбызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылып җан аткан, шуна бөтен көчен, талантын багышлаган милләтпәрвәр шәхес. Аның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге турында шактый язмалар пәйда булды, әле тагы да, һичшиксез, язылыр. Бүгенге сүзебез исә каләмен әдәбиятның проза, публицистика, шигърият, драматургия өлкәсендә сынап караган һәм һәрберсендә үз сүзен, саллы сүзен әйтеп килгән язучы Фәүзия Бәйрәмова турында. Әдибәнең киң катлау укучылар тарафыннан яратып кабул ителгән «Болын», «Моң», «Күл балыгы» һ. б. әсәрләре хакында Мансур Вәлиев, Фаяз Дунай, Фәиз Зөлкәрнәй, Рафаэль Мостафин кебек тәнкыйтьчеләр үз фикерләре белән уртаклашканнар иде. Әлеге иҗат, бәхәссез, җентекле, тулы өйрәнүне сорый. Безнең игътибар үзәгендә Ф. Бәйрәмованың «Безне онытмагыз» *(Казан, 1999)* исемле пьесалар җыентыгы тора.

Биредәге төрле елларда язылган әсәрләр жанрлары белән генә түгел, бәлки күтәрелгән тема-проблемалары, аларны хәл итү юллары белән дә бер-берсеннән шактый аерыла. Әмма аларны берләштерүче үзәк тә бар—ул автор үзе. Һәрбер пьеса артында без әдибәнең тынгысыз җанын, әзләнүчән характерын һәм күңел ярсуларынын, заманның чын мәгънәсендә актуаль мәсьәләләренең үткен һәм сәнгатьле каләм белән кәгазьгә төшерелүен күрәбез. Хәер, сәхнә өчен язылган әсәрләрнең үзләренә сүз бирик.

Татар әдәбиятында күренекле шәхесләрнең әдәби образларына мөрәҗәгать итү традициясе байтактан килә. Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Сөембикә, К. Насыйри, Акмулла, Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Яруллин кебек танылган әдәбият-сәнгать әһелләренә багышланган әсәрләр язылды. Ф. Бәйрәмова «Атылган йолдыз» драмасында егерменче елларның иң күренекле шагыйре Һади Такташны шәхес һәм әдип буларак аңларга тырыша, аның тормыш фаҗигасе сәбәпләрен ачыкларга омтыла. Үзәктә шәхес һәм җәмгыять каршылыгы тора. Әйе, катлаулы чор кешеләрне нәрсәне дә булса сайлау алдына куя. Берәүләр, намусларына хыянәт итмичә, Кеше дигән олы исемгә турылыклы булып калса, икенчеләр исә, хакимият идеологиясенә буйсынып, аның җырын җырлап, күбрәк шәхси мәнфәгатьләре белән генә яши һәм еш кына теләсә нинди түбәнлеккә төшә. Әсәрдә шундыйларның икесе шартлы исем белән Ак дус һәм Кара дус дип бирелә. Әйтергә кирәк, Такташ образын ачуда алар үзләренә салынган йөкләмәне тулысынча үтиләр. Ак һәм Кара дусларның тормыштагы прототиплары ачык гәүдәләнү, автор кулланган документаль язмаларның текстка уңышлы кертелүе Такташ яшәгән мохитне, аның кичергәннәрен, чор каршылыкларын тулырак сизэмләргә ярдәм итә.

Ф. Бәйрәмова шагыйрь Такташны әдәби процесс, сүз сәнгатенә гомуми караш фонында ача. Ул чорда еш кына үткән мирас, аның гүзәл казанышлары кире кагыла. Әдәбиятның асыл мәгънәсе һәм максаты бозып аңлатыла. Сәнгать әсәрләреннән тормышны натуралистларча күрсәтүне таләп итәләр, һәртөр футуризм, имажинизм кебек юнәлешләргә тарталар һәм, шул ук вакытта, әдәби иҗатка хас шартлылык, символ кебек сурәт тудыру алымнары кире кагыла. Алар, осталык үрнәге булудан бигрәк, булдыксызлык дип бәяләнә. Такташ әнә шундый шартларда иҗат итә. Әсәр

башында ул жаны-тәне белән халкына хезмәт итәргә чыккан яшь шагыйрь булып алга килеп баса. «Мин янмыйммы?! Бөтен уйларымны, хис-тойгыларымны, җанымны кешеләргә өләшәм»,—ди әдип. Шашкан хисле, күкрәге «янар таулар» белән тулы шагыйрьне әдәбиятка сөйрәлеп баручылар аңламый, кабул итми. Такташка яшьләр фикере генә ышаныч һәм көч бирә. Ф. Бәйрәмованың уңышы шунда—ул Такташ образын үсеш-үзгәрештә һәм бөтен каршылыгында күрсәтә алган. Ә бит герой алдына авырлык-кыенлыклар өелеп кенә тора. Хәтта дус булып йөрүчеләр дә заманга, системага яраклашырга өнди. Әлеге фикер драманың төп идеясе белән дә бәйле. Нәкъ менә яңа хакимияткә мәдхия укып яшәмәгәнгә атылган йолдыз кебек тиз янып бетә Такташ! Драматургның да монә күңеле сыкрый, җаны әрни. Әмма атылган йолдыз кебек бик азга гына караңгылыкны яктыртса да, Такташ үзенең иҗаты һәм шәхесе белән күпләргә шатлык өләшә, аның «атылган» юлы әдәбият үсешенә маяк булып хезмәт итә. Шагыйрьнең әдәбияттагы традицияләр, яңалыклар турындагы уйлары игътибарга лаек. Күренекле язучы, тәнкыйтьче Гали Рәхим Һ. Такташ иҗатына бүген дә кыйммәтен җуймаган бәя бирә: «Бу яшь шагыйрьдә безнең татар шагыйрьләренең күбесендә булмаган бер ялкын белән бергә гаҗәп нәзек шигърият һәм әдәби зәвык булганы күзгә бәреләә». Әлеге фикерне буржуазлык, мещанлык карашы диюче Кара дуска Такташ болай җавап бирә: «Революциянең теге ягыннан килгән тәнкыйтьчеләр әдәбиятны бик яхшы беләләр. Дөнья әдәбиятын! (...) Аларга каршы чыгарга түгел, алардан өйрәнергә кирәк». Әлеге юллар белән шагыйрь безгә дә мөрәҗәгать итә. Икенче яктан, драма авторы да бу фикерне яклый һәм Такташ кебек олы шәхесне, шагыйрьне әле безгә өйрәнергә дә өйрәнергә ди кебек.

«Шагыйрь үзе шигырьләрендә яши» дигән гыйбарә бар. Ф. Бәйрәмова да Такташ шигырьләрен, аерым штрихларда гына булса да, зәвыклы укучы-тәнкыйтьче буларак бәяли, шулар аша шагыйрьнең күңел дөньясын ачарга тырыша. Гомумән, әсәрдәге драматик хәрәкәтне үстерүдә шигъри текстлар зур роль уйный. Такташны иҗатчы буларак бәяли барып, драматург аның шигъриятенең үз чорында гына түгел, бүген дә заманча яңгырашын күрсәтә.

Такташны кеше буларак ачу зур җаваплылык сораса да, драматург үз максатына ирешкән. Шагыйрьнең эш-гамәлләре, характер сыйфатлары, ике Гөлчәһрәгә булган мөнәсәбәте укучыны ышандыра. Мәхәббәт хисе аңа көч, илһам бирә. Ул ярата да, яраттыра да белә. Такташ шәхесе турында уйланганда, автор белән әдәби образ арасындагы охшашлык, якынлыкны да сизәсең. Ф. Бәйрәмова олы шагыйрьнең хис-кичерешләр байлыгын, каршылыгын, җан газапларын бөтен күңеле белән аңлап, үзенеке кебек кабул иткән һәм драмада сәнгать чаралары белән шуларны сурәтли алган.

Бу җыентыктагы пьесаларны язмышлар дәрьясы дип атап булыр иде. Әдибәнең күпчелек геройлары—яшәп килгән система тарафыннан кагылган-сугылган хәлдә дә Кеше дигән олы исемгә тап төшермәгән характерлар. Андыйлар ил тәнендә тирән җәрәхәт калдырган вакыйгалар фонында тулырак ачыла. Әфган сугышы... империянең асылын гына түгел, бәлки бу илдә кеше гомере, милләтләр язмышы белән дә шахмат тактасындагы фигуралар кебек кенә эш итүләрен бөтен дөнья алдында фаш итте ул. Сиксәненче елларда татар авылында барган вакыйгаларны үз эченә алган «Сандугачның балалары» драмасы әнә шул турыда. Ике егет анасы Сандугач фаҗигасен Ф. Бәйрәмова милләт фаҗигасе дәрәҗәсенә күтәргән. Моңы, матурлыгы белән тирә-якта дан тоткан, хыялга бай күңел дөньясы белән яшәгән Сандугачның олы улы сугышта хәбәрсез югала, кайгыдан ана акылдан яза. Кече улын да әлеге мәхшәргә җибәрәләр, ирен төрмәгә ябалар. Б ерникадәр вакыттан соң, дөньядан хәбәре булмастай гариплэнгән олы улының, ни үле, ни тере дигәндәй, хәрәкәтсез гәүдәсен кайтаралар, ә кече улының үлгән хәбәре килә. Әлеге вакыйгаларда татар язмышы гәүдәләнә. Кемнәрнеңдер «шахмат уены» шартларына буйсынып, безнең милләт үзенең ин булдыклы, иң көчле, таза халыкның киләчәген тәэмин итәрдәй егетләрен Әфгандагы иттурагычка илтеп тыгарга мәҗбүр булды.

Вакыйгалар драматизмы Сандугач гаиләсе белән авыл советы рәисе Бәкер каршылыгына бәйле ике яссылыкта үстерелә. Совет власте исеме артына качып, авылдашларын төрлечә түбәнсетеп яшәүче Бәкер әлеге нәселнең тамырын корытмакчы. Баласының хәбәрсез югалуы, тормыш гаделсезлеге чыгырыннан чыгарган Габделхәйнең аңа балта күтәрүе тикмәгә түгел. «Мин болай да төрмәдә,—ди ул җан ачысы белән.—Минем мал көтүдән башкага хокукым юк». Бу инде гомере

буе көтү көтеп, булганына риза булып һәм власть алдында баш иеп яшәгән кешенең дөньяга ачык күз белән карый башлавы, күп нәрсәләрне аңлавы. Алай гына да түгел, бу инде аның яшәп килгән системадан ризасызлык белдерүе, каршылык күрсәтүе. Соңгысы исә өстә утыручылар өчен куркыныч нәрсә. Шуңа да алар төрле юллар белән Бәкер кебек куштан, куркак жаннарны, башка кеше сүзе белән генә яшәүчеләрне тәрбияләргә тырыштылар. Әсәрдә абстракт ил вәкиле белән сөйләшүче Брежнев сүзләре һәм Бәкернең фикер-карашлары арасындагы охшашлыкны күрми мөмкин түгел. Икенче яктан, автор милләтнең үз эчендәге куркыныч чирне дә читләтеп үтә алмый. Ананың олы улы Илһам армиягә киткәндә авылдашларына болай ди: «Бер-берегезне саклагыз!» Яшь егетнең әлеге тирән мәгънәле сүзләре халкыбызның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйланырга мәжбүр итә. Әйе, милләтебезгә хас сабырлык, түземлек, чисталык, хезмәт ярату, олыларны хөрмәтләү кебек сыйфатлар бары тик ихтирам гына уята. Шул ук вакытта, фажигале тарихыбыз күрсәткәнчә, хөсетлек, бергәлек булмау аны эчтән тарката, көчсезләндерә. Шундый шартларда Бәкер кебек куркак-ялагайлар тагы да арта башлый. Илһам сүзләре авторның безгә дә мөрәҗәгате булып тора.

Сандугач әсәрдә гомумиләштерелгән образ дәрәҗәсенә күтәрелеп, милләт анасы буларак ачыла. Әдибә аны матур кешелек сыйфатлары белән тасвирлый. Бала хәсрәтеннән акылын жуйган хәлдә дә ул Бәкер кебекләрдән бер башка өстен. Олы йөрәкле әлеге изге зат менә дигән балалар үстергән, сизгер ана күңеле аңа нәселен дәвам иттерергә мөмкинлек биргән, бердәнбер дөрес юлны күрсәтә.

Ф. Бәйрәмова символик образлар, шартлы алымнар, метафора булып килеп, мөһим идеяне аңларга ярдәм иткән күренешләр белән шактый иркен эш итә. «Сандугачның балалары»нда утын тумраны рәвешендәге «бала» тирән мәгънәгә ия. Тормышның ямен-тәмен тоеп, балалар үстереп, бәхеткә лаек булганнарның сугыш утында януы, аяк-кулсыз гарип булып калуы—бу гайре табигый күренеш. Моның белән автор милләт тамырына балта чабуга, аның киләчәгенә куркыныч янауга ишарә итә. Бу фикер Илһамның өенә үлгән сандугач баласы алып кайтуы сурәтләнгән, метафора булып килгән күренештә дә үстерелә—Табигать кошы сандугачның ике-өч баласы була, алар үтерелсә, әлеге затлы кош нәселе юкка чыгачак. Шулай да драматург үз әсәрен оптимистик рухта тәмамлый.

«Вакыйга жүләрләр йортында бара» пьесасында Ф. Бәйрәмова өр-яңа тормыш материалының сәнгатьчә сурәтләнешен укучыга тәкъдим итә. Әлеге сәяси сатирада жүләрләр йорты ул—Рәсәй дип аталган империя уртасында калган Татарстан, тасвирланган күренешләр—безнең яшәеш. Автор туксанынчы елларда һәркемнең телендә булган «ирек», «азатлык», «демократия», «суверенитет» кебек төшенчәләр аңлаткан фикерләрне сәхнәдәге күренешләр аша аңлатуны, әлегәчә ак-караны аера алмый йөрүчеләрнең күп нәрсәгә күзен ачуны максат итеп куя. Әсәрдә үткән белән бүгенгенең диалектик бәйләнеше ачык тоемлана. Түбәндәге өзеккә игътибар итик: «Демократ. Бу империя—дөньяның үзәге. Бөтен дөнья безнең аяк, то есть, кул астында булырга тиеш.Чөнки без—Иваннар—дөньяда иң акыллы халык. (...)

Милләтче. Һәм шушы тиле фикер сезне жүләрләр йортына китерде дә инде. Халкыгызны—һәлакәткә.

Демократ. Әмма бу вакытлы күренеш. Безнең йолдызыбыз мәңге сүнмәячәк. Ә мин сезне кызганам, Сөенбикә—ханбикә. Сезне милләтегез күзен дә йоммый сатып жибәрде.

Милләтче. Азатлык хакына алыштырды. Тынычлык хакына».

Тарих кабатлана диләр. XVI гасырдагы фажигале вакыйгаларның аерым чагылышларын без хәзер дә күрмибезмени? Әлеге диалог шуңа ишарә итә бит. Сөенбикә милләттәшләре тарафыннан «азатлык хакына» урысларга сатыла. Безнең көннәрдә, туксанынчы еллар башында, милли хәрәкәт лидерлары да «халыклар дуслыгы»н саклыйбыз дип, үз халкы кулы белән (дөрес, хакимият тарафыннан оештырылып) кыйналмадымени?

Пьеса әйләнә-тирәбездә барган һәм бара торган бик күп хәлләрне, вакыйгаларны яңача кузалларга, байтагының асыл мәгънәсенә тирәнрәк төшенергә ярдәм итә.

«Демократ. Күпме телисез, шул хәтле ирек алыгыз! Тик жүләрләр йорты кысаларында!

Тиле карт. Сон, моның нәрсә икәнен җүләр дә аңлый бит—җүләрләр йорты булсын да, ирек тә булсын!»

Әсәрдә, гомумән, демократия турында сүз боткасы ясап, халыкны талау, ил, республика байлыгын сатуның ничек оештырылуы, сәнгать чаралары мөмкинлек биргән хәлдә, шактый ачык сурәтләнә. Рәсәйнең, шул исәптән Татарстанның бөтен дөнья өчен сынау урынына, тәҗрибә мәйданына әйләнүен автор кат-кат басым ясап әйтә.

Публицистик стиль өстенлек иткән пьесада Тиле Ир һәм Тиле Хатын образларына бәйле фәлсәфи агым килеп керә. Драматург көтелмәгән каршылык тудыра: бу дөньяда әле матурлык, ярату дигән төшенчәләр дә бар икән бит!

«Тиле Ир. Кемнеңдер, нәрсәнеңдер колы булу белән кеше яшәүдән туктый.

Тиле Хатын. Без шундый ачыш ясадык—кеше кол булу өчен түгел, ярату өчен туган».

Әмма аларны аңламыйлар һәм аңларга да теләмиләр. Кызганычка каршы, бүгенге җәмгыятебездә һәртөр әхлаксызлык, ямьсезлек, пычраклык өстенлек итә шул.

Җыентык исеме итеп тә алынган «Безне онытмагыз» драмасы «37 ел синдромы»н аңларга омтылу белән игътибарга лаек. «Шәхес культы»ның канлы фаҗигалары, барлыкка килү сәбәпләре турында шактый әсәрләр дөнья күрде. Ф. Бәйрәмова аларны кабатламый. Әсәрдә вакыйгалар ике катламда булып, үзәктә 37 ел афәтен үз башларыннан кичергән кешеләрнең 50 елдан соң ул хәлләргә мөнәсәбәтен ачыклау тора. Әлеге вакыйгалар сиксәненче еллар уртасында җәмгыятьне куркуга салган күренеш—яшүсмерләрдән торган төркемнәрнең үзара сугышулары фонында бара. Алай гына да түгел, драматург тарихка «Казан феномены» исеме белән кереп калган әлеге коточкыч хәлнең сәбәпләрен шул ук утызынчы елларга бәйләп аңлата. Тоталитар система кешене физик яктан бигрәк рухи яктан какшата, аның акылын ала, күңеленә куркаклык, мескенлек, коллык психологиясе сеңдерә. Ахыр чиктә без дә бит шул куркытылганнарның балалары, оныклары. Яшь буын вәкиле Эдик әнә нәрсә ди: «Безнең максат—мескен булмау! Безнең максат—кол булмау! Безнең максат—тимергә әйләнү!» Икенче урында ул тормышка карашын тагын да ачыграк әйтә: «Безнең ышаныр нәрсәбез калмады, шуңа күрә барысын ватабыз да җимерәбез. Кайда Аллагыз, кайда идеалларыгыз?! Үткәннәрне гел яндыра, юкка чыгара барасыз».

Драмада «халык дошманнары» хатыннары Айсылу, Суфия, Гадилә, куркытудан гомере буе «телсез» булып яшәгән Җамал, НКВД работнигы Кыяметдин типик образлар буларак ачыла. Чор каршылыклары, җәмгыятьтә биләгән урыннары, ихтыяр көче, характер сыйфатлары аларның эш-гамәлен билгели. Баланы анадан, хатынны ирennән баш тартырга мәҗбүр иткән җәмгыятькә җан әрни. Чорның кешегә китергән газап-михнәтләре сурәтләнгән урыннарны тыныч кына укып та булмый. 20 ел лагерьда булып, аннан сукыраеп кайткан Галимҗанның үзеннән баш тартырга мәҗбүр булган хатыны Айсылу белән соңгы кабат очрашуында кешегә төшкән фаҗиганең аяусызлыгы, язмышка ачыну бөтен тулылыгында һәм авторның җан сыкравы булып ачыла:

«Галимҗан. (...) Үтте дә китте гомер. Яшәмәгән дә кебек... Башка күрешмәсәк, бәхил бул, Айсылу.

Айсылу. Син мине кичерә алмассың инде, Галимҗан? Гаебем зур. Кичерә алсаң, кичер мине. (Алдына тезләнә.)

Галимҗан. Синең гаебең юк, Айсылу... Мин булмасам, син бу газапларны күрер идеңме? Бәхет өчен туган идең бит син. Дөнья миннән көчлерәк булып чыкты. Берни эшли алмадым синең өчен... Берни эшли алмадым».

Драма үткәнне сурәтләсә дә, киләчәккә атап язылган. Теге вакытта каршы якта, җәза бирүчеләр төркемендә булган Кыяметдин Эдикка беркайчан да шөреп хәленә калмаска, башкалар кулында корал булмаска киңәш итә. Ә инде Айсылуның үзләренә биргән бәясе безгә дә кисәтү булып яңгырый: «Ул елларда халык (...) куркакка әйләнде. Халык бергә укмашканда гына халык шул, аерым-аерым башны кистергәндә аны сарыкка әйләндерәләр».

Безне онытмагыз... Әлеге исем белән автор, бер яктан, утызынчы еллардагы репрессия корбаннарын, ул афәтне башларыннан кичергәннәрнең якты истәлеген сакларга чакырса, икенче яктан, тарихыбызның фаҗигале сәхифәләрен онытмаска

әнди. Чөнки алар онытылу яңа, тагы да зуррак кайгы-хәсрәтләргә китерәчәк. Чечен республикасындагы канлы вакыйгалар шуның ачык мисалы түгелмени?

Мәгърифәтчелек чорыннан алып ук татар әдәбиятының үзәгендә торган милләт язмышы мәсьәләсе Ф. Бәйрәмова пьесаларын да иңләп үтә. Ерактагы һәм якындагы тарихка мөрәҗәгать итеп, язучы алар белән бүгенгебезне тоташтыра һәм киләчәгебезгә күпер сала. Һәр сурәтләнгән вакыйга-күренештә «яхшылык» һәм «явызлык» төшенчәләренә бәйле көрәш эстетик кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрелә. Ф. Бәйрәмова драмаларының идея-эстетик үзенчәлеге, беренче чиратта, автор идеяларының ачыклыгы, чисталыгы, чынбарлыкны әхлакый кыйммәтләрдән чыгып аңлавы белән бәйле. Әдибә үзенең фикерләрен, карашларын олы характерлар дәрәҗәсенә күтәрелгән образлар аша укучысына житкерә һәм, әйтергә кирәк, алар җыелма, типик яисә Такташ кебек олы шәхеснең әдәби сурәте булырга мөмкиннәр, әмма аларның һәрберсенең үз йөзе бар.

Әдәби әсәр язучының тормышка карашы, аны кузаллавы нәтиҗәсендә туа. Пьесаларында драматург әйләнә-тирә дөньяны үз аңлавында сурәтли. Аларда уңышлы гомумиләштерүләр булган кебек, ул күзаллаган яшәеш, ягъни яклаган яки кире каккан кыйммәтләр бер төрле генә кабул ителмиләр, бәлки күптөрле фикерләр уятып, укучыны нинди дә булса актив хәрәкәткә чакыралар. Әсәрләрнең асыл мәгънәсенә тулырак төшенгән саен, авторның безгә караганда күбрәк, тирәнрәк күрүен, аңлавын тоясың.

Белгәнебезчә, әсәрнең кыйммәте идея-проблематиканың актуальлеге һәм аны укучыга житкерүче алым-чараларның муллыгы, бизәклеге белән бәйле. Ф. Бәйрәмова һәр пьесасында эчтәлек һәм форма берлегенә ирешә алган. Аның Г. Коләхмәтов, К. Тинчуриннардан ук килә торган символик һәм метафора булырдай вакыйгалардан, шартлылыктан, аллегорик образлардан уңышлы файдалануы турында алда сүз булган иде. Алар, яңа эчтәлек белән баетылып, язучының иҗат индивидуальлеген күрсәтәләр. Драматургның телен матур, чиста дияр идем. Дөрес, әсәрләре чагыштыруларга, мәкаль-әйтемнәргә h. б. сурәтләү чараларына артык бай түгел, урыны белән публицистика теле өстенлек итә. Әмма ул сүз эзләп кесәгә керми, фикерен укучыга ачык, аңлаешлы житкерә ала.

Татар театрлары Ф. Бәйрәмова пьесаларына бик аз мөрәҗәгать итә. Бу, бер яктан, әсәрләренең сәнгати дәрәҗәсе бертөрле генә булмау белән аңлатылса, икенче яктан, моңа драматургның фәлсәфи тирәнлек, сәяси үткенлек бөркелеп торган пьесаларыннан режиссерларның «куркуы» сәбәптер, күрәсең. Әлеге җыентыкка кергән әсәрләр дә төрле фикер-карашлар уятыр. Пьесаларның эшләнешендә житешсезлекләр дә бар, билгеле. Мисал өчен, «Сандугачның балалары»нда урыны белән бераз ясалмалылык сизелсә, «Вакыйга җуләрләр йортында бара» да драматик хәрәкәт сүлпәнрәк булып, вакыт-вакыт сурәтләүдән бигрәк сөйләү өстенлек итә кебек. Арада «Атылган йолдыз» драмасы аерылып тора. Пьеса сәнгати эшләнеше, акцентларның ачыклыгы, заманча яңгырашы белән сәхнәгә соралып тора. Драманың Г. Камал театры сәхнәсендә уйналуы татар поэзиясе күгендә балкып янган, әмма вакытсыз атылган йолдыз Һади Такташның 100 еллык юбилеена зур бүләк була алыр иде.

Гомумән, «Безне онытмагыз» җыентыгы Фәүзия Бәйрәмованың үзенә хас стиле барлыгын, аның драматург буларак тулысынча формалашып житүен, хәзерге сәхнә әдәбиятында үз урынын торган саен киңрәк яулый баруын раслый һәм, үз чиратында, әдибәнең киләчәк эзләнүләренә ныклы нигез булып тора.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,**
*КДУ доценты*

*Дин һәм тормыш*

# КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

## 1—Фатиха (ачучы) сүрәсе

*(Фатиха сүрәсе 7 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Корьәнне башлаучы, Корьән эченә алып керүче, китапны ачучы, Корьән укый башларга рөхсәт бирүче сүз—Фатиха. Ана телебезгә ул сүз: атаң-анаң фатихасын алмыйча эш кылма, фатихасыз башлаган эш уңышлы булмас, ягез,—бер фатиха, диган кебек тәгъбирләрдә еш кулланыла. Фатиха сүрәсеннән башка Корьән ачылмас, намаз да укылмас.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Мәрхәмәтле вә рәхимле Аллаһ исеме белән *(башлыймын)*.

**2.** Бөтен галәмнәрнең *(халыкларның)* хуҗасы *(тәрбиячесе)* Аллаһка шан-шәрәфләр булсын!

**3.** *(Ул)* мәрхәмәтле, рәхимле.

**4.** Җәза Көненең *(Ахирәтнең)* хуҗасы.

**5.** Бары тик Сиңа *(гына буйсынып)* гыйбадәт кылабыз һәм (бары тик) Синнән (генә) ярдәм өмет итәбез.

**6.** Безне туры юлга—рәхмәтенә-нигъмәтләренә ирешкәннәр юлына күндер.

**7.** *(Зинһар)* юлдан язганнар вә нәфрәтенә дучар булганнар юлына төшермә!

***(Менә бу—Фатиха сүрәсенең асыл нөсхәсендәгеңә якын тәрҗемәсе. Бу сүрәне галимнәр нигездә бер төрле тәрҗемә итсәләр дә, аермалары шактый. Һәр телнең үзенчәлеге, көче, куәте булган кеби Ана телебезнең дә үзенчәлекләрен искә алып, без Фатиха сүрәсен, тәҗрибә буларак, шушы шәкелдә, ягъни, тәфсирле тәрҗемәдә тәкъдим итеп карыйбыз.)***

Әгүзү билләһи миннәш-шәйтан ир-ражим

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

Игелекле эшемне, изге догамны, ялваруымны мәрхәмәтле вә рәхимле Аллаһның исеме белән башлыймын. Бөтен галәмнәрнең, барча халыкларның гадел хуҗасы, тәрбиячесе Аллаһка шан-шәрәфләр, дан вә мактаулар булсын! Йа, Иляһем, Син мәрхәмәтле, Син рәхимле. Син—бу дөньяның да, Ахирәтнең дә хуҗасы һәм тәрбиячесе. Бары тик Сиңа гына буйсынып, баш орып, гыйбадәт кылабыз. Бары тик Синнән генә ярдәм өмет итәбез. Без, бәндәләреңне, изге кешеләр йөри торган туры юлга, ягъни рәхмәтенә, нигъмәтләренә ирешкәннәр юлына күндер, безгә мул нигъмәтләреңне насыйп әйлә. Зинһар, безне юлдан язганнар вә Синең нәфрәтенә, җәзаңа дучар булганнар юлына төшермә!

*(Фатиха сүрәсен укып тәмамлагач, **ә-ә-ми-и-ин**, ягъни, **теләкләремне кабул кыл**, дип әйтеш кирәк.)*

## 2—Бәкара (сыер) сүрәсе

*(Бәкара сүрәсе 286 аятьтән тора. Мәдинә шәһәрендә иңгән. Бәкара—сыер дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

*1.* Әлм *(Әлиф, ләм, мим)*. *(Өч хәрефтән торган ошбу кыска аятьнең төгәл мәгънәсен әйтүче юк. Татарча тәфсирләрдә «Бу хәрефләрнең мәгънәсен бер Аллаһ белә» дип кенә әйтелә. Ләкин соңгы тәрҗемә һәм тәфсирләрдә бу хәрефләрдән ӘЛМ — «Я, Аллах, лучший Знающий» дип, Лондон нөсхәсендә «Я — Аллах Всеведущий» дип аңлатыла.*

*Татарчада: «Мин — Аллаһ — чиксез кодрәт һәм белем иясе», Галәмдә Миңа тиң кодрәт вә гыйлем иясе юк, дип шәрехләр идек).*

**2.** Шөбһәсез ки, бу Китап мөттәкыйлар *(үз бурычларына тугры кешеләр)* өчен юл күрсәтүчедер.

*(**Мөттәкыйн**—тәкъва, дин кануннарын ихлас тотучы, гөнаһ кылудан, Аллаһның нәфрәтеннән куркучы саф мөселман.)*

**3.** Алар күзгә күренмәгәннәргә ышана, алар намаз укый, Без биргән малларын Аллаһ юлында сарыф итә.

*(**Күзгә күренмәгәннәр:** Аллаh, фәрештәләр. Матдәләрнең иң вак кисәкчекләрен һәм сулыш торган һавабызны без күрмибез, әмма мантыйк (логика) һәм күңел күзе белән аларны күрәбез, аларның барлыгына инанабыз. Шулай итеп, без Аллаһның Үзен, фәрештәләрне, җеннәрне күрмәсәк тә, аларның барлыгына ышанабыз. Аллаһ ярдәме белән тапкан малларыбызны Аллаһ юлында сарыф итәбез: хәер-садәка, зәкят бирәбез, хаҗга барабыз, ятимнәргә, мохтаҗларга ярдәм итәбез.)*

**4.** *(Ий, Мөхәммәд)* алар сиңа индерелгән һәм сиңа чаклы индерелгәннәргә *(Коръәнгә, аннан алдагы изге китапларга)* инаналар, Ахирәт көненә дә чын күңелдән ышаналар. **(5)** Алар Раббы күрсәткән хак юлдадыр вә тәмуггтан котылуга ирешүчеләр дә шулар булыр.

**6.** *(Дөресе шулдыр ки)* кәфер кылучыларны *(Ахирәттәге җәзалар белән)* кисәтсәң дә, кисәтмәсәң дә—барыбер; алар ышанмас *(иман китермәс)*. **(7)** *(Кылган гөнаһлары, кулланган харамнары өчен)* Аллаһ аларнын күңелләренә йозак салды һәм аларның колакларын томалады, аларның **(күңел)** күзләрен элпә белән каплады вә алар өчен җәза әзерләде.

**8.** Кешеләр арасында шундыйлар да бар, күңелләре белән инанмаган килеш: Аллаһка вә Ахирәт көненә ышанабыз,—дип әйтсәләр дә, андыйлар чын мөселман түгел.

*(Эчтән ышанмыйча, үз файдалары өчен, кешеләр алдында гына ышанган булып кыланучы бу икейөзле бәндәләр «монафикъләр» дип атала.)*

**9.** Алар *(монафикъләр)* Аллаһны да, мөэминнәрне дә алдамакчы була. Ләкин алар үзләре алдана һәм алданганлыкларын абайламыйлар да. **(10)** Аларның күңелендә чир *(икейөзлелек чире)* бар. Аллаһ аларның бу чирен тагын да арттырды. Ялган сөйләгәннәре өчен аларга хәтәр газап бардыр.

**11.** Аларга:—Җир йөзендә коткы таратмагыз *(бозыклык, фетнә чыгармагыз)*,—дип әйтелсә дә, алар:

—Без фәкать Җир йөзен коткыдан *(бозыклыктан, фетнәләрдән)* тазартучылар,—диләр.

**12**. Шуны белеп торыгыз, алар, чыннан да, үзләре коткы таратучы *(фетнә чыгаручы)*. Ләкин алар моны сизми *(бу турыда башларына да китерми)*.

**13.** Аларга:

—Иман китергән адәмнәр кеби, сез дә иманга килегез,—дип әйтелсә дә алар:—Ахмаклар иман китерә, дип, без дә иман китерикме?—диләр. Чынлап та, алар үзләре ахмак, ләкин бу турыда үзләре генә белми.

*(Ислам динен кабул итүчеләр фәкыйрь-юксыл кешеләр иде. Алар арасында хәтта коллар да булган. Монафикъләр үзләренчә: әнә шул мескен бәндәләргә охшап, без дә мөселман булыйкмы, без дә мескен булыйкмы, диделәр.)*

**14**. *(Монафикъләр)* мөэминнәр белән очрашканда:

—Без дә иман китердек,—диләр. Үзләрен аздыручы шайтани затлар янында бергә-бер калгач:

—Без сезнең белән бергә: без аларны *(мөселманнарны)* мыскыл итәр өчен генә шулай шаяртабыз,—диләр.

**15**. *(Чынлыкта исә)* Аллаһ алардан *(мыскыллы)* көлә *(мәсхәрәгә калдыра)*, азгынлыкларына юл куя. *(Шуңа күрә)* алар *(үзләрен үзләре белештермичә)* шулай адашып йөри. **(16)** Иманга килеп, тугры юл сайлыйсы урында азгынлык юлын сатып алган затлар шулар булыр. Ләкин аларның бу сәүдәсе уңышлы булмас һәм үзләре тугры юлга басмас.

*(Адәмнәр берничә төргә бүленә. Беренчеләре—мөселманнар, мөэминнәр биш баганага таяна. 1. Тәүхид: «Лә иләһә иллалаһу вә Мөхәммәде Рәсүлуллаһе» (Аллаһтан башка тәңре юк, Мөхәммәд аның илчесе). 2. Намаз уку. 3. Ураза тоту. 4. Зәкят бирү. 5. Хаҗга бару.*

*Мөселманның тайпылмыйча үтәргә тиеш вазифалары шулар. Икенче төр кешеләр—кяферләр. Исламны кабул итмәгәннәр, Аллаһны инкарь итүчеләр. Өченче төр кешеләр: монафикълар. Икейөзле ялганчылар, мәкерле бәндәләр. Игелексез кешеләр. Денсез булып та, Аллаһка ышанган булып кыланучылар.)*

**17**. Алар караңгыда чыра яндырып утыручыларга охшаш. Чыра тирә-якка яктылык сирпеп торганда, Аллаһ яктылыкны сүндерсә, тегеләр күзгә төртсәң күренмәслек дөм караңгыда калачак.

*(«Монафикълар башта Исламны кабул итеп, ягъни яктылыкка ирешкәч кенә, соңыннан кяферлеккә кайталар да, күңелләрендәге нур сүнеп, аларның җаннары караңгыда кала».)*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**18**. *(Алар)* сукыр, телсез-чукраклар. *(Шуңа күрә, алар тугры юлга)* әйләнеп кайталмыйлар. **(19)** Алар Күктән чиләкләп койган яңгырга эләгеп, Күк күкрәүләр вә дәһшәтле яшеннәр астында калгандай булыр. Ул монафикълар яшен сугудан куркып, бармаклары белән колакларын томаларлар. Ләкин Аллаһ кяферләрне һәрьяклап *(җәзасы белән)* чорнап алачак. **(20)** Яшен аларның күзләрен көйдереп чыгарырдай булып, якында гына яшьни, тирә-юньне яктыртып алганда, алар бераз алга китә, кинәт ингән караңгыда алар баскан җирләрендә катып кала. Әгәр теләсә, Аллаһ, әлбәттә, аларның колакларын саңгыраулата, күзләрен сукырайта ала. Чынлыкта Аллаһ һәрнәрсәгә кадир *(һәрнәрсәне эшли ала торган кодрәткә ия)*.

*(Дөньяда Ислам дине барлыкка килгәч, кяферләрнең зиһенендә фикер вермәләре куба; аларны икеләнү, курку биләп ала. Бәлки Ислам юлыннан китәргәдер, дигән кебек уйлар белән җәфалана башлыйлар.)*

**21**. Әй, инсаннар! Сезне һәм сездән элек яшәгәннәрне яралткан Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз. *(Шулай итсәгез)* бәлки сез *(гөнаһтан, начарлыктан, Аллаһның җәзасыннан)* котылырсыз, тәкъвалыкка ирешерсез.

**22**. Ул сезнең өчен җирне ястык итеп түшәде. Күкне дә гөмбәзле итеп, бина кылды. Күктән су агызып, сезнең тамагыгыз туйсын, дип төрле-төрле җимешләр үстерде. Шуны белгән көе Аллаһка тиңдәш эзләмәгез.

**23**. Әгәр илчебезгә *(Мөхәммәдкә)* индерелгән *(Коръән)*гә шикләнеп карасагыз, әгәр дә сез хаклы икән, Аллаһтан башка ярдәмчеләрегезне чакыртып, шуңа охшаш, ичмасам, бер сүрә китереп күрсәтегез. **(24)** Әгәр шулай эшли алмасагыз, һич шик юк ки, сез моны эшли алмаячаксыз, утын урынына кешеләрне, ташларны ягып кыздырган җәһәннәмнән сакланыгыз. Җәһәннәм уты кяферләр өчен әзерләнде.

**25**. *(Ий, Мөхәммәд)* иман китереп, игелекле гамәлләр кылгучыларга чишмәләре агып торучы җәннәтләр булачак, дип кешеләрдән сөенче ал. Ул җәннәтләрдә аларның алдына җимешләр китереп куйгач, алар:

—Бу җимешләрне без фани дөньяда да ашаган идек бит инде,—дип әйтерләр. Ләкин ул җимешләр тышкы яктан гына тегеләренә охшаган булыр. *(Тәмнәре бөтенләй үзгә, гаҗәеп ләззәтле вә татлы булыр.)* Алар өчен *(җәннәттә)* пакъ хатыннар булыр. Вә алар *(мөэминнәр)* анда мәңге яшәп калачак.

26. Шик юк ки, Аллаһ черки вә аннан башка хәшәрәтрәкләрне дә гыйбрәти мисал итеп китерергә тартынмас. Иманлы кешеләргә килсәк, алар мондый гыйбрәтле мисалларның Раббыдан килгәнлеген һәм ул мисалларның дөрес вә чын икәнен аңларлар.

Кяферләргә килсәк, алар:

—Аллаһ нинди максат илә шундый гыйбрәтләр китерә?—ди.

Аллаһ бу гыйбрәтле мисаллары белән байтак кешеләрне адаштырыр, байтагын тугры юлга юнәлтер. Китергән мисаллары белән Аллаһ бары тик азгыннарны гына адаштырыр.

**27**. Алар *(фасикълар, азгыннар, әхлаксызлар)* шундый бәндәләр ки, ант итеп, сүз бирәләр дә, шул сүзләреннән таналар. Аллаһ тоташтырырга боерган нәрсәләрне кисәләр *(мөселманнардан, Коръәннән аерылалар)* вә Җир йөзендә фетнә-тәртипсезлек *(азгынлык)* китереп чыгаралар. Менә шулар инде чынлыкта алданачак *(зыян-зәхмәт күрәчәк)*.

**28**. *(Һәй, кяферләр!)* Сез җансызларга җан өреп җанландырган *(сезне дөньяга китергән)* Аллаһны ничек инкарь итәсез? Соңра Ул сезнең җаныгызны алачак, янә тагын сезне *(Ахирәттә)* терелтәчәк. Һәм ахырда сез Аның каршысына кайтачаксыз.

*(**Инкарь итү**—Аллаһны танымау, Кыямәт көненә ышанмау, пәйгамбәрләрнең вәгазьләрен ялганга чыгару.)*

**29**. Жир йөзендә ни булса, Ул барысын да сезнең өчен яралтты. Сонра Күккә юнәлде, аны жиде кат итеп корды. Ул барысын да белүче.

**30**. *(Ий, Мөхәммәд)* исеңдә тот, Раббың фәрештәләргә әйтте:

- Мин Җир йөзенә *(Адәмне)* хәлифә *(башлык, хуҗа)* итеп яралтачакмын,—диде. Фәрештәләр әйтте:

- Безләр Сине мактап, тәсбих әйтеп, Аллаһ Тәгалә кимчелекләрдән азат, дип, Сине зурлап торганда, Җир өстендә азгынлык кылачак һәм кан коячак бәндәннеме хәлифә итеп куячаксың?—диделәр.

*(Аллаһ аларга)* әйтте:

—Сез белмәгәннәрне һәрхәлдә мин беләмен,—диде. *(Хәлифә—урынбасар, өстән боерганнар буенча эшне дәвам итүче, варис, хуҗа.)*

**31**. Аллаһ Адәмгә дөньядагы бөтен исемнәрне *(атамаларны)* өйрәтте дә, аларны фәрештәләренә белдереп боерды:

—Әгәр дә сез әйткәннәр дөрес булса, ул белгән исемнәрне әйтеп бирегез,— диде. **(32)** Фәрештәләр әйтте:

—Сөбхәналлаһ! *(Дан Сиңа, пакъ Раббыбыз)*: Син безгә өйрәткәннәрдән гайре без һичнәрсә белмибез. Шик юк ки, Син Үзең һәм галим, һәм хаким. **(33)** *(Аллаһ)* әйтте:

—Ий, Адәм, исемнәрнең барчасын да аларга санап күрсәт,—диде.

Адәм фәрештәләргә ул исемнәрне әйтеп биргәч, Аллаһ янә әйтте:

—Мин сезгә: Күкләрдәге һәм Җир йөзендәге күренмәгән нәрсәләрне дә, серләрне күреп-белеп торам, димәдеммени? Сезнең ачык рәвештә һәм яшерен кылганнарыгызны белеп торамын, димәдеммени? **(34)** Һәм Без фәрештәләргә әйттек ки:

—Адәмне хөрмәтләп, аңа сәҗдә итегез,—дидек.

Иблистән кала, барча фәрештәләр дә сәҗдә итте. Ул әмеремнән йөз чөерде. Горурлыгын җиңә алмады; ул ышанмаучы кяферләрдән иде. **(35)** Вә Без әйттек:

—Ий, Адәм, син хатының белән бергә җәннәттә яшәрсең, җәннәтнең теләсә кай төшендә, теләгәнегезчә ризык җыегыз, ләкин бары тик менә бу агачка гына якын килмәгез. Бу агачның җимешен ашасагыз,—икегез дә гаделсез золымчы булырсыз,— дидек.

**36**. Шайтан котыртып *(бу агачның җимешен ашасагыз, мәңге җәннәттә калачаксыз, дип)*, аларны юлдан яздырды һәм җәннәттән чыгарттырды. *(Шунда Без)* әйттек ки:

—Сез *(Адәм белән Иблис)* бер-берегезгә дошман булып, Җиргә төшегез. Җир сезнең торыр урыныгыз булыр. Яшәү өчен анда кирәк-ярак табарсыз. Һәм сез үз вакытыгыз килеп житкәнчегә чаклы шунда гомер кичерерсез,—дидек.

**37**. Аннан соң Адәм *(кылган эшенә тәүбә итте)* Раббыдан гафу үтенде. Аллаһ аны кичерде. Аллаһ тәүбәләрне кабул итүче миһербан ияседер.

**38**. Без әйттек ки:

—Бөтенегез *(өчегез дә: Адәм, Һәүва, Иблис)* җәннәттән чыгыгыз *(Җиргә төшегез)*. Миннән сезне тугры юлга өндәүче күрсәтмәләр килер, шул аятьләремә тугры калганыгызга бернинди дә куркыныч булмас һәм андыйлар хәсрәт чикмәс.

**39**. Аятьләребезне инкарь итүчеләр, ул сүзләрне ялганга чыгаручылар ут әһелләре *(җәһәннәмнекеләр)* булыр, алар анда мәңге калачак.

**40**. Әй, Исраил токымы, *(Исраил—Ягъкуб пәйгамбәрнең бүтән исеме)*. Сезгә биргән нигъмәтләремне исегездән чыгармагыз. Миңа биргән вәгъдәгезне *(китапта язылганча яшәрбез, дигәнегезне)* үтәгез. Мин дә сезгә вәгъдә иткәннәремне *(җәннәтне)* бирермен. Бары тик минем җәзамнан гына куркыгыз. **(41)** Кулыгыздагы китап *(Тәүрат)*ны раслау өчен иңдерелгән *(Коръән)*гә иман китерегез. Аң булыгыз, аны беренче булып инкарь итүчеләрдән булмагыз. Аятьләремне дөнья малына сатмагыз. Бары тик Мин бирәчәк җәзадан гына куркыгыз. **(42)** Хак сүзне нәҗес-ялганга алмашмагыз. Белгән көенчә, дөреслекне яшермәгез. **(43)** Намазны төгәл укыгыз, зәкятны тиешенчә бирегез. Рөкугъ иткәннәр белән бергә рөкугъ итегез. **(44)** Сез китап *(Тауратны)* укыйсыз, кешеләрне игелеккә өндисез, ә үзегез кылган *(яманлыклар)*ны онытасыз. Шулар турында акылыгыз белән уйлап бакканыгыз бармы? **(45)** Сабырлык белән намаз укып, Аллаһтан ярдәм сорагыз. Шик юк ки, бу эш күңелләрендә Аллаһка мәхәббәт тәрбия иткәннәр өчен кыен булмас. Башкалар өчен *(сабыр итү, намаз уку,*

*ураза тоту, хаҗга бару, зәкят бирү)* бик тә кыен эштер. **(46)** Алар *(түзем-сабыр кешеләр, намаз укучылар)*—Раббы белән кавышачакларына һәм Аның хөкеменә кайтачакларына нык инанган кешеләр. **(47)** Һәй, Исраил токымы, сезгә биргән нигъмәтемне вә сезне барча галәмгә *(халыкларга)* өстен кылганымны онытмагыз. **(48)** Сез киләчәк шундый бер Көннән *(Кыямәттән)* куркыгыз, ул Көнне һичкем башка кеше өчен химая тотмас. *(Аллаһтан башка)* һичкем тәүбәләрне кабул итмәс. Фидия *(җәзадан котылу өчен түләү)* алынмас, аларга *(гөнаһлыларга)* ярдәм итүче булмас. **(49)** Онытмагыз, сезне Фиргавен токымыннан коткардык. Алар сезгә хәтәр афәтләр китереп, яңа туган ир балаларыгызны суеп, кызларыгызны гына исән калдыра иде. Бу да сезгә Аллаһ тарафыннан җибәрелгән хәтәр сынау иде.

***(Рөкүгъ**—намазда, Аллаһ алдында баш ию, иелү.)*

***(«Борынгы Мысыр падишаһлары «фиргавен» диеп йөртелә иде. Хәзрәти Мусаның дөньяга киләчәге турында хәбәр ителгәч, күрәзәчеләр Исраил (Ягъкуб) нәселеннән туган ир баланың Фиргавеннең таҗын бәреп төшереп, тәхетен тар-мар итәчәге турында әйтәләр. Шуңа күрә, Фиргавен яңа туган һәр ир баланы бугазларга боера»).***

Али Өзәк тәфсиреннән.

**50**. Әүвәлендә Без сезнең өчен диңгезне урталай ярдык. Сез карап-күреп торганда Фиргавен кавемен дә диңгезгә батырып, һәлак иттек.

**51**. Мусага кырык көн, кырык төн көтәргә боерып, шул вакыт эчендә аңа китап иңдерергә сүз биргән идек. Соңра сез бозауга табына башладыгыз һәм гөнаһка батып, залим булдыгыз.

***(«Хәзрәти Муса кырык көн Күктән китап иңгәнне көткән арада Самири исемле берәү алтыннан бозау сыны ясап, кешеләргә: бу сезнең Раббыгыз, диде. Мусаның кардәшләре, ягъни яһүдиләр, шул сынга табына башлады»).***

Али Өзәк тәфсиреннән.

**52**. Шул кылмышыгыздан соң *(акылга килерсез)* шөкер итәрсез, дип сезне гафу иттек. **(53)** Тугры юлны табарсыз дип, Мусага Китапны һәм *(Хакыйкатьтән яманны аера торган хөкемнәрне)* Фурканны бирдек. **(54)** Шуннан соң Муса үз кавеменә әйтте:

—Әй, кардәшләрем, шик юк ки, сез бозауга табынуыгыз белән үзегезгә зыян китердегез. Шуңа күрә, кылганнарыгыз өчен, Яралтучы каршында үзегезнең гөнаһлы нәфесләрегезне үтерегез. Шулай эшләсәгез, Яралтучы каршында йөзегез ак булыр. Аллаһ тәүбәләрне кабул итә. Тәүбәләрне кабул итүче, мәрхәмәтле ярлыкаучы бары тик Аллаһ кына.

**55**. Сез миңа шулай:

—Ий, Муса, без Аллаһның Үзен үз күзләребез белән күрмәенчә, сиңа ышанмыйбыз,—дип басып карап торган чагыгызда сезне яшен сукты. (56) Аннан соң сезне яңадан терелттек. Бәлки шөкер итәрсез? Ә? (57) Өстегезгә болыт җибәреп, сезгә күләгә ясадык. Күкләрдән илаһи эчемлек белән бүдәнә ите иңдердек.

—Без биргән тәмле ризыклардан авыз итегез,—дидек. Чынлыкта алар Безгә түгел, үзләренә начарлык кылды.

*( **Ногманида:** ширбәт һәм кош ите, диелгән. Күпчелек тәфсирләрдә: кодрәт хәлвәсе, дип язылган. Бүдәнәнең ите бик тәмле, иң шөһрәтле ризыклар рәтенә керә.)*

**58**. Бу авылга *(Әрихәгә)* керегез; анда ни тапсагыз, шуны теләгәнегезчә, мул итеп ашагыз; капкадан иелеп керегез. Кергәндә:

—Аллаһ, зинһар, безне гафу ит,—диеп әйтегез.

Шулай эшләсәгез, хаталарыгызны кичерербез. Итагатьле булганнарга артыгы белән казаныш бирербез,—дидек. **(59)** Ләкин бу итагатьсезләр кушканны үтәмичә, башка сүзләр сөйләнеп, капкадан узды. Кылган яманлыкларына күрә, Без ул залимнәр өстенә Күктән әче газап иңдердек.

**60**. *(Чүлдә чакта)* Муса үзенең халкы өчен *(Аллаһтан)* су сорады. Без аңа:

—Таягың белән ташка ор!—дидек.

Шул мизгелдә уникe чишмә бәреп чыкты. *(Мусаның халкы унике кабиләдән тора иде.)* Һәр кабилә үз чишмәсен тапты.

—Аллаһ биргән ризыкны ашагыз, эчегез, ләкин сак булыгыз, Җир йөзендә азгынлык-бозыклык таратмагыз,—дидек.

**61**. Янә сез әйттегез:

—Ий, Муса, без шушы ризыкларга гына разый түгел; безнең өчен Раббыңнан

сорап дога кыл да, ул жирдән үсеп чыккан нәрсәләрдән, яшелчәләрдән: кыярдан, сарымсактан, ясмыгыннан, суганыннан безгә дә өлеш чыгарсын,—дидегез.

Шуннан соң Муса сезгә әйтте:

—Затлы ризыкларны начарракларына алыштырырга телисезме? Алайса, сез шәһәргә керегез. Сез теләгән ризыклар шунда булыр,—диде.

Шулай итеп, аларга түбәнлек, юксыллык тамгасы сугылды. Алар Аллаһның җәзасына юлыкты. Бу бәлаләр Аллаһның аятьләрен инкарь итүдән туктамаганнары өчен, нахакка пәйгамбәрләрне үтергәннәре өчен иңдерелде. Бу афәтләр аларның тыңлаусызлыгы вә җинаятьчел дуамаллык белән хәттин ашканнары өчен төшерелде.

**62**. Шик юк ки, яһүдиләр, христианнар вә *(төрле әйберләргә табынучы)* сабийлар Алаһка, Ахирәт көненә чын күңелдән ышанып, гадел гамәлләр кылса, иман китерсәләр, алар Раббы катында бүләкләр алыр. Аларга куркыныч янамас, алар кайгы кичермәс.

*(«Яһүд» сүзе алтын бозауга табынудан ваз кичеп, тәүбә иткән Исраил токымына, ягъни Ягъкуб пәйгамбәр балаларына тагылып калган кушамат, диләр. «Насара-христиан» кәлимәсе Гайсә пәйгамбәр пәйда булган Насыра бистәсенә бәйле, дип караучылар да бар. Гайсә пәйгамбәрне Аллаһ илчесе, дип таныганнар мөселман булып китә, Гайсәне Аллаһның углы, дигәннәр кяфер-христиан була. Сабийләр турында да төрле юраулар бар. Яһүдләр белән христианнар арасында аерым бер дин тотучылар әнә шул сабийләр була, дип язалар. Бәгъзе берәүләр исә, сабийләр Бабилдә яшәүче ярымхристиан халык иде, ди»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**63**. Хәтерлисезме, сез миңа ант иттегез, Без сезнең өстегезгә Тур *(Синай)* тавын корып куйган идек.

—Сезгә бирелгән китап *(Тәүрат)*ны кулыгызда нык тотыгыз, шунда язылганнар буенча гадел гамәл кылың, шуннан соң, ихтимал, Аллаһның җәзаларыннан курка башларсыз *(тугры юлга басарсыз)*,—дидек. **(64)** Шуннан соң да сез антыгызны боздыгыз *(юлдан яздыгыз)*. Әгәр дә Аллаһның мәрхәмәте вә рәхмәте булмаса, сез харап була идегез. **(65)** Сезнең арада шимбә көнендәге тыюларны *(харам саналганнарны)* бозучылар булды, шуның өчен аларга:

—Нәҗес маймыллар булыгыз!—дигәнебезне хәтерлисездер шәт?

*(Һәм алар маймылга әверелде дә.)* **(66)** Без аларны *(кешедән маймыл булганнарны)* үз күзләре белән күреп торганнарга гыйбрәт буларак һәм дә Аллаһның җәзасыннан курыкканнарга нәсихәт булсын дип, харап иттек.

**67**. Халкына карап, Муса болай диде:

—Аллаһ сезгә бер сыер суярга боерды,—диде. Алар:

—Син бу сүзләреңне безгә шаяртып әйттеңме?—диделәр.

Ул:

—*(Сезнең белән шаярып)* ахмак-надан булып күренмәс өчен, мин Аллаһка сыенамын,—диде. **(68)** Алар тагын әйтте:

—Безнең исемнән дога кылып, Раббыңнан сора: ул безгә нинди сыер бугазларга куша икән?—диделәр.

Муса:

—Аллаһ: артык карт та, артык яшь тә булмасын, уртача сыер булсын, дип боера,—диде.—кушылганны тиз башкарыгыз!

**69**. Тагын:

—Безнең исемнән Раббыңа дога кылып сора: Ул безгә сыерның төсен дә әйтеп бирсен,—диделәр.

Муса:

—Сыерның төсе ачык-куа булсын, тиресе елкылдап торсын, караганнарны сокландыра торган *(көр)* булсын,—диде. **(70)** Алар:

—*(Ий, Муса)* безнең өчен дога кылып тагын Раббыңнан сора инде, Ул безгә сыерның нинди булырга тиешлеген дә ачыклап бирсен: сыерлар бер-берсенә бик тә охшаш бит; без нинди сыер суярга тиеш соң? Без, иншалла, боерганнарны үтәрбез, ул сыерны табарбыз,—диделәр.

**71**.—Аллаһ шулай боерадыр ки: ул сыер кулга ияләштерелмәгән, җир сөрмәгән, игеннәргә су ташымаган, иректә утлап йөргән булырга тиеш, ул сыер чуар булмасын һәм һич кимчелексез булырга тиеш,—диде Муса. Тегеләр:

- Менә хәзер без ул сыерның нинди булырга тиешлеген аңладык,—диделәр

дә, шундый сыерны теләр-теләмәс кенә суйдылар.

**72.** Сезнең арада берәү кеше үтергән иде. Үтерүче турында сез *(кем үтерде, дип)* бик каты кычкырышкан идегез. Аллаһ яшерен эшләрегезне дә фаш итүче.

**73.**—Сыер түшкәсеннән кисеп алынган бер кисәк ит белән мәеткә сугыгыз,—дидек.

Менә шулай итеп, Аллаһ үлеләрне терелтә вә сез сабак алсын дип *(пәйгамбәрләре аша)* могҗизаларын күрсәтә.

*(«Исраил токымыннан булган ике яһүд егет мирас бүлешкәндә агаларын үтерә. Үтерүчене таба алмагач, хәзрәти Муса Аллаһка мөрәҗәгать итә. Сыер тәненнән кисеп алынган ит кисәге белән мәеткә кагылгач, мәет терелә дә, үтерүченең кем икәнен әйтә. Аятьтә шул вакыйга турында сөйләнә. Мысыр халыкларының сыер хайванына табынганлыгы һәм яһүдиләрнең дә берара алтын бозауга табынганнары мәгълүм»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**74.** Шуннан соң да сезнең күңелләрегез таш булып катты, таштан да катырак булды. Ташларның да төрлесе була, asларыннан чишмәләр бәреп чыга, кайбер ташлар ярылса, эченнән шаулап су ага. Ташларның бер төрлесе Аллаһтан куркып, югарыдан түбәнгә тәгәри. Аллаһ сез кылганнардан һәрвакыт хәбәрдар.

**75.** *(И, мөселманнар, моннан соң)* сез инанганнарга алар да инаныр, дип өмет итәсезме? Алар *(яһүдиләрнең бер кавеме)* Аллаһның хөкемнәрен *(Тәүратны)* ишеттеләр, ләкин бик яхшы аңласалар да, үзгәрттеләр.

**76.** *(Монафикълар)* мөселманнар белән очрашканда:

—Без иман китердек,—диләр.

Үзләре генә калгач, бер-берсен ачуланып:

—Нигә сез Аллаһның ачык әйткәннәрен мөселманнарга ирештерәсез, Аллаһ каршысында безгә каршы сөйләсеннәр дипме? Шул турыда уйламыйсыз,—диләр.

*(Яһүдләргә иңдерелгән Тәүратта Ахырзаман пәйгамбәренең киләчәге турында хәбәр бирелә. Яһүдләр шул хакыйкатьне бозып күрсәтәләр.)*

**77.** Яшерен һәм ачык рәвештә эшләгән эшләрен Аллаһ күреп-белеп торганын алар белмимени? **(78)** Алар арасында наданнар да очрый, алар китап *(Тәүратны)* укый белми. Аларның бөтен мәгълүматы имеш-мимештән генә тора. *(Алар хорафатлар белән генә яши.)* **(79)** *(Укый-яза белгәннәре)* куллары белән китап язып, шуны юк бәягә сатып, *(сәяси)* файда алыр өчен:

—Бу *(китап)* Аллаһтандыр,—дигән кешеләргә ни языктыр. Куллары белән язган бу *(ялган)* китап өчен алар бичара хәлдә калачак. Алар һичбер файда күрмичә, зарар күрәчәк.

**80.** Исраил халкы үзләрен болай юата:

—Берничә көн генә безне утта тотачаклар, безгә шуннан башка җәһәннәм булмаячак,—диләр. *(Мөхәммәд)* син әйт аларга:

—*(Сезне җәзаламасынга)* Аллаһтан сүз алдыгызмы әллә?

Аллаһ вәгъдә бирсә, вәгъдәсен үтәми калмас. Әллә сез Аллаһ турында белмәгәнегезне сөйлисезме?

**81.** Яманлык кылган кешене үзе кылган яманлык чорнап алачак. Андый кеше җәһәннәмлектер, андыйлар мәңгегә утта калыр.

**82.** Иман китереп, игелекле гамәлләр кылган кешеләр җәннәттән урын алыр. Алар анда мәңгегә калыр.

**83.** Исраил токымыннан Без сүз алдык:

—Бары тик Аллаһка гына буйсыначакбыз, ата-анага, якын кардәшләргә, ятимнәргә, юксылларга игелек кылачакбыз,—диделәр.

—Кешеләргә тәмле телле булыгыз, намаз укыгыз, зәкят биреп барыгыз,—дип боердык.

Соңыннан сез антыгызны боздыгыз, бик азыгыздан башка, барыгыз да инкарьчы булдыгыз.

*(«Корьән иңгән заманнарда яһүдләр Тәүратны үзгәртеп-бозып, андагы хакыйкатьне яшерергә тырыша башладылар. Хәзрәти Мөхәммәд пәйгамбәрлек вазифаларын үти башлаганда Мәдинә шәһәрендә һәм аның бистәләрендә гаять күпсанлы яһүдләр яши иде. Ахырзаман пәйгамбәрен яһүдләр үз араларыннан көтә иде. Мөхәммәднең гарәп халкыннан булганына яһүдләрнең ачуы чыкты. Корьәндә яһүдләр турында бик күп сүз булуының сәбәбе дә шуннандыр. Яһүдиләр чит кавемнән булган Пәйгамбәргә каршы*

*сугыш ачты. Мөхәммәд тә аларга каршы сугышырга мәҗбүр булды. Шулай итеп, яһүдләр белән мөселманнар арасында озакка сузылган дошманлык хасил булды»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**84**. *(Һәй, Исраил токымы, Ягъкуб балалары):*

—Бер-берегезнең канын коймаска, бер-берегезне йортларыгыздан куып чыгармаска!—дип Мин сезне ант иттердем.

Тирә-яктагы бөтен гамәлләребезне күреп, сез боларны кабул иттегез, ант эчтегез. **(85)** Шуларны эшләмәскә сүз биргәнегез көенчә, сез бер-берегезне үтерәсез, үз халкыгызның бер өлешен өйләреннән кудыгыз, яман эшләрдә вә дошманлыкта сез берләшеп, аларга зыян саласыз. Аларны йортларыннан куу ярамаган эш икәнен белсәгез дә, бу эштән туктамадыгыз. Аларны йортларыннан куу сезгә харам ителде. Әсирләрне мал биреп азат итәргә дип, сез сүз бирдегез. Сез китапның *(Тәүратның)* бер өлешенә ышанып, икенчесен инкарь итәсезме? Сезнең бу кылмышларыгыз бу дөньяда рисвайлык саналса, Ахирәттә исә иң каты җәзага китерер. Аллаһ сезнең бу кылмышларыгызга битараф калмас.

**86**. Алар бу дөнья тормышын *(Ахирәттән баш тартып)* сатып алган кешеләр. Шуңа күрә, аларның җәзасы җиңеләйтелмәс. Үзләренә ярдәм дә булмас.

*(Исламга чаклы Мәдинәдә яшәүче яһүдләр ике кабилә булып яши иде. Берсе—Әвес, икенчесе Хазрәч кабиләсеннән иде. Бу ике кабилә үзара сугышып, бер-берләрен үтереп, әсир алып, малларын талап көн күрә иде. Әсирләрне мал түләп алалар иде. Нигә сез бер-берегезне үтерәсез, талыйсыз, дип сораганнарга каршы алар: ни кылаек, Аллаһның әмере шундый, дип хәйләлиләр, көферлек кылалар иде»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**87**. Хактыр ки, Без Мусага китап *(Тәүрат)*ны иңдердек. Аннан соң Без тагын пәйгамбәрләр күндердек. Мәрьям углы Гайсәгә могҗизалар куәте *(Инҗилне)* бирдек. Аны Изге Рух белән кодрәтләндердек. Сезнең күңелегезгә хуш килмәгән сүзләр *(Хакыйкатьне)* сөйли торган берәр илчем килсә, сез үзегезне аннан югары куясыз. Сезгә килгән пәйгамбәрләрнең берничәсен сез: ялганчы, дидегез, башкаларын исә үтердегез.

**88**. *(Пәйгамбәрләрне шаяртып әйттеләр):*

—Күңелләребез пәрдәле *(син ни сөйләсәң дә файдасы булмас)*,—диделәр. Көферлекләре һәм гыйсъяннары сәбәпле, Аллаһ аларга ләгънәт орды. Аларның бик азы гына иман китерде.

**89**. Мөшрикләргә *(мәҗүсиләргә)* каршы сугышта җиңәр өчен, алар *(Аллаһтан)* ярдәм сорады. Колларындагы китап *(Тәүрат)*ның бозык урыннарын төзәтер өчен җибәрелгән *(Коръән)*не алар инкарь итте. Алар *(Тәүратта)* алдан ук әйтелгәннәрнең *(Ахырзаман Пәйгамбәренең киләчәге турындагы хәбәрнең)* тормышка ашканын *(Мөхәммәднең Коръән белән килгәнен)* күргәч тә иман китермәделәр. Аллаһның ләгънәте инкарьчылар өстенә төшәчәк.

**90**. Аллаһ үзе теләгән колларына пәйгамбәрлек тәгаенли. Алар шуннан көнләшеп, Аллаһ иңдергән Китапны *(Коръәнне)* инкарь итеп, үзләрен көферлеккә дучар иттеләр, ләкин файда күрмәделәр. Алар газап өстенә газапка дучар булдылар. Кяферләрне рисвай итеп, хурлыкка калдырачак җәза әзерләнгән.

**91**. Аларның үзләренә:

—Аллаһ иңдергәнгә иман китерегез,—дигәч:—Без бары тик үзебезгә иңдерелгәнгә *(Тәүратка)* гына ышанабыз,—диләр. Шуннан башкасын (Коръәнне) инкарь итәләр. Гәрчә, ул үз колларындагы бозылган Тәүратны дөресләүче сыйфатында килгән хак китаптыр. *(Ий, Мөхәммәд)*, әйт син аларга:

—Әгәр дә сез чынлыкта инанган булсагыз, моннан алда Аллаһ күндергән пәйгамбәрләрне ни өчен үтердегез?—диген.

**92**. Чынлыкта Муса сезгә ап-ачык аятьләр *(Тәүратны)* китерде. Сонра сез, гаделсез залимнәр буларак, бозауга табына башладыгыз.

**93**. Исегездәме Тур тавын баш очыгызга элеп куйган идек, сез шунда ничек ант иттегез? Сезгә боерылды ки:

—Сезгә бирелгән китапны *(Тәүратны бозмыйча)* нык тотыгыз, сөйләгәннәремне яхшы аңлагыз!—дидек. Сез:

- Ишеттек вә гыйсъян иттек,—дидегез. Имансызлыклары аркасында, аларның йөрәкләренә бозауга мәхәббәт хисләре кереп тулды. Әйт син аларга:

—Әгәр дә *(бозауга)* инансагыз, бу эшегез сезгә әллә нинди яман хәлләр китерәчәк,—диген.

*(«Аллаһтан тагын бер пәйгамбәр киләчәге турында яһүдләр Тәүраттан укып беләләр иде. Килгән пәйгамбәрнең яһүдләр арасыннан булмаенча, гарәп халкыннан сайланганын белгәч, алар Мөхәммәд Пәйгамбәрне рәсүл итеп танымадылар. Аятьләр алып килгән булса да, Мусага да алар чынлап ышанмады. Ул Тур тавына киткәч, алар бозауга табына башладылар»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**94**. *(Ий, Мөхәммәд)* әйт:

—Аллаһ катындагы җәннәт йорты башкаларга булмыйча, бары тик безгә генә, дип расларга тырышсагыз, әйткәнегездән хак дип санасагыз, үлем теләгез,—диген.

**95**. Алар үзләре кылган *(гөнаһлары, гыйсъян)*нары аркасында бервакытта да үлемне теләп алмас.

Аллаһ залимнәрне бик яхшы белә.

*(«**Яһүдләр:** Ахирәт тормышы бары тик безнең өчен генә, башка халыклар тege дөньяда рәхәткә лаек булмас, дип расларга тырышалар».)*

**96**. Чыннан да, тормышка ябышып ята торган халыкларның иң үҗәте алар икәнен син белерсең. Потпәрәстләр *(сыннарга табынучылар)* бигрәк тә ачкүз-комсыз була: алар мең ел яшәргә тели. Мең ел яшәсә дә, алар җәзадан качып котыла алмас. Аллаһ аларның ни кылганын күреп тора.

**97**. Әйт син:

—Җәбраилгә кем дошман, шул яхшы белеп торсын, Аллаһның рөхсәте илә Коръәнне минем күңелемә тугры юл күрсәтүче сыйфатында, аннан элек килгән китапларны дөресләүче вә мөэминнәргә сөенче буларак *(Җәбраил)* китерде,—диген.

*(«Риваятьләргә күрә, Фәдәк равиннарыннан берсе, ягъни яһүди җитәкчеләреннән Абдуллаһ бине Сурия хәзрәти Мөхәммәд белән бәхәскә керә: сиңа вәхийны кем китерде, дип сорый. Мөхәммәд: Җәбраил, ди. Тегe: ул безнең дошманыбыз. Вәхийны башка берәүгә иңдергән булса, без иман китергән булыр идек, ди. Шуннан соң шушы аять иңә»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

*(**Вәхий**—Аллаһ, ерак арадан торып, теләгән пәйгамбәренә әмерләрен вәхий итә, иречтерә, күңеленә сеңдерә. Үз ихтыярына буйсындыру кодрәте—вәхийдыр.)*

**98**. Аллаһка, фәрештәләргә, пәйгамбәрләргә, Җәбраилгә, Микаилгә дошман булган кеше—кяфер булыр. Аллаһ—кяферләрнең дошманы.

**99**. Шик юк ки, сиңа ап-ачык аятьләр иңдердек. Аларны фасикълар гына инкарь итәчәк.

*(**Фасикъ**—әхлаксыз, азгын, бозык, фахиш кеше.)*

**100**. Нича тапкыр алар сүз бирде, ант итте. Араларыннан берничә төркем, антларын бозып, сүздә тормадылар. Аларның күбесе имансыз булып калды. **(101)** Үзләренә Аллаһ тарафыннан иңдерелгән китап *(Тәүрат)*ны дөресләргә дип илче *(Мөхәммәд)* җибәрелгәч, китаплы төркем *(яһүдләр)*, белмәгәнгә салышып, Аллаһның Китабын арка якларына ыргыттылар.

**102**. Сөләйманның хөкемдарлыгы вакытында алар шайтаннарның *(уйдырма)* ялганнарына иярделәр. Сөләйман кяфер түгел иде. Әмма шайтаннар кяфер булды. Чөнки алар Һарут белән Марут исемле ике фәрештәгә иңдерелгән сихерләрне Бабил илендәге кешеләргә өйрәттеләр. Гәрчә, бу ике фәрештә бөтен кешегә:

—Без бары тик *(кешеләрне)* сынау өчен төшерелдек. Сак булыгыз, ялгышып, бездән сихер өйрәнеп, кяфер була күрмәгез,—дип кисәтүдән башка һичкемгә *(сихер)* өйрәтмәделәр.

Алар шушы ике фәрештәдән ир белән хатын арасын боза торган сихерләр өйрәнделәр. Сихерчеләр, Аллаһның рөхсәте булмаган килеш, һичкемгә зарар эшли алмас. Алар үзләренә файда китерә торганны түгел, үзләренә зарар китерә торган сихерне өйрәнделәр. Сихергә катнашканнарның Ахирәттә насыйбы булмаячагын алар яхшы белә иде. Сихер бәясенә алар үзләрен сатты. Моннан да яман эш булырмы? Әгәр алар моны аңласа... **(103)** Иман китереп, үзләрен бу яманлыктан коткарсалар, шөбһәсез, Аллаһ тарафыннан биреләчәк савап алар өчен тагын да хәерлерәк булыр иде. Алар моны аңласыннар иде!

**104**. Һәй, иман китергән кешеләр!

—Рагыйнә—димәгез.—Унзурна,—дип әйтегез! Аның вәгазен колак салып тыңлагыз.

Кяферләр өчен кайгы бирүче җәза әзерләнгән.

*(«Рагыйнә» сүзе гарәпчә «Безне күзәтеп, тугры юлга күндер» мәгънәсендә булып, шул ук сүз яһүдләрчә сүгенү була икән. Яһүдләр Мөхәммәдне мыскыллап көләргә тотыналар. Шуннан Аллаһ бу сүзне кулланудан тыя. Аның урынына «унзурна» сүзен кулланырга куша»).* Али Өзәк тәфсиреннән.

*(**«Рагыйнә»** сүзе «тыңла, ишет» мәгънәсендә булып, басым белән әз генә үзгәртелгәч, «ул ахмак, аңгыра, шашкан» мәгънәләрен ала икән. Яһүдләр бу сүзне әнә шулай үзгәртеп, мөселманнарны мыскыл итә торган булалар. «Унзурна» сүзе исә «безне көтегез, безгә бераз вакыт бирегез» дигән мәгънәдә.)*

Мөхәммәд Али тәфсиреннән.

**105**. *(И, мөэминнәр)* китаплы халык та, мөшрикләр дә Раббыгыздан сезгә нигъмәтләр иңдерелүен һич тә теләмиләр. Аллаһ рәхмәтен Үзе теләгәннәргә иңдерә. Аллаһ — чиксез мәрхәмәт ияседер.

**106**. Без бирәр аятьнең көчен гамәлдән чыгарсак яки аны оныттырсак, һичшиксез, тагын да яхшырагын яки шуңарга охшашын бирербез. Аллаһның бар нәрсәгә кодрәте житкәнен син белмисеңме әллә?

*(«Аллаһ Тәгалә кешеләрнең мәдәни үсеш дәрәҗәләренә карап, ихтыяҗларына күрә, пәйгамбәрләр җибәрә торды, китаплар иңдерә торды. Әүвәлрәк гамәлдә булган кайбер кагыйдәләр, кануннар Коръән иңгәннән соң көчен югалтты. Нәсехителде»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**107**. Күкләрнең, Җирнең байлыгы, шулар белән идарә итү бары тик Аллаһ ихтыярында икәнен син белмисеңмени? Сезнең өчен Аллаһтан башка дус та, ярдәмче дә юк.

**108**. Әллә сез әүвәлдәгечә, Мусага сораулар биргәнегез кебек, бу пәйгамбәрегезгә дә сораулар яудырмак буласызмы? Иманын югалткан кеше, һичшиксез, тугры юлдан тайган булыр.

*(**Кяферләр:** Аллаһны безгә күрсәт, шуннан соң без синең шул Аллаһка иман китерербез, дип хәзрәти Мусага сораулар яудыралар.)*

**109**. *(Әй, мөэминнәр)* китап әһелләренең күбесе, Хак Тәгалә үзләренә *(Тәүрат белән)* чын—дөреслекне бәян иткәннән сон, эчләрендәге хөсетлек, көнләшү аркасында, сезне иманыгыздан яздырып, яңадан кяфер итмәкче булалар. Хәзер инде сез аларны кичерегез һәм Аллаһның әмере килгәнчегә кадәр, алар белән аралашмагыз. Шик юктыр ки, Аллаһның бөтен нәрсәгә кодрәте житә.

**110**. Намаз калдырмагыз, зәкятны тиешенчә һәм вакытында биреп барыгыз. Алдан ук үз файдагызга кылган игелегегез өчен Аллаһ катында әҗерен алачаксыз. Шик юктыр ки, Аллаһ сез кылганнарны тулаем күреп тора.

**111**. *(Китап әһелләре):*

—Яһүдләр һәм насаралардан *(христианнардан)* башка бер генә халык та җәннәткә кермәс,—диләр.

Бу аларның нигезсез хыялыдыр. Син аларга:

—Әгәр дә сез чыннан да хаклы икән, моңа дәлилләр китерегез!—диген.

**112.** Юк инде! Йөзен ихластан Аллаһ тарафына юнәлдергән кешегә әҗер Раббы белән кавышкач булыр. Шундыйлар өчен куркыныч булмас, шундыйларга кайгы килмәс.

**113**. Яһүдләр:

—Христианнарның таянычы юк *(алар хак диндә түгел)*,—диделәр. Христианнар исә:

—Яһүдләрнең таянычы юк *(аларның дине дөрес түгел)*,—диделәр. Гәрчә, алар бер үк китапларны укый. *(Хәбәре булмаганнар да, укый-яза белмәгәннәр дә)* нәкъ шулар сүзен кабатлый. Бәхәсчеләрнең кайсысы хаклы, кайсысы хаксыз икәне турында Кыямәт көнендә Аллаһ хөкем чыгарачак.

**114**. Мәчетләрендә Аллаһның исемен телгә алмаска боеручы вә *(мәчетләрне)* җимерергә тырышучылардан да залимрәк кем бар икән бу дөньяда? Чынлыкта, алар анда курка-курка керергә тиеш. Андыйлар өчен дөньяда түбәнлек, Ахирәттә җәза әзерләнгән.

**115**. Көнчыгыш тарафы да, Көнбатыш тарафы да Аллаһныкыдар. Кай тарафка баксагыз да, сез йөзегез белән Аллаһка карап баскан булырсыз. Хактыр ки, Аллаһның рәхмәте киң. Ул һәрнәрсәне белеп тора.

*(«Күңелең Аллаһка тугры булганда, кай тарафка карап намаз укысаң да, төнлә, томан, буран эчендә Кыйбланы таба алмаганда, син кая карап сәҗдә итсәң дә, дөрес булыр, намазың кабул кылыныр. Көнчыгыш тарафы да, Көнбатыш тарафы да—бөтен Җир шары дигән мәгънәдә»).*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**116**. *(Кяферләр):*

—Аллаһ бала атасы булды!—диделәр.

Әстәгъфирулла! Ул мондый түбәнлекләрдән азат. Күкләрдәге вә Җирдәге бөтен нәрсә Аныкы, барысы да Аңа буйсына.

*(«Яһүдләр Гозәерне, христианнар Гайсәне, мөшрикләр фәрештәләрне Аллаһ Тәгаләнең балалары, диделәр»).*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**117**. Ул күкләрне һәм Җирне юктан бар итүче. Берәр нәрсә барлыкка китерергә теләсә, Ул:

—Бар бул! — ди һәм. Ул теләгән нәрсә шундук бар була.

**118**. Наданнар:

—Аллаһ безнең белән сөйләшсен иде,—диләр, яки:

—Безгә дә берәр могҗиза индерсен иде,—диләр.

Алардан элек яшәгән наданнар да нәкъ менә шулай диләр иде. Алар күнелләре белән бер-берләренә тач охшаш. Юкса, Без дөресен белергә теләгәннәргә аятьләрне ап-ачык итеп иңдердек.

**119**. Дөресе шулдыр, Без сине Хак *(Коръән белән җәннәт турында)* сөенечле хәбәр бирер өчен вә *(җәһәннәм турында)* кисәтүче сыйфатында күндердек. Син *(Мөхәммәд)* җәһәннәмдәгеләр өчен җавап тотмаячаксың.

**120**. Аларның динен кабул итмәсәң, яһүдләр дә, христианнар да асылда синнән разый булмаслар. Әйт син аларга:

- Дөрес юл бары тик Аллаһ күрсәткән юл гына,—диген. Сиңа килгән гыйлемнән соң, алар юлыннан китсәң, шул булыр: сине бер генә дустың да, бер генә ярдәмчең дә Аллаһның нәфрәтеннән коткара алмас.

**121**. Үзләренә китап индерелгән кешеләр *(мәгънәсен бозмыйча, сүзләрен үзгәртмичә)* инанып укыйлар, чөнки алар китап укыганнан соң иман китерделәр. Шул китапны инкарь итүче кяферләр исә *(һәм матди, һәм мәгънәви)* зыян күрәчәк.

*(«Яһүд галиме Абдулла ибне Сәлам белән аркадашлары Коръәнгә инанып, мөселман булдылар. Бүтән риваятькә күрә, Җафәр бине Әбү Талип белән Хабәшстаннан килгән кырык кешелек җәмәгать Коръән укып, Ислам динен кабул иттеләр»).*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**122**. Әй, Исраил токымы, сезгә биргән нигъмәтләремне вә бөтен галәм халыкларыннан сезне өстен куйганымны исегезгә төшерегез. **(123)** Һичкем башка кеше өчен һични эшли алмаячак, *(гөнаһларны юу өчен түләү)* фидия кабул ителмәячәк, хәтта шәфәгатьнең һичкемгә ярдәме тимәячәк Көннән *(Кыяматтан)* куркыгыз.

**124**. Заманында Раббы Ибраһимны берничә сүз белән сынап карады һәм эш тәмам булгач, әйтте:

—Мин сине кешеләрне өндәүче *(имам)* итеп куячакмын,—диде.

Ибраһим:

—Йә, Раббым, минем кардәшләрем арасыннан да имамнар билгелә,—диде.

Аллаһ әйтте:

—Залимнәр *(кяферләр)*гә андый вәгъдәм юк, диде.

*(Хәзрәти Ибраһим нәселендә мөселманнар да, кяферләр да бар иде.)*

**125**. Без Йортны *(Кәгъбәне)* кешеләр бергә җыелсын дип, иминлек урыны иттек.

—Сез дә Ибраһимның баскан җирен намаз уку урыны итегез. Ибраһим белән Исмәгыйльгә: таваф итәргә килүчеләр, гыйбадәт кылучылар, рөкүгъ вә сәҗдәгә киткәннәр өчен өемне пөхтә тотыгыз,—дип боердык.

*(**Таваф**—Кәгъбәнең әйләнәсен зиярәт итү, йөреп чыгу.)*

**126**. Ибраһим әйтте:

- Йә, Раббым, шушы шәһәрне имин ит. Аллаһка вә Ахирәткә инанганнарны җиләк-җимешләр белән сыйла,—диде.

Аллаһ боерды:

- Инкарьчылар аз вакытка гына бу нигъмәтләрдән файдаланыр. Ләкин соңыннан андыйларны җәһәннәм утына атачакмын. Бик тә хәтәр урын ул—җәһәннәм.

*(«Аллаһ Тәгалә инкарь итүчеләрне кяферләрне дөньяда ризыклы итәр, теләгәннәренчә шул ризыкларны файдаланырга мөмкинлек бирер. Дөнья ризыгы кяфергә дә, мөселманга да тәгаенләнгән. Аллаһның бер исеме дә Рахмән, ягъни барысына да тигез карап, нигъмәтләрдән файдалану хокукы бирүче, дигән сүз. Байлык, залимлек, хөкемдарлык азгынлыкка, рухи гариплеккә илтсә, бу дөнья рәхәтен җәһәннәм алыштырачак»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**127**. Ул заманда Ибраһим белән Исмәгыйль икәүләшеп Бәйтүлланың *(Кәгъбә)* нигезен күтәрделәр.

—Йә, Раббыбыз, догабызны, эшебезне кабул ит, зинһар. Шик юктыр ки, Син безне ишетеп, күреп торасың,—дип гыйбадәт кылдылар.

*(«Җәннәттә яшәгәндә хәзрәти Адәм Аллаһка гыйбадәт кылсын дип, нурдан ясалган багана барлыкка китерелә. Шул нур баганасын тавaф итеп, әйләнеп йөри-йөри, Адәм гыйбадәт кыла торган була. Кылган гөнаһлары өчен, Адәм белән Һәуваны җәннәттән сөреп, Җиргә куып төшерәләр. Җир йөзенә алар аерым-аерым килеп төшкәнгә күрә, аймыл булалар. Һәм, ниһаять, Гарафат тавы янында алар бер-берсен табыша. Шушы сөенечтән хәзрәти Адәм Аллаһка гыйбадәт кылырга тели. Аллаһ аңа тагын нур баганасы хасил итә. Адәм шунда гыйбадәт кыла башлый. Күп заманалар узгач, тора-бара нур баганасы юкка чыга. Аның урынына караташ торып кала. Хәзрәти Шис пәйгамбәребез шул урынга дүрт почмаклы бина корып куя. Һәм караташны шул бина эченә урнаштыра. Ул таш бүген дә исән. Хаҗәр-и Әсвәд исемле бу изге таш Кәгъбәтулланың тап уртасында тора. Туфан суы калыккач, ул таш та, бина да су астында кала. Су кайткач, күренә ки: бина ком астында калган. Аллаһ әмере илә Ибраһим галәйһиссәләм шул урынны эзләп таба. Хатыны белән углы Исмәгыйльне дә шул тирәгә урнаштыра. Углы Исмәгыйль белән хәзрәти Ибраһим комны казып, бинаны ачалар. Хәзрәти Шис корган бинаның нигезен табып, шул урынга Кәгъбәтулланы җиткезеп куялар»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**128**. *(Ибраһим белән Исмәгыйльнең догасы):*

—Йә, Раббыбыз, зинһар, безне Үзеңнең мөселман колларыңнан сана, нәселебездән Сиңа итагать итүче бер өммәт хәзерлә; безгә гыйбадәт урыннарын һәм ысулларын өйрәт; тәүбәләребезне кабул әйлә, безне ярлыка. Тәүбәләрне кабул итүче, чиксез мәрхәмәтле Раббы бары тик Син генә.

**129**. Йә, Раббыбыз, *(Ибраһим токымына)* үз араларыннан чыккан, аларга аятьләреңне укып бирүче, китап һәм хикмәтләрне өйрәтүче, аларның күңелләрен сафландыручы бер пәйгамбәр күндер. Бөтенебездән өстен, һәр нәрсәне кирәгенчә башкаручы бары тик Син генә.

**130**. Ибраһим тоткан диннән үзен-үзе белештерми торган диваналардан башка кем баш тартсын? Без аны бу дөньяда сайладык. Шөбһәсездер ки, ул Ахирәттә изгеләр рәтендә булыр. **(131)** Чөнки Раббы аңа:

—Мөселман бул!—диде.

—Галәмнәрнең Раббысына баш орамын,—диде Ибраһим да.

**132**. Ибраһим галәйһиссәләм дә моны балаларына васыять итте. Хәзрәти Ягъкуб та:

—Угылларым, сезнең өчен бу динне Аллаһ сайлап бирде, шуңа күрә, бары тик мөселман булып яшәгез, мөселман булып үлегез,—диде.

**133**. *(Әй, кяферләр)* Ягъкуб җан биргәндә, сез аның янында идегезме, юкса? Үләр алдыннан *(Ягъкуб)* улларына:

—Миннән соң кемгә итагать итеп яшәрсез?—диде.

—Синең ата-бабаларың Ибраһим, Исмәгыйль, Исхакның Тәңресе булган бер Аллаһка буйсыначакбыз, без бары тик Аллаһка гына итагать итәчәкбез,—диделәр Ягъкуб балалары.

**134**. Дөньяга килеп-киткән өммәтләр кылган *(гөнаһ-саваn)* аларнын үзләренә булыр. Сез кылганнар—үзегезгәдер. Сез алар *(гөнаһлылар)* өчен җавапка тартылмассыз.

**135**. *(Яһүдләр белән насаралар):*

—Яһүди яки христиан булыгыз, хаклык юлын табарсыз,—диделәр.

Әйт син:

—Юк!—диген.—Без хәниф Ибраһим тоткан саф динне тотачакбыз. Ул беркайчан да мөшрик булмады?

*(«**Хәниф**—туры күңелле адәм баласы: хак дингә күчкән кеше»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**136**. —Без Аллаһка ышанабыз вә безгә иңдерелгән *(Корьән)*гә ышанабыз; Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб вә аның оныкларына иңдерелгәнгә, Мусага иңдерелгән Китап *(Тәурат)*ка, Гайсәгә иңдерелгән *(Инҗил)*гә, Аллаһ тарафыннан бүтән пәйгамбәрләргә иңдерелгәннәргә аермаенча ышанабыз һәм бары тик Аллаһка гына итагать итәбез,—диген.

**137**. Әгәр алар да, сез инанган кебек, *(Аллаһка)* инанса, тугры юлны тиз табачаклар. Әгәр дә инде Аллаһтан баш тартсалар, һичшиксез, гыйсъянчы булып, адашачаклар. Аларга каршы көрәшер өчен сиңа бер Аллаһ җитә. Аллаһ барысын да ишетеп, белеп тора.

**138**. Аллаһ нуры турында *(әйтсәк)*: Аллаһ *(диненең)* нурыннан кайсы *(диннең)* нур(ы) күркәмрәк? Без Аллаһ *(диненә, Корьән)* нурына коендык. Без *(бары тик)* Аңа гына буйсынабыз (гыйбадәт кылабыз),—диген.

**139**. Әйт син аларга:

—Безнең Раббыбыз—Аллаһ Тәгалә,—диген.—Аллаһ Тәгалә сезнең дә Раббыгыз. Шулай булгач, сез нигә безнең белән тарткалашырга булдыгыз? Без кылган *(саваn)* үзебезгә, сез кылганнар *(гөнаһ)* үзегезгә. Безнең күңелләребез ихластан Аллаһка бәйләнгән.

**140**. Сез: Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб вә аларның оныклары кайчандыр яһүд һәм насара булган, дип уйлыйсызмы? Әйт син аларга:

—Бөтен нәрсәне сез беләсезме, әллә Аллаһмы?—диген. Аллаһ иңдергән аятьләрне яшерергә тырышучылардан да яманрак беркем булмас. Аллаһ сез кылганнардан хәбәрсез түгел.

**141**. Дөньяга килеп киткән өммәтләр кылган *(гөнаһ-саваn)* үзләренә булыр. Сез кылганнар—сезгә. Сез алар кылган *(гөнаһлар)* өчен җавапка тартылмаячаксыз.

*(«Хәзрәти Мөхәммәд Мәдинәгә килгәч, мөселманнар Кодускә (Иерусалимгә) таба карап намаз укыйлар иде. Яһүдләр аларны мыскыллый башлыйлар: Мөхәммәд белән сәхабәләре кыйблаларының кай якта икәнлеген дә белмиләр, без аларга юл күрсәттек, диләр. Мөхәммәд: мөселманнарга Кыйбланы күрсәт, дип Аллаһка ялварды. Шуннан соң мөселманнар Иерусалимгә карап түгел, Мәккәгә йөз тотып намаз укырга керештеләр»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**142**. Кешеләрнең ахмак-наданнары әйтте:

—Кыйблаларын үзгәртергә аларны ни мәҗбүр итте?—диделәр. Әйт син аларга:

—Көнчыгыш та, Көнбатыш та *(бөтен Җир йөзе)* Аллаһныкыдыр. Ул кешеләрне Үзе теләгәнчә турылар,—диген.

**143**. Менә шулай итеп, Без сезне кешеләр кылган гамәлләргә шаһит булсыннар дип, арадашчы олуг бер өммәт иттек. Рәсүлебезне дә сезнең тугры юлда булуыгызга шаһит булсын дип, җибәрдек. *(Ий, Мөхәммәд)* син сәҗдә иткән кыйбланы мин сынар өчен бирдем: сиңа ияреп барырлармы, әллә үкчәләрен ялтыратып, башка юлдан китәрләрме, дип. Иманнары какшау булганнарга кыйбла үзгәртү бик тә кыен эш иде. Аллаһ сезнең иманыгызны, теге кыйблага карап кылган намазларыгызны юкка чыгармас. Шик юк ки, Аллаһ кешеләргә чиксез мәрхәмәтле һәм рәхимле.

*(Иманнары какшау булганнарга кыйбла үзгәртү бик тә кыен эш иде, гыйбарәсен болай аңларга кирәктер. Бу очракта мөселманнар хәзрәти Мөхәммәд Пәйгамбәргә шул кадәр инанганнар иде ки, ул кайсы якка сәҗдә итсә, алар шул якка сәҗдә итә, Мөхәммәдкә ышанычлары какшау булганнар исә, аңа иярми, Кәгъбәтуллага борылмый, һаман яһүдләр тарафына йөз тотып гыйбадәт кыла.)*

**144**. —*(Ий, Мөхәммәд)* Без синең Күккә карап торганыңны *(югарыдан хәбәр көткәнеңне)* күрәбез. Хәзер Без Кыйбланы син бик тә разый булачагың тарафка

күчерәбез. Хәзер инде син йөзенне Мәсжед-и Харам *(Кәгъбәтулла)* тарафына юнәлт! *(Ий, мөселманнар)* кайда гына булсагыз да *(намаз вакытында)* йөзегезне шул Кыйблага туры тотыгыз. Шик юк ки, китаплы халык *(яһүдләр һәм христианнар)* бу гамәлләрнең Аллаһтан килгән чынбарлык икәнен бик яхшы белә. Аллаһ аларның ни кылганнарыннан хәбәрсез түгел.

*(Хәзрәти Мөхәммәд Кыйбла ягын хәзрәти Ибраһим төзегән йорт тарафында булуын бик тели иде. Бу теләген ул Җәбраил фәрештәгә сөйләде. Бу мәсьәләне хәл итәр өчен, Җәбраил Күккә менеп китте. Мөхәммәд Күккә карап, хәбәр көтә иде.)*

**145**. Син никадәр генә ышандырырлык итеп сөйләсәң дә, үзләренә китап индерелгәннәр *(яһүдләр, насаралар)* синең кыйбланңа сәҗдә итмәс. Син дә аларның кыйбласына баш ормассың. Алар да бер-берсенең кыйбласына иелмәс. Үзенә индерелгән гыйлемнән соң да син алар ихтыярына иярсән, чыннан да, залим-кяфер булырсың.

**146**. *(Китаплы халык)* үз балаларын яхшы белгән кебек, китапларны *(анда Мөхәммәд Пәйгамбәр киләчәге турында язылганны)* да яхшы беләләр. Ләкин аларның бер кавеме, белгән көенчә, китаптагы дөреслекне башкалардан яшерә килә.

*(«Яһүдләр—Тәураттан, христианнар Инҗилдән укып, Ахырзаман пәйгамбәренең киләчәген беләләр. Хәтта алар ул Пәйгамбәрнең килүен зарыгып көтәләр иде. Әммә ул пәйгамбәрнең ятим үскән бер гарәп икәнен күргәч, көнчелектән, ачудан, ыругчылык-расачылык хисләренең күперүе аркасында, пәйгамбәрне инкарь иттеләр»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**147**. Хакыйкать—Аллаһтандыр. Шулай булгач, син шикләнүчеләрдән булма.

**148**. Һәркемнең кыйбласы бар. Сез *(мөэминнәр)* кешеләргә күбрәк игелек кылуда ярышыгыз. Кайда гына булсагыз да, Аллаһ һәрберегезне бер урынга туплар. Аллаһның һәрнәрсәгә кодрәте житә.

**149**. Кайсы яктан гына *(сәфәргә)* чыксаң да, *(намаз укыганда)* син йөзеңне Мәсжед-и Харам тарафына тот. Бу—Аллаһтан килгән хакыйкый әмер. Аллаһ ни кылганнарыгыздан хәбәрсез калмас.

**150**. Кайсы яктан гына *(сәфәр)* чыксаң да, *(намаз укыганда)* син йөзеңне Мәсжед-и Харам тарафына тот. Кайда гына булсагыз да йөзегезне шул якка борыгыз, кешеләр сезне хата эшләүдә гаепли алмасын. Алардан курыкмагыз. Бары тик Миннән *(җәзамнан)* куркыгыз. Шулай булганда, Мин мәрхәмәтемне тәмамлап, сезгә тапшырырмын, бәлки сез тугры юлга басарсыз.

**151**. Шулай итеп, сезгә аятьләребезне укырга, сезне яманлыктан арындырырга, сезгә китапны вә хикмәтләрне өйрәтергә, белмәгәннәрегезне белдерергә үз арагыздан сайлап, бер Рәсүл жибәрдек.

**152**. Шулай булгач, сез Мине *(гыйбадәт кылып)* зикер итегез, Мин дә сезне зикер итәчәкмен. Миңа шөкер итегез. Аң булыгыз, Миңа көферлек кылмагыз!

*(**Зикер**—искә алу, онытмау.)*

**153**. И, иман китергән адәмнәр, сабыр-түзем булып, намаз укып, Аллаһтан ярдәм сорагыз. Хактыр ки, Аллаһ *(түзем)* сабыр кешеләр белән бергә.

**154**. Аллаһ юлында *(Жиһадта)* үтерелгәннәргә «мәетләр» димәгез. Чынлыкта алар тередер. Ләкин сез моны аңламыйсыз гына.

**155**. Һәрхәлдә сезне бераз куркытып, ачлыкта тотып, малларыгызны азайтып, нигъмәтегезне киметеп, якыннарыгызның жанын алып сыныйбыз. Түзем булганнардан *(Аллаһның әҗере була, дип)* сөенче ал.

**156**. Чыдам булганнар, башларына берәр бәла килсә:

—Без—Аллаһның бәндәләре, Аллаһ хозурына барачакбыз,—диләр. **(157)** Алар Аллаһның рәхмәтенә һәм Аның ярлыкавына лаектыр. Тугры юлны тапканнар да шулар булыр.

**158**. Шик юк ки, Сафа белән Мәрвә таулары Аллаһның галәмәтләредер *(гыйбадәт өчен тәгаенләнгән урын)*. Кем *(Хаҗ максаты илә)* Кәгъбәтулланы зиярәт итеп, *(аның тирәли)* тавaф кылса, андыйларның гөнаһысы булмас. Үз ирегe белән, ихластан игелек кылган кешенең гамәлләрен Аллаһ, һичшиксез, кабул итәр һәм әҗерен бирер. Ул барысын да белеп тора.

*(«Сафа белән Мәрвә—Кәгъбәтулланың Көнчыгыш тарафындагы ике калкулык. Һаҗәр анакай хәзрәти Исмәгыйль өчен су эзләп йөргәндә шушы калкулыклар арасын*

*җиде тапкыр әйләнә. Бүген хаҗ кылучылар, Кәгъбәтулланы зиярәт итүчеләр, тавафчылар Сафа белән Мәрвә калкулыкларына да баралар. Әлеге аятьтә ике тау арасында йөренүнең гөнаһысы юк, диелә. Җаһәләт вакытында бу ике тау түбәсенә дә берәр пот куелган була. Бу сыннарны юкка чыгарган булсалар да, кайберәүләрнең күңелендә шик кала, янәсе, ул тауларга бару—шул потларга табыну була. Аять әнә шул шикне юкка чыгара»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**159**. Без иңдергән ачык аятьләрне, китапта тәфсилләп күрсәткән тугры юлны яшерүчеләрне һәм Аллаһ, һәм бөтен ләгънәтләүчеләр—каһәрләр. **(160)** Яшәү рәвешләрен үзгәртеп, яшергән дөреслекне бөтен халыкка чыгарсалар һәм тәүбә итсәләр генә, аларның тәүбәләрен кабул итәрбез. Без тәүбәләрне күпләп кабул итүче һәм ярлыкаучы. **(161)** Аятьләребезне инкарь итеп, кяфер булып үлгәннәр турында, алар Аллаһның, фәрештәләрнең вә бөтен иманлы халыкның ләгънәтенә дучар. **(162)** Алар мәңгегә ләгънәт эчендә калыр. Аларның газаплары кичектерелмәс, җиңеләйтелмәс. Аларга мәрхәмәтле караш та булмас.

**163**. Илаһыгыз бары тик бер Аллаһтыр. Аннан башка илаһ юк. Ул мәрхәмәтле, рәхимле.

**164**. Шик юк ки, күкләрнен, Җирнен яралтылуында, төн белән көннең бер-берсен алыштыруында, кешеләргә файдалы йөкләр төягән көймәләрнен, диңгезләрне ярып, йөзүендә, Аллаһ Күктән иңдереп, җансыз туфракны җанландырган яңгырда, Җир йөзендә һәртөрле җан иясен булдыруда, җилләрне вә Җир белән Күк арасында йөзеп йөрүче, Аллаһның һәр әмеренә буйсынучы болытлар турында фикер йөртүче халык өчен *(Аллаһның барлыгын, берлеген)* раслый торган байтак дәлилләр бар.

**165**. Кайбер халык Аллаһтан башка илаһ уйлап чыгара да, Аллаһны сөйгән кебек, шул уйдырманы сөя башлый. Исламга килгәннәрнең Аллаһка булган мәхәббәтләре исә аларныкына караганда күп тапкырга артык. Әгәр ул кяфер залимнәр үзләренә тиешле газапның нинди икәнен белсәләр, бөтен кодрәтнең Аллаһтан икәнен вә Аллаһ биргән җәзаның нинди дәһшәтле икәнен аңлаган булырлар иде. **(166)** Менә шул вакыйганы *(Кыямәт көнендәге җәзаларны)* күреп, үзләренә ияреп килүчеләрдән *(аларның котыртуы белән кяфер булганнардан)* качарлар; ашыгып үз иярченнәреннән ераклашырлар; алар *(ияртүчесе дә, иярүчесе дә)* җәза күрер һәм аларның арасы өзелер. **(167)** Яманнарга ияргәннәр шуны әйтер:

—Аһ, фани дөньяга тагын кире әйләнеп кайтсак, бүген алар *(яманлыкка котыртучылар)* безне ташлап качканнары кеби, без дә алардан качар идек.

Шулай итеп, Аллаһ аларга дөньяда кылган яман эшләре аркасында кайгы-хәсрәткә калачакларын күрсәтә һәм алар инде уттан кача алмас.

**168**. Әй, инсаннар, Җир йөзендә булганнарның *(ризыкларның)* хәләл вә саф-тазаларын гына ашагыз. Шайтан артыннан иярмәгез. Шайтан сезнең кан дошманыгыз. **(169)** Ул сезне бары тик яманлык турында, Аллаһ хакында чирканыч, ялган нәрсәләр турында сөйләргә котырта.

*(«Шайтан кеше күңелендә булган яман теләкләрне: хәмер эчү, кеше малына, харам хатыннарга кызыгу, зина һәвәслеге кебек эшләрне хуплый. Хәзрәти Әбү Бәкер сүзе: олуг адәм нәфесенә (комсызлыкка, вәсвәсәгә) юл куймас. Яки нәфесенә юл куймаган адәм олуглыкка ирешер»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

*(Нәфес—кирәгеннән артыкка омтылу, башкалардан күбрәк мал туплау, кеше малына, хатынына кызыгу.)*

**170**. *(Кяферләргә):*

—Аллаһтан иңгән *(Коръән)*гә генә иярегез,—дигәч, алар:

—Юк, без аталарыбыз нинди юлдан йөргән булса, шул юлны тотачакбыз,—диделәр. Аталары бернәрсә дә аңламыйча, дөрес юлны тапмаган булсалар? **(171)** Аллаһка ышанмаган кяферләрнең хәле, чакырып кычкырган тавышны ишетеп тә, һични аңламаган хайванныкы кебек. Аларның *(кяферләрнең)* күңел күзләре сукыр, алар телсез-чукрак кебек. Шуңа күрә, аларның башы уйлар дәрәҗәдә түгел.

*(Аять иске карашларга ябышып ята торган, яңа фикерләрне кабул итәр дәрәҗәдә булмаганнарга ишарәли. Инҗил, Тәүрат һәм башка китапларны үзгәртеп язганнан соң, шул китапларга гына табынып яшәүчеләр Коръәннең яңа фикерләрен кабул итә алмый.)*

**172**. Ий, иман китергән адәмнәр, үзегезгә бирелгән ризыкларның саф-таза, хәләл булганнарын гына ашагыз. Бары тик Аллаһка гына инанасыз икән, Аңа гына шөкер итегез. **(173)** Аллаһ сезгә бары тик үләксә ашауны, кан, дуңгыз ите ашауны вә Аллаһтан башка затка багышлап суелган итне харам кылды. Ләкин мәҗбүр хәлдә калса, чамадан тыш булмаганда, аз микъдарда ашаса, гөнаһы булмас.

Шик юк ки, Аллаһ ярлыкаучы вә рәхимледер.

*(«Исламда ирексезләү юк. Кеше ачтан үләр чиккә җиткән булса, хәләл булмаган ризыкны да ашый ала: аның бу гамәле гадәткә әйләнеп китмәсә. Харам ризыкны җан саклау микъдарыннан артык ашарга ярамый. Урыс армиясендә хезмәт итәргә мәҗбүр мөселманнар, зиндандагылар дуңгыз ите ашар, бәлки аның гөнаһы булмас. Әмма иленә кайткач, ireккә чыккач, ул бу харам ризыклардан ваз кичәргә тиеш».)*

**174**. Аллаһ индергән китаптагы хакыйкатьне *(яһүдләр, христианнар)* яшерделәр һәм аны юк кына бәягә дөнья малына сатып көн күрә башладылар. *(Шул акчага сатып алынган ризыклар белән карыннарын тутыралар)*, эчләренә ризык түгел, ут тутыралар алар. Кыямәт җиткәч, Аллаһ алар белән сөйләшеп тормас, аларны ярлыкамас. Аларны анда җанны көйдерүче җәза көтеп тора.

*(«Яһүд руханилары Пәйгамбәребезнең Тәүратта күрсәтелгән сыйфатлары турындагы хәбәрне халыктан яшерделәр. Аллаһ иңдергән китап—Тәүратны алар бозды, үзгәртте. Шушы эшләре өчен, ягъни бозык Тәүраттагы бозык фикерләрне сатып, алар халыкны алдады, талады. Аларның шулай итеп тапкан маллары карыннарына ут булып кабачак»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**175**. Алар тугры юлны ялган юлга алмаштылар. Ярлыкану урынына алар газап юлын сатып алдылар. Утта януга алар ничек итеп түзәрләр икән?

**176**. Аллаһның китабы Хакыйкать буларак иңдерелде. Ул китап турында шикле бәхәсләр оештыручылар, әлбәттә, *(Хактан)* аерылып, ераклаштылар. Газаплар аларга шуның өчен бирелер.

**177**. Йөзегезне Көнчыгыш яки Көнбатышка таба карату гына *(гыйбадәт кылу гына)* игелек кылу түгел. Чын игелек ул—кешенең кылган яхшы гамәлләредер: Аллаһка, Ахирәт көненә, фәрештәләргә, китапларга, пәйгамбәрләргә инану; якыннарга, ятимнәргә, юксылларга, юлда калганнарга *(адашканнарга)*, теләнчеләргә вә колларга *(әсирләргә)* кадерле малыннан өлеш чыгару, намаз кылу, зәкят бирү. Антыңны җиренә җиткезү, авыр заманнарда, хасталыкта вә сугыш вакытларында сабыр итү, түзем булу. Чын мөселман кешесенең сыйфаты шулардан тора. Мөттәкыйлар *(Аллаһның җәзасыннан курыккан мөэминнәр)* бары тик шундыйлар гына була ала.

**178**. *(И, мөэминнәр)* үтерелгән кеше өчен сезгә үч кайтару фарыз ителде. Ирекле кеше өчен—ирекле, кол өчен—кол, хатын өчен—хатын *(үтерелергә тиеш.)* Ләкин үтерүченең гаебе мәрхүмнең кардәше *(гаиләсе)* тарафыннан гафу ителсә, гореф-гадәт буенча, үтерүче шул нәселгә игелек кылсын. Алда әйтелгәннәр, Аллаһтан иңдерелгән җиңеллек *(гадел хөкем)* вә рәхмәттер. Моннан соң да берәрсе шушы чикләрне боза калса, аңа хәтәр җәза бирелер.

**179**. И, акыл ияләре, үтергән кешене үтерүдә сезнең өчен яшәү көче бар. Касастан *(үтерүчегә биреләчәк җәзадан)* куркып, бәлки сез шундый җинаятьләр кылмассыз?

**180**. Берәрегезгә әҗәл якынлаша калса, аның малы кала торган булса, анасына, атасына, якыннарына гадел рәвештә өлеш чыгарылырга һәм васыять ителергә тиешлеге Аллаһның җәзасыннан курыкканнар өчен бер бурычтыр. **(181)** Васыятьне ишеткәч һәм кабул иткәннән соң, бу васыятьне үзгәрткән кешеләр гөнаһлы булыр. Шик юк ки, Аллаһ барысын да ишетеп, күреп тора. **(182)** Васыятьне кабул итүче варис васыятьнең шәригатькә хилафлык белән яки гаделсезлек белән яздырылган дип шикләнсә, ике як белән килешеп, васыятьне хакыйкатькә туры китереп үзгәртә ала, ул гөнаһлы булмас. Шөбһәсез ки, Аллаһ ярлыкаучы һәм дә кичерүчедер.

**183**. И, иман китергән бәндәләр, сездән алда килеп-киткәннәргә фарыз ителгәне кеби, ураза тоту сезгә дә фарыз кылынды. Бәлки сез *(бу фарызларны үтәп)* котылу юлына басарсыз?

**184**. Ураза санаулы көннәрдә генә тотылыр. Берәрегез хаста булса яки сәфәрдә йөрсә *(ураза тотмас)*, соңыннан тотылмаган көннәре өчен ураза тотар. *(Картлык*

*зәгыйфьлегендәге кеше яки сәламәтләнеренә өмет калмаган чирле кеше ураза тотмас)* ураза тотарга көче житмәгәннәр *(матди мөмкинлекләре булса)* бер фәкыйрьне *(утыз көн)* көн туйдырырлык фидия бирергә тиеш. Шулар өстенә кеше үз ихтыяры белән хәер-садака бирсә, үзе өчен бик тә хәерле булыр. Белеп торыгыз, ураза тоту сезнең өчен тагын да хәерлерәк.

**185**. Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр. Шуңа күрә, шушы айга килеп ирешкәннәр ураза тотсын. Хаста булганнар яки сәфәрдәгеләр *(тотылмаган көннәре хисабынча)* башка көннәрне ураза тотар. Аллаһ сезгә җиңеллек тели, кыенлык теләми. Санаулы *(ураза)* көннәрне тәмам итеп, сезгә тугры юл күрсәткәне өчен, Аллаһны олылагыз, шөкер итегез.

**186**. Бәндәләрем Минем турыда сораштырсалар, әйт: Мин *(һәр кешегә)* бик якын торам. Миңа дога кылганнарның теләкләренә җавап бирәм. Алар да тугры юл белән барыр өчен Мине ишетсеннәр, Миңа ышансыннар. Һәм әмерләремне үтәсеннәр.

**187**. Ураза төнендә хатыннарыгызга якынаерга сезгә хәләл кылынды. Хатыннарыгыз сезнең күлмәгегез кеби, сез дә аларга юрган *(бөркәвеч)* кебидер. Аллаһ сезнең үзегезгә үзегез хыянәт иткәнегезне белде. Тәүбәгезне кабул итеп, сезне ярлыкады. Инде хатыннарыгызга якынлашыгыз вә Аллаһ рөхсәт иткәннәрне эшләгез. Иртәнге якта *(ак җепне кара җептән аера алганчыга)* Таң нуры караңгылыктан аерыла башлаганчыга *(ягъни Кояш чыгарга сәгать ярым кала)* кадәр ашагыз, эчегез, көне буе ураза тотып, ахшамда авыз ачыгыз. Мәчетләрдә *(итикаф вакытында, ягъни Рамазан аеның соңгы ун көнендә)* гыйбадәт кылган вакытта хатыннарыгыз белән берләшмәгез. Болар Аллаһ тарафыннан куелган чикләрдер. Сак булыгыз, аларга якынлашмагыз. Шушы рәвештә Аллаһ аятьләрен сезгә аңлата. Бәлки *(гөнаһ кылудан)* сакланырсыз?

*(Ир белән хатынның үзара мөнәсәбәте монда шундый матур итеп сурәтләнгән. Беренчедән, җенси теләк, бер җенеснең икенчесенә тартылуы ачлык, сусау кебек хисләр белән рәттән куела. Бу хис-теләкләр табигать тарафыннан бирелгән. Адәм баласы тәненең бу ихтыяҗларын үтәмичә булдыра алмый, ашамыйча-эчмичә тора алмаган кебек, җенси ихтыяҗларын да канәгатьләндерү мәҗбүрендә. «Хатыннарыгыз сезнең күлмәгегез кеби, сез дә аларга юрган (бөркәвеч) кебидер дигән белән безгә ир-хатын мөнәсәбәтләре табигый теләкне үтәүдән тыш, тагын да бөек мәгънә турында сөйләнә. Ир белән хатын бер-берсенә саклавыч кием рәвешендә дә хезмәт итә, ягъни кием тәнне суыктан-эсседән саклаган кебек саклый, ир-хатын бер-берсен саклый, юата, бер-берсен тулыландыра, бизи, берсенең җитешмәгән ягын икенчесе тулыландыра»).*

М.Мөхәммәд Али тәфсиреннән.

*(«Ислам дине тарала башлаган заманнарда Рамазан уразасы тотканда сәхәр ашалмаган. Ураза тотучы кеше ахшамда авыз ачып, ястү намазы укып, йокларга ятканга чаклы гына ашаган. Шуннан соң ашау-эчү, хатын белән якынлык тыела иде. Бу кырыслыкка чыдый алмаенча, бәгъзеләре хатыннарына якынлык кыла иде. Арып кайтканлыктан, кайберәүләр исә, авыз ачу белән үк йокыга китеп, икенче көнне хәлсез йөри иде. Аллаһ мөэминнәрне кызганды вә аларга җиңеллек өчен, кайбер ташламалар ясады»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**188**. Бер-берегезнең малын гаделсезлек белән тартып алып ашамагыз. Кешенең малын өлешчә генә булса да махсус тартып алыр өчен, хөкемдарларга ришвәт бирмәгез.

**189**. *(Ий, Мөхәммәд)* синнән *(ел эчендәге)* айлар турында сорарлар. Син әйт:

- Айлар кешеләргә хаҗ вакытын билгеләр өчен,—диген.

Игелек ул—өй артыннан кереп йөрү түгел.

*(«Элек гарәпләр: хаҗ вакытында ишектән йөрергә ярамый, дип өйләренең арткы тарафыннан тишек ачып, өйләренә шуннан кереп-чыгып йөри торган булганнар. Аллаһ кешеләрне бу мәшәкатьтән коткарыр өчен, шушы аятьне иңдерә»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

Игелек ул—гөнаһ кылудан саклану. Өйләрегезгә ишектән кереп йөрегез. Аллаһның газабыннан куркыгыз. Шулай булганда сез *(котылышка)* морадыгызга ирешерсез.

**190**. И, мөэминнәр, Аллаһ юлында сугышучылар белән бергә *(сезгә һөҗүм иткәннәргә каршы)* сугышыгыз, ләкин артыгын кыланмагыз, Аллаһ артыгын кылганнарны бер дә сөйми.

*(Үзегез сугыш башламагыз, тыныч халыкны кырмагыз, җиңелгән халыкны, әсирләрне җәберләмәгез. Ягъни, сугышта да хәттин ашмагыз.)*

**191**. *(Үзләре сугыш башлаган)* кяферләрне кай җирдә очратсагыз, шунда үтерегез; сезне куып чыгарган җирләрдән аларны да куыгыз. Фетнәлек кеше үтерүдән дә яманрак.

Мәчеттә алар сезгә ташланмаса, сез дә һөҗүм итмәгез; алар сезгә каршы сугышса, сез аларны үтерегез. Кяферләр өчен җәза шул булыр. **(192)** Алар сугыштан баш тартса, Аллаһ аларны гафу итәр, аларга рәхмәтле булыр.

**193**. Фетнә тулысынча юк ителгәнгә кадәр; бары тик Аллаһ дине *(Ислам)* гына торып калганчыга чаклы сугышыгыз. Фетнәдән ваз кичеп, сугыштан туктасалар, аларга дошманлык һәм аларны кысрыклау булмаячак.

**194**. Харам ай харам айга бәрабәрдер: кем сезгә явызлык кылса, сез дә аларга кылган явызлыклары кадәр явызлык кылыгыз. Аллаһтан *(җәзасыннан)* куркыгыз вә белеп торыгыз: Аллаһ гөнаһ-харамнан курыкканнар белән бергә булыр.

*(«Һиҗрәтнең алтынчы елында гыйбадәт кылырга дип, Мәккә шәһәренә килгән мөселманнарны кяферләр Харам мәчетенә кертмәделәр. Бу эш сугышлар тыелган, ягъни сугыш харам ителгән Зөлкагдә аенда булды. Сугышырга харам ителгән айда кяферләр мөселманнарга каршы сугыш ачтылар. Сугыш тукталгач, ике арада килешү төзелде. Икенче елда харам аенда Харам мәчетендә кяферләр түгел, мөселманнар баш булачак, диелде. Икенче елда, чыннан да, мөселманнар Харам мәчетендә гыйбадәт кылдылар. Шулай итеп, харам айга каршы харам ай гамәлгә кереп калды»).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**195**. Аллаһ юлында тиешле малларыгызны кызганмагыз. Үз кулларыгыз белән үзегезне куркыныч җәзага ташламагыз. Һәр гамәлегездә игелек белән эш итегез. Аллаһ игелек кылганнарны сөя.

**196**. Хаҗны һәм нәфел хаҗ *(корбан чалмаенча гына хаҗ кылу)* йолаларын Аллаһ риза булырлык итеп, төгәл үтәгез. Әгәр бу эшләр сезгә кыенга туры килсә, кулыгыздагы корбанлыкны биреп җибәрегез. Корбан тиешле урынга барып житмәенчә, чәчегезне кырдырмагыз. Берәрегез хаста булса яки башка берәр төрле рәхәтсезлеге булса *(хаҗга барып җитә алмаса)*, ураза тотып яки садака биреп яки корбан чалдыру урынына фидия садакасы биреп, бурычын үтәр. *(Хастадан, башка төрле рәхәтсезлекләрдән)* имин булсагыз, хаҗ көннәренә чаклы гүмрә, ягъни корбансыз гына Харам мәчетен зиярәт итәргә теләсәгез, ул кеше үз җаена карап корбан чалдырырга тиеш. Корбан салдырмаган кеше хаҗ көннәрендә өч көн, иленә кайткач, жиде көн, жәмгысы ун көн ураза тотар. Бу әйтелгәннәр, гаиләсе Харам мәчете тирәсендә яшәмәгәннәр өчендер. Аллаһтан *(нәфрәтеннән)* куркыгыз. Белеп торыгыз ки, Аллаһның гөнаһлыларга бирәчәк җәзасы бик тә хәтәр булачак.

**197**. Хаҗ кылу мәгълүм бер айларда була. Шул айларда хаҗга барырга ниятләгән кеше *(ихрамга керә, ягъни)* хаҗ дәверендә хатынына якынаймаска, гөнаһ саналган бөтен нәрсәләрдән ваз кичәргә, кешеләр белән гаугалашмаска тиеш. Игелек эшләгәнегезне Аллаһ күреп тора. *(Әй, мөэминнәр, Ахирәт өчен)* ризык әзерләгез. Белеп торыгыз, ризыкның иң хәерлесе—иманлы булу. И, акыл иияләре, Минем әмерләремне үтәмәүдән куркыгыз.

**198**. *(Хаҗ фасылында сәүдә итеп)* Раббыгыздан ризык *(сәүдә файдасы)* теләсәгез, сезгә гөнаһ юктыр. Гарафат тавыннан төшеп, төркем булып Мәшгар-и Харамга кайткач, Аллаһны зикер итегез вә адашып йөргәнегездә *(таш сыннарга табынган чагыгызда)* сезне тугры юлга бастырганы өчен Аны искә алыгыз.

*(«Ихрам» сүзенең ике мәгънәсе бар. Ихрам—энәсез, җепсез хәзерләнгән кием. Бу ак тукымага төренеп, мөселманнар хаҗга бара. Кәфенгә охшашлыгы белән ул, бәлки, үлемне, Ахирәт көнен искә төшереп торыр өчен тәгаенләнгәндер. Бөтен мөселманнарның, нинди милләттән булуларына карамастан, ак тукымага төренеп хаҗга җыелуы аларны рухи яктан берләштерә, теләктәшлек, рухи туганлык хисен арттыра булса кирәк. Кайдан гына килгән булсак та, нинди генә телдә сөйләшсәк тә асылда без кардәшләр, Аллаһ-безнең уртак Тәңребез, дигәнне аңлатадыр бу уртак ак кием. Икенче мәгънәсе, хаҗга барыр алдыннан ук тәкъва тормышка күчү, чистарыну, уразадагы кебек, үзеңне тыю, шикле-гөнаһлы эшләрдән ваз кичү, дигән сүз ул ихрам).*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**199**. Соныннан *(кулга-кул тотышып)* башка кешеләр төркем-төркем булып төшкән җирдән *(Гарафат тавыннан)* сез дә төшегез. Аллаһтан ярлыкау сорагыз. Шөбһәсез ки, Аллаһ һәрвакыт ярлыкаучы, кичерүчедер. **(200)** Хаж гыйбадәтләрегезне тәмамлагач, ата-бабаларыгызның рухын искә алганыгыз кебек, хәтта алардан да ныграк Аллаһны зиһенегездә тотыгыз. Кешеләрнең шундыйлары да бар, алар:

—Йа, Раббыбыз, безгә дөньяда *(яхшы тормыш)* бир,—диләр. Андыйлар өчен Ахирәттә ярлыкау насыйп ителмәс. **(201)** Шундыйларның кайберләре:

—Йа, Раббым, безгә дөньяда да яхшы тормыш бир, Ахирәттә безне җәннәткә урнаштыр. Безне җәһәннәменнән коткар,—диләр. **(202)** Менә аларга, үзләре казанганнарга бәрабәр, насыйбы булыр. Аллаһ тиз арада исәп-хисап алачак. **(203)** Санаулы көннәрдә *(ягъни хаҗ көннәрендә)* Аллаһны зикер итегез. Ашыгыч рәвештә ике көндә *(Мина тавыннан төшеп, Мәккәгә)* китәргә теләгән кешенең гөнаһысы булмас. Кичеккән кеше, бер көнгә соңга калса, аның да гөнаһысы булмас. Ул эш тәкъвалар өчен. Аллаһның җәзасыннан куркыгыз вә белеп торыгыз, һич шик юк ки, сез барыгыз да Аның хозурына килеп басачаксыз.

**204**. Кешеләр арасында шундыйлары *(мәкерлеләре)* бар ки, андыйлар *(дин тотулары турында)* дөньядагы тормыш хакында *(татлы)* сүзләр сөйләп, сине хәйран калдырыр. Тугрылыкларын исбатлау өчен алар Аллаһ исеме белән ант итәләр. Гамәлдә алардан да куркыныч дошман юк.

*(«Икейөзле, ягъни монафикъ кяфердән дә яманрак, мәгънәсендә. Әхнәс бине Шураек исемле бер бәндә Рәсүлебез янына килеп, матур сүзләр сөйли, күңеленең Аллаһка тугры икәне турында лаф ора, соңыннан мөселманнарның игеннәрен яндырып, малларына зур зыян салып китә»).*

Ногмани тәфсиреннән.

**205**. Андый кеше синең яннан китеп *(эш башына утырса)*, астыртын эш йөртә башлый. *(Фетнәгә, гаугага сәбәпче була)* вә игеннәрне, малларны харап итеп, нәсел корыту өчен җан ата. Аллаһ *(астыртыннарны)* Фетнәчеләрне сөйми. **(206)** Ана: Аллаһтан курык, дисәләр, ул тагын да тәкәбберләнә, аның бу мин-минлеге тагын да бозык юлга этәрә. Ана иң зур җәза—җәһәннәм газабы. Җәһәннәм ул—иң хәтәр торак урыны.

**207**. Кешеләр арасында тагын шундыйлары да була: алар Аллаһның ризалыгын алмак өчен, җанын да кызганмый. Аллаһ колларына гаять мәрхәмәтле.

**208**. Әй, иман китергән кешеләр, барыгыз да *(татуланып)* берләшеп, Ислам диненә керегез. Шайтан артыннан иярмәгез. Ул сезнең кан дошманыгыз.

**209**. Шундый ап-ачык дәлилләр килгәннән соң да сез юлдан язсагыз, ан булыгыз: Аллаһ, һичшиксез, кодрәтле һәм хикмәткә ия.

**210**. Алар *(Исламны кабул итмәгән кешеләр)* Аллаһ болытларга төренеп, фәрештәләре белән бергә килеп төшәр һәм эшләрне тәмамлар, дип көтәләрме икән әллә? Хәлбуки, бөтен эшләр дә Аллаһ хозурына килер.

**211**. Исраил токымына *(яһүдләргә)* әйт син: аларга ничәмә-ничә анлаешлы аятьләр бирдек. Кем үзенә Аллаһ тарафыннан күндерелгән нигъмәтне *(Тәүрат һәм Коръәнне)* үзгәртсә, алмаштырса, шөбһәсез: Аллаһның җәзасы *(аңа)* бик тә хәтәр булачак.

**212**. Кяферләргә бу дөнья рәхәт тормыш буларак күрсәтелде. Алар иман китергән кешеләрдән көлделәр. Гәрчә, иманга тугры булганнар Кыямәт көнендә тегеләрдән өстен чыгачак.

Аллаһ Үзе теләгән кешеләргә хисапсыз ризык бирер.

**213**. Кешеләрнең барысы да бер өммәттән иде. *(Әмма кешеләр кайсысы иман китерде, кайсылары кяфер булып китте һәм алар бер-берсенә дошман булды)* шуңа күрә, Аллаһ *(иман китергәннәрне җәннәт турындагы)* *сөенечле хәбәрләр илә куандырырга, (имансызларны җәһәннәм белән кисәтеп)* куркытырга пәйгамбәрләрен юллады. Кавемнәр арасындагы каршылыкларны хөкем итәр өчен, хак китаплар иңдерде. Ләкин үзләренә китап иңдерелгән кавемнәр, ап-ачык дәлилле китаплар алганнан соң да, көнчелекләре аркасында, диндә килешә алмаенча, аерылдылар *(төрле фиркаларга бүленделәр.)* Бу мәсьәләдә Аллаһ иман китергән кешеләргә үз ихтыяры белән тугры юл күрсәтте. Теләгән кешеләрне Аллаһ тугры юлга күндерә.

**214**. *(Ий, мөэминнәр)* әллә сез үзегездән элек яшәгән кешеләр күргән кыенлыкларны күрмичә генә, җәзалар татымыйча гына җәннәткә керергә

хыялланасызмы? Алар хәерчелектә яшәде, күп төрле кыенлыклар күрде, аптырашта, чарасыз калды. Хәтта пәйгамбәрләр мөэминнәр белән берлектә:

—Аллаһның ярдәме кайчан килер?—диделәр.

Күзегезне ачып карагыз: чынлыкта Аллаһның ярдәме якындыр.

**215**. Алар садакага нәрсә бирергә кирәклеге турында сорарлар. Син әйт:

—Яхшы малдан биреләсе өлеш—ата-анага, кардәшләргә, ятимнәргә, ярлыларга, сәфәрдәгеләргә бирелгән кебек. Игелекле һәр эшегезне, шөбһәсездер ки, Аллаһ белеп тора.

**216**. *(Ий, мөэминнәр)* сугыш эшләренә нәфрәтле булсагыз да *(дошманнарга каршы)* сугышу сезгә фарыз ителде. Шулай да була: кайбер нәрсәләрне сез сөймисез, ә ул сезнең өчен файдалы; кайчак сез үзегезгә зарарлы булганнарны да сөясез. Боларның барысын да Аллаһ белә, сез белмисез.

**217**. Харам аенда булган бу сугыш турында синнән сорарлар. Син әйт:

—Ул айда сугышу—зур гөнаһ. *(Кешеләрне)* Аллаһ юлыннан барудан тыю, Аллаһны инкарь итү, Мәсҗед-и Харамга керергә теләгәннәрне тыю, халыкны аннан сөреп чыгару исә Аллаһ катында тагын да зуррак гөнаһ. Фетнәче—кеше үтерүчедән дә яманрак. Көчләре житсә, кяферләр денегездән яздырганчыга чаклы сезнең белән сугышачак. Берәрегез диненнән язса, кяфер булып үлсә, аның дөньяда кылган яхшы эшләре Ахирәттә файда бирмәс. Алар утның дусты булыр. Алар анда *(җәһәннәм утында)* мәңгегә калачак.

**218**. Хакыйкатән, иман китергән кешеләр, йортларыннан күчеп китеп, дин юлында сугышканнары өчен, Аллаһның рәхмәтен өмет итә. Аллаһ иман китергәннәрне ярлыкаучы, аларны житди рәвештә гафу итүче.

**219**. Исерткеч эчү вә отышлы азгын уеннар турында синнән сорарлар. Син әйт:

—Аларның һәр икесендә дә зур гөнаһлар һәм файда да бар. Гөнаһлары файдаларына караганда күбрәк,—диген.

Янә синнән садаканың ничек бирелергә тиешлеге турында да сорарлар. Син әйт:—Ихтыяжыңнан артканын бир,—диген. Аллаһ аятьләрен әнә шулай аңлатып бирә. Бәлки уйланырсыз?

**220**. Сез дөнья турында да, Ахирәт турында да уйланыгыз. Синнән *(Мөхәммәд)* ятимнәр турында да сорарлар. Әйт:

—Аларны тиешенчә тәрбия итү, тормышларын яхшырту—игелектер,—диген.— Алар белән бергәләшеп яшәсәгез, алар сезнең кардәшләрегез булып китәр. Аллаһ *(ятимнәр)* файдасына гамәл кылганнарны да, яманлык кылганнарны да белеп тора. Теләгән кешесенә Аллаһ зыян-зәхмәт китерә ала. Шик-шөбһәсездер ки, Аллаһ— җиңүчедер, хөкем вә хикмәт ияседер.

*(Пороховада: «И если примете их в свои заботы, они вам станут братья».*

*М. Алидә: «И если ты смешаешься с ними (с сиротами), они братья твои».*

*Йазирда: «Үзләре белән катнашып яшәсәгез, алар сезнең кардәшләрегез (булыр)».*

*Йылдырымда: «Әгәр аларга хуҗа-тәрбияче булыр өчен, алар белән бергә яшәргә теләсәгез, бу да мөмкиндер».)*

**221**. *(Ий, мөэминнәр)* Аллаһтан башка нәрсәләрне тәңре диеп табынучы *(потпәрәст, мәҗүси)* хатыннарга *(иман китермәстән)* өйләнмәгез. Иман китергән жария *(кол хатын)* мәҗүси хатыннан—ул сезгә бик ошаса да—күпкә яхшырак. Мөселман хатыннарны да мөшрик ирләргә *(әгәр ул ирләр Исламны кабул итмәгән булса)* кияүгә бирмәгез. Мөэмин колирекле мөшрик ирдән яхшырак, хәтта ул *(мөшрик ир)* сезгә бик ошаса да. Алар *(мөшрикләр)* сезне җәһәннәмгә тарта, Аллаһ исә үз теләге белән җәннәткә һәм ярлыкауга чакыра. Ул кешеләргә аятьләрен ап-ачык итеп аңлата. Яхшылап уйлаганнан соң, бәлки гыйбрәт алырлар *(тугры юлга басарлар, мөэмин булып китәрләр)*.

222. Алар синнән хатыннарның айга бер тапкыр була торган халәтләре турында да сораштырырлар. Син әйт:

—*(Хатын-кыз өчен)* ул бер җәфа инде,—диген.—Шуңа күрә, күрем вакытында хатыннарыгыздан аеры торыгыз, *(җенси мөнәсәбәтләргә кермәгез)*, алар аруланып беткәнче хатыннарыгызга якынлашмагыз. Арулангач, алар белән, Аллаһ боерганча гамәл кылыгыз. Һәрхәлдә, Аллаһ тәүбә иткәннәрне һәм пакьләнгәннәрне сөя.

**223**. Хатыннарыгыз сезнең өчен иген басуыдыр. Иген басуыгызга теләгәнегезчә барыгыз. Алдан ук хәзерләнеп, үзегезнең киләчәгегез өчен яхшы гамәлләр кылыгыз. Вә Аллаһның җәзасыннан куркыгыз һәм белеп торыгыз, хакыйкатән, сез Аның хозурына барачаксыз. Иман китергән кешеләргә сөенечле хәбәрләр ирештер.

**224**.—Валлаһи, игелек кылачакмын, мин тәкъвалыкка күчәчәкмен, мин кешеләрне дуслаштыручы,—диеп, беркайчан да Аллаһ исеме белән ант итмәгез, үз юлыгызга киртә куймагыз. Аллаһ барысын да ишетеп, күреп тора.

*(Начар эш эшләрмен, дип ант иткән булсагыз, антыгызны бозыгыз, яхшы эш кылыгыз, антыгызны бозганыгыз өчен кәффарәт итегез, ягъни өч көн ураза тотыгыз.)*

**225**. Аллаһ *(үзегез белештермичә биргән, хәсете-мәкере булмаган)* антыгыздагы хаталар өчен җәзаламас. Фәкать күңелегездәге хәсетлек өчен җәза бирер. Аллаһ ярлыкаучы вә рәхимледер.

**226**. Хатынына якынлык кылмаска ант иткән кеше *(хатынын янә теләсә дә)* дүрт ай көтәргә тиеш. Ирләр шуннан соң антыннан ваз кичсә *(кәффарәт итсә, өч көн ураза тотса)* хатыннары белән якынлык кыла алалар. Шик юк ки, Аллаһ житди рәвештә ярлыкаучы, чыннан да, кичерүче.

**227**. Аерылырга теләү котылгысыз булса, *(ир белән хатын)* аерылыр. Шөбһәсез ки, Аллаһ ишетеп, күреп торучы. **(228)** Талак алган хатыннар *(башка ирга чыгарга теләсә)*, өч тапкыр күрем күргән вакыт узганчы сабыр итәр. Аерылган хатыннар, әгәр алар Аллаһка ышансалар, Ахирәт көненә инансалар, үз карыннарындагы *(беренче иреннән балага узганлыгын)* яралгысын яшерсә, хәләл булмас. Аерган ир шушы *(өч ай)* вакыт эчендә, татулашырга теләп, хатынын кире кайтарса, хәерле булыр. Ирләрнең хатыннары өстеннән хокуклары булган кеби, хатыннарның да ирләре өстеннән хокуклары бар. Ләкин йола буенча ирләрнең *(гаилә башлыгы буларак)* хатыннар өстеннән булган хокукы күбрәк. Аллаһ — мотлак җиңүчедер, хакыйкатән, хөкем чыгаручы вә хикмәт иясе. **(229)** Талак (ир белән хатынның аерылуы) ике өлештән тора. Ир кеше хатынын ике тапкыр талак итсә, янадан торырга теләсә, каршылыксыз хатынын кире алырга хаклы, яхшылап торырга хокуклы. Яки яхшылык белән, тиешен биреп, аерып җибәрә. Аерганда хатыннарыгызның мәһәрен *(аларга бүләк ителгән нәрсәләрне)* алып калу хәләл булмас. Әгәр алар икесе дә Аллаһ куйган чикләрне бозарбыз дип курыкса гына. Әгәр дә шул чикләрне узарбыз дип курыксагыз, ул хатын иренә калым малын, мәһәрен биреп, азатлык *(талак)* алыр. Ул чагында аларның икесе дә гөнаһлы булмас. Сөйләнгәннәрнең барысы да Аллаһ куйган чикләнүләрдер. Шул чикләрне бозмагыз. Шул чикләрне бозган кешеләр залим булыр. **(230)** Ир кеше хатынына өч тапкыр талак әйтсә, ул хатын иренә хәләл булмас; икенче бер ир белән никахлашып, аннан талак алгач кына, беренче ир шушы хатын белән янә никахлаша ала. Бу эштә гөнаһлылар юк. Әгәр дә алар алга таба Аллаһ билгеләгән чикләр эчендә яшәүләренә инансалар. Менә болар Аллаһның чикләүләре булыр. Аллаһ бу чикләүләрне аңлардай белемле кешеләргә бәян итә.

*(«Җаһәләт вакытында, ягъни Коръән иңгәнчегә чаклы, халыклар надан заманнарда, ирләр хатыннарын бер аерып, бер кушылып, теләсә ничек кыланып яшиләр иде. Хатыннар хокуксыз иде. Ислам дине бу башбаштаклыкларны чикләп куйды. Ирләргә хатыннарга караганда өстенрәк хокуклар бирсә дә, хатыннарның да хокукын яклап, талак тәртипләрен кертте. Икенче иргә чыгып, аннан аерылгач кына элеккеге хатынына яңадан өйләнү тәртибе дә өйрәнсез ирләргә кисәтү, аерасың икән, ныклап уйла, хатын белән уйнама, дигән сүз»).*

Х. Караман тәфсиреннән.

**231**. Хатыныгызны аерасыз икән, аның гыйддәте *(билгеләнгән вакыты)* узгач, яхшылап кына торыгыз яки яхшылап кына аерып җибәрегез. Ләкин сез аны ирексезләп, әүәберләптотмагыз. Шулай кыланган кеше, үзенә йазык әзерли. Аллаһның аятьләрен көлкегә әйләндермәгез. Аллаһның сезгә биргән нигъмәтләрен, сезгә үгет-нәсихәт бирер өчен иңдергән Китабын *(Коръәнне)* вә аның хикмәтләрен исегездән чыгармагыз. Аллаһның җәзаларыннан куркыгыз вә белеп торыгыз. Хакыйкатән, Аллаһ барысын да белеп тора.

*(**Гыйддәт**—ир хатынына ике кат талак әйткәч, хатын аерылып китмәс. Өч тапкыр күрем күреп, пакъләнгәненә чаклы ир йортында торыр. Ягъни балага узган-узмаганны төгәл*

*белгәнчегә чаклы шунда яшәр. Шул вакыт «гыйддәт» дип атала.)*

**232**. Хатынын аергач һәм хатынның гыйддәте үтсә, алга таба шәригатьчә хатыны белән яшәргә теләсәләр, аларның янадан никахлашуына комачауламагыз. Аллаһка, Ахирәт көненә иман китергәннәргә шушындый үгет бирелә. Бу сезнең өчен бик тә файдалы вә пакьлектер. Бу эшләрнең барысын да Аллаһ белер, сез белмәссез.

**233**. Аналар балаларын ике ел дәвамында имезергә тиеш. *(Бу хөкем)* имезүдән туктарга теләгәннәр өчен. Гореф-гадәт буенча *(аналарның)* ашау-эчүе, киеме баланың атасы өстеннән булырга тиеш. Беркемнән дә мөмкинлегеннән артыгы соралмас. Баласы аркасында анасын рәнҗетү, бала өчен атасын рәнҗетү булмасын.

***(Баланы имезергә көчләү, имезергә теләгән хатынның кулыннан баланы тартып алып, имезүдән тыю хәләл түгелдер.)***

Мирасчы өстенә төшкән вазифа да шулай ук. *(Баланың атасы үлеп китсә, имезүче хатынны ашату-эчерту мирасчы өстенә төшә.) (Ата-ана)* арасында ризалык вә уртак килешү булса, *(ике яше тулмаган баланы)* күкрәктән аерырга теләсәләр, икесенә дә гөнаһ булмас. Балаларыгызны имезер өчен башка хатын ялласагыз, гөнаһ юктыр. Аллаһның җәзасыннан куркыгыз вә белегез: шик юк ки, Аллаһ сез ни кылсагыз, шуны күреп тора.

**234**. Арагыздан берәрсе үлсә, аның тол калган хатыннары *(башка ир белән аралашмыйча)* яки аерылган хатын ялгызы дүрт ай да ун көн *(гыйддәт)* көтеп яшәр. Менә шушы вакыт узуга, алар үзбашларына яши башласа, сезнең өчен гөнаһ булмас. Аллаһ сез ни эшләсәгез дә, хакыйкатән, хәбәрдардыр.

***(«Гыйддәт вакытында тол калган хатын кияүгә чыгарга, мәрхүм иренең өеннән чыгып йөрергә, бизәнергә тиеш түгел. Шушы вакыт эчендә хатынның иреннән йөкле калдымы, юкмы икәне беленер. Йөкле калган булса, хатын шул йортта бала туганчыга кадәр кала. Соңра башка кешегә кияүгә чыга ала. Йөкле булмаса да, гыйддәт вакыты узгач, хатынның кияүгә чыгарга хокукы була. Гыйддәт вакытында хатынның йөге төшсә, гыйддәтне азагына кадәр дәвам итү ихтыяҗы калмый»).***

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**235**. *(Гыйддәт тоткан)* хатыннарга *(никах белән)* өйләнергә теләвегез яки шуңа өмет итеп, эчтән генә хыялланып йөрүегездә гөнаһ юк. Аллаһ беләдер ки, сез аларны *(бу кагыйдәләрне)* һич тә онытмассыз. Ләкин *(гыйддәттәгеләрнең)* үзләре белән яшерен вәгъдәләшмәгез, әдәп чикләрендәге гадәти сүзләр генә сөйләгез. *(Мәҗбүри булган)* гыйддәт вакыты ахырына килеп җитмәенчә, никах турында сүз кузгатмагыз. Аң булыгыз, гыйддәт узмаенча, никах турында сүз кузгатмагыз. Аң булыгыз, Аллаһ сезнең күңелегездәге ниятләрнең барысын да, әлбәттә, белеп тора. Аның җәзаларыннан куркыгыз һәм янә белеп торыгыз: хакыйкатән, Аллаһ бик күп мәрхәмәт итүче, Ул сабырдыр.

**236**. Никахлашканнан соң, хатынга кагылмаган булсагыз, калым-бирнә алынмаган булса, бу хатынны талак итсәгез, гөнаһ юк. Мөлкәтегез рөхсәт иткәнчә, матди кысынкылыкта булганда да, *(аерылган хатынга)* кадәри хәл өлеш биреп җибәрегез. Мондый эш игелек итүченең бурычыдыр. **(237)** Сез аларны кагылмаган килеш аерсагыз, аларга мәһәр тәгаен иткән булсагыз, ул вакытта тәгаенләнгән малның яртысы аларга булыр. Мәгәр ки алар үзләре мәһәрдән баш тартса, кулында никах шарты булган кеше гафу итсен. *(Һәй, ир кешеләр)* сезнең киң күңелле булуыгыз тәкъвалыкка якын булыр. Сезгә бирелгән өстенлекне онытмагыз. Шөбһәсез ки, сез ни кылсагыз, Аллаһ шуны күреп тора.

**238**. Намазларны вә урта намазны *(икендене)* калдырмаенча дәвам итегез. Түбәнчелек белән Аллаһка итагать итеп, намаз укыгыз. **(239)** Ләкин *(сугыш вакытында, ташкын басканда яки шуңа охшаш куркынычлар булганда, итагать илә иркенләп намаз укырга мөмкинлекләр булмаганда)* шөбһәле мохиттә дә аягөсте яки җайдак барган *(Кыйблага карарлык шартлар булмаганда да)* намаз укыгыз. Куркыныч *(яки хасталыгыгыз)* узып киткәннән соң, элек белмәгәнегезне Аллаһ сезгә ничек өйрәткән булса, шулай, Аллаһны мактап, намаз кылыгыз.

**240**. Берәрсе хатыннарын тол калдырып үлеп китсә, үләр алдыннан хатыннарына аның өендә мохтаҗлык күрмәенчә, бер ел яшәргә рөхсәт иканлеге турында васыять әйтсен. Әгәр *(тол калгач)* алар үз теләкләре белән өйдән китсәләр һәм үзләре теләгәнчә, шәригатьчә яши башласалар, варисларга гөнаһ юк. Аллаһ—

һәрвакыт кодрәт вә хикмәтләр иясе.

**241**. Талак кылынган хатыннарга ирләре *(шәригать кушканча)* мал бүлеп бирергә тиеш. Хатын хакын бозмау—мөэмин мөселманнарның изге бурычы.

**242**. Сезнең зиһеннәрегезгә барып җитсен дип, Аллаһ аятьләрен менә шулай аңлата.

**243**. Үлемнән качып, меңнәрчә кешеләрнең үз өйләреннән атылып чыкканнарын син күрмәдеңмени? Аллаһ аларга:

—Үлегез!—диде.

*(Алар үлде)* аннан соң аларны терелтте. Хакыйкатән, Аллаһ кешеләргә миһербанлы, ләкин күпләрегез шөкранә кылмадыгыз.

*(«Хәзрәти Мөхәммәд ул дәвердә яшәмәгән булса да, Хак Тәгалә аңа: күрмәдеңме, дип мөрәҗәгать итә. Бу гарәп теленең сөйләм ысулына туры килә, ягъни үзе шаһит булмаганда да: күрдеңме, ягъни ишеттеңме, укыдыңмы, дип әйтү табигый сөйләм рәвеше»).*

Али Өзәк Тәфсиреннән.

**244**. Аллаһ юлында сугышыгыз. Аң булыгыз, Аллаһ һичшөбһәсез, ишетеп-белеп торучы.

**245**. Әҗәткә биргән кебек, Аллаһ каршында игелек кылучы *(хәер, зәкят бирүче)* кем ул? Аллаһ та аның *(дәрәҗәсен, малын)* кат-кат арттырыр. Аллаһ кемнедер кысан яшәтер, кемнәрнедер мул яшәтер. Бөтенегез дә бары тик Аллаһ хозурына китереләчәксез.

**246**. Мусадан соң килгән Исраил токымының җитәкчеләренә бакмадыңмы? Алар үзләренә җибәрелгән пәйгамбәргә:

—Безгә бер хаким күндер дә, без Аллаһ юлында сугышырбыз,—диделәр. Пәйгамбәр дә әйтте:

—Сезне сугышка язсак та, сез сугышмассыз бит,—диде. Алар әйтте:

—Нишләп сугышмыйк, ди! Безне йортларыбыздан куып чыгардылар, балаларыбыздан мәхрүм иттеләр,—диделәр.

Ләкин кяферләр белән сугышу фарыз ителгәч, аларның күбесе *(сугыштан)* баш тартты, бик азы гына сугышты. Аллаһ барысын да *(монафикъларның икейөзле гамәлләрен)* бик яхшы белеп тора.

*(«Мисыр белән Фәлистин арасында яшәүче Амалика падишасы Җалут әмерендәге гаскәр Исраил кавеменә һөҗүм итте, аларны тар-мар китерде. Исән калганнарын йортларыннан куып чыгарды. Шул вакыт Исраил кавеме пәйгамбәрдән үзләренә бер җитәкче җибәрүен үтенде».*

Али Өзәк тәфсиреннән.

**247**. Аларга Пәйгамбәр әйтте:

—Хакыйкатән, Аллаһ сезгә хаким итеп Талутны күндерде,—диде. Алар әйтте:

—Андый хаким булырга без үзебез дә аннан ким түгел. Байлыгы да, малы да булмаган кеше ничек итеп безнең өстән хакимлек итәр икән?—диделәр.

Пәйгамбәр әйтте:

—Чыннан да, Аллаһ Талутны сезгә хаким итте, ул белем өлкәсендә дә, куәте белән дә сездән өстен. Аллаһ милекне кемгә бирергә теләсә, шуңар бирә. Аллаһ-мәрхәмәт иясе, гыйлеме белән юмарттыр, барысын да белеп торучы.

*(Талут хаким үзе көтүче иде, падиша булыр өчен байлык түгел, акыл кирәк, куәт кирәк, дигән мәгънәдә.)*


آمين الله اكبر

*Дәвамы киләсе санда*

*Фән*

# ТАТАР ХАЛКЫ ОЕШУГА ЯҢА КАРАШ

Соңгы елларда татар тарихына кагылышлы эреле-ваклы басмалар шактый күп нәшер ителә. Гәрчә аларның шактые фәннилеккә дәгъва кылса да, югары гыйльми дәрәҗәдә эшләнеп, фәнгә этәреш бирерлекләре бик аз. Шул ук вакытта, искене ямап-ялгап, еллар дәвамында кат-кат чәйнәлүдән таушалып беткән тарихи чыганакларны, әдәбиятны тагын да уннан сулга, сулдан унга авыштырып кына корыштырылган «фәнни» басмаларның ишәюе күзәтелә. Табигый ки, боларыннан нинди дә булса яңа гыйльми ачыш-табышлар эзләү файдасыз шөгыльдер. Галәтенчә, карын кайгысын кайгыртып яшәгән бер чорда мирасханәләрдә «өч бакыр тиенгә» яңа тарихи чыганаклар эзләп, «энә белән кое казып» утырырга теләүчеләр әллә ни күп түгел шул. Галим-голәмәдән беришеләренең моңа вакыты, жегәре яисә, гомумән, теләге дә житенкерәмәсә, икенчеләренең төрле юллар белән ирешелгән олуг фәнни дәрәҗә-исемнәре дә чабуыннан тарта, андый «түбәнчелекккә төшәргә» ирек бирми. Нәтиҗәдә, галиҗәнап фундаменталь тарих фәне әкренләп сәяси-популяр юлга табан авышып, аның мажаралы матур әдәбият жанрыннан әллә ни ерак тормаганлыгы ачыграк күзаллана бара. Әлбәттә, шушындый шартларда матбагада дөнья күргән һәр яңа ихлас гыйльми хезмәт үзенә күрә бер вакыйга буларак кабул ителә. Бу уңайдан соңгы вакытларда дөнья күргән тарихи басмалар арасында, беренче нәүбәттә, үзенең фәннилеге, кузгалтылган гыйльми мәсьәләләрнең житдилеге, аларның куелышы һәм үзенчәлекле чишелеше белән галим, этнограф Дамир Исхаковның «Урта гасыр татарларыннан яңа дәвер татарларына» («От средневековых татар к татарам нового времени *(этнологический взгляд на историю волго-уральских татар 15-17. вв.)» - Казань: «Мастер Лайн», 1999.)* дигән яңа тарихи монографиясе аеруча игътибарны жәлеп итә.




Д. М. Исхаков ике дистә елдан артык вакыт дәвамында тарих, этнография, социология кебек үзара чиктәш фәннәр өлкәсендә житди гыйльми тикшеренүләр алып баручы галим һәм, шулай ук, сәяси-иҗтимагый эшлекле буларак та күпләргә мәгълүм шәхес. Асылда яңа басма аның төрле елларда дөнья күргән күп санлы гыйльми язмаларында теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш тапкан милләтнең урта гасырлардагы этник, сәяси-сыйнфый тормышына кагылышлы уй-фикерләренең яңа тарихи материаллар белән тулыландырылып-үстерелеп бер китапка тупланган сыгынтысы, ягъни галимнең бу өлкәдәге күпъеллык фәнни хезмәтенең үзенчәлекле бер нәтиҗәсе.

Мәгълүм булганча, татар гавамының халык, милләт буларак оешу баскычлары, анда төрле төрки кавем-дәүләтләрнең тоткан урыны әлегәчә иң четерекле вә бәхәсле гыйльми мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Бу проблема тирәсендә моназара инде озак еллар дәвам итеп, татар җәмгыятенең төрле катлауларына үтеп керде һәм шулкадәрле популярлашты ки, этник тарих буенча гыйльми эзләнү-тикшеренүләргә азмы-күпме мөнәсәбәте булган галимнәр генә түгел, хәтта моңарга кагылышлы беренчел чыганаклардан бөтенләй бихәбәр инсаннар да анда «кул уйнатып» шул рәвешле ансыз да хәттин ашкан бәхәс йомгагына бер генә карыш булса да жеп ялгап

куюны үзенә күрә бер мәртәбә саный башладылар. Галимнәрдән беришләре татар халкы оешу мәсьәләсен, нигездә, Идел буе болгарлары белән бәйләп, Болгар дәүләтенең турыдан-туры варисы итеп каралган Казан ханлыгы чикләрендә хәл итәргә омтылса, икенчеләре аны Алтын Урдада, бу олуг мәмләкәтнең таркалу нәтиҗәсе буларак күзалланган соңгырак дәвер татар дәүләтләрендә (Казан, Хаҗитархан, Касыйм ханлыкларында, Нугай Урдасында һ.б.) барган катлаулы этник процесслар яссылыгында чишәргә тырышты. Шул кимәлдә белгечләр, татар халкы оешуга «болгарчылык» яки «татарчылык» тарафдарлары булуларына карап, ике төркем хасил итүләре рәвешле, еш кына гыйлем дөньясын онытып, фани дөнья ваклыкларына, шәхси мөнәсәбәтләргә күчүче очсыз-кырыйсыз бәхәсләр дәрьясына кереп чумды. Проблеманың үтә катлаулылыгын, урта гасырлардан бирле сакланып калган чагыштырмача аз санлы, өтек мәгълүматлы, аерым очракларда бер-берсен инкарь да итүче беренчел тарихи чыганакларның аны җиңел генә, берьяклы хәл итәргә мөмкинлек бирмәгәнлеген искәрткән хәлдә, кайбер галимнәрнең, гомумән, каралган мәсьәләдә ахыр нәтиҗәләр ясаудан тыелып торуын таныргa мәҗбүрбез.

Совет Берлеге чорында милли тарихка «болгарчылык» карашы «агач атка атландырылып» рәсмиләштерелгән иде. Әмма аннан соңгы дәвердә тарих куласасы төрле фасылда әйләнеш кичерде, гыйльми мәсьәләләрдә азмы-күпме хөрлек заманы килде, шул рәвешле элгәре кагылган-сугылган шанлы Алтын Урдага рәсми мөнәсәбәттә дә берникадәр үзгәрешләр күзәтелде. Ә «болгарчылар» белән «татарчылар» арасындагы моназара исә тагын да кыза төшеп, вакыты-вакыты белән Марс кырындагы мәгълүм тарихи вакыйгаларны хәтерләтә башлады. Шул кызу бәхәсләрнең нәтиҗәсе буларак, берьяктан, Алтын Урда дәүләтенең әле башлангыч чорында ук очсыз-кырыйсыз Идел, Кубан, Дон буе далаларын тутырып исәпсез-хисапсыз «татар» кабиләләренең күченеп йөрүе «ачыкланса», икенче яктан, борынгы Идел буе болгарларының да, урта гасырлардан бирле бүгенгәчә «саф килеш» сакланып калулары, күп йөзләр дәвамында кимсетелгән хокукларын яклап аваз салулары мәгълүм булды. Бәгъзе бәндәләр, үзләренә «татар», дип эндәшүдән хурланып, кайтарып бирүне таләп итә башлады. Тарихи процессларның үсеш закончалыкларын, беренчел тарихи мәгълүматларны, ахыр чиктә, тормыш чынбарлыгын санга сукмаучы мондый тәкәббер сәяси кыйланышларның фәнни мәсьәләне гыйльми чишүгә һич тә булышлык итмәгәнлеге, аннан битәр, татар җәмгыятен эчтән таркатуга, көчсезләндерүгә китергәнлеге аңлашыладыр булса кирәк.

Гадәттә, фәндә гыйльми бәхәсләр үзләре табигый булып, еш кына аны алга этәрүгә хезмәт итәләр. Әмма каралган очракта алар бер-береңне аңлау-ишетүне күздә тотмаган очсыз-кырыйсыз буш сүз көрәштерүләргә, итәк астыннан ут уйнатуга кайтып калганлыктан, нәтиҗәдә, җәмәгатьчелек аңында да татар халкының этник тарихына нисбәтле берникадәр фикри чуалчыклыклар, каршылыклар тууга сәбәпче булдылар. Шул рәвешле, тарихи белемнәрнең алгарышына, милли тәрәккыяткә комачаулык тудыручы житди проблемаларның берсенә әверелделәр.

Д. М. Исхаковның этнология белән тарих фәннәре чигендә эшләнгән яңа монографиясенең «сөйкемле сөяге» шунда ки, ул татар халкы (аерым алганда, Идел-Урал буе татарлары) оешу мәсьәләсендә әлегәчә яшәп килгән «болгарчылык», «татарчылык» карашларына алмашка аларның синтетик кушылмасы булып карала алган үз чишелешен тәкъдим итә. Берочтан, озак еллар дәвамында «укмашып каткан» бәхәс төенен сүтү өчен дә алшартлар тудыра.

Моңарчы галим үзе дә фәнни даирәләр, җәмәгатьчелек күзаллавында милли этник тарихка радикал «татарчалык» карашы тарафдарын гәүдәләндергәнлектән, яңа монография чыгу унаеннан соңгы вакытларда аның бу өлкәдәге гыйльми күзаллаулары (көрәсең, фәнни тикшеренүләр, аралашулар нәтиҗәсендәдер) берникадәр табигый үзгәрешләр, үсеш кичергән, дип уйларга кирәк. Ниһаять, ул, нигездә, үзенең элеккедән килгән фәнни инануларына тугры калган хәлдә, татар халкы оешуда борынгы болгар компонентының ролен кимсеткән соңгы чиктәге «татарчылык» карашларының да, Алтын Урда кебек дөньякүләм әһәмияткә ия олуг төрки-татар мәмләкәтендә, аның җирлегендә оешкан соңгырак дәвер татар дәүләтләрендә барган гаять катлаулы этник процессларны санга сукмаучы «саф болгарчылык» карашларының да, үзләренең үтә берьяклы булулары сәбәпле, мәсьәләне гыйльми чишү өчен өлге була алмауларын аңлау дәрәҗәсенә ирешә. Шул ук вакытта, татар халкы оешу баскычларын җәмгыяти чорларга бүлеп өйрәнү ысулына таянып ачыкларга тырышуның да, беренче нәүбәттә ул ысулның этник берәмлекләрдә аерым җәмгыяти дәверләр дәвамында барган эчке үзгәрешләрне бәяләү мөмкинлеген

бирмәве сәбәпле, максатка яраксызлыгын искәртә. Милләтнең этник тарихына кагылышлы фәнни әдәбиятны жентекле өйрәнү аша ясалган шушы мөһим методологик нәтижәләр аңарга каралган мәсьәләдә моңарчы калыплашкан назари (теоретик) кысаларны бушата төшеп, проблемага яңа караш ташларга, аны чишү максатында үзгә юллар эзләргә мөмкинлек бирә. Ә аларны табу исә жинел түгел. Аерым алганда, этник жәмгыятьләрнең кабилә, халык, милләт буларак яшәү чорлары, аннан битәр, аларның санап кителгән сыйфатларда көнкүреш иткәндәге эчке үсеш баскычлары арасындагы тарихи чикләрне нинди алшартларга нигезләнеп уздырырга? Кызганычка каршы, тарихи этнологиядә бу методологик проблеманың әлегә ахыргача чишелеш тапканы юк. Күп белгечләр (шул исәптән китап авторы да) таныганча, моңа этник жәмгыятьләрнең бер сыйфаттан икенче сыйфатка ирешү юлында мәгълүм бер ара «күчеш хәләндә» тереклек итүләре дә сәбәпче. Дөрес, этногенез тәмамланып, халыкның, шәхсән, үз этник тарихы башлануның төп билгесе булып этник жәмгыятьләрдә ачык төсмерләнгән милли үзаңның калыплашуы хезмәт итә ала, дигән фикер ныгый бара. Ләкин, чынлыкта аң эшчәнлеге белән бәйле бу нечкә үзгәрешләрне тарихи чыганаклар нигезендә күзәтү гаять кыен. Шуның белән бергә, этник жәмгыятьләрнең төп үсеш баскычларын билгеләү өчен совет чорыннан бирле кулланылып килгән фәнни төшенчәләр жыелмасының да күп очракта бәхәслелеге, максатка ярашсызлыгы күзаллана. Әмма санап кителгән кыенлыклар асылда әле аларның бер өлеше генә. Икенче зур проблема XV-XVII гасырдан сакланып калган тарихи чыганакларның торышы белән бәйле. Кызганычка каршы, Идел-Урал буе татарларының шул чордагы этник тарихын яктырта алырлык материаллар күп түгел. Бу аеруча XVI йөз урталарына кадәрге вакытка-мөстәкыйль төрки-татар дәүләтләре дәверенә кагыла.

Бу дәвер, гомумән, милләтебезнең этник тарихында иң караңгы, аз өйрәнелгән чорларның берсе булып кала. Шул ук вакытта, ул татар халкы оешуда хәлиткеч әһәмияткә ия. Идел-Урал буйларында бу дәвердә барган катлаулы этник процессларга ачыклык кертелгән очракта, аның татар халкының соңгырак чорлардагы этник тарихын өйрәнү өчен дә ачкыч була алачагы ачык төсмерләнә. Моны автор яхшы аңлый. Теманы эшләү өчен бик үк уңайлы булмаган шартларда ул, бер яктан, тарихи этнология өлкәсендәге соңгы назари казанышларга таянып, анда үз өлешен дә кертергә омтылса, икенче яктан, гыйльми хезмәтенең тарихи нигезен XV-XVII йөзләргә караган язу-теркәү кенәгәләре (писцовые, переписные книги) кебек, этник тарих буенча үзләрендә шактый мәгълүмат туплаган, ләкин кайбер сәбәпләр аркасында гыйльми әйләнешкә аз кертелгән яңа төр чыганакларны киңрәк куллану, этнография, тел белеме материалларын да файдалану исәбенә тагын да төрлеләндерергә, баетырга-ныгытырга тырыша. Авторның монографияне язганда Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Киров, Пермь, Пенза, Оренбург шәһәрләрендәге 11 мирасханәнең 27 фондында тупланган гаять күп тарихи чыганак, төрле илләрдә, төрле елларда урыс, инглиз, татар телләрендә, башка төрки телләрдә дөнья күргән 515 исемдәге фәнни әдәбият белән эш итүе үзе үк аның бу юнәлештә никадәр ижтиһад иткәнлеге турында ачык сөйли булса кирәк.

Этник процессларның сәяси, сыйнфый-икътисади күренешләрдән алып этномәдәни, этнопсихологик сәбәпләргә, географик жирлеккә, яшәү рәвешенә кадәрле гаять күп төрле алшартларга бәйлелеге закончалыгын нык үзләштергән хәлдә, автор монографиясендә күтәрелгән төп мәсьәләне дә төрле тарихи күренешләрнең үзара йогынтысы яссылыгында, комплекслы рәвештә тикшерергә омтыла. Шул уңайдан, фәнни хезмәттә XV-XVII йөзләрдәге Идел буе татар жәмгыятьләрендә сыйнфый бүленеш һәм аның этник процессларга йогынтысы, Алтын Урда дәвереннән соңгы татар ханлыкларындагы сәяси-административ төзелешнең урта гасырларга хас нәсел-ыру жирлегендә бүленешкә мөнәсәбәте, Нугай Урдасының Казан, Касыйм ханлыклары белән үзара мөгамәләләре һәм Идел-Урал буе татарлары калыплашуда нугай компонентының роле, Урал буе татарлары оешуда төрки-угор жирлектәге «иштәк» этник мирасының әһәмияте, XV-XVI йөзләрдәге татар жәмгыятьләренең XVII гасыр Идел-Урал буе татарларыннан аермалыгы кебек, бихисап күп, берсеннән-берсе катлаулы, аз өйрәнелгән, бәхәсле мәсьәләләр күтәрелә һәм алар теге яки бу рәвешле чишелеш тә таба.

Шунысы әһәмиятле, галим үзенең гыйльми эзләнүләрендә, еш кына очракларда күзәтелгәнчә, этник тарих темасына буш сүз куертулар юлы белән түгел, ә бәлки беренчел чыганакларда, фәнни әдәбиятта тупланган тарихи мәгълүматларны вәземле барлау-тикшерү, үзара чагыштыру аша нәтижәләр ясау юлы белән, ягъни

тарихи анализ-синтез, чагыштыруларга корылган ихлас фәнни ысул белән барырга омтыла. Нәтиҗәдә, байтак гыйльми табышларга юлыга. Шул ук вакытта, монографиядә урын алган кайбер нәтиҗәләрнең, фәнни дәлилләү житенкерәмәү сәбәпле, әлегә бары тик гыйльми фараз буларак кына бәяләнә алганлыгы да аңлашыла. Мәсәлән, бу авторның Казан ханлыгындагы сәяси-административ даругаларны (өлкәләрне) дәүләттәге аерым идарәче нәсел-нәсабәләргә (кланнарга) мөнәсәбәтле биләкләр (кенәзлекләр) итеп күрсәтү омтылышына кагыла.

Кайбер белгечләр фикеренчә, Кырым ханлыгы үзенең башлангыч чорында нәсел-ыруг җирлегендә бүленешкә нигезләнгән дүрт биләктән гыйбарәт булган. Алар башында Ширин, Аргын, Барын, Кыпчак ырулары башлыклары торган. Соңрак бу биләкләргә көчле Мангыт (яисә Мансур) биләге дә өстәлгән. Санап кителгән идарәче нәсел-ырулар вәкилләре ханлыкта карачы биләр (карачылар) системасы, дип йөртелгән дәүләт идарәсе тәртибенең нигез ташын тәшкил иткәннәр. Карачылар (һәр идарәче нәсел-ырудан берәр карачы) ханның «уң кулы», иң якын киңәшчеләре, дәүләттә аннан кала иң йогынтылы, дәрәҗәле кешеләр булып, илнең эчке, тышкы сәясәтендә гаять мөһим роль уйнаганнар. Алардан олуг карачы, дип аталганы (ул бәкләр бәге, ягъни кенәзләр кенәзе дип тә йөртелгән) аеруча зур йогынты, дәрәҗә белән файдаланган. Кагыйдә буларак, болары дәүләтнең башлангыч чорында Ширин, соңрак Мангыт ырулары вәкилләреннән булган.

Үз заманында В.В.Вельяминов-Зернов, М.Г.Худяков кебек галимнәр язып калдырганча, Алтын Урда чорыннан мирас булып калган бу идарә системасы Казан ханлыгына да хас булган. Дәүләттә Шириннар өстенлек иткән дүрт идарәче нәсел-ыру (клан) булуы турында әйтелә. Ләкин аталган тарихчылар аларны ханлыктагы сәяси-административ бүленеш белән бәйләп карамыйлар, һәм табигый ки, андый бәйлелекне күрмиләр дә. Шул рәвешле, китерелгән тарихи хәбәрләрнең әле үзеннән-үзе Казан ханлыгындагы сәяси-административ даругаларны (өлкәләрне) андагы идарәче нәсел-ыруларга мөнәсәбәтле биләкләр итеп тану өчен җитәрлек җирлек бирмәгәнлеге аңлашыла. Бу проблемага ачыклык кертү исә турыдан-туры башка берничә мөстәкыйль, аз өйрәнелгән, катлаулы тарихи мәсьәләне чишү белән бәйле. Беренчедән, китап авторы Казан ханлыгында югарыда атап кителгән идарәче нәсел-ырулардан барысының да фани дөньяда булуын күздә тотса да, проблема өстәмә ачыклауны, фәнни дәлилләүне сорый. Шулай ук, бу дәүләттәге даругалар да махсус гыйльми тикшерүне таләп итә.

Монарчы Казан ханлыгында биш сәяси-административ даруга (өлкә) - Арча, Алат, Гәреч, Җөри, Нугай даругалары булган, дип исәпләнелә иде. Галимнәрдән берсенең «җиңел кулы» белән фәнни әдәбиятка «кереп киткән» бу фикер, гадәтенчә, китаптан-китапка күчә килде. Ләкин, XV-XVI йөзләргә караган тарихи чыганакларны өйрәнү мәсьәләнең алай ук гади булмаганлыгын күрсәтә. Мәсәлән, атап кителгәннәрдән тыш, аларда Чуаш («Чувашская дорога», чыганакларда «чуваш» төшенчәсе «чюваш»рәвешендә бирелә), Югары Чуаш («Верхняя Чувашская дорога»), Урта Чуаш («Средняя Чувашская дорога»), Үкрәч («Окречская дорога»), Яке («Якийская дорога»), Аты («Атызская дорога») даругалары да искә алына (сүз уңаеннан, китап авторы Казан өязенең 1565-1568 еллардагы язу кенәгәсенә нигезләнеп искә алган «Алгы Чуаш» даругасы - «Передняя Чувашская дорога» - безгә мәгълүм түгел, күрсәтелгән кенәгәдә дә күзәтелми). Тарихи чыганакларның эчтәлеге санап кителгән төшенчәләрнең аларда гади «юл» мәгънәсендә генә кулланылмыйча, аерым сәяси-административ берәмлекләрне аңлатканлыкларына шик калдырмый. Болардан тыш, ханлыкта Түбән Чуаш даругасының да булуы аңлашыла. Бу даругаларның Урыс дәүләте чорында сакланмаулары (урыс хөкүмәте оештырган Казан өязендә Арча, Алат, Гәреч, Җөри, Нугай даругалары гына була) аларның Казан ханлыгы дәверенә караганлыклары турында сөйли. Шуның белән бергә, Җөри даругасы тарихи чыганакларда беренче тапкыр 1570-1574 елларда гына искә алына. Ханлык чорындагы Чуаш даругасының (Югары, Урта, Түбән Чуаш даругаларының) да, соңгырак дәвердәге Җөри даругасының да Казаннан көнчыгышка таба җирләрне биләгәнлекләрен исәпкә алып, бер үк даруганың төрле заманда, сәяси шартларда төрлечә аталуы турында фикер йөртергә мөмкин. «Даругалар» белән бәйле проблемаларны яхшы аңлаган хәлдә, автор үзе ханлык чорындагы Чуаш, Яке даругаларын Урыс дәүләте дәверендәге Җөри, Гәреч даругаларына тиңли. Шул рәвешле, Казан ханлыгындагы урын алган биш идарәче нәсел-ыруга шул кадәрле үк даруга туры килүгә корылган арифметик мантыйкка ирешергә омтыла. Чөнки, шуның соңында, ханлыктагы биш идарәче нәсел-ыруны аларга мөнәсәбәтле биләкләр

(кенәзлекләр) буларак күзалланган «даругаларга» аерым-аерым «беркетеп» чыгасы гына кала. Ләкин, чынлыкта, ханлыкта даругалар саны биштән күбрәк булган булса кирәк. Әйтик, автор үзе үк ханлык чорында, Яке даругасы белән берләштән, Гәреч даругасының да булуын танып, асылда үз-үзенә каршы килә. Үкрәч даругасының тагын да шул ук Урыс дәүләте чорындагы Җөри даругасы булуы мөмкинлеген фаразлау белән генә чикләнә (югыйсә, Үкрәч даругасына исем биргән Лаеш юнәлешендәге ханлык чоры кальгасы соңрак Нугай даругасына караган). Ә инде кечкенә Аты даругасы (Казан өязенең 1565-1568 еллардагы язу кенәгәсендә искә алынган бу даруга үз исемен Арча ягындагы Аты авылыннан алган), күрәсең, галимгә мәгълүм түгел. Моннан тыш, тарихи чыганаклар югарыда искә алынган Югары, Урта, Түбән Чуаш даругаларының да Чуаш даругасының аерым өлешләре генә булмыйча, аерым сәяси-административ берәмлекләр булганлыгына ишарәле булса кирәк. Шул рәвешле, Казан ханлыгы чоры «даругалары» белән бәйле шактый зур проблемалар йомгагы хасил була. Бу унайдан, «ханлыктагы биш идарәче нәсел-ыруга биш даруга» арифметик мантыйгы да мәгълүм дәрәҗәдә шик-шөбһә уята.

Язма тарихи чыганакларны өйрәнүче галим М.Ә.Усманов фикеренчә, татар ханлыклары чорындагы даругалар алар, гомумән, җирле идарәчеләр. Ул, шулай ук, «даруга» төшенчәсенең чыганакларда «даруга бәге» («даруга-бек») гыйбарәсе белән үзара бәйлелектә кулланылуына да игътибар итә. Шуңа нисбәтле, соңгы төшенчә «даруга белән идарә кылучы бәк (кенәз)» мәгънәсендә аңлашыла. Даруга бәкләренең турыдан-туры карачыларга-билекләр башлыкларына буйсынуы турындагы фаразны кабул иткәндә, «ханлыкта ханның идарәи хокуклары, гомумән, нидән генә гыйбарәт булды икән соң?» - дигән урынлы сорау туа. Бу очракта ул дәүләтнең эчке сәясәтенә (димәк, тышкы сәясәтенә дә) житди йогынтысы булмаган «курчак» идарәче булып күзаллана. Ә тарихи чыганаклар исә ханның илдә, гәрчә карачылар, дәүләт диваны (киңәше) тарафыннан берникадәр чикләнгән булса да, хакимият белән файдаланганлыгы, эчке, тышкы сәясәттә хәлиткеч әһәмияткә ия булганлыгы турында сөйлиләр. Бу унайдан, «даруга бәкләренең» тагын да шул хан боерыгы белән аерым даругаларга (өлкәләргә) административ күзәтүче, идарәче итеп билгеләнгән дәүләт хезмәтендәге аксөякләр булуы ихтимал. Моннан тыш, ул чорда ханлыктагы күп җирләрнең (бигрәк тә Казан шәһәре тирәсендәгеләрнең) хан биләмәләре (ягъни, дәүләт җирләре) булып исәпләнүе мәгълүм. Чыганаклардан күренгәнчә (һәрхәлдә, XVI йөзнең икенче яртысына - XVII йөз башына караган чыганаклар шуңа ишарәли), ул биләмәләр, Казаннан кайсы юнәлештә булуларына карап, төрле сәяси-административ даругаларга караганнар. Ә инде аерым даругаларны тәшкил иткән җирләрнең урта гасырлар дәвере феодаль биләмәләренә һич тә хас булмаган дөрес геометрик җисем — бер очы ханлык башкаласы Казанга орынып торган өчпочмак рәвешендә күзаллануы бу сәяси-административ берәмлекләрнең «өстән билгеләнгәнлеге», ясалмалылыгы турында сөйли. Шуларны искәрткән хәлдә, аларның ханлыктагы аерым идарәче нәсел-ыруларга, карачыларга бәйле билекләр булуы мөмкинлеге берникадәр шик тудыра. Шул унайдан авторның Кырым ханлыгын үрнәк итеп алуына бәйле сораулар да туа. Әйтик, Кырым ханлыгыннан аермалы буларак, Казан ханлыгында борынгы болгар мирасы зур урын алып торганлыктан, беренчесе икенчесендәге сәяси-административ төзелеш мәсьәләләрен өйрәнү өчен бернинди искәртмәләрсез генә өлге итеп кабул ителә аламы? Гомумән, Кырым ханлыгында сәяси-административ «даругалар» булганмы? Булган хәлдә, ханлыктагы билекләр (кенәзлекләр) белән даругалар арасындагы үзара тәңгәллек анда ни рәвешле чагылыш таба? Проблемага кагылышлы бу сораулар әлегә җавапсыз кала.

Шулай да, автор Казан ханлыгындагы Нугай даругасын Мангыт, Арча даругасын Кыпчак, Гәреч даругасын Аргын, Алат даругасын Барын, ә Җөри даругасын Ширин идарәче нәсел-ыруларына (кланнарына) бәйле билекләр (кенәзлекләр) итеп күрсәтү өчен күп көч сарыф итә. Әмма бу юнәлештәге тырышлыклар, нигездә, теге яки бу идарәче нәсел-ыру вәкилләренең, яисә аларга нисбәтле борынгы төрки-татар кавемнәренең (кыпчакларның, нугайларның, мангытларның һ.б.) Казан ханлыгында, дәүләттәге аерым сәяси-административ даругаларда булу-булмавын, яшәү-яшәмәвен ачыклау омтылышы белән чикләнгәнлектән, әлеге кителгән нәтиҗәне бирмиләр.

Аерым алганда, автор урыс елъязмаларындагы мәгълүматларга таянып, ханлыкта «Мангыт йортының» (ягъни, Мангытлар феодаль биләмәсенең, билегенең) булуын фаразлый һәм асылда бары тик мангытларның, башка нугай кабиләләрнең ул чорда Нугай даругасында тереклек итү мисалларына нигезләнеп кенә беренчесен икенчесенә тиңли. Казан ханлыгында «Мангыт йортының» булуы мөмкинлеген

таныган очракта да, өтек тарихи мәгълүматларның аның биләмәләрен географик күзлектән якынча гына булса да шәрехләргә ирек бирмәвен, феодаль биләмәгә һәм сәяси-административ берәмлеккә исемнәр биргән «мангыт», «нугай» төшенчәләренең тәңгәл килмәвен (мангытлар ике дистәгә якын нугай кабиләсенең берсе генә), нугайларның исә ханлык чорында, Нугай даругасыннан тыш, башка даругаларда да (мәсәлән, Алат, Чуваш-Җөри даругаларында) яшәвен һәм, ниһаять, «Мангытлар жиренең» «даругалардан» бәйсез берәмлек булуы ихтималын да күздә тотсак, бу нәтиҗәнең ни дәрәҗәдә шартлы икәнлеге аңлашыла булыр.

Галим, аерым тарихи күзәтүләргә таянып, Зәй, Чишмә, Минзәлә, Ык, Түбән Агыйдел буендагы жирләрнең дә ханлык дәверендә Нугай даругасына (димәк ки, «Мангыт йортына») кергән булуы мөмкинлеген фаразлый. Ләкин, язма чыганаклар Нугай даругасының XVII йөздә - XVIII йөз башында Казаннан көньяк юнәлештәге жирләрне үз эченә алып, Чулман аръягында көнчыгыштан Чишмә елгасы белән чикләнгәнлеге (шартлы рәвештә) турында сөйлиләр. Бу елгадан көнчыгыштарак жирләр Җөри даругасына нисбәтләнә. Үз чиратында, соңгысы көнчыгыштан Уфа өязе белән чикләнгән. Шуларны искәрткәннән соңында, атап кителгән елгалар буендагы жирләрнең ханлык дәверендә Нугай даругасына (димәк ки, «Мангыт йортына») караганлыгы зур шик-шөбһә уята.

Автор, аерым татар аксөякләренең нәсел шәҗәрәләренә, башка тарихи хәбәрләргә таянып, Нугай даругасын «Мангыт йорты», язма чыганакларда күп тапкырлар искә алынган «Арча кенәзләрен» («Арские князья») Кыпчаклар, ә Гәреч даругасына нисбәтләнгән легендар Чура батыр (Нәрек углы Чура, «Чура Нарыков») нәселен Аргыннар белән бәйләү-тинләү аша Нугай, Арча, Гәреч сәяси-административ даругаларының Мангыт, Кыпчак, Аргын билеклекләре булганлыкларын әле күпмедер дәрәҗәдә нигезләргә омтылса, дәлилләр булмау сәбәпле, Алат даругасын Барыннарга, Җөри (Чуаш) даругасын Шириннарга калдыклык мантыйгы буенча гына, ягъни «калган идарәче нәсел-ыруларга - калган даругалар» мантыйгына нигезләнеп кенә беркетә. Шул рәвешле, үзе үк мәсьәләнең әлегә ахыргача чишелеш тапмаганлыгын таный.

Димәк ки, урта гасырлар дәүләтләрендә кабилә, нәсел-ыру мөнәсәбәтләренең зур әһәмияткә ия булганлыгын искәрткән хәлдә дә, Казан ханлыгындагы сәяси-административ даругаларның (өлкәләрнең) дәүләттәге аерым идарәче нәсел-ыруларга бәйле билекләр булуы мөмкинлеге турындагы фикернең әлегә бары тик гыйльми фараз буларак кына бәяләнә алганлыгы төсмерләнә. Проблемага ачыклык кертү исә күп дәрәҗәдә югарыда китерелгән сорауларга җавап табу, шик-шөбһәләрне тарату белән бәйле.

Табигый ки, монографиядә күтәрелгән мәсьәләләр фәнни әдәбиятта эшләнеш дәрәҗәләренә, тарихи чыганаклардагы мәгълүматларның тулылыгына карап, төрле микъдарда чишелеш табалар.

Казан ханлыгында, XVII йөз уртасына кадәр Урта Идел буенда татарлар арасындагы сыйнфый бүленешнең халык оешуга нисбәтле этник процессларга бәйлелегенә багышланган бүлек тә аерым игътибарга лаек. Мәсәлән, автор монда, Казан ханлыгындагы аксөякләр катлавын барлап-тикшереп чыкканың соңында, нәсел-ырудашлык нигезендә оешкан татарлар бу дәүләттә хакимлек итүче феодаллар даирәсенең нигезен тәшкил иткәннәр, дигән нәтиҗәгә килә. Хәер, Алтын Урда таркалганнан соң, аннан чыккан аксөяк татарларның Казан ханлыгында идарәче феодаллар катламының төп өлешен тәшкил иткәнлеге турындагы фикерне үз заманында кайбер XIX йөз урыс тарихчылары да язып калдырган иде. Ләкин, галим ул феодалларның нәсел-ырудашлык нигезендә оешканлыкларына игътибар итеп, фикерне тагын да конкретлаштыра, тулыландыра төшә. Хәлбуки, нәтиҗәне алга таба яңа дәлилләр белән ныгытырга кирәк булачагы аңлашыла. Чөнки, Кырым ханлыгыннан аермалы буларак, Казан ханлыгында кабилә аерымлыкларының, нәсел-ырудашлыкка нигезләнгән мөнәсәбәтләрнең, утрак тормышка нигезләнгән борынгы болгар этник, рухи-мәдәни мирасы йогынтысында, мәгълүм дәрәҗәдә «йомшарган», юкка чыккан булуы да ихтимал. Бу бигрәк тә ханлыкның соңгы дәверенә кагыла. Тарихи үсеш законлылыгы шуны искәртә ки, моңа күп дәрәҗәдә утрак тормыш, хуҗалык итү рәвеше дә сәбәпче була.

Казан ханлыгында феодаллар катламының мөселман руханилары, бәкләр, морзалар, огланнар (уланнар), казаклар кебек сыйнфый төркемнәрдән торганлыгы бәхәссез. Шул ук вакытта, авторның урыс елъязмаларындагы «эчкеләр» («ички») төшенчәсенә дә мөстәкыйль сыйнфый эчтәлек биреп, аларны дәүләттәге идарәче

даирәләргә - бәкләр, морзалар төркемнәренә нисбәтләве белән килешүе кыен. Беренчедән, «эчке» сүзе, гомумән, исемне, җисемне белдермичә, аның асыл сыйфатын гына билгели (мәсәлән, «эчке дөнья», «эчке базар», «эчке сәясәт» һ.б.) «Эчке» сыйфатына күплек кушымчасы кушылып ясалган «эчкеләр» төшенчәсе исә, кагыйдә буларак, шул «эчке» сыйфатына ия исем-җисемнәрнең җыелмасын (тупланмасын) аңлата.

Димәк ки, мәсьәләгә кагылышлы тарихи чыганакларда урын алган «эчкеләр» («ички») гыйбарәсе, Казан, Кырым ханлыкларындагы феодалларның төрле катлауларындагы хезмәт итү урынына, рәвешенә нисбәтле, эчке бүленешне аңлатучы сыйфат төшенчәләренең берсе буларак кузаллана. Мәсәлән, елъязмадагы «ички, дворные и задворные казаки» гыйбарәсендә искә алынган эчке казакларның сарай хезмәте белән бәйле (биредә хан сарае күздә тотыла) хәрбиләр булганлыгы әллә ни шик тудырмый. «Сарай казакларын» («дворные казаки») шулай ук хан сарае, яки ханның шәхси карамагындагы гаскәриләр мәгънәсендә аңларга була. Боларның тыныч вакыттагы хезмәте, күрәсең, хан сарае, шәһәр кирмәне белән чикләнмичә, «хан йорты», ягъни хан биләмәләре (сарай, дәүләт карамагындагы җирләр) белән бәйле булган. «Сарай казакларының», «эчке казаклар» белән берлектә, хан гвардиясенең (ягъни, турыдан-туры хан сарае, дәүләт идарәсе карамагындагы гвардиянең) нигез ташын тәшкил иткән булуы ихтимал. «Задворные казаки» гыйбарәсе белән шәрехләнгән казаклар исә ханлыктагы аерым феодаль биләмәләр белән бәйле дәрәҗәле аксөякләр-бәкләр, морзалар кул астындагы гаскәриләр булган булса кирәк. Кирәк чакта, алар хан боерыгы буенча, үз бәкләре, морзалары җитәкчелегендә хан гаскәренә килеп кушылганнар. Шулай ук аксөякләр тарафыннан үзара эчке ызгыш-талашларда да файдаланылганнар. Әлбәттә, татар ханлыкларындагы казаклар хәрби катламы махсус өйрәнүне сорый. Әмма тарихчы В. Е. Сыроечковский «киң мәгънәдәге «эчке» - хезмәтче төшенчәсе иң югары дәрәҗәдәге сарай хезмәтчеләреннән алып иң түбән дәрәҗәдәгеләренә кадәр - барысын да иңләгән», дип язуы һәм «эчкерләрнең» гади «хәрби хезмәткәр» («военный слуга») да, кенәз дә булырга мөмкинлекләрен искәртүе белән, мөгаен, күп дәрәҗәдә хаклы. Тарихи чыганакларда урын алган «эчке казаклар» («ички казаки»), «эчке кенәзләр» («ички князи») гыйбарәләре шуларны раслый гына төшә шикелле. Шул ук вакытта, «эчкеләрнең» феодаллар сыйныфына нисбәтле төшенчә булганлыгы да шик тудырмый.

Аерым очракларда «эчкеләр» төшенчәсе урыс елъязмаларында мөстәкыйль яңгыраш та ала сыман. Мәсәлән, аларда «а се салтаны и сеиты, шихзоды, моллы, уланы, князи, мурзы; а ичкам имена ведомо учинили», яки «... от сеита и от уланов и от князей и от карачей и от ичек и от мурз и от молн и от шихозд и от всех казанских людей» кебек юлларны да укырга була. Ләкин, китерелгән мисалларда «эчкеләр» сүзенең шулай ук җыелма мәгънәгә ия булып, феодалларның төрле катлау вәкилләреннән торган сарай әһелләрен күздә тотуы ихтимал. Бу уңайдан, урыс елъязмаларына, риваятьләр жанрына якын торучы хикәяти чыганаклар буларак, гомумән, терминнар белән ирекле эш йөртү, сыйнфый төшенчәләр белән этник терминнарны бутау кебек кимчелекләрнең хас булуын искәртеп үтү дә зарур. Шул сәбәпле, татар ханлыкларында яшәгән халыкларны, кавемнәрне ачыклау максатыннан, алардан һәр очракта тулы мәгълүмат эзләү дә мәгълүм дәрәҗәдә файдасыз шөгыльдер.

Китапның Казан ханлыгындагы «түбәнге» сыйнфый катламнарга, XVI-XVII йөзләрдәге Казан, Зөя өязләре «ясаклы чуашлар»ы мәсьәләсенә багышланган өлеше иң уңышлы, тулы эшләнгәннәрдән берсе буларак бәяләнә ала.

XVI гасырның икенче яртысына-XVII гасырга караган язу-теркәү кенәгәләрендә, башка тарихи документларда теркәлгән бу «ясаклы чуашлар» тарихчы галимнәрнең инде берничә буын вәкилләренә тынгылык бирми. Эш шунда ки, XVII йөзнең икенче яртысыннан башлап алар барысы да диярлек тарихи чыганакларда «ясаклы татарлар», дип атала башлыйлар. Искә алынган «чуашлар» Казан ханлыгының үзәк җирләрендә, татар халкы оешуда гаять зур әһәмияткә ия булган, аның «Мәккәсе» булып исәпләнгән Казан артында, Тау ягында җирле халыкның чагыштыргысыз күпчелеген тәшкил иткәннәр. Ханлыкның башкаладан көнчыгышка таба җирләрен үз эченә алып торган сәяси-административ өлкә («даруга») дә «чуаш» атамасын йөрткән.

Галимнәрнең беришләре атап кителгән «ясаклы чуашларны» этник чуашлар, икенчеләре борынгы удмуртлар белән бәйләргә тырышса, өченчеләре «ясаклы чуаш»

гыйбарәсендәге «чуаш» төшенчәсенә бары тик сыйнфый мәгънә биреп, аларны шул ук ясаклы татарлар, дип санады. Дүртенчеләре, теге яки бу рәвешле, бу «чуашларны» Идел буе болгарлары этник мирасына нисбәтләде. Еллар дәвамында мәсьәләгә төрле карашлар калыплашу сәбәпле, проблема озакка сузылган фәнни моназара җисеменә әйләнде.

Үзеннән-үзе аңлашыла ки, Казан, Зөя өязләре «ясаклы чуашлары» мәсьәләсенә ачыклык кертми торып, XVI-XVII йөзләрдә Урта Идел буенда барган катлаулы этник процессларны бөтен тулылыгы белән күзаллау мөмкин түгел.

Китап авторы проблеманы инде күптәннән бирле күз уңында тота, гыйльми мәкаләләре аша аны өйрәнүгә үз өлешен кертә. Мәсьәләгә кагылышлы фәнни әдәбиятны, XVI-XVII йөзләрдә «ясаклы чуаш» төшенчәсенең таралу географиясен яңабаштан җентекләп күздән кичергәннең соңында, ул проблеманың әле һаман да кәнәгатьләндерерлек дәрәҗәдә чишелеш тапмаганлыгын искәртә һәм бу өлкәдә ирешелгән гыйльми казанышларга, үзендә тупланган тарихи мәгълүматларга таянып, аны ахыргача ачыкларга алына. Нәтиҗәдә, максатына ирешә диярлек. Тарихи чыганаклар шуны ачык тасвирлый: 1) Искә алынган Казан, Зөя өязләре «чуашлары» Казан артында, Тау ягында ханлык чорында да яшәгәннәр. XVI йөзнең икенче яртысы һәм XVII йөз тарихи чыганакларында шуларга бәйле урын алган «ясаклы чуашлар» («ясачные чюваша») гыйбарәсе дә ханлык дәвереннән килгән традицияләрнең бер чагылышы булып тора; 2) Бу «чуашлар» XVI йөздә үк әһле ислам динен тотып, вафат булган кешеләрен дә «татарлар» белән бер үк мөселман зиратларында җирләгәннәр, соңгылары белән бер үк авылларда яшәгәннәр, алар белән бернинди арадашчысыз (тәрҗемәчесез), турыдан-туры аралашканнар (димәк ки, «татарлар» белән бер үк телдә, яисә, һичьюгы, аларга бик якын, аңлаешлы шивәдә сөйләшкәннәр). Мәгълүм булганча, хәзерге чуаш теле татарларга чуашлар белән арадашчысыз, турыдан-туры аралаша алу мөмкинлеген тәэмин итми; 3) Бәгъзе «чуашлар», теге яки бу дәрәҗәдә, Идел буе болгарлары этник мирасы белән бәйле; 4) XVII йөз уртасына кадәр (һәрхәлдә, XVI йөзнең икенче-XVII йөзнең беренче яртыларында) «ясаклы чуаш» гыйбарәсендәге «ясаклы» һәм «чуаш» төшенчәләре тарихи чыганакларда үзара бәйлелектә кулланылып, мәгълүм дәрәҗәдә аваздаш, сыйнфый мәгънәдәш сүзләр булганнар. Ягъни, «чуаш» төшенчәсе шул ук «ясаклы кеше»не аңлаткан. Шуның белән бергә, каралган «чуашларның» феодаллардан бәйле «крепостной» кешеләр («чюваша-дворовые люди») булуы очраклары да билгеле. Тулаем алганда, алар «түбәнге»сыйнфый катлам вәкилләреннән, «кара халыктан» гына торган.

Тарихи хәбәрләрне күзәтүгә нигезләнгән шушы беренчел нәтиҗәләр үк инде XVI-XVII йөзләрдәге Казан, Зөя өязләре «чуашларының» борынгы удмуртларга әллә ни катнашы булмаганлыгы турында искәртәләр. Асылда бу фараз бары тик гыйльми хыял офыкларының чиксезлеген раслаучы бер мисал буларак кына карала ала.

Югарыда шәрехләнгән нәтиҗәләр искә алынган «чуашларны» турыдан-туры этник чуашлар белән бәйләргә дә мөмкинлек бирмиләр. Югыйсә, Казан ханлыгы халкының төп өлеше чуаш халкы вәкилләреннән торган, дип фикер йөртергә туры килер иде.

Мәгълүм булганча, хәзерге чуашлар Идел буе болгарлары белән борынгы фин-угор кавемнәре (бигрәк тә борынгы марилар) кушылуы нәтиҗәсендә оешкан халык. Алар беркайчан да ислам динен тотмаганнар. Шуның белән бергә, атамалардагы тәңгәллекнең борынгы Идел буе болгарларына нисбәтле уртак мираска бәйлелеге дә аңлашыла. Күрәсең, моның сере Идел буе Болгар дәүләте оешу чорына ук барып тоташа. VII-IX йөзләрдә Дон, Кубан буе далаларыннан Урта Идел буена күчерелгән төрки болгарлардан Иделнең уңъяк ярында, җирле фин-угор кавемнәре арасында төпләнгән бер өлеше, соңгылары белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштырып, ни рәвешледер, IX йөздә Идел буе Болгар дәүләте оешу, соңрак бу дәүләттә ислам дине кабул итү белән бәйле процесслардан берникадәр читтә торып калган булса кирәк. Шул сәбәпле, болгарларның Урта Идел буендагы ике төркеме үзләренең алга таба этник, рухи-мәдәни үсешләрендә ике юнәлеш алалар. Табигый ки, бу үсешнең нәтиҗәсе дә төрлечә. Идел буе болгарларының дәүләт төзүгә, ислам дине кабул итүгә нисбәтле, нигездә Иделнең сулъяк ярында, өлешчә уңъяк ярында да яшәгән зур күпчелеге, төрле мәгълүм тарихи сәбәпләр аркасында, Алтын Урда, Казан ханлыгы дәверләрендә Азов (Азак), Дон, Кубан, Түбән Идел буе далаларыннан Урта Идел буена үтеп кергән кыпчак телле кардәш төрки кавемнәр (кыпчаклар, нугайлар һ.б.) белән тыгыз бәйләнешләр нәтиҗәсендә XIV-XV йөзләрдә тел ягыннан кыпчаклашу («татарлашу») чорын кичерә. Хәзерге чуашларның көчле фин-угор йогынтысы

астында яшәгән, тора-бара аерым билгеләре буенча (тормыш-көнкүреш, гореф-гадәтләр һ.б.) соңгыларына хас сыйфатларга да ия була барган, асылда мәҗүси бабалары исә янә моннан читтә торып кала. Шул рәвешле, болгар чыгышлы ике этник төркемнең беренчесе татар халкы оешу, икенчесе чуаш каваме калыплашу белән бәйле катлаулы процесслар казанында «кайный». Нәтиҗәдә, алар яңа дәвергә дә татар, чуаш халыклары сыйфатларында «аяк басалар».

Табигый ки, этник процесслар гасырлар буена сузылып, бер этник халәттән икенче этник халәткә күчү юлында мәгълүм бер ара «күчеш чорын» да кичерәләр. Бу уңайдан, күрәсең, Казан ханлыгы дәверендә болгар чыгышлы ике этник төркемдә дә әле аларны башка якын, кардәш төрки ыру-кавемнәрдән аерып торучы, шул ук вакытта үзара берләштерүче гомуми, мөстәкыйль «болгар» этник үзаңы берникадәр дәрәҗәдә сакланган булса кирәк. Дөрес, XV йөздә-XVI йөз башында бу үзаң күп дәрәҗәдә этник чыгышка нисбәтле тарихи хәтергә, игенчелеккә корылган яшәү рәвешендәге уртаклыкка гына корылган булса кирәк (хәер, XV йөз уртасына кадәр болгар чыгышлы этник төркемнәр арасында мәгълүм дәрәҗәдә тел уртаклыгы да сакланган булуы ихтимал). Чөнки, каралган чорда болгар этник мирасына ия ике төркем арасындагы аерымлыклар, беренчесенең ислам диненә нигезләнгән рухи-мәдәни тормыш белән яшәве, кыпчаклашуы («татарлашуы»), ә икенчесенең исә асылда мәҗүси булып калуы, фин-угор халкына хас сыйфатларга ирешүе сәбәпле, шактый зур булган булырга тиеш.

Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында Идел буе болгарлары, аларның турыдан-туры варислары асылда аксөякләрдән (феодаллар сыйныфыннан), хәрбиләрдән торган кыпчак («татар») телле кардәш төрки кавемнәргә карата буйсыну хәлендә булып, нигездә жирле халыкның «түбәнге» сыйнфый катламнары вәкилләреннән-игенчеләрдән торганлыктан, «чуаш» төшенчәсенең ханлык дәверендә сыйнфый төсмер дә алуы табигый. Чөнки төшенчәнең этник һәм сыйнфый эчтәлекләре нигездә тәңгәл килгән диярлек. Үз чиратында, болгар этник мирасына ия ике төркем арасындагы сыйнфый уртаклык аларны бер исем астында берләштерергә мөмкинлек биргән алшартларның берсе булган булса кирәк. Димәк ки, XVI-XVII йөзләр тарихи чыганакларындагы «чуаш» төшенчәсе, беръяктан, этноним булып, болгар этник мирасына ия халыкны аңлаткан, икенче яктан, «кара халык», «түбәнге сыйнфый катлам вәкиле» мәгънәсендәге сыйнфый эчтәлеккә дә ия булган. Шунлыктан, ул сыйнфый - этник термин буларак бәяләнә ала.

«Чуаш» төшенчәсенең гарәп илчесе Ибн Фадланның 922 елга караган сәяхәтнамәсендә искә алынган «суаз» дигән болгар кабиләсенә бәйле атамадан килеп чыккан булуы ихтимал. Дөрес, «чуаш» этнонимы урыс тарихи чыганакларында XVI йөзнең беренче чирегеннән башлап кына чагылыш таба башлый. Ләкин, бу әле аның берәр болгар кабиләсе исеме яки болгарларның икенче бер синонимик атамасы рәвешендә аңарчы да кулланылмаганлыгын аңлатмый (мәсәлән, шундый исем белән болгарларны күрше фин-угор халыклары атап йөрткән булуы бик ихтимал һ.б.).

«Чуаш» этнонимының үзатама булуы-булмавы мәсьәләсе әлегә ачык кала. Бу исемнең үзатама булуы да, Казан ханлыгында феодаллар катламын тәшкил иткән «татарлар» яки күрше фин-угор кавемнәре тарафыннан кушылган булуы да ихтимал. Бу уңайдан, тел галиме Р. Әхмәтьяновның төшенчәне «игенче» сыйфатында мәгънәсендә шәрехләве кызыклы. Идел буе болгарларының X-XI йөзләрдән үк төп шөгыле игенчелек булганын искәртсәк, аңлатманың дөреслеккә туры килү мөмкинлеге куәлланыр. Һәрхәлдә, хәзерге чуашларның борынгы бабалары «чуаш» этнонимын XVI йөздә үк үз иткәннәр булса кирәк. XVI йөз дәүләт эшлеклесе А. Курбский язмаларындагы «Черемиса горная, а по их Чуваша зовомые» («Тау чирмешләре, ә аларча Чуашлар, дип аталучы») гыйбарәсе шундый фикергә этәрә (мариларның борынгы бабалары - «тау чирмешләре» чуаш халкы оешуда шулай ук катнашканнар). Ахыр чиктә, «чуаш» төшенчәсенең хәзерге чуаш халкы исемендә чагылыш табуы табигый. Ләкин бу инде мәгълүм дәрәҗәдә фин-угорлашкан кавем.

Китап авторы Урта Идел буена кагылышлы тарихи чыганакларда урын алган XIV-XV йөзләр «бисерменнәре» белән XVI-XVII йөзләр «ясаклы чуашлары» арасында да уртаклык таба. Галим фикеренчә, Алтын Урдада, бигрәк тә аның Болгар вилаятендә ким дигәндә XIV йөздән бирле яшәгән һәм нигездә ислам дине тоткан «чуашлар» (аларга кадәр «бисерменнәр») мөстәкыйль этник төркем тәшкил иткәннәр. Аның оешуында болгарлар хәлиткеч роль уйнаган. Шул ук вакытта, бу этник төркемнең калыплашуында башка этник компонентлар да (кыпчаклар һ.б.) катнашкан булуы ихтимал. Тулаем алганда, автор урыс чыганакларындагы XVI-XVII йөзләр «ясаклы

чуашларын» һәм аларга кадәрге «бисерманнарне» Алтын Урданың Болгар вилаятендәге, соңрак Казан ханлыгындагы аерым сыйнфый-этник берәмлек («этносословное образование») итеп карарага кирәк, дип исәпли. Казан ханлыгында бу төркем сыйнфый яктан Казан татарларының «түбәнге» - феодаль бәйле өлешен тәшкил иткән.

Әлбәттә, мәсьәләгә кагылышлы башка төрле фикерләр дә булырга мөмкин. Алга таба проблема тагын да ачыклана, конкретлаша төшәр. Әмма авторның аны эшләүгә күп көч сарыф итүе, нәтиҗәдә аны чишүгә зур өлеш кертүе бәхәссез.

Яна монографиядә шулкадәрле күп, кызыклы, аз өйрәнелгән тарихи проблемалар күтәрелә ки, күләме нык чикләнгән язма кысаларында аларның барысына да тукталу, әлбәттә, мөмкин түгел. Хәер, бу максат итеп тә куелмады. Ул мәсьәләләрнең ни дәрәҗәдә четерекле дә, кызыклы да икәнлеген шәрехләү өчен аларның кайберләренә генә тукталып узылды. Ә инде Идел-Урал буе татарларының этник тарихына кагылышлы гаять күп проблемаларны өйрәнгәннән-тикшергәннән соң, галим тарафыннан ясалган ахыр нәтиҗәләр аерым игътибарга лаек. Мәсәлән, автор Идел-Урал буе татарларының XV-XVII йөзләрдәге этник алгарышында өч баскыч билгеләргә була, дип саный: 1) Алтын Урдага бәйле соңгы дәвер (XV йөз - XVI йөз уртасы); 2) күчеш чоры (XVI йөзнең икенче яртысы - XVII йөзнең беренче унъеллыклары); 3) оешу-берләшү дәвере (XVII йөзнең 30 елларыннан алып гасыр азагына кадәр). Шул ук вакытта, соңгы ике баскычны, «гомум татар халкы» оешуның уртак чоры буларак, берләштереп карарга да була, дип исәпли. Казан, Касыйм ханлыклары дәверендә бу дәүләтләрдә ике якын кардәш төрки-татар халык - Казан татарлары һәм мишәр феодаль халыклары калыплашу процессы бара. Беренче очракта бу процесс XVI йөзнең уртасында, икенчесендә — гасыр азагында тәмамлана. Дәүләтчелекне югалту, демографик катастрофа һәм татар дәүләтләрендә калыплашкан элеккеге сыйнфый структураларның җимерелүе нәтиҗәсендә, XVI йөзнең икенче яртысыннан башлап, Идел-Урал буе татар феодаль халыкларында («народность» мәгънәсендәге) XVII йөзнең 30 елларына кадәр барган «күчеш чоры» башлана. Бу чор татарларда сыйнфый аерымлыкларның кимүе, аларның эчке сыйнфый-этник төркемнәрдән арынуы, берләшү тенденциясе белән билгеләнә. Автор фикеренчә, этник тәрәкъкыяттәге өченче дәвер башы XVII йөзнең 30 еллары белән билгеләнсә дә, чынлыкта «Идел-Урал буе татарлары», дигән сыйфат ягыннан яңа халык («народность») оешу процессы элегрәк, инде атап кителгән «күчеш чорында» ук башлана. Идел-Урал буе татарлары арасында XVI йөзнең икенче яртысында-XVII йөздә барган этник процессларның юнәлешен, барыннан да бигрәк, мәгълүм сәяси, сыйнфый-икътисади сәбәпләр аркасында, XVII йөздә аеруча көчәеп киткән массакүләм күченүләр үзгәртә. Бу күченүләр нәтиҗәсендә Казан татарларының мишәрләр белән үзара бәйләнешләре күпкә көчәя. Нәтиҗәдә, XVII йөз ахырына «Идел-Урал буе татарлары», дигән сыйфат ягыннан яңа халык («народность») оеша. Шул рәвешле, урта гасырлар татарлары үзләренең этник үсешләрендә яңа дәвергә «аяк басалар». Болар - автор тарафыннан чыгарылган төп нәтиҗәләр. Алардан галимнең Идел-Урал буе татарларының XV-XVII йөзләрдәге этник тарихына үзенчә, оригиналь карашы булганлыгы күзаллана. Ә инде китапның төрле бүлекләрендә урын алган, темага кагылышлы төрле аерым тарихи проблемалар буенча ясалган бихиһая башка күп гыйльми нәтиҗәләр, күзәтүләр үзләре аерым игътибарга лаек. Әлбәттә, автор нәтиҗәләре белән килешергә яки өлешчә килешмәскә, кайбер тарихи мәсьәләләр буенча бәхәскә керергә дә мөмкин. Бу табигый дә. Чөнки Идел-Урал буе татарларының XV-XVII йөзләрдәге этник тарихына бәйле барлык катлаулы, четерекле, чагыштырмача аз өйрәнелгән тарихи проблемаларны бер монография кысаларында гына ахыргача чишеп бетерү мөмкин дә түгел. Әмма шунысы хак: автор яңа китабы белән ул проблемаларны ачыклауга, урта гасырлар дәвере татар халкы тарихын өйрәнүгә үзенең саллы өлешен кертә. Шуның белән үзен гаять катлаулы, күләмле гыйльми мәсьәләләрне дә чишә алырлык, житлеккән белгеч итеп таныта. Әле чагыштырмача күптән түгел генә ул татар халкының XVII-XX йөзләрдәге мәдәни-этник үсешенә багышланган башка бер күләмле монографиясен дә дөньяга чыгарган иде (кара: Исхаков Д. М. Проблемы становления и трансформации татарской нации. - Казан: «Мастер Лайн», 1997. - 248 б.). Ул басма да аерым игътибарга лаек. Бу унайдан, галимнең иҗади омтылышы, гыйльми кыюлыгы, тырышлыгы игътибарга һәм хуплауга лаек.

**Рәшит ГАЛЛӘМОВ,**
*тарих фәннәре кандидаты.*

*Хәтер*

# ХАКЫЙКАТЬКӘ ЮЛ ОЗЫН

Безнең әтиебез Зарипов Харис Зариф улын 1941 елның 18 июлендә кулга алганнар. Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы башланып, бер ай үтәр-үтмәстән! Әллә соң ул немец шпионы булганмы икән?! Юк! Гаебе: имеш, ул социалистик дәүләт төзелешенә каршы корткычлык эшләре алып барган, коммунистлар партиясен һәм совет хөкүмәтен хурлап сөйләгән, алай гына да түгел, дөньяда иң гадел беренче эшче-крестьяннар дәүләтебез юлбашчыларына тел тигезгән! Һәм кемгә, диген?! Бөек Юлбашчыбыз Даһи Сталинның үзенә!..

Илдә сугыш бара. Авыллар-калаларны калдырып, Кызыл Армия гаскәрләре чигенә... чигенә... Ә монда, ниндидер бер татар авылында шул фашист тегермәненә су коючы бәндә табылсын әле! Бу «халык дошманы»ның эшен тиз тотканнар. Кирәкле шаһитлары да бик тиз табылган. Тикшерүче сержант Хәбибуллин протоколга болай дип язып куйган: «ТАССРның Сарман районы Петровка поселогында яшәүче Зарипов Харис Зариф улы, ВКП(б)га һәм Совет властена каршы дошман фикерле булып, халык арасында даими рәвештә советка каршы агитация алып барган, ВКП(б) һәм Совет хөкүмәте юлбашчыларына яла яккан... Кулга алынучы РСФСР Җинаятьләр Кодексының 2 бүлеге, 58-10 нчы статьясы буенча җинаятьче сыйфатында тикшерүгә тартыла. Зарипов Харис үзенең гаебен тулысынча таныды, шулай ук шаһитлар, алар белән күзгә-күз очраштырулар һәм башка документлар белән житәрлек фаш ителде». Әлеге язу бик үк грамоталы булмаса да, төп фикере ачык аңлашыла: Зарипов Харис - халык дошманы!

1941 елның 27 октябрендә, - немец фашистлары Мәскәү төбенә килеп житәргә ерак калмаган бер вакытта! - әтинең «эше» буенча «гадел совет суды» утырышы була. Утырыш ябык тәртиптә үткәрелә, залда ни гаепләнүчене яклаучы адвокат, ни дәүләт гаепләүчесе прокурор булмый, бары тик судья, утырышчылар, гаепләнүче... Ярты сәгатьмедер барган бу «суд» утырышында алай да әле әтигә соңгы сүз әйтү хокукы бирелә. Үзенең соңгы сүзендә әти: «Мин үзем батрак идем... Мин беркайчан да контрреволюцион агитация алып бармадым... Менә, кулыма корал тотып, Ватаныбызны сакларга мөмкинлек бирегез...» - дип үтенә. Бирәләрме соң?! Хөкем карары катгый: ун ел төрмә һәм тагын биш елга барлык хокукларыннан мәхрүм ителү...

Әтинең аклануын, юридик тел белән әйткәндә, реа-би-ли-та-ция-сен безгә кырык бер ел (!) көтәргә туры килде.

Шуннан соң уналты ел үткәч, 1999 елда, журналист-язучы буларак, Сталин режимының сәяси репрессияләре корбаннары турындагы «Хәтер китабы»н язуда катнашуымны үтенделәр. Шулай итеп, гаиләбез фаҗигасен сөйләп бирү мөмкинлеге туды.

Мин бары тик дөресен генә сөйләргә телим. Бернинди арттыруларсыз, ачу-үпкәсез, бары тик дөресен генә... Чөнки бу дөреслеккә, бу хакыйкатькә юл, ай-һай, кыен вә озын булды!

Бер генә искәрмә: бу хәл-вакыйгалардан соң инде алтмыш елга якын вакыт үткән, әлеге фаҗигагә катнашы булган кешеләрнең күпчелеге вафат, кайберләре, бәлки әле дә исәндер дә-алардан ни-нәрсә сораша аласың?-кемнәрнеңдер туганнары, балалары хәзерге шыксыз-шөкәтсез илебездә гомер кичереп яталардыр - шуңа күрә мин бу язмамда кайбер исем-фамилияләрне үзгәртеп бирергә кирәк таптым. Төптән уйлаганда, алар гаепле түгел бит, шул замандагы сис-те-ма, режим гаепле...

1941 елның 22 июне. Якшәмбе. Советлар Союзы халкы берваемсыз ял итә, ул тирән йокыда... Иртәнге сәгать 4.00. Һәм...

Гитлер Германиясенең 170 дивизияле гаскәре, менә кадәр бөтен Көнбатыш

Европа өстеннән җиңүле марш белән үтеп, сугыш игълан итеп тормастан, хыянәтчел төстә Советлар иленә ябырыла. Күктә — кара тәреле бихисап бомбовозлар. Татлы таң йокысы белән йоклап яткан авыл-шәһәрләр өстенә бомбалар ява. Кызыл Армиянең әзерлексез чик сакчыларын изеп-сытып танклар үкереп килә, туплар гөрселди, мотоциклар тырылдап чаба... Ил өстендә — афәт! Фашизм афәте...

Әйе, сугыш! Безнең илебез тарихына Бөек ватан сугышы иseme белән кереп калачак канкойгыч сугыш. Ил үзенең 20-30 миллион халкын корбан итәчәк сугышның башлануы бу...

Рәтле-юньле коралы да булмаган, данлыклы командирларын Сталин-Берия тегермәне «тартып он иткән», хәрби әзерлеге түбән Кызыл Армия, заманча коралланган, бинихая көчле фашист армиясенең һөҗүменә түзә алмыйча, чигенә... чигенә... Фашистлар өерелеп килә. Фюрер Гитлер үзенең «Бүре өне» дип аталган ставкасында инде Советлар Союзы Башкаласы Мәскәүдә немец гаскәрләренең Җиңү парады көнен билгели, үзен Ленин мавзолее трибунасында басып торган кебек хис итә. «Барбаросса планы» тормышка аша! Яшен тизлегендәге сугыш менә-менә хәл ителәчәк! Форвертс, алга!

Әмма... даһи Сталиннан тыш гади совет халкы да бар бит әле. Бөтен ил-халык, бердәм булып, немец-фашист юлбасарларына каршы изге көрәшкә күтәрелә. Тарих белә: халыкны бервакытта да җинеп булмый.

Бу канкойгыч сугыш илебездәге һәр гаиләгә, һәр йортка килеп керә. Юлбашчыбыз Сталинның даһилыгына инанган совет халкы аның ышанычлы тавыш белән өметләндергеч сүз әйткәнен көтә. Әмма Сталинның тавыш-тыны юк. Башка юлбашчылар, җиңелмәс кызыл командирлар — Молотов, Ворошилов, Буденныйлар да — ләм-мим. Халык тәшвишләнә, халык борчулы сорауларга җавап эзли: «Ни өчен безнең гаскәрләр чигенә? Кайда безнең атабыз даһи Сталин? Ник дәшми ул? Ник халыкны изге яуга күтәрми?» Бер саксыз сүз өчен төрмә-лагерьларга ябылган, сөргеннәргә сөрелгән «халык дошманнары» мисалында куркып-өркеп яшәргә күнеккән совет халкы телгә килә. Кешеләр, анда да, монда да төркем-төркем җыелышып, хөкүмәтне сүгә, фашистларга әсирлеккә тулы полк, дивизия, армияләрне ташлап качучы куркак командирларның тетмәсен тетә. Имеш-мимешләр тарала. Имеш, совет хөкүмәте Мәскәүдән чыгып качкан, имеш, ул әллә Идел буенда, Урал артында ук яшерен җир асты сарайларында хәзер, имеш, Сталин үзе бөтенләй Себер тайгаларына сыпырткан...



*Нәни Марсель əти-әнисе белән. 1932 ел.*

Акыллы-зиһенлерәк кешеләр төптәнрәк каера. Ни өчен юлбашчыларыбыз Гитлерга үзебезне алдарга мөмкинлек бирделәр? Германия белән һөҗүм итешмәү, дуслык турындагы килешү-договор кирәк идеме? Ни өчен аларның чит ил эшләре министры, фашист Риббентроп белән безнең чит ил эшләре халык комиссарыбыз, коммунист Молотов Мәскәүдә кочаклашып фоторәсемнәргә төшеп йөрделәр? Кайда даһи юлбашчыбыз Сталинның зирәклеге, алдан күрүчәнлеге?

Бу сораулар, әлбәттә, урамда кычкырып йөреп әйтелмәгәннәр. Алар бер-берсен якын белгән, үзара сүз сыйган кешеләр арасында гына әйтелгәннәрдер, бәлки. Әмма әйтелгәннәр... Һәм шул сүзне әйтүчеләр арасында, гонаһ шомлыгына каршы, минем әти дә булган... Ул әнә шундый «төптәнрәк каеручылар»ның берсе була бит, әй!

Яшьлегендә ике сугыш - Беренче бөтендөнья сугышы һәм гражданнар сугышы кичергән, дөньяга күзе ачылган гади крестьян малае Харис житәкче эшләргә тартыла.

Хәер, башта аның тәрҗемәи хәленә күз төшереп узыйк әле. Әтинең суд эше кәгазьләре арасында 1941 елда авыл советы тарафыннан бирелгән характеристика бар. Анда болай диелгән: «Зарипов Харис Зариф улы 1895 елда Татарстан республикасының Сарман районы Янурыс авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган. Хуҗалыкларында 1 йорт, 1 ат, 1 сыер, 1 балчык келәтләре булган. Башка нәрсәләре

булмаган, революциягә кадәр дә, революциядән соң да шулай яшәгәннәр. 1921-1923 елларда авыл советы сәркатибе булып эшли, 1923-1925 елларда Языково волосте башкарма комитеты сәркатибе була, 1925 елдан Нөркәй волостенә күчә, анда да сәркатип булып эшли. Нөркәй волостенда эшләгән вакытында суд җаваплылыгына тартыла, әмма аклана. Шуннан соң ул Янурыс авылына әйләнеп кайта. 1929 елда коллективлаштыру чорында колхозга керә. Туганнары һәм якыннары арасында раскулачить ителгәннәр юк».

Анкеталарында «түбән белемле» дип язылган булса да, әти үз заманы өчен шактый укымышлы, аңлы кеше була. Ул Янурыс авылы мәдрәсәсен тәмамлаган, ә мәдрәсәләр хәзерге урта мәктәпләр, гимназия-лицейлар биргән дәрәҗәдә диярлек белем биргәннәр. Уку-язуы гарәп имласы нигезендә булганга күрә генә, ул ирексездән башлангыч белемлеләр рәтендә йөргән. Юкса революциягә кадәр үзе укыган мәдрәсәдә мөгаллимлек тә иткән, герман сугышы солдаты һәм гражданнар сугышы кызылармеецы да булып, аның дөньяга карашы шактый мәгълүматлы булган. Караңгы татар авылына ул инде большевистик карашлы, яңа тигез тормыш төзергә әзерлекле кеше булып кайткан. Шуның өчен дә аны авыл советы сәркатиблегеннән район күләмендәге җитәкчелеккә — волисполком сәркатиблегенә кадәр күтәргәннәр.

Ләкин әти начар җитәкче, начар коммунист булып чыккан. Коммунистлар партиясе игълан иткән гадел-тигез, рәхәт-имин мул тормышны төзү өчен эчке һәм тышкы дошманнар белән аяусыз көрәш алып барырга, кирәксә, кан коярга да туры килгән. Социалистик төзелешнең ул чорында авыл кулакларын тамырыннан корыту, гади генә итеп әйткәндә, таза-нык тормышлы, тырыш крестьяннарның бар байлыгын тартып алып, гаиләләре-ниләре белән Себергә сөрү максат итеп куелган. Күрәсең, үзе дә крестьян булган әтинең холкы-табигате мондый рәхимсезлек белән килешә алмагандыр. Аңсыз крестьяннарны көчләп колхозларга куып кертергә кирәк булганда, ул йомшаклык күрсәткән, кемнәрнедер кызганган, кемнәргәдер ярдәм иткән... Әтине берничә ел «тәрбияләп карарга» тырышканнар, дошманнарга карата революцион килешмәүчәнлек күрсәтүен таләп иткәннәр, ләкин бу «тәрбия эшендә» уңышка ирешә алмаганнар булса кирәк, озакламый партия үзенең ышанычсыз сугышчысыннан баш тартырга мәҗбүр булган. Алай гына да түгел, аны суд җаваплылыгына да тартканнар.

КПССның Татарстан өлкә комитеты архивыннан алынган тагын бер белешмә бар. Ул ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты партия өчлеге утырышы беркетмәсеннән өземтә.

«Зарипов Харис, - диелә анда, - кулаклар белән бәйләнештә булганы, үз вазифаларына салкын караганы өчен 1929 елның 17 сентябрендә ВКП(б)ның Нөркәй авылы ячейкасы тарафыннан партиядән чыгарыла һәм чит элементларга урманнан ташламалы бәя белән агач биреп җибәргәне өчен җинаять җаваплылыгына тартыла. Татарстан Республикасы Башсудының күчмә утырышы карары белән 2,5 елга иреgennән мәхрүм ителә; 1930 елның 16 мартында Югары суд Башсуд карарын юкка чыгара, җинаять эше туктатыла...

Сарман районы контроль комиссиясе, Зариповның аппеляция үтенечен караганнан соң, аның партиядән чыгарылуын... раслады.

Зарипов Харис партия сафларын чистартканда тикшерелмәгән. Аппеляциясендә партиядә торгызылуын үтенә. Аның партия эшендә пассивлык күрсәтүе турында ячейканың белешмәсе бар. Зарипов гаризасын үзеннән башка гына тикшерүне үтенә, аппеляциясен тикшергәндә үзе катнашмый.

Карар кылынды: партия тормышында тулы пассивлык күрсәтүе сәбәпле, Зариповның партиядән чыгарылуын расларга».

Ләкин шундый ачы сабак алганнан соң да әти: «Сүзең көмеш булса, дәшми торуың - алтын», - дигән хакыйкатьне оныта. Мин аның эчкерсез, ачык күңелле, шук-шаян, сүзчән кеше булуын хәтерлим. Ул уен-көлкегә дә оста, кешеләргә ышанучанлыгы өстенә, бик хисчән, балаларча беркатлы да иде. Дусларча мәҗлесләрдә бу «тел бистәсенә» тиңнәр табылмый, сүзләре уйлап бетергәнче үк авызыннан очып чыга, теләсә нинди мәсьәлә буенча үз фикерен ярып салырга ашыга, соңы ни булып бетәсен дә уйлап тормый. Шуңа да ул әлеге холкы-табигате аркасында еш кына кыен ашый.

Сталин совет халкына мөрәҗәгать белән бары тик 3 июльдә генә чыгыш ясый. Сугыш башланып, ике атна диярлек вакыт үткән, немецлар Днепрга килеп җиткән булалар инде. Кызыл Армия исә һаман чигенә. Радио көн саен: «Безнең гаскәрләр

фәлән-фәлән шәһәрләрне калдырдылар...» - дип сөйләп тора...

Шулай туры гына килгәнме, әллә язмышның берәр шуклыгымы - дәүләт юлбашчыларына яла ягуда гаепләп әтигә карата «эш» кузгатылу да нәкъ даһи Юлбашчының әнә шул мөрәҗәгате көнне ачылган.

Әтине «чагып» аның өстеннән әлек язучылардан нәкъ 1941 елның 3 июлендә сорау ала башлаганнар. Канкойгыч рәхимсез сугыш бара. Юлбашчыга турылыклы совет халкы үзен аямыйча фронтта сугыша, тылда фидакарь хезмәт батырлыклары күрсәтә. Ләкин шушы монолит кебек бердәм халык арасында моңа кадәр фаш ителеп бетмәгән «контрлар» да бар икән әле! Алар һәртөрле зарарлы-усал имеш-мимешләр тараталар, Совет Ватанына пычрак ягалар, фронттагы вакытлы уңышсызлыклар өчен хөкүмәт җитәкчеләрен, даһи Юлбашчыбызны гаепләргә җөрьәт итәләр. Ни өчен бу юк ителеп бетмәгән дошманнар намуслы совет халкы арасында яши, ни өчен алар төрмәләрдә-лагерьларда түгел? Менә шулай итеп, Татарстанның сизгер чекистлары караңгы татар авылында яшеренеп яткан бер «явыз дошманның» эзенә төшәләр.

Әти бу вакытта, аны-моны уйламыйча, Петровка спирт заводында эшләп йөри.

Тикшерүче алдына яла ягучылардан беренче булып спирт заводының ярдәмче хуҗалыгы завхозы Сафуанов килеп баса. Тикшерүченең беренче соравы бик гади генә: «Сез Зарипов Харисны беләсезме, аңа нинди характеристика бирә аласыз?» Җавап: «Бергә эшләвебез буенча беләм, белемле, хөкемгә тартылган булган, ни өчен икәнен төгәл генә әйтә алмыйм, эчкәли, күп сөйләшә, шаяртырга ярата, сәяси яктан тотнаксыз». Әһә, тотнаксыз, димәк! Кармак салынган, җим йотылган. Сафуанов, әлбәттә, сөйләячәк. Сөйләми генә карасын! Икенче сорау турыдан-туры маңгайга бәреп, катгый куела: «Зариповның антисоветчыл сөйләнү фактлары турында сезгә нәрсәләр билгеле?» Бу сорауны ишеткәч, шаһит тикшерүчегә барысы да мәгълүм икәнлеген аңларга тиеш, бары тик шул белгәннәрне расларга гына кирәк. Шулай эшләмәсән, үзеңне «фактларны яшереп калдыруда» гаепләячәкләр. Вакытында әйтмәгәнсең, тиешле органнарга җиткермәгәнсең, дошманны фаш итәргә булышмагансың, димәк, аңа фикердәш булгансың. Җәза бер - ун ел төрмә!

Сафуанов, әлбәттә, тикшерүче теләгәнчә җавап бирә: «Зарипов Харисның антисоветчыл сөйләнү фактлары турында миңа түбәндәгеләр билгеле. 1941 елның 24 июнендә заводның материаллар складында, завсклад Ваһапов, тимерче Сәетвәлиев, эшче Козлов барында, Зарипов, партия һәм хөкүмәтебез җитәкчеләре иптәш Сталин һәм Молотовларга яла ягып, болай диде: «Безнең Германия белән дуслык договорыбыз бар иде, Гитлер безгә һөҗүм итте. Хөкүмәтебез җитәкчеләре безне тупыйкка китереп керттеләр. Сталин һәм Молотов кебек җитәкчеләрнең бәясе сукыр бер тиен...»

Шушы ук «фактны» сүзгә-сүз диярлек, шаһит буларак, тимерче Сәетвәлиев тә раслый. Ул бары тик: «Дуслык договоры булуга карамастан, Гитлер безгә һөҗүм итте» дигән сүзләргә: «Тапканнар кем белән дуслашырга» - дип әйтте», - дип кенә өсти.

Шаһит Газиев сөйли: «Зарипов Харис волисполком сәркатибе булып эшләгән чорында кулаклар белән тыгыз бәйләнештә булды, аларны раскулачивать итүдән яшереп, ялган документлар биреп утырды. Шуның өчен эшеннән алынып, ВКП(б) сафларыннан куылды. Совет хөкүмәтенә каршы дошман фикердә, җәмәгать эшләрендә катнашмый». Әһә, монысы чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, эшне тагын да катлауландыра. Гаепләүләр тирәнәя бара.

Шаһит Кузнецкий: «22 июнь ял көне иде бит. Без эчеп утыра идек. Зарипов Харис аракыга барып килде, шатланып кайтып керде: «Ну, дуслар, немец безне бомбага тота башлаган!» - ди. Мин аңа: «Кирәкмәгәнне юкка сөйләмә!» -дидем дә чыгып киттем. Бәладән баш аяк!» Әһә, сугыш башланганга шатланган! Димәк, фашистлар яклы!

Завод агрономы Александровская, шаһитлык кылып, чимал цехы башлыгы Зариповның колхоз һәм совхозларга дошман булганлыгын, хосусый милекчелек карашларын алга сөргәнлеген, сәяси тотнаксызлыгын, антисоветчыл коткылар таратканлыгын сөйли дә: «Мин ышанып әйтәм: Зарипов советларга каршы кеше, иске тормышны мактый. Элек агрономнарсыз да яхшы уңыш ала идек. Хәзер агрономнар дөнья тулы, ә барыбер рәт юк», дип әйтә! - ди.

Завод эшчесе Мәүлетов тагын да тирәнрәк «чокыр казый»: «Аерым кешеләрнен сөйләвеннән беләм, Зарипов 1929 елда солтангалиевчелеккә бәйләнеше булганга күрә, ВКП(б) сафларыннан чыгарылган», - дигән сүзләр яздыра.

Мирсәет Солтангалиев - Иосиф Сталинның кайчангыдыр көрәштәше. Милләтләр эше халык комиссариатында хезмәт иткән чорында, юлбашчының

күпмилләтле совет дәүләтен төзү турындагы карашлары белән килешә алмыйча, үз тәгълиматын тәкъдим итә - совет кешеләрен берләштерүнең гадел юлы милләтләр тигез хокуклы республикалар төзегәндә генә була ала, дигән фикерне алга сөрә. Шуңа күрә, Сталин аны юк итәргә карар кыла. Мирсәет Солтангалиевны 1940 елның 28 гыйнварында атып үтерәләр. Хатыны һәм ике баласы да төрмәдә һәлак була. Аның фикердәшләре, дип, бик күпләрне харап итәләр. Кара әле син, ә монда аларның тагын берсе яшеренеп калган икән бит! Эш пешә болай булгач!

Шуннан соң менә мондый документ язылa: «Мин, дәүләт куркынычсызлыгы оперуполномоченные сержант Хәбибуллин, Зарипов Харисның җинаятьчел эшчәнлеге турында кергән материалларны караганнан соң, аның совет хөкүмәтенә һәм хөкүмәт үткәргән чараларга карата дошман караштa булуын, халык арасында даими рәвештә антисоветчыл агитация алып баруын, ВКП(б) һәм совет хөкүмәте җитәкчеләренә яла ягуын ачыкладым.

Иректә калса, Зариповның тикшерүдән һәм суд җаваплылыгыннан качып китү мөмкинлеген игътибарда тотып, аны кулга алу кирәк».

Капкын ябылды...

Тикшерүченең кулга алынган әтидән беренче сорау алулары саңгырау белән телсезнең сөйләшүен хәтерләтә. Саңгырау телсезне ишетми, телсез саңгырауга аңлата алмый.

Тикшерүче: «Сез советларга каршы пропаганда алып барган өчен кулга алынгансыз. Гаебегезне таныйсызмы?»

Кулга алынучы: «Юк, танымыйм. Мин беркайчан да советларга каршы агитация алып бармадым».

Тикшерүче: «Сезнең халык арасында даими рәвештә советларга каршы агитация алып баруыгыз турында бездә дәлилләр җитәрлек. Сезнең киреләнеп маташуыгыз файдасыз. Дөресен сөйләргә тәкъдим итәбез».

Кулга алынучы: «Мин үземнең кайчан советларга каршы агитация алып барганымны һич хәтерләмим. Сәетвәлиев белән Сафуановның шаһитлык кылып сөйләгәннәрен миңа укыдылар, мин аларны кире какмыйм. Ул чагында без, чынлап та, Германиянең Советлар Союзына һөҗүме турында газеттан укыдык. Мин ике ил арасындагы договор турында үз фикеремне әйттем, ләкин мин яла якмадым, ә дөресен генә сөйләдем».

Әһә, кире какмый! Димәк, гаебен таный! Оперуполномоченный канәгать. Тулысынча сөйләтербез. Сөйләрсең!..

Күрәсең, әти дә шатлангандыр - аны сындыра алмадылар бит, ул үзенең кайнарланып китеп әйткән сүзләреннән ваз кичми. Дөресе шулай ич! Кырыс, әмма әдәпле вә гадел тикшерүче сорау алу беркетмәләрен ертып ташлар да, аны азат итәргә ордер язып бирер! Аның нинди гаебе бар? Ул урлашмаган, халык милкенә зыян китермәгән, кеше таламаган, хулиганлык кылып сугышып йөрмәгән. Суд икән - суд булсын, намуслы кешене гадел совет суды белән куркытып булмый. Судьялар, утырышчылар, адвокат белән прокурор җыелсын, әти алар алдында да үз сүзләрен әйтеп бирәчәк, бер ялган сүз дә, яла да юк бит! Фашистлар башлыгы Гитлер аяк астына салып таптаган договор - Советлар Союзы белән Германия арасында һөҗүм итешмәү турында договор булганлыгы дөрес түгелме әллә? Совет наркомы Молотов Берлинга бармады, немецлар министры Риббентроп Мәскәүгә килмәде, алар фикердәшләр булып, Сталин белән рәсемгә төшмәделәр, дип кем әйтер? Бәлки, немец генералы Гудериан Казан танк училищесында укып, белем алып кайтып китмәгәндер? Белем генә алдымы икән әле? Халыклар язмышын, дөнья язмышын хәл итәрдәй бу мәкерле уенда кем кемне алдады: Сталин Гитлернымы, Гитлер Сталиннымы?

Их, әти, әти! Гаделлеккә ышанучан, балаларча беркатлы әтием! «Гадел совет суды» синең бу сүзләреңә колак салыр дип уйлап, бик каты ялгышкансың шул... Эшне озын-озакка сузмыйча, үзенә ун елны чәпәп тә куйганнар... Аннары тагын әле биш елга барлык хокуклардан мәхрүм ителүе дә бар бит...

Судка кадәр ярты еллап тикшерү барганда төрмәдә утырган әти «суга батканда саламга тотынып карый», югарыга кассация жалобасы яза, әмма, ни аяныч, аның шикаяте кире кагыла. РСФСР Югары суды хөкем карарын көчендә калдыра... 1942 елның 3 гыйнварында сәяси каторжан Зарипов Харис Зариф улы сөргенгә - «ГУЛАГ»ка озатыла.

Безнең гаиләне 1941 елның көзендә, әле әтигә судның хөкем карары чыгарылганчы ук, «халык дошманы» гаиләсе итеп, заводның ике бүлмәле фатирыннан куып чыгардылар. Анысы да әллә ни унайлыклары булган фатир түгел иде инде, миче

утын яки сасы торф ягып жылытыла, суга коега йөрисе, калган «унайлыклар» да ишек алдында иде. Әни белән без - дүрт бала - ярым жимерек баракның кысан бер бүлмәсенә күчендек. Әни үгезләр карый башлады, атлар кызыл кавалериягә алынган, аларны үгезләр алыштырган һәм ул мәхлуклар жигеп йөртелә иде. Кар астында калып өшегән черек бәрәңгене изеп, аз гына арыш онында әвәләп, таба төбен берәр төрле май белән ялтыратып кыздырсаң - теленне йотарлык кәлжемә була иде! Язга чыккач, кәлжемә янына яшь кычытканы, кузгалагы-балтырганы өстәлә, җәй инде, үзегез беләсез -дөньяның бер рәхәте! Әле бит безнең сыерыбыз да бар! Дөрес, авызга ит эләкми, бозауны мәжбүри салым түләргә бирәбез, әле сыердан да 400 килограмм сөт тапшырырга кирәк, әмма калганы да безнең гаиләнең «печтеки генә» ихтыяжын канәгатьләндерергә житә иде. Иртә-кичен завод халкы жыела торган салкынча подвалда коллектив сепаратор - сөт аергыч машина бар, шунда капкачын тасма белән бәйләгән яшел кәстрүлебез дә тора. Ул аертылган сөт өсте белән тулган көннәрдә - өйдә бәйрәм! Әни май яза, маен бер кадаклы (400г) йомарлаклар итеп оештырып куя, үзебезгә бик тәмле майлы әйрәне белән аертылган сөте кала, сөтеннән катык оетабыз. Май йомарлакларын исә мин базарга чыгарып сатам, акчасын иң-иң кирәк-яракларны алырга гына тотабыз.

Кышларын мин икесе ике сыңар булган төрле төстәге киез итек киеп йөрим. Язгы кар сулары төшкәч, аякта - күтәрмәле чабаталар. Әни караңгыдан ук үгезләре янына чыгып йөгерә, аларны жигүгә алып киткәнче ашатып-эчертеп каласы бар, ә мин кечкенәләрне карыйм. Энемә - дүрт яшь, сеңлемә - ике, үземә - ун. Ипи паегы шундый кечкенә була, көнлек норманы бер-ике кабуда ялмап йотасың. Нәниләр шыңшый, ашарга сорыйлар. Үземнең дә үзәкләр өзелеп ашыйсым килә. Әмма еламаска тырышам, түзәм. Мин инде зур. Кулыма Робинзон Крузо турындагы китапны алам да, кычкырып укырга тотынам. Менә ул бер кешесез утрауда, менә ул тәмле ботка пешерә... Шуның ярдәме тия иде - ашыйсы килү кимемәсә дә, энем белән сеңлем, шыңшудан туктап, авыз ачып тыңлыйлар.

Сталин лагерьларында иза чиккән Солженицын, Шаламов, Разгон, Рыбаков ише Рәсәй язучылары, аннары үзебезнең Салахов, Гыйләжев, Тавлин кебек язучыларыбыз язганнарга ышансаң, бөтен халык Сталин һәм аның иярченнәренә инанган, алар коткысына бирелеп, «халык дошманнарын» кырып, юк итеп бетерүне таләп иткән, имеш. Юк, һич тә алай түгел иде. Караңгы авылларда яшәүчеләр дә бәлагә тарганнарга теләктәшлек күрсәтә, ярдәм итәргә әзер тора һәм ярдәм дә итә иделәр. «Халык дошманнары» гаиләләренә дә жинаять кодексының каһәрле илле сигезенче статьясының бер кара канаты кагыла: хатыннарын лагерьларга илтеп тыгалар, кечкенә балаларын ятимнәр йортларына жыеп алалар. Ләкин безнең әнигә, нишләптер, кагылмадылар. Мөгаен, үтә сизгер чекистлар арасында да рәхим-шәфкатьлеләре булгандыр. Без биш кешелек гаилә булып яши бирдек. Завод поселогында төрле халык яши, нигездә татарлар белән урыслар, бераз гына башка милләт кешеләре дә бар иде. «Халык дошманы» гаиләсе, дип, кемнәрнеңдер бездән көлгәнен, рәнжеткәнен хәтерләмим. Киресенчә, күршеләребез дә, бөтенләй таныш түгел кешеләр дә күңелебезне күтәрергә, ничек булса да безгә ярдәм итәргә тырышалар иде. Мәктәптә дә башкалар белән тигез укыйм, билгеләремне дә киметмиләр, тиешлесен куялар, урманга мәктәп өчен утын кисәргә дә үз чиратымда гына барам, монысы бишенче сыйныфтан мәжбүри була иде.

Әтиебез «ГУЛАГ»ларда үлеп калмады, ун елга хөкем ителгән булса да, ике елдан әйләнеп кайтты. Бу минем өчен табышмак иде. Ни өчен вакытыннан алда азат иткәннәр аны? Соңыннан, үсеп егет булгач, аңладым: үзен алып киткәндә ул көче ташып торган, сау-таза кырык биш яшьлек ир булган, ә егерме ике ай дигәндә, өйгә зәңгәрләнеп ябыгып беткән, корык-корык ютәлләүче чирләшкә бер карт булып кайтып керде ул. Ниемә кирәк ди лагерьда бу жаны чыгарга торган адәм?! Көч-жегәре беткән... эшкә яраксыз... Лагерь барагында чахоткасын башкаларга йоктырып ятканчы, өенә кайтып дөмексен! Менә шундый ният белән «азат иткәннәр» дә инде әтине...

Сугыш вакытында спирт заводына яңа директор китереп утырттылар. Һади Хәким улы Заһидуллин иде ул - бик кайнар канлы, кырыс холыклы кеше. Аның бурычы - заводның эшчәнлеген туктатмау, бертуктаусыз спирт куу. Спирт госпитальләрдә ятучы яралы солдатларны дәвалау өчен, синтезкаучук заводларында танк, самолет детальләре ясарга яраклы тыгыз резин эшләү өчен, Мәскәүдән Берлингача жиңүле марш белән барып житәсе совет солдатларының күнитек табанына ябыштыру өчен дә шул ук резин кирәк. Заһидуллин абый, бик жилле,

эшлекле кеше булуы өстенә, бик кыю-куркусыз да булып чыкты. Әтиебезне яңадан үз эшенә чимал цехы башлыгы итеп куйды, ике бүлмәле фатирыбызны да кайтарып бирде. «Халык дошманына» яхшылык кылганы өчен директорның үз башы да Себер китәргә мөмкин булгандыр. Ләкин ул куркып тормады. Без аңа гомер рәхмәтле булып калдык.

Әмма... әтиебез үлем сулышын тоя иде инде... Яз-көзләрен рәхимсез туберкулез өянәге кузгалып, бик газаплана иде... Сугыштан соңгы беренче елда ук ул кара гүргә кереп ятты...

Ундүрт-унбиш яшьлек үсмер малай идем инде мин. Иң авыр кичерешләрем, кайгы-хәсрәтләрем шул чорда булгандыр. Минем яшьтәшләремнең кайберләре сугыштан исән кайткан әтиләренең, абыйларының йолдызлы пилоткаларын киеп, кайчагында әле хәтта түшләренә аларның сугышчан орден-медальләрен дә тагып, кәперәеп йөриләр иде. Ә мин?.. Мин - «халык дошманы» улы -Җиңү бәйрәме көннәрендә нәрсә тагарга тиеш идем? Шул кара тамганымы?!

1946 елны мин үз гомеремдә беренче мәртәбә имтиханнар бирдем. Әй тырыштым да инде «бишле»ләр алырга, әй тырыштым! Авыру әтиемне үземнең «уку фронтындагы» зур җиңүем белән куандырырга теләдем. Беренче имтиханнан «бишле» алып, кош кебек очып кына өйгә кайттым... Әмма... соңга калдым... Әтиебез җан биргән иде инде...

Әлбәттә, «халык дошманы» балалары булу безнең дә язмышларыбызны сындырды. Кем белә, әтинең ышанычлы канаты астында без дә, үз вакытында урта белем алып, югары уку йортлары тәмамлап, фән үрләренә дә күтәрелә алган булыр идек. Без җиде сыйныф бетерүгә эшкә җигелдек, кичке мәктәпләрдә укып йөргәндә инде утыз яшьләр тулып узган иде. Мин диңгез белән, дөнья тирәли сәяхәтләр белән хыяллана идем. Робинзон Крузо, Жюль Верн китапларын уку эзсез үтмәгән булса кирәк. Җидееллыктан соң диңгезчеләр училищесына китәргә ниятләдем. Бу теләгемне ишеткәч, әнием елап җибәрде: «Син, балакаем, син дә китсәң, бу йорт-җирне, хуҗалыкны кем карар? Ике кечкенә эне-сеңелләрең белән бер ялгызым мин нишләрмен?» - диде. Мин спирт заводының иң сасы исле, иң исерек цехына эшкә барып кердем. Анда икенче «диңгез» иде -анда, Туфан Миннуллин әйтмешли, «аракы - море!» Шулай итеп, хезмәт кенәгәсен ундүрт яшемнән алып, эшкә җигелдем. Армия хезмәтенә китәр вакыт җиткәндә мин инде аракыны шешәләргә тутыру цехының өлкән эшчесе идем.

Хыялым тормышка ашты! Мин хәрби флотка эләктем. Әмма хыял - бер нәрсә, тормыш икенче икән... Диңгездә биш ел хезмәт итеп, туган якларыма әйләнеп кайттым. Аннан соңгы тормыш юлым: бораулаучылар мәктәбе, нефть промыселларында эшләү, әвәле шәһәр газеты журналисты, аннары республика матбугаты һәм, ниһаять, КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Югары Советы органы булган «Советская Россия» газетында - чирек гасыр... Мактану дип кабул ителмәсен, искәртеп кенә үтәм: Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген алучы беренче журналист та мин булдым. Күрәсең, әтиемнең «тел бистәсе» булуының да тәэсире бардыр инде. Нәселдән килә торгандыр.

Шуны да әйтеп үтәргә тиешмен: без - «халык дошманы» балалары - дүртебез дә югары белем алдык. Һәм бернинди түләүсез-нисез. Алай гынамы соң, энем белән сеңлем стипендия алып укыдылар. Изаил абый белән мин читтән торып укыдык, имтиханнар чорында безгә түләүле ял көннәре бирәләр иде. Анкеталар тутырырга туры килгәндә, дистәләрчә сораулар арасында «халык дошманы» улы түгелме?» дигәнрәк сорау беркайчан да очрамады. Ил-халык ул каһәрле елларның фаҗигасен тизрәк онытырга тели шикелле иде. Әмма онытыламы соң?!

Тагын бер табигый сорау. Ни өчен без - гаепсезгә харап ителгән әтиебез балалары - халык әйтмешли, «укып кеше булгач та», аның намуслы исемен аклатырга тырышып карамадык? Үз балаларыбызга, оныкларыбызга әтиебезнең ачы язмышы турында сөйләмәдек? Бу сорау бик җиңел кебек, әмма аңа җавап бирүе бик авыр. Тырышып карадык... Сөйләдек... Ләкин бик соңлап...

Тиран Сталин исән чагында әтине, әти кебек миллионлаган сәяси тоткыннарны аклату - реабилитация турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Ул җәллад үзенең утыз елга якын хакимлеге чорында ничәмә-ничә дистә миллионнарча кешеләрне корбан итте. Халык: «Инде канга туйгандыр, сугыштан соң бу афәткә чик куелыр...» - дип өметләнеп көтте. Ләкин... әсирлектә булган солдатларыбызны эшелонлап-эшелонлап Себергә, Ерак Көнчыгышка озата тордылар. Аннары «Ленинград эше», «табиблар эше», «космополитлар эше» кебек тузга язмаган «эшләр»

бер-бер артлы оештырылып кына торды. Әй тырышып та карады соң инде Сталинның баш җәллады Берия! Үлем тегермәне шулай тартуында булды...

«Халыклар атасы, бәхет кояшы» Иосиф Сталин тагын ни-нәрсәләр кылган булыр иде - әйтүе кыен. Әмма әҗәл дигәнең көннәрдән бер көнне ул явызның үзен дә якасыннан алды. 1953 елның мартында бу тиран да дөньядан кичте. Мөгаен, туптуры тәмугкадыр!

Аннан соң КПССның халыкны тетрәнергә мәҗбүр иткән атаклы XX съезды. Никита Сергеевич Хрущев Сталинның һәм аның иярченнәренең илгә коточкыч фаҗигаләр китерүе турында доклад ясый. Ил вәзгыяте «җепшеклек» («оттепель») кичерә. Күпмедер дәрәҗәдә халыкка иркенлек килә. Әмма озакка түгел, шул ук Хрущев яңадан «кыраулар чоры»н башлап җибәрә. Аны бәреп төшергән Леонид Брежнев исә «диссидент-мөртәтләрне» «психушкаларга» яптыра башлый.

Шундый шартларда, әлбәттә, әтинең «эшен» яңадан карауны кузгату мөмкин түгел иде.

Инде Леонид Брежневның да комы коелган, әҗәл аны да якасыннан алган иде. Аның вафатына өч атна кала - 1982 елның 17 октябрендә мин әтинең «суд эшен» яңадан карауны үтенеп, Татарстан Прокуратурасына хат яздым. Дөресен әйткәндә, өметем бик аз иде. Әле Михаил Горбачевның «үзгәртеп кору» чорына да өч ел вакыт бар. Хәзерге демократик реформаларга исә - чынлап та демократик реформалар булуына шигебез дә бар бит әле - тагын да ераграк иде.

Минеке шикелле үтенеч хатларын карауга бер ай вакыт бирелә икән. Бер ай да, ике ай да үтте - бер җавап юк. Инде өченче ае да үтеп киткәч, өметемне тәмам өздем: булмагач -булмый икән!

... Ниһаять, хакыйкатькә юл озын булса да, аның чиге күренде: әтине 1982 елда аkладылар! Тагын ундүрт елдан соң, 1994 елның 23 ноябрендә минем кулыма таныклык тапшырдылар. Ул таныклык буенча мин, «бәлигъ булмаган яшьтә ата тәрбиясеннән мәхрүм булганлыктан, шулай ук сәяси репрессияләрдән зыян күргән зат» булып саналам. Безнең ишеләргә дә льгота-җиңеллекләр бар икән: шәһәр тирәсе автобуслары һәм электр поездларында бушлай йөрү, квартирга, телефонга, даруларга яртылаш кына түләү хокукларым бар... Матди яктан караганда, болар әллә ни ис китәрлек нәрсәләр дә түгел, әмма әхлакый җиңүебезне бәһаләп бетереп булмый. Без -«халык дошманы» балалары түгел! Без - залим Сталин золымы корбаннары.

Соңгы ун ел эчендә бер Татарстанда гына да бер гаепсезгә хөкем ителгән ике йөз меңнән артык элекке сәяси тоткыннарның исемнәре акланды. Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның исемнәре тупланган беренче «Хәтер китабы» серияләре басылып чыкты. Хәзер исә шундый ук «Хәтер китабы»ның икенче серияләре - сәяси тоткыннарның исемнәре тупланып чыгарылачак.

Вакытлар үтү белән тау-ташлар җимерелә, дингезләр кибә. Ә халык хәтере - мәңгелек. Килер буыннар тарихның данлы сәхифәләрен дә, хурлыклы-фаҗигале сәхифәләрен дә белергә тиеш. Ул фаҗигале еллар яңадан беркайчан да кабатланмасын!

**Марсель ЗАРИПОВ**

*Сафа Сабировка 85 яшь*

# ҮЗ ЗАМАНЫ БАЛАСЫ

Бу чор татар язучыларынын язмышы бер-беренә бик тә охшаш. Ятимлек. Балалар йорты. Һөнәр мәктәбе (ФЗӨ). Берәр төрле техникум. Бернична ел эшчеләр арасында һәм хәрби хезмәт. Аннары сугыш...



Әдәбиятыбез аксакалы Сафа Сабир улы Сабиров (Нәзыйров) та шул юлны үтә. 1915 елның 19 августында хәзерге Татарстан Республикасының Питрәч районы Искейорт авылында дөньяга килә. Октябрь түнтәрелеше, Ватандашлар сугышы илнең астын өскә китереп, давыллап узып китә. Дүрт яшендә әтисез, унбер яшендә әнисез калып, 14 яшенә кадәр балалар йортында тәрбияләнә. Чүплек базларына, урамнарга сибелгән ятим-ятимәләрне жыеп тәрбия итү өчен ачылган бу йортлар Совет властеның иң игелекле эшләреннән берсе булгандыр мөгаен. Меңләгән яшьтәшләренең уртак язмышын кичергән Сафа абый үз заманының баласы буларак яңа дәүләткә, әлбәттә, мең рәхмәтледер.

Совет власте аны тимерь юлчылар мәктәбендә укытып, паровозчы-слесарь һөнәре һәм жидееллык белем бирә. Әти-әнисез, ятим үскән малай өчен инде бу бик югары белем баскычы була. Әмма ана укуны тагын да дәвам итәргә язган икән. Бер ел туган ягында Тауиле мәктәбендә балалар укытканнан соң, булачак язучы 1934 елда атаклы Казан елга техникумына килеп керә. Биредә ул беренче мәртәбә кулына каләм ала. Әдәбият түгәрәгенә житәкчелек итә. 1938 елда укуын тәмамлап, Иделдә пароход капитаны ярдәмчесе булып эшли генә башлый, хәрби хезмәткә чакырыла. Шул елның сентябреннән 1946 елның августына кадәр - сигез ел буена ул Ерак Көнчыгышта - Хәрби диңгез флотында.

Сугыш елларында безнең дистәләгән язучыбызның язмышы Ерак Көнчыгыш белән бәйләнгән.

Салих Баттал, Локман Бадыйкшан, Әдип Маликов, Әбрар Кәримуллин, Габдулла Шәрәфи, Гиз-эл Габид, Ислам Беляев. Аларның һәрберсенең ижатында бу ерак төбәк үз урынын алган. Хикәяләр, повестьлар һәм шигырь, поэмалар ижат ителгән. Локман Бадыйкшанның «Мөртәт» романындагы вакыйгалар тулысынча шунда бара.

Татар телендә флот гәзитәсе чыгу да юкка гына булмагандыр. Инде каләм жене кагылган Сафа абый Ерак Көнчыгыш край органы булган «Красное знамя» газетасы каршындагы әдәби түгәрәктә йөри. Ике телдә дә мәкаләләр, хикәяләр яза. Хәрби диңгезчеләр тормышыннан дәвамлы-дәвамлы очерклар бастыра.

Моннан 55 ел элек - 1945 елда аның өч хикәясе «Казан кызы», «Мистер тавык», «Карт эшче» «Казан утлары» (ул чакта «Совет әдәбияты») журналында басылып чыга. Әнә шулай итеп, аның әдәби язмышы рухи мәркәзебез Казан белән тоташа.

Хәрби хезмәттән котылу белән Идел аны үзенә суырып ала. Сагынылган. Ул бит хезмәт юлын биредән башлаган иде. Яңа үзгәрешләр башлана. Куйбышев гидростанциясе... Казан елга порты төзелә... Атаклы «Маркиз» утравы су астында кала. Ун ел буена диңгезче Сафа белән язучы Сафа тарткалашалар. Дөрес, алар үзара сугышмыйлар. Бер-берсен тулыландырып яшиләр. Шуның матур нәтиҗәсе булып, «Яшь диңгезчеләр» повесте (1949) дөнья күрә. «Дүрт елга буйлап» (1950), «Зур Идел туганда» (1952), «Ике хикәя» (1953) китаплары басылып чыга.

Ниһаять, ул, батырчылык итеп, тулысынча язу эшенә алына. 1957 елдан 1975 елга кадәр (пенсиягә чыкканчы) Татарстан китап нәшриятында эшли. Бүлек мөдире. Әмма аның ижатының төп каһарманнары булып кырыс холыклы диңгезчеләр кала. Ул

аларны белә, ярата. Кыскасы, аларның эчке дөньяларында судагы балык кебек «йөзә». Шуңадыр да аның хикәяләренә, повестьларына документальлек хас. Бу үзенчәлеге аның иҗатын ышандыру көче белән баета.

Сафа абый бик төгәл, пөхтә кеше. Балалар йортында тәрбияләнгәндер дә димәссең дә... Бәлки уку еллары аны шулай үстергәндер. Ни дисәң дә, тимерь юлчы һөнәре дә гаять төгәллекне таләп итә бит. Бәлки аны хәрби хезмәт (ни дисәң дә 8 ел!) шулай тәрбияләгәндер.

— Бәлки шулайдыр, Сафа агай, — дип сорау бирәм аңа...

— Бәлки шулайдыр, - ди ул, салмак кына уйланып. - Аннары бит әле шунысы да бар, бөтен Совет иле татардан гына тора сымак иде. Владивостокка бар - тоташ татар гаиләләре... Аяк сөртеп, сәлам биреп керәсең, син үз кеше. Иге-чиге юк урман, иге-чиге юк ил - кая барма, үзебезнең халык. Хәзер кая микән алар?.. Алар түгел, хәзер үзебезнең Казанда да юк инде андый гаиләләр. Мин Казан елга портында эшләгәндә (1945 - 1954) татары урысча, урысы татарча белеп бергә яшиләр иде. Кинәт кистеләр дә куйдылар. Каршы килеп кара. Башың бетәр!

Сафа абый төгәл, пөхтә кеше, дидем. Бу сыйфаты аның Татарстан китап нәшриятыннан пенсиягә китеп, музей төзегәндә дә күренде. Кысан гына, китапханә бүлмәсендә булуына карамастан, бу музей үзенең байлыгы, тарихи эзлекле тәртибе белән Дәүләт музееның кайбер бүлекләре белән ярыша ала. Ә бәлки аны чынлап та таралып, чәчелеп бетмәсен өчен шунда күчерергә кирәктер. Татарстан китап нәшриятының соңгы 10-15 ел эчендәге казанышларын гына өстисе ләбаса.

Өлкән язучыбыз белән мин 1969 елдан аралаша башладым. Көннәрдән бер көнне — Бауман урамының икенче катында урнашкан Язучылар союзы тирәсеннән узып барганда, Равил Фәйзуллин очрый. Хәл-әхвәл алышабыз.

- Әйдә, бер җилләнеп, өлкәннәр белән аралашып кайт әле, - ди бу.

Түбән Камада язучылар, рәссамнәр, композиторлар белән, иҗат оешмаларының өлкә комитеты семинары үткәрелә икән. Элек шундый аралашу мөмкинлекләре тудырыла иде. Кунакханәгә Кама буендагы ял йортына урнаштыру мөмкинлеге бар, диделәр. Сафа абый җитәкчелегендәге бер төркем без шуны сайладык. Яз көне су күтәрелгәндә ярга кертеп калдырылган, бик зәвык белән җиһазланган пароход иде бу. Төркем-төркем гапләшеп утырырга салон ашханәсе дә бар. Без үзеннән-үзе бер төркемгә берләштек. Мирсәй Әмир, Хөснул Вәлиуллин, Галимҗан Латыйп, Сафа абый һәм мин. Мирсәй ага шигырьләр ярата икән. Ярата гына түгел, һәр якты, һәр җылы очкынны тоеп ала. Тынлый-тынлый да йә сабыйларча сөенә, йә аксакалларча тирән уйга кала. Кайчакта чын күңелдән борчылып: «Барып чыкмаган бу» - дип куя. Шундый шигырь кичәләренең берсендә ул әйтә куйды:

- Кара әле, Сафа, резервтан булса да, бер мөмкинлек табып, бу шагыйрь егеткә бер игелек эшлик әле. Кош теледәй генә җыентыгын чыгарсак, калганын үзе карар иде. Суга ыргытсаң, йөзәр сыман бу, ә, - дип моңсу гына елмаеп куйды.

- Бездә аның кульязмасы да бар, - дип куйды Сафа абый.

Мин гаҗәпләнеп аңа карадым. Хәл болай булган икән. Берничә ел элек, мин әле урта мәктәптә укыганда, Чаллы әдәби берләшмәсенә Казаннан чакыру хаты килде. Анда миңа, район газетасында, «Яшь ленинчы»да, «Ялкын»да чыккан шигырьләремне җыеп һәм яңаларын да алып Язучылар союзына килергә әйтелгән. Һәм «Әдәби консультант: Абдулла Гомәр», дип куелган иде. Казанга баргач, мине шагыйрь Зыя Мансурның өенә җибәрделәр. Зыя абый бик нык авырый иде инде. Шулай да ул минем белән ял итә-итә көне буе утырды. Дистәләгән шигырьләрне әр-яңадан эшләтте, күчертте. Шигырьләремне яшь шагыйрьләрнең «Дуслык» китабына әзерли икән. 700 юл шигыремне алып калды. Кайткач та мин аңа тагын утызлап шигырь өстәп җибәрдем. Ул китапны мин бик зарыгып көттем. Китап чыкты. Минем шигырьләр генә юк иде. Озакламый Зыя ага да дөньядан китеп барды. Ул чакта инде мин Казанда идем. Ул минем, монда күченеп килгәч, соңгы юлга озаткан беренче шагыйрем иде. Сафа абый шул кульязмалар хакында әйтә икән. Димәк, югалтмаганнар. Зыя ага аларны тапшырган. Сөенеп куйдым.

Сүз шуның белән тәмамланды. Семинар да тәгәлләнде. Мин дә мәктәбемә укытырга кайтып киттем. «Учак урыннары» дип папка тышына ат башы кадәр хәрефләр белән язып куйдым да китап әзерләргә керештем.

Көз үтте. Кыш үтте. Шаулап язлар килде дә җәйгә кердек. Ниһаять, мин дә култык астына «Учак урыннары» китабының саллы гына кульязмасын кыстырып килеп, «Матур әдәбият» редакциясе мөдире: «Сафа Сабиров» дип язылган күн белән тышланган ишекне шакыдым. Хуҗа мине күптәнге танышы кебек, тиң күреп, колач җәеп каршылады. Эчемә җылы кереп китте.

- Менә, Сафа абый, китап төзеп китергән идем, - дидем.

- Вот, шагыйрьләр дают! - дип көлә ул. - Әле беренче китабы сатуга чыгып та

житмәгән, инде икенчесен күтәреп килеп тә житкән. Бар, авторский 10 китабынны Сәлимә апаннан кереп ал!

Мин берни дә аңламыйча, ул әйткән Сәлимә апага кереп киттем. Мина беренче «Кыңгырау» исемле китабымны бирделәр. Исемне дә тапканнар! Нәрсә аңлата инде ул кыңгырау. Шулай да сөенеч бит. Кинәт кенә Мирсәй аганың сүзләре искә төште: «Кош теледәй генә!» Чыннан да, кош теле дисә дә кош теле. Юка гына. Шулай да үземнеке!

Димәк, теге вакытта Кама буендагы пароход салонында Мирсәй ага әйткәнне Сафа абый күнеленә салып куйган. Онытмаган. Сигез ай гына узды бит әле.

Сафа абый «Учак урыннары» кульязмасын үлчәгәндәй кулында тотып торды да:

- Теге юлы Зыя абыенның бәясе мәсьәләне хәл итте. Бу юлы үзең теләгән олы шагыйрьгә эчке рецензиягә бирик. Сүзе үтәрлек булсын. Кемгә?

- Йә Хәсән ага Туфанга, йә Сибгат ага Хәкимгә...

- Хо-хо-хо! Курыкмыйсынмы? Алар кире фикер әйтсә, бөтенләйгә юлың ябыла. Матри!

- Мин аларга да, үземә дә ышанам, - дидем.

Менә шулай ачыктан-ачык, егетләрчә сөйләшүе белән кадерле дә ул безгә, Сафа абый.

Сафа абый Сабиров үз заманының баласы. Аны Совет власте тәрбияләп үстергән. Ул ана намуслы хезмәт иткән. 70 ел мәйдан тоткан ул Властьны мактарга мөмкин, яманларга мөмкин. Әмма ул безнең тарих. Ә Сафа абыебыз аның «аяклы тарих»ы. Аяклы тарихларыбызның кадерләрен белү бик кирәк. Бик тә кирәк.

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМ**
*2000.*

# *Укучы сүзе*

* * *

Хөрмәтле редакция!

Сезгә Мәскәүдәге укучыларыгызның берсе яза. Журналыгызны 1988 елдан бирле алып торам, тик бик ошатып бетерми идем—консервативрак, провинциаль рухлы зәгыйфь әсәрләр байтак иде аның битләрендә. Үз телемне онытмас өчен генә язылa идем инде. Берничә ел алмый да тордым.

Соңгы елларда журнал күзгә күренеп үзгәрде. Былтыргы саннар иң зур бәягә лаек. Иң ошаганы Н. Әхмәдиевнең «Амбирак яки кара каен кайгысы» булды. Шулай сөйләшүчеләрне бер тапкыр метрода да очраткан идем. Үзбәкләр ахрысы дип уйлаган идем, алар безнең кешеләр булган икән.

Журналның быелгы ике санын да укып чыктым инде. Шундый уңышларыгыз фонында аянычлы хаталар жибәреп тагын үзәкне өзәсез бит. Менә беренче санда Р. Фәйзуллин «тинейджер—компьютер жанлы кешеләр» дип язган. Инглиз телендә *ten*—ун, *age*—яшь дигән сүз. 13-19 яшьлек үсмерләрне шулай диләр. Компьютер кыстырырлык урын юк монда. Житди, программалы мәкаләдә шундый хата бигрәк күзгә ташлана. *(Әйе, тинэйджер сүзе яшүсмерләр дигән сүз, әмма аны хәзер компьютерга мөкиббән киткән яшьләр төшенчәсен аңлату өчен дә еш кулланалар. Бу очракта «компьютер жанлы кешеләр» дип автор шигъри образ рәвешендә нәкъ шундый даирәне күздә тота да инде. Редакция искәрмәсе).*

Шул ук санда (168 бит) бик кызык, тирән фикерле тикшеренүдә («Идегәй» дастаны турында) *неосфера* дип язылган. Ә бит *нео*—яңа дигән сүз. Монда *ноосфера*, ягъни акыл сферасы булырга тиеш иде. Аннары Вернадскийга хәтле беренче булып ул турыда француз рухание һәм археологы Тейяр де Шарден язган.

Редакциягә журналның сыйфатын тагын да югарырак күтәрүдә уңышлар теләп калам.

**НАСРЕТДИНОВ И. К.**
**Мәскәү.**

## *Salix Battalnıŋ tuuına 95 yıl*

**Salix Battal**

### Tuğan yağıma

Aqsa ineş çıltırap yə
buılıp, dulqınlanıp;
niçek ütsə də ğəmerem—
şatlanıp, yə moŋlanıp,

bezneŋ ineş suı kəmeş
İdelgə quşılıp kitə,
minem ğəmer də gəreldəp
ilemə quşılıp kitə.

Ləkin nigəder küŋelgə
bik yaqın tuğan yağım.
Tuğan yaq ber genə şul ul,
ikençese yuq anıŋ.

Nığraq tarta bara ul
min yıraq kitkən sayın;
yaratuım da kəçəyə
ğəmerem ütkən sayın.

Küktə oçsam hər bolıtta
ineş tamçısın ezlim;
cirdə yərsəm hər adımda
sineŋ yazmışnı küzlim.

### Qar qatlamnarı

Tışta, əyneŋ işek qırında
ber kvadrat metr urında
qatlam artı qatlam eri qar.
Hər qatlamnıŋ ayırım sere bar.

* * *

Yazğı qoyaş kəlep qaradı:
eregən qar əste qaraldı.
Zavod qorımın da, kəlen də
kürdem şunda işek təbendə.
Direktornı kürşe zavodnıŋ
uylap, şunda beraz mawıqtım.

* * *

İrtəgesen irtə torğaç ta
yərdəm qulın suzdım qoyaşqa:
seberep attım qorım qatlamın,—
yaᶇa ezlər kürə başladım.
İskə təşte nəni botinka:
anı kiep yəri Katen'ka.
Kün buqçası anıᶇ qulında—
berençe qış məktəp yulında.

* * *

Kənnər ütte, qatlam erede;
kiᶇ, suzınqı ber ez kürende—
avto təgərməçe sırlağan.
Kürep qalğan idek ber zaman—
gər-gər itep dəw ber maşina
tuqtap tordı işek qarşında.
Əү cihazı aᶇar təүəlde.
Həm ul yaᶇa yortqa yünəlde:
zur semyalı beznen kürşelər
irken toraqlarğa küçtelər.

* * *

Menə soᶇğı qatlam erede.—
Ul iᶇ elek yawğan qar ide.
Tabıp aldım zur ber sədəpne.
Xəterlədem: tənge səğətne
ber qız tordı şunda yılışıp,
səүgənenen qulın yılıtıp,
quyıp yərəgenen əstenə,
kükrəgenə—pal'to eçenə.
Pal'tosınnan tege sədəp tə
əzelgənder şuşı səğəttə.
Ə üzlərə inde qawışqan—
bügen qayttı alar zagstan.
Min alarnı qotlap baş ordım
həm sədəpne qızğa tapşırdım.

* * *

Qar erede. Citə inde maү.
Poeziəgə ilem şundıү baү!—
yazıp beterep bulmıү şiğerdə
ber kvadrat metr ciren də...

*Безнең календарь*

## Халикъ Садриның тууына 110 ел

Габделхаликъ Гариф улы Садретдинов 1890 елның 4 августында Самара губернасының Богырыслан өязе (хәзерге Куйбышев өлкәсенең Келәүле районы) Иске Ярмәк авылында бик ярлы кеше гаиләсендә дөньяга килә. Яшьли ятим калып, чит кешеләр кулында тәрбияләнә. Башта авылда, аннан соң Уфа, Баку, Самара, Оренбург шәһәрләрендәге предприятиеләрдә, нефть промыселларында эшли.

Февраль революциясе вакытында Халикъ Садри, большевиклар ягында торып, революцион көрәш хәрәкәтендә катнаша. Октябрь көннәрендә Самара шәһәрендә Совет властен урнаштыру өчен һәм Идел буенда акгвардиячеләргә каршы сугышларда катнаша.

1925 - 1928 елларда ул Казанда татар коммунистлары университетында укый. Аны тәмамлагач, озак еллар Казанның «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында һәм башка промышленность предприятиеләрендә җитәкче урыннарда эшли. Бу чорда ул уйлап табу һәм хезмәтне рационализацияләштерү өлкәсендә эшли, шул мәсьәләләр буенча фәнни-популяр характердагы дистәгә якын брошюра язып бастыра.

Бөек Ватан сугышы елларында Халикъ Садри, полк хәрби комиссары буларак, фронтның алгы сызыгында сугыша. Батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Халикъ Садри СССР Әдәби фондының Татарстан Язучылар берлегендәге вәкиле булып эшли.

Халикъ Садриның әдәби иҗат эше Октябрь революциясенә кадәр үк башлана. 1913 елда Уфа матбугатында аның «Тегермәндә» исемле беренче хикәясе басыла. Иҗатының башлангыч чорында шигырьләр, сәхнә әсәрләре, очерк һәм хикәяләр яза. 1919 елда иҗат ителгән «Унике ел төрмәдә» исемле пьесасы шул елларда сәхнәләрдә куела.

Утызынчы елларда Халикъ Садри «Ил батырлары», «Тимерче малае», «Безнең таң» исемле повестьларын яза. Әсәрләрнең сюжетлары язучының үзе кичергән вакыйгаларга нигезләнгән, аларда авыл крестьяннары, эшчеләр тормышы сурәтләнә.

Илленче елларда «Йөзмә госпитальдә» исемле очерк-хикәясе, драматург Әнәс Камал белән бергә «Юллар» дигән сәхнә әсәре, курчак театрлары өчен язган «Камал бабай әкияте» пьесалары дөнья күрә.

Халикъ Садри 1955 елның 8 мартында Казан шәһәрендә вафат булды.

Ул 1939 елдан Язучылар берлеге әгъзасы иде.

## Мөхәммәт Әблиевнең тууына 100 ел

Мөхәммәт Шәриф улы Әблиев 1900 елның 15 июлендә Казан губернасындагы Даныш авылында (хәзерге Кама Тамагы районы) крестьян гаиләсендә туа. 1915 елда Казанга килеп төрле эшләрдә эшләп көн күрә. 1920-21 елларда партия мәктәбендә укып белем ала. Туку фабрикасында яшьләр арасында уку-тәрбия эшләре алып бара. 1922 елда Урта Азияне басмачылардан азат итү хәрәкәтләрендә катнаша. Бөек Ватан сугышы башланганчы төрле өлкәләрдә хәрби һәм партия хезмәткәре вазифаларын башкара, сугышка алынып, анда һәлак була.

Язучы буларак М. Әблиев иҗатын «Минем дустым сугышта» исемле хикәя, «Ком улы», «Итекче кызы» повестьлары белән башлап җибәрә. Каләмен драматургиядә дә сынап карарга тели һәм «Шәмсекамәр» пьесасын иҗат итә. 1938 елларда Татар дәүләт академия театрында зур уңыш казанган бу пьеса, соңыннан аерым китап булып та дөнья күрә.

Ул 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

## Малик Хәмитовның тууына 70 ел

Алтмышынчы — җитмешенче елларда очерк жанрында актив эшләгән Малик Хәмитов (Габделмалик Әхмәдулла улы Хәмитов) 1930 елның 22 августында Татарстан АССРның Яшел Үзән районы Күгәй авылында игенче гаиләсендә туа. 1948 елда Норлат урта мәктәбен һәм 1952 елда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.

Университетта укыганда ук вакытлы матбугатта очерклары, рецензияләре белән катнаша. 1952 — 1955 елларда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында әдәби хезмәткәр, соңрак Татарстан радиокомитетында хәбәрче һәм Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. 1956 елдан алып 1978 елга кадәр ул «Казан утлары» журналы редакциясенең очерк һәм публицистика бүлегенә җитәкчелек итә. М. Хәмитов укучыларга көндәлек матбугатта басылган күпсанлы очерклары, публицистик язмалары һәм Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып чыккан «Гүзәл җимешләр», «Ышану», «Күтәрелештә», «Егетлек» исемле җыентыклары белән таныш. Күбесе авыл темасына багышланган бу очеркларда шул заманның колхоз тормышы, аның алдынгы кешеләре, җитәкче кадрлары сурәтләнә, авыл кешеләрен борчыган актуаль мәсьәләләр күтәрелә.

Иҗат эшчәнлегенең соңгы елларында әдип, тематик диапазонын киңәйтә барып, фән һәм техника кешеләре, галимнәр, сугыш ветераннары турында да кызыклы гына очерклар язды. М. Хәмитов 1983 елның 17 июлендә Казанда вафат булды.

Ул 1966 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

*Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## БӨТЕНРОССИЯ ЖУРНАЛИСТЛАРЫ БӘЙРӘМЕ

21-24 июнь көннәрендә «Бөтенроссия-2000» дип исемләнгән гаммәви мәгълүмат чаралары фестивале булып үтте. Бу бәйрәмгә төрле республикалар һәм өлкәләрдән 700 дән артык кунак килгән иде.

Фестиваль кысаларында «Русия матбугаты энциклопедиясе», «Төрки-славян тарихи-мәдәни мөнәсәбәтләре: үткәне, бүгенгесе, киләчәге», «Гасырлар алышынганда Русиядә мәгълүмат иреге», «Журналистның җәмгыять алдындагы җаваплылыгы» дигән темаларга багышланган сөйләшүләр булды.

Бауман урамындагы «Матбугат дөньясы» бәйрәме дә кунаклар күңелендә соклану уятты. Әлеге күргәзмә-ярминкәдә югары сыйфатлы басмалар,шул исәптән безнең «Казан утлары» журналы да халыкка тәкъдим ителде.

Казанда журналистлар йортын ачу үзе бер мәгънәле зур вакыйга булды. Региональ телерадиокомпанияләр вәкилләре Азнакайда махсус программа буенча фестиваль үткәрделәр.

Фестивальгә җыелган кунакларга М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты күрсәтелде.

Русия журналистлары Казан Сабан туен да күреп киттеләр.

## СУВЕРЕНИТЕТНЫҢ 10 ЕЛЛЫГЫНА

13 июльдә Татарстан Республикасының Язучылар берлегендә Иҗат берлекләренең координацион советы утырышы булды. Анда сүз Татарстанның суверенитеты турындагы Декларацияне кабул итүгә 10 ел тулу алдыннан Иҗат берлекләренең мөстәкыйльлек шартларында мәдәният үсешенә багышланган уртак пленумын үткәрү турында барды.

Әлеге утырышта чыгыш ясаган Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин, Рәссамнар берлеге рәисе Абрек Абзгильдин, Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова һәм башкалар соңгы елларда республикада милли традицияләрне, Татарстан халыкларының телен һәм мәдәниятен торгызуда һәм үстерүдә алга китеш булуын ассызыкладылар. Суверенитет - кабинетларда уйлап чыгарылган төшенчә түгел, ул - Татарстанның Югары Советында законлы нигездә хәл ителгән халык ихтыяры. Бүген аңа нинди генә бәяләмә бирелсә дә, ул - тарихыбызның бер өлеше, халкыбыз тормышының бер өлеше.

## ОНЫТЫЛМАС ОЧРАШУ

21 июньдә Татарстан язучылары йортында дөньякүләм мәшһүр язучылар Чыңгыз Айтматов һәм Олжас Сөләйманов белән очрашу узды. Алар Татарстанга «Бөтенроссия — 2000» журналистлар фестивале уңае белән килгәннәр иде. «Түгәрәк өстәл» әңгәмәсендә олуг әдипләр белән Татарстан ягыннан Равил Фәйзуллин, Миркасыйм Госманов, Фоат Галимуллин, Әхмәт Рәшитов, Әхәт Гаффар чыгыш ясадылар. Кырыкка якын язучы һәм журналист катнашкан бу очрашуда дөньяда һәм Россиядәге сәяси вәзгыять, бүгенге көн әдәбияты, төрки халыклар арасындагы тарихи бәйләнеш, латин имласына күчү мәсьәләсе, һәм гомумән, мондый аралашуларның әһәмияте турында җитди сүз булды.

## МАНСУР ХӘСӘНОВКА - 70 ЯШЬ

«Республика өчен бу — күренекле вакыйга». Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев зур дәүләт эшлеклесе, академик, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов эшчәнлеген 26 июньдә булган тантаналы җыелышта менә шулай бәяләде.

«Гасыр тәмамланып килә, йомгаклар ясала. Әмма республиканың күренекле кешеләре, фән һәм җәмгать эшлеклеләре исемлегендәге беренче урыннарның берсендә Мансур Хәсән улы Хәсәнов исеме торачак. Аның 40 елдан артыкка сузылган хезмәте, аның характеры, сәләте, карашлары аркасында халкыбызның рухи тормышы хәзерге югары дәрәҗәдә тора. Әгәр Мансур Хәсәнович булмаса, ихтимал, Татарстан Фәннәр академиясе барлыкка килмәс иде. Нәкъ менә Сез аңа нигез салучы булып торасыз,- дип белдерде Минтимер Шәймиев, юбилярга мөрәҗәгать итеп. - Сездән башка Татар энциклопедиясе институты да булмас иде», диде Президент. Ул М. Хәсәновка Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә IV дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» орденын тапшырды.

Тантаналы утырышта Татарстан Министрлар Кабинеты вәкилләре Татарстан Дәүләт Советы әгъзалары, республика шәһәр һәм районнары башлыклары, вузлар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, предприятие һәм оешмалар җитәкчеләре катнашты.

## ТАТАРСТАН ОСТАЛАРЫНА - ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕ

Татарстан Республикасы Зур концерт залының интерьерын үзгәртеп эшләү проекты Русия Федерациясенең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Проект Казанның архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы урынбасары В. Логинов, Казан дәүләт төзелеш академиясенен кафедра мөдире Е. Прокофьев һәм Казан дәүләт консерваториясе ректоры Р. Абдуллин тарафыннан эшләнде.

## БЕЛАРУСЬ ИЛЕНДӘ САБАНТУЙ

2-3 июньдә Беларусьның Гродно шәһәрендә III Бөтенбеларусь милли мәдәниятләр фестивале үткәрелде. Анда беларусь, урыс, татар, молдован, азәрбәйҗан, әрмән, яһүд, литва һ.б. күп кенә милләт вәкилләре җыйналган иде.

Минск шәһәрендә өченче ел инде «Чишмә» дип аталган татар-башкорт халкының рухи мирасын үстерүгә хезмәт итүче мәдәни фонд эшләп килә. Фондның президенты — Иран Исхак улы Богданов. Аның активлыгы һәм тырышлыгы белән Гродно шәһәрендә беренче тапкыр татар Сабан туе үткәрелде. Әлеге фестивальдә һәм Сабан туенда «Чишмә»нең утызлап вәкиле чыгыш ясады.

Татарстан Мәдәният министрлыгы булышлыгы белән фестивальдә «Идел» журналының баш мөхәррире Рашат Низамиев, Татарстанның халык артисты Искәндәр Биктаһиров, Татарстанның атказанган артисты биюче Ләйсән Хәмитова да катнашты. Артистларыбыз фестивальнең мактаулы дипломына лаек булды.

***

Татарстан Язучылар оешмасының берлеккә кабул итү коллегиясенең (рәисе - Равил Фәйзуллин) чираттагы утырышы булды. Анда соңгы дистә еллар эчендә монарчы Берлеккә кабул ителмичә яткан 52 авторның иҗади эшләре тикшерелде, иң лаеклылары сайлап алынды. 2 июльдә Язучылар берлеге идарәсе коллегия тәкъдим иткән өч авторны — Азнакайдан шагыйрь Энәс Исхаков, Актаныштан прозаик Әмирҗан Моталлапов, Казаннан әдәби-документаль китаплар авторы Рәмзи Иляловларны Татарстан Язучылар берлегенә кабул итте.

## МӘСКӘҮДӘ ШИГЫРЬ КИЧӘСЕ

Татарстанның Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиллегендә шагыйрә һәм тәрҗемәче Венера Вәлиеваның (академик Камил Вәлиевнең җәмәгате) иҗат кичәсе булды. Анда Дәрдмәнд, Тукай, Җәлил, Туфан шигырьләре һәм бүгенге күн авторлары әсәрләре яңгырады. Соңыннан шагыйрә үзенең әсәрләрен укыды.

## ОНЫТЫЛМАС ЯЗУЧЫ

Быел мәшһүр әдип, Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевкә 70 яшь тулган булыр иде. Инде дүрт ел арабызда үзе булмаса да, аның әсәрләре, гыйльми эшләре яши, иҗаты милләт күңелендә.

5 июль көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында әдипне искә алу кичәсе булды. Аны Татарстан Язучылар берлеге һәм Мәдәният министрлыгы оештырды. Олуг язучының иҗаты турында доклад белән ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыкты.

Кичәдә Мөхәммәт Мәһдиевнең якташлары, туганнары, каләмдәшләре, укучылары, артистлар катнашты.

6 июль көнне туган авылы Гөберчәктә язучы истәлегенә музей-йорт ачылды.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

***

Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында күренекле шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Роберт Әхмәтҗановның иҗат кичәсе булып узды. Әлеге бәйрәм шагыйрьгә 65 яшь тулу уңае белән оештырылган иде.

***

4 июль көнне Казан шәһәренең «УНИКС» концертлар залында 50 яшьлек юбилее уңаеннан язучы-сатирик Камил Кәримовнең иҗат кичәсе үткәрелде.

## ДЕРЖАВИН ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ

Мәгълүм булганча, рус поэзиясенә нигез салучыларның берсе — безнең якташыбыз Г. Р. Державин (1743 - 1816). Лаеш районы хакимияте һәм Татарстан язучылар берлеге (шагыйрь Лаеш районының Сокуры авылында туган) Державин исемендәге премия булдырды. Язучылардан бу премиянең беренче лауреаты — Казанда яшәүче рус язучысы Владимир Корчагин булды.

## ГАМИЛ АФЗАЛ УРАМЫ

Әлмәт шәһәрендәге Агропоселок дип аталган бистәнең яңа төзелгән урамнарының берсенә Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гамил Афзал исеме бирелде.

***

Казанның Азино бистәсендәге яңа урамга Татарстанның халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Х. Бигичев исеме бирелде.

Хәйдәр Бигичев урамыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә үтә торган урам татар композиторы, Татарстан Республикасы халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Җәүдәт Фәйзи исеме белән йөртеләчәк.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# КИЧ КОЛАЧЛЫ ИҖАТЧЫ

Шамил Шәйдуллин милли башлангычларны, халыкчан рухи халәтне, татар бизәү сәнгате алымнарын оста кулланып иҗат итүче рәссамнардан. Аның рәсемнәрендә татар сынлы сәнгатенә аеруча хас авыл темасы дөньяви әһәмияткә ия булып яңгырый башлый. Тарихи бөтенлеген, миллилеген югалтмаган авыл — рәссам күзаллавынча — иҗтимагый һәм экологик бәла -казалардан коткаручы дәва да, рухи байлык һәм тотрыклылык чыганагы да («Шомырт җыю», «Печәннән кайту», «Сабантуй», «Асыл ил»). Ул әсәрләрдә, һәм, гомумән, рәссам иҗатында хакимлек итүче сәнгати фаразлар, эстетик һәм әхлакый канунният чагылышы сәнгаткярнең иҗатына кабатланмас төсмер бирәләр.

Ш. Шәйдуллин сынлы сәнгатебезне якты төсләр һәм зур күләмле милли образлар, фәлсәфи уйланулар, лирик хисләр белән баетты. Хәзер аның иҗаты Татарстанда гына түгел, чит илләрнең сәнгать сөючеләренә яхшы ук таныш.


Рәссамның өзлексез эзләнүләре, капма-каршы төсләрне тетрәндергеч рәвештә куллана белүе, метафорик уйлау сәләте, язу осталыгы, әсәр төзелеше өлкәсендәге кыю тәҗрибәләре, рухи күтәренкелеге аны постмодернизм сәнгатенең иң талантлы рәссамнары рәтенә куя («Икмәк турында баллада», «Ульяновлар»).

Ш. Шәйдуллин, күпсанлы пейзаж, натюрморт, картиналар иҗат итү белән бергә, кешенең күңел дөньясына үтеп керә алган портрет остасы, картинаның төзелеш-композициясен новаторларча күзаллаучы буларак та киң танылды. Соңгы елларда рәссам милли тарихи темага актив эшли. Бу үзенчәлек «Сөембикә - Казан ханлыгының соңгы патшабикәсе» дигән зур күләмле әсәрдә *(тышлыкның беренче битендә)* ачык чагыла. Бу әсәр урыс һәм татар сәнгате казанышлары - палех һәм татар шәмаилләре, көнчыгыш миниатюра жанры алымнары бергә үрелгән катлаулы сюжеты, төсләр уены, зур колачлы панорамасы белән таң калдыра.

Соңгы елларда иҗат иткән «Яңа Сабантуй» исемле күп өлештән торган картиналар циклы җәмәгатьчелекне аеруча сокландырды. Әлеге хезмәтләре өчен Шамил Шәйдуллин быел Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Данил Салихов.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Атлас истории Татарстана и Татарского народа. - Казань — Москва: ДИК нәшр., 1999. — 65 бит. Тиражы — 15300 данә.

Казанның бер төркем галимнәре (Р. Фәхретдинов, Б. Солтанбәков, П. Старостин, С. Суслова, Р. Хәкимов, А. Астайкин, М. Әхмәтҗанов) Мәскәү картографлары белән берлектә тарихыбызда беренче тапкыр буларак уникаль басма әзерләделәр.

Бу китап-атласның фәнни җитәкче һәм җаваплы мөхәррире — тарих фәннәре докторы, археолог Равил Фәхретдинов. Күп санлы төсле карта-рәсемнәр белән баетылган, һәр тарихи чор хакында кыскасы, әмма тирән эчтәлекле язмалар белән тулыландырылган, халкыбызның борынгы дәверләрдән алып, бүгенге көннәргә кадәр сузылган, озын, тирән һәм гаҗәеп бай тарихын эченә алган бу басма Татарстан мәгариф министрлыгы тарафыннан мәктәпләргә тәкъдим ителә. Бу басма төрки дөньяның, татар халкының һәм Татарстанның озын-озак юллар үткән бөек тарихы белән кызыксынучы һәркемнең игътибарын җәлеп итәр дип ышанабыз.

Индекс 73210



Данил Салихов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)